ФОАТ
САДРИЕВ

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

Өченче китап

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84 (2 Рос=Тат)-44
С15

**Садриев Ф.М.**

С15 Бәхетсезләр бәхете: роман / Фоат Садриев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 366 б. — 3000 д.

ISBN 978-5-298-01535-6

Бу — «Бәхетсезләр бәхете» романының өченче китабы. Әсәрдә гаделлек белән икейөзлелек, пакьлек белән бозыклык, бәхет белән кайгы-хәсрәтнең капма-каршылыгы гыйбрәтле вакыйгалар мисалында ышандырырлык итеп тасвирлана.

ISBN 978-5-298-01535-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Садриев Ф.М., 2007

# Беренче кисәк

## 1

Ирек кузгала алмыйча, чит кеше кебек ишек төбендә басып тора бирде. Рашатның көлүе аның бөтен тәнен эсселесуыклы итте, бала йоннарын кабартты, тезләрен калтыратты. Әйтерсең лә өстенә һавадан көчле өермә килеп төште дә аны, аунаклата-аунаклата, яфрак кебек каядыр очыртып алып китте. Рашат көлүдән туктагач, Ирек бераз аңына килгәндәй булды. Беренче уе «Бу аның өрәге түгелме икән?» дигән сорау булды. Юк, бу өрәк түгел иде. Шул ук вакытта бу элеккеге җиңел холыклы, бер минут эчендә әллә ничә төрле халәткә керә торган дуамал Рашат та түгел иде бугай. Аның күзләрендә, йөзендә нindидер авырлык сизелә, ул нәрсә кургаш кебек бөтен гәүдәсенә кунган. Рашатның өстендә чем-кара кыйммәтле костюм-чалбар, кофе төсендәге күлмәк, муенында куе зәңгәр галстук, аякларында елкылдап торган шундый ук кара төстәге затлы туфлиләр. Диванга салып куйган куе зәңгәр плащы, кара эшләпәсе дә өр-яңа, тузанмазар кунмаган, бүген генә кибеттән алгандай иде.

— Нәрсә ишек катына ябышып каттың? — диде Рашат, боздай салкын тавыш белән. — Аңлыйм, аңлыйм, син бит инде мине күптән күмгән идең. — Ул тагын хихылдап көлеп куйды. — Әйе, үлгән идем, рәхәт түгел анда. Тоттым да җир астыннан чыктым. Ник әле сез монда йөргәндә мин анда череп ятарга тиеш?! — Рашат костюмының күкрәк кесәсеннән алып өстәлгә коньяк утыртты. Аннары, күзләрен алартып, башын Зәнфирәгә таба борды. — Бәлкем, өстәлгә берәр нәрсә куярсыз, ханым? Безнең татар хатыннары бит бик кунакчыл була торган иде.

Ирек киемнәрен салып аның каршына килеп утырды. Зәнфирә өстәлгә ипи, киселгән тозлы кыяр куйды, икесенә дә аерым йомырка тәбәсе китерде, бер рюмка куйды.

— Бусы ни була инде?! — Рашат рюмканы эләктерде дә шапылдатып Ирекнең алдына утыртты.

— Мин бит эчмим, — диде Ирек, рюмканы кабат аның алдына куеп.

— Эчмисең?! — Рашат әллә нинди кәҗә тавышлары чыгарып кеткелдәп куйды.
— Әйе, эчмим.
— Ни булды?
— Организмыма ярамый.
— Син хитрить итмә! — диде Рашат, күзләрен ачулы уйнатып. — Минем белән эчәргә җирәнәсеңмени?
Ул җилпенеп сикереп торды да барып шкафтан бер стакан алды, коньякны башта рюмкага салды, аннары калганын стаканның күзеннән итеп тутырды.
— Әйдә, тоттык! Без бит икебез дә теге дөньяга ычкынган идек. Бу дөньяда очрашу хөрмәтенә.
Ирек рюмкасын чәкештерде дә аның эчкәнен көтеп тора башлады. Зәнфирә яшь белән тулган күзләрен мөлдерәтеп аңа төбәлде. Ул күзләрдә ни язылганын Ирек бик яхшы аңлады. Рашат башын артка ташлады да, авызын зур ачып, стаканны түнтәрде. Коньякның, зур бүрәнкәгә салган су кебек шарылдап, аның тамагыннан эченә төшеп киткәне ишетелеп торды. Кунак тирән итеп сулады да шытырдатып кыяр чәйнәргә кереште, ипи белән йомырка тәбәсе элеп капты, аннары Ирекнең алдында торган рюмкага ияге белән ымлады:
— Ә син?
— Ачуланма, булдыра алмыйм, — диде Ирек.
— Ярар, аңладым мин сине, — диде Рашат, кисәтүле тавыш белән. — Вакыт бар, барысына да өлгерербез. Әле бит башы гына. Шулаймы?
Ирек дәшмәде. Рашат сәгатенә карап алды да, күзләрен йомып, нәрсәдер уйлагандай, беркадәр торды, аннары кинәт аягын сузып җибәрде.
— Билем авырта, иелә алмыйм, ботинкаларымны салдыра алмассызмы икән? — дип, күзләрен Зәнфирәгә төбәде.
Зәнфирә агарып китте, йөзенә хурлану галәмәтләре чыкты, күзләрендә ачулы очкыннар биеште. Ул, яклау эзләгәндәй, Иреккә карап алды, ләкин Ирек берни дә кылмады, аның башын бер уй томалаган иде: Рашат нинди максат белән килгән, аның уенда нәрсә?
— Ирек дус, хатының сиңа карый бит, сиңа салдырырга куша. — Рашат уң аягын күтәреп Иреккә таба борды.
— Үз өемдә мин үзем хуҗа, монда без боерабыз. Шуңа күрә, Рашат дус, син гафу ит инде. Минем әтинең дә аяк киемен салдырганым юк.
Рашатның йөзе караңгыланып китте. Аннары ул, чыраен ачуташ капкандай җыерып, ясалма елмайды.
— Син Мәскәүдә минем квартирада яшәгәндә болай сайрамый идең. Үзгәргәнсең, нык үзгәргәнсең.
— Ә-ә-ә, аңладым тел төбеңнең кая барганын, — диде

Ирек, күңелендә ачу кузгала башлавын тоеп. — Күпме түләргә кирәк?

— Күпмеме? — Шулай диде дә Рашат тагын сәгатенә күз төшереп алды һәм, нәрсәдер тыңлагандай, күзен йомып, башын артка ташлады. Ирек бу очрашуның төш түгеллегенә һаман ышанып бетә алмады. Ничек исән калды икән соң ул? Рашат кинәт күзләрен ачты. — Түләвең шушы инде. — Ул аягын сузып селеккәләп алды.

— Без синдә яшәгән өчен аяк киеме салдырырга сөйләшмәдек бит.

— Молодец! — диде Рашат һәм шапылдатып кул чапкандай итеп куйды. — Горурлык ир кешегә бик кирәк нәрсә ул. Әгәр өеңә сыя алса. Тик монда бик тар, сыя алмый синең горурлыгың. Кайда саклана соң ул? — Аның тавышында ачыктан-ачык мыскыллау билгеләре сизелде. — Син аны токмач басарга он алып кергән кебек сарайдан көнлекләп алып керәсеңме? Әллә кесәңә тутырып йөрисеңме? Көнбагыш кебек кирәк чакта кешеләрнең йөзенә кабыгын чиертәсең, әйеме?

Ирек, инде ачуын яшерә алмас дәрәҗәгә җитсә дә, тешләрен кысты, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып, Рашатка таба иелде һәм болай диде:

— Кайда сакласам да, үземә җитә. Һәрхәлдә, синнән әҗәткә сорамам.

— Молодец! Ха-ха-ха!

Рашат көлүеннән кинәт туктады, йөзе караңгыланып, тартышып куйды. Ул, күзләрен Иректән алмаган килеш, акрын гына уң кулын костюмының эчке кесәсенә тыкты, анда нидер капшады да хәрәкәтсез калды. Кулын кесәсеннән алмаган килеш, сәер итеп иренен кыйшайтты. Бу елмаю да, мыскыллау да түгел, әллә нинди яшерен бер уйны чагылдыра иде. Аның кысылган керфекләре арасыннан елтыраучы күзләрендә ниндидер куркыныч көч шәйләнә, ул менә хәзер дөртләп кабыныр, шартлар кебек тоелды. Рашат кинәт кулын алды да беләге белән өстәлдәге әйберләрне түргә таба сыпырды, аннары, терсәген өстәлгә терәп, бармакларын бер йодрыкка төйнәде, бер җәйде:

— Әйдә, кул көрәштереп карыйк әле.

Аның шул сүзен көткәндәй, Ирек шундук үзенең учын аның учына салды. Зәнфирә, йөрәге ярылырдай булып, аларга карап тора иде. Ирек тынычлан дигән мәгънәдә аңа керфек сирпеп куйды. Менә алар кул көрәштерә башладылар. Беренче тотыну белән Ирек аның үзеннән көчле икәнлеген аңлады. Бу эшләгән, бирчәеп беткән кул түгел, әмма ифрат та саллы, көчле иде. Ирек, тешләрен кысып, кулын туры тотарга тырышты, җиңәргә омтылмады, бары тик шушылай төз

торырга кирәк иде. Аларның икесенең дә маңгайларындагы, муеннарындагы тамырлары бүртеп чыкты, кып-кызыл булдылар, еш-еш сулыш алганнары ишетелде, әмма куллары шул бер урында тора бирде. Ахырда Рашат кулын ычкындырды.

— Минем уң кул имгәнгән иде, төзәлеп җитмәгән, әйдә сулы белән, — диде ул, бармаксыз кулын өстәлгә куеп.

Бусында Ирек каршы тора алмады. Рашат аның кулын тоту белән шартлатып өстәлгә китереп салды.

— Мәскәүләр менә шулай тота, — диде ул, кимсетүле караш ташлап. — Буйсынырга өйрәнергә кирәк булыр.

Зәнфирә курку катыш ачулы күзләре белән аның һәр хәрәкәтен күзәтеп тора иде. Бу Рашатка ошамады.

— Кара әле, Ирек дус, — диде ул, зарланган булып. — Хатының күзе белән миңа атмасын әле. Өегезгә кергәннән бирле мин аның карашы астында пистолет көпшәсе алдында торган сыман торам. Ату бит ул гаҗәп нәрсә. Берәү мәңгелек йокыга тала, икенчесенә яшәү килә. Берәүгә инде берни кирәкми, икенчесенә байлык, гамьсез күңел ачулар килә. Килешәсеңме? Атарга ниятләгән кеше берни дә уйламаска тиеш.

— Синең сүзләреңне мин аңлап бетерә алмыйм.

— Аңлатам. Син Мәскәүдә торганда, үзең хакында, мин арыган, хәлсезләнгән пуля шикелле, дигән идең. Һәрбер кеше — тормыш көпшәсендәге пуля, дип тә өстәгән идең. Хәтерлисеңме?

— Әлбәттә.

— Кешенең һәр көне, бер мәртәбә тәтегә баскач, мишеньгә барып тияргә тиеш, дигәнең дә хәтердә. Менә мин дә пуля, тик арыган түгел. Очып киләм, кая барып тиям, яшәү белән үлемнең хәл ителми калганы юк әле. — Ул башын Зәнфирәгә таба борды. — Зинһар, атмагыз инде күзегездән. Мин мондый карашка күнекмәгән. Алла сакласын... Минем дә атып куюым бар. — Ул кисәк кенә көлеп җибәрде. — Күз белән диюем. — Рашат сәгатенә карады да кинәт сикереп торды: — Миңа китәргә вакыт.

Ул плащына үрелде, аның кесәсеннән калын блокнотка охшаган бер әйберне алып Иреккә сузды.

— Менә син моны укып чык әле. Мәскәүдә самиздатта чыккан китап бу. Охшаса, тәрҗемә итәрсең. Юк, син аны охшамаса да тәрҗемә итәчәксең. Һичшиксез, татарча чыгарырга кирәк.

Аның сүзләрендә боеру, мәҗбүр итү яңгыраса да, Ирек нишләптер китапны алды. Рашат плащын, эшләпәсен киде, аннары бер генә мизгелгә хәрәкәтсез торганнан соң, плащ кесәсеннән алып, Иреккә бер төргәк акча сузды. Төргәк, банкта ябыштырылган хәлендә, бишлекләрдән генә тора иде.

— Минем бай чак, ничек яшәвегезне күреп торам. Ал инде, ал, — диде ул, Иреккә якынлашып.

Ләкин Ирек артка чигенде. Рашат акчаны диванга ташлады.

— Сыегыз өчен рәхмәт булыр бу.

Аннары ул чыраен Ирекнең йөзенә тери язып якын китерде. Карашы әллә нинди, аңлаешсыз, күзләре каядыр качкан, аларның урынында куе кара сөрем генә кебек күренде. Ирекнең күңелен шомландырып, чыннан да өрәк бугай бу дигән уй йөгереп узды. Җылы, тәмсез аракы исе бөркелде, укшыта язып борынына керде.

— Әгәр минем монда булганны ялгышып берәр җан иясенә ычкындырсагыз, икегезгә дә бик начар булачак. — Рашат, үлем тынлыгы ясап, тукталып калды. — Әле без очрашырбыз.

Ул ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Зәнфирә белән Ирек тораташ катып калдылар. Аларның икесен дә әллә нинди шом, табигатьне дәһшәтле давыл алдыннан биләгән халәт баскан иде. Бөтен кош-корт, җәнлек, бөҗәкләр ничек тынып калган булса, аларның да йөрәге тибүдән туктагандай булды, өй эченә үлем тынлыгы җәелде. Ирек коточкыч бер әйбергә төшенде: иң әүвәл тырышып-тырмашып ул аны уеннан куарга тырышты, чөнки ул җимергеч нәрсә иде. Әмма күпме генә теләсә дә куа алмады һәм аның белән килешергә мәҗбүр булды.

— Акчаларны... — Зәнфирәнең калтыранган куллары диванга таба сузылды. — ... акчаларын, зинһар, чыгарып бир үзенә, — дип пышылдады ул, көч-хәл белән.

Ирек төргәкне эләктерде дә ишегалдына атылды, капкага таба йөгерде. Көчле җил күтәрелгән иде. Капканы ачып, тыкрыкка күз ташлады, ләкин анда беркем дә күренмәде. Күктә ай йөзә, җил уйнаткан агачларның шәүләләре, ычкынып китәргә теләгәндәй, җирдә шуышалар, бәргәләнәләр. Шул арада Рашатның чыгып китүе мөмкин түгел иде. Димәк, ул ихатада. Ирек кабат борылып өй турына килде, як-ягына каранды. Абзар-кура ягына күз ташлап:

— Рашат, син мондамы? — дип кычкырды.

Җавап бирүче булмады, абзар эчендә, нәрсәдер дөпелдәгәндәй, аяк тавышы ишетелгәндәй булды. Ирекнең күңеленә әллә нинди ямьсез уй килде. Шомланып, ул ишекне ачты һәм өй алдындагы балтаны эләктерде. Тавыш чыгармыйча, абзар ягын күзәтә башлады, өйдән Зәнфирә килеп чыкты.

— Бирдеңме акчасын? — диде ул.

— Юкка чыккан ул. Тыкрыкта да күренмәде.

— Кулыңа нишләп балта тоттың?

— Аяк астында калган бит.

— Юкны сөйләмә, мин аны үз кулларым белән кертеп сөядем.

— Рашат! — дип кычкырды тагын Ирек.

Җавап бирүче булмады.

— Мин нишләптер куркам, Ирек. Тизрәк капканы биклик тә өйгә керик.

— Керә тор, — диде Ирек. — Үзем бикләп киләм.

Ул капканы ачып тагын бер мәртәбә тыкрыкка күз салды. Шушы арада Рашатның чыгып китеп өлгерүенә һич тә ышанырлык түгел иде. Ай зур кара болыт астына кереп юк булды, бөтен җиһан караңгылыкка чумды, җил көчәйгәннән-көчәйде. Ирек капканы бикләде дә бераз тыңланып торды, уйланды. Рашатның ул үзенә килгән бәла икәнлеген аңлады. Аның күз карашы рәхимсез, җанга шом сала иде. Аны куып та җибәрү мөмкин түгел, аңардан качып та котылып булмаячак. Аларның тормышында ниндидер хәвефле сызык башлана, язмыш шуны кисәтә, әзер булырга куша иде.

Ирек көчәйгәннән-көчәя баручы җилдә пальтосын эләктермәгән килеш бик озак басып торды. Әллә кая поскан айның сизелер-сизелмәс кенә сирпелүче яктылыгында каядыр шуышучы болытлар шәйләнә, йолдызлар чагылып ала, гүя бөтен җир шуыша, үзе белән бергә Иректне дә алып китә иде. Аның күңеленең беркайчан да бу дәрәҗәдә ачыргаланганы булмады. Тагын Рашат дип уйлады ул. Димәк, Ирек аның белән һаман бер дәрәҗәдә. Күпме генә югарыга омтылып та, үзен олы гамь белән яшим дип хисаплап та, Рашатлар, куркыныч Вышкалар дәрәҗәсендә калган булып чыкты. Бу тоткынлыктан, бу түбәнлектән ул мәңге чыга алмаячакмы, бу нинди зур ялгышлык булды? Ирек бит алардан күпкә өстен кебек, ә менә бүген ул җан өшеткеч хакыйкатьне аңлады: һич тә өстен түгел, бер дәрәҗәдә, алай гына да түгел, Рашат хәзер аның өстеннән таптап йөрергә кайткан. Җавап эзләгәндәй, ул тагын күк йөзенә карады, сызгырып искән җилне тыңлады, әмма җавап юк иде. Аны эзләп чыккан Зәнфирәнең эндәшүенә ул сискәнеп китте. Зәнфирәгә ияреп, буш һава шары кебек, үзенең бернинди авырлыгын, җанынтәнен сизмичә өйгә керде. Зәнфирә ниләрдер сөйләде, Рашат турында сорады, куркам, диде, ләкин аның сүзләре Ирек өчен әһәмиятсез иде. Аны бары бер уй көйдерде: тормышта алар белән бер дәрәҗәдә хурлыклы сөйрәлү. Ул шушының сәбәбен дә тапты кебек. Әгәр гомеренең иң кадерле вакытларын коточкыч кара сөрем белән агуламаса, ул хәзер әллә нинди югары биеклекләрдә булыр иде. Рашатлар аңа якын килү турында уйлый да алмаслар, бәлкем, аны танымаслар да иде. Үзең кискән канатлар тиз генә үсмидер. Телисеңметеләмисеңме, хәзер син алар белән.

## 2

Рашат, Ирекләрнең капкасыннан чыгу белән, эшләпәсен сумкасына салып, күзенә кадәр батырып кара башлык киде һәм ашыга-кабалана юлга таба атлады. Аңа ашыгырга, бик ашыгырга кирәк, ераккарак китәргә, беркемне дә очратмаска кирәк иде. Ахмак дип тиргәде ул үз-үзен, әле бу араларда аңа Болынкырга аяк басарга бөтенләй ярамый ич. Ирек янына теләсә кайчан кайтып була. Йөрәкләренә шом салуыннан канәгатьлек алды алуын. Ә бит шушы бер адым аны харап итәргә мөмкин. Ул йөгерә-атлый Болынкырның уравыч юлына чыкты. Сул якта — караңгылык каплаган ялан, ә уңда утларын балкытып Болынкыр утыра. Шул яктан плащ итәкләрен, чалбар балакларын йолкып юеш җил исә. Рашат, юлда фара яктысы күренүгә, койма буена йөгереп шуннан атлады, яктылык бетүгә, тагын юлга чыкты. Авыл ягыннан искән җил аны сул якка этте, әмма Рашат нишләптер җилгә каршы Болынкыр эченә таба тартылды. Әйтерсең лә бу юеш җилнең уртасында аны каршы якка сөйрәүче икенче бер агым бар иде. Шулай карышып бара торгач, ул авыл эченә килеп керде. Урам баганаларындагы лампочкаларның яктылыгыннан качып, өй, агач шәүләләре караңгылаган урыннарга елышты, тыкрыкларга чумды. «Кит, читкә кит, кермә!» дип боерды ул үз-үзенә, әмма гәүдәсен, аякларын буйсындыра алмады, сулышы кысылды, әллә куркудан, әллә кабаланудан йөрәге дөп-дөп типте. Ул үзенең аракыдан түгел, бүтән аңлаешсыз нәрсәдән ярым исерек хәлендә икәнлегенә төшенде. Ниндидер көч, аның эчке боерыкларына буйсынмыйча, Рашатны һаман Болынкырның уртасына куалады...

Берничә минуттан ул үзләре янында иде инде. Каршыдагы караңгы агач бакчасының эченнән ул үзләренең калай түбәле мәһабәт йортына, аның челтәрләп бизәлгән матур кәрнизле тәрәзәләренә карап торды. Тамагы ачкан кеше ашарга әзерләнгәндәй, берничә мәртәбә төкереген йотты, кипшенгән кайнар иреннәрен ялмап куйды. Зал ягы тәрәзәләре, кухня ягы караңгы иде. Күрәсең, гадәттәгечә әнисе үз бүлмәсендәдер. Рашатның өй эченә тәрәзәдән генә булса да күз саласы килде, бу теләкнең төзәтә алмаслык хатага китерү ихтималын уйлап, бер генә мизгел икеләнеп торгач, тәвәккәлләде. Бу вакытта инде капка бикле булганын ул белә, урам яктан койма өстеннән керергә ярамый — туктаусыз үтеп-сүтеп йөриләр. Рашат, караңгы почмаккарак барып, урамны аркылы чыкты, үзләреннән өченче өйнең бәрәңге бакчасына койма өстеннән генә сикерде, иелеп йөгергәннән соң, үзләре турына барып җитте. Бәләкәй капка аша ишегалдына кермәкче булды — ул йозак белән бикләнгән иде. Мунча

белән сарай арасындагы тар гына бушлыкка помидор бәйли торган таяклар, такта-токта, көрәк-тырма кебек нәрсәләр тутырылган икәнлеген ул белә. Рашат яны белән борылып, кысыла-кысыла агач бакчасы ягына чыга башлады. Такталар шалтырап авып төште, ботына нидер төртелеп, яндырып алды, ул чак кына кычкырып җибәрмәде. Төртелгән нәрсә аның мәктәптә укыганда кулланган чаңгы таягы иде. Рашат таякны ачу белән тартып алып агачларга таба ыргытты да аралыктан шуышып чыкты. Агачлар әле яфрак ярмаган, алмагач, чия, карлыган бөресе исләре, кар астыннан чыккан үлән исләренә кушылып, аның борынын кытыкладылар. Ул комсызланып, бу исләрне суырып бетерергә теләгәндәй, тирән итеп шактый озак сулап торды. Аннары сумкасын җиргә куйды да, аяк очларына гына басып, әнисе бүлмәсенең уң як тәрәзәсенә килде, сакланып кына пыялага читтән бер күзен китерде. Әнисе китап-дәфтәрләренә иелгән, дәресләренә әзерләнә иде, күрәсең. Рашатның тамагына нидер тыгылды, сулышы туктап калды. Ул тагын шулай күпме басып торыр иде, әмма әнисе, аның басып торганын сизенгәндәй, акрын гына урыныннан торды, тәрәзәгә таба йөзен борды. Рашат, башын читкә алып, аркасы белән стенага сыланды. Бераздан карашын сакланып кына тагын эчкә юнәлтте. Ләкин әнисе каядыр чыккан иде. Бәлкем, ул зал ягындадыр? Ул зал тәрәзәсенә килде. Әтисе йөзе белән тәрәзәгә борылып креслога утырган, почмакта телевизор эшли. Тик ул аны карамый, башын бераз кыек салып, йокымсырап киткән. «Мөгаен, исеректер», — дип уйлады Рашат, өнәмичә.

...Миңзаһит, нидер сизенеп, күзләрен ачып җибәрде һәм тәрәзәгә капланган кара шәүләне күрде. Ул сикереп торды, акрын гына шәүләгә таба атларга теләде, ләкин, үзе дә сизмәстән, артка чигенде. Шул арада шәүлә юк та булды.

— Хәят! — дип кычкырды ул, карлыккан тавыш белән. — Хәят, кер әле тизрәк!

Хатыны кухнядан атылып-бәрелеп аның янына килде.

— Ни булды, ник шулкадәр кычкырасың?!

Миңзаһит җиңелчә генә калтырый иде. Ул, уң кулының имән бармагын тәрәзәгә таба төбәп:

— Анда кемдер бар! — дип пышылдады.

Хәят аптырап иренә карады да тәрәзәгә китте, иелеп тышка күз ташлады, әмма берни дә күрмәде.

— Берни дә юк бит.

— Бар, дим мин сиңа, бар! Мин урынымнан торгач, юкка чыкты.

Хәят аптырап баш чайкап торды.

— Соңгы вакытта сәер син, Миңзаһит. Кем йөрсен без-

нең ихатада? Мин дә бит әле яңа үз бүлмәмнән чыктым. Берни дә ишетелмәде.

— Мин синең тел төбеңне аңлыйм — ычкына башладың димәкче буласың. Дәлилем юк. Әмма күрүем хак.

— Әйдә чыгып әйләнеп керик алайса.

Хатынының тәкъдименә Миңзаһит ансат кына ризалаша алмады. Ул сүзсез генә урам яктан башлап барлык тәрәзәләрдән ишегалдын, бакчаларны җентекләп күзәтеп чыкты, шуннан соң гына:

— Әйдә, булмаса әйләнеп керик, — диде.

Алар, барлык утларны гөлт итеп яндырып, ишегалдына чыктылар, сакланып кына агач бакчасына, әле генә Миңзаһитның котын алган тәрәзә турына килделәр.

— Менә күрәсеңме, — диде Миңзаһит, чүгәләп.

Юеш җир өстендә олы ботинка эзләре ярылып ята иде. Эз аларны мунча белән сарай арасындагы аралыкка алып килде, анда куелган әйберләрнең ауганлыгын күргәч, Хәят та иренең хаклыгына ышанды.

— Әйдә, тизрәк керәбез, — диде ул, Миңзаһитның кулыннан эләктереп. — Кемдер йөргән шул...

Алар, ишекләрне бикләп, кухнядагы өстәл янына килеп утырдылар. Икесенең дә йөзенә курку билгеләре чыккан иде.

— Казанга барып эш турында ныклап сөйләшеп кайтырга кирәк, — диде Хәят, авырлык белән сулыш алып. Күрәсең, анын өянәге якынлаша иде. — Күпме сузарга була? Безне куркытып куарга теләүләредер бу...

Миңзаһит авыр сулап куйды.

— Нишләптер күңелем тартмый минем Казанга... Әз генә булса да иректә яшисем килгән иде. Ташпулатка бикләнгәндәй, дүрт стена эченә кереп утырып кара әле син. Аягың белән әнә шул бакча туфрагына басарга да тилмереп ятачаксың бит.

— Безгә башка юл юк бит инде, Миңзаһит. Мин әйткәнгә риза булмадың.

— Әйе, сиңа ансат, хәзер мин шул малайларга баш иеп, шуларның күзенә карап, шулар боерганны үтәп йөрергә тиеш. Юк инде! Бусы беркайчан да булмас. Ачка үлсәм үләрмен, ул малайларга барып тезләнмәм. Аларда миһербан да, оят та, намус та юк.

Тышта нидер дөпелдәгән кебек булды. Алар икесе дә сискәнеп куйдылар.

— Нәрсә икән бу? — диде Хәят, шомланып.

— Җил, җил генәдер, түбә калаен селкеткәндер, — диде Миңзаһит, хатыны алдында куркуын яшермәкче булып. Ә үзе тизрәк барлык утларны сүндереп чыкты, тәрәзәләрдән

тагын бер мәртәбә тышны күзәтте, андый-мондый хәрәкәт, шәүлә күренмәде.

— Йокларга ятыйк булмаса, — диде Хәят.

Вакыт әле шактый иртә булса да, Миңзаһит ризалашмый булдыра алмады. Кухняда янган бердәнбер ут та сүнде. Ярсып искән җил караңгы тәрәзә пыялаларына, түбә калайларына килеп сарылды да, анасының усал карашын тоеп үпкәләгән бала читкә борылгандай, беразга тынып калды...

* * *

Әтисе урыныннан тору белән, Рашат иелеп агачлар арасына йөгерде. Мунчага барып җиткәч, артына борылып карады. Әтисенең тәрәзә каршында басып торуын күрде. Сизендеме, әллә таныды дамы дигән уй аның күңелен көйдереп үтте. Таныса да, танымаса да, качудан башка юл юк иде. Һәр мизгелнең кадерле икәнен аңласа да, ул, үз-үзен белештермәстән, кабат сикереп кенә ике адым атлады һәм кергән чакта ыргыткан чаңгы таягын кулына алды, аннары бер ыргылуда теге тар аралыктан бәрәңге бакчасына чыкты. Ярым иелгән хәлдә бакча буйлап йөгерде. Түргә барып җиткәч, тар тыкрыкка сикерде. Үзенең күңелен һаман бер уй бимазалады: әтисенең милиция чакыруы бар иде. Рашат кабаланып тыкрыкның караңгырак урынына атлады һәм әз генә тын алырга туктады. Шулчак аның алдында ерак та түгел фосфор кебек ике нокта ялтырап алды, һәм мәче кычкырган тавыш ишетелде. Ул арада мәче яктырак урынга чыкты. Бу — кара койрыклы ап-ак мәче иде. Ул Рашатка карый-карый үтте дә аларның бакча коймасы өстенә сикереп менде. Рашатка мәче бәхетле булып күренде. Аларның кап-кара ана мәчеләре бар иде. Әллә шул агарып, койрыгында гына карасы калганмы? Әллә шуның баласымы? Мәче коймадан сикереп төште дә аларның өенә таба чапты. Рашат аны күздән югалганчы карап калды. Үзенең шушылай табаннары җиргә ябышкандай хәрәкәтсез торуына котырып ачуы чыкты. Тизрәк китәргә, ераккарак китәргә кирәк иде.

Ун минуттан ул олы юлдан шактый ерак булган Чабырлы тау буйлап кызу-кызу атлый иде. Тыз-быз узып торучы машиналар тынган арада, юлны аркылы чыгып, ziратка юнәлде. Аның нарат-чыршы, каен, усак агачлары белән томаланган аргы ягына барып җитте. Шунда ул аучылар куып арыткан кыргый җәнлектәй, адымнарының хәлсезләнүен, гәүдәсенең камырдай йомшавын тойды. Йөрәгенең кагуына, күңеленең болгануына, ике чигәсенең кысуына түзәрлек түгел иде. Бу хәлдә беркая да китә алмаячагын ул яхшы аңлады. Сирәк кенә коелган койманың ике тактасын шартлатып ку-

барды да, хәлсез аякларын авырлык белән сөйрәп, эчкә атлады. Әгәр шушында иртәгә кичкә кадәр йокларлык җылы кабер булса, ул ике дә уйламас, хәзер үк шунда кереп авар иде. Өч-дүрт адым атлауга, авыш җирдәге юеш каудан үләненнән аягы таеп, ул сырты белән барып төшкәнен сизми дә калды. Калак сөяген ниндидер каты нәрсә авырттырып алды. Сикереп торгач, Рашат һаман чытырдатып кыскан сумкасын, чаңгы таягын читкә селтәде дә теге әйбергә үрелде. Кулы тию белән тәне чымырдап китте. «Баш сөяге!» — дип уйлады ул, куырылып. Җентекләп караганнан соң гына аның кеше башы түгел, ә бәлки череп беткән кабер бурасының сынып төшкән башы икәнлеген абайлады. Әмма күңелен биләгән шом таралмады. Черегән үләннәрдән, яфраклардан, юеш җирдән килгән кабер исе аны әллә нишләтеп җибәрде. Ул кабаланып зират эченнән чыкты һәм, коймага күкрәге белән сөялеп, бераз күзләрен йомып торды. Күзләрен ачуга, аста үзенең җем-җем иткән утлары белән җәйрәп яткан Болынкыр пәйда булды. Әйтерсең лә галәмнең барлык йолдызлары меңьяфрак чәчәгедәй бергә шунда җыелганнар, аларның җылысында күпме кеше бернинди гамьсез гомер кичерә. Бары аңа гына, бары аңа гына моннан читкә, мөмкин кадәр ераккарак китәргә кирәк...

Ул башын югарырак күтәрде. Күктә йолдызлар калмаган диярлек. Туктаусыз җил куалаучы болыт ертыклары арасыннан күренеп алганнары да салкын һәм шомлы, алар корбанын эзәрлекләүче күпсанлы бүре өеренең күзләрен хәтерләтәләр. Йолдызлар да, бүре күзләре дә, эзәрлекләүчеләр дә бер үк. Бөтен нәрсә буталды, кайсысы нәрсә икәнен, булдыра алсаң, үзеңә аерырга туры килә...

Ул, коймага аркасын терәп, юеш чирәмгә утырды, сумкасын ачып, башланган коньяк шешәсе, кабымлыклар чыгарды. Коньягын шешә борыныннан гына голт-голт эчте дә колбаса, ипи кабып чәйнәргә кереште. Күптән түгел генә яңгыр юып киткән үләннәрнең юеше салкын булып тәненә үтте, тик ул моңа игътибар бирмәде, комсызланып умырып алып, колбаса белән ипи чәйнәде, гәүдәсенең җылына баруын тойды. Җил һаман басылмады, зират эчендәге агачлар тагын да шомлырак булып шауларга керештеләр.

Ул чәйнәвеннән туктап калды. Нәкъ аның баш очында «торрыйк-торрыйк» дигән тавышлар ишетелде. «Торналар кайта!» — дип уйлады ул. Торналар кайта... Кошлар туган якларына төнлә очалар — Рашат моны яхшы белә. Ул башын күтәреп һавага карады, әмма торналар күренмәде...

Кошлар туган җирләренә төнлә очалар...

Аның уен сизгәндәй, тагын торна тавышлары көчәйде.

Бер төркеме узып китеп, икенчесе килеп җиттеме, әллә шул ук төркемме? Кошлар туган җирләренә юлны йолдызларга карап та билгелиләр, диләр. Әллә алар, үз йолдызларын югалтып, болытлар арасында адашып кычкыралармы?

Кинәт тып-тын булып калды, хәтта җил дә акрынайды бугай. Рашат шешәсен күтәреп тагын эчте, тик бу юлы берни дә капмады. Аңа әллә ни булды, бөтен барлыгын салкын бушлык биләп алды, гәүдәсен кайнар ут көйдерде, һәм ул күзләрен йомды. Шулай да аның фикере сизгер иде: юк, сиңа йокларга ярамый, дип кисәтте ул. Рашатка бүген үлеп-җитеп булса да төнлә тимер юл вокзалына барып җитәргә кирәк. Бу тирәдән эзне суытырга, ерагаерга, шау-шулы, ыгы-зыгылы, буталчык вокзал дөньясына чумарга. Тизрәк теләсә кайсы поездга утырып, ераккарак сызарга! Ул уйный торган хәтәр уенның кануны шундый. Бу канунны бозсаң, барысы да бетте дигән сүз... Әгәр Вышка аны Ирек белән сугыштырганда Рәсүл үзләренең төркемен алып килмәгән булса, менә болай йөрергә дә туры килмәс, ул рәхәтләнеп кара җир куенында йоклап ятар иде. Әнә бит күпме кешеләр йоклый, берсен дә борчучы, куалаучы юк. Больницадан чыгу белән күзне йомып шушында — Болынкырга ычкынасы булган. Ә ул һаман Мәскәү тормышына кызыкты, һаман нидер җитмәде. Квартирасын хуҗаларына тапшырып, урамда калды. Рәсүл төркеменә ияреп, Вышканың күзеннән югалырбыз дип уйлады. Мәскәү зур, җир астында да тулы бер шәһәр, күзләренә чалынмам дип өметләнде. Әмма бер ай да үтмәде, ничек килеп капканын сизми дә калды. Вышка хәзер дә аның бар икәнен белми, югары даирәләр эчендә кайнаша. Ә Рашат барыбер ул корган пәрәвезгә эләккән килеш. Пәрәвез җепләренең кайларга кадәр, күпме җирләргә сузылганын Вышка үзе генә белә... Рашатка соңгы корбанын юк итәргә бер ай вакыт бирделәр. Ул, аның койрыгына ябышып, күрше районга кадәр кайтып җитте. Төрмәдә утырган дустына килүе булган икән. Рашат бер атна сагалады, мунча кергән вакытында эш итте. Сабынланып ята иде, сизми дә калды...

Якында гына сагышлы итеп торналар каңгылдаша башлады. Рашат аларны аңлагандай булды. Торналар да аны куалый, ашыктыра, ә бәлкем, без төшәсе җирне билисең, диләрдер. Аларның тавышы үткен хәнҗәр белән Рашатның йөрәгенә сызып җибәргәндәй итте һәм ул, гел сизмәстән, беркайчан булмаганча, тыелгысыз үксергә тотынды...

Кошлар туган якларына төнлә очалар... Кошлар туган якларына очалар...

Рашат кул аркасы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә торып басты һәм тешләрен шыкырдата-шыкырдата ыңгырашып

җибәрде. Ул чаңгы таягын эләктереп алды да ике куллап тотып һаваны айкарга кереште, гүя анда каңгылдашучы торналарны куркытырга, туктатырга теләде. Аннары үзен-үзе белештермәс хәлгә килеп, таяк белән зират коймасына уңлысуллы сугарга тотынды. Койма башлары кителгәнче, алюмин таяк кәкрәеп-бөгелеп беткәнче такталарны кыйнады. Тәмам ярсып, тирләп чыккач, таякны зират эченә томырып, олы юлга атлады. Әле күрәсе көннәрегез алда, әле сез берни дә белмисез, йолдызларыгыз алай күңелле, шат янмас, дип янады ул, аста җемелдәп яткан Болынкыр утларына карап. Рашат елаудан туктаган иде инде.

Төн аны үз кочагына алды. Торналар йөрәкләрне кабындырырлык каңгылдаша-каңгылдаша туганякларына очуларын дәвам иттеләр...

## 3

Кәрәм бу очрашуга бик озак җыенды. Аның хәтта санаторийга барганда, Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләргә сәфәр чыкканда да бу кадәр әзерләнгәне юк иде. Очрашырга кыймыйча апрель дә үтте, менә майның уртасы килеп җитте. Башкача соңару мөмкин түгел. Быел укуын тәгәлләячәк оныгын ничек булса да институтка кертергә кирәк. Ә Арслановның элемтәләре ул мәсьәләдә шактый зур. Ул үзе бер яклап эш итсә, икенче яклап Арсланов, өченче яклап тагын берәрсе этсә-төртсә, бәлкем, ниятләре барып та чыгар. Кәрәм элегрәк бер генә мәртәбә булса да Арсланов янына кагылып чыкмаганына үкенеп бетә алмады. Хәл белергә кирәк иде югыйсә. Турысын әйткәндә, ул аннан шүрләде. Сизенгәндер, чыраема ябышыр дип уйлады. Әмма бервакыт телефоннан ялгыш эләгеп, алар сөйләшеп киттеләр. Арсланов аны үзенә чакырды. Кәрәм, ярар, ярар, диде һәм шуның белән калынды. Ул чакта Арслановның тавышы бик мөлаем, ягымлы чыкты. Димәк, үзен райкомнан очыруда Кәрәмнең төп дирижер булганлыгын аңламаган иде.

Ул бик затлы коньяк алды, күптән хәстәрләп куелган Рига бальзамын шуның янына салды, затлы конфет, шоколад, лимон өстәде. Бөтенесен дипломатына тутырганнан соң, иң яхшы киемнәрен киде, туфлиен көзге кебек ялтыратты. Көн тып-тыныч, костюмнан йөрерлек җылы булса да, күкне салынкы болытлар каплаган иде, зонтигын да онытмады. Шуны гына көткәндәй, капкадан чыкканда ук яңгыр сибәләргә тотынды. Кәрәм, зонтигын җәеп, ашыкмыйча гына урам буйлап китте. Ул Арслановның өенә туп-туры бармады. Инде бер җитешкәч, борынын салындырып ята торгандыр дип уйламасыннар өчен, башын югары күтәреп, Болынкырның

үзәк урамнарыннан ук әйләнеп барды. Кибетләр турында тукталды, очраган кешеләр белән әңгәмә корды. Ул Арслановларның капкасыннан кергәндә, сәгать икеләр тулган иде инде. Болдыр яңагына беркетелгән кыңгырау төймәсенә каткат басса да, өйдән чыгучы булмады. Ул түргәрәк китеп бакча ягына карады һәм аннан күтәрелгән зәңгәрсу төтенне күргәч, хуҗаның шунда икәнлеген аңлады. Бакча капкасын ачуга, пыскып янган чүп өеме өстенә сәнәк белән салам ташлап маташкан Арслановны күрде. Бу шөгыле белән ул шулкадәр мавыккан иде, үзенә якынлашып килүче Кәрәмгә игътибар да итмәде. Ул аягына иске галош кигән, өстендә бер кызыл сәдәфкә эләктерелгән иске яшькелт куртка, үзе яланбаш иде. Алмагач, чия, күгәнә чәчәкләре арасыннан саркып чыккан төтен Кәрәмнең борынын кытыклады. Ул кинәт көчәеп, Арслановны да күренмәслек итте. Кәрәм зонтигын күтәргән килеш агачлар арасына салынган сукмактан ботакларга эләкмәс өчен иелә-бөгелә атлады. Ниһаять, Арсланов аны күреп алды.

— О-о-о, Кәрәм Нәҗмиевич! Син дә исән икәнсең! — Арсланов сәнәген җиргә кадады да аның каршына килде.

Кәрәм дипломатын янәшәдәге җиләк түтәленә куйды, һәм алар авыл картлары кебек ике куллап күрештеләр. Арслановның кулы балчыкка буялып беткән, юеш һәм бака кебек салкын иде.

— Син бу киемнәрең белән менә мондарак кил инде, — дип күрсәтте ул, мунчадан ерак булмаган чатырга ишарәләп.

Алар нарат такталарыннан чәер исе килеп торган чатыр астына керделәр. Кәрәм зонтигын җыйды, затлы чалбары белән шәрә тактага утырырга-утырмаска белмичә карангалап тора башлады.

— Эх, шушы интеллигентларны! — диде Арсланов, көлеп.

Тиз генә йөгереп барып, мунча верандасыннан зәңгәр палас алып чыкты, утыргычка җәйде, шуннан соң гына Кәрәм паласка арты белән терәлде.

— Йә, ни хәлләрдә ятасыз, Миңзаһит Усманович? — диде ул, бик самими, мөлаем итеп елмаерга тырышып.

— Отлично! — диде Арсланов һәм курткасын ычкындырып ике якка ачып җибәрде. Аның тәне шәп-шәрә, хәтта майкасы да юк иде.

Чәчләреннән яңгыр тамчылары тәгәрәп, колакларын, муенын, күкрәген чылаталар, ул аларны гүя сизми иде. Кәрәм аның кимендә ике көн кырынмаганлыгына да игътибар итте. Шулай булса да аны бер нәрсә гаҗәпләндерде: Арсланов ничектер яшәргән, җиңеләйгән, күзләреннән дәрт ташып тора иде.

— Башыгызга кимисезме, Миңзаһит Усманович? Салкын тигерүегез бар бит.

— Син бик нык ялгышасың, Кәрәм Нәҗмиевич! Анысы булмас инде.

Ул, балчыкка буялган имән бармагын күтәреп, әз генә туктап тор дигәндәй хәрәкәт ясады да ишеге ачып куелган сарайга кереп китте. Аннан кечкенә подноска утыртылган «XX гасыр» аракысы, тозлы кыяр, ипи, колбаса кисәкләре күтәреп, чатыр өстәленә китереп куйды. Подноста рюмка берәү генә һәм ул күп тотудан балчык кисәкләре ябышып, каралып беткән иде. Шундый ук төскә кергән шешәдән Арсланов рюмканы тутырып аракы салды һәм Кәрәмгә сузды. Кәрәм аны үрелеп алды, әмма кайсы төшеннән эчәргә белмичә икеләнеп торганнан соң, иреннәренә тигермичә генә авызына каплап куйды. Арсланов савыттагы киселгән кыяр кисәген әләктереп аңа сузды. Кәрәм баш чайкагандай итте дә тизрәк үрелеп юри помидор алды.

Арсланов ютәлли-ютәлли көләргә кереште.

— Җирәндерәмме, Кәрәм Нәҗмиевич? Ышан миңа, бередә бернинди микроб та юк.

Ул үзенә салып эчте дә балчыклы бармаклары белән кыскан кыярны шатыр-шотыр чәйнәргә кереште.

— Кәефләрегез ничек? — диде Нәҗмиев, нindидер әңгәмә кору нияте белән.

— Отлично! — диде Арсланов, бер сүз белән. — Беләсеңме, Кәрәм Нәҗмиевич, райкомнан киткәннән бирле галстук таккан юк, үтүкләнгән чалбар кигән юк — рәхәтлеген белсәң! Баш авыртмый, нервылар тәртиптә, йокы сабый балаларныкы кебек.

Кәрәм сигарет чыгарып Арслановка сузды, ләкин ул баш чайкады, астан гына елмаеп, кесәсеннән бер кап махорка алып куйды, икенче кесәсеннән шакмаклап бөкләнгән газетасын чыгарып ертты.

— Мин менә шушыны тартам. Ә бу сезнең сигаретлар, гафу ит, алар күксегән мүк кенә.

Ул газета кәгазенә ике мәртәбә чеметеп тәмәке салды, шәпләп кысып төрде, теле, иреннәре белән төкереклә ябыштырды һәм, бер башын бөтереп куеп, икенче башыннан авызына капты. Кәрәм бу вакытта зажигалкасын чыгарып кабыза гына башлаган иде, Арсланов аны бәреп үк төшерә язды. Аптыраудан Кәрәмнең күзләре шакмакланып киттеләр.

— Син нәрсә инде, Кәрәм Нәҗмиевич?! Шушындый урында зажигалка чыгарасың! — диде ул, аны тиргәгәндәй һәм күренер-күренмәс ялкын телләре чыгарып төтенләп утыручы учактан башы күмерләнгән бер ботак алып килде. — Иң шәбе менә шушы инде аның. — Төтенләп торган ботак

башын иң элек Кәрәмнең мөштеккә кигерелгән сигаретына тигерде, аннары үзенең тәмәкесен кабызды.

Кинәт яңгыр көчәеп, шаулап ява башлады. Шуны күргәндәй, Арсланов, тәмәкесен суыра-суыра, учак янына китте, аны болгаткалады, борылып килде, әмма чатыр астына кермәде. Ике учы белән тәмәкесен каплап суыра бирде, аның чәчләреннән, йөзеннән, кулларыннан шыбырдап су ага иде. Кәрәм Арсланов трикосының тез турларыннан тишкәләнеп беткәнлеген, кызарып тәне күренгәнлеген абайлап алды.

— Бирегә керегез инде, Миңзаһит Усманович.

Арсланов әйтерсең аны ишетмәде, көлемсерәгән хәлдә тәмәкесен тарта бирде, шактый вакыттан соң гына түбә астына керде. Лычкылдап беткән тәмәкесен бармак арасына кыскан килеш:

— Син бит берни дә аңламыйсың, Кәрәм Нәҗмиевич, — диде ул һәм тәмәкесен тагын авызына капты. Ул инде сүнеп бара иде, лач-лоч суыра торгач, тагын төтенли башлады. — Мин хәзер беркемгә дә баш имим. Моның ләззәтен син аңлый алмыйсың. Менә кара әле. — Ул галошыннан бармак аралары каралып беткән аягын чыгарып, Кәрәмгә таба күтәрде. — Бөтен кеше киенеп йөри, ә мин киенмим. Менә син шушы махорканы кәгазьгә төреп, күмердән кабызып, яңгырдан сүндермичә учың белән саклап тартып кара. Дөньяда аннан да рәхәт берни дә юк! Син баядан бирле минем тез башларыма карыйсың. Әйе, юри эзләп табып кидем мин бу триконы. Хатын курткага өч сәдәф тагып куйган, кичә аларны кисеп атып, уртадагысын гына калдырдым. Мин үземчә яшим, сез үзегезчә яшәгез. Бу җир минеке. — Арсланов, учы белән умырып, янәшәдән генә балчык алды. — Күрәсеңме, теләсәм, мин анда агач үстерәм, теләсәм, кыяр, суган, сарымсак, кәбестә утыртам. Ул миңа тулысынча буйсына, әрепләшми, аны буйсындыру өчен бюро утырышы да, киңәшмәләр дә, пленумнар да кирәкми. Минем өстемнән болытлар йөзә, төнлә йолдызлар җемелди, көндезен кояш нур коя, менә шушындый җылы яңгырлар ява. Мин үзем дә шушы бакчаның бер үсемлеге, тик мин йөри алам, уйлый алам — аерма шунда гына. Мин тагын бер нәрсәгә куанам: шушы рәхәтлек эчендә йөзгәндә, адәм балалары, бөтен кешелек тыны-көне бетеп каядыр ашыга, кабалана, бәргәләнә, көрәшә, кемнәрдер кан коя, кемнәрдер һәлак була, кемнәрнеңдер бәхетләре җимерелә, кемнәрдер бәхетләрен таптым дип куана. Аларның берсенең дә җаны тыныч түгел. Ә менә минеке тыныч...

Арсланов инде сүнеп, лычкылдап беткән тәмәкесен чапчоп суырып карады да өстәл читенә куйды.

— Аңладыңмы син мине?

— Аңладым, — диде Кәрәм һәм дипломатын ачып җибәрде.

Арсланов аның дипломатын ябып куйды.

— Андый әйбер булмый. Син миңа кунак булып килгәнсең икән, сыйлау миннән.

— Кунак күчтәнәчсез йөрми бит.

— Юк, юк, әйттем — бетте!

— Сез мине үпкәләттегез, Миңзаһит Усманович. Китәм мин алайса.

— Ашыкма, китәрсең. Әле иң зур сый куелмаган.

Арсланов подносны алды да инде ялкыннары сүнгән, төтеннәре генә чыгып яткан чүп өеме янына килде. Аның кырына чүгәләп, бер таяк белән шактый вакыт көлне актарды, аннары урыныннан торды һәм ун-унбиш кабыклы бәрәңге салынган подносны өстәлгә куйды.

— Менә бусы деликатес була инде, — диде ул.

Тагын нидер исенә төшеп, ерактарак яшелләнеп утыручы түтәлләргә таба китте, умырып-умырып берничә учма кузгалак, суган, петрушка өзде. Түбәдән шарылдап су агып утыра торган зур калай мичкәдә чайкагандай иткәч, үләннәрен өстәлгә куйды. Су тамып торган куллары белән теге рюмканы тутырып Кәрәмгә сузды. Аңардан соң үзе дә эчеп куйды. Каяндыр саргаеп беткән эре тоз китереп куйды. Кәрәм помидор капкалаган арада, ул тышлары көеп беткән бәрәңгенең берсен алып урталай ярды, эре тоз сибеп, суган, кузгалак белән ашый да башлады. Кәрәмнең бәрәңгене алырга куркып утыруын күреп, иң нык күмерләнгәнен аңа тоттырды. Кунак аны учында сикерткәләп тора башлады, чөнки бәрәңге кайнар иде.

— Син ник җирәнәсең, Кәрәм Нәҗмиевич? — диде ул, кап-кара корымга баткан иреннәре, битләре белән елмаеп. — Тормышны чистартып булмый, ничек бар, шул килеш кабул итәргә кирәк аны.

— Анысы шулаен шулай, — диде Кәрәм, төптән үк киселгән тырнаклары белән көеп каткан бәрәңге кабыгын кубармакчы булып чокый-чокый.

— Чокыма, кубарма, мин әйткәнне аңламадыңмыни? — Арсланов икенче бәрәңгене алып ашарга керешкән иде инде. — Менә сине чистартып буламы соң?

Кәрәм, нидер сизенеп, аңа ялт итеп карап куйды.

— Нигә аптырадың? Чистартып булмый сине, Кәрәм Нәҗмиевич. Мин бит сиздем...

Кәрәм, бәрәңгесен чәйнәүдән туктап, авызын ярым ачкан килеш аңа карады һәм тамак төбеннән көч-хәл белән ике генә сүз чыгарды:

— Нәрсәне сиздегез?

Арсланов җавап бирергә өлгермәде, бакча капкасы шапылдаган тавыш ишетелде. Алар икесе дә шул якка борылдылар һәм, чәйни башлаган бәрәңгеләрен онытып, авызларын ачкан килеш калдылар. Уртадагы сукмактан ап-ак булып утырган алмагач ботакларына кагыла-кагыла Чукаева килә иде. Икесенең дә эчләре жу итеп куйды. Гандәлифә беркайчан да юньлелек белән килми, хәзер нидер кубарачак. Мәче балалары белән булган вакыйгадан соң Миңзаһит аңа бигрәк тә шикләнеп карый башлады. Чукаева кулына нидер тоткан, аны зәңгәрсу сөлге белән каплаган. Кәрәм белән Миңзаһит бомбага караган кебек шул сөлгегә карап каттылар. Менә сөлге ачылып китте, һәм өстәлгә түгәрәк пластик савытка салынган гөмбәләр килеп утырды. Бу хәл аларны тагын аптыратты. Чукаеваның йөзендә ниндидер серле елмаю яшерелгән, карашы бераз кызганулы да кебек иде.

— Атларны тугаргансыз икән, — диде ул, әле Кәрәмгә, әле Миңзаһитка күз атып. Аның чәчләренә алма чәчәге таҗлары ябышкан иде. — Әйдә, сыйланып алыгыз.

Миңзаһит, ушын җыя алмыйча шактый торганнан соң:

— Рәхмәт инде, иптәш Чукаева, — диде.

— Ташла инде шул иптәшләреңне, иптәш Арсланов!

Бу сүзләрнең авызыннан ничек чыгып киткәнен Гандәлифә сизми дә калды. Колагы белән ишетеп, нәрсә ычкындырганын аңлагач, иң элек үзе көләргә тотынды, аннары Миңзаһит белән Кәрәм кушылды. Өчесе дә күзләреннән яшьләре чыкканчы көлделәр. Миңзаһитның авызыннан кузгалак катыш күмерле бәрәңге кабыкларына кадәр чыгып очты. Миңзаһит каяндыр өч калак алып килде, аннары рюмканы тутырып Гандәлифәгә сузды.

— Әйдә әле, алмалар уңсын өчен берне тотып җибәр әле.

Гандәлифә ялындырмады, рюмканы уң кулына алды, ә сулын аларга таба сузды:

— Бер бәрәңге бирегез инде.

Миңзаһит аның кулына зур гына бәрәңге салды. Ул җиңел генә эчеп куйды да, гөмбә белән бәрәңге ашый башлады. Миңзаһит белән Кәрәм дә аның үрнәгенә иярде.

— Тәмле пешергәнсең бәрәңгеңне, — диде Гандәлифә, иреннәрен корымлы бармаклары белән сөртә-сөртә, битләрен дә шактый каралтып.

Миңзаһит аңа тагын бәрәңге сузды, ләкин ул баш тартты.

— Булды, рәхмәт.

— Гөмбә өчен үзеңә рәхмәт. Тагын берәрне тотыйк инде.

— Акылың алтын икән, — диде Гандәлифә, күзләрен уйнатып һәм кычкырып көлеп җибәрде.

— Нигә көләсең?

— Бәрәңгең тәмле булды, шуңа көләм.

Чукаева көлә-көлә чыгып та китте.

— Миңзаһит Усманович, син кайнар бәрәңге белән бергә минем авызга кайнар күмер дә ыргыттың бит әле, — диде Кәрәм, икесе генә калгач. — Нәрсә сиздегез сез?

Арслановның йөзенә канәгатьләнү билгеләре чыкты.

— Син инде, Арсланов берни дә белмәде, мин моны төп башына бик шәп итеп утырттым, дип уйладың.

Кәрәм, бәрәңгесен подноска ташлап, сикереп торды.

— Мондый сүзләр ишетермен дип килмәгән идем... — Ул зонтигын кулына алды.

Арсланов сүзсез генә аңа утырырга ишарә ясады.

— Кәрәм Нәҗмиевич, әйдә син юкка көчеңне сарыф итмә. Мин райком секретаре түгел, син оештыру бүлеге мөдире түгел. Сайлауларны әйбәт оештырдың, ниятең барып чыкты. Яшермим, мин син корган ятьмәгә туп-туры эләктем, син балыкны ярга алып ыргыттың. Барысы да син теләгәнчә булды кебек. Тик соңыннан безнең Әхнәф дигән егетебез сине дә ыргытты.

— Син ялгышасың, Миңзаһит Усманович, — диде Кәрәм, һаман акланмакчы булып.

Арсланов аңа таба кул селтәп куйды:

— Кирәкми инде, кирәкми! Минем бит уйланырга вакытым бар иде. Икебез эшли башлаганнан ук булган хәлләрне мин барысын да бер җепкә тезеп чыктым. Нинди уйлар белән эшләгәнеңне, миңа, башкаларга булган мөнәсәбәтеңне энәдән-җептән үткәрдем. Хәзер шушында тезләнеп, башыңны җиргә бәрә-бәрә әллә ниләр сөйләсәң дә, фикеремнән кире чигендерә алмыйсың. Күзләреңне алан-йолан китермә, Кәрәм Нәҗмиевич. Сиңа әз генә дә үпкәм юк, гафу иттем. Ничә еллар бергә эшләп, мин дә синең күңелеңне аз яраламаганмындыр. Ул яраларга тозы да сибелгәндер. Тоз ул менә бу бәрәңгегә сибәргә әйбәт, ә күңел ярасына эләксә, ай-яй авыр! Син минем чынлап әйткәнгә ышандыңмы?

— Ышануын ышандым. — Кәрәм бәрәңгесен кулына алып, әйләндергәләргә тотынды. — Сезнең фикер буенча мин гомер буе аяк чалу белән шөгыльләнгәнмен булып чыгам. Без бит уртак мәшәкатьләр белән яшәдек. Нәрсәдер килеп чыккан икән, анысын чыннан да кичерергә кирәктер. Инде без эчкерсез сөйләшәбез икән, минем бер соравым бар. Эштән киткәч, күңелегездә бушлык сизмәдегезме?

— Юк! — диде Арсланов, кискен итеп. — Анда бушлык түгел, утлы өермә, шайтаннар, аждаһалар туе иде. Мин бөтен дөньяны каргадым! Сезнең бөтенегезне эттән алып эткә салып сүктем. Ләкин беркөнне... — Арсланов, сүзеннән тук-

тап, тәмәкесенә үрелде. — Төнлә йокысызлыктан ишегалдына чыктым. Апрель уртасы, чалт аяз, күктә ай балкый, агачларның шәүләләре җиргә сузылган. Шушы чатырга утырдым да айга карадым. Бөтен дөньяда тынлык, иксез-чиксез, тып-тыныч күк, йолдызлар җем-җем итә. Шунда башыма бер уй килеп төшмәсенме! Миңзаһит, мин әйтәм, синең кай төшең авырта, тәнеңнең кай төшендә чир бар? Үзем үк җавап бирдем: юк, мин әйтәм, сау-сәламәт. Торыр җирең бармы? Бар, дим. Ашарыңа бармы? Бар, дим. Яныңда хатының бармы? Бар, дим. Ни җитми соң сиңа, дим. Дөньяны яулап аласың киләме? Юк, дип җавап бирәм үз-үземә. Соң, алай булгач, сиңа ни җитми? Шушы түгәрәк ай астында, йолдызлар астында, шушы җирдә рәхәтләнеп яшәргә, һәр яшәгән көнең өчен куанырга ни җитми, дим. Сорау арты сорау, җавап арты җавап бирә торгач, күңелдәге шайтаннарның котыруы кимеде, ахырда алар юкка да чыктылар. Вакытлар үткәч, мин сезне сүгүдән дә туктадым. Соравыңа җавап бирдемме мин синең?

— Бирдегез кебек. Ә менә мин алай түгел. Бергә эшләгән, үзебез дус дип санаган яисә дошманга хисаплаган кешеләр көндез дә, төнлә дә каһәр төшкән уй чоңгылына җыелалар да бимазаларга тотыналар — һич котылмак юк шулардан!

— Ә син гафу итәргә тырыш аларны.

— Булдыра алмыйм…

Кәрәм үзенең шушындый ачыктан-ачык сөйләшүгә килеп китүенә хәйран калды. Бу аның планнарында бөтенләй юк иде. Аңа оныгы мәсьәләсендә сүз кузгатырга, кемгәдер шылтыраттырырга кирәк иде. Әмма үзе кылган барлык гамәлләрен Арслановның төгәл хисаплап чыгарган булуы Кәрәмнең башына китереп сукты. Шуның өстенә алып килгән күчтәнәчтән дә баш тартты. Димәк, гафу иттем дип болай гына әйтә. Аның эчендә һаман да шайтаннары, аждаһалары котыралар, ул аларны сизмәскә һәм сиздермәскә генә тырыша. Ә бәлкем, арыгандыр? Шунлыктан аның сизү сәләте беткәндер? Шок вакытында кеше авыртканны сизми, бәлкем, Арсланов та шундый хәлгә килгәндер? Аның менә шушындый кыяфәттә йөрүе, өстенә шыбырдап яуган яңгырны да тоймавы шул хакта сөйләми микән? Ничек кенә булмасын, бүген Кәрәмнең юлы уңмады. Күпмедер көтәргә кирәк, ә көтәр вакыт калмаган, июньдә чыгарылыш имтиханнары башлана. Шулай да Арслановка юлны шарт итеп ябып куярга ярамый иде.

— Гафу итүегез өчен рәхмәт, — диде Кәрәм, тотынып әйбер эзләп. — Сезнең күңелегездә беркайчан да кешелеклелек бетмәде. Әйе, мин абынгаладым, ләкин, хөрмәтле Миң-

заһит Усманович, Казаннан торып миңа юнәлеш бирүчеләр булганлыгын да онытмасагыз иде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Арслановның йөзе җитдиләнеп китте. Ул, ялгыш ишетәмме әллә дигәндәй, башын чайкап куйды.

— Казаннан да?! — дип сорады ул, тавышын күтәреп. — Кемнәр ул?

Кәрәм әлеге ялганны әйткәне өчен үзен-үзе ботарлап атардай булды. Ахмак! Ник кирәк иде инде бу?

— Гафу итегез, мин аларны әйтә алмыйм.

— Әйтә алмагач, кирәкми, — дип куйды Арсланов, төксе итеп. — Ә мин ачыктан-ачык сөйләшүгә исәп тоткан идем...

— Сезне Казанга эшкә китәсез, диләр. Әгәр мин кемнәрнеңдер исемен атасам, бу сезнең үзегезгә дә, аларга да уңайсызлыклар тудырыр иде. Онытсак, әйбәтрәк булыр.

— Мин уйлап карамын әле, — диде Арсланов, ничектер серле итеп. — Ә менә сиңа, Кәрәм Нәҗмиевич, минем үземне шактый көннәр борчый башлаган бер сорауны бирәм, шуны алып кит тә менә шушы бәрәңге кебек чәйнәп кара әле, эре тоз сибеп. Очына чыга алырсыңмы, юкмы?

— Нинди сорау? — диде Кәрәм, шикләнеп.

— Сорау бик гади: кеше ни өчен яши? Синең белән мин ник яшибез? Бәлкем, хәзер үк җавап бирерсең?

Кәрәм зонтигын, дипломатын алып урыныннан торды.

— Без бу сорауга җавапны киләсе очрашуга калдырыйк әле. — Кинәт аның башына бер отышлы уй килде: — Без сезне Хәят ханым белән бергә үзебезгә чакыргач, ул сорауга җавап эзләрбез.

— Юк, юк, юк! — диде Арсланов, ике кулын күтәреп аркылы-торкылы йөртә-йөртә. — Без инде бу сорауга җавапны менә шушы нейтраль зонада икебез генә утырып эзлик.

— Сез безгә килүне түбәнлек саныйсызмыни? — диде Кәрәм, өметен өзмичә.

— Мин үземнең мөстәкыйль дәүләтемне, беркем бернәрсәдә дә чикли алмаган шушы яшәешемне бозарга теләмим. Үпкәләмә, Кәрәм Нәҗмиевич. Чакыручылар күп булды, берсенә дә аяк басмадым. Әйттем бит — мин үз юлымда, сез үз юлыгызда.

Кәрәм зонтигын җәйде, Арсланов, галошларын лыштыр-лыштыр сөйрәп, аны капка төбенә кадәр озата чыкты.

— Яңгыр күптән туктады, зонтигыңны җый, — диде аны озатканда Арсланов.

Кәрәм аптырап китте. Арслановка гына түгел, аның үзенә дә нидер булган иде, ахрысы...

## 4

Татлы ширбәткә манчылгандай бу җылы, гүзәл язгы көн Әхнәфнең исендә мәңгегә калыр. Бу аның беренче булып үз җитәкчелегендә, үзе оештырып чәчүне төгәлләгән истәлекле язы. Әйтерсең лә һәр басу, һәр кишәрлек тере кеше күзләре белән карый, Әхнәфкә рәхмәт әйтеп пышылдый, үзләренең эч серләрен сөйли, бәрәкәтле мул киләчәк вәгъдә итә кебек. «УАЗ» машинасы комлы басу юлыннан җай гына алга йөгерә. Әхнәфнең чәчләрен җылы, хуш исле бармаклары белән язгы җил кытыклый, муенынннан, колакларыннан үбә, күлмәк эчләренә үтеп керә. Бүген шактый хуҗалыклар механизаторлар белән язгы сабантуй үткәрәләр. Әхнәф, өч хуҗалыкта булып, игенчеләрне кыр эшләрен уңышлы төгәлләүләре белән тәбрик итте. Менә хәзер ул Наратбашка якынлашып килә. Биредә дә әле бәйрәм төгәлләнмәгәндер, аның килүен халык үзенә күрә бер мөрәүвәт итеп кабул итәчәк. Наратбашлыларның бәйрәмнәрен кайда үткәргәннәрен дә Әхнәф яхшы белә. Бу авылның күкләргә ашкан нарат урманыннан Ыкка сузылган шактый текә ике тавы бар. Дөя өркәче төсле ул таулар Ык ярына кадәр төшкән итәкләре белән үзара тоташалар. Менә шушы ике өркәч арасында көмештәй елтырап чишмәләр ага, иртә яздан юа, кузгалак чыга. Үзәнлекнең ике яклап күтәрелгән үрләрендә алмагачлар, чияләр шау чәчәктә утыралар. Алар чәчәкләрен коеп бетерүгә, балан чәчәк ата, димәк, кармакка җәен кабар чак җитте дигән сүз. Уң як өркәчнең иң очына килеп җиткәч, Әхнәф шоферына туктарга кушты. Алар икәүләп җиргә төштеләр. Биредәге манзараның гүзәллегенә сокланып туярлык түгел иде. Нәкъ каршыда зәңгәрсу пәрдә аша Наратбаш күренә, аның яныннан борыла-сырыла аккан Ык елгасы тип-тигез булып килә дә, үзенең көмеш сулары белән шушы ике өркәчнең итәген юып, юлын дәвам итә: иске тегермән янына җиткәч, тыныч көннәрдә дә шактый еракка ишетелерлек кечкенә шарлавык ясый, аннары тагын өстен пыяладай тигез ялтыратып, еракларга юл ала.

Әхнәф анда-санда сап-сары куак булып утыручы янар чәчәк үләннәренә күз ташлады да шоферына:

— Рәис, әнә шул янар чәчәкләрнең коелмаганнарын пакетыңа бераз җыя тор әле, мин җәяүләп кенә төшәм. Утыз-кырык минуттан шунда килерсең, — диде.

Бу урыннарга Әхнәф ел саен булмаса да, исләреннән исереп егылып китмәле чабыр үләне, чәнчә үлән җыярга хатыны Фәһимә белән килә, көзләрен җимешләрне дә шушыннан алып кайталар. Барысы да йөрәккә. Тормыш нервыларны, йөрәкләрне яндыра тора, ә табигатьнең шифалы үләннәре,

җимешләре ныгыта, кабат сафка бастыра. Шушы янар чәчәкнең бер генә чеметемен суда төнәтеп бер генә кашык эч — йөрәгең тынычланыр, тәнеңә рәхәт изрәү таралыр.

Үзәнлеккә төшеп, сыек зәңгәр төтен күтәрелгән, машиналар туктаган, халык мәш килеп ял иткән урынга таба атлады, күкрәген киереп, тирән итеп сулады. Хуш исләрдән исермәле иде. Сагызлы каен яфраклары, яшь үлән, язгы чәчәк, туфрак исләре, бергә куерып, үзәнлектән Ыкка таба дулкын булып агыла, гүя алар синең борыныңны кытыклап кына үтмиләр, ә бәлки бөтен тәнеңә, каныңа, җаныңа сеңәләр. Аны баядан бирле, агачтан агачка күчә-күчә, бер шыркылдык саескан озата барды. Ахырда ул чәчәкләре коелып бетмәгән зур гына алмагачның ботагына килеп кунды, ботак селкенеп китүгә, чәчәк таҗлары ябалак кар бөртекләредәй аска коелдылар. Табигатьнең ямен күрү, тою ягыннан караганда, кошлар кешеләрдән күп мәртәбә бәхетлерәктер дип уйлап куйды Әхнәф. Алар менә бу гүзәллекне өстән күзәтәләр, теләгән урыннарына төшеп куналар. Алар биредә исәпсез-хисапсыз җан иярен — зәһәр сызгырып, җәй буе бер-берсе белән сөйләшүче йомраннарны, сизгер куяннарны, хәйләкәр төлкеләрне, нәзакәтле кыр кәҗәләрен, үлән араларын айкаучы җитез кәлтәләрне үчекләп, өсләреннән фырылдап узалар, агач башларына кунып, аларга дәшәләр, тагын һава дулкыннарына күтәрелеп, теләгән җирләренә, Ык өсләп Наратбаш ягына очалар, су өстендә акчарлаклар белән очрашалар, үз телләрендә чыр-чу киләләр, аннары талчыккан канатларын ял иттерү өчен Әби тавы башындагы мәһабәт имәннәргә барып куналар. Әйе, валлаһи, кошлар кешеләрдән бәхетлерәктер! Әле яз, әле май азагы гына. Ә җәйләре! Биредәге җиләк-җимешләрнең беркайчан да җыелып беткәне юк. Биредәге печәннәр чапкан артыннан үсә баралар. Нинди юмарт, нинди бай, нинди мәрхәмәтле җирләр! Күзләрен бирегә килсәң, меңнәрчә төсләрдән күзләрең камаша. Ә кышның шушы хуш исле җирне энҗе-мәрҗән кебек җемелдәүче кар бөртекләре белән каплаган чаклары! Биредәге җәнлек! Кош-корт, чаңгы, чана эзләре!

Әхнәф, хис-тойгылар дулкынында бара-бара, бәйрәм ясаучылар янына килеп җиткәнен сизми дә калды. Биредә барысы да гармун, җыр-бию тавышларына күмелгән. Бер якта шашлык пешә, чирәмгә җәелгән озын клеенка өстендә сый-нигъмәт. Аның каршына совхоз директоры Фаяз Шәймөхәммәтов, партком секретаре Сабирҗан Нуриев, эшчеләр комитеты рәисе Әнәс Нәбиуллин йөгерә-атлый килеп җитте, табынга чакырдылар. Әхнәф халыкның инде шактый кызганлыгын бер карауда сизде. Моның шулай икәнлеген Нуриев белән Нәбиуллинның бурлаттай кызарган йөзеннән дә ча-

малап була иде. Игенчеләрне бәйрәм белән котлаганнан соң, аны табынга чакырдылар. Шунда ул Нәбиуллинның матур читекләр, бәби итәкле ал күлмәкләр, зәңгәр камзуллар кигән кызлар тирәсендә бөтерелүен, ниндидер күрсәтмәләр бирүен күрде. Кинәт дәртле бию көе яңгырады, һәм кызлар тезелешеп бии-бии аның каршына килделәр дә түгәрәк ясап уратып алдылар. Әхнәф уртада калды. Кызлар биеделәр, халык бердәм рәвештә кул чапты, арада чегән төсле кара, биле өзелеп чыгардай нечкә, бераз кысыграк шомырттай күзләреннән ут чәчеп торучы бер кыз бар иде. Ул үзенең карашы белән Әхнәфне көйдереп-көйдереп алды. Ахырда башкалар читкәрәк таралды, һәм кыз, уртага чыгып, аны биергә чакырды. Әхнәф түзмәде, әллә нинди эчке дәрт белән очынып биергә кереште. Ул үзенең начар биемәгәнен белә иде. Кыз белән алар, алдан репетиция ясагандай, төгәл хәрәкәтләр аша тулы бер сюжет ясап биеделәр. Әхнәф бию хәрәкәтләре белән аңа мәхәббәтен белдерде, кыз ялындырды, читкә тайпылды, Әхнәф каршы төште. Ахырда алар кулга-кул тотышып, кара-каршы биергә керештеләр. Әхнәф кызның бер кулын бармакларыннан тотып өскә күтәрде, кыз күз иярмәс тизлек белән шул хәлендә аның алдында бөтерелеп торды. Бию аларның култыклашып әйләнүе белән тәмам булды. Халык Әхнәфкә мактау сүзләре яудырды, рәхмәт әйтте, туйганчы алкышлады. Биегәндә Әхнәф кызның Сылу исемле икәнен белеп калды.

Алкышлар тынгач, Әнәс Нәбиуллин:

— Менә, Әхнәф Хәсәнович, сез безне генә биеткәндәй түгел, без дә сезне биеттек әле, — диде.

Аның бу сүзләренә тагын гөрләтеп кул чаптылар. Берничә минуттан, хуҗалар белән хушлашып, Әхнәф кайтырга кузгалды. Ул бик тә канәгать иде.

Өйгә кайтып чишенүгә, Фәһимә аңа бик игътибар белән сынап карады, йөзенә ягымлы елмаю җәелде, Әхнәф аптырап аңа карады.

— Нидер бар бугай, карчык...

— Бар шул, — диде Фәһимә, серле елмаеп.

— Йә, әйт инде, сузма.

— Рәхмәт, карткаем, — диде Фәһимә, аның муеныннан кочаклап, кайнар иреннәре белән иреленнән үбеп алды. — Синең бүген салмыйча кайтып керүең минем өчен зур бәйрәм булды.

Әхнәфнең йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыкты.

— Бигрәк инде син, Фәһимә. Әйтерсең мин һәр көн эчеп, исереп кайта торган кеше.

Фәһимә аның кулына үзенең йомшак, кайнар кулын салды.

— Дөрес әйтәсең. Ләкин мин бүген бер нәрсә өчен бик нык борчылган идем. Әгәр син районның дүрт-биш хуҗа-

лыгында берәр генә йотым аракы капсаң да, моның халык арасына таралуыннан курыккан идем. Халык бит хәзер синең һәр хәрәкәтеңне күзәтә, бизмәнгә сала. Эчәрме беренче секретарь, юкмы? Әгәр син эчеп куясың икән: «Әһә, — диләр, — Беренче эчә икән, нигә безгә ярамасын?» Табын янында булганнары булмаганнарыннан сораштыра: Беренче нишләде, эчтеме-юкмы? Бөтенесен шушы әйбер генә кызыксындыра. Синең бер кабуың инде иртәгә бөтен районга чиләге белән эчкән булып тарала.

— Рәхмәт лекцияң өчен, — диде Әхнәф, елмаерга тырышып. — Мин дә нәкъ шулай уйлаган идем.

— Уйларыбыз туры килгәндә ничек әйбәт, — диде Фәһимә, аны тагын ирененнән үбеп.

Төнлә Әхнәф куркыныч төш күрде. Имеш тә, әтисе-әнисе белән җиткәләшеп яшел болын уртасыннан баралар. Нидер сөйләшәләр, көлешәләр. Көн якты, күктә серле булып кояш балкый. Шулчак алда биек яр күренә. Әхнәф нишләптер кызыгып шул ярга таба атлый. Яр астыннан моңлы музыка ишетелә. Әтисе белән әнисе, аны кулларыннан тотып, ярга бармаска кушалар, ялыналар, ялваралар, тыялар. Ә инде ул чакта Әхнәф яр кырына җиткән, аның астындагы әлеге серле музыка үзенә чакыра. Анда чәчәкле яз, анда тәмлетәмле җимешле агачлар үсеп утыра, аллы-гөлле чәчәкләр хуш ис бөрки. Әтисе белән әнисе аны һаман читкә тарталар, ә ул көлә-көлә яр астыннан күтәрелеп торган иң эре, иң зур чәчәккә үрелә, үрелүе була — шул чакта аяклары җирдән аерылып, гәүдәсе, җиргә төшкән яфрак кебек, салмак кына тирбәлә-тирбәлә аска төшә башлый. Үзе туктаусыз көлә, әтисе белән әнисенә кул болгый, аларны үзе янына чакыра. Кинәт Әхнәф эсселе-суыклы булып китә: ул инде күз иярмәс тизлек белән аска оча, теге матурлыкларның берсе дә калмаган, инде өстә алсу шәфәкъ кара кургаш төсле тузан белән каплана бара... Ул үзенең гәүдәсе белән нindидер кара, куркыныч болытларны тишеп үтә, тагын нindидер текә, сары яр ышкылып кала, агач ботаклары битен сыдыра, үрмә гөл төсле сузылган нәрсәләрне ертып үтә, кулы белән аларны эләктермәкче була, әмма тота алмый, тотканы да өзелеп кала. Кинәт аның күзе аска төшә һәм йөрәге ярылгандай була: аста — бик еракта — меңнәрчә сөңгеләр очлары өскә каратып тезелеп куелганнар. Алар барысы да кып-кызыл. Әхнәф аларның үзенең төшүенә махсус кыздырып, әзерләп куелганлыкларын аңлый. Сөңгеләрнең кып-кызыл очлары коточкыч аксылланып, төтенләп-төтәп тә тора. Әхнәфнең йөрәге куркудан кысыла, ярдәм сорап кычкырмакчы була — тавышы чыкмый. Кызарып-төтәп торган дәһшәтле сөңге очларына килеп бәрелгәнен күрмәс өчен, күзләрен чытырдатып йома,

кулларын йодрыклый, тезләрен күкрәгенә кыса, бөтен гәүдәсен бер ноктага җыеп китерә. Колак төбендә ниндидер куркыныч улау ишетелә. Менә бәреләчәк... менә хәзер... авыртуны гына сизмәскә иде... Шул килеш юк булырга...

Шунда ул кинәт уянып китте. Йөрәге күкрәк читлеген җимерерлек булып тибә, ул еш-еш тын ала, үзе шабыр тиргә баткан, бөтен тәне дер-дер калтырый, күзән җыергандай тартыша. Мондый куркыныч төштән уянгач, Әхнәф, шатланып, җиңел сулап куя торган иде. Әмма бу юлы, ни гаҗәп, җиңел сулый алмады, күңелен шом басты. Ул бик озак уйланып ятты, шомланырлык-хәвефләнерлек берни дә юк иде. Районда эшләр майлагандай бара. Әллә очраклы гына төшме? Уйлана торгач, ул телевизордан кичтән караган сөңгеләр белән сугышу вакыйгалары тәэсиредер дип тә гөманларга тырышты. Әмма нишләптер шом китмәде, ниндидер хәвеф-хәтәр булыр кебек тоелды...

* * *

Әнәснең күңеле күкнең җиденче катында иде. Совхоз эшчеләрен менә шушылай җыеп бәйрәм иттерү аның өчен иң бөек көн була. Ул көнне синдә нишләсәң дә сүз әйтүче юк, син оештыручы, син продукция аласың (бераз үзеңә дә эләгә), аш-суын әзерләтәсең, аракысын, башка эчемлекләрен тиешле урынына ташыйсың. Бөтен халык синең чабулавыңны, ничек тырышып йөрүеңне күреп тора, син бу бәйрәмнең дирижерына әвереләсең. (Бәйрәмнән соң бәйрәм итәргә әле тагын бер атналык запас та кала.) Мондый чараларның иң әйбәт ягы шунда: сине эшлексез, бушка акча алып ята, тагын әллә ниләр дип сүгүчеләрнең, сине яратмаучыларның дәрте басыла, кикрикләре шиңә. Син бүген эшлисең, мине күрегез, дисең, минем бер минут та вакытым юк, дисең, мин халык өчен җанымны ярып бирергә дә әзер, дисең.

Бүген дә шулай булды. Шәймөхәмматов бүлмәсендәге нәрәттән соң Әнәс: «Мин оештырырга киттем», — диде дә иң элек яраткан гадәти эшеннән башлады: хатыны эшкә киткәч, кайтып әйбәтләп ашап, бер чөлне салып куйды. Аннары бәйрәм тәгәрмәче су тегермәне куласасы кебек әйләнергә кереште. Аерма шунда гына иде: ул куласага су урынына туктаусыз аракы акты, ә куласа урынында Әнәс бөтерелде. Беренче секретарь килгәндә, аның инде битләре, муеннары иртә өлгерә торган «башкирская красавица» алмасы кебек алланып чыккан иде. Шәрифуллинны биеткәч, аны кешеләр: «Ай, шәп иттең, ну шәп тә итеп әйттең!», — дип мактадылар, кулын кыстылар, аркасыннан сөйделәр. Әнәс күңелендәге патриотик хисләр, бөтен дөньяны ярату тойгысына әверелеп,

бу кешеләрнең һәрберсен кочаклап үбәсен китерде, ләкин бу физик яктан мөмкин түгел иде. Шуңа күрә Әнәс җитешә алганнарын гына үпте, калганнары үпкәлиләрдер инде дип көяләнде, шул арада, һәммәгезгә дә җитешә алмыйм, гафу итегез дигән мәгънәдә әле бер, әле икенче якка баш иде. Дөньядагы искиткеч яхшы, ягымлы бу кешеләрнең кәефен күтәрергә кирәк иде. Ул күңеле белән нидер җитмәгәнлеген аермачык тойды. Күптән кузгалган кайнар хисләре аны диалектика кануннары буенча шул җитмәгән нәрсәне эзләттеләр. Әнәс Нәбиуллин үзен Мәскәүнең Съездлар сарае сәхнәсендәге кебек хис итте. Әйтерсең лә бөтен партия, дәүләт җитәкчеләре, политбюро, Верховный Совет президиумы членнары борыннарын сузып, күзлекләрен елтыратып аңа төбәлгәннәр, яннарында утыручы хатыннары бигрәк тә зур өмет белән Әнәстән нидер көтәләр. Бередәге халыкны ул шулай күз алдына китерде. Балачактан ук Әнәс нидер җитмәүчелек чире белән авырый иде. Кечкенә буйлы булганлыктан, аңа гомере буе буй җитмәде, егет булгач, мыек-сакал чыкмаудан җәфа чикте. Тавышы, үч иткәндәй, нечкә килеш калды, калынлык җитмәде. Шушы һәм башка җитмәүчелекләрен ул сәхнәгә чыгып җиткерергә теләде. Үзенең башкалардан артыграк якларын күрсәтмәкче булды: биеде, җырлады, нәфис сүз сөйләде, спектакльләрдә уйнады. Комсомол, партия җыелышларында һәрвакыт чәчрәп торып чыгыш ясады. Җитмәгәннәрне шушылар белән капларга тырышса да, аның күңелендәге кимсенү беркайчан да югалмады. Менә хәзерге минутларда әлеге тойгы үзенең апогеена күтәрелде. Ул Әнәсне һава шары кебек очырып алып китәр төсле иде. Шуңа буйсынып, эшчеләр комитеты председателе, аяк астыннан тузаннар очырып, ялгызы биергә кереште. Аның аягы җиргә тисә тиде, тимәсә тимәде, ул бөтерелә-бөтерелә биеде, бии-бии костюмын да салып ыргытты. Язган сарык йонын хәтерләтеп, алар турында туктап торучы күктәге ак болыт өемнәрен таратырга теләгәндәй, кулларын югары күтәреп, туктаусыз һаваны айкады, учларын бер-берсенә бик каты бәреп чәбәкләде, үзеннән туктаусыз тир акты, авызы йомылмады, елмайды да елмайды. Ләкин һаман нидер җитми иде. Биюен тагын да камилләштерү максатында, ул чүгә-чүгә табынга якынлашты һәм, кемдер ыргыткан буш шешәгә аягы эләгеп, чалкан тәгәрәп китте. Халык күтәрелеп көләргә кереште. Әнәс ничек егылган булса, шундый тизлектә сикереп торды һәм шешәне борынынннан эләктереп алды. Шешә борын тишегеннән телен күрсәтеп, аны үчекләгән кебек тоелды. Аның аркасында көлкегә калырга ярамый, ә бәлки шешәнең үзен көлкегә калдырырга кирәк иде. Шул вакыт аның башына шалт итеп искиткеч фикер килде: фокус! Фокус күрсәтергә! Егет чак-

та аның күз иярмәс тизлек белән чөл шешәсен чалбар биленнән тыгып җибәреп, балак очыннан алып, халыкны хәйран калдыра торган гадәте бар иде. Кайларда гына күпме мәртәбә күрсәтсә дә, бернинди сере булмаган бу манипуляциядән егыла-егыла көләләр иде. Әнәс нәкъ менә шушының җитмәгәнлеген аңлады. Ходай аны шешәгә абындырып, бүгенге тантананың чишелешен төртеп күрсәткән иде, ахрысы. Ул шешәне югары күтәрде дә, борынын аска каратып, чалбар биленнән кертеп җибәрде. Ләкин ни сәбәпледер шешә түбән төшмәде, чалбар төбе тирәсендә буталып калды. Кул белән ярдәм итү дә, сикергәләп карау да көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Шунда гына Әнәс шешәнең трико эченә үк кереп киткәнлеген аңлады. Ләкин аның зиһене искиткеч үткенлек, тапкырлык белән тулган иде. Ул җәһәт кенә кулын кесәсенә тыкты да шешәне, уртасыннан эләктереп, борын ягы белән алга каратты. Бу бик тә нәтиҗәле булып, чалбарын төртеп, шактый алга чыкты. Кемнәрдер тыела алмыйча көләргә кереште, кемнәрдер тыела алмыйча кул чапты, кемнәрдер «молодец» дип кычкырды. Бу тамашага хәйран калгандай, Назыйм Әшрәфҗановның үзенә охшаган, иреннәре салынып төшкән карт бурзае килеп, шешә борыны турын иснәп тора башлады. Аннан берничә тамчы сыеклык та чыгып, чалбарга җәелгән иде. Ләкин эт озак тормады, борынын җыерып китеп барды. Баянчы тагын бию көе уйнап җибәрде. Әнәс шешәне тоткан килеш биергә кереште. Кояш яктысында чалбарыннан тырпаеп торган шешәнең җиргә төшкән шәүләсен күргәч, Әнәс үзенең бу чыгышының искиткеч нәтиҗәле икәнен аңлады. Наратбаш халкы гына түгел, бөтен СССР халкының да мондый тамашаны күргәне юк һәм күрәчәге дә юк. Нык тырышудан Әнәснең үзенең борыны да, көчле җилгә куйган шешә борыны кебек, сәер тавышлар чыгара иде. Әйтерсең лә ул борын эчендә каен тузының юка тышкы катламы куелган һәм ул менә хәзер, менә хәзер сызгырып китәм дигәндәй тавышлар чыгара, вакыт-вакыт бер ягы кубып җилфердәгәндәй фырылдап та куя иде. Шулчак кайсыдыр юньсезе, әллә изге ният белән, әллә болай гына, аның аяк астына гел майдан гына торган бер кисәк шашлык ыргытты. Әнәс, төзәп баскандай, нәкъ үкчәсе белән аңа китереп басты һәм, таеп, арт ягына тәкмәрләп китте. Баядан бирле нишләргә белмичә чарасыз торган Фаяз Шәймөхәммәтов аны сыңар кулы белән генә чалбар биленнән тотып күтәрде дә тизрәк читкә алып китте. Әнәс корт чаккандай аягына басты. Аның күзләре гарьләнүдән әллә нинди очкыннар чәчәләр иде.

— Нәбиуллин, әллә син ычкындыңмы? Ничек оялмыйсың?! — дип пышылдады аңа директор.

Ярсудан, хурланудан Әнәс буылды, сүзен әйтә алмыйча

азапланды. Ниһаять, тамак төбеннән ачулы ут булып сүгенү сүзе чыкты.

— Нәрсә эшләгән мин?! — диде ул шуннан соң һәм Фаязның күкрәгенә китереп төртте.

Шәймөхәммәтов аны, чиерткән төсле генә итеп, маңгаеннан этеп җибәрде, Әнәс ике-өч адым чигенде дә, чалкан китеп, өркәчнең авыш җиреннән аска тәгәрәде.

— Бәйрәмне бозып йөрмәсен, кайтарып куегыз, — диде директор янындагы егетләргә.

Кич Әнәснең хатыны елап Арслановка шылтыратты, булган хәлне җентекләп сөйләп бирде.

Миңзаһит, аны тыңлап тәмам арыгач:

— Хәзер үк миңа килсен, — диде.

— Ул берни белмичә йоклый.

— Алайса, иртүк җибәр.

Әнәс иртәнге алтынчы яртыда килеп җитте. Аның йөзе кайнар үтүк белән бастырып чыккан төсле, куллары калтырап тора иде.

— Нишләтим соң инде мин сине? — диде Миңзаһит, аның каршына басып.

Әнәс борынын тартып, башын аска игән килеш сүзсез басып торды. Миңзаһит кинәт ярсып аны типкәләргә тотынды, ләкин Хәят, арага кереп, аны читкә этте.

— Дуңгыз син! — диде Миңзаһит, ярсуыннан тыела алмыйча. — Мине позорить иттең! — Ул Әнәснең иягеннән тотып, башын югары күтәрде. — Кая барасың инде хәзер? Йә, әйт: бармы барыр җирең?

Әнәс елап җибәрде:

— Ай, ык ялгыштым мин, Миңзаһит абый!

— Күпме ялгышырга мөмкин? Ә?! Җавап бир! Күпме ялгыша кеше?! — Әнәс дәшмичә борынын тартып тора бирде. — Оятсызлар гына туктаусыз ялгыша. Синең намусвөҗданың калмаган. Шуңа күрә үзеңнең ни кылганыңны контролировать итә алмыйсың. Бар кайт! Иң элек Шәймөхәммәтовтан, Нуриевтан, специалистлардан, синең позорыңны карап торган һәрбер кешедән гафу үтен!

Әнәс чыгып киткәч, алар Хәят белән өстәл янында бер сүз дәшмичә, һәрберсе үз уена батып шактый утырдылар.

Хәят эшкә киткәч, Миңзаһит бакчага чыкты. Һәр көн үзәкләрне өзеп сайраучы сандугач килеп җиткән иде инде. Әй сайраплар да куя соң! Бәләкәй генә кошчыкның теле ничек шулай чәтелдәп тора, каян аның нәни күкрәгенә шулкадәр моңнар сыйган?! Иртә сайрый, кичләрен дә сайрый, саргаеплар үлсен ди бугай, дип, халык юкка гына әйтмәгән икән. Миңзаһит чатырына керә дә, сәгатьләр буе, хәтта тәмә-

ке дә тартмыйча, шул кошны күрмәкче булып посып утыра. Юк, күренми сандугач, сыңар ботак та селкенеп карамый. Аны күрергә теләве юкка гына түгел. Үз күңеленең дә иң тирән чоңгылында билгесез нәрсә көйрәп ята, сандугачны тыңлаган саен, бәгырен телеп, күренмәс үткен кыл кебек, җанын урталай телеп уза... Ул аңлаешсыз әйбер инде кайчаннан бирле җәфалый, баш ваттыра. Аның ни икәнен Кәрәм Нәҗмиев килгән көнне, ниһаять, аңлады Миңзаһит. Биредә үтә рәхәт булса да, җаны-тәне белән тугарылса да, сандугачлар сайрап торган шау чәчәкле алмагачлар төбендә гомер итеп, яшәвен монда төгәлләргә риза түгел икән бит ул! Болай тереклек итү никадәрле матур, шигъри һәм бөек булуына карамастан, ул инде үзенең мондый тормыш эргәләренә ятмый торган бүрәнә икәнлеген аңлап бара иде. Мүкләп, чутлап салсаң да юк, бүлтәеп чыгып, ул барлык диварларны бозачак кына...

Бая Әнәсне типкәләгәндә, Миңзаһит аны түгел, үзен типкәләде, күңелендәге тынычлыгын алган әлеге кылны өзмәкче булып типкәләде. Әмма абзарга ябылган ат күпме генә ярсып тибенсә дә, киртәләрне җимерә алмаган кебек, ул кылны өзә алмады. Киресенчә, кыл тагын да сиздеребрәк тартылды, аның әлегә бик тирәндә көйрәгән уты сандугач тавышлары тәэсирендә өскә таба юл алды. Миңзаһит аның тиздән йөрәгенә үк килеп җитәчәген һәм дөртләп кабыначагын ачык сизде...

## 5

Элек райкомга чакыртсалар, Ирекнең йөрәге кысылып куя торган иде. Бүген ул аның баскычларыннан тып-тыныч күңел белән югары күтәрелде. Дөрес, башында «Әхнәф ни өчен чакырта икән?» дигән уй бөтерелде, ләкин ул аны һич тә борчымады. Аның җаны тыныч, беркем алдында да бурычы юк, кемдер биргән күрсәтмәләрне үтәү өчен чыгып йөгерәсе юк. Кабул итү бүлмәсендә шактый кеше җыелган булып чыкты. Секретарь кыз аның килгәнен хәбәр итү белән, Әхнәф Ирекне чакырды. Алар кочаклашып күрештеләр.

— Иҗатыңнан бүлгән булсам, гафу ит, дустым, — диде Әхнәф, аңа урын күрсәтеп. Үзе түргә бармады, Ирекнең янәшәсенә утырды.

— Бу арада иҗат эшләре бакча тирәсендәрәк йөри әле, — диде Ирек, аның сөрмәле зәңгәр күзләренә туп-туры карап.

— Ә син язны ычкындырма, анда бит синең ындыр артында табигатьнең чын мәгънәсендә туй иткән чагы. Иҗат кешеләре илһамны шуннан алалар, диләр. Дөресме?

— Минем өчен алай түгел бугай ул. Көн саен эшләгәндә генә илһам килә.

— Дөрес әйтәсең, иҗат кешеләренә дә үзләрен билгеле рамкада тотар өчен көн саен эшли торган эш кирәк, дустым, — диде Әхнәф, кулын аның иңбашына салып. — Минем читтән редактор китертәсем килми. Алын шул эшкә, зинһар өчен.

— Без бит бу хакта сөйләштек инде, Әхнәф.

— Сөйләшүен сөйләштек, аннан соң күп сулар акты, язгы җилләр исте, чәчелмәгән басулар чәчелеп, игеннәр шытып чыкты. Бөтен дөнья үзгәрә, синдә дәниндидер үзгәреш булырга тиеш бит инде.

— Юк, Әхнәф, мәҗбүриләмә, — диде Ирек, аның кулын иңбашыннан алып куеп.

— Соң, тик ята алмыйсың ич инде син. Әрәмтамак дип закон нигезендә җавапка тарттырам мин сине.

Әхнәф рәхәтләнеп көлеп җибәрде, Ирекнең иңбашына җиңелчә генә төртеп алды.

— Эшләргә кирәк, әлбәттә. Ә редакциягә килгәндә... Беләсеңме, теге вакытта Арсланов районнан куган Мәкъсутов Чаллыда эшли ди бит. Чакырт шуны. Бер дигән редактор ул.

— Ярый, ярый, уйлашырбыз, — диде Әхнәф, сак кына. — Алайса, мин сиңа бик тыныч эш тәкъдим итәм. Безгә музей директоры кирәк. Бинасы иске, акрынлап ремонт та ясарбыз. Алынасыңмы?

— Менә анысы хакында уйлап карамын, — диде Ирек.

— Әгәр син анда эшләсәң, акрын гына район тарихын да яза башларга кирәк иде. Гомер уза бит.

— Шушы изге ниятең өчен генә дә, мөгаен, ризалашырга туры килер, — диде Ирек, елмаеп.

Шул вакыт телефон шылтырады.

Әхнәф трубканы тыңлап кире куйды да ярым пышылдап Ирекка:

— Арсланов килгән, кабул итү бүлмәсендә утыра, — диде. — Бер атна керергә йөри инде. Юри кырык төрле сәбәп табып, тинтерәтәм тегене.

— Ай-яй, үчлекле икәнсең, — диде Ирек, көлемсерәп.

— Ә син? Аңардан үч алмас идеңмени?

— Белмим, — диде Ирек, башын чайкап.

— Белмәвең бик начар.

— Ярый, мин киттем, — диде Ирек, урыныннан торып. — Ә шулай да син аны кабул ит инде. Алай йөртмә.

Ирек чыгып китүгә, бүлмәгә Арсланов килеп керде. Ул эшләгән вакытларына караганда да пөхтәрәк киенгән, яхшылап кырынган, сөртенгән — хушбуй исләре бөркеп тора иде. Кул биреп күрешкәч, бер генә мизгелгә күзгә-күз карашып

тордылар. Һәркайсы каршысында басып торучының күзеннән үзе көткәнне: Әхнәф — рәнҗеш билгеләре, Арсланов җиңү тантанасы эзләде. Икесенең дә уйда тоткан өметләре акланмады. Рәнҗеш тә, тантана да юк иде.

— Күптән күренгәнегез юк, Миңзаһит Усманович, — дип сүз башлады Әхнәф. — Ни хәлләрдә ятасыз?

— Безнең эш беткән бит инде. Ашыйбыз да телевизор карыйбыз.

Алар кара-каршы утырдылар. Күрәсең, секретарь кыз алдан кисәтелгән иде, ул, керт-керт атлап, түр бүлмәгә кереп китте һәм кечкенә поднос белән ике чынаяк чәй, печенье, конфетлар алып чыкты.

— Бөтен җирне ремонтлагансыз, акча бирделәрмени? — дип сорап куйды Арсланов, чәенә лимон салып.

— Таптык инде. Бик нык эзләсәң, табыла бит ул.

— Анысы хак. Эзләсәң, табыла. Безнең Әнәс Нәбиуллин да тапкан бит әнә. Турысын гына әйткәндә, мин шуның мәсьәләсендә сөйләшмәкче идем, Әхнәф Хәсәнович.

— Да-а-а, әйбәт булмаган, — диде Әхнәф, йөзенә җәелә башлаган елмаюын тыеп. — Директоры кергән иде. Аңа да кул күтәргән бит ул.

— Шәймөхәммәтовның фикере ничек соң?

— Ничек булсын, билгеле инде...

Алар икесе дә шунда тынып калдылар, ваклап-ваклап чәй йоттылар.

Тынлыкны Арсланов бозды:

— Миңа бирегә килүнең, кабул итү бүлмәсендә көтеп утыруның, синең каршыга керүнең авырлыгын белсәң син, Әхнәф Хәсәнович. — Миңзаһитның башы сүз әйткән саен түбәнрәк иелде. — Минем эчке халәтемне берничек тә аңлатып бирү мөмкин түгел...

Әхнәф аңа шактый вакыт текәлеп карап торды.

— Аңлатырга кирәкми дә, — диде ул, тыныч кына. — Минем кебек әле генә эшли башлаган бөҗәккә филнең баш иеп килүе... Мин аңлыйм... Җир йөзендә кешеләрне горурлык харап итә. Ул коточкыч агу кебек. Еллар буе кеше насос белән кертгәндәй тутырыла, кабара да кабара. Үзе утырган кәнәфигә генә түгел, яшәгән җиренә дә сыймый башлый...

— Сүзләреңнең миңа кагылганын бик яхшы аңлыйм.

— Юк, Миңзаһит Усманович. Бу — гомуми канун, барыбызга да кагыла.

Арсланов кинәт башын күтәрде, күзләрендә элекке усал очкыннар уйнап алды.

— Бик тиз акыллыланып киткәнсең әле син, Әхнәф Хәсәнович.

— Урыны шундый бит. Монда утыру белән акыл керә.

Нишләп алай икән ул? Югарырак үрләсәң, тагын да акыллырак буласың.

Арсланов урыныннан сикереп торды:

— Минем белән болай сөйләшмәскә киңәш итәр идем, — диде ул, һәр сүзенә басым ясап. — Әле бит арыслан үтерелмәгән, тешләре дә, тырнаклары да исән. Кемнәрнеңдер оста корган тозагына эләгеп кенә харап була язды. Ну что ж, бывает. Мине Казанга эшкә чакыралар, Әхнәф Хәсәнович.

— Ишеттем, ишеттем, — дип куйды Әхнәф. — Сезнең кебек кадрны ничек эшсез калдырсыннар инде.

— Так что, безгә бер-беребездән башка яшәү юк.

Әхнәф берaзга гына уйланып торды. Чыннан да аның элемтәләре җитәрлек. Өлкә комитетындагы дусты бу хакта аны кат-кат кисәткән иде. Шуңа күрә ул көчәнеп булса да елмаерга, арысланның йонын уңайга сыпырырга мәҗбүр булды:

— Турысын әйттем, күңелегезгә авыр алмагыз.

— Ярый, вакыт югалтмыйк. Син аны, Әхнәф Хәсәнович, ичмасам, партиядән чыгарма инде.

Әхнәф, кулын артка куеп, бүлмәне акрын гына урап чыкты да Арслановның каршына ук килеп басты һәм күзләренә туп-туры карап болай диде:

— Сез үзегез мондый очракларда бер дә жәлләми идегез бит, Миңзаһит Усманович.

— Моныкы аерым очрак. Бары тик үзегезгә генә әйтәм: ул минем абыемның малае. Ләкин ул бер яше тулганчы ук асрамага алынган малай. Хәтта кайсы милләттән икәне дә билгесез. Бәләкәйдән үк бөтенләй башбирмәс, ялганчы, тәртипсез булды. Аның белән чиләнә торгач, абый белән җиңги икесе дә инфаркт алдылар. Аны кеше итәм дип, минем дә чәчләрем аз агармады. Әгәр дә ул хәзер партиядән чыгарылып эшсез калса, мин нәрсә буласын уйларга да куркам. Монда аның үз язмышы гына түгел, хатыны белән балаларыныкы да, абый белән җиңги язмышы да үлчәүгә салынган.

Арсланов тынып калды.

— Мин сезне аңладым, — диде Әхнәф, авыр сулап. — Аны жәлләп, нинди үрнәк күрсәтәм соң инде мин?

— Турысын әйтәм, мин үзем жәлләмәс идем, — диде Арсланов. — Ләкин син моны булдыра аласың. Мондый игелекле адымнар, гафу итүләр әле сиңа кирәк. Халык бит Әнәснең моны усал ният белән, явызлык белән эшләмәгәнлеген бик яхшы аңлый.

— Анысы шулаен шулай. Үтерүче, талаучы, көчләүче дә үзенең җинаятен мин дә кешечә яшәргә тиеш дигән уй белән башкара. Атабыз Адәм белән анабыз Хава да үз балаларын изге ният белән яратканнар. Ә җир йөзендә мәхшәр.

— Рәхмәт, аңладым, — диде Арсланов, ишеккә таба кузгалып.

— Миңзаһит Усманович, син тәртәне кинәт сындырма әле! Партиядә калдырган сурәттә дә совхозда эшли алмый бит инде ул.

— Анысы белән килешәм, — диде Арсланов, чыга башлаган җиреннән туктап. — Бәлкем, Болынкырда берәр тишек табылыр?

— Былтыр эткә ашарга биргәч, сыртын яратып сыпырган идем, беләкне тешләде дә алды.

Аларның күз карашлары тагын очрашты. Бу карашлар инде хәзер берни дә эзләми, әмма бик җитдиләнгәннәр иде.

— Кулыгызны Нәбиуллин ялап кына торыр, тешләмәс, — диде Арсланов, ярым пышылдап. — Анысы өчен үзем ручаюсь.

Сүз шуның белән тәгәлләнде, алар кул биреп аерылыштылар.

## 6

Нинди көн булды соң бу? Кайбер көннәрне эшкә киләсең дә тәгәрмәчтәге тиен кебек бөтерелә башлыйсың: әле райкомга чакыралар, әле ишек төбенә кешесе җыела, әле Казаннан, әле авыллардан шылтыраталар. Көннең ничек үткәнен дә сизмисең. Әйтерсең лә бөтен дөньяның кендеге сиңа береккән, әйтерсең барысы да сиңа карап торалар, синең фәрманыңнан башка берни дә эшли алмыйлар. Андый көннәрдә арыйсың, талчыгасың, әмма эш көне бетеп өеңә кайтканда ниндидер канәгатьләнү кичерәсең. Бу үзенә күрә рәхәт талчыгу, канәгатьләнү халәте була. Ә менә бүген, үч иткәндәй, Сөембикәгә беркем дә шылтыратмый да, туктаусыз булып тора торган киңәшмәләр, җыелышлар да юк, ишек төбендә чират көтүчеләр дә күренми. Ичмасам, кем дә булса керсен иде. Сөембикә шулай дип уйлап бетерә алмады, ишек шакыдылар.

— Керегез, — диде ул, эчке куану белән.

Ишек акрын гына ачылды, һәм анда Кәбировның йөзе күренде.

— Әйдә, кер, Мөнир абый, уз, — диде Сөембикә, аңа каршы барып.

Кәбиров ничектер моңа кадәр булмаганча сак, куркулы карашы белән Сөембикәне, бүлмәне капшап чыкты. Аны каршына утырткач, Сөембикә аптырап китте: туганнан туган абыйсы шактый картаеп, ябыгып киткән, чәчләре коелмаса да, көмештәй чаларган, кашлары гына кап-кара килеш иде.

— Ни хәлләрдә ятасыз, абый?

— Казаннан кайтып килешем. РКБга барган идем.
— Әйе, ишеткән идем.
Кәбиров башын аска иеп, уйланып торгандай итте, борынын тартып куйды.
— Миңа теге чир эләкте бугай...
Аның нәрсә турында әйткәнен Сөембикә бик яхшы аңласа да, шик-шөбһәсен таратырга теләп:
— Хәзер барыбыз да шуны эзлибез инде, — дип куйды. — Йөрәге авырткан бар кешегә инфаркт диагнозы куялар. Ә кеше дигәнең җир җимертеп яши бирә.
— Рәхмәт яхшы сүзең өчен, үт куыгы ялкынсынган, диләр. Үзебездә дәваланырга кушалар, дарулар билгеләделәр дә кайтардылар. Булырлык булса үзләре дәваларлар иде. Яшерә врачлар...
— Чирең җитди түгелдер, Мөнир абый. Син бит чүкеч кебек кеше, терелерсең.
— Рәхмәт, — диде Кәбиров, урыныннан торып.
— Хәзер чәй эчәргә кайтабыз, машинаны чакырам, — диде Сөембикә, телефон трубкасын кулына алып.
— Юк, юк, чакыра күрмә! Мине колхоз машинасы көтеп тора. Сиңа йомыш белән генә кергән идем. — Кәбиров беразга тынып торды. — Казандагы минем врачның әтисенең йомышы бар синдә.
— Кем соң ул? — диде Сөембикә, сәерсенеп.
— Син аны беләсең, Сөембикә. Ул ишек катында басып тора. Әгәр булдыра алсаң, зинһар, ярдәм кулыңны суз.
Кәбиров чыгып ишекне ябуга, аны кемдер шакыды һәм, Сөембикәнең тавышын ишетүгә, шакучы үзе дә килеп керде. Алар исәнләштеләр, Сөембикә бер генә мәлгә хәрәкәтсез калды. Бу кеше аңа бик таныш та, таныш та түгел кебек тоелды. Ниһаять, аның фамилиясе хәтеренә келт итеп килеп төште: Янчурин! Әйе, бу шул үзе, Янчурин иде. Какао төсендәге затлы плащы, шундый ук чалбары, замш туфлиләре, аксыл төрткеләр төшкән көрәнсу галстугы аның үзенең дә затлы кеше икәнлеген күрсәтә кебек. Сөембикә белгәндәге ялтырап торучы алсу битләр шактый эчкә batканнар, аның хәзер йөзе коры, вак җеп белән тартылгандай, нечкә җыерчыклар белән капланган. Озын гәүдәсе элеккедән дә ябыграк. Дулкынланудан Сөембикәнең сулышы кысылды. Янчурин аның тормышында иң күңелсез эз калдырган кешеләрнең берсе иде. Бернинди җинаяте булмаса да, Сөембикә артыннан ул нәрсәдер эзләп, аны гаепләү өчен дәлилләр тупларга килгәндер кебек тоелды.
— Тыңлыйм сезне, — диде ул, калтыранган тавыш белән.
Янчурин, озын гәүдәсен сузып, Сөембикәгә таба иелде һәм:

— Минем сезнең янга килүдән башка чарам калмады, — диде.

Сөембикә аның авызы тулы алтын теш икәнлеген күрде.

— Сез мине хәтерлисездер дип уйлыйм...

Сөембикә, кулларының калтыранганын күрсәтмәс өчен, аларны өстәл астына яшерде. Әгәр хәленнән килсә, ул бу кешене каргый-каргый бүлмәсеннән куып чыгарыр иде.

— Хәтерләмим, — диде ул, күзеннән зәһәр очкыннар чәчеп.

Янчуринның күзләре түгәрәкләнеп китте, йөзенә аптырау билгеләре чыкты.

— Мин бит сезгә Кәбиров артыннан күп мәртәбәләр сәлам юлладым. Ничә еллар буе... Әйтмәдемени?

— Тизрәк йомышыгызны әйтегез!

Әлбәттә, Сөембикә барысын да хәтерли иде. Аның сәламен тапшыргач, Мөнир абыйсына үпкәләп тә йөрде. Яңадан миңа аның турында бер сүз дә әйтмә, исемен ишетәсем килми, диде.

Янчурин ярым пышылдап сүз башлады:

— Әгәр сез ярдәм кулы сузмасагыз, мине утыртачаклар.

— Миннән ярдәм?! — диде Сөембикә, чыннан да гаҗәпләнеп. — Фамилиягезне ишеткәлим, газеталардан да укыштырам. Бик югары хокук органында эшлисез...

— Анысы шулаен шулай...

— Димәк, һаман да гаепсезләрне утырту, гаеплеләрне коткару белән шөгыльләнәсез.

— Беләсезме, Сөембикә Даутовна, бу гөнаһлы җир йөзендә гаепле кешеләр юк. Камил булмаган законнар гына бар.

— Сезнең телегездән кайчандыр «Җинаять кодексының фәләненче статьясы, Җинаять кодексының төгәненче статьясы» дигән сүзләрдән башка гыйбарә ишетелми иде.

— Сезнең үтенечегезне мин кире какмадым, — диде Янчурин, Сөембикәнең күзләренә туп-туры карап. — Менә хәзер үзем бик начар ситуациягә эләктем. Сез ярдәм кулы сузмасагыз, мине утыртачаклар. Дөресрәге, сезнең беренче секретарегызның йогынтысы кирәк.

— Юкәдә икән чикләвек! — дип куйды Сөембикә, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

— Минем язмышны хәл итүче кеше сезнең Шәрифуллин белән институтта бергә укыган, тулай торакта бер бүлмәдә торган. — Янчурин ул кешенең фамилиясен әйтте. — Шәрифуллин, теләсә, аңа йогынты ясый алачак.

Сөембикә кулларының гына түгел, бөтен гәүдәсенең калтырый башлавын тойды. «Күземнән югал!» дип кычкырып җибәрүдән аны ниндидер көч туктатты.

— Мине ришвәт алуда гаепләделәр, — диде Янчурин, башын аска игән хәлдә авыр сулап. — Бернинди гаебем юк... Дошманнарым оештырды...

Сөембикәнең аны әллә ничекләр итеп мәсхәрәлисе килде, әмма тыелып калды.

— Ярый, сөйләшеп карармын, — диде.

Янчурин ишек тоткасына үрелде.

— Мин сезнең каршыда мәңгегә бурычлы булып калам.

— Бурычлы булмассыз, мин, вакыты җиткәч, сезне үзем эзләп табармын.

Сөембикә аның адресын, телефоннарын язып алды да, коридорда Янчуринның аяк тавышлары басылуга, тәрәзәне һәм ишекне киереп ачып җибәрде. Өстәлдәге кәгазьләрне җилфердәтеп, үтәли җил йөри башлады. Бүлмәне җилләтеп була, ә менә Янчуринның үзен күңелдән берничек тә кырып ташлап булмый иде. Һич көтмәгәндә-уйламаганда килеп чыккан шеш кебек, ул ни үсмәде, ни тишелмәде, ничә еллар буе Сөембикәнең күңелен сызлатты да сызлатты... Бүлмә җилләгәч, ул ишекне япты да тәрәзә төбенә барып утырды. Аның уйлары шул ерак елларга юнәлделәр.

Сөембикәнең Кәшифулланың мәсхәрәләвен онытып бетереп килгән чоры иде ул. Беркөнне фермада Фәйзрахман хатыны Кәримә белән әнисе канга батканчы сугышканнар. Ызгыш сыерларга бирәсе фураж аркасында чыккан. Кәримә, имеш тә, аның әнисен фураж урлауда гаепләгән. Халык арасында сәбәп анда түгел, әнисенең Фәйзрахман белән шаяруында дигән хәбәр дә таралды. Кәриманең бер кабыргасы сынып, больницага баруы хак иде. Ул әнисен судка бирде. Әнисеннән туктаусыз сорау алдылар, шаһитларны авыл Советына чакырып, эшнең ничек булганлыгын ачыкларга керештеләр. Әнисенә кимендә өч ел төрмә яный иде. Сөембикә белән алар икесе дә мичтә янган кара күмер кебек көйделәр, чөнки язмышлары упкын читенә килеп терәлде. Беркөнне әнисе фермада чакта Мөнир абыйсы Сөембикә янына керде.

— Эш бик җитди төс ала. Кул кушырып утырырга ярамый, — диде ул, Сөембикәнең иңбашларыннан кагып.

Аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламакчы булып, Сөембикә Кәбировның күзләренә төбәлде.

— Нишләргә соң?

— Бүген тикшерүче монда. Ул ферма хатыннарын чакырта. Кеше беткәнен сагалап тор да янына кер. Коткаруын сора. Алар бит законны ничек телиләр, шулай боралар.

— Мине тыңлар дип уйлыйсыңмы? — диде Сөембикә, аптырап.

— Тыңлатырга кирәк. Башка чара юк.

Кәбиров урыныннан торды, инде чыгарга кузгалгач, Сөембикәгә таба борылып:

— Яхшы киемнәреңне киен, бизәнебрәк бар, — диде.

Сөембикә аның бу сүзләреннән аптырашта калды. Яхшырак киенеп, бизәнеп баргач ни була инде бу? Абыйсының ни әйтергә теләгәнен ул аңлады да, аңламады да кебек. Бизәнде, төзәтенде, иң яхшы туфлиләрен киде, ләкин аягы тартмады. Урамга чыгып, авыл Советы тирәсенә барды, анда кергән-чыккан кеше күренмәде. Эченнән генә күз яшьләрен йотып, тагын кире борылды. Каршысына Фәһимә очрады, ул Әхнәфнең мотоциклына утырган иде. Алар ике мәртәбә көлә-көлә Сөембикәне урап әйләнделәр дә нәкъ каршына килеп туктадылар. Аларның шулкадәр кәефле, шулкадәр шат булуларына Сөембикә көнләшеп карады, көчәнеп булса да елмаерга тырышты. Фәһимә аның хәлләрен сорады, кич килеп утырырга чакырды, мотоцикл белән район үзәгенә танцыга барырбыз, диде. Фәһимә Сөембикәләрнең нинди упкын читендә торуларын башына да китерә алмый, чөнки ул бәхет диңгезендә рәхәтләнеп йөзә иде. Сөембикәнең икеләнүе юкка чыкты. Ул, башын игән хәлдә җәһәт-җәһәт атлап, авыл Советына юнәлде. Бер тирән итеп сулыш алды да ишек шакыды. Тикшерүче Янчурин председатель өстәле артында утыра иде. Уң якта авыл Советы секретаре гарип куллы Камалиев нидер яза, ярты өстәлне алып торучы счет төймәләрен кәкре кулы белән чалт-чолт сала да нәтиҗәсен кәгазьгә язып куя.

— Мин Газизова кызы булам, сезнең белән сөйләшергә кирәк иде.

Янчурин дәшмичә генә аны баштанаяк карап чыкты да секретарьга таба борылды:

— Иптәш Камалиев, сезгә әбәткә кайтырга вакыт түгел микән?

— Ярый, ярый, хәзер...

Камалиев чыгып киткәннән соң, тикшерүче аңа урын тәкъдим итте. Янчуринның бөтен йөзе каз мае белән майлагандай елтырый иде. Хәтта борын астындагы нечкә генә матур итеп калдырылган мыегы да ялтырый. Иреннәрен теле белән әледән-әле ялаганлыктан, алар гел юешләнеп торалар. Аның күз карашы Сөембикәнең йөзеннән дә, матур тез башларыннан да йөгереп-йөгереп узды. Ул ничек итеп сүз башларга белмәде. Тиешле сүзләр таба алмыйча шактый вакыт торганнан соң:

— Әнкәйнең гаебе юк, зинһар, коткарыгыз, абый! — диде дә күз яшьләренә буылып еларга тотынды.

— Әниегезнең җинаяте кире каккысыз, аны ничек коткарыйм?

— Ул хатын бит үзе башлаган. Ул гомер буе әнинең күңеленә тоз салды. Иреннән көнләште бит ул.

— Ире Фәйзрахман килә идеме соң сезгә?

— Юк, — диде Сөембикә, кып-кызыл булып.

Фәйзрахманның килгәнен, әнисе белән эчеп тә утырганнарын белә иде ул. Ләкин бу хакта тикшерүчегә әйтәсе килмәде. Алай уйласаң, аларның өендә кереп салып утыручылар азмыни? Ирләре генә түгел, хатын-кызлары да җитәрлек.

— Син алдашасың! — диде Янчурин, аның күзләренә туп-туры төбәлеп.

Шунда Сөембикә аның күзләренең эчкә батканлыгын һәм хәтәр елтыравын абайлады.

— Мин сезгә дөресен әйтәм, — диде ул, үз тавышын үзе чак-чак ишетеп.

Янчурин, бүлмә буйлап йөри-йөри, аңа сорау арты сорау яудырды. Әнисе кемнәр белән аралаша, аларның өйләренә ир-атлардан һәм хатын-кызлардан кемнәр килә, җитәкчеләрнең булганы бармы, әнисе эчәме, аны кыерсытмыймы һәм башкалар, һәм башкалар.

Сөембикәнең башы тәмам тубал булгач, ул сәгатенә карады да:

— Төш вакыты җиткән икән. Әйдә, мотоцикл белән район үзәгендә ашханәдә сыйлап алып киләм, — диде.

Сөембикәнең кашлары җыерылды, күзенә курку билгеләре чыкты.

— Юк, юк! — диде ул, ишек катына йөгереп.

— Кешеләргә ышанмыйсың икән, — диде Янчурин, кисәтүле тавыш белән. — Сиңа бик авыр булыр ялгыз яшәве. Хатын-кызның бөтен бәхете ирләр белән уртак тел таба белүендә.

Тикшерүче тагын ниләр сөйләгәндер — Сөембикә ишетмәде. Ул күз яшьләренә буылган хәлдә урамнан йөгерә-йөгерә өйләренә кайтып бара иде инде...

Шуннан соң ничә көн үткәндер, анысын ул артык хәтерләми. Кич клубта район үзешчәннәре концерты бара иде. Бер егет үзенең җыры белән бөтен халыкны әсир итте. Моң дөньясына батып, күз яшьләрен сиздермичә генә сөртеп утырган Сөембикәнең иңбашына кемдер кагылды:

— Сине Кәбиров чакыра, чыгып кер әле.

Агыйделнең аръягында
Күлләр диңгез түгел ул.
Берәү моңлы, берәү моңсыз —
Дөнья тигез түгел ул...

Җыр өзелеп калды. Клуб ишегеннән чыгу белән, Мөнир абыйсы аны читкәрәк алып китте.

— Тикшерүче бүген монда, колхоз кунакханәсендә куна, — диде ул, пышылдап. — Сиңа аның янына барырга кирәк.

Кәбировтан аракы исе килә иде.

Сөембикә, ачынып:

— Мин бит инде аның белән сөйләштем — файдасыз, — диде.

— Ә син башкача сөйләшеп кара. Иртәгә йә берсекөнгә әниеңне кулга алырга мөмкиннәр. Син моның ни икәнен аңлыйсыңмы?

— Ничек башкача?

— Белмим, белмим! — диде Кәбиров, нишләптер аңа ачулангандай. — Бигрәк бала-чага буласың. Мин әле генә аның белән утырып чыктым. Кылларын тартып караган идем, ул, теләсә, барысын да эшли ала. Миңа шулайрак тоелды. Зөбәрҗәтне дә, үзеңне дә коткару синең кулда. Әйдә киттек.

Мөнир абыйсы кызу-кызу атлап, аны йөгертеп диярлек урам буйлап алып китте. Сөембикә кычкырып елый башлагач, шып туктады да иңбашына төртеп куйды.

— Әйдә, елый бир. Менә шулай елап, әниеңне озатып калырсың. Икегез дә юкка чыгачаксыз. Уян, акылыңа кил! — Шулай диде дә Кәбиров китеп барды.

Ул үксеп басып тора бирде. Әллә яшькелт, әллә зәңгәрсу, әллә көмеш төсендә ай үзенең нурларын койды. Сөембикә үзенең җиргә төшкән шәүләсенә караган килеш үкседе дә үкседе.

Ул, үзләренең турына җиткәч, агач күләгәсе астында туктап, койма буендагы утыргычка утырды. Күз яшьләре кипкән, башы ничектер ачыграк эшли башлаган иде. Аңа хәзер ихтыяр көче, тәвәккәллек кирәк. Сөйләшүнең ничек тәмамланачагын да ул якынча чамалый кебек. Аны менә шул куркыта да. Ниһаять, ул, койманың күләгәле ягына чыгып, кешеләр күрмәсен өчен иелеп, кунакханә ягына атлады. Анда килеп җиткәч, тәрәзәдән төшкән яктылыкка карап туктап калды. Юк, бүген булмый. Иртәгә район үзәгенә барып күрергә. Ул шул уй белән тагын кире борылды, әмма каршысына көлешә-көлешә килгән яшьләр төркемен күреп, кире борылды һәм кунакханә артына посты. Алар үтеп киткәч, тәвәккәлләп кунакханә ишеген какты. Янчуринның «Керегез!» дигән тавышын ишетүгә, дер-дер калтырап, кыюсыз адымнар белән эчкә узды. Ул ап-ак күлмәктән, кара галстуктан, кара трикодан иде. Бүлмә яхшылап җыештырылган, андагы караватларның өстенә ап-ак җәймәләр җәелгән, мендәрләр күпертелгән, Янчурин аны терсәгеннән йомшак кына тоткандай итеп кухняга алып керде, сый-нигъмәттән сыгылып торган өстәл янына утыртты.

— Сезнең эчегезгә салкын төшкән, бөтен тәнегез белән калтырыйсыз, — диде Янчурин, өстәлдәге башланган аракы шешәсен кулына алып.

— Миңа кирәкми, миңа салмагыз, — диде Сөембикә, ялварып.

— Ул чакта ширбәт белән генә сыйлыйм, — диде Янчурин, ачык елмаеп.

Ул, серванттан кызыл аракы алып, Сөембикәнең каршындагы бокалны күзеннән тутырып куйды.

Сөембикә торып басты:

— Мин сезгә үтенеч белән генә килгән идем...

— Үтенеч яңадан. Бүген минем туган көн, — диде Янчурин, аны урынына утыртып. — Шул хөрмәткә шәраб эчеп куюдан баш тартмассың бит инде, Сөембикә?

Сөембикә күзләрен йомып, берничә мәртәбә шәрабны йотып куймакчы булган иде, Янчурин үзенең кулы белән күтәрә-күтәрә аны эчертеп бетерде.

— Менә рәхмәт, — диде ул, шоколад сузып.

Бераздан Сөембикә калтыраудан туктады. Ләкин аның башы коточкыч әйләнергә тотынды. Әйтәсе сүзен тизрәк әйтеп чыгып китмәсә, шушында егылыр кебек тоелды. Аның кызлар белән бергәләп мәҗлесләрдә, туган көннәрдә кызыл аракы капкалаганы бар иде, ләкин болай кинәт баш әйләндерә торганына беркайчан да туры килгәне булмады.

— Мин сезгә... — дип сүз башлады ул, ләкин теленең үзенә буйсынмавын тойды. — Ник килгәнемне беләсез... Мине... ятим итмәгез...

— Әниеңне коткару өчен Кәримә Шәмгунованың гаризасын кире алдырырга кирәк. Син аның белән сөйләшә аласыңмы?

Сөембикә аның сүзләрен ниндидер бер битарафлык белән тыңлады, ул сүзләр аңа кагылмыйлар, каяндыр читтән үтәләр, күңеленә төшмиләр иде. Ул, торган саен авырая барган башын тоту өчен ияген учына куеп, терсәгенә таянды. Әмма кулы ычкынып, шапылдап өстәлгә төште. Ул йомылып барган керфекләре арасыннан Янчуринның ут сүндерергә дип үрелгәнен күреп калды. Бүлмә кап-караңгы булды. Янчурин Сөембикәне күтәреп алды да зал ягына алып чыгып китте. Ул нидер кычкырды, янады, ләкин аңа каршы торырлык көче калмаган иде инде...

Сөембикә ничәдә кайтканны да хәтерләмәде. Аның келәне калай кисәге белән ачып кереп ятканын әнисе сизмәде дә. Шуннан соң ике-өч көн Сөембикә шомлы томан эчендә йөрде. Әнисенең эштән кайтуын коты алынып көтте. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кораллы милиционерлар килеп керер дип хафаланды. Түзә алмагач, Мөнир абыйсына

барды. «Сабыр ит, без уйлаганча барып чыга бугай», — диде ул, аны тынычландырып. Көннәр уза торды, ахырда эшне яптылар. Аны беренче булып хәбәр итүче Фәйзрахман булды. Ул төнге уннарда тәрәзә шакып аларга керде.

— Нәрсә булды, нишләп йөрисең? — дип ташланды аңа әнисе.

— Синнән мәгәрич, — дип шаркылдады кызмача Фәйзрахман. — Хатын гаризасын кире алган. Тикшерүче ничектер аның үзен куркыткан, миңа сөйләп бетермәде. Мәгәричеңне куй.

Әнисе мич астыннан алып бер чөл чыгарды, алар шушы шатлыкны юарга өстәл янына утырдылар... Фәйзрахман үзе чыгарган көйгә үзе генә җырлый торган җырын урам буйлап җырлап кайтып китте:

Агыйделне буйлый-буйлый,
Килә аккош атучы.
Атма аккош, ат сандугач —
Шул безне саргайтучы...

Эшне япканнан соң, Янчурин мотоцикл белән аларга туктап, Сөембикәне район үзәгенә үзенең фатирына кунакка чакырды. Сөембикәнең хәйләсе әзер иде: авырыйм, миндә нindидер үзгәреш бар, дип, аның котын алып җибәрде. Ничә еллар узды, күпме җилләр исте, тормышта күпме очрашулар, аерылышулар булгандыр, һәммәсе дә вакыт кочагында, еракта калдылар. Янчуринны да шулай дип уйлаган иде Сөембикә, ә менә алай түгел икән. Ул үзенең ялгызлыгының сәбәбен аңлаган кебек булды. Аның тормыш көймәсенә Янчурин, Шәвәлиев кебек сигезаяклар, сөлекләр, хәшәрәт кабырчыкларябышкан, алар аны акрын гына тормыш төбенә сөйриләр. Сөембикәгә беркем дә кул сузмый, ул нишләсә дә япа-ялгызы... Аның елыйсы килде, үзен кемнәндер кызгандырасы килде. Ни аяныч, андый йомшак куллы кеше юк, иркәләргә теләүчеләр күренми. Ичмасам, ике күзенең берсеннән дә сыгылып сыңар яшь тамчысы да чыкмый иде. «Әллә мин хатын-кыз булудан туктадыммы, бөтенләй тимергә әйләндемме?» — дип уйлады ул, хафаланып. Кешелек калгандыр бит әле аңарда. Ничек кенә күңеле теләмәсә дә, ничек кенә карышса да, Янчуринга ярдәм итәргә кирәк. Күрәсең, шушындый халәт, гел шушылай теләмәгәнне эшләү туганда ук аның маңгаена язылган. Инде өлкәнәеп барганда булса да, моның шулай икәнлеген аңлап, язмышка күнәргә, бернинди газаплар кичермичә, үзең теләмәгән эшне башкарырга, хәтта мең төрле чаралар, алдау-йолдаулар белән булса да башкарырга кирәк иде.

## 7

Эштән кайткач та Сөембикә Янчурин турында уйланды. Мең кат үлчәгәннән соң, анык карарга килде: аны коткарырга! Айгөлгә урта мәктәп бетерергә дә күп калмый. Кая да булса укырга кертим дисәң, югары урында утыручы кодрәт иясе кирәк. Дошманмы ул, хәшәрәтме ул — Сөембикә өчен киләчәктә, һичшиксез, бер таяныч булачак. Күрәсең, пычракка кермичә яшәп булмыйдыр, тормыш кануны шундыйдыр. Хәер, кем белә, изге гамәлләр генә кылып яшәгән кешеләр, бәлкем, гомер юлларын да пакь килеш кичә алалардыр, илаһи биеклектә калып, бу дөньядан китеп баралардыр. Сөембикәгә андый язмыш турында хыялланырга да ярамый, бу мөмкин дә түгел иде инде, ахрысы. Ирек белән аерылышкач, ул, Болынкырны ташлап, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ерак җиргә — Камчаткага ук китәргә карар кылган иде. Анда әнисе ягыннан туганнары яши, Сөембикә хат язды. Алар үз яннарына чакырдылар, эш тә күп, акчасы да әйбәт, дигәннәр иде. Тик аны иң элек Айгөл куркытты. Ул бала татар тормышыннан, әтисеннән аерылып нишләр? Аны гомере буе каһәрләмәсме? Инде ниятләп бетерүгә, Ирекнең баш күтәрми эчә башлавы Сөембикәнең күңелендә әллә нинди давыллар кузгатты. Үз кызы әтисенең шушы хәлгә төшүендә ул гаепле иде бит! Уйлана торгач, Болынкырда калырга, ә элекке Сөембикәне үтерергә карар кылды. Гөнаһлы тәнгә пакь җан, саф рух иңдерәм дип яшәде һәм бу карарыннан чигенмәде. Тик... менә бит юллар тагын ул теләмәгән якка сөйри һәм аларга буйсынмыйча булмый, күрәсең.

Әхнәфкә кереп, барысын да җентекләп сөйләп бирергә, аның ярдәмен сорарга кирәк. Әхнәф турында уйлагач, ул ничектер күңелендә җиңеллек тойды. Хәер, бу тойгыны Сөембикә генә түгел, районның барлык җитәкчеләре дә кичерә иде. Иң беренче эше итеп ул куркыту дигән нәрсәне ташлады. Нинди генә авыр хәлләрдә дә, әллә нинди киеренке киңәшмәләрдә дә Арсланов кебек, җитәкчеләргә ырлап капмады, кешенең сүзен башына китереп суккандай бүлмәде, һәркемне зур сабырлык белән тыңлады, күп кенә мәсьәләләрне уртага салып, үзе читтәрәк калырга тырышып, гомуми фикердән, киңәшләрдән чыгып хәл итәргә тырышты. Ул кадрлар алыштыру белән дә артык мавыкмады. Арсланов кырыннан чыкмыйча аңа ялагайланган, гомере буе кемнәрнедер әләкләп, кемнәрнедер сатып көн күргән Өлфәт Җәмилев кебекләргә дә кагылмады, халык арасында Әхнәф Шәрифуллинның «кадрлар белән уйнарга ярамый, һәркемнең гаиләсе бар, әти-әнисе бар, балалары бар, әгәр кеше ялгышкан икән, аны төзәтергә тырышыйк» дигән сүзләре афоризм кебек йөр-

деләр. Үзенә икенче секретарь итеп ул Наратбашта эшләп киткән Зәйнуллинны алды. Күпләр башта аңардан химик дип көлеп маташсалар да, бу егет кешеләрне тирән аңлый торган, йомшак күңелле, мәдәният, матбугат, медицина, көн-күреш мәсьәләләрендә дә бик тирәнтен белеп фикер йөртә торган җитәкче булып чыкты. Аның да эш стиле, беренче секретарьныкы кебек үк, үзара аңлашуга, киңәшүгә корылган иде. Хасбулатов, теләпме-теләмичәме, отставкага китте, ә Изабелла Назаровнаны кабат дубляж буенча редактор урынбасары иттеләр. Редактор булып элек районнан куылган Максутовның кайтуы күпләр өчен сенсация булды. Райкомның оештыру бүлеге мөдире итеп Фәнис Сәлаховны куйгач, җитәкчеләр, Шәрифуллин ТИҮ белән ныклап торып никахлашырга уйлый, ахрысы, дип сөйләнә башладылар. Бу сүзләрдә шатлану күбрәкме, әллә иронияме — монысын әйтү кыен иде. Май ахырында ул Болынкырның нәкъ урта бер җирендә хуҗасыз ике йорт урынына Әхнәф, сайлаучылар алдында биргән вәгъдәсен үтәп, балалар яслесе салдырта башлады. Бусы инде яшь гаиләләрдә һәр көн иртә-кичен Әхнәф Шәрифулинны рәхмәт хисләре белән искә алырга, әби-бабалары, ата-аналары тарафыннан аның исәнлеген теләп дога кылырга мәҗбүр итте. Ул бөтенесен тәмам туйдырган, көненә әллә ничәшәр мәртәбә үткәрелүче һәртөрле җыелыш-киңәшмәләрне җыюдан туктады, җитәкчеләр рәхәтләнеп, киң сулыш алып эшли башладылар. Фермаларга, игенчелек буенча колхоз-совхозларга вәкилләр куу, алардан бастырып сорау алу дигән нәрсәләр бетте. Аның бүлмәсенә кергәндә калтырап торулар, йөрәк даруы кабулар да онытылды, җитәкчеләр беренче секретарь белән үзара рәхәтләнеп киңәшеп, үз фикерләрен курыкмыйча әйтеп, сөйләшеп була, рәхәткә чыктык, дип, уртак куанычларын белдерәләр иде.

Ирек музей директоры булып эшли башлады. Ул турыдан-туры Сөембикәгә буйсына, һәр мәсьәләдә аңа мөрәҗәгать итәргә тиеш булса да, алар икесе дә бу кыен бәйләнештән котылырга тырыштылар. Ирек үз көенә эшләп йөрде, аның горурлыгына кагылмас өчен, Сөембикә мәдәният хезмәткәрләрен семинарга-киңәшмәләргә җыйганда да элекке ирен чакырмады. Ирекнең эшли башлавы Айгөл өчен әйбәт булып чыкты. Ул мәктәптән кайтканда әтисе янына керә, бергә сөйләшәләр, серләшәләр. Шунлыктан йөзендәге элекке күңел төшенкелеге, ятимлек чалымнары юкка чыкты, күзләрендә дәртле очкыннар күренде, карашы яктырды.

Сөембикә бик четерекле мәсьәлә белән мөрәҗәгать итәчәген белсә дә, Әхнәф янына кыенсыну тойгысы кичермичә, тыныч күңел белән китте. Ләкин кабул итү бүлмәсендә кеше бик күп иде. Ул бюро көне икәнен хәтереннән бөтенләй

чыгарган. Сөембикә кабул итү бүлмәсендәге кешеләр белән исәнләшеп тә бетерә алмады, Әхнәф бүлмәсеннән өлкә комитеты инструкторы Хисаметдинов белән килеп чыкты. Күрәсең, ул аны Казанга озатып җибәрде. Кабат әйләнеп кергәндә сәгатенә карады да:

— Иптәшләр, гафу итегез, Сабитовадан башкагызны кабул итә алмыйм, — диде һәм үзе белән Сөембикәне ияртеп алып кереп китте.

— Йә, ни хәлләрдә яшәп ятасыз? — диде ул, урынына утыргач.

Сөембикә серле генә елмайды да:

— Барына канәгать, югына сабыр итәбез, — диде.

— Бу тормыш әллә ниндигә әйләнеп китте бит әле, Сөембикә. — Әхнәф, гаепле кеше кебек, як-ягына каранып алды, уң кулы белән чәчләрен артка сыпырды. — Заманында бик аралашып яши идек. Хәзер килеп тә чыкмыйсың. Фәһимә белән әллә урамда гына очрашасыз инде?

Сөембикә аңа ни әйтергә дә белмәде. Әхнәф беренче секретарь булып сайланганнан соң, Фәһимә алыштырган кебек үзгәрде дә куйды. Аның адымнары салмакланды, гәүдәсе турайды, күз карашы, ничектер сиңа кагылмыйча читтән генә үтеп, бик еракка, әллә кая юнәлә торганга әйләнде. Моның шулай икәнлеген аңа якын булган, элек аралашкан хатын-кызлар үзара хәйран калып сөйләшсәләр дә, Сөембикә үзенә карата Фәһимәнең алай кылануын сизмәде сизүен. Шулай да ул элекке Фәһимә түгел иде. Очраган саен хәл сораша, Ирек белән үзара мөнәсәбәтләрен төпченә. «Эштән башка аралашмыйбыз» дигән сүзне ишетсә, Сөембикәне кызганырга тотына, төрлечә юата, хәленә керә. Ә Сөембикәнең һич тә үзен аңардан кызгандырасы килми. Шул ук вакытта элекке дустының кызгануларына каршы куярлык дәлил дә таба алмый. Нинди дәлил табасың? Ул ирсез, ул ялгыз, ул берүзе кыз үстерә, башкалар белән, бигрәк тә Фәһимә белән чагыштырырлык та түгел. Аның кызгануларыннан туеп, Сөембикә мөмкин кадәр аның белән очрашмаска тырыша. Ахырда ул бу кызгануларның Фәһимә Сөембикәне үзеннән читләштерү өчен уйлап тапмады микән дип тә уйлады. Ул бит Сөембикәне мескенләндерүне күтәрә алмаганлыгын бик яхшы белә.

Әлбәттә, Әхнәфнең соравы урынлы, бәлки, ул бу мәсьәләне Фәһимәнең башкалардан бик кинәт, күзгә күренерлек дәрәҗәдә аерылуын күреп кузгаткандыр. Хатынының башкаларга югарыдан каравы аны бит һич кенә дә бизәми, киресенчә, күпмедер дәрәҗәдә абруена китереп суга.

— Тормыш та үзгәрә, үзебез дә картаябыз бугай, — диде Сөембикә, эчкерсез елмаеп. — Хәзер сер капчыкларын ур-

тага куеп, туйганчы бушатып утырырга әллә вакыт юк, әллә моның кызыгы бетте инде.

— Син Фәһимәне ташларга тырышма, — диде Әхнәф. — Талпынып һавага оча башласа, аягыннан сөйрәп төшер. — Ул сәгатенә карады да: — Йомышыңны сөйлә, — диде.

Сөембикә аңа Янчуринның махсус килүен, бәлагә таруын һәм аны коткару өчен Әхнәфнең кем белән сөйләшеп ярдәм итә алачагын аңлатты. Аны тыңлап бетергәч, Әхнәф шактый вакыт дәшми утырды, аннары әллә ничек, мыскыллауга тартым елмаю белән елмайды да:

— Сөембикә, Янчурин кем соң ул сиңа? — дип сорады.

— Заманында ул минем әнине төрмәгә утырудан йолып калды. Мин аның каршында мәңге бурычлы, — диде Сөембикә.

Әхнәф, бармагы белән якасын тартып, галстугын бушатып куйды, учлары белән йөзен, муенын сыпырып алды.

— Синең өчен җаным-тәнем белән ниндидер яхшылык эшлисем килә. — Ул торып өстәл тирәсендә йөргәндәй итте. — Тик беләсеңме, без Янчурин белән ул заманда якага яка килеп туктадык бит. Әгәр шулай булмаса, ул сиңа түгел, туп-туры минем үземә килгән булыр иде. Янчурин «Сельхозтехника»да эшли торган бер комсомолецыбызны төрмәгә тыкты. Гел юктан җинаять эше әвәләп. Егет ике ел утырып кайтты. Без аның белән очрашкач, Янчуринның әлеге егетнең хатыны артыннан сөйрәлгәнен, аны юлыннан алып ату өчен төрмәгә утыртканын белдем. Син шуны коткарырга кушасың.

— Мин аңладым, — диде Сөембикә, чыгарга әзерләнеп.

— Уйлыйм әле, Сөембикә. Үз-үземне җиңсәм дә, синең хакка гына җиңә алырмын...

Сөйләшү шуның белән тәгәлләнде.

## 8

Сөембикә чыгып киткәч, Әхнәф йөрәк даруы эчеп куйды һәм бюрога килүчеләрне чакырды. Ишектән дөбердәшеп бюро членнары, Әнәс Нәбиуллин белән Сабирҗан Нуриев, райком инструкторлары керде. Әхнәф сүз биргәннән соң, Нуриев гадәттәгечә кулына тоткан бер уч кәгазен актарырга кереште, каян ничек башларга белмичә җәфа чикте, әле күзлеген сөртте, әле кулъяулыгы белән тирләгән йөзен сыпырды, әле коелган кәгазьләрен иелеп идәннән җыйды. Менә шушы да партком секретаре булып йөри инде, дип ачынып уйлап утырды Әхнәф. Куып чыгарсаң, пенсия яшенә җитәргә санаулы көннәр калган, әле ул бит ялгызы түгел, районда аның кебек секре-

тарьлар шактый. Ярый инде Нуриевның ул урынга элэгүе дә, тиешле белеме булмавы да тормышның бер фаҗигасе. Ләкин бит арада сау-сәламәт, гайрәте ташып торган, белемле партоешма секретарьлары да көн үтсенгә йөриләр. Андыйларның коммунистлар каршында гына түгел, халык алдында да бернинди абруе юк, шуларга карап райкомга да, аның секретарьларына да әйбәт булмаган бәя куялар. Нуриев, сүзен бетереп, нишләтерсез микән дигәндәй, куркулы карашын Әхнәфкә юнәлтте. Совхоз коммунистлары Әнәс Нәбиуллинга учет карточкасына язып каты шелтә биргәннәр иде.

— Йә, Нәбиуллин, — диде Әхнәф, — сөйләгез.

Нәбиуллин урыныннан торып басты. Ул бер генә җыерчыгы да күренмәгән өр-яңа костюм-чалбардан, кара галстуктан, ап-ак күлмәктән иде. Һич тә эшчеләр комитеты председателе дип уйламассың, башкаладан килгән опера җырчысыннан ким түгел.

— Миңа бу эшне үзләштерү беренче елларда шактый кыен булды, — дип башлап китте Нәбиуллин. — Ни әйтсәң дә, эшчеләр комитеты ул — администрация белән халык арасында торган сандал кебегрәк бернәрсә. Аңа өстән дә чүкеч белән оралар, астан да. Тора-бара уртак тел табылды. Комитет механизаторларның, терлекчеләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартлары турында кайгырта.

— Туктагыз әле, — дип бүлдерде аны Әхнәф. — Сез инде монда эшчеләр комитетының эше турында безнең каршыда отчет куймагыз. Конкрет кына теге көнне булган хәлләрне сөйләгез.

— Нәрсә сөйлим инде, — диде Нәбиуллин. — Механизаторларның ул бәйрәменә мин атна буе әзерләндем. Ярышка йомгак ясадык, бүләкләр алып кайттым. Бәйрәм көнне иртүк бергә укыган дустымны озатасым булды. Ул кичтән килеп кунган иде. — Әнәс бусын үзенең хәлен җиңеләйтү өчен баштук уйлап чыгарган иде. — Аны озатканда да бераз тотарга туры килде. Аннары көне буе продукция, әйберләр ташыдым. Бәйрәм вакытында салынды инде. Шуннан тәртип ягы йомшап киткән.

Ул туктап калды. Башын иеп, астан гына бюро членнарына берәм-берәм күз йөгертеп чыкты.

— Сөйләгез, сөйлә, — диде Әхнәф. — Азагы ни белән бетте?

— Директорга ялгыш сукканмын...

— Белерлек хәлдә түгел идегезмени? — дип сорап куйды оештыру бүлеге мөдире Сәлахов.

— Белерлеген белерлек идем. — Әнәс, мәктәптәге дәресен белмәгән малайга охшатып, күзләрен челт-челт йомып,

карашын әле түшәмгә, әле идәнгә юнәлтте. — Кызып кителгән салган баштан...

— Сез совхоз эшчеләренә үрнәк күрсәтергә, аларны тәрбияләргә тиешле кеше. Партком секретаре үрнәк күрсәтә алмый, аның нәрсә белән шөгыльләнгәнен барыбыз да беләбез. Сез бит яшь кеше. Шыр исерек хәлдә ничек халык алдына чыгарга мөмкин? — диде Әхнәф, ачуын яшерә алмыйча дулкынланып. — Мин килгәндә үк йөзегезгә карарлык түгел иде.

— Гаебемне тулысынча таныйм, — диде Әнәс, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән башын аска иеп. — Иртүк салырга кирәк булмаган. Шуның белән ялгыштым.

— Сез бит, Нәбиуллин, минем киләсен белеп тордыгыз. Исереклегемне беренче секретарь күрер дип тә уйламадыгызмыни?

— Уйламадым шул...

Гаҗәпләнүдән баш чайкап, Кәшифраз Әхмәтҗанов:

— Бу сезнең җаваплылык тойгыгызны тулысынча югалтуыгыз турында сөйли. Үз-үзегезгә дә, халыкка да, район җитәкчеләренә дә сансыз булуыгызны күрсәтә.

— Совхоздан бушка бик күп әйбер алгансыз, диләр, — дип сүзгә кушылды Гаскәров. — Бусын ничек аңларга?

— Үземә генә алган әйберләр түгел инде ул. Шулай килеп чыкты... Аларның бәясен түли башладым инде мин. Әҗәткә кереп булса да, бер-ике айда түләп бетерергә сүз бирәм.

— Ә совхоз директоры белән мөнәсәбәтләрегез ничек булып бетте? — дип сорады Гаскәров. — Мин эшегез судта дип ишеткән идем.

Аның соравына Әнәс бернинди дә җавап бирмәде.

Нуриев, урыныннан торып, аңлатма бирде:

— Әйе, эш зурга киткән иде. Нәбиуллин үзе кат-кат гафу үтенгәч, Фаиз Сәгыйтович белән кат-кат сөйләшкәч, ул, олы җанлылык күрсәтеп, эшне туктатты.

Әнәс Нәбиуллиннан ваклый-ваклый сорау алу шактый дәвам итте.

Ахырда Әхнәф:

— Ә инде чалбар эченә шешә тыгып биюе нәрсә? — диде.

— Менә анысы гел кирәк булмаган...

Бюро члennарыннан кемдер Әнәс Нәбиуллинның бу җавабыннан кеткелдәп көлеп куйды.

— Димәк, башкалары ярагаn? — дип куйды Әхнәф. — Мәсьәлә аңлашылды, сузуда мәгънә юк. Кемдә нинди фикерләр бар?

Шулай диюгә, Дамир Зәйнуллин сүз алды, аның дулкынланганы күренеп тора иде.

— Миңа Наратбаш мәктәбендә укытырга туры килде. Әнәс Нәбиуллинны шул вакыттан ук яхшы беләм, — дип башлады ул сүзен. — Турысын әйтим, сез, иптәш Нәбиуллин, халыктан ихтирам казана алмадыгыз. Менә без бүген тикшергән мәсьәләне алсак та, нинди җитәкче буласыз инде сез? Сезнең шул бер көндә кылган гамәлләрегез дә халык тарафыннан бер сүз белән бәяләнә: тере дурак, ди ул, беттекитте. Сезнең эчүчелек белән шөгыльләнүегез бер бүген түгел. Үзегезгә бирелгән машина белән авуларыгыз да ишетелеп тора. Хатын-кызга мөнәсәбәтегезне дә беләбез. Мин укыткан чорда гына да сезнең аркада берничә гаилә бозылышып бетте, аерылышу дәрәҗәсенә җитте. Шушылардан чыгып, минем, Әнәс Нәбиуллинда эш кайгысы юк, дип әйтәсем килә. Ул үз-үзен тотуы белән коммунист исеменә инде күптән кара тап төшерде. Аның безнең сафларда калырга бернинди дә хакы юк.

Зәйнуллинның чыгышыннан соң бүлмә тып-тын булып калды.

— Тагын чыгыш ясаучылар бармы? — диде Әхнәф, бюро членнарына күз ташлап.

— Мәсьәлә ачык, тавышка куярга кирәк, — диде Гаскәров.

— Ә сезнең фикерегез? — диде Әхнәф аңа.

— Әле минем тавыш биргәнче уйларга вакытым бар, — диде Гаскәров, елмаеп.

— Синең сүзең бармы, Нәбиуллин?

Әнәс җитез генә торып басты, бик мескен тавыш белән, башын аска иеп болай диде:

— Мин үземнең барлык ялгышларымны да таныйм. Зинһар, партия сафларында гына калдырыгыз. Ышанычыгызны үземнең хезмәтем белән аклармын.

— Мин биредә утыручыларның барысының да күңелендә нәрсә кайнаганын бик яхшы аңлыйм, — диде Әхнәф. — Алар бөтенесе дә, Нәбиуллин, син игътибар белән кара аларның йөзләренә, бөтенесе дә бер фикердә: синнән котылырга. Шулай да, иптәшләр, мин аңа тагын бер мәртәбә ышанып карау ягында торам үзем. Хатынына, балаларына мәңгелек кара якмыйк инде. Әйдәгез, тәрбияләп карыйк. Мин инде сезгә кайбер серне дә ачам. Аны бюрога китертүне мин юри суздым. Күңеле белән газаплансын, уйлансын, яңадан андый эшләрне эшләмәскә тәүбә итсен, дип озак йөрттем мин аны. Хәзер аңлагандыр дип уйлыйм. Шулаймы, Нәбиуллин?

— Әйе, — диде Нәбиуллин, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән. — Төн йокыларым качты.

Тавышка куйгач, бюро членнары аңа, учет карточкасына

язып шелтә белдерергә, дигән карар өчен тавыш бирделәр. Нибары ике кеше — Гаскәров белән Зәйнуллин гына — ни каршы, ни уңай якка кул күтәрмәде.

— Бюро утырышы ябык, — диде Әхнәф. Барысы да дәррәү кузгалып чыга башлауга: — Нәбиуллин, сез калып торыгыз әле, — диде. Икәүдән-икәү калгач, Әхнәф сүзен дәвам итте: — Син мине ни дәрәҗәдә гадел булмаган карар кабул иттергәнемне аңладыңмы, Нәбиуллин?

— Аңладым, Әхнәф Хәсәнович. Рәхмәт сезгә.

— Аңласаң, шул: син хәзер минем кеше булачаксың. Бертуган энем кебек. Хәзер мин синең һәр адымың өчен җавап бирәм. Шушы ук кешеләр, андый-мондый нәрсә сизелсә, минем йөземә төкерәчәкләр. Син инде анда эшчеләр комитеты председателе булып эшли алмыйсың. Үзең ни уйлыйсың?

— Мин теләсә нинди эшкә риза. Тик Наратбашта гына булмасын.

— Ярый, уйлашып карабыз. Мин үз исемемнән сиңа үтә дә җаваплы бер эш тапшырмам микән әле.

— Нинди эш?! — диде Нәбиуллин, урыныннан сикереп торып.

— Ашыгып атланма, тумаган биянең билен сындыруың бар. Вакыты җитәр, чакырырмын.

Нәбиуллин рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Әхнәф өстәлгә бармагын шакылдатып утырды-утырды да Гаскәровка шылтыратты:

— Сәет Мөбарәкович, сез бу Ирек Сабитовка квартира мәсьәләсендә берәр карарга килдегезме?

— Юк әле, — диде Гаскәров.

— Һаман сузыла бит. Бер якка хәл итәргә кирәк инде. Сөйләшкән вариантларның берсен сайларга вакыттыр.

— Ярый, бу атнадан да калмабыз.

«Ирек Сабитов, Ирек Сабитов», — дип кабатлады Гаскәров эченнән. Күңелен авырттырып нәрсәдер кыймылдап куйгандай булды. Үзе янына чакыртырга, сөйләшергә кирәк булыр. Бәлкем, бүгеннән калдырмаска да кирәктер. Ул Ирекнең башкарма комитет бинасында дежур торган чакларын күз алдына китерде. Сакларга тырышты, барып чыкмады. Ә шулай да Гаскәров аңа хөрмәт белән карый. Эштән киткәннән соң, аның турында әйбәт булмаган сүзләрне дә шактый ишетергә туры килде. Ә нигә чакыртырга соң әле аны? Барырга да кайтырга.

Кич эштән соң, үзе генә машинага утырып, ул кайчандыр апасы яшәгән таныш йортның капкасы төбенә килеп туктады. Аның килеп керүен күргәч, Ирек белән Зәнфирә каушап киттеләр. Өстәл артында язып утырган җиреннән Ирек кабаланып аның каршына чыкты.

— Әйдәгез, рәхим итегез, — диде түргә чакырып.

Зәнфирә, нишләргә белмичә, ул арада өстәл әзерләргә кереште. Ирек, өстәлдән язуларын җыеп, шкафка куйды.

— Зинһар өчен, бернәрсә җыймагыз, бернәрсә әзерләмәгез, — диде Гаскәров. — Мин хәл белергә генә кердем.

Шулай да Ирек аның плащын салдырып чөйгә элде. Алар өстәл янына кара-каршы утырдылар.

— Ни хәлләрдә яшәп ятасыз?

— Рәхмәт, Сәет Мөбарәкович, — диде Ирек. — Әлегә зарланып булмый.

Гаскәров, күзе белән өйнең һәр почмагын карап чыкканнан соң:

— Мин үземне сезнең алда гаепле санап йөрим, — диде.

Ирек баш чайкап куйды:

— Алай димәгез. Минем өчен мөмкин булмаганны да эшләдегез. Сезгә мин гомерем буе рәхмәтле. Ә упкынга мин үзем төштем. Сез кисәтә килгән упкынга төштем. — Ирек башын иеп тынып калды. Аннары ул, урыныннан торып, Зәнфирәне өстәл янына алып килде. — Ул упкыннан мине менә шушы изге җан тартып чыгарды. Ничек сабырлыгы, көче җиткәндер.

Зәнфирә бурлаттай кызарды.

— Йә инде, Ирек, кирәкми, — диде ул, пышылдап.

— Мин аны синең үзеңә әйтә аламмыни? Ичмасам, Сәет Мөбарәкович белсен.

Зәнфирә кызык кына итеп кулын селтәп җибәрде дә:

— Үлән чәе белән сыйлыйм әле үзегезне, — дип, кече якка атлады.

— Үлән булса, эчәм. Ә болай чәйне мин өнәмим. Дөресрәге, врачлар эчмәскә кушалар, йөрәк шаяра.

— Ә менә бу чәй йөрәкне тынычландыра, — диде Зәнфирә, аларның икесенең дә алдына тулы чынаяк куеп.

Шунда ук бал, конфет, вареньелар да пәйда булды.

— Чын бальзам белән бер бу сезнең, — диде Гаскәров, чәйне тәмләп чөмерә-чөмерә. Аннары, бер түшәмгә, бер идәнгә карап, уйчан гына сүзен дәвам итте: — Апаның өе дә таушалган икән. Тәбәнәкләнгән. Сезгә торыр урын кирәк булачак бит инде.

— Үз өең — агач кашыгың, — дип куйды Ирек, елмаеп.

— Сезгә Әхнәф Хәсәнович үзләренең өен тәкъдим иттем дигән иде. Алар көзгә Арслановныкына күчәчәкләр. Минемчә, сезгә дә күчәргә кирәк.

— Без андый йортка ничек керик инде, Сәет Мөбарәкович?

— Андый йорт? Ул да әллә кайчан салынган. Гади генә авыл өе. Мөмкинлек барында керергә кирәк.

— Унар ел чират көтүчеләр бар бит.
— Бар, Ирек Хәйриевич, бар! Тик иҗат кешесенә без аерым шартлар тудырырга тиешбез.
— Анлык иҗатым юк минем. Сизеп торам, сез Әхнәф кушуы буенча килгәнсез.
— Үз талантыгызны үзегез бәяләп бетермәвегез кызганыч. Үкенмәссезме икән?
— Үкенерлегенә үкендем бугай инде.
— Яхшы булып күренү, яхшы булып кылану заманнары үтеп бара, Ирек Хәйриевич.
— Сез дә шушы сүзне сөйлисезме?!
— Метафора буларак кабул итегез. Иҗат кешесе метафораларны дөрес аңлап, дөрес бәяли белергә тиеш. — Гаскәров, чәен кабып, әллә аның тәмен тоярга теләп, әллә югалган фикер җебен эзләп, шактый гына утырды, аннары әллә нинди сак, кисәтүле тавыш белән дәвам итте: — Өстә ниндидер җитди үзгәрешләр бара, ил буенча... Таныш булмаган җилләр исә... Кеше күңелен киптерүче җилләргә охшаган.
— Мин тормыштан шулкадәр аерылдым микәнни? — дип куйды Ирек, үз-үзеннән сорагандай.
— Сез хыял белән яши торган халык. Ә хыялны кысрыклый торган нәрсәләр арта бара. СССР дигән гранит кыяны да селкетә башладылар. Гариза биреп партиядән чыгуларның да булганы юк иде. Бөтен системаның асты өскә килергә мөмкин. Әгәр шулай булса?.. Ярык тагарак кырында калмагыз диюем.
Гаскәров урыныннан торды. Ирек аны озатып кергәндә, Зәнфирә бик күңелсез утыра иде.
— Нәрсәгә кәефең кырылды? — диде Ирек, аның иңбашларына кулын салып.
— Мин сине аңламыйм, Ирек. — Зәнфирә аңа туры карамады, үпкәләгәндәй, йөзен тәрәзәгә таба борды. — Әллә артык кыланасың? Быел кышны да ничек чыкканыбызны беләсең. Бәрәңгеләргә салкын тиеп бетте. Әҗәттән башка акча күрәсебез юк.
Гаскәровның килүе Ирекнең кәефен күтәреп җибәргән иде. Шуңа күрә ярым шаяртып, ярым чынлап болай диде:
— Кайгырма юкка, карчык. Менә Минзәлә театрындагы пьесам чыкса, аны Культура министрлыгы әйбәт кенә бәягә сатып алса, пьеса куюдан гонорар килеп торса, тотарбыз да бер өй сатып алырбыз.
Тик хатынының йөзе тагын да караңгыланды.
Ирек кисәтүле тавыш белән болай диде:
— Алтын өйдән баш кыйбат. Ишетәсеңме?
Зәнфирә дәшмәде.

* * *

Шул ук көнне тагын бер вакыйга булды. Әнәс Нәбиуллин бюродан чыгып үзенең фургон «Москвич»ына килеп җиткәндә, аны күптәнге йөреше Шәһрия елмаеп көтеп тора иде. «Оныттың бу арада, — дип каршылады аны чибәркәй. — Бүген көтәм, кил». Әле бюроның кайнарлыгы бетмәгән иде, шуңа күрә Әнәс сүзне кыска тотты: «Җай чыкса, карармын», — диде дә китеп барды. Ул көнне Әнәс өйләнешкәннән бирле үз гомерендә бер көн айнык кайтты. Бу хәлне күргәч, хатыны гаҗәпләнеп бот чапты, тәүбәгә килүе шушы икән дип куанды, райком бюросына, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенә, аның Үзәк Комитетына һәм Генераль секретарена кат-кат рәхмәт укыды. Ләкин Әнәснең башында бүтән уйлар бөтерелә, йөрәге сихри дөньяга ашкына иде. Бүгенге бюро аңа «үтә дә сак булырга кирәк!» дигән сабак бирде. Шуңа күрә ул терлекчелек буенча төнге дежур торачак ветврачка: «Бүген мин торыйм әле, мин торасы көнне син торырсың», — дип, дежурлыгын алышты. Сәгать кичке тугызларда төнге дежурга дип чыгып китте дә Болынкырга җилдерде. Чибәркәе аны иңнәренә сарылып каршылады. Туксан ике яшьлек әбисен үз почмагына кертеп утырткач, алар олы бәйрәм ясадылар. Әллә нинди үләннәр белән төнәтелгән көмешкәсе дә искиткеч, Шәһрия үзе дә шәһәреңне бөрерлек иде. Әнәс иртән сәгать өченчедә генә уянып китте. Уяну белән ул гадәттә кабаланып кухня ягына чыга, плитә өстендәге өч литрлы чәйнектән бүрәнкәләнгән иреннәренең уртасына су коя, ул бугазыннан горгылдап, махмыр калдыкларын юып аска төшеп китә иде. Бүген дә ул шул гадәте буенча плитә өстендәге ай нурларына коенып утырган ялтыравыклы чәйнекне өскә тырпайган тоткасыннан эләктерде һәм вулкан кратерыннан бәргәндәй ялкын бөркеп торучы авызына су койды. Ә су... Йа Аллам!.. Су уттай кайнар иде! Әллә тагы Әнәскә бу дөньяда кылган гөнаһлары өчен тәмугта авызына агызасы кайнар сумалага чиркәнчек рәвешендә куелган иде! Ул үгез кебек үкереп җибәрде, чәйнекне тәрәзәдән көлеп карап торган айның чыраена томырды. Чәйнек тәрәзә пыяласын ансат кына ватып чыкса да, тиешле космик тизлекне ала алмаганлыктан, төзәлгән объектына барып җитә алмыйча, бакчадагы ике түтәл арасына, нәрсәгәдер ишарәләгәндәй, борыны белән төшеп кадалды. Бу фаҗиганең сәбәпчесе Шәһриянең әлеге дә баягы йөзгә сигез елы тулып җитмәгән әбисе иде. Ул эченең авыртуына төне буе борсанлый торгач, бер чәйнек суны кайнарлап, грелкасына салган, ә калганы төнге кунакка насыйп булган иде.

Динозавр кебек үкерә-үкерә, Әнәс өйдәге бөтен әйберне

җимереп йөгерергә тотынды. Өч катлы панель йортның барлык фатирларындагы чебен-үрмәкүч ише бөҗәкләрдән башлап сабый балаларга кадәр урыннарыннан сикертеп торгызырлык бу дәһшәтле тавышның борынгы заманнардан бирле җир йөзендә яңгыраганы да булмагандыр, яңадан ишетергә дә язмасын иде. Кырык ел буе берни ишетмәгән тома чукрак кортка булып, ул да башыннан ук төренеп яткан мамык юрганы аша әлеге коточкыч тавышка уянып, кухняга йөгереп чыкты. Аның тез турыннан читкә таба җәенке почмак ясап бөгелгән итсез сыйраклары дер-дер калтырый, бүксәсеннән аяк арасына шуып төшкән зәңгәр грелкасына яшел күлмәк итәге эченнән тач-точ нидер тамуы бу күренешкә серлелек һәм фәлсәфи төсмер өсти иде... Әнәснең әбигә әйткән китапка язып булмый торган сүзләрен җыеп кушкач, кортка үз яшенең инде йөздән узып, йөз иллегә якынлашып килүен башына да китермәде.

Шәһрия үтә дә ушлы хатын булып чыкты. Ул суыткычтан бер литрлы банкага салынган катыкны алып, Әнәснең авызына олы агач кашык белән каптырырга кереште. Катык беткәндә, кунак кычкырудан туктап шыңшуга күчте. Аңкавының, теленең пешкән тиреләрен эскәк белән тарткалап алганнан соң, Шәһрия Әнәснең авызына күп итеп каз мае сылады да өенә озатты...

## 9

Арсланов акрынлап шәһәр тормышына күнегә башлады. Министрлар Советы аппаратында аның элекке танышлары, пенсиягә чыккан партия-совет җитәкчеләре шактый иде. Биредә авыл райкомындагы сыман иртә таңнан төнгә кадәр чабу, нервы туздыру дигән нәрсәләр юк, кешеләр бер-берсе белән бик җылы мөнәсәбәттә, нindидер йомышың бар икән, берәрсенә әйтәсең дә китеп барасың. Ярты көн йөрисеңме, артыгракмы — сиңа үпкә белдерүче юк. Өч бүлмәле квартирада Эльза белән ире тора иде. Әтиләре Казанга күчкәч, кияү кеше үз йортларына кайтырга ниятләде. Ләкин Миңзаһит аның әти-әнисе янына ашкынудан түгел, ә бәлки үзенең килүе аркасында гына биредән кузгалырга теләвен яхшы аңлады. Хәят әле Болынкырда иде. Шуңа күрә «бу ялан кадәр квартирада берүзең хыялланып үләргә кирәк бит» дигәч, алар бергә яшәргә риза булдылар. Өчәүләшеп эшкә чыгып китәләр, өчәүләшеп кайтып керәләр, сирәк-мирәк өчәүләшеп концерт-спектакльләргә баралар.

Беркөн Эльза газета алып кайтты да урта битен ачып аңа сузды. «Укы, кешеләрнең ничек эшләүләрен күр әнә», — диде. Газетаның икенче битен тутырып, Ирек Сабитовның

«Болынкыр таңнары» дигән язмасы урнаштырылган иде. Анда Әхнәф Шәрифуллинның эш стиле бик җанлы, ышандырырлык итеп сурәтләнгән, районда кузгатылган зур-зур эшләр күрсәтелгән иде. Кыска гына арада файдалануга тапшырылган ясленең, анда тәрбияләнүче балаларның, яңа күтәрелүче төзелешләрнең фоторәсемнәре урнаштырылган. Юлларга да асфальт җәелә икән. Ул, йөрәгенә чыдый алмыйча, урамга чыгып китте, кафега кереп, бик озак эчеп утырды, ләкин нишләптер исерә алмады. Миңзаһит үз-үзенә туктаусыз бер сорауны бирде: «Мин эшләмәдеммени?!» Башта Сабитовка ачуы килсә дә, тора-бара йомшады. Гадәттә мондый язмаларны элекке җитәкчене тәнкыйтьләүдән, аның бөтен эшне тоткарлаучы тормоз булуын тәмләп чәйнәүдән башлыйлар. Сабитов моңа бармаган, аның хакында ләм-мим бер сүз әйтмәгән иде.

Миңзаһит бу мәкалә тәэсиреннән күп вакытлар айный алмады. Болынкырга ул атна саен диярлек кайта, кайткач, урамда бик үк күренәсе килми иде. Инде хәзер гомумән чыгарлыгы калмады. Миңзаһит, Болынкырдан киткәндә, Шәрифуллиннан машина сорый, ул нәкъ кирәкле вакытта «Волга»сын китереп туктата. Акрынлап Миңзаһит үзенең Шәрифуллин өчен кисеп атылырга тиешле сукыр эчәк кебек артык нәрсә икәнен тоя башлады. Ул вәгъдә иткән машина йә соңарып килә, яисә үзенең машинасы чынлапмы-юриме ватыла да, берәр җитәкченең «уазигы»н җибәрә. Болар аның ике арада киләп сарып йөрмәвен үтенү кебек тоела. Шуңа күрә алар Хәят белән әйберләрен акрынлап барлыйлар, яхшылап бәйлиләр, тутырырдаен капчыкка тутыралар. Үзен илтә торган машинаның урыны булганда, Миңзаһит ул әйберләрнең сыйган кадәресен Казанга алып кайта тора. Менә бу ялда да ике көн буе әйбер җыйнап эт булдылар. Миңзаһит әле тагын өч көнгә Болынкырда калырга рөхсәт сорап та кайтты. Һич югы октябрь башларына күченергә кирәк иде.

Алар эңгер-меңгер төшкәндә генә өйгә керделәр. Хәят чәй куйды, ашарга көндез пешергән пилмәнне кайнарлады. Инде өстәлдән кузгалып кына китәбез дигәндә, шартлап ишек ачылып китте. Аларга, ишек кыңгыравына басмыйча, берәүнең дә кергәне юк иде. Аптырашып, икесе дә урыннарыннан тордылар һәм өнсез калдылар: ишектән керүче бер кулына дипломат, икенчесенә юл сумкасы тоткан Рашат иде.

— Исәнмесез, көтмәгән идегезме? — диде ул, дипломаты белән сумкасын идәнгә куеп. Аннары үрелеп ярым ачык калган ишекне япты.

Миңзаһит кулын сузып аңа атлады. Алар салкын гына күрештеләр. Хәят, урыныннан кузгала алмыйча, очып китәргә теләгәндәй, кулларын күкрәгенә куеп, терсәкләрен

җәйгән, күзләре зур булып ачылган, иреннәре калтырый һәм бөтен өйгә ишетелерлек итеп сулыш ала иде. Кинәт ул аякларын бөгеп чүгәләгәндәй итте дә идәнгә егылды. Миңзаһит йөгереп барып аны күтәреп алды һәм үз бүлмәсенә атлады. Аның артыннан ияргән Рашат әнисенең пөхтәләп җыелган йокы караваты өстендәге эш планы дәфтәрләрен читкә алуга, Миңзаһит Хәятны шунда китереп салды. Рашат кухняга чыгып салкын су алды, учына салып әнисенә су сипте. Миңзаһит аны читкә этәрде дә, мамык белән нашатырь спирты алып, Хәятның борынына китерде. Ул шундук күзләрен ачты. Мондый чакта нишләргә кирәген белгән Миңзаһит, аның халат кесәсеннән ингаляторын алып, авызына берничә мәртәбә өрдергәч, йөрәк даруы эчергәч, Хәятка ныклап торып җан керде. Миңзаһит аны иңбашыннан күтәреп утырткандай итте, аркасы турына икенче кулы белән мендәр салды. Рашат ашыгып чыгып китте, сумкасыннан абрикос согы тутырылган шешә алып керде. Әнисенә бокалга салып сок сузды. Хәят иреннәрен бераз ачкандай итте, бокалның чите аның тешләренә тиде, ләкин ул авызын ачмады, тамак төбеннән әллә нинди өзек куркыныч тавыш кына килде, һәм ул калтыранып елый башлады. Рашат бокалны читкә алып куйды.

Бераздан Хәят тынычлангандай булды һәм:

— Бар, ашат баланы... — диде.

Алар кухня ягына чыктылар. Рашат өстәлгә үзе алып кайткан апельсин, мандарин, виноград кебек күчтәнәчләрне таратты, колбаса кисте, бер коньяк чыгарып утыртты. Зур гына тәлгәш виноградны юып килде дә аның бер өлешен, чәй тәлинкәсенә салып, әнисенә алып кереп китте. Карашын каядыр почмакка төбәп утырган Хәят аны күрү белән күзләрен йомды.

— Әни, менә виноград кабып кара әле...

Хәят тәлинкәне кулына алды һәм «бар, чык» дигән мәгънәдә кулын ишеккә таба селтәде. Рәхмәт тә әйтмәде дип уйлап куйды Рашат. Ул кергәндә, Миңзаһит рюмкаларга коньяк салган иде инде.

— Әйдә, с приездом! — диде ул малаена.

Чәкештерделәр дә җиңел генә эчеп куйдылар. Шунда әтисе нишләптер зал ягына чыгып китте. Бераз торгач, Хәят бүлмәсенә үтте, аннары кабат кухняга керде. Аның күзләре дымланган иде. Бусында алар Рашат тутырып куйганны эчтеләр.

— Ни хәлләрдә ятасыз соң? — диде Рашат, суган белән колбаса чәйни-чәйни.

— Безме? Без менә шушылай инде... — Миңзаһит сүзен әйтә алмады, улын кочаклап алды һәм тавышсыз гына еларга кереште.

Рашат аны читкә этте:

— Әртисләнмә әле, җенем сөйми!

— Нәрсә?! — дип пышылдады Миңзаһит. Ул тозлы күз яшьләренең ирен читләреннән йөгереп авызына керүен сизде. — Син миңа ышанмыйсыңмыни?

— Мин күз яшьләрен күреп туйдым инде, чынын да, ялганын да. — Ул җәһәт кенә рюмкаларны тутырды да шешәне шапылдатып урынына утыртты. — Күз яшьләре күрергә дип кайтмадым мин.

Арсланов, шулай йомшап китүенә хәйран калып, үзен-үзе тиргәп утырды. Малаена болай җебеп төшүен һич тә күрсәтәсе килми иде. Рашатның соңгы сүзләре аның күңелен айкалдырып-чайкалдырып җибәрделәр.

— Күз яшьләрен күрәсең килмәсә, вакытында кайтырга идең! — диде ул, йодрыгы белән өстәлгә сугып. — Һич тә булмаса исән икәнеңне белдерергә идең!

— Әгәр белдерергә ярамаса?

— Андый нәрсә булмый! Болар барысы да боргалану, җаваптан качу, — диде Арсланов, бармак селкеп.

Аннары ул тагын җәһәт кенә Хәят янына чыгып керде. Ул кергәндә, Рашат рюмкасын аударып куйган иде инде.

Миңзаһит үпкә сүзләрен тезүен дәвам итте:

— Мин сине ничекләр генә эзләмәдем! Укуыңны ташлагансың. Ярар, анысына кул селтәдек. Бөтенләй хәбәрең ишетелмәгәч, хат яздык, моннан барган инструктор кереп чыкты. Квартира хуҗаларың кайдалыгыңны белми. Кеше шулай яшиме соң?

— Яши бит. Миңа сезнең белән элемтә тотарга ярамый иде. Исәнлегегезне саклау өчен.

— Саклadың, сакламый ни! Чамалыйм мин синең кайда булганыңны. Мин коткармасам, әле һаман да чыга алмаган булыр идең.

Аның бу сүзләреннән Рашат сискәнеп китте.

— Ничек коткардың син мине?

— Килделәр миңа...

— Кемнәр? — диде Рашат, пышылдап.

— Белмим. Берсе озын гәүдәле, озын башлы, ап-ак чырайлы, куркыныч, күзләре эчкә баткан.

Аның һәр сүзеннән Рашат куырыла барды һәм акрынлап урыныннан кубып аягүрә басканын сизми дә калды.

— Тагын кемнәр? — дип сорады ул, Миңзаһитның йөзенә йөзен якын китереп.

— Берсе тәбәнәк буйлы. Дүрт меңне биреп җибәрергә туры килде...

— Соң бит сине алдаганнар! — диде Рашат, кычкырып.

— Тсс, шаулама! Бу хакта әниең белсә, хәзер йөрәге ярыла.

Рашат шактый вакыт хәрәкәтләнмичә, уйланып утырды.

— Ярый, мин сиңа аны биш мең итеп бирермен, — диде ул.

Миңзаһит тагын Хәят бүлмәсенә юнәлде, аңа Рашат та иярде. Хәят мендәрен җайлап салган да йоклап киткән иде. Рашат әнисенең бер генә виноградны да өзеп капмаганын күрде. Алар утны сүндереп, аяк очларына гына басып, кухняга чыктылар. Сөйләшер сүз калмаган иде инде.

— Мин ике төн йокламадым, берәр җиргә урын салып бир әле, — диде Рашат.

— Үзеңнең бүлмәңә кер, анда һәммә нәрсә бар.

Рашат, дипломатын алып, бүлмәсенә үтте. Чыннан да, ул нәкъ элеккечә. Әйтерсең лә Болынкырдан чыгып киткәндә ничек җыештырылган булса, шул хәлендә аны көтеп торган. Бераз гына ниндидер тынчу ис кенә килгән сыман. Ул тәрәзәне ачып җибәрде, әйберләрен тиз-тиз анда-монда ыргыткалап, урынны җәйгәндәй итте, дипломатыннан бер төргәк акча алды да, залга чыгып, әтисенә сузды:

— Менә монда биш мең.

Миңзаһит акчаны шикләнеп кенә алды. Ялган түгелме дигәндәй, әйләндереп-әйләндереп карады.

— Нинди эштә эшлисең соң син?

— Акчаң күп, дип әйтмәкче буласыңмы?

— Әйе, шулай дип әйтмәкче булам, хәрам акча килешми ул безгә.

Рашат әллә нинди гырылдавык тавыш белән көлеп җибәрде.

— Райком секретареның хәләл акчасы буламыни? Син аны берәр авыл гыйбадына сөйлә инде, — диде дә бүлмәсенә кереп китте.

Миңзаһит сүзсез генә чыгып китте. Ул, әле Хәят бүлмәсенә кереп, әле залда телевизор карап, Рашатның бүлмәсеннән ишетелгән гырылдауны тыңлады, төнге берләргә кадәр керфек тә какмады.

Иртән Хәят мәктәпкә киткәндә, Рашат йоклап калды. Ул көндез генә торды, башын төзәтә-төзәтә ашады. Миңзаһит алып китәсе әйберләрне җыештыру белән мәшгуль иде. Рашат белән бергәләп зал ягындагы зур сервантны сүттеләр, шул чакта Рашат аңардан ничек эштән алулары турында сорады. Миңзаһит сөйләп биргәч, яңагын чәйни-чәйни:

— Әхнәфне тотып ярыйммы соң? — диде.

Миңзаһит аңа усал итеп карады:

— Ахмак! Син монда джунгли законнарыңны оныт!

Хәят мәктәптән кайткач, алар өчәүләп табын янына утырдылар.

Шактый вакыт сүзсез генә ашап-эчкәч, әнисе Рашатка:

— Йә, сөйлә, кайда йөрдең? Ник безгә бернинди дә хәбәр бирмәдең? — диде ачулы күзләрен елтыратып.

— Миңа чит илгә чыгып китәргә туры килде. Бер фирма акчалы эш тәкъдим итте.

— Кайда инде ул?

— Сүриядә.

— Синең бит бернинди дә белгечлегең юк, — диде Хәят. — Син анда нишли аласың?

— Кеше эшләмәгән эш юк бит, өйрәнергә туры килде. Измә дә ясадым, кирпеч тә салдым.

Хәят кулындагы чәнечке-пычакларын шалтыратып өстәлгә атты да:

— Ялган, һәр сүзең ялган! — диде.

Аннары үкереп елап, Рашатны уңлы-суллы яңаклый башлады. Ул күзен йомган хәлдә, селкенмичә утыра бирде. Хәят ярсыганнан-ярсый барды.

— Беләсеңме син безне вакытыннан алда гүргә керткәнеңне?! Син хайван өчен бөтен йөрәгебезне бетердек, елап сукыр кала яздым!

Рашат дәшмәде, Хәят куллары тәмам авырткач туктады да тагын бүлмәсенә кереп ауды. Рашат, шуны гына көткәндәй, сикереп торып киенергә керешә. Әйтерсең аның өчен Миңзаһит бөтенләй юк иде.

— Кая барасың? — диде ул, ачу белән.

Рашат эндәшми-нитми киенеп бетте, дипломатын кулына алды.

— Ник җавап бирмисең?

— Урап кайтам әле...

## 10

Урамда кичке утлар кабынган иде инде. Рашат, беренче секретарь бүлмәсенең тәрәзәләрен күзәтә-күзәтә, әллә ничә мәртәбә райком тирәсеннән үтте. Кичке җидегә кадәр йөрсә дә, тәрәзәдә утлар кабынмады. Үзенең бер классташына кагылып, шактый кәефләнгәннән соң, ул Сөембикә яшәгән йорт каршына килде. Керергәме-юкмы дип икеләнеп торганнан соң, кыяр-кыймас кына капканың келәсен күтәреп эчкә этте, ләкин ул ачылмады. Олы капканың аркылы торбасы тыгып куелган иде. Рашат аны үрелеп карады, ачып кереп ишек кагуның шау-шуы зурга китү ихтималын уйлап, кул селтәде дә кире борылды.

Икенче көнне кичен ул тагын райкомга таба китте. Бүген Әхнәф бүлмәсендә ут балкып яна иде. Рашатка сәгатьтән артык сагаларга туры килде. Ахырда берәм-берәм утлар сүнеп, сәгать алты тулгач, райком ишегеннән җәйге пальто, эш-

ләпә кигән Әхнәф килеп чыкты. Ул баскычтан төшеп уңга борылуга, Рашат аның каршына килеп басты:

— Нихәл, иптәш секретарь?

Аның каш астыннан гына карап, теш арасыннан сыгып әйтелгән бу сүзләре Әхнәфне куркытып җибәрде, ул артка чигенеп куйды. Ниһаять, танып алгач:

— О-о-о, Рашат! Нинди җилләр ташлады? — дип, аңа кул сузды.

— Замана җилләре. — Рашат, аны култыклагандай итеп: — Бәлкем, серләшә-серләшә урам әйләнербез? — диде.

— Ярый, — диде Әхнәф.

Алар акрын гына кузгалып киттеләр. Әхнәф исенә нидер төшкәндәй тукталып калды.

— Болай булмый бит инде, Рашат, — диде ул, елмаеп. — Син бит кунак кеше. Әйдә, минем бүлмәгә керик.

— Миңа барыбер, — диде Рашат.

Бүлмәгә кергәч, Әхнәф аның киемнәрен, хөрмәт күрсәтеп, үзе шифоньерга элде, кунак бүлмәсенә алып кереп, түрдәге йомшак кәнәфигә утыртты, суыткычтан азык-төлек чыгарды. Рюмкаларга аракы салды.

— Йә, синең тәмам Мәскәү кешесе булуың өчен!

Рашат Әхнәфнең чәкештерергә китергән рюмкасын читкә этте.

— Юк, моның өчен эчмибез, — диде ул. — Бу ялган тост була, чынбарлыкка туры килми.

— Ничек инде алай? — диде Әхнәф, гаҗәпләнеп.

— Анысын соңрак әйтермен. Беләсеңме, без моны синең эшеңдә тагын да югарырак баскычка күтәрелүең өчен эчәбез.

Әхнәф, кунакның сүзләрендә нинди киная ятканын аңласа да, каршы килеп сүз әйтүне кирәк тапмады.

— Әйдә, мин каршы түгел.

Бераз капкалаганнан соң, Әхнәф рюмкаларны тагын тутырды да:

— Әйдә, бусын очрашу хөрмәтенә, — диде.

Өченче мәртәбә аракы салгач, күңелен кымырҗыткан соравын бирмичә булдыра алмады:

— Нишләп соң әле син Мәскәү кешесе булуга каршы килдең? — диде.

— Тотып куйыйк, аннары җавап бирермен.

Бу юлы эчкәч, Рашат бер әйбер дә капмады, урыныннан торып әйләнеп килде дә шапылдатып кулын Әхнәфнең иңбашына салды. Әхнәфнең тәне эсселе-суыклы булып китте, тез буыннарын калтырау алды. Ул авырлык белән генә аягына баса башлады. Әмма кунакның кургаштай авыр кулы аны дыкылдатып урынына утыртты. Аның кыргый җанвар-

ныкы төсле янучы рәхимсез күзләрен күреп, Әхнәфнең коты очты. Рашат, ташланырга әзерләнгәндәй астыртын елмаеп, кәнәфиен, кузгалып чыгып китәрлек араны томалап, аның каршына ук шудырды, тезен Әхнәфнең тезенә терәп килеп утырды. Әллә нинди салкын, астыртын, кинаяле тавыш белән сүз башлады:

— Менә хәзер җавабын бирәм. Беләсеңме, Әхнәф Хәсәнович, безнең әти-әниләр Казанга күчеп китә бит.

— Әйе, — диде Әхнәф, сагаеп.

— Ә менә мин күчәргә теләмим. Болынкырда яшисем килә.

— Син бит Мәскәүдә яшисең.

— Ялгышмагыз, Әхнәф Хәсәнович, мин Болынкырдагы йортка язылган, пропискадан төшкәнем юк. — Ул паспортын чыгарып, Әхнәфкә күрсәтте. — Йорт миңа кирәк.

— Син бөтенләй мөмкин булмаган әйбер сөйлисең, Рашат.

— Мин аңлыйм, син анда үзең күчмәкче буласың, — диде Рашат. — Ләкин син минем калырга хаклы икәнемне онытма!

Әхнәф бармаклары белән маңгаен, ике чигәсен сыпырырга кереште.

— Әйдә, без аңлашып сөйләшик әле, Рашат. Син Мәскәүдән кайтмакчы буласыңмыни?

— Юк, кайтмакчы булмыйм. Мин инде кайттым.

— Сиңа квартира кирәк. Шулаймы?

— Миңа квартира кирәкми. Мин шушы үзем туып үскән йортта яшәргә телим. Барысы да законлы.

— Бу әйбернең Болынкырда гына хәл ителмәячәген, өлкә комитеты да барлыгын син онытасың.

— Мин законны гына беләм.

— Әйе, законны саклау өчен хокук органнары бар. Әле бит синең фәлән ел буе яшәмәгәнеңне алар башка юллар белән дә раслый алалар. Моның бер кыенлыгы да юк. Болынкырның акыл ягыннан зәгыйфь булмаган һәрбер кешесе шаһит була ала.

— Әгәр дә мин шаһитларсыз гына эшлик дисәм?

— Син юкка көчәнмә, Рашат. Бу барып чыкмаячак. — Әхнәф шулай дисә дә, эчендә әллә нинди шомлы уйлар бөтерелде. Рашатның күзләрендәге кыргый очкыннар аның теләсә нинди нәрсәгә сәләтле икәнен раслый иде. Әхнәф компромисс эзләде: — Әгәр кайтырга ниятең бар икән, бәлки, башка вариант табарбыз?

— Нинди?

— Мин сиңа Чаллыдан бер дигән квартира алырга ярдәм итә алам. Үзе шәһәр, Болынкырдан да ерак түгел. Бәлкем, бергәләп берәр кибет кебек нәрсә дә ачып җибәрербез.

Рашат рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Син минем тәртәне бөтенләй икенче якка борасың бит әле. Минем өчен заманчиво бу.

— Соң, әйдә уйлашыйк, — диде Әхнәф. — Эшмәкәрләргә хәзер бөтен җирдә юллар ачыла. Мин синең белән хезмәттәшлек итәргә һәрвакыт әзер.

Алар, шактый вакыт гәпләшеп утыргач, анык карарга килмәсәләр дә, икесен дә канәгатьләндерә торган уртак вариант эзләргә дигән ният белән аерылыштылар.

Рашат квартира мәсьәләсен Әхнәфнең ачуын китерергә, ызгыш-талаш чыгарырга, куркытырга, җае чыкса, бераз аны типкәләп-бәргәләп алу нияте белән генә кузгаткан иде. Сөйләшүнең һич көтелмәгән борылыш алуы Рашатны дәртләндереп җибәрде. Ул Болынкыр урамыннан очына-очына атлады, ләкин үзләренә кайтып җиткәч, нидер уйлап, ялт кире борылды да аскы урамга төшеп китте. Ул урамның ике ягын бер итеп атлады, алдында киң юллар ачылгандай тоелды. Менә ул таныш тыкрыкка борылды, Ирекләр яши торган өйнең капкасын ачып ишегалдына керде. Тәрәзәләрдә утлар яна, ләкин эчтә ни барын күрерлек түгел — пәрдә тартылган иде. Рашат ишеккә килде. Ул бикле түгел иде. Өй ишеген кагып тормады, яртылаш ачты да:

— Мөмкинме? — диде.

— Әйдә, керегез, — диде Ирек, аны каршылап.

Өйдә ул үзе генә иде. Алар кул биреп күрештеләр.

Өстәлгә таратып ташланган кульязмаларга карап, Рашат:

— Нәрсә язасың? — дип сорады.

— Үзебез яшәгән тормышны, — диде Ирек, елмайгандай итеп.

Ирек плитәне кабызып чәй куя башлауга, Рашат аны туктатты:

— Кирәкми, мин ашап кына чыктым. Әгәр инде тегесе булса... Анысыннан баш тартмыйм.

— Гафу ит, анысын өйгә керткән юк. Мин ул нәрсә белән араны өздем.

— Начар эшләгәнсең. Бу җир йөзендә бөтенебезне дә якын итә торган, бөтенебезгә дә үзен жәлләмичә бирә торган берләнбер зат бит ул. Хатыннар белән үз гомереңдә әллә ничә мәртәбә аерылышып була торгандыр. Ә моннан башка яшәү яшәү түгел. Нык ялгышасың син.

— Бөтенләй дә ярамый ул миңа. Башка ярамый.

— Андый кешеләрне күп беләм мин. Ярамый, ярамый, диләр дә шундый итеп эчеп җибәрәләр, аяк асларында җир яна башлый. — Рашат иелеп Ирекнең өстәлдәге язуларын караштыргалады да башын күтәреп болай диде: — Монда миңа кирәк әйбер күрмим әле мин. Теге китапны тәрҗемә итеп куйгансыңдыр бит?

— Юк, — диде Ирек. — Мин аны тәрҗемә итмәячәкмен. — Ул китапны шкафтан алып Рашатка сузды.

Ләкин Рашат аны алырга уйламады.

— Бу ни дигән сүз була инде, дустым? Мин сиңа бер үтенеч белән килдем, ә син шуннан да баш тартып торасың. Нәрсәсе ярамый?

— Син үзеңнең миңа ни биргәнеңне беләсеңме? — Ирек китапка берничә мәртәбә кул сырты белән суккалап алды. — Бу бит фашизмны җәелдерүгә юнәлтелгән әйбер.

— Әйе, шулай шул.

— Безнең илгә фашизм китергән бер афәт җитмәдемени? Инде хәзер үзебезнең яшьләрдән фашистлар ясыйбызмы?

— Син гел әллә кем булма әле, — диде Рашат, Ирекне урындыкка таба этеп, үзе каршына утырды. — Фашистмы, түгелме — синең белән миңа пычагымамы алар? Аның бит инде дөньясы барыбер беткән. Тәрҗемә итеп бир дә акчаны кесәңә салып куй.

— Син бик куркыныч эшкә алынгансың. Артыңда кемнәр торганын мин белмим, тик моның ахыры әйбәт булып бетмәячәк. — Ирек китапны Рашатның тезе өстенә шапылдатып китереп салды. — Бу атом бомбасыннан да куркынычрак әйбер.

Рашат, күзен кысып, аны мыскыллагандай, озак итеп карап торды.

— Әгәр хәзер менә мин сиңа ике «Жигули» машинасы алырлык акча бирсәм? Тәрҗемә итәсеңме?

— Син, Рашат, мине бөтенләй белмисең. Әгәр дә акчага кызыга торган кеше булсам, мин бу өйдә дә яшәмәс идем. — Ул шкафтан ак кәгазьгә төреп кара җеп белән чорналган кечкенә генә төргәкне алып, әлеге китап өстенә куйды. — Бусы син теге вакытта калдырган акчалар. Минем беркемнән дә аванс та, хәер дә алганым юк.

Рашат, иреннәрен кыегайтып, мыскыллы елмайды.

— Ну что ж, — диде ул, сикереп торып, — баш тартасың алайса?

— Баш тартып кына калмыйм. Сиңа да бу хәтәр эшкә кул тыкмаска киңәш бирәм. Куркыныч нәрсә бу. Син кемнәрнеңдер ятьмәсенә эләккәнсең. Тик алар бит бүген йә иртәгә юк ителәчәк.

Рашат ямьсез итеп көлеп җибәрде. Шул чакта Ирек аның алтыннан ясалган куш коронкасының төшәм-төшәм дип калтырап торуын күрде.

— Кем юк ителер икән? Карарбыз! Әле мин үзем генә кайттым. Киләчәктә ялгыз булмам. Безне беркем дә буйсындыра алмый. Уйлый тор, сиңа моны барыбер тәрҗемә итәргә туры киләчәк. Безнең таләп шундый.

— Кем соң ул «без»?

— Яңа көч. Ул көч килгән җирдә һәркемне буйсындыра.

— Син ата-анаңа, әби-бабаларыбыз корган тормышка каршы барасың. Бу китап милләтләрне көчләп юк итүгә корылган. Сиңа барыбермени?

— Барыбер булса, мин алар белән булмас идем бит.

— Менә хәзер барысы да аңлашылды, — диде Ирек. — Ә минем тормышка тыкшынма. Мин үзем теләгәнчә яшәргә телим.

— Берәүнең дә үзенең генә тормышы була алмый, дустым. Алай булсын өчен айда яшәргә кирәк. Яхшы чакта ал син бу китапны.

Рашат китапны Ирекнең бугазына терәде. Ул аны кулы белән читкә какты.

— Син элекке чакларыңны оныт әле, Рашат, — диде Ирек, аның үзе кебек басым ясап.

— Син хәзер беренче секретарь малае түгел диюең инде. Әтине төшерүдә кулыңны нык уйнаткансың.

— Кул уйнатырга ул капчык сугышы түгел, — дип, Ирек аңа үзе кебек мыскыллы караш ташлады.

— Куанырга ашыкма, дустым. Сез Шәрифуллин белән икегез, Арслановны җиңдек, дөньяның кендегеннән алдык, барысына да хуҗа булдык, дип уйлыйсыз. Ә сез тома сукырлар. Сез бит барыгыз да болындагы үләннәр. — Рашат тагын көлеп җибәрде. — Исеме җисеменә туры килеп тора: Болынкыр! Ха-ха-ха! Печән чабучылар әле килмәгән, үләннең калынаюын көтәләр. Җиләк тә өлгермәгән. Аны җыярга тубал тотып шулай ук әзер торалар. Бөтенесе көтә. Шулай да чалгы янаган тавышлар инде ишетелә. Маңгаеңны җыерма, сез ул тавышларны ишетмисез. Сез генә түгел, алар өчен бөтен Җир шары — олы болын, печәнлек.

— Кемнәр өчен? — диде Ирек, Рашатның фикерен ачыграк аңламакчы булып.

— Беләсең киләмени? Юк алар, юк! Оныт минем сүзләрне! Күп сораштыра башласаң, муеныңны сындырулары бар. Сезнең өчен алар юк, алар өчен сез юк. Бернинди бәйләнеш юк. Булыр иде — сез күптән тере түгел, язмышыгызның инде әллә кайчан хәл ителеп куелганын да белмисез. — Рашат шунда имән бармагын Ирекнең күзенә тери язып аңа юнәлтте, үзе туктаусыз хихылдады. — Әнә күзләреңдә курку, куркасың бит, шыр җибәрдеңме?!

Аның өенә бәреп кереп шулай мыскыллавы Ирекнең йөрәгенә китереп бәргәндәй итте.

— Мин сиңа бер әйбер әйтимме, Рашат?

— Әйт.

— Без бәләкәй чакта тычканны тота идек тә артына салам

тыгып өреп кабарта идек. Тычкан бик зур булып, әүмән-тәүмән йөгереп китә иде. Беркөн телевизордан сөйләделәр: үзбәкләр сарыкны исертәләр икән дә тире арасына насос белән һава тутыралар икән. Аннары базарга алып чыгалар. Сарык пел кебек булып кабарып басып тора. — Ирек туктап калды.

— Шушының белән беттемени? — диде Рашат.

— Әйе.

— Ник сөйләдең син моны?

— Нишләптер келт итеп исемә төште.

— Ярый, аңладым кебек мин сине... — Рашат тешләрен шыкырдатып куйды. — Тик кабатлап әйтәм: мин дигәнчә булачак. Хатыныңа сәлам әйт.

Ул ишекне шартлатып ябып чыгып китте...

## 11

Әхнәф менә ничә көннәр инде Рашат белән очрашуны хәтереннән чыгара алмыйча йөри. Ничә көннәр буе үзен-үзе, калтырап төштең, дип сүгә. Югыйсә Мәскәүдән кайткан ул җилкуарның ике сүз белән авызын томаларга да бүлмәсеннән куып чыгарырга иде. Терсәк бик еракта калды шул. Чаллы квартирасын ишеткәч, Рашатның күзләрендә хәтәр очкыннар кабынганын Әхнәф бик ачык хәтерли. Шушы очрашудан соң исә аның уң күз кабагы әллә ни гомерләр сикергәләп, тартышып йөрде. Кичләрен телефон шылтыраса, Рашаттыр дип коты алынды. Ул хәзер, җилкәңә бер атландыргач, тимер авызлык каптырылган атны үрле-кырлы сикерткәндәй, рәхимсез кыланачак. Бәгырен телгәләгән шушы чарасызлык аңа күптән баш ватып йөргән кыен мәсьәләне хәл итәргә дә этәргеч бирде бугай. Турысын гына әйткәндә, Арсланов йортына күчәсе килми иде аның. Аларның хәзер яши торган йорты белән чагыштырганда, сүз дә юк, ул әйбәт, әмма заманадан ерак тора. Бүгенге район җитәкчеләре башкача яши. Әшли башлау белән үзеңә йорт салу бик хәтәр нәрсә. Иң элек моны халык өнәмәячәк. Болынкырда гына да өч йөзгә якын кеше квартирага чират көтә. Партия өлкә комитеты да бу мәсьәләдә район җитәкчеләрен, бигрәк тә беренче секретарьларны туктаусыз кисәтеп тора. Бу борчуларны Әхнәф үзе кайнатты, хатынына сиздермичә генә, ачуташ капкандай, йөзен җыерып йота бирде. Фәһимә исә күңеле белән инде әллә кайчан Арслановлар йортына күчкән иде, ул анда яши, төрле-төрле җиһазлар ала, ремонтлар ясата, бакчасына чәчәкләр, агачлар утырта. Әле хыялында гына йөргән шул мәшәкатьләре хакында Әхнәфкә очына-очына сөйли һәм шуның белән аның болай да борчулы күңеленә тоз сипкәнен уйлап та карамый. Күңелен көне-төне бимаза-

лаган каршылыклы уйларны хәл итә алмагач, Әхнәф эшне хатыныннан башларга уйлады.

Бүген ул көне буе фермаларда йөрде. Яздан бирле торакларны кышка әзерләү турында кисәтеп килүгә карамастан, малларны җәйләүләрдән кайтаргач, сөт кими башлады. Борчудан авырайган иңбашларына яңаларын төяп, ул кичке сигезенче яртыларда гына кайтып керде. Әлбәттә, хатынының ишектән керү белән «Нишләп бу вакытка калдың?» дигән соравына «Фермаларда булдым» диде дә өстәл янына утырды. Ничек сүз башларга икәнен ашаганда төрле яклап уйлады, моның өчен вакыт бик уңайлы иде: малайлары Таһирның чыгып киткән чагы. Ул инде университетның юридик факультетында беренче курс студенты. Башкаларны Арча ягына бәрәңге алырга җибәргәннәр, ә ул менә бер атнага кайткан иде.

Фәһимә җәелгән камырын рюмка авызы белән кискәләп маташкан җиреннән борылды да:

— Бик үк ныгытып ашама әле, пилмән дә салып алам, — диде.

Әхнәф көлеп җибәрде. Таһирның иң яраткан әйберсе — пилмән, менә өч көн инде әнисе аны шуның белән сыйлый.

— Нигә көләсең?

— Таһирны гел кайтарып торырга иде, пилмәнне мин дә яратам бит, — диде Әхнәф. — Ясашыйммы?

— Әстәгъфирулла! — дип сузып куйды хатыны. — Болынкыр урыныннан күчмәс микән соң?

— Әйдә ясашыйм әле. — Әхнәф пилмән камырына савыттан калак белән фарш алып салды да бөрә башлады. — Болынкырны Ык ярыннан бер илле метр өскәрәк күтәрсәк, начар булмас иде. Күпләр су басудан интегәләр бит.

Әхнәф пилмәнен бөгеп бетерүгә, камыры икенче яктан ертылып, ите килеп чыкты.

— Нигә аны сыймаслык итеп саласың? Артыгы бит барыбер кире чыга.

— Шулай шул, — дип куйды Әхнәф. — Сыймаслык әйбер кыен инде ул. Мин бит әле бүген әти белән әни янына кагылдым. Үзең беләсең, икесенең дә рәтләре чамалы. Кышка әллә безгә килергә микән дип торалар. Сыйдырырбыз бит инде аларны?

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Фәһимәнең карлыгач канатыдай кара кашлары берничә генә секундка җыерылып алды, иреннәре дә кысылып куйдылар.

— Сыйдырмый нишләрсең? — диде мөмкин кадәр тыныч тавыш белән. — Үзләре сагынып интекмәсәләр...

— Бер кышка түзәрләр.

— Кайчан килмәкче булалар соң?

— Анысы инде аның синең белән миннән тора, — диде Әхнәф, камырны тишеп чыккан ит кисәген савытка атып. — Арсланов йортына күчкәч алып килербез.

Шулчак ишек кыңгыравы шылтырады. Әхнәф кулларын сөртте дә:

— Таһир кайткандыр, — дип, ишеккә таба китте.

Ләкин керүче малайлары түгел, үзләренең урамында хат ташучы булып эшләүче хатын иде. Әхнәф аның иңенә асылган сумкасы булмавыннан, ачулы чыраеннан ниндидер күңелсез хәл барлыгын аңлады.

— Әйдәгез, түргә узыгыз, Сәрия, — диде ул.

— Юк, узмыйм. Хәерчегә нишләсәң дә көн юк. — Сүзен әйтеп бетермәстән, ул елый да башлады.

— Ни булды, аңлатып сөйләгез, — диде Әхнәф.

Ул арада Фәһимә дә атылып алар янына чыкты.

— Мин инде сезгә әллә ничә мәртәбә кермәкче булдым, — диде Сәрия, күз яшьләрен кул аркасы белән сөртәсөртә. — Сезнең Таһирыгыз минем Илшатны кыйный да кайтара. Өченче көн киемнәрен ертып бетергән. Мин бит сезнең кебек кесә тутырып акча алмыйм. Ялгыз хатын дигәч тә...

Фәһимә аны кулыннан тотып кухня ягына алып чыкты.

— Сез ялгышасыздыр, Сәрия. Безнең малайның беркайчан да кеше белән сугышып йөргәне юк.

— Таһирыгыз мәктәптә укыганда ук ике мәртәбә кыйнаган иде инде. Хәзер Казаннан кайтып кыйнаган. Нинди үче бардыр? Унынчы класста укый торган баланы кыйный ала инде ул.

— Моның булуы мөмкин түгел, — диде Әхнәф. — Кем күргән?

— Кем күрсен, малай үзе әйтте. Кайтып кергәненә әле аның ярты сәгать. Нәрсә беләндер сугып иренен ярган. Курткасы кара канга баткан. Чыксын малаегыз монда.

— Ул бит әле кайтмады, — диде Фәһимә, нишләргә белмичә өзгәләнеп.

— Мин аның кайтканын көтәм, — диде Сәрия, бераз тынычлангандай булып.

Фәһимә, аны чишендермәкче булып, өстендәге иске җәйге пальтосының сәдәфен ычкындырырга үрелде.

— Әйдәгез, чишенегез. Таһир кайткач, аңлашырбыз.

Ләкин Сәрия кире чигенде.

— Сезнең кебек кешедә ничек курыкмыйча чишенмәк кирәк?! Шушында гына басып торам.

Аның бу сүзләренә Фәһимәнең чырае бозылды.

— Без кеше ашамыйбыз, Сәрия. Бу йортта кеше каны эчә торган аждаһа да яшәми.

— Аждаһасын белмим, малаегыз ник минем Илшатыма үчләшә?

Күпме генә кыстасалар да, Сәрия узмады. Аның сүзләре Әхнәф белән Фәһимәне олы хафага салды. Бер атнага ялга кайткан Таһирның сугышып йөрүе, кеше кыйнавы алар өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде.

Сәрия, бераз тынычлангач:

— Мин моны болай калдырмыйм. Хәзер үк милициягә барам, — дип урыныннан кузгалды.

Әхнәф белән Фәһимә аның икесе ике ягыннан килеп туктаттылар:

— Зинһар өчен, сабыр итегез! — дип өзгәләнде Фәһимә. — Башта әйбәтләп аңлашыйк.

— Без аңа җәзаның иң катысын бирербез, — дип өстәде Әхнәф.

— Илшат белән кайтып сөйләшәм. Ул ни әйтсә, шул булыр. Безгә үпкәләмәгез...

Сәрия чыгып киткәч, Әхнәф белән Фәһимә икесе берьюлы кухня өстәле янына барып утырдылар. Пилмән кайгысы беткән иде.

— Минем моңа мәңге ышанасым юк, — диде Фәһимә, ирексездән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртә-сөртә. — Үз гомеренә беркем белән сугышканы юк бит аның.

— Син күз яшьләреңне агызырга ашыкма әле. Гаепнең Сәрия малаенда булуы да бар. Таһир дуамал егет түгел. Сугышкан сурәттә дә мин ул хаклыдыр дип уйлыйм.

— Мин хаклы дип кенә кеше кыйнамыйлар бит, Әхнәф.

— Без хәзер синең белән бу хакта күпме генә бәхәсләшсәк тә, очына чыга алмыйбыз. Әйдә, пилмәнне ясыйк. Ә әниләрне барыбер алып килергә туры киләчәк.

Алар шактый вакыт бер сүз дә дәшмичә пилмән ясадылар.

Аннары Фәһимә болай дип сүз башлады:

— Минем бит Хәят апаларда булганым бар. Әллә ничек ваклап-бүлгәләнеп беткән өй инде ул. Бүлмәләре бәләкәй. Минем әнкәйнең дә ялгыз яшәрлек рәте юк.

— Иркенләп яшәрлек түгел икәнен беләм инде мин ул өйнең.

Фәһимә аның беләгенә кагылып куйды.

— Янкорма салырбыз! Кешеләр бит шулай зурайталар өйләрен.

Фәһимәнең шул сүзеннән соң гына Әхнәф яшереп саклаган фикерен оста уенчы уен тузын ыргыткандай әйтеп салды:

— Арслановлар йорты безгә тәтемәс тә кебек әле ул...

Фәһимәнең фаршлы калагы кулыннан төшеп китте:

— Нәрсә?!

— Малае белән кызы кайтырга йөри, диләр.

— Гайбәт, гайбәт! — диде Фәһимә, ярсып. — Ничек инде андый нәрсә булсын?!

— Беркөн Рашаты минем янга кереп чыкты инде.

Әхнәфнең бу сүзләрен ишеткәч, Фәһимә шартлап урындыкка утырды.

— Әйе, кайтканын сөйләгәннәр иде.

— Ул да пропискадан төшмәгән булган, — дип дәвам итте Әхнәф. — Болынкырга яшәргә кайтасы килгән дә кебек...

— Юк, юк, йортны аларда калдыру мөмкин түгел! Обком бар бит әле.

— Обкомда Арслановның үз кешеләре. Барысы да мөмкин.

— Ә без?! — диде Фәһимә, ачыргаланып. — Без шушы бәләкәй өйдә калабызмыни?

Әхнәф хатынының нәкъ үзе теләгән эзгә килеп төшкәнлеген аңлады.

— Мине дә шул сорау борчый шул. — Ул көмеш кашык белән өстәлгә шакы-шокы суккалап шактый вакыт торды. — Әллә безгә яңа йорт салу турында уйларгамы, карчык? Анда күчеп, олылыклап ремонт ясатып, янкорма төзеп җәфа чиккәнче, шулай әйбәтрәк булмас микән?

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәһимәнең йөзе кояштай балкып китте, күзләре уттай янарга тотынды.

— Ну баш та үзеңдә! — Өйдә икесе генә булсалар да, ул як-ягына каранып куйды, Әхнәфне биленнән кочаклап, колагына пышылдады: — Төзик бер дигән итеп! Син бит моны булдырасың!

Әхнәф аңа җавап бирергә өлгермәде, Таһир кайтып керде. Ул мышык-мышык борынын тарта, уң як яңагында кып-кызыл булып сузылган яра эзе ярылып ята иде.

— Битеңне кайда сыдырттың, улым? — диде Әхнәф, аңа якын ук килеп.

— Парктан агач арасыннан бара идек, ботакка эләкте, — диде дә Таһир җәһәт кенә үз бүлмәсенә кереп китте.

Әхнәф белән Фәһимә бер-берсенә сүзсез генә карашып алдылар. Күпме көтсәләр дә, Таһир чыкмады.

— Чакырыйк, — диде Фәһимә, түземлеген җуеп.

— Бар, эндәш. Мин залга чыгып утырам.

Аның артыннан ук Таһир белән Фәһимә керде.

— Әллә берәр нәрсә булдымы, улым?

Әтисенең бу соравыннан Таһир сискәнеп киткәндәй булды.

— Ю-у-у-ук, — дип сузды ул, акрын гына.

— Син яшермә, — дип сүзгә кушылды Фәһимә. — Кулларың да тырналган.

Таһир аның бу сүзенә бөтенләй җавап бирмәде.

— Йә, сөйләп бир. Без бит әниең белән барысын да беләбез.

Таһир аларның әле берсенә, әле икенчесенә карады. Әлеге сүзләр аның кыяфәтен шундук үзгәртте: йөзе кып-кызыл булды, ул, чыгып китәргә теләгәндәй, ишеккә таба омтылды, тешләрен кысып туктап калды.

— Йә, көтәбез.

— Бер әйбер дә юк дидем бит инде...

— Илшат белән ни булды? — Фәһимә малаеның күзләренә туп-туры карады. — Аның әнисе безгә килде, милициягә хәбәр итәм, ди.

Әнисенең бу сүзләреннән соң Таһир башын аска иде.

— Ул бит үзе... өч малай ияртеп каршыга чыкты...

— Университеттан кайтып, бала-чага белән сугышып йөргәч, әйбәт инде ул, — диде Фәһимә, шелтәле тавыш белән. — Әтиеңә шуннан соң ничек халык каршына чыгарга, ничек аларны тәрбияләргә кала инде? Милиция хәбәр итсә, университеттан да куарга мөмкиннәр.

— Гаеп аның үзендә, — диде Таһир, каш астыннан күзләрен усал елтыратып. — Аны мәктәптә беркем дә яратмый. Кызларга чат ябыша, бәйләнә. Кайберләренә кул да күтәргән.

— Ә-ә-ә, син шул кызларны яклаучы булып Казаннан кайттың инде, әйеме? — диде Әхнәф, киная белән.

— Мин берсен генә яикладым.

— Сер булмаса, әйт инде, кайсысын?

Таһир эндәшмичә шактый торды. Дулкынланудан аның каш-керфекләре сикерештеләр.

— Айгөлне яикладым. Илшат аны былтырдан бирле кыерсыта.

— Кайсы Айгөлне? — диде Фәһимә.

— Сөембикә апа кызын.

— Ә сиңа ник кирәк ул? — диде Фәһимә, чәрелдәп. — Кем ул сиңа?!

Гаҗәпләнүдән Таһирның күзләре зураеп китте:

— Ничек инде, әни?! Сез бит Сөембикә апа белән... Ирек абый белән дуслар. Ничек инде мин Айгөлне кыерсыттырыйм...

— Дуслар идегез, диген. — Фәһимә ачуыннан аяк тибеп куйды. — Яшь чакта булган да җилгә очкан! Кайчандыр аралашкан һәрбер кеше өчен сугышып йөри башласаң, безгә монда ничек яшәргә?!

— Ярый, барысы да аңлашылды, — диде Әхнәф. — Эшне зурга җибәрмәскә кирәк. Син хәзер үк киенеп Сәрияләргә

бар, Илшаттан гафу үтен. Югыйсә эшнең катлаулануы мөмкин.

— Син нәрсә, әти?! — диде Таһир, ярсулы тавыш белән. — Алар бит үзләре мине кыйнарга килделәр. Егып, туйганчы типкәләделәр. Гафу үтенү... Алайга китсә, мин үзем милициягә әйтергә тиеш.

— Син бит булачак юрист. Шаһитларың бармы соң?

— Каян булсын? Без бит аулак почмакта.

— Димәк, барыбер син гаепле. Гафу үтенмәсәң, өйләренә бар, әнисе белән сөйләш.

— Юк, үзен генә җибәрмим, — диде Фәһимә, ярсып. — Бергәләп барабыз, бергәләп аңлатабыз!

— Нишләп мин сине ияртеп йөрим инде, әни? — Таһир бераз уйланып торды да ныклы карарга килде: — Ярый, сезнең хакка барам. Тик үзем генә.

Таһир чөйдә эленеп торган курткасы янына барды да, аның кесәсеннән нидер алып, аларның каршына килде:

— Менә Илшат минем яңакка нәрсә белән сыдырды, — диде.

Таһирның кулында велосипед чылбыры иде. Әхнәф малаеның кулыннан чылбырны алды да җентекләп карарга кереште.

— Сез бөтенләй башка тормыш белән яшисез бугай, улым, — диде ул, баш чайкап. — Безнең дә яшь чаклар бар иде. Күпме еллар комсомолда эшләдем. Әмма мондый рәхимсезлекне күргән булмады. Хәзер көн саен әле бер, әле икенче авылдан яшьләр арасында булган тәртипсезлекләр турында чәчләреңне үрә торгызырлык хәбәрләр килә. Чылбырыңны өйдә калдырып тор әле...

Таһир чыгып киткәч, Әхнәф Фәһимәне тынычландыра алмыйча бик озак азапланды.

...Әхнәф авылларына бөтенләй кайтмаган иде. Әйе, ул алдады. Инде күптән эчендә яшереп йөрткән уен башлап Фәһимә авызыннан әйттерү өчен алдады. Шуңа күрә иртәгә иртүк әти-әнисе алдындагы гаебен юарга авылга кайтырга карар кылды. Әтисе инде алтынчы ел параличланган хәлдә. Гомер буе физкультура укыткан, йөгерү, чаңгы буенча разрядлы спортчы. Чирнең ни икәнен белмәгән әтисен инсульт бәреп еккач, авыл халкы аһ итте. Ул, коточкыч авыр әйберне бау белән үзенә таба тарткан кешедәй, гәүдәсен алга авыштырып, юньләп бөгелмәгән аякларын көч-хәл белән сөйрәп, капка төбенә чыгып утыра. Кем килсә дә, йөзе кинәт чалшая, һәм ул тавышсыз гына еларга керешә. Аның туктаусыз яшь агучы күзләренә, йөзендәге газаплану билгеләренә карагач, Әхнәфнең үзенең дә күңеле тула...

Әйе, иртәгә иртүк кайтып киләчәк ул алар янына.

## 12

Бүген эштән кайтканда, Сөембикәгә култыклашып баручы әллә ничә пар очрады. Алар көлешә-көлешә сөйләшеп урамнан атлыйлар, йөзләрендә канәгатьлек билгесе, алар иртәсенкичен дә, бүген-иртәгә дә гел бергә. Сөембикәнең исә сөялеп торыйм дисә бакчасында ялгыз миләше генә бар. Тик аның белән серләреңне уртаклашып булмый, ул синең күкрәкләрең белән терәлүеңә дә битараф... Соңгы вакытларда ялгызлык дигән нәрсә бәгыренә кадалган усал сөлек кебек суырды да суырды аны. Ул суырган саен, кояш яктырак, тормыш матуррак, кешеләр бәхетлерәк кебек тоелды. Элек аның өчен агач яфраклары шаулашкан, кошлар чыркылдашкан кебек тоелса, хәзер ул тавышлар Сөембикәгә аларның үзара сөйләшүе булып тоелды. Хәтта аларның да сөйләшерлек нindидер уртак нәрсәләре бар, бары тик мин генә ялгыз, дип кайчакларда сагышланды Сөембикә. Ул алардан көнләшә, кайчакларда бөтен дөньясына ачуы килә, кайчакларда бөтенләй төшенкелеккә бирелә, кайчакларда күзенә бер генә якты нур да чалынмый, хәтерен котырган этләр өере кебек гел караңгы истәлекләр генә яралап тора. Шушы тойгылар әледән-әле йокыдан уяталар, ул әйләнә-тулгана җәймәсен, одеялын бау кебек ишеп бетерә, бер рәхәтләнеп еласам, җиңеләеп калыр идем, ди, әмма елый алмый. Андый чакта күктә ай булса, күңеленнән шуның белән сөйләшә. Сөембикә инде хәзер айның гашыйклар өчен түгел, йоклый алмыйча газапланучы ялгызлар өчен чыгуын аңлады. Ул, су сибелмәгән гөл кебек, көннән-көн сула баруын сизде. Авылда чакта әнисенең ни өчен кич клубка чыгармаганлыгын төшенә башлады. Сөембикәдән «Кая да булса укырга керәм, эшкә керәм» дигән сүзләрне ишеткәч, әнисенең елый-елый «Беркая да җибәрмим! Синнән башка мин үләм!» дип ни өчен өзгәләнүләре аңа хәзер генә барып җитте. Авыл мәктәбендә укыганда, Сөембикә әнисен күралмый, аның юри ачуын китерә, каршы әйтә, аның белән әрепләшә иде. «Синең яныңда шешәң, стаканың бар», — дип, аны елаткан чаклары да күп булды. Ялгызлык дигән аждаһа үз өстенә килеп иңгәч кенә, тавышсыз кычкырып тыпырчынырга тотынды. Айлы төннәр ялгыз адәм баласының уйларын җил кебек әллә кайларга очырып алып китеп, урманнар-кырлар өстеннән, йолдызлар-айлар яныннан йөртеп, әллә ничә катлам елларны үтеп, яшьлек чорларына, бала чакларга ук алып кайта ала икән. Ах, ул айлы төннәр! Яшь чакта сихри булган ул төннәр нишләптер уйларны, үзләренең көмеш нурларына күтәреп, менә шулай йөртәләр-йөртәләр дә, җиһанның кайсыдыр урынында дулкынланып торучы сагыш диңгезләрендә чайкап, сиңа кире кайтаралар.

Шушындый айлы кичләрдә, Сөембикәне хәйран калдырып, бер вакыйга хәтеренә килә башлады. Алар ничәнчедер класста укыганда, җәй көне Казанга экскурсиягә барганнар иде. Барысын да тулай торакка урнаштырдылар, ә тулай торакның ишегалдында су колонкасы бар. Көне буе шәһәр карап йөреп, тирләп-пешеп, аяк табаннары ут булып янып кайткач, шул колонкага чыгып, барысы да рәхәтләнеп юыналар, су сибешәләр, туйганчы чыркылдашалар иде. Сөембикәләр Казанда дүрт-биш көн булдылар. Иртәгә кайтабыз дигән көнне кич ул йоклый алмыйча азапланды.

Төнге уникеләрдә, ичмасам, салкын су белән аякларны юып кереп ятыйм әле дип, теге колонкага чыкса, төннең якты-лыгына, күктәге айның кояштай балкуына хәйран калды. Аяк астында яткан энәне дә аермачык күрерлек төн иде бу. Сөембикә, ике тезен бергә терәп, колонкадан су агыза башлады. Шулчак кемдер, арттан килеп, колонканың тимерен күтәрде, су агудан туктады, Сөембикә ялт итеп артына борылды, суны туктатучыга карады. Ул ап-ак күлмәк, шундый ук чалбар кигән, кояшта янып каралган, кап-кара чәчле егет иде.

— Гафу итегез, — диде ул, тигез ак тешләрен күрсәтеп елмая-елмая. — Гомерлек чир алуыгыз мөмкин.

— Ә бәлки, мин чирләргә телимдер, — диде Сөембикә, чытлыкланып, һәм кабат су агыза башлады. — Бәлки, минем бу дөньядан китәсем килә торгандыр.

— Алай булса, — дип, егет колонка тимерен күтәрде, — сез ялгышасыз. Адәм баласы дөньяга бик авырлык белән килә. Ә сезнең кебек чибәр кызлар бигрәк тә сирәк туа, — диде егет, серле итеп карап.

Сөембикә, кинәт кенә колонканың тимеренә басып, учына су агызды да егеткә чәчеп җибәрде һәм, көлә-көлә:

— Борын астыңа су чәчрәде, сөрт! — дип йөгереп кереп китте.

Малайлар торакның икенче башында торалар, бу егетне аның килгән көнне дә күргәне бар иде. Икенче көнне автобуска утырганда, теге егет аны эзләп тапты.

— Минем исемем Айдар, — диде ул, мәхәббәтле караш ташлап. — Сез кайдан?

— Болынкырдан.

— Ә исемегез?

— Сөембикә.

— О-о-о, нинди тарихи исем! — диде Айдар. — Мин үзем Молдавиядән.

Аларны автобуска чакырдылар, икесе дә нидер әйтмәкче булды, ләкин вакыт калмаган иде инде. Айдар да үзенең автобусына таба йөгерде. Айлы төннәр нишләптер шушы сихри очрашуны Сөембикәнең хәтерендә туктаусыз яңарт-

тылар. Яңарган саен ул очрашуга яңадан-яңа матур бизәкләр өстәлде. Егетнең уң як теше бераз китегрәк икәне дә хәтеренә төште. Әмма шушы китек теш аңа әйтеп бетергесез сөйкемлелек бирә иде...

Ялгызлык, йокысыз төннәр аша ул тагын бик күп нәрсәләрне аңлады. Айгөл белән алар арасындагы мөнәсәбәтләр торган саен җитдиләнә бара. Соңгы вакытта кызындагы ниндидер яшерен үзгәрешне Сөембикә чамалый, гөманламакчы була, әмма моның асылына төшенә алмыйча җәфалана. Әйтмичә кинәт кенә өйдән чыгып китүләр, кичләрен соң кайтулар, көндәлегендә моңарчы булмаган өчлеләрнең күренә башлавы аны бик тә борчый иде. Менә хәзер бер атна кичен Ирекләргә китә. Икешәр, өчәр сәгать шунда булып кайта. Ниләр сөйләштегез, дигәч, берни дә әйтми. Вак-төяк инде шунда, ди дә куя. Ирек белән Зәнфирә аңа начар йогынты ясарлар дип һич тә уйламый ул. Ләкин йогынты төрлечә була. Әгәр ул анда еш бара башлаган икән, аңардан ерагая дигән сүз.

Сөембикә бүген эшеннән арып-талчыгып, кәефсез кайтты. Өйдә булмагач, Айгөлне ул мәктәптәдер дип уйлады. Әмма кызы караңгы төшкәч тә, сәгать төнге ун тулгач та күренмәде. Ул машинасын ишегалдына куйган иде. Унберенче киткәч, түзмәде, кабалана-кабалана киенде дә, машинасын кабызып, Ирекләргә юл тотты. Анда барып керүе кыен булса да, эчендәге шайтанның «ничек яшиләр икән — күз генә салып чык» дип аны гел котыртып торуына түзә алмады, җиңелде.

Ирек кәгазь өеменә чумып язып утыра, Зәнфирә кече якта мәшәләнә иде. Сөембикә килеп кергәч, алар икесе дә аның каршына килделәр.

— Әйдә, түрдән уз, — диде Зәнфирә, беренче булып.

— Юк, уза тормыйм, мин Айгөлне алып кайтыйм дип кенә килгән идем.

— Айгөл? — диде Ирек, аның ни әйткәнен аңламагандай төртелеп калып. — Ул бездә юк бит.

— Сезгә дип киткән иде. Ә кичә булдымы соң?

Зәнфирә белән Ирек бер-берсенә карашып куйдылар.

— Аның бездә күптән булганы юк инде. Әле үзем шылтыратмакчы идем, авырып-мазар китмәде микән дип.

Сөембикәнең буыннары мамыктай йомшап киттеләр. Димәк, Айгөл ничә көннәр буе аны алдаган! Ул колак очы белән генә Ирек белән Зәнфирәнең үзен түргә узарга кыстауларын ишетте, әмма аларның бер генә сүзе дә башына барып җитмәде.

— Ярый, хушыгыз, — диде дә кабаланып чыгып китте.

Тыкрык башына җиткәч, олы юлдан килүче машинаның каршына чыга язды, зиһене тәмам таралган иде. Теге шофер машинасын туктатты да, йөгереп килеп, «уазик»ның ишеген

ачып җибәрде. Руль артында хатын-кыз икәнлеген күргәч, тозлап-борычлап сүгенгән җиреннән:

— Син нәрсә, түти, әллә исерекме?! — дип җикереп җибәрде. — Әгәр хатын-кыз булмасаң, авызыңа берне ямый идем! — дип китеп барды.

Сөембикәнең ике чигәсе сызлый башлады, аяклары дер-дер килде. Була язып калган фаҗиганең үзенә кагылган җилен ул хәзер генә аңлады. Акрын гына кузгалып китте. Бәлкем, кайткандыр дип, өенә юнәлде, тик ут юк иде. Машинаны туктатып, бераз уйланып утыргач, Сөембикә тагын кузгалды. Ул аның Чукаеваларга бара торган гадәтен белә иде. Гандәлифә карчыкның капкасының ачык булуын, өендә ут януын күргәч, һичшиксез, шушында икән дигән өмет уянды. Ишек эчтән бикле иде. Дөбердәтүгә Чукаева аны ачып җибәрде. Алар өйгә керделәр, әмма Айгөл биредә дә юк иде.

— Әйдәгез, узыгыз.

— Мин Айгөл юк микән дип килгән идем.

— Юк шул. Нишләптер кагылмый башлады әле ул.

Сөембикә ишек янындагы урындыкка утырмыйча булдыра алмады.

— Берәр төрле йөрәк даруыгыз юкмы? — диде ул, күкрәген тотып.

Гандәлифә аңа корвалол салып бирде. Аны эчкәч, Сөембикә сулышының иркенәюен тойды, әмма күңеле тынычлана алмады.

— Болай бусага янында утырып булмый инде. Зинһар, узыгыз.

Аның сүзләренә буйсынып, Сөембикә, курткасын, итеген салып, өстәл янына узды. Гандәлифә термостан агызып икесенә дә мәтрүшкәле кайнар чәй алып килде.

— Бик борчылгансыз, берәр нәрсә булдымы әллә?

— Булуын булмады да... Ялгыз кешенең хәлен сезгә сөйләргә кирәк түгелдер. Айгөл — минем күз нурым. Ә аның кайтып та кергәне юк. Берүзем көтәм дә көтәм. Мин шулкадәр ялгыз, шулкадәр ялгыз!.. — Сөембикә күзеннән яшь бәреп чыгуын сизми дә калды. Кулъяулыгын чыгарып, ул күзләрен, битен сөртеп алды. — Аның сезнең янга килгәләп йөрүенә куанам, рәхмәт сезгә. Ул да бит ятим бала, кая барып бәрелергә белми торгандыр. Шулай да сез аны кичләрен кагылганда тизрәк кайтарып җибәрсәгез иде.

Гандәлифә аның бу сүзләренә «ә» дә, «җә» дә димәде.

— Турысын әйтүем өчен гафу итегез, — дип башлады ул сүзен, шактый күп вакыт үткәч. — Сезне япа-ялгыз итүче гаепле кешене беләм кебек мин.

Сөембикә аптырап китте. Чукаевадан ул мондый сүзләр көтмәгән иде. Әллә Айгөл берәр нәрсә сөйләде микән?

— Мин андый кешене белмим, бу минем өчен яңалык, — диде Сөембикә, аптырап.

— Юк, сез аны бик яхшы беләсез. Ул кеше— сез үзегез!

«Минем үткәндәге тормышым турында хәбәрдар микәнни бу?» — дип уйлады Сөембикә аңа рәнҗеп. Халык арасында аның турында гайбәтләр йөри микәнни? Инде бит ир-ат кулы тотып карамаганына да ничә еллар. Әнә бит Чукаеваның карашы нинди усал, ачулы. Димәк, ул Сөембикәне гаепли.

— Рәхмәт турысын әйтүегез өчен, — диде Сөембикә, чыгып китәргә урыныннан торып.

— Әз генә сабыр итегез! — дип туктатты аны Чукаева. — Әгәр түземлегегез җитсә, әйтеп бетерәм.

Аның сүзләре Сөембикәне бер яклап куркытсалар, икенче яклап кызыксыну уяттылар. Чыннан да, халык аның турында ни сөйли икән?

— Мин сезне тыңлыйм. Тик яшермичә сөйләгез...

— Йокысызлыктан интеккән карчыкның саташкан уйлары димәсәгез, сөйлим. — Чукаеваның кырыс карашы кинәт ягымлылангандай булды, тавышы да йомшарып китте. — Сез берничек тә ялгыз була алмыйсыз. Ник дисәң, һәр көн кешеләр арасына мәҗбүриләп тартып алып керә торган эшегез бар. Сез сау-сәламәт, яшь, чибәр, талантлы. Мин санаган әйберләр— үзләре генә дә сезнең иң якын дусларыгыз инде. Аларның һәрберсе кешеләрне ымсындыра, үзенә тарта. Теләсәгез дә ялгыз була алмыйсыз сез! Сез әнә шул ялгыз дигән уегыз белән тормышыгызны агулыйсыз, үзүзегезгә бикләнергә азапланасыз. Ә бу иң әшәке чир, ул кешене үтерә!

— Болар барысы да сүзләр бит, Гандәлифә апа, — диде Сөембикә, авыр сулап. — Китап сүзләре, шигъри сүзләр.

— Ашыкмагыз! Китаплар да тормыштан алына, — дип дәвам итте Чукаева. — Менә мин сезгә үз тарихымны сөйлим. Авыл хуҗалыгы институтында укый башлаганда, мин куркак куян баласы идем. Мине, гарип бәбкәне сау-сәламәт бәбкәләр туктаусыз талаган кебек, рәнҗетеп, кыерсытып, тулай тораклан да сөрделәр. Бәхетемә, шундагы бер укытучы, кызганып, квартира табып бирде. Ул— рус театрында эшләүче ялгыз марҗа иде. Ире татар булган, безнеңчә теттереп сөйләшә. Берәр атна торгач, бу минем кем икәнне аңлады бит. «Тормышта син болай яши алмыйсың, балам, — ди. — Сине таптап, изеп китәчәкләр. Шәһәрдә яшәргә теләсәң, усал булырга кирәк», — ди. Мин инде моны үзем дә аңлый башлаган идем. Ничәмә-ничә мәртәбәләр мине сәгатьләр буе торган чиратымнан төртеп чыгардылар. Трамвай, троллейбуска утыра алмыйча калучы да мин идем. «Мин усал була алмыйм», — дидем мин аңа. Ә ул болай ди: «Менә мин

сәхнәдә, кирәк булса карак булам, кирәк булса — фахишә, кирәк булса — министр, — ди. — Ә асылда барыбер үзем килеш калам. Әйдә, мин сиңа бер роль бирәм, — ди. — Син шуны гына уйна. Коточкыч усал булып кылан. Кемдер сиңа ташланганчы, син үзенә ташлан. Кемдер сиңа бер сүз әйткәнче, син унны әйт. Ташбаканы сыртындагы каты кабырчыгы саклаган кебек, шушы сине саклар», — ди. Башта ул мине җитәкләп, үзе өйрәтеп йөрде. Тирләдем, пештем,ниләр генә булып бетмәде. Өйрәндем бит, әй! Үзебезнең группадагы иптәшләр дә минем шулай кыюланып, усалланып китүемә хәйран калдылар. Ярар, хәзер Казанда патша булып йөрим. Мине белгән кешеләр куркалар, бәрелешкә керергә теләмиләр. Болынкырга институт бетереп эшкә килгәндә, эчемдә һаман шул элекке куян калтырап утыра, ә үзем усал итеп карыйм, усал итеп сөйләшәм, пәрмә-пәр талашам. Болынкыр халкы арттан пышы-пышы килеп кала, йөзләрендә курку билгесе, ә мин эчтән генә көләм. Бу гадәтем миңа бик күп дуслар китерде. Җыелышларда райондагы гаделсезлекләрне тәнкыйтьлим, булдыксыз җитәкчеләрне пыр туздырып сүгәм бит, хәтта урамда кычкырып йөрим. Әнә шулай курка-курка усаллана торгач, курыкмый торганга әвереләдем. Әкияттәге камырдан әвәләп ясалган Камыр батыр кебек, үземне үзем әвәләп ясадым. Менә мин кем! Ә ялгызлык онытылды! Качты ул. Минем хәзер, гомер буе инспекциядә эшләгәндә үз кулларымнан тикшерү узган чәчү орлыклары кебек, якыннарымның, танышларымның исәбе-хисабы юк.

Чукаева туктап калды, Сөембикә хәйран калып баш чайкады:

— Бу мөмкин әйбер түгел! Үз-үзеңне үзгәртү, белмим, монысы әкияттә генә буладыр.

— Алайса, тере әкият каршыгызда утыра. Безнең бер этебез бар иде. Аның кебек усал итеп тешен ыржайткан, аның сыман куркыныч өргән этне белмим. Өргәндә, өзәм дигәндәй, буыла-буыла тамак төбе белән ырылдый, башларын чайкый. Аны күрүгә, кешеләрнең коты алына. Ә менә шул котырып өргән чакта янына кем дә булса килсә, аякларын күтәреп чалкан ята, койрыгын ялагайланып болгый иде. Ялгызлык дигән уйга юл куйсагыз, ул әлеге эт кебек сезнең котыгызны алачак! Ә курку кердеме— кеше бетте дигән сүз. Эшләгез бер батырлык! Ялгызлык дигән уйны күңелегездән куып чыгарыгыз!

Чукаеваның сөйләгәннәреннән айный алмыйча бик озак уйланып утырды Сөембикә. Ахырда:

— Тырышып карыйм әле, Гандәлифә апа, — диде.

— Ниятенә керсәгез, һичшиксез булдырачаксыз! — диде Чукаева, зур җанлану белән. — Мин сезгә тагын бер серем-

не ачыйм әле. Сезгә, яшь кешегә, бәлкем, кирәге чыгар. Адәм баласының тормыштан әйбәт булып китәсе килә икән. Картайгач бу нәрсәне мин бик нык аңладым. Кеше үзеннән нәрсә калуын уйлый. Олы эшләрең булса, әйбәт тә, ә булмаса? Халык хәтерендә истәлек кенә кала. Әйбәтме ул, начармы? Бу барыбер түгел икән. Шуңа күрә, җай чыккан саен, кешеләргә куркак, йомшак куян икәнемне сөйлим. Рәхәт булып китә, каһәр. Тик бу серне күпме генә сөйләсәм дә, мин инде бу дөньядан барыбер «усал Чукаева» булып китәрмен. Бөтен кешегә дә үземнең эчемне ачып бетерергә өлгерә алмам шул. Ә «усал» дигән исемне юып китәсе килә...

Сөембикә, аның яныннан чыкканда, ялгызлык тойгысыннан котылгандай җиңеләеп калган иде. Менә сиңа усал Чукаева! Күпме рухи җегәр бу карчыкта! Теге батырлыкны һичшиксез эшләячәк Сөембикә. Ул кайтышлый Яшьләр үзәгендәге дискотекага кагылырга булды. Акрын гына, сиздермичә генә керде дә почмактан күзәтеп тора башлады. Төрле утлар белән балкып торучы ярым караңгы залда кызлар, егетләр кыргый музыкага дөньяларын онытып бииләр. Бераз читтәрәк әле бала-чагалыктан чыгып җитмәгән яшьләр төркеменә күз ташлагач, Сөембикә тынычланып китте: Айгөл шунда иде. Аның башкаларга караганда сыгылмалырак, матуррак хәрәкәтләр ясавын ул шатланып күзәтте. Ничек кергән булса, шулай тып-тын гына чыгып та китте. Машинасына утырып кайтканда да, кайтып өйгә кергәч тә, башыннан бер уй чыкмады: Айгөл үсеп җиткән икән бит! Ул инде балалыктан чыгып бара, яшьлек хисләре аны үзе кебек кызлар, егетләр янына тарта. Димәк, ул атна буе дискотекага йөргән. Күрәсең, ул әле моны үзе өчен ярамаган эш дип кабул итә. Әгәр шулай булмаса, «әти янына барам» дип алдашыр идемени? Димәк, икесе арасындагы мөнәсәбәтләр турында гына түгел, кызының киләчәге хакында ныклап уйланыр көннәргә дә әллә ни ерак калмый...

## 13

Әхнәфнең үзләренең өен тәкъдим итүе әллә нинди бер серле әйбергә әверелде. Өй асылда бар да, юк та кебек. Аның тирәсендә купкан мәрәкә Ирекне генә түгел, Зәнфирәне дә чыгырыннан чыгарды бугай. Ирек инде ул өйдән курка ук башлады. Иңбашыннан тотып, башы белән ярамаган җиргә көчләп керткән кеше кебек тойды ул үзен. Артык күп кеше тырыша иде аны башы белән анда тыгарга. Ирекне шул сагайтты да. Әхнәф тә, Гаскәров та берничә тапкыр чакырдылар. Зәнфирә көн саен диярлек җайлап кына сүз уңаен китерә дә шул өйне кузгата. Алар тырышкан саен,

Ирек үҗәтләнеп баш тартты. Арслановлар кыш башында күчеп китеп бардылар, Әхнәф аның йортына күчәргә ашыкмады. Моны төрлечә юрадылар, гайбәт арты гайбәт таралды. Имеш тә, ул йортны малае Рашат даулый икән, Казандагы кызлары да кияве белән кайтырга җыена икән, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр.

Болынкыр халкы шулай йорт тирәсендә баш ватып яткан көннәрнең берсендә музейга Фәнис Сәлахов килеп керде.

— Миндә әллә кайчаннан бер бакыр акча ята, — дип, Иреккә борынгы акча сузды.

Аннары Сәлахов хәйран калып экспонатларны карап йөрде.

— Сездә мамонт тешләренә кадәр бар икән! Бер мәртәбә дә кергәнем юк иде, — дип тел шартлатты.

Музейда экспонатларны Сәлахов белән шактый карап йөргәннән соң, Ирек:

— Минем күптән бер әйбер сорыйсым килеп йөри, — диде. — Сез бит хуҗалык җитәкчесе, ничек оештыру бүлеге мөдире иттеләр?

Аның бу соравыннан Сәлахов көлеп куйды:

— Мин бит Югары партия мәктәбен бетергән кеше. Партия мәктәбенә кадәр югары белемле агроном идем. Шәрифуллин минем биографияне өйрәнгән. Сезгә килгәнче, мин райкомда оештыру бүлеге мөдире булып эшләгән идем. Кая гына барсам да, эшемнән «үз теләгем белән» җибәрделәр. Яшь чакта бик хыялый идем, хакыйкать өчен гомеремне дә бирергә әзер идем. Андый хыяллар белән дөрләгән чаклар еракта калды инде...

— Арсланов белән көрәшкәндә үзегезне бик шәп күрсәттегез. Әле йөрәгегездә ялкын сүнмәгән. Сезгә теләсә нинди очракта таянып була.

— Яхшы сүзегез өчен рәхмәт. — Сәлаховның йөзе уйчан төскә керде, җитдиләнде. — Тукай нәрсә дигән әле? «Бара милләт зәгыйфь, абыныр-абынмас, сүнә яшьләрдә ут, кабынbackcabынмас...»

Аның Тукай шигыреннән өзек китерүе Ирек өчен көтелмәгән яңалык булды. Моңа кадәр ул Фәнисне хуҗалык җитәкчесе, үтә дә кырыс кеше дип белә иде.

— Минем хәтерләвемчә, Тукайның бу шигырен ятлау мәктәп программасында юк иде.

— Тукайга мин балачактан ук гашыйк. Аның шигырьләренең шактыен яттан беләм. Сөйләп күрсәтимме?

— Сөйләгез әле. Мин һаман да ышанып бетә алмыйм. Менә минем аның «Кисекбаш»ын тыңлыйсым килә.

— Ә мин аны көнгә ун мәртәбә сөйләргә риза, — диде дә Сәлахов поэманы шундый тәэсирле итеп сөйләп чыкты.

Ирек аны тын да алмыйча тыңлады. Сөйләп бетергәч, чын күңеленнән Фәниснең кулын кысты һәм болай диде:

— Сезне музейда тере экспонат итеп тотарга кирәк. Тукайны белүче кеше дип.

Алар икесе дә рәхәтләнеп көлешеп куйдылар.

— Инде хәл-әхвәлләрне белешә башлаганбыз икән, бер сорау мөмкинме? — диде Сәлахов. — Сезне Шәрифуллин йортына керүдән баш тарткансыз диләр. Дөресме шул?

— Әйе, дөрес.

— Зерә-ә-ә. Начар түгел бит ул йорт.

— Нишләптер күңелем ятмый. Күңелемә каршы барсам, минем беркайчан да теләгемә ирешә алганым юк.

— Ялгышмасагыз ярый да.

— Әхнәф үзе дә күчәргә ашыкмый бит әле.

Бу сүзне ишеткәч, Сәлаховның йөзендәге тынычлык юкка чыкты, күз алмалары нәрсәдер эзләгәндәй йөгерештеләр. Аннары, кызыксынуын яшерә алмыйча, Ирекка шактый якын килеп:

— Сезгә сәбәбен әйткәне юкмы соң? — диде.

— Кызыксынганым да юк, әйткәне дә юк.

Ул киткәч, Ирекнең башына бер уй килде: Сәлахов инде ничә еллар катнаш азык заводының кечкенә квартирасында тора. Бу сүзне Әхнәф йортына үзе күзен салганга кузгатмады микән ул? Ирек, күңелендә дулаган давылдан котылырга ниятләп, аның артыннан ук Әхнәфкә китте.

— Мин сиңа, иптәш секретарь, бер шәп тәкъдим белән кердем әле, — диде ул.

— Йә, сөйлә.

— Синең йортыңны иң авыр эшне башкара торган уң кулыңа бирергә кирәк.

— Кем ул?

— Сәлахов. Өч баласы белән син аны кайчанга кадәр хәерче алачыгында яшәтмәкче буласың?

Бу сүзләрне ишеткәч, Әхнәфнең йөзендәге Ирекне каршылагандагы якты елмаю, самимилек, кояшны болыт каплагандай, шундук юкка чыкты. Ул үзенең халәтен яшерергә дә теләмәде.

— Мин сиңа рәнҗер идем, Ирек, әмма... — Ул нәрсәдер уйлап торды да өстәп куйды: — Синең әзрәк түбәң кыйшая башламады микән? Шуңа күрә рәнҗемим. — Аның күзендә усал очкыннар уйный башлады, кашлары җыерылды, тавышы да бөереннән чыкты: — Белеп тор: шул өйгә үзем дә кермим, башкага да бирмим! Синең кирелэнүеңә үч итеп мин дә киреләнәм!

Күп уйлаша торгач, Әхнәф белән Гаскәров бер уртак фикергә килделәр: Арсланов йортын көнкүреш комбинатына бирергә.

Халык телевизор, суыткыч, кер юу машинасы кебек әйберләрне ремонтлатырга күрше районнарга йөри. Болынкырда шушы эшне алып барырлык уңайлы бина таба алмыйлар иде. Ләкин һич көтмәгәндә аларның кабул ителгән карарын кырып җимерергә Чукаева күтәрелде. Ул Әхнәф бүлмәсенә өермә кебек килеп керде, исәнләшеп тә тормады, орлыкчылык инспекциясенең яралганнан бирле теләсә нинди иске биналарның берсеннән икенчесенә күчерелүе, тиешенчә эшләрлек бернинди шарт булмавы хакында йодрыгын Әхнәфнең борын төбендә селти-селти, ярты сәгать буе ярсыды. Череп беткән, җылытылмый торган салкын биналарда йөри-йөри, бөтен сәламәтлегемне югалттым, диде, сез орлыкчылык эшенә болай төкереп каравыгыз белән игенчелекнең тамырына балта чабасыз, диде. Әгәр шушы йортны орлыкчылыкка бирмәсәгез, партия Үзәк Комитетына, Генераль секретарьның үзенә үк язам, диде. Әхнәф, аны көйләп-чөйләп чыгарып җибәргәч, телефон шылтыравына да җавап бирмичә, килгән кешеләрне дә кабул итмичә, кара уйга батып бик озак утырды. Әле бит ул чыгып киткәндә кабат йодрык янады. Әгәр минем шушы үтенечемне канәгатьләндермәсәгез, белеп торыгыз, мин сезнең мәңгелек дошманыгыз булам, диде. Чукаева белән дошманлашу запалы алынган граната өстенә утыру белән бер иде. Ул йортны көнкүреш хезмәтенә бирдең ни, орлыкчылыкка бирдең ни — моның әллә ни аермасы юк. Тик Әхнәф өчен бер кыен ягы шунда: Гаскәров белән инде күпме вакытлардан бирле әвәләп килешенгән фикердән кире кайтырга кирәк иде. Моның кем аркасында ясалганлыгын Сәет Мөбарәкович кына түгел, халык та беләчәк. Син бер генә мәртәбә чиген — абруең төшә дә китә. Әһә, диячәкләр, моның нечкә җире бар икән бит, диячәкләр, моны куркытып була икән бит, дип куаначаклар. Кемнәрдер шул юл белән үз дигәннәренә ирешү өчен җиң сызганып эшкә дә керешәчәк. Өч көн баш ватты Әхнәф. Шулай да горурлыгын җиңә алды, Гаскәровны чакырып хәлне сөйләп бирде. Тагын тарткалаш башланды. Гаскәров төп дәлил итеп халыкның ризасызлыгын, интегүен китерде һәм ул хаклы иде. Уйлаша торгач, анысына да урын таптылар. Шул көнне үк Әхнәф Арслановның өенә китте. Аның ихаталарын караштырып чыккач, Чукаеванықына сугылды. Беренче секретарьның үз өенә килеп керүен күргәч, Гандәлифә аптырап китте, аны түргә дәште, чәй эчәргә чакырды. Ләкин Әхнәф каттый төстә баш тартты, кешеләр көтеп тора, биш кенә минутка кагылдым, диде.

— Тәкъдимегезне кат-кат уйлаганнан соң, сезнең белән килештем, — диде Әхнәф. — Йортны инспекциягә бирәбез.

Бу яңалыкны ишеткәч, Гандәлифә нишләргә белмәде, туктаусыз рәхмәт укыды, мәңгегә сезнең турылыклы ярдәмчегез булырмын, диде.

Әхнәф ишегалдына чыккач, аңардан:

— Гандәлифә Нәҗмиевна, кирәк әйберләрегез юкмы соң? — дип сорады.

— Юк, юк, рәхмәт.

Әхнәф абзарга таба атлады, андагы кәҗәләргә, сарыкларга күз төшерде.

— Печәнегез кайда соң?

Утар түбәсенә күз аткач, анда куанырлык нәрсә күрмәде Әхнәф. Капкадан чыкканда, Чукаева аны беләгеннән тотып туктатты.

— Иптәш Шәрифуллин, нәрсә булды? — диде ул, күзләрен мөлдерәтеп.

— Ник андый сорау бирдегез?

— Мондый хәлнең гомергә булганы юк иде бит. Җитәкче кешенең ихатага кереп хәл белешүе...

— Беренче секретарь күршегездә генә иде бит. Аңа барысы да күренеп торган, шуңа кермәгән.

Әхнәф кычкырып көлеп куйды, аннары кинәт җитди кыяфәткә керде һәм акрын гына болай диде:

— Минем бер үтенечем бар, Гандәлифә Нәҗмиевна, сез инде, зинһар өчен, Арсланов йортын инспекциягә мин алып бирдем, дип йөри күрмәгез. Сүз бирә аласызмы?

— Теш арамнан да чыкмас, — диде Гандәлифә. — Ышаныгыз.

Әхнәф Чукаева яныннан кайту белән авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигына шылтыратты. Аның кушуы буенча икенче көнне үк Чукаеваның ишегалдына бер машина урман печәне, бер трактор арбасы салам кайтарып аудардылар.

Арсланов йортын инспекция өчен үзгәртеп эшли башлагач, Зәнфирәнең кәефе кырылды. Дөрес, ул Ирекқә авыз ачып бер сүз дә әйтмәде, ләкин аларның гөрләп барган тормышы җәһәт-җәһәт атлаган кеше сулышы кабып туктагандай тынып калды. Өйдә бала-чага кебек элеккеге гөнаһсыз үртәшүләр, шаярып сөйләшүләр дә бетте. Моның сәбәбен алар икесе дә беләләр иде.

Беркөнне эштән кайткач, Зәнфирәнең тәрәзәгә караган килеш уйланып утыруына Ирек, эче пошып:

— Син землянкада яшәргә дә риза идең, фикерең үзгәрде, ахрысы? — дип куйды.

Зәнфирә, аның дәшүен генә көткәндәй, әләктереп кенә алды:

— Риза булу әле ул землянка казый башлау дигән сүз түгел! Ә безгә шул калачак, менә күрерсең!

Шуннан соң күп тә үтмәде, Зәнфирәнең Гаскәровка керергә аның кабул итү бүлмәсендә утырганын ишетте Ирек. Хатынының нигә керүен сорагач, ул:

— Авылдагы өйне сату мәсьәләсен сөйләштек, — диде.

— Ничек инде? — диде Ирек, гаҗәпләнеп. — Ничек сата аласың син аны?!

— Башка чараң булмагач, нишлисең? Акчасына берәр өй алырбыз.

— Ә Зирәк? Заһит абыйның сеңелләре шунда яшәп ята.

— Ничек тә килешербез әле, — диде Зәнфирә.

— Син бу уеңны ташла! — диде Ирек, ачуын яшерә алмыйча. — Кешелекле әйбер түгел бу. Саткан сурәттә сине авылдашлар мәңге гафу итмәс.

Зәнфирә әллә ничек сәер итеп елмайды. Аның күз карашында шаяру, мутлану галәмәтләре дә чагылып китте кебек.

— Ул өйдә минем тулы хакым бар. Ниятемнән чигенмәячәкмен.

Ирек аның ялгышын аңлатырга теләде, ә хатыны һаман үзенекен тукыды. Күпме бергә яшәп әйткәләшкәннәре юк иде, бозылышып туктадылар. Атна буе юньләп сөйләшмәделәр, ашаган ризыкның тәме китте, күздән йокы качты.

Шулай яшәгәндә, беркөнне Зәнфирә эштән очынып кайтты. Ирек сорарга да өлгерә алмады, ул шатлыгы белән үзе уртаклашырга ашыкты:

— Больница безгә квартира салачак!

— Кемгә ул «безгә»?

— Миңа инде алайса, миңа!

Эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенгән Ирек ни әйтергә белмичә телен тешләде. Берничә көннән баш врачның хуҗалык буенча урынбасары кереп: «Иртәгә фундамент блоклары кайтачак, кран белән бушатырга урын әзерләгез», — дип китте. Иртәгесен бәрәңге бакчасының коймасына терәп блоклар бушаттылар. Аларны ташу шактый дәвам итте. Язга таба йортның бурасы да кайтарып утыртылды. Ихатага такталар да килеп керде. Эчтән өнәмичә, тыштан эндәшмичә йөрсә дә, үзенең бәләкәй иске өе белән уртада бөрешеп калуын тойды Ирек. Тай нихәтле тәртәгә дошман булса да, ат булгач үзе кергән кебек, Ирек тә бирешүен аңлады. Май аенда, бәрәңге бакчасын экскаватор белән казып, блокларны салдылар. Ишегалдында бүрәнә эшкәртү башланды, олы хәрәкәт кузгалды. Ниргә арты ниргә күтәрелде. Зәнфирә язгы күбәләкләр белән бергә очып кына йөрде. Ирек инде бернигә дә карышмады, осталар чакырганда бүрәнә башына барып ябышты, күтәрешеп салышты, эш коралларын җыеп алып керде, иртән алып чыгып бирде. Ә үзенең эчендә ниндидер килешмәүчән нәрсә утыра бирде. Кысрыклаучы теге билгесез көчкә каршы тора алмавына, йомшаклыгына эченнән акрын гына сызды, алдың белән керсәң, артың белән дә чыга алмавың бар дип хафаланды...

## 14

Быел урак бик авыр башланды. Техника туктаусыз кырыла, шуның өстенә явымнар да комачаулый, оештыру да җитми. Беренче секретарь булып эшли башлавының беренче көнендә үк хуҗалыкларга район үзәгеннән вәкилләр йөртмим дип сүз биргән Әхнәф аны бозарга мәҗбүр булды. Бюро карары белән хуҗалыкларга гына түгел, хәтта аерым бригадаларга да вәкилләр билгеләнде. Шуннан соң әз генә алга таба кымшану сизелде кебек. Ләкин бу әле канәгатьләнерлек түгел иде. Партия өлкә комитетыннан, Министрлар Советыннан, Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан үтергеч шылтыратулар һәр көн йөрәкне телгәли.

Бүген иртән тагын ару гына яңгыр явып узды. Янә эш туктады. Яшен тизлегендә телеграмма бирдереп, Әхнәф барлык хуҗалык җитәкчеләрен, агрономнарны, инженерларны, партком секретарьларын, авыл Советы председательләрен райкомның киңәйтелгән бюросына чакыртты. Ул утырышлар залында нәкъ сәгать бердә башланды. Гаскәровның урыпҗыю эшләренә ясаган күзәтүеннән соң, берәм-берәм трибунага менгереп, колхоз-совхоз җитәкчеләрен тыңладылар. Соңыннан Әхнәф үзе, трибунага чыгып, һәр хуҗалыкка атналык задание җиткерде. Аны өзгән суәттә, партбилетларын кесәләренә салып, райком бюросына төшәчәкләрен искәртте. Ул сөйләгәндә, утырышлар залының президиум өстәле турындагы пыяла ишеге берничә мәртәбә ачылып ябылды. Аны ачып ябучы район эчке эшләр бүлеге начальнигы майор Мохтаров иде. Майорның түземсезләнүе Әхнәфнең ачуын китерде, фикерен таркатты. Ишек ачылган саен, президиумда утыручылар да шул якка борылып карадылар. Ахырда Фәнис Сәлахов түзмәде, Мохтаров ачкан ишектән коридорга чыкты һәм, ачуын яшерә алмыйча:

— Сез нәрсә, Мохтаров, астыгызга корт кергән кебек кыбырсыйсыз?! Бюро барганын күреп торасыз бит.

— Ашыкмыйча булмады шул, — диде Мохтаров, телеграмма сузып. — Алу белән монда йөгердем.

Сәлахов, телеграммага күз салгач, эсселе-суыклы булып китте. Анда райкомның барлык бүлмәләрен бикләп печатьләргә, милиция сагы куярга, бер сәгатьтән үтәлеш турында турыдан-туры Республика Эчке эшләр министрлыгына хәбәр итәргә кушылган иде.

Сәлахов телеграмманы тагын бер мәртәбә укып чыкты. Аның мәгънәсе әле һаман да аның башына барып җитми иде.

— Бу хакта беркемгә дә әйтмәдегезме?

— Юк.

— Алайса әйтми торыгыз. Бюродан соң элемтәгә керербез.

Сәлаховның кулына кәгазь тотып керүеннән, йөзенең агарып китүеннән Әхнәф ниндидер гайре табигый хәл булганын аңлады. Аның бу фикерен ныгытып, Сәлахов бармагы белән түгәрәк ясагандай итеп һәм күз карашы белән бюроны төгәлләргә ишарәләде. Әхнәф сүзен бетергәч, бюро яисә киңәшмәнең тәмам булуын әйтә һәм зал урыныннан кубып тора башлый иде. Бу юлы алай эшләмәде, Сәлаховтагы яңалыкны белеп, бәлкем, ашыгыч әйтергә туры килер дигән уй белән урынына барып утырды. Сәлахов аның алдына телеграмма куйды. Әхнәф телеграммадагы сүзләрне өч мәртәбә укып чыкты, алар аның күз алдында тере җан ияләре кебек сикерештеләр. Кемдер күрмәсен дигәндәй, ул телеграмманы арткы ягы белән әйләндереп салды, бармакларын кара-каршы китереп, бер-берсенә керештергәч, телеграмма өстенә бастырып куйды. Ул үзен бөтен тормышы бер селтәнүдә сызып атылган кеше итеп тойды. Аның өчен хәзер үзенә төбәлгән залдагы бу кешеләр бер чокырга кисеп аударылган агач өемедәй тоташ масса булып чайкалалар иде. Күрәсең, аның мондый халәте озаккарак сузылды, Сәлахов, аңа иелеп:

— Халыкны кайтарып җибәрик инде, — дип пышылдады.

Аның сүзләре Әхнәфне айнытып җибәрде. Ул, үзен кулга алып, көч-хәл белән аягүрә басты.

— Бюро тәмам, — диде ул, тонык тавыш белән. — Барыгыз да урыннарыгызда булыгыз. Андый-мондый... — Әхнәф телен тешләп туктап калды. «Андый-мондый хәл булса, хәбәр итәрбез», — дип, чак кына ычкындырмый калды ул. — Урыпҗыю бүгенге генераль бурыч булып кала. Аңладыгызмы? Кайтырга мөмкин!

Әхнәф белән Сәлахов бюро члennарының чыгып киткәнен дә, залның бушап беткәнен дә урыннарыннан кузгалмыйча көтеп утырдылар. Менә утырышлар залы тып-тын булып калды.

— Ишекне яп әле, — диде Әхнәф.

Сәлахов президиум өстәле турындагы ишекне ябып килде. Әхнәф телеграмманы, язулы ягы белән өскә әйләндереп, тагын бер мәртәбә укыды, кулы белән сыпырып куйды һәм, аңардан күзен алмыйча:

— Йә, нишлибез? — диде.

— Минемчә, буйсынмый чара юк, — диде Сәлахов. — Без барыбыз да китәбез, сез бүлмәгездә каласыз.

— Ә нишләп мин калам?

— Сез бит район Советы председателе. Безнең баш очында Татарстан флагы җилферди.

Оештыру бүлеге мөдире урыныннан торып чыгарга әзерләнде.

— Туктале, Сәлахов, — диде Әхнәф. — Чыкмый тор әле анда.

Ул һәр киңәшмәдән соң кабул итү бүлмәсенә халык җыелганын белә, һәммәсе дә бер җитешеп килгәч, аның янына кереп, ни дә булса хәл итәргә тырыша. Ә бүген алар менә хәзер шушы минуттан беренче секретарьның юк икәнлеген белмиләр.

— Алдан һичнәрсә сизелмәде, — диде Әхнәф. — Берәр авантюрага охшаш аңлашылмаучылык кына түгел микән бу? Партияне юк итү өчен төрле омтылышлар булганын мин сизә идем инде. Тик бу дәрәҗәдә кинәт...

— Минемчә, Әхнәф Хәсәнович, дискуссия оештырып тора алмыйбыз. Безнең буйсынмый хакыбыз юк.

— Мин дә шулай уйлыйм. Алайса, болай итәбез. — Әхнәф сәгатенә карап алды. — Унбиш минуттан барлык райком работникларын минем бүлмәгә алып керегез.

Алар чыкканда, коридор тулы халык шау-гөр килеп тора иде. Кабул итү бүлмәсендә дә йөрмәле түгел.

Әхнәф халыкны ерып керде дә ике кулын өскә күтәрде:

— Иптәшләр, гафу итегез, беркемне дә кабул итә алмыйм.

— Әхнәф Хәсәнович, бер генә минут!

— Минем бер генә нәрсә сорыйсым бар...

— Мин үзегез кушкан документларны алып килгән идем, кул гына куегыз.

— Юк, юк, юк! — диде Әхнәф, бүлмәсенең ишеген ачып. — Ярты минут та вакытым юк!

Кемнәрдер көтеп торачакларын әйттеләр.

— Аңлыйсызмы, бүген беркемне дә кабул итмәячәкмен. Барыгыз, кайтыгыз, эш оештырыгыз!

Ул бүлмәсенә керде дә секретарь кызга шылтыратты:

— Барысын да чыгарып җибәрегез. Бүген дә, иртәгә дә беркем дә кабул ителмәячәк.

Әхнәф өлкә комитетының берничә телефонына шылтыратып караса да, җавап бирүче булмады. Ул арада ике секретаре, бүлек мөдирләре, инструкторлар, кыскасы, райком аппаратының барлык кешеләре, аның бүлмәсенә кереп утырдылар. Һәрберсенең йөзендә аптыраш билгеләре иде. Әхнәфкә алар нишләптер якын кешеләрен теге дөньяга озатырга җыелган халыкны хәтерләттеләр. Ул акрын гына басты да кычкырып теге телеграмманы укып чыкты һәм:

— Моның нәрсә икәнлеген барыгыз да аңлыйсыздыр? — дип өстәде.

Ул сүзен әйтеп бетерер-бетермәстән, машинистка Бәдрия Минһаҗева аның каршына йөгереп килде, куркыныч булып тартышкан чыраен әле аңа, әле җыелган кешеләргә борып, нидер әйтергә маташты:

— Иптәш Шәрифуллин... Иптәш Шәрифуллин!..

Гомере буе райком инструкторы сыйфатында районнан районга күчеп йөргән, ял көнен дә, көнне-төнне дә белмәгән, гаилә төземәгән, ябык гәүдәле бу хатын пенсиягә чыккан көненнән машинистка булып эшләүче хыялый бер зат иде. Бәдрия Минһаҗеваның бөтен тормышы партия эшеннән генә торды. Аның эчке халәтен, ник өзгәләнүен бүлмәдәгеләр яхшы аңладылар. Ахырда ул аһырып ике сүз әйтә алды:

— Партияне бетергәннәр!!!

Моны ул шундый ачыну белән, үтә дә куркыныч итеп әйтте ки, барысының да тетрәнүдән тәннәре чемердәп куйды. Авызын ачкан килеш өзек-өзек сулыш алган Бәдрия Минһаҗева, чигенеп, артындагы урындыкка ауды. Кемдер аңа су бирде, дару эчерделәр, шуннан соң култыклап бүлмәдән алып чыгып киттеләр.

Әхнәф сүзен дәвам итте:

— Ярты сәгать эчендә һәрберегез шәхси әйберләрегезне җыештырып бетерегез, сейфлары булган иптәшләр бикләп, ачкычны үзегез белән аласыз. Шоферлар, машиналарын куеп, гаражны бикләрләр һәм ачкычларын миңа тапшыралар. Соңыннан сүзе булмасын өчен, бүлмәләрегезне үзегез карап торып сургучлатыгыз. Шушыннан ары мин бер сүз дә әйтә алмыйм. Чөнки үзем дә берни белмим. Һәрхәлдә, паникага бирелергә кирәкми. Беркем дә эшсез калмас. Кемнәрнедер хөкем итәргә дә җыенмыйлардыр дип уйлыйм. Сораулар бармы?

Беркем дә бер сүз дә дәшмәде. Барысы да, башларын игән хәлдә, акрын гына чыгып киттеләр. Кырык минут үтүгә, барлык бүлмәләрнең сургучлап печать басылуы, ишек төбенә бер милиционер куелуы турында Фәнис Сәлахов килеп хәбәр итте.

— Ярый, кайтыгыз, — диде Әхнәф аңа.

Райком бинасы тып-тын калды. Казаннан бер генә шылтыратучы да юк иде. Әхнәф түзә алмыйча өлкә комитетының оештыру бүлегенә шылтыратты. Әмма җавап бирүче булмады. Башка бүлекләр белән дә шул ук хәл кабатланды. Ул инде, батып баручы корабның капитаны кебек, ишеген ачык калдырып, коридорга чыкты. Биредәге тынлыкка исең-акылың китмәле иде. Ул беренче катка төшеп китте. Ишек янындагы дежур торучылар утыра торган өстәл янындагы милиционерга күз ташлады. Ул моннан күп еллар элек Казанда Әхнәф алдап качкан Иван Урусов иде. Беренче секретарьны күргәч, ул урындыгыннан кузгалып, шартлап торып басты. Аңа якын килгәч, Әхнәф инде хәзер капитан дәрәҗәсен йөртүче Урусовның үзенә кызганып каравын сиз-

де. Аның һич тә кызганыч хәлгә каласы килми иде. Шуңа күрә көчәнеп кенә елмайды да:

— Менә бит тормыш дигәнең ничек, иптәш капитан, — диде. — Казанда мин синнән бик ансат котылган идем, ничә ел куа торгач, тәки китереп каптырдың бит.

Урусов саран гына елмайды да:

— Яңадан куышырга язмасын иде инде, Әхнәф Хәсәнович, — дип куйды.

— Менә анысын кистереп әйтәм инде мин сиңа: кабат минем белән куышу булмаячак. — Шулай диде дә Әхнәф тагын бүлмәсенә күтәрелде.

Коридор буенча барганда, бүлмәләрдә туктаусыз телефон шылтыравы ишетелде. Димәк, әле халык нәрсә булганлыгын белеп бетерми. Бүлмәсенә кергәндә, аның телефоны да бик каты шылтырый иде. Трубканы алуга, Наратбаштан Нуриевның калтыранган тавышы ишетелде:

— Әхнәф Хәсәнович, без ишеткән хәбәр дөресмени?

— Әйе, дөрес, — диде Әхнәф, мөмкин кадәр ышанычлы тавыш белән җавап бирергә тырышып.

— Ни була соң инде бу? Безнең эш урыны да беттемени?

Болай да шартларга торган күңелен басар өчен Әхнәф, ачу белән:

— Синең эш урының сакланыр инде, Нуриев агай. Тик райком гына булмаячак, — диде дә трубканы куйды.

Шуның ише мәгънәсез шылтыратулардан тыш Казан тарафыннан бернинди хәбәр дә, күрсәтмә дә булмады. Әхнәф ни уйларга да белмәде. Гүя аяк астындагы җир убылып төште. Аяк астында гына түгел, аның гомер буе корган мәһабәт сарае, ул сарай тирәсендәге чәчәкләр белән бизәлгән бакчасы — бөтенесе юкка чыкты. Тормышны яңадан башларга туры киләчәк иде. Ә инде башлау өчен хәзер соң, хәзер башлау түгел, аны яхшы итеп төгәлләү турында уйларга вакыт җиткән иде. Ул хакта Әхнәфнең инде күңелендә эшләнгән ачык планы да бар иде. Бу план тормышка ашса, аның үзен дә, гаиләсен дә искиткеч якты көннәр көтә иде. Хәзер инде ул планнар турында беркемгә дә авыз ачып әйтмәгән өчен куанырга гына кала. Әгәр әйткән булса, кайсылары бармак төртә-төртә көләрләр, мыскыл итәрләр иде. Ә болай Әхнәф инде аны үз күңелендә яшерен генә учак ягып, шунда дөрләтеп яндырыр да көлен һавага очырыр. Аның нинди гөнаһлары өчен килеп чыкты икән бу бәла? Ә бәла ялгыз йөрми, аның артыннан шәүлә булып икенчесе килергә тиеш. Анысы хакында уйласаң, күз алды бөтенләй караңгыланып китә. Ул бөтен ачуын, рәнҗешен басар өчен әллә рәхәтләнеп бер эчим микән дип уйлады. Тик бу уеннан кире кайтты. Кайгыдан эчсәң дә, бер иптәш кирәк иде. Ишек

төбендә сакта утырган милиционер янына ярты күтәреп төшә алмый бит инде ул. Тораташ булып, башыннан мең төрле уй үткәреп, кичке алтыга кадәр урыныннан кузгалмыйча утырды ул. Аннары акрын гына киенә башлады. Шулчак телефон шылтырады. Шылтыратучы Рашат иде.

— Добрый вечер, Әхнәф Хәсәнович! — диде ул, бераз гына исерегрәк тавыш белән. — Как дела?

— Әйбәт кенә әле, — диде Әхнәф.

— Әхнәф Хәсәнович, мин сезнең исәнлекне белешергә дип шылтыратмыйм, Чаллы мәсьәләсе ничегрәк? Миңа крыша мәсьәләсе?

— Хәзергә берни дә әйтеп булмый, Рашат.

— Минем ничә мәртәбә шылтыратканны беләсеңме син, Шәрифуллин? Шушы моментта мин Ленин мавзолее каршындагы бер йорттан шылтыратам. Переговор өчен түләгән акчаларны сездән даулаячакмын бит мин.

— Аңла, квартира мәсьәләсе бик нык катлауланды.

— Ә нигә алдадың мине, Шәрифуллин?!

— Алдамадым. Алай җиңел генә хәл ителми ул.

— Ярар, мин кайтып килермен әле.

Рашат трубкасын куйды. Әхнәф йодрыгы белән өстәлгә шартлатып сукты. «Бик кирәк иде синең кайтуың» диде ул эченнән ярсып.

Фәһимә аны югарыга ыргытып төшергән туп ничек сикергәләсә, шулай сикергәләп каршылады.

— Менә булдырдың! — дип ташланды ул аңа, бусаганы атлап керү белән. — Арсланов йортына күчеп калган булсак, ак сакаллы карт була идек!

— Ә анда күчәргә теләмәүче син түгелме соң? — диде Әхнәф.

Фәһимә аңа очып кына кунды:

— Мин түгел, син! Менә хәзер шымытыр башы тотып калдык инде!

— Кит каршымнан, ахмак! — диде Әхнәф, бөтен ачуын аңа чыгарып. — Башны кискәндә, чәч кайгысымы монда?!

Фәһимәнең тавышы ысылдап чыкты:

— Кабатла әле, нәрсә дидең син?

Әхнәфнең инде күптән аңа алай тупас бәрелгәне юк иде.

— Минем хәлемә керер чакта, эт сыман миң ташланасың. Ахмак булып тугансың, ахмак булып үләрсең.

Әхнәф җилләнеп залга керде дә, партия мәсьәләсендә яңа хәбәр тапшырмаслар микән дип, телевизорны кабызды. Күңелгә ятышлырак берәр хәбәр көтеп, баскан килеш зал уртасында торды. Шул вакыт артында Фәһимәнең нидер кычкырганы ишетелде. Ул борылып карарга өлгерә алмады,

баш түбәсенә шартлап уклау килеп төште. Бу хәл күз ачып йомган арада булды. Әхнәф авыртудан кычкырып җибәрде, баш түбәсеннән стенага кан сиптерде. Үзенең нишләгәнен аңлап алган Фәһимә кычкырып еларга тотынды һәм «ашыгыч ярдәм» чакырырга телефонга ташланды. Әхнәф бер кулы белән башын тотып, икенчесе белән телефон трубкасын аның кулыннан тартып алды.

— Нишлисең?!

— «Ашыгыч ярдәм» чакырам.

— Ахмак кына түгел, дурак син! Бәйлә тизрәк! Алып чык берәр нәрсә!

Фәһимә каушавыннан, шифоньердан юрган сырырга дип алып төрелгән ике килограмм мамыкны эләктереп, Әхнәфнең каршына килде. Мамыкны куйды да кухня ягыннан ялтыравыклы чәй кәгазе, бер кәшемир яулык тотып йөгереп килде. Әхнәф бер кулы белән мамык умырып алды да калганын телевизорга таба тибеп очырды. Фәһимә мамык өстеннән кәшемир яулыкны калтырана-калтырана, елый-елый бәйләп куйды. Шулай итеп, партия беткән көн Әхнәфнең тормышыннан кан белән китте...

## 15

Партиянең бетерелүен, СССРның таркалуын ишеткәч, Хәйри коелды да төште. Җанындагы җегәре кинәт юкка чыкты, тәнендәге каны суынгандай булды. Ул сәгатьләр буе уйланып ята башлады, туктаусыз авыр сулап уфылдады, йөрәк дарулары эчте. Вакыт-вакыт, хәлсез аякларын сөйрәп, басулардан, болыннардан урап кайтты, колхоз идарәсенә сугылды, кешеләр белән сөйләште, әмма үзенә урын таба алмады. Нидер эзләгәндәй күпме генә йөрсә дә, бушлык томанына барып керде. Халыкны яктырак тормышка чыгарыйк дип көне-төне түккән маңгай тирләре, күкрәк көчләре, сугыш михнәтләре, аннан соңгы дәверләрдәге ашкынутталпынулар — бөтенесе дә элекке мәгънәләрен җуйдылар, әһәмиятсез, төссез чәбәләнүгә әйләнеп калдылар. Аның мәгънәле тормышы сызып атылган иде.

Беркөнне кичкырын Хәйри идарә тирәсеннән урап кайтырга, кешеләр белән сөйләшеп, җанының сызлауларын аз булса да басарга дип урамга чыкты. Үзләренең турыннан үтәргә дә өлгермәде — күкрәген яндырып нидер кысып алды, күз алдында кара нокталар биешергә тотынды һәм ул кесәсендәге нитроглицеринын авызына кабарга да өлгерә алмыйча җиргә ауды. «Ашыгыч ярдәм» машинасының килүен, больницага илтеп салуларын, Ирек белән Зәнфирәнең үзе янында бөтерелүләрен ул төштәге кебек кенә хәтерләде...

Әтиләренең авыруы барысын да хафага төшерде. Интенсив терапия нәтиҗәсендә аның хәле күзгә күренеп әйбәтләнде. Бер ай дигәндә Хәйрине больницадан чыгардылар. Әмма врачлар Мэлс белән Ирекка куандырырлык сүз әйтмәделәр. Сездән яшереп торуның файдасы юк, әтиегезнең йөрәге соңгы чигендә эшли, бүген-иртәгә ни буласын әйтүе кыен, диделәр.

Беркөн төштән соң Хәлимә музейга шылтыратты. Аның тавышын ишетү белән, Ирекнең эче жу итеп китте.

— Әтинең хәле ничек? — диде ул, кабаланып.

Хәлимә көттереп кенә җавап бирде:

— Сезне чакыра ул. Кайтып килсәгез әйбәт булыр иде...

— Хәле начарланмагандыр бит?

— Алай ук дия алмыйм, үзегез белгәнчә инде. Айгөлне дә алып кайтыгыз, — диде.

Ирек шундук шылтыратып абыйсына хәбәр итте. Аннары ул Сөембикә белән элемтәгә керде, хәлне аңлатып бирде.

— Мин Айгөлне үзем генә алып кайтырмын, — диде Сөембикә, Мэлсларның ничәдә кайтачагын ишеткәч. Аннары сүзләренә басым ясый-ясый өстәп куйды:— Минем кайтуга син каршы килмәссең бит?

— Үзеңә кара, — дип куйды Ирек.

Кич Мэлс белән Нәфисә кайтып төште. Алар күтәртеп түбәсе ябылып куелган яңа өйне эченнән дә, тышыннан да карап йөрделәр, бик шәп була, дип мактадылар, исән-имин бетереп керергә язсын, диделәр. Капкалап алганнан соң, дүртәүләп авылга юл тоттылар.

— Мин бит теге Чаллы күрәзәчесенә барып кайттым, — диде Нәфисә, Болынкырны чыккач.

Мэлс янәшәсендә утыручы хатынына ялт итеп ачулы караш ташлады. Аның бу карашына Нәфисә, рәнҗүле тавыш белән:

— Нигә инде син берни юкка шулай итеп карыйсың? — дип үпкәләвен белдерде.

— Син бит сихерчеләр белән аралашып яшәргә тиеш түгел, андый нәрсәләргә чик куярга тиеш.

— Сихерче түгел ул, чын күрәзәче. Әтинең фоторәсемен алып бардым. Хәле бик авыр, диде, һичшиксез җиңәчәк, диде. Әле кимендә ун ел гомере бар, диде.

— Авызыңа бал да май. — Мэлс машинаның тизлеген арттырды да Нәфисәгә таба башын иде. — Мине нәрсә диде соң?

— Ничек сине? — Нәфисәнең гаҗәпләнүдән авызы ачылды.

— Минем дә фотоны алып баргансыңдыр бит? Тагын ничә ел яши диде?

— Нервыма тимә, зинһар!

— Кем кемнекенә тиядер бит. Укытучы кешенең шундый алдауларга ышанып йөрүе мәзәк инде ул...

Ирек белән Зәнфирә аларның әрепләшүен ярым елмаеп, сүзсез генә тыңлап бардылар.

Алар кайтып кергәндә, әтиләре ястыкка аркасы белән сөялеп утыра иде. Күрешеп хәл-әхвәл белешкән арада Айгөл белән Сөембикә дә кайтып җитте. Айгөл керү белән бабасына барып сарылды. Бабасы аның чәчләрен сыпырды, иңнәреннән сөйде, бик озаклап карап торгач:

— И кызым, син дә үсеп җиттең бит, — диде.

Күзеннән бер тамчы яшь чыкты, аны Гөлҗамал җәһәт кенә алъяпкыч итәге белән сөртеп алды.

— Безнең Алмаз белән Гөлназ икесе дә囲 эштә бит әле, әти, Казан артында ук, — диде Нәфисә.

— Беләм, кызым. Кайту белән алып килерсез. Сагындым...

Гөлҗамал аларны кече якка әйдәде:

— Капкалап алыйк, балалар. Син утырасыңмы, әтисе?

— Әлегә берни дә кабасым килми. Барыгыз, ашагыз. Без монда малайлар белән сөйләшә торыйк әле.

Хәйри иңбашын селкетеп ястыгын күчерергә азапландымы, Мэлс белән Ирек аның гәүдәсен турайттылар да ястыкны кабартып салдылар. Әтиләре рәхмәт әйткәч, аларның икесенә дә бик җитди итеп озаклап карап торды. Шуннан соң әллә нинди йөрәк өзгеч тавыш белән пышылдады:

— Әйтегез миңа, партиягә ни булды?

— Таралган иде бит инде ул, әти, — дип куйды Мэлс.

Аның сүзләре белән килешмичә, Хәйри баш чайкады:

— Без төзегәнне сез харап иттегез... — Әтисенең сулышы кысылды, күзләре йомылдылар, гүя ул тавышсыз гына елый иде. — Ил юкка чыкты. Без шул ил дип яшәдек...

Әтисе сүзеннән туктады, аның маңгаена, битләренә тир бәреп чыкккан иде. Ирек кулъяулыгы белән аның тирен сөртеп алды.

— Бакчаны чүп-чарлардан чистарту кирәк бит инде, әти, — диде Мэлс. — Ул яшәреп, үсеп китәчәк.

— Чистартуны күргән бар, — дип сузды әтиләре. — Ата абруе бетсә, гаилә таркала. Партия миңа атам кебек иде. Ә менә ата-баба үстергән бакчаны балалары кисеп ташласа, бу инде хәтәр нәрсә. Иң олы афәт шунда. — Әтиләре тынып, тагын бераз хәл җыеп торды. — Мин үзем сездән канәгать, балакайларым. Төчеләнә алмадым. Анысы өчен кичерерсез инде. Шулай да... мәхшәр килә. Бөтенесен сатачаклар, моның азагы хәтәр булачак. Менә әти әйткән иде диярсез.

Хәйри күзләрен йомып, башын бераз кыегайтып ястыкка терәлде. Мэлс белән Ирек сүзсез генә бер-берсенә карашып куйдылар.

— Арыттык бугай, теге якка чыгыйк, — диде абыйсы, пышылдап.

Ләкин әтиләре аларның сүзен ишетеп яткан булып чыкты. Күзләрен ачты да:

— Туктагыз, — диде. — Сезгә васыятем бар. Үлгәч, партбилетымны күкрәгемә куярсыз. — Ул аңладыгызмы дигән мәгънәдә һәр икесенә озаклап карап торды. — Мин инде үзгәрә алмыйм. Уйланмадым түгел, күп уйладым. Әнә күрше Гариф абыегыз мәчеткә йөри, аның гомер буе коммунист икәнен беләсез. Мин алай булдыра алмыйм. Андый кешеләрне аңлый да алмыйм. Ялгышамдыр, бәлки... Миңа шул заман кешесе булып китәргә рөхсәт итәрсез бит?

Ирек, кабаланып:

— Син бүгенге заман кешесе, әти! — диде ул, аны тынычландырырга теләп. — Барлык коммунистлар да синең кебек булсыннар иде әле.

— Үтәрсезме минем әйткәнне?

— Үтәрбез, — диде Ирек.

— Рәхмәт, балалар, — диде әтиләре, әллә нинди җылы, ягымлы тавыш белән. — Чакыруым шуның өчен иде. Зинһар, авырыксынмагыз. Мөмкинлек барында әйтеп калыйм дидем. Ә хәзер барыгыз, әниегез янына чыгыгыз. Мин бераз ял итәм...

Әтиләре шулай диде дә күзләрен йомды. Аның утырып торуына, сөйләшүенә, зиһененең сафлыгына сокланып кайтып киттеләр алар.

Дүрт көннән Хәлимә кабат Ireккә шылтыратты.

— Хәйри абыйның хәле әйбәт түгел, — диде.

Сәгать ярымнан Мэлс белән Ирек авылга кайтып җитте. Дүрт көн эчендә әтиләренең кыяфәте үзгәрүенә ышанырлык түгел иде. Ул суырылып, саргаеп, кечерәеп калган. Хәтта үзе яткан караватта гәүдәсенең калкып торуы да сизелми кебек. Сүзләрен дә бик авырлык белән, туктап-туктап кына сөйләде.

— Кичә кич әнә шул аралыкка әниең белән тышка чыгарга көчкә бардым. Бүген инде кузгалырлык рәтем юк...

Ирек аның яныннан китмәскә булды. Икенче көнне кич Хәйри телдән калды. Әтисенең сәгатьләп түгел, минутлап сула баруын күрү Ирекнең үзәген өзде. Аның күңелендә әтисе әле һаман бернидән курыкмаучы, тормышны аяусыз ерып баручы илаһи зат буларак яши иде. Әтисенең хәле авыраюы яшен тизлеге белән бөтен авылга таралды. Өч көн буе иртәдән кичкә кадәр өйдән кеше өзелмәде. Сөйләшә

алмаса да, ул аңында иде. Хәлен белергә килүчеләрнең: «Мине таныйсыңмы?» — дигән сүзләренә керфек кагып җавап бирде. Өченче көнне төштән соң ул күкрәге белән сулыш ала башлады. Зәнфирәне алып, Мэлс белән Нәфисә дә кайтып җиттеләр.

Әнисе Ирекка:

— Кулыннан тот, улым, юкса аңа бик кыен булачак, — диде.

Ирек әтисенең кулыннан тотты. Ул инде нык суынган, җан билгеләре сизелми иде. Алдагы көнне үк каралган аяклары һаман төсен үзгәртә бардылар. Сәгать дүртләрдә, икенде вакытларында, әтисенең сулышы өзелде...

Хатын-кызлар елашырга керештеләр. Җанын кая куярга белмичә, Ирек тә әле ишегалдына чыкты, әле өйгә керде. Абыйсы гына салкын канлылык саклый алды. Җирләү мәшәкатьләрен хәл итү өчен ул машинасы белән авыл Советы председателен, колхоз җитәкчеләрен күрергә китте. Әтисенең өстенә ак простыня ябылган, күкрәк турына аркылыга пычак куелган, тирә-юненә карт-коры, үзенең замандашлары җыелып утырган иде. Ирекнең ике чигәсе сулык-сулык килеп сызлый башлады. Ул өйдән чыгып китте, йөгереп диярлек бәрәңге бакчасы аша үтеп, ындыр коймасы буена барып утырды. Биредә талгын гына җил исә, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, чикерткәләр чырлый, берни булмагандай, кояш бүген батып, иртәгә чыгу өчен офыкка якынлаша иде. Әтисе юк! Мәңге булмаячак. Ул бу вакытта җирдә дә, һавада да түгел, ниндидер хыялый дөньяда йөзде, кешенең тууыннан юкка чыгуына кадәрге юлын барлады.

...Кеше ана карынында ярала, шунда үсә, соңга таба хәтта тышкы дөньядагы тавышларны да ишетә, диләр. Бервакыт аңа нидер төртә, кыса, бөтен җирен авырттыра башлый. Ул ахырда каядыр шууын сизә. Ниндидер каты, рәхимсез нәрсәләр аны капшый, тарта, ул гәүдәсенең таш булыпката баруын тоя һәм аны коточкыч курку били. Бу курку — бөтен галәмгә җитәрлек кара курку. Әгәр кеше туып яши алса, мондый куркуны тагын бер мәртәбә соңгы сулышын алганда тоячак. Кеше үз дөньясыннан ниндидер коточкыч тирәлеккә күчүен сизә, әмма берни дә аңламый. Тәүге сулыш белән эченә ниндидер ят, салкын нәрсә керүен тоя, тончыга-тончыга үкереп елый. Кеше сукыр, саңгырау, акылсыз булып туа, яши-яши ишетә, күрә, фәһемли башлый. Аңа бөтен тереклектән өстен итеп акыл бирелә. Кеше дөньяны күрә башлый, берни дә аңламый, әнисенең сөтен имә дә йоклый. Тора-бара әнисен таный, көлә, ләкин әле берни дә аңламый. Аңларга тырыша, гомере буе аңлап бетерә алмый. Шатлыклар, газап-

лар кичерә. Газаплары шатлыклардан күбрәк була, әмма барыбер җирдә тормышны аңлый алмый. Күпләр, дөнья малына, ләззәтләренә алданып, кабат сукырая, чукраклана, аңын югалта... Гомер азагы җитә. Иң бәхетле кешеләр — кинәт үлеп китүчеләр. Газапланып үлүчеләр бала булып туган чактагы барлык халәтне дә кичерәләр: авырту, дөнья дигән карыннан җиргә күчкәндәге коточкыч тартышу! Әгәр озак ятса, кеше көннәрен, сәгатьләрен саный, үзе белән хушлашырга килүчеләрне күрә, сөйләшкән тавышларны ишетә. Соңгы сулыш, соңгы авырту, җанның бүтән дөньяга талпынуы һәм инде хәлсезләнгән тәннең аны тота алмыйча ычкындыру дәһшәте... Бөтенесе бергә бутала... Җан адәм баласына карында иңә, җанның яшәгәндә үк авызга килгән чаклары була, җан белән тән гомер буе тартышалар, шул ук вакытта берсе икенчесеннән башка яши алмый. Никадәр гаделсезлек! Ике дошманны бер тәнгә бикләү нигә кирәк булган? Бу гомер буе тартышуның азагы барыбер җанның тәнне ташлап китүе, кешедән котылуы белән тәмамлана...

Ирек уйларына батып бик озак утырды. Инде кызарырга өлгергән кояшка күз кабагын күтәрмичә, керфекләре арасыннан нишләптер рәнҗеп, үпкәләп карады...

* * *

Хәйрине җирләргә авыл халкы гына түгел, районның барлык җитәкчеләре җыелды. Килгән җиңел машиналар Болынкырның ярты юлыннан башлап Баллы Төбәккә кадәр сузылганнар иде. Әтиләрен юып кәфенләгәч, Ирек белән Мэлс картлар янына керделәр.

Ирек, әтисенең партбилетын кесәсеннән чыгарып:

— Әтинең әйткән васыяте бар иде бит, агайлар, — диде.

Мулла вазифаларын башкаручы Миңлегәрәй:

— Әйдә әйт, улым, нинди васыяте бар иде? — дип сорады.

— Җирләгән чакта партия билетын күкрәгенә куярга кушкан иде.

Бу сүзгә картлар дәррәү ризасызлык белдерделәр. Арада аның васыятенә каршы килмәскә кирәк диючеләр дә табылды.

Миңлегәрәй, бөтен кешене тынычландырып, үз сүзен әйтте:

— Шәригать кануннары буенча бу һич тә ярый торган эш түгел. Мин үзем моңа каршы.

— Без бит аңа сүз бирдек! — диде Ирек, дулкынланып. — Әтине ышандыргач, әгәр васыятен үтәмәсәк, бу бит безне гомер буе борчый торган бер яра булачак. Шулай бит, абый?

Мәлс бер сүз дә әйтмәде. Картлар тагын шаулаша башладылар. Кемнәрдер, монда баш бетәрлек нәрсә юк, дип, Ирек ягыннан сөйләделәр, икенчеләре каршы төште.

Ахырда Миңлегәрәй, нидер уйлап:

— Барыгыз әле, Гөлҗамалны алып керегез, — диде.

Кече өйгә чыкканда, Ирек абыйсына:

— Ник бер сүз дә дәшмисең? — диде үпкәсен белдереп.

— Ничек дәшим белмәгәч? Йола зурракмы әллә кешеме?

— Син бит әтигә, куярбыз, дидең.

— Каршы әйтергә идемени?

Әниләре авызын яулык очы белән каплап керде дә, түргә узмастан, ишек яңагына сөялде. Аның йөзе кәфендәй агарган, күз карашы битараф, күңелендә дөнья кайгысы калмаган иде. Картлар хәлне аңлаткач, барысы да Гөлҗамалга төбәлделәр.

— Мин ни әйтим соң инде? — диде ул, авыр сулап. Аннары Хәйри янына ук килде дә ничектер кинәт кенә башын күтәрде, күзләренә нур инде. — Барыгызга да мәгълүм, бу фани дөньяда ул баш иярга яратмады, үз кануннары белән яшәде. Әгәр аның васыятен үтәмәсәм, теге дөньяга баргач, мин аңа ни дип җавап бирермен? Безнең хөкем ярамас монда, хөрмәтле картлар, Ходайның үз хөкеменә тапшырыйк...

Әниләренең шул сүзе мәсьәләне хәл итте дә куйды: кәфеннең бер урынын ачып, партия билетын нәкъ йөрәге турына куйдылар. Хәйринең гәүдәсен ишегалдына чыгаргач, урам яклап капка төбендә зур митинг булды. Аны Гаскәров алып барды. Беренче булып Әхнәф чыгыш ясады, эштә дә, шәхси тормышында да халыкка үрнәк булуын, шундый күркәм шәхесне югалтуның авырлыгын әйтте. Аннары районның башка җитәкчеләре, авыл кешеләре чыгыш ясадылар. Соңыннан Мәлс та сөйләде, әтисен соңгы юлга озатырга килүчеләргә рәхмәт әйтте. Алар арасында Батталов кебек колхоз-совхоз җитәкчеләренең булуы, аларның һәркайсының килеп кайгы уртаклашуы Иректе чиксез дулкынландырды. Кызы Айгөл әбисе яныннан китмәде. Бабалары исән чакта ук кайтып җиткән Алмаз белән Гөлназ да күбрәк әбиләре янында булдылар.

Менә Хәйринең мәетен күтәреп ишегалдыннан алып чыктылар. Кайгы ташкыны, тавышсыз гына чайкалып, капка төбеннән кузгалды. Шушы урам чирәмнәрендә тәгәрәп үскән, нәни аяклары белән шушы урамның кайнар тузаннарын таптап йөгергән, дөнья кубарып кычкыра-кычкыра гөрләвек суларын ерган малай шушы урамга бүтән беркайчан да кайтмаска тып-тын гына китеп барды...

# Икенче кисәк

## 1

Иске кызыл «Жигули» карлы юлдан Болынкырга таба элдерә. Юньләп чистартылмаган юлда машина туктаусыз салулый, аның рулен Фәрит Хәбиров кабалана-кабалана әле уңга, әле сулга боргалый, уртага чыгара. Юлга аркылы йөгерүче җәяүле буран, читтәге кар өемнәренә ышыкланып, туктаусыз кар сала, машина эзе күмелә бара. Нәфисә уң якта аларны озатып баручы, саргылт нурын сүрән генә койган кояшка карап ала һәм тагын күңелен билгесезлек телгәли башлый. Районга ник чакырганнарын ул, әлбәттә, белә, инде ничә көннәр буе карышып та карады. Бүген тагын шылтыраткач, математика укытучысы Фәрит Хәбировны алып чыгып китүдән башка чара калмады. Сәгать унда шылтыратсалар да, дәресләр бетмичә кузгалмады. Менә хәзер аның башында, җәяүле буран себергәндәй, буталчык уйлар каядыр туктаусыз агылалар. Ник кирәк булды аңа директор булу? Шушы сорауны үз алдына куя да Нәфисә «кирәк иде» дигән җавапны бирә. Ничә еллар буе аны шул эшкә кыстадылар, гел баш тарта килде. Әмма тора-бара уйлары акрынлап үзгәрде, чөнки мәктәптәге барлык оештыру, укыту-тәрбия эшен төпкә җигелеп ул сөйрәде. Асылда директор Зөһрә Вәлиевна Закирова булса да, барлык эш Нәфисә җилкәсенә төште. Дөрес, Зөһрә Вәлиевна искиткеч йомшак күңелле, кешелекле кеше иде. Нәфисә институт тәмамлап, курка-курка гына Наратбаш мәктәбенә килеп төшкәч, ул аның өчен әнисе кебек булды. Беренче көнне үк Нәфисәне үз өенә алып кайтты, һәм ул анда елдан артык бушлай яшәде. Зөһрә Вәлиевнаны йомшаклыгы, һәркемне гафу итүе өчен мәктәптә бик яраталар, тагын йөз ел эшләсә дә, барысы да аңа риза, рәхмәт укыячак иде. Нәфисә, тора-бара бөтен эшнең авырлыгын гомере буе шулай күтәреп барып, мәктәп ирешкәннәрдә үзенең өлеше булмавын, төгәлрәк итеп әйткәндә, аны Зөһрә Вәлиевна хезмәте дип бәяләүләрен бик авыр кичерде. Тагын шунысы да бар: директорның йомшаклыгы, һәрнәрсәне гафу итүе укыту-тәрбия эшен оештыруда уңайсыз киртә булып торды. Аңардан узып та булмый, аныңча эшләп тә булмый. Коллективта күпчелек директор яклы, уку-укыту бүлеге мөдире буларак, бүгенге педагогик таләпләр белән эш оештыручы Нәфисәне хуплап бетермиләр. Барысын да үлчи торгач, ул инде директорлыкны үзенә алырга дигән нәтиҗәгә килгән иде. Гөнаһ шомлыгына каршы, аның ниятен белгән төсле, кабат директор эшенә өндәүче дә булмады.

Нәфисә бер ел көтте, ике ел көтте, ахырда түзмичә турыдан-туры әйтмәсә дә, мәктәптәге хәлне методик кабинет мөдиренә сөйләп бирде. Нәфисәнең инде күп еллардан бирле формаль булмаган директор икәнлеген район мәгариф бүлегендә яхшы беләләр иде. Бу сөйләшүдә ул болай эшләүдән арыганлыгын, һич югы үзенең җитәкче булырга тиешлеген турыдан-туры әйтмәсә дә, бик нечкә генә итеп сиздереп куйды. Нәтиҗә көттермәде, аңа директор булырга кабат тәкъдим ясадылар, һәм ул берсүзсез ризалашты. Менә ел ярым инде ул шушы камытны кигән хәлдә чабулый. Аның янында, сүнгән йолдыз кебек, инде күптән пенсия яшендә булган Зөһрә Вәлиевна һаман укытып йөри. Нәфисә аның дәресләренә иң югары таләпләрдән чыгып анализ ясады, ялгышларын рәхимсез кисәтте, элекке директорга педсовет утырышларында да шактый гына таяк эләкте. Аның Зөһрә Вәлиевнаны кысуын беркем дә өнәмәде. Җай чыккан саен, моны сиздереп тә куйгаладылар. Нәфисә исә аларга туп-туры: «Хәзер физиканы алай укытмыйлар», — дип җавап бирде. Аның таләпләре заманча югары, принциплары какшамаслык иде. Әлбәттә, Нәфисә үзен-үзе дә гаепләде. Ләкин бит икенче хакыйкать тә бар: бер кешене кызганып, йөзләрчә балаларның язмышы белән уйнарга ярамый. Нәфисәне Зөһрә Вәлиевнаның үпкәләмәве тынычландырды. Ул эштән тавышсыз-тынсыз гына китеп барды. Аның өенә Нәфисәне каралтырга, хурларга килүчеләрне карт укытучы тыңламаган, шулай тиеш, дип кире борып чыгарган. Бу эше өчен аңа Нәфисә чиксез рәхмәтле иде. Аны китәрлек дәрәҗәгә җиткергән чагында кичергән эчке газаплары, үзенә игелек кылган кешегә каты таләпләр куюы аңа коточкыч кыен булды. Өлкән укытучының дәресенә һәр анализ, бәлкем, Нәфисәнең яшисе гомерен кыскарткандыр. Менә хәзер Зөһрә Вәлиевнаның шушыларны аңлавы өчен барып рәхмәт әйтергә, бәлки, гафу үтенергә дә кирәктер. Тик Нәфисә нишләптер бу адымга бара алмады.

Машина хакимият бинасы каршына килеп туктады. Нәфисә, машинадан чыгып, тирән итеп бер сулады да, мәрмәр баскычлардан күтәрелеп, зур пыяла ишекләрне ачты һәм өскә узды. Кызык хәл: партия беткәч, бөтенесе ах-ух килде, дөнья беткәннән ким кыланмады, кемнәрдер кара кайгыга төште, кемнәрдер билгесезлек эчендә бәргәләнде, кемнәрдер астыртын гына сөенде, күптән кирәк иде, дип, читтән күзәтеп тора башлады. Менә бит, ике катлы бина шул урынында, аңа беркетелгән кызыл пыялада гына икенче төрле сүзләр язылган. Эчендә дә шул ук кешеләр диярлек. Элек беренче секретарь булган Әхнәф Шәрифуллин — хакимият башлыгы, идеология секретаре булган Зәйнуллин — социаль мәсьәләләр буенча аның урынбасары, Фәнис Сәлахов — аппарат җитәкчесе.

Кыскасы, партия корабы батты, ә аның экипажы тулысынча сакланды, икенче исемнәр генә алды. Зәйнуллинның кабул итү бүлмәсендә алты-җиде кеше чират көтеп утыра иде.

Нәфисә алар белән баш кагып исәнләште дә, өстен-башын салып, чәчләрен тарады, төзәтенде, аннары, секретарь кызга мөрәҗәгать итеп:

— Мин Наратбаш мәктәбеннән Сабитова булам, бик ашыгыч чакырткан иде, — диде.

Утырырга урын юк иде, Нәфисә коридорга чыгып туктаусыз йөренә башлады. Үткән саен үзе кабул итү бүлмәсенә күз салды, тик анда һаман хәрәкәт сизелмәде. Ярты сәгать эчендә ике кеше кереп чыга алды, ахырда Нәфисә түзмәде, секретарь кызның «ашыкмагыз» диюенә карамастан, өченче кеше артыннан ияреп керде.

— Мине тизрәк җибәрсәгез иде, — диде ул, исәнләшеп тә тормастан.

Зәйнуллин урыныннан сикереп торды, аның күзләрендә зәһәр очкыннар кабынып китте.

— Сезгә симпатия белән караганым өчен генә чиратсыз кертә алмыйм ич инде мин, — диде ул, кызарып.

— Мин дә сезне яратканнан килмәдем, чакырганга гына.

— Между прочим, сез кичә үк килергә тиеш идегез. Көтегез.

Нәфисә хурланып чыгып китте, тагын коридорда йөрергә керešте. Аның күзләренә яшь тулды. Әллә кайтып китәргә микән дип тә уйлап куйды. Ләкин бу адымны ясарга ярамый иде. Ул шушы директор вазифасын алып барган ел ярым эчендә бер бик ләззәтле дөньяга кергән иде. Ул дөнья күпмедер дәрәҗәдә аңа ирек дигән нәрсәнең тәмен татытты. Нәфисә гомер буе канәгатьсезлек кичерде, ниндидер идеал эзләде, таба алмады. Ә менә директор булгач, коллективтагы эшне ул үзе теләгәнчә оештыра башлады, яңа планнар корды һәм аларны тормышка ашырды, кешеләр аңа буйсындылар, кушкан гамәлләрне кылдылар һәм моның азагы әйбәт нәтиҗәләр бирде. Ул ифрат та әсәрләнүчән кеше иде, гомер буе күзеннән яшь кипмәде, шул ук вакытта, әле күзләрендә яшь тамчылары эленеп торганда, ул көлеп тә җибәрә иде. Аны рәнҗетергә ярамый, ә инде тупас кагылу Нәфисә өчен фаҗигагә әверелә, күз яшьләренә китерә. Ул гомер буе нечкә, кешелекле мөнәсәбәтләргә корылган тормыш турында хыялланды. Директор булгач та эшен әнә шундый мөнәсәбәтләргә нигезләнеп алып барырмын дип уйлаган иде. Ләкин үзе дә сизмәстән, каты, кискен, чигенми торган принциплар белән эшли башлады. Үз-үзен: «Бу хәзергә генә шулай, коллективны сындырырга кирәк, билгеле вакыттан соң барысы да йомшак, табигатьтәге кебек камиллек белән барыр», —

дип тынычландырды. Әмма, гранитны кайнатып ширбәт ясап булмаган кебек, безнең тормыш шартларында бу мөмкин нәрсә түгел иде, күрәсең. Ул вакыт-вакыт дилбегәне ычкындырып, принципларыннан чигенеп, йомшап карады. Ләкин чак кына һәлак булмыйча котылып калды. Чөнки әз генә йомшауга, югарыдагылар да, астагылар да өстеңә менәләр, рәхимсез изә башлыйлар иде. Менә шушы нәрсә Нәфисәне үзенең күз яшьләренә рәхимсез катылыкны кушарга мәҗбүр итте.

Секретарь кызның кабул итү бүлмәсеннән чыгып: «Керегез», — дип дәшүе Нәфисәнең уйларын бүлде.

Ул кергәндә, Зәйнуллин галстугын төзәткәләп тора иде. Аклангандай, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Кеше алдында минем дәрәҗәмне төшермәсәгез дә ярар иде, Нәфисә Фәрвәзовна, — дип куйды ул. — Яхшымы-яманмы, мин бит әле хакимият башлыгының урынбасары.

— Керү белән сезгә дә яңакка чапкан кебек итмәскә иде.

— Нишлим соң? Мәктәптә бер хатын-кыз кул астында эшләгәндә өйрәнеп калган идем. — Шулай диде дә Зәйнуллин астан гына карап елмайгандай итте.

Нәфисә дә аңа булдыра алганча елмаеп җавап бирергә тырышты, әмма бер сүз дә дәшмәде.

— Нәфисә Фәрвәзовна, ни өчен чакырганны беләсездер?

Күңеле белән сизенсә дә, Нәфисә юри:

— Мин бит күрәзәче дә, экстрасенс та түгел, — диде.

— Саттаров мәсьәләсендә, мәгариф бүлеге мөдире кушканны үтәмәгәнсез.

— Үтәмәдем, — диде Нәфисә, тавышын күтәреп. — Тора салып кешене эштән куа алмыйм мин.

— Ләкин аның мәктәптә эшләргә хакы юк.

Нәфисә дөртләп кабынды:

— Ничек хакы юк? Нәрсә эшләгән ул Саттаров?! Әллә төрмәдә утырып кайтканмы?

— Эчүчелек белән шөгыльләнгән кешенең балалар алдына чыгып тәрбия бирергә хакы юк. Болынкыр урта мәктәбеннән нәкъ шуның аркасында куылганлыгын сез беләсез бит.

— Тормышта бер очрак берни дә хәл итми. Аннан соң ничә еллар узды. Саттаров кебек укытучыны мин белмим. Аның дәресләре балалар өчен бәйрәм.

— Нәфисә Фәрвәзовна, биредә дискуссия урыны түгел. Монда кушканны гына үтиләр.

— Кара, әйбәт урын икән! — диде Нәфисә, киная белән. — Баш ватасы юк, уйлыйсы юк. Сезнең ник күчкәнегезне аңладым мин.

Зәйнуллин аның бу сүзләреннән кып-кызыл булды. Ул туктаусыз галстугын төзәтте, костюмының сәдәфләрен бер

ычкындырды, бер каптырды, алдындагы кәгазьләрне бер урыннан икенче урынга күчерде.

— Сез миңа турысын әйтегез: Саттаровны эштән алырга приказ язасызмы, юкмы?

— Ә мин аны нинди нигездә языйм? Мәгариф бүлегеннән килеп дәресләрен тикшерделәр, бәйләнер нәрсә тапмадылар. Һәм мине хәзер төп гаепле кеше итеп калдырырга уйлыйсыз.

— Аңлагыз, эчкече яшь буынны тәрбияләүдә эшли алмый. Алар икесе дә тынып калдылар. Нәфисә хакимиятнең ни өчен Саттаровтан курыкканын бик яхшы аңлый иде. Үзенең әтисе кебек үк, ул гомер буе җитәкчеләрнең гаделсез гамәлләрен фаш итте. Шул хакта теләсә нинди җыелышта сөйләде, республика газеталарында язып чыкты. Заманында, аның салган вакытын туры китереп, Болынкыр мәктәбеннән кудылар. Шуннан соң Саттаров шактый еллар төрле районнарда эшләп йөрде, ләкин кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмый дигәндәй, аның вакыт-вакыт салып ала торган гадәте тагын юлына аяк чалды. Күрше районның бер авылында укытып йөргән җирдән Зөһрә Вәлиевнаның эштән китүен ишеткәч, ул Нәфисә каршына килеп тезләнде. Уку елы башланган, инде октябрь азагы иде. Мәктәпне ремонтларга акча бирмичә Нәфисәнең җанына тиделәр. Гомумән, кайсы яклап кына алсаң да, игътибарсызлык сизелеп торды. Әйтерсең лә Наратбаш мәктәбе безнең дәүләткә керми, чит дәүләтнең бүленеп калган территориясе иде. Бәлкем, бу Нәфисәнең Мэлс янына күчеп китүен теләүдән дә булгандыр. Саттаровның килеп тезләнүен Нәфисә шушы хәлне җимерү өчен бик оста файдаланды. Мәгариф бүлеге мөдире әле яшь кеше, Саттаровның кем икәнен белми, Нәфисәнең мактаулары буенча аның приказын куана-куана алып, үзенекен язды. Ә инде бу эш хакимияткә билгеле булгач, барысының да күзләре маңгайларына менде, колакларын торгыздылар, гел читтә калып килгән Наратбаш мәктәбе игътибар үзәгенә әйләнде. Акрын гына Саттаровны эштән алуны да сиздерә башлагач, Әмир Җаббаровичка ул бик сак булырга, эчү дигән әйберне бөтенләй онытырга, дәресләргә һәр көнне идеаль төстә әзерләнергә кушты.

— Сез аңа эчкече мөһере суга алмыйсыз, — дип каршы төште Нәфисә. — Әгәр андый факт булса, мин аны бер сәгать тә мәктәптә тотмаячакмын. Ләкин Саттаров ул чиреннән күптән арынган. Шулай булгач, без аны ни дип куабыз?

— Аңлагыз, бу минем фикер түгел, җитәкчелек фикере. Гомуми таләп! — диде Зәйнуллин, тавышын күтәреп.

— Нинди җитәкчелек? — диде Нәфисә, башын юри аңгырага салып.

— Район җитәкчелеге.

— Җитәкчеме, җитәкчелекме?

— Икесе дә.

— Менә хәзер аңлашылды, — диде Нәфисә һәм урыныннан торды. — Миңа китәргә мөмкинме?

— Кушылганны үтәргә сүз биргәч тә китәсез.

— Аңламадыгызмыни, әйттем ич: үтәмәячәкмен!

Зәйнуллин шактый вакыт утырган урынында тамак кырды, боргаланды, кәгазьләрен күчерде, галстугын төзәтте, йөзе тагын да кызара төште, карашын күтәрмәде һәм тирән итеп сулыш алгандай әйтеп куйды:

— Ул чакта сез китәсез.

— Рәхмәт, — диде Нәфисә, шуны гына көткәндәй. — Бик кирәк иде бу эшегез сезнең миңа. Муеннан гарык! — Ул Зәйнуллинның каршына ук килеп утырды, алдында яткан бер бит ак кәгазьне алды да гариза яза башлады.

Зәйнуллин кәгазьне тартып алды:

— Белүегезчә, гаризага мин кул куймыйм.

— Менә бит сезнең эшегез ничек җайлы! — диде Нәфисә, мыскыллы тавыш белән. — Ярый, хәзер үк мәгариф бүлегенә керәм. — Ул урыныннан торды, Зәйнуллинга иелеп, ягымлы тавыш белән: — Карагыз әле, Дамир Нәгыймович, ник сез миңа туры карап сөйләмисез? — диде.

Зәйнуллин аңа, башыма суга күрмә дигәндәй, куркып кына керфек арасыннан караш ташлап алды да, пышылдап диярлек:

— Күзләрегез күземне чагылдыра, — дип куйды.

— Пәри күзләре кебек ямьсез булып янып торамыни?

— Матур...

— Матур күзләр караганчы, киемегезгә игътибарлырак булыгыз, әнә галстугыгыз кыегайган.

Аның бу сүзләрен ишетү белән, Зәйнуллин ике куллап галстугына ябышты.

— Тиз дә ышанасыз икән, юри генә әйткән идем, — диде дә Нәфисә елмаеп чыгып китте.

Мәгариф бүлеге мөдире уртача гәүдәле, әле яшь булуына карамастан, түбәсе пеләшләнгән башлы, ике бите сабый балаларныкыдай күпереп, алланып торучы Айтуганов, аның «гариза язам» дигән сүзен ишеткәч, йөрәгенә ябышты:

— Нәфисә Фәрвәзовна, сез бит мине пычаксыз суясыз! — диде ялварулы тавыш белән. — Йә, әйтегез, ник кирәк булды ул Саттаров сезгә? Барыбер эшли алмаячак, менә күпмедер вакыттан ычкыныр да, үзегез үк куарсыз. Ә мин сезнең кебек директорны каян табам? Зинһар, колак салыгыз минем сүзләремә.

— Юк! — диде Нәфисә, кисеп. — Мине ни өчен куганыгызны белсеннәр!

Ул шундук гаризасын язып аның алдына куйды. Айтуганов иңбашларын сикертте дә бүлмә буйлап йөренә башлады. Аннары туктап:

— Ярый, кайтыгыз, тагын бер мәртәбә уйлап карагыз әле, — диде.

— Кайтмыйм, иптәш Айтуганов, хәзер үк приказ языгыз!

Мөдир сызлана-сызлана кадрлар бүлеге инспекторын чакырып кертте. Гаризаның почмагына резолюция салып, аңа бирде.

Нәфисә, приказны алып чыккач, бераз уйланып торды, нәрсәгәдер күңеле тулды, нәрсәгәдер ачуы килде, җене котырып, үзен-үзе сүкте. Ник сүккәнен дә аңламады. Шул ук вакытта һәммәсе дә ачык иде кебек. Хәзер ул, асфальт юлдан барган машина салулый-салулый пычрак, балчыклы юлга төшкәндәй, тагын Зөһрә Вәлиевна заманындагы кебек эшли башлаячак. Акылы бармы-юкмы, хакмы-нахакмы, беләмебелмиме, хәзер аңа юнәлеш бирәчәк, ел ярым эчендә оештырган мөстәкыйль эш казанының хуҗасы булмаячак. Бу хакта гариза язганчы ук уйлыйсы булган да бит! Нәфисәнең бер юлы бар: Фәһимә. Ул гына бүрене тук итә ала, сарыкны да исән калдыра ала. Иң киеренке чакларда алар очрашып эч серләрен бушаталар, кайгыдан булса — елашалар, кыенлык туса — чыгу юлларын эзлиләр, бер шатлык килсә — биш итеп куанышалар. Аларның дуслыгы бераз сәеррәк тә кебек. Ни гомерләр аралашып, аларның беркайчан да дүртәүләп, ягъни ирләре белән очрашканнары булмады.

Наратбаш урманындагы пионер лагеренда вожатый булып бергә эшләү аларны гомерлеккә берләштерде. Баш бирмәс балалар, урманның сихри табигате, олы диңгезне хәтерләтүче аллы-гөлле чәчәкләр, көмештәй Ык сулары, шаян күбәләкләр, тәүлек буе тынмаган сандугачлар җыры, җәйге талгын җилләр һәм, әлбәттә, серле йолдызлы төннәр аларның күңеленә күпер салды. Лагерьдагы ул көннәр Нәфисәгә сукыр кешенең күзе ачылгандай тәэсир итте. Җәйге тымызык кичләр иңүгә, мотоциклларында пырылдап егетләр килеп җитә. Кызлар, аларны юри көттереп, бүлмәләреннән чыкмыйлар, чытлыкланып төрлечә үртиләр. Бу җәй алар өчен эштән битәр тылсымлы уенга әверелде. Ни булса да, Нәфисә, егылып тезен авырттырган сабыйдай, Фәһимә янына йөгерде, аңа сыенды, кыз исә аны рәнҗеткән усал егетләрне лагерь капкасыннан ут өертеп куып җибәрде яисә куып җибәрү белән куркытты. Әнә шул ике ай тормыш аларга гомер буе сөйләрлек искиткеч кадерле истәлекләр бирде, очрашкан саен, алар, кыз чакларын сагынып, икесенә генә билгеле булган мавыктыргыч әкиятне сөйләгәндәй, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, шул хатирәләр эчендә йөзделәр. Тора-

бара ул хатирәләргә бүгенге тормыш килеп кушылды. Фәһимәнең искиткеч сыйфаты бар иде: аңарга сөйләнгән сер беркайчан да беркемгә дә чыкмый, гайбәт итеп сөйләнми, сейфка салынган акча кебек, ышанычлы саклана. Әнә шул сыйфаты өчен аңа күпләр тартыла, күпләрнең сере аңарда тупланган. Ул беркайчан да берсенекен икенчесенә җиткерми, араларны болгатмыйча, күңелендә саклый бирә. Аның банк управляющие булып китүе дә юкка гына булмагандыр. Менә хәзер дә Нәфисә дусты янына йөгерә, кабаланып язган гаризасы өчен, гомергә күз яшьләренә сәбәп булган ашыгу гадәте өчен үзен тирги-тирги йөгерә...

Фәһимә аны ишек катына йөгереп килеп кочаклап алды. Аңардан бөркелгән тәмле хушбуй исләреннән Нәфисәнең башы әйләнеп китте һәм эченнән генә көнләшеп тә куйды: мәктәптә, бик теләсәң дә, борынны ярып керә торган хушбуйлар сибенә алмыйсың, модалы итеп киенә дә алмыйсың. Ул яктан караганда, мәктәп Алла каргаган урын булса, Фәһимәнең эше нәкъ менә шуның өчен яратылган кебек. Аңа, иң затлы хушбуйларын сузып, районның барлык җитәкчеләре дә елмая, ялагайлана, чөнки акча кирәк. Юк, картаймый Фәһимә. Нәфисә аның кара бөдрә чәчләренә, сөрмәләнеп торган зур кара күзләренә, бераз гына усаллык билгесе сизелсә дә, юка, әмма матур иреннәренә, колакларына тагылган алтын алкаларына бернинди көнләшүсез сокланып карап торды. Фәһимәнең гәүдәсенә сыланып торган затлы шәмәхә костюмы да аның кыяфәтенә бик ятышлы иде.

— Әйдә, утыр. Син дә исән икәнсең, — диде Фәһимә, аның пальто сәдәфләрен ычкындыра-ычкындыра.

Дустының барлык теләкләренә буйсынып, пальтосын, бүреген элеп куюын сабыр гына көтеп торган Нәфисә түземсезләнеп сүз башлады:

— Минем бит әле бик күңелсез әйбер килеп чыкты, малай, — диде ул, басып торган килеш.

— Тукта, тукта, — дип бүлдерде аны Фәһимә. — Син шушылай, бер чынаяк чәй дә эчмичә, аягүрә генә сөйләшеп чыгып китмәкче буласыңмыни?

— Миндә чәй кайгысымы?! — Нәфисә, күзләренең дымлана башлавын тоеп, ридикюленнән кулъяулык чыгарды. — Караңгы төшкәнче кайтып җитәргә кирәк. Юлга кар сала.

— Ә нәрсә сине бу кадәр борчыды соң әле? — Фәһимә аны култыклап өстәл янына алып килде дә үзе янына утырды. — Кергәндә үк йөзеңдә борчылу иде. Ул синең күңелеңнең чып-чын барометры, эчеңдәге беркайчан да яшерә алмыйсың.

Нәфисә кулъяулыгы белән күзләрен, борынын сөрткәләде

дә Фәһимәгә әле генә алып чыккан приказны сузды. Аны укыгач, дусты аптырап баш чайкады:

— Нәрсә булды?! — Аның кара кашлары бер-берсенә тия язып җыерылдылар.

Нәфисә кыска гына итеп хәлне аңлатып бирде.

— Барысына да үзем гаепле, кызып киттем, гариза язасы түгел иде миңа, — диде.

— Мин дөрес аңлаган булсам, синең эшеңнән китәсең килми. Шулаймы?

— Директорлыктан китеп, бик күп мәшәкатьләрдән котылам, — диде Нәфисә. — Тик гариза язгач кына, икенче әйбер башыма китереп сукты. Әле бит коллектив бар. Минем хакта, менә ел ярым көч-хәл белән эшләде, булдыра алмагач, алып бәрделәр, диячәкләр. Бу бит минем өчен үлем белән бер. Аңлыйсыңмы?

Ул яшьле күзләре белән Фәһимәгә төбәлде. Фәһимә бер сүз дә әйтмәде, ике кулын ирләрчә биленә куеп, бүлмә буйлап йөрергә тотынды. Нәфисә аның шык-шык атлаучы матур аякларына, затлы туфлиләренә сокланып карап утырды. Директор булып эшләргә теләүнең әле иң зур, төп сәбәбе бар иде. Анысын ул дустыннан яшерде. Үзенең директор булуы белән Нәфисә Мэлска мөстәкыйль яши алуын, хәтта үзенең аннан югарырак та икәнен исбатлап килде. Ире ничек кабул иткәндер, әмма ул үзе моннан, тормышының гаҗәп авыр булуына карамастан, билгеле бер ләззәт ала иде. Мэлс кайткан саен аны үзе эшли торган районга кыстады, ә Нәфисә үзенең әлегә аның белән бер дәрәҗәдә яши алуын күрсәтү өчен сәбәп арты сәбәп тапты. Дөресрәге, ул Мэлсны ничек тә булса кире кайтару, районда ниндидер җитәкче эшкә урнаштыру уе белән яна иде. Кызлары Гөлназ өчен аның җанын фида кылырга әзер икәнен белгәнлектән, үз ягыннан төп көч итеп кызын файдаланды. Әгәр мин синең янга күчсәм, Гөлназ ят мохиткә әләгәчәк, диде. Район үзәгендә яшьләрнең әллә нинди азгын группалары барлыгы турында үзең сөйләп торасың, ә кыз кешене өйдә бикләп тотып булмый, җитмәсә, урта мәктәпне тәмамлар елы да якынлаша бара, шуңа күрә Наратбашта калу аның өчен иң яхшысы булачак, диде. Әллә шушы дәлил көчле булды, Мэлс яңадан аңа ялынмады, бу нәрсәне кузгатмады, атна саен яисә ике атнага бер кайтып йөрде. Шуның өстенә Нәфисә аннан үлеп көнләште. Мэлс янына барса, урамда да, башка урыннарда да гел чибәр хатыннар гына очратты, аларны күргән саен, көнчелек уты ныграк дөрләсә дә, тешен кысып түзде. Әгәр нәрсә дә булса сиздерсә, үзенең ваклануын, аңардан түбән икәнлеген күрсәтер кебек тоела иде. Эчендәге әнә шул уфтанулы өзгәләнүләрен ул төрлечә чыгара барды. Әле, сирәк кайта-

сың, диде, әле, кызыбызга игътибарың юк, диде, йә булмаса, нервыларым какшады, дип, үзенең аеры яшәүдән канәгать түгеллеген белдерә килде.

— Беләсеңме нәрсә... — Фәһимәнең дәшүе аны уйларыннан арындырып җибәрде. — Мин Әхнәф белән сөйләшеп карармын. Хәзер приказны юкка чыгару аңа да җиңел булмаячак.

— Рәхмәт, — диде Нәфисә, урыныннан торып. — Син инде минем кергәнне әйтә күрмә.

— Мин шуны әйтә торган кешеме соң?! Син инде балалар белән эшләп, үзең дә шуларга әйләнеп беткәнсең, — дип көлеп җибәрде Фәһимә. — Әйдә чәйләп алабыз.

— Юк, юк, юк, кая ди ул!

Нәфисә кабаланып киенде, дустына рәхмәт әйтте дә аның бүлмәсеннән чыгып йөгерде. Фәһимә аның машинага утырганын һәм киткәнен тәрәзәдән карап торды. Күңелендә каршылыклы уйлар бөтерелде. Күпме бергә яшәп, аның беркайчан да Нәфисәне алдаганы юк иде бугай. Ләкин менә бу юлы башкача мөмкин булмады. Фәһимә Нәфисәне кабат эшенә кайтаруны бөтенләй кузгатмаска булды. Нәфисәнең үтенечен канәгатьләндерү өчен Фәһимә бу эшкә барыр да иде, ләкин ни өчен соң әле ул районда калып, Мэлсны чакырып торучы маяк кебек янарга тиеш? Ә Мэлсның кайтуы — халык арасында инде андый хәбәрләр дә күптән йөри — районның бүгенге тыныч тормышын бозар кебек тоела Фәһимәгә. Аның холкы әз генә дә чигенүне белмәүче, вакыты белән усал һөҗүм итүче, законны әз генә дә әйләнеп үтү дигән нәрсәләрне гафу итми торган гамәлләргә корылган. Район җитәкчесе шуларга гына нигезләнеп эшләсә, бу инде һәр көн кемнәр беләндер кара сугыш, ызгыш-талаш, тавышгауга дигән сүз. Юк, Фәһимә беркайчан да Нәфисә хакында Әхнәфкә сүз катмаячак...

* * *

Нәфисәгә әллә нәрсә булды. Ул Болынкырдан чыкканын да, инде юлның шактый өлешен узганнарын да әллә ни сизмәде. Гүя ул беркадәр вакытка каядыр югалып торды. Машина, кар салган урынга кереп, ни алга, ни артка бара алмый башлагач кына, ул бу дөньяга кайткандай булды. Ә бу дөнья алар килгәндәге кебек ап-ак түгел, алсу нурларга манылган, шактый караңгылана төшкән иде. Аларны озатып килгән кояш инде хәзер кызарып, офыкка килеп кунган һәм акрын гына зур кызыл шар булып батып бара. Юлны себереп торучы җил тагын да көчәйгән кебек. Хәер, ул туктауны белмидер, ул инде ничә көннәр, ничә төннәр тырышкандыр, салкын канаты белән яңа яуган җиңел яшь кар бөртекләрен

еракларга-еракларга себереп алып киткәндер. Ул себереп шомарткан кар өстендә офыктагы салкын олы кызыл шарның шәүләсе җыерчыклы пыяладай елтырый. Шул елтыраучы пыяла өстеннән каяндыр куалап алып килгән кар бөртекләрен кешеләр туктата, тоткарлый күрмәсеннәр дигәндәй, җил ашыктыра да ашыктыра. Алар җилнең канаты астында алсу төтендәй күпереп тә алалар, әмма туктап калу хәлләреннән килми, һаман каядыр билгесезлеккә, салкын, шома өслектән еракка-еракка йөгерәләр.

Фәрит, машина астындагы карны көрәп, тагын алга таба тарттыра башлады. Нәфисә төшеп машинаны җан көченә этте, әмма арт тәгәрмәчләр инде юлны шомартып өлгергәннәр, карны эретеп боз ясаганнар һәм бер урында тәгәрәп торалар иде.

— Хәзер мин агач ботаклары салып карыйм әле, — дип, Фәрит юл буендагы агач полосасына таба атлады.

Нәфисә дә аңа иярде. Менә ул ботакларына калын булып кар утырган, шул авырлыктан ботакларын аска игән нарат янына килде. Борынына тәмле булып сагыз-сумала исе, нарат ылысы исе килде. Астагы корыганрак ботагын сындырып алмакчы булып иелүгә, аның битенә нарат энәләре тиеп китте. Нәфисә искәнеп куйды, гүя ул үзенең бите белән Мэлсның битенә терәлде. Аның гадәттәгечә әйтә торган: «Эх, карчык, ашыгасың да соң!» — дигән сүзләрен дә ишеткәндәй булды. Ул күзләрен йомды да битен нарат ылысларына ышкырга кереште, күзләреннән сыгылып яшь чыкты. Нарат кәүсәсенең кытыршы, каралыбрак торган бер урында кабыгы ярылган, шул урынга чәере сыланган иде. Нарат үз чәере белән үз ярасын үзе ямый, диләр. Әллә мин дә шулай инде, дип уйлап куйды Нәфисә. Элек берәр нәрсә булса, Зөһрә Вәлиевнага бара иде, хәзер бара алмый. Мэлстан үзенең югарырак булуын күрсәтү өчен, директорлыкка риза булды. Аның үзе янына чакырып ялынуын көтте, ләкин максатына ирешә алмады... Әшәкедер мин, дип уйлады ул эченнән һәм күз яшьләренең тагын да ныграк агуын теләде. Беркайчан да ызгышсыз тора алмыйм, дип, эченнән генә үзен битәрләде. Алмаз белән һәрвакыт элгәләште, хәзер Гөлназ белән, Мэлс белән нәрсә дә булса китереп чыгара. Әгәр аның тагын да ныграк ялынуын теләмәгән булса, ул инде әллә кайчан анда китәр, бергә рәхәтләнеп кенә яшәр, менә хәзерге кебек бот төбеннән салкын кар эчендә басып тормас иде. Каплап куйган олы савытны хәтерләтүче кояшка ул ылыс энәләре аша сагышланып карап торды. Әллә үзе селкетүдән, әллә җил тәэсирендә нарат ботагындагы калын гына кар кисәге аның кулына килеп төште. Кар бөртекләре, җиң эченә кереп, тәнне өттереп алдылар. Ул, перчаткасын салып, карны бармаклары белән чыгарырга кереште. Кар бөртеклә-

ре төссез тамчыларга әверелеп эределәр. Физика дәресендә кар кристалларын ак та түгел, зәңгәр дә түгел, төссез дип өйрәтәләр. Ләкин аларның аралыкларына һава тула, һәм, шул яктылыкны чагылдырып, безгә ак булып күренә. Менә ул хәзер, алсу төсне чагылдырып, кояшның шул төсенә буйсынган. Хәтта укытучылары, ак чәчәкләр дә ак түгел, аларның күзәнәк аралыкларындагы һава аркасында гына таҗ яфраклары безгә ак булып күренәләр, дип сөйли иде. Менә хәзер дә Нәфисә үзен әллә нинди сагышлы әкият эчендә басып торгандай хис итте. Каршысында ылыслар артыннан төшеп баручы кояшның кызыл түбәтәе, ак карлар да, күк йөзе дә алсу нурга күмелгән.

Фәрит машинасын кычкыртты. Нәфисә алга таба атлады һәм, инде чыгып җитәм дигәндә, тагын бер мәртәбә артына борылып карады. Тигез булып тезелгән яшел наратлар уртасында әле бер ялгыз имән дә тора икән. Шунысы сәер: имәннең яфраклары коелмаганнар, гүя бөтен дөньяның аклыгына, бөтен агачларның яфрак коюына каршы килеп, усаллanып җилфердиләр. Алар кузгалып киткәндә, кояшның түбәсе дә офык артына төшеп югалды, бары тик аның кызгылт нурлары гына һаваны аллandырып торуын дәвам итте.

Нәфисә кайтып кереп ашарга әзерләргә дә өлгерә алмады, телефон шылтырады. Ул йөгереп барып трубканы алды. Шылтыратучы Зәйнуллин иде.

— Мин сезгә барысын да аңлата алмадым... — дип, әллә ничек аңлаешсыз, өзә-төтә сөйләргә кереште ул. — Ашыгырга кирәкми иде. Мин дә бит үтәүче генә.

— Акланырга кирәкми, мин барысын да аңладым, — диде Нәфисә.

— Мин акланырга теләмим. Әйтергә теләгәнем шул гына... Мин һаман да сезнең каршыгыздагы укытучы. Күңелемдәге бер генә тойгым да сүрелмәде... — Ул, шактый вакыт туктап торгач, сүзен төгәлләде: — Сез миңа бер генә әйбер әйтсәгез, күпмедер дәрәҗәдә тынычланыр идем...

— Нәрсә әйтергә тиеш мин сезгә?

— Ачу сакламам, рәнҗемәм, дип кенә. Шул сүз җитә...

— Ачу да сакламыйм, рәнҗемим дә.

— Рәхмәт.

Сөйләшү шуның белән тәмам булды.

## 2

Дамир Зәйнуллин нәкъ сөйләшенгән вакытта — кичке алты туларга унбиш минутта ишектә күренде. «Өлгер дә, төгәл дә, молодец!» — дип куйды эченнән генә Әхнәф. Зәйнуллин төз озын гәүдәсен гадәттәгечә бераз як-якка чай-

калдырыбрак атлап килде дә аңа көчле каты кулын сузды. Әхнәф бераз көнләшү тойгысы белән аның тыныч ак йөзенә, әле чал кунарга өлгермәгән коңгырт чәчләренә яратып карап торды. Урынбасарның йөзендә, һәр хәрәкәтендә эшлеклелек, үз-үзенә ышаныч сизелә, ә иң мөһиме, ярарга тырышу, ялагайлануның әсәре дә юк иде. Менә ул ай азагында булачак мәдәният хезмәткәрләре семинарының планын, анда күтәреләчәк мәсьәләләрне сөйләргә кереште. Барысы төптән уйланган, нигезләнгән, дәлилле. Әхнәфләр комсомолда эшләгән еллардагы кебек, үрдә дулаган аттай, уйлап бетермичә, атылып-бәрелеп алга чабу юк. Социаль мәсьәләләр буенча урынбасар эзләгәндә, аңа кемнәрне генә тәкъдим итмәделәр. Әхнәф барысын да кире кага килде, Зәйнуллинны башына да китермәде. Шул көннәрдә ничектер Мэлс белән сөйләшкәндә, Зәйнуллин хакында ул аның бик акыллы, эчкерсез егет булуын сөйләгән иде. Кабат аның шәхси эшен карагач, документларын актаргач, Әхнәф Зәйнуллинның үзен әңгәмәгә чакырды. Гаиләсе булмаганга күрәме, әллә инде бу олы эш аны канатландырып җибәрдеме, Зәйнуллин ике дә уйламыйча ризалашты. Эшли башлау белән аның нәкъ менә шул урын өчен яратылган кадр икәнлеген күпләр Әхнәфкә туп-туры әйттеләр. Рәхәт иде аның белән эшләве. Хәзер дә Әхнәф аның һәр сүзен башын җиңелчә генә ия-ия раслап барды.

Кинәт Зәйнуллин аны сискәндерерлек нәрсә әйтеп ташлады:

— Наратбаш мәктәбе буенча сезнең боерыгыгыз үтәләчәк. Әмма мәсьәлә катлауланыбрак китте.

— Ничек?

— Сабитова үзе эштән китәргә мәҗбүр булды.

Менә бусын Әхнәф һич тә теләмәгән иде. Ләкин Саттаровны эштән җибәрә алмаган очракта бу вариант та күздә тотылды. Зәйнуллинның бу сүзләренә ул үзенең мөнәсәбәтен белдермәде. Бераз уйланып торды да:

— Сезнең беттеме? — дип куйды.

— Әйе, — диде Зәйнуллин һәм урыныннан торып чыгып китте.

Инде кайтып китәргә кирәк булса да, Әхнәф шактый вакыт уйланып утырды. Мәсьәләнең болай хәл ителүе аңа ошамый иде. Димәк, Нәфисә үз фикереннән чигенмәгән. Мәктәптәге бөтен укыту эше Саттаровка терәлеп калганмы, әллә башка сәбәп бармы? Бу борчулы уйларны күңелдә йөртергә кирәкми, алардан котылу хәерле. Ә котылу өчен һәммәсен дә уч төбендәгедәй ачык күрергә кирәк...

Өч көннән соң ул Наратбаш мәктәбенә юл тотты. Иң элек Нәфисә белән очрашты. Мәктәп хәлләре белән танышты, мине эштән гаделсез алып аттыгыз диюен көтте,

әмма элекке директор теш арасыннан бер генә зарланырлык сүз дә ычкындырмады. Әхнәф тә, аның директор түгелле-ген бөтенләй белмәгәндәй, мәктәптәге укыту-тәрбия эшләре белән җентекләп кызыксынды, класс-кабинетларны карады, хәтта бер дәрескә дә кереп утырды. Шул ук көнне кичкы-рын халык мәгарифе бүлеге мөдирен бүлмәсенә чакырып кертте.

Ул керү белән:

— Ягез, Наратбаш мәктәбе белән нишлибез? — диде.

— Яңа директор эзләргә туры килә инде, — диде мә-гариф бүлеге мөдире, җиңүче кыяфәтендә аның күзләренә туп-туры карап.

Аның бу сүзләренә Әхнәфнең ачуы чыкты.

— Рәхмәт күземне ачуыгыз өчен, — диде ул, кинаяләп. — Әле бит мин анда директор кирәк түгелдер дип уйлый идем. Ул хакыйкатьне үз акылыгыз белән ачтыгызмы, әллә берәр акыллырак кеше өйрәттеме?

Мөдир аның сүзләреннән кып-кызыл булды, ык-мык килүдән башка сүз әйтә алмады.

— Мин бит сезнең белән сөйләшенгәнчә...

— Без Саттаров турында сөйләштек сезнең белән, аның идеологиясе турында.

— Әгәр директор буйсынмаса... аның урынына да кеше эзләргә туры киләчәк, дидегез.

— Ә сез «киләчәк» дигән сүзнең мәгънәсен аңлыйсызмы?

Мөдир карашын аска төшерде.

— Уку елы уртасында түгел. Мин бүген аның мәктәбендә булдым. Сезнең барганыгыз бармы анда?

— Бар...

— Эш ничек оештырылган?

— Башкаларга үрнәк итеп куярлык.

— Мин дә шулай уйлыйм. Димәк, приказыгызны үзгәр-тергә туры килер. Аңладыгызмы?

— Аңладым.

— Барыгыз, Сабитова белән яхшылап сөйләшегез, гафу үтенегез. Әгәр үпкәләп баш тартса, мин үтенде диегез. Эшенә кире кайтарылган булсын.

* * *

Нәфисә кичтән үк тәмләткечләр белән эшкәртелгән куян итен духовкага тыкты да күлмәкчән килеш кенә тышка чы-гып йөгерде. Әле сәгать ике генә тулып киткән булса да, инде кич якынлашуы сизелеп тора, күктән берән-сәрән генә эре кар бөртекләре төшә. Йөгереп барып, ул олы капканы ике якка ачып куйды. Шәрә беләкләренә төшкән кар бөр-

текләрен, кышкы салкын һаваны да сизмичә, кабат өйгә керде. Инде өч көн күңеленнән бәйрәм итә Нәфисә. Мәгариф бүлеге мөдире Айтуганов аны эшеннән алу турындагы приказны юкка чыгарачагын әйткәч, ул моңа котырып каршы төште. Инде үзенең теләгенең тормышка ашуын күргән килеш, шуңа каршы килеп маташты. Әллә инде бу үпкәләүдән, әллә мөдирдән үч алырга теләүдән, әллә үзенең аны җиңүеннән бер очыну идеме — бусын Нәфисә әйтә алмый. Айтуганов «Шәрифуллин үзе үтенде» дигәч кенә күнде. Икенче көнне приказны ул сөенә-сөенә аңа алып килеп тоттырды. Әхнәфнең моны Фәһимә үтенече буенча эшләгән булуына һич тә икеләнмәде. Нәфисәнең дусты белән бер чөкердәшеп утырасы, аңа рәхмәт әйтәсе килде. Уйлый торгач, ул берни дә әйтмәскә, бары тик аны Әхнәф белән бергәләп үзләренә кунакка чакырырга ниятләде. Бер мәртәбә булса да, хакимият башлыгының аларның өенә аяк басарга тиешлеген ул инде күптән уенда йөртә иде. Кичтән үк Мэлска да шылтыратты. Ул, Казанга китүем мөмкин, әгәр китмәсәм, кайтырмын, диде. Фәһимә башта, әллә берәр нәрсә бармы, дип, бу чакыруның сәбәпләрен төпченеп маташса да, ярар, Әхнәф килә алмаса да, үзем әйләнермен, диде. Нәфисәнең чакыруы Фәһимәгә өстенә салкын су койгандай тәэсир итте. Аның уйлавынча, Нәфисә аларның икесен дә чакырып, Әхнәфнең күңелен йомшартмакчы һәм үз дигәненә ирешмәкче иде. Фәһимә, бөтенләй теләмәсә дә, дустының үтенече хакында Әхнәфкә сөйләргә мәҗбүр булачак. Һәм, кем белә, Нәфисәгә барып сый-хөрмәт тә күрсә, аның теге приказны үзгәрттерүе дә бар иде. Фәһимә бу хәлдән төрле-төрле котылу юлларын эзләде. Күп уйлый торгач, максаты анык төс алды. Нәфисә белән араны якынайту түгел, мөмкин кадәр ерагайтырга кирәк ләбаса! Шул күзлектән чыгып караганда, бернәрсә дә үзгәрмәскә тиеш, шулай калган очракта гына Фәһимә әлеге теләгенә ирешәчәк. Кыскасы, ул Әхнәфкә берни дә әйтмәде. Нәфисә алдындагы гаебен юу өчен тәм-томнардан күчтәнәчләр әзерләде, башында аның белән сөйләшәсе мәсьәләнең планын эшләп куйды.

Куян ите авыз суларыңны китерерлек тәмле исләр чыгарып чыжылдый башлаганда, Фәһимә кояштай балкып килеп керде һәм, пальтосын да салып тормыйча, дустын кочагына алды, аның аш-су белән кайнашудан кызарып-кайнарланып чыккан битләрен чат-чот үбеп алды. Өстәл әзер, Нәфисә шатлыктан биеп тора, өйдә икесе генә, күңелләр очрашудан тулышкан иде. Бәллүр рюмкалар затлы шәраб белән тулгач, хәл-әхвәлләр сорашкач, алар тәмләп әңгәмә кора-кора ашарга керештеләр. Ирләренең үзләре янында булмавына ризасызлыкларын белдерсәләр дә, аларның йөзләре якты,

дөньялары түгәрәк иде. Хәер, моны икесе өчен дә алай ук дип булмый. Фәһимәне эчендәге борчулы уйлары бик тирәнгә куарга теләсә дә, туктаусыз бимазаладылар. Шуңа күрә ул Нәфисә башлаганчы ук сүзгә керешергә булды.

— И малакаем, синең алда бурычлы булып йөрим бит әле мин һаман, — диде ул, бәллүр рюмкаларның икенчесен чәкештергәч. — Теге көнне үк Әхнәфкә бөтенесен сөйләп бирдем. Менә җене белән карышты бит, юк, ди, мин роно мөдиренең боерыгын үзгәртә алмыйм, ди. Аласың, дим. Син юри миңа үчләшәсең, сезнең аны алып атарга хакыгыз юк, дим. Өченче көн дә шушының аркасында талашып беттек, елап та куркыттым, һич тә кузгата алмыйм.

Нәфисә аны, тәҗрибәле педагог буларак, җентекләп күзәтеп утырды. Аның һәр сүзен, һәр кыланмышын күңеленә салып барды һәм, ничә еллар буе дус булып йөргән ахирәтенең күзгә карап алдашканын күреп, хәйраннар калды. Фәһимә акланды да акланды, булмаганнарын да бар итеп, бөтен гаепне Әхнәфкә аударды. Нәфисә аны берничә мәртәбә бүлдерергә тырышып карады, әмма Фәһимә борып куелган патефон табасы сыман сөйләде дә сөйләде, аны туктатуы мөмкин түгел иде. Аны тыңлаганда, Нәфисә бер сорауга җавап эзләде: дусты үзен Нәфисә алдында гаепле саныймы, шуннан кыенсынып кына алдашамы, әллә башка сәбәп бармы? Аның сөрмәле матур күзләренә карап, Нәфисә әнә шуңа җавап эзләде. Тора-бара ул Фәһимәнең Әхнәфкә берни дә әйтмәгәнлеген аңлады. Димәк, аның каршында утыручы дусты элекке Фәһимә түгел яисә ул элек тә шушы Фәһимә булган, әмма дус булып кына кыланган. Нәфисәнең әле күңеле тулды, әле котырып ачуы килде, ул берничек тә үз-үзен кулга ала алмады. Ниһаять, ул Фәһимәне бүлдереп, ачуын яшерә алмыйча, аның күзләренә туп-туры карады да:

— Фәһимә, тукта, зинһар! — диде. — Кабат эшемә кайтканыма дүрт көн булды. Әхнәф кушкан...

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәһимә, авызындагы куян итен чәйнәүдән туктап, өнсез калды. Аның кызыл иреннәре арасыннан, куян койрыгын хәтерләтеп, ак ит кисәге селкенеп тора иде.

— Кых... кых... — Фәһимә куян итен учына алды. — Кушкан?! Әхнәф?!

— Әйе, — диде Нәфисә. — Синең аны көн саен игәүләүләрең юкка булмагандыр инде. Бик зур рәхмәт сиңа, дустым.

— Әйе, ни... тырыштым, тырыштык инде... — диде Фәһимә, һаман ушына килә алмыйча. — Ул кадәр әйтүгә дә...

— И Фәһимә! — диде Нәфисә, аның ялганына капмавын сиздереп. — Син бит Әхнәфкә бер сүз дә әйтмәгәнсең.

— Каян беләсең? — дип кычкырып җибәрде Фәһимә.

Нәфисә өчен инде хәзер барыбер иде. Шуңа күрә ул аннан да хәтәррәк итеп алдашырга кереште:

— Әхнәф үзе әйтте, мин сораган идем. Берни дә әйтмәде, диде.

— Ах оятсыз! Алдаша ул, — диде Фәһимә, ниндидер котылу чарасы эзләп. Аның күз алмалары туктаусыз сикерештеләр. — Мин әйттем аңа, җене белән карышты. Карале, алар беркөн Мэлс белән очрашканнар, шуннан соң кире уйлагандыр Әхнәф. Ирең сине үз янына китертмәс өчен Әхнәфтән директор итеп калдыруын сорагандыр.

— Булмас... — диде Нәфисә, үзен аның каршында мескен итеп калдырырга теләмичә.

Фәһимә аның төшенке тавышыннан үз кармагына килеп капканлыгын аңлады. Инде аны ычкындырмаска кирәк иде. Һәм ул учлап яңа җим сипте:

— Син артык беркатлы, дускаем! Бер хатын миңа беркөн бер әйбер сөйләде Мэлсың турында...

Нәфисәнең күңелендә сүрелер-сүрелмәс яткан көнчелек уты, кинәт чыккан җилдән дөрли башлаган кебек, ярсыткыч сулышын өрергә кереште.

— Нәрсә сөйләде?! Кем ул хатын?!

— Ярый инде, калып торсын. Мин аның исемен әйтә алмыйм.

— Ә нәрсә сөйләде соң ул?

— Кем әйткәнен төпченмәсәң генә.

— Төпченмим, төпченмим! — диде Нәфисә, аңа таба урындыгын шудырып.

— Бер ай элек бер хатынны ире Мэлс белән тота язган...

Нәфисәнең чырае бозылды, куллары йодрыкланды, ешеш сулыш алудан аның күкрәге бер күтәрелде, бер төште.

— Юк, мин моны болай калдырмыйм! — дип кычкырды Нәфисә. — Әйт, кем сөйләде?!

— Ачу китереп утырма инде, зинһар! Моның ни әһәмияте бар? Әйтерсең лә ирләрнең син кем икәнен белмисең. Янында түгел икән, син инде аның йөрүенә риза дигән сүз. Аларның бит кулларын биленә салган чакта да күзләре тирә-юньдәге хатын-кызны айкый.

Нәфисә акрын гына урыныннан торды. Ачудан аның күз бәбәкләре чекерәйгән, иреннәре калтырый иде. Ул акрын гына Фәһимәгә таба килә башлады, тавышы хәтта юньләп тә ишетелмәде:

— Син миңа бер генә әйбер әйт: кем ул хатын?!

Фәһимә чәрелдәп җибәрде:

— Син бит төпченмим дидең — төпченмә!

Нәфисә аның каршына килеп басты:

— Әгәр әйтмәсәң, мин сине чыгармыйм.

Фәһимә чигенә-чигенә өстәлне әйләнде дә йөгереп барып тунына үрелде. Нәфисә арыган-талчыккан кыяфәттә ишек яңагына сөялде һәм, тыныч, битараф тавыш белән:

— Син бит ялганладың, шулаймы? — дип сорады.

— Юк, ялганламадым... — диде Фәһимә, тунының сәдәфләрен каптырып.

— Безнең өйгә кергәннән бирле син бер генә дөрес сүз дә сөйләмәдең. — Нәфисә тыны кысылып, бераз бүленеп торды. — Син беркайчан да дус булмагансың! Син мине гомер буе алдагансың!..

— Ничек син миңа шундый гаеп ташлый аласың?! — диде Фәһимә, кыза барган кыяфәткә кереп.

— Кыланма, файдасыз! — дип бүлдерде аны Нәфисә. — Мин һәрвакыт синең сүзләреңдә нәрсәдер сизенеп килдем. Тик үземнең сиңа Аллага ышанган кебек ышануым аркасында ялгыш сүзеңне дә күңелем белән төзәттем. Син минем белән сабый бала белән уйнагандай уйнагансың.

— Бер мәртәбә Фәһимә ярдәм итә алмагач, хәзер аңа пычрак атасыңмы? Әйдә, ат! — диде Фәһимә, ярсып.

— Ә син икейөзле, ялганчы! Бүгеннән син минем дошманым!

— Дошманың булгач, син инде безнең районнан чыгып ук кит! Юкса муеныңны сындыруың бар. Мин бит синең гадәтеңне беләм: хәзер елыйсың, акырасың, биш минуттан акылыңа киләсең. Кисәтеп куям: чәчеңне йолкый-йолкый гафу үтенсәң дә, бу сүзләрең өчен мин сине кичермәячәкмен!

Нәкъ шул минутта, ишек ачылып, Мэлс килеп керде. Аны күргәч, бер чыраның ике башына эленгән ике ялкын кебек, бер-берсенә таба дөрләп килүче хатыннар шып туктап калдылар.

— Нәкъ менә син кирәк идең! — диде Нәфисә, ачулы тавыш белән.

— Ярый, мин киттем, — дип Фәһимә ишеккә кузгала башлауга, Нәфисә аны барып туктатты.

— Юк, китмисең! Менә хәзер әйт: Мэлсны кайчан, кем белән, кайда тотканнар?!

Мэлсның сала башлаган пальтосы идәнгә төшеп китте:

— Ни сөйлисез сез?!

Нәфисә Фәһимәне беләкләреннән эләктереп иренә таба сөйрәде:

— Әйт, менә күзенә карап әйт: кайчан тотканнар аны?

— Мин сиңа күрдем димәдем! Мин сиңа кеше сөйләгәнне әйттем!

— Ә син менә шул кешене әйт! Хәзер өчебез дә янына барабыз. Исемен әйт!

Ярсудан Нәфисәнең чәче-башы тузган, йөзе куркыныч кыяфәткә кергән иде.

Мэлс, Фәһимәгә якын ук килеп:

— Йә, Фәһимә, әйт. Минем өчен бик зур яңалык бу, — диде.

Фәһимәнең куркулы күз карашы дерт-мерт килеп уңгасулга йөгерде, кашлары сикерде.

— Мин әйтмәдем... Мин кеше сөйләгәнне генә сөйләдем... — Ул Нәфисәне читкә этеп җибәрде дә ишеккә ташланды.

— Тукта! — дип кычкырып, Нәфисә аның артыннан ыргылды.

Ләкин ул шундук елый-елый борылып керде. Мэлс кулларын күкрәк турына кушырып, тешләрен кыскан хәлдә ачу белән карап тора иде. Нәфисә, борынын тарта-тарта, лышыклышык елап, өстәлгә куян ите китереп куйды.

— Аша әнә...

Мэлс аны иңбашларыннан тотып өстәл янына утыртты, үзе каршы якка утырды. Ашъяулык өстеннән әле яңа башланган күпереп пешкән ипине кулына алды, аны әйләндерепәйләндереп карады, иснәде һәм ипигә карап сүз башлады:

— Менә сез монда нәрсә тикшереп ятасыз икән... Миннән дә ахмаграк кеше юк! — Ул бераз тынып торды да кинәт, каты тавыш белән: — Кара әле миңа! — диде. Нәфисә кыпкызыл булган күзләре белән аңа төбәлде. Мэлс өстәлдән әлеге ипине кулына алды. — Менә шушы ипине тотып ант итәм! Әгәр алдагы якшәмбедә син минем белән күчеп китәргә әзер булмыйсың икән, өйләнәм!

Нәфисә, сикереп торып, кычкырып еларга кереште. Әле залга, әле кухняга чыкты, үзе туктаусыз сөйләнде:

— Өйлән, йөри торган кешең бардыр!.. Мин монда берүзем хуҗалык алып барам, мәктәптә укытам, бала тәрбиялим, кайтарган керләреңне юып, үтүкләп җибәрәм, ә син анда өйләнү планнары белән яшисең икән...

Кинәт Мэлс сикереп торды да йодрыгы белән дөпелдәтеп өстәлгә китереп сукты, нәрсәдер шартлап ауды.

— Җитте! — дип кычкырды ул. — Син гомер буе газап чигүче Гайсә пәйгамбәр ролен уйнадың. Күз яшьләрең белән минем җанымны ашадың! Бу сүзләрнең дөреслегенә син бит үзең дә ышанмыйсың. Синең үзеңне газап чигүче итеп күрсәтәсең килә. Әнә карагыз, ул мине ничек газаплый, янәсе! Ә мин нинди сабыр, янәсе! Сез минем шундый икәнемне күрәсезме, янәсе?! — Мэлс йодрыгы белән өстәлне дөпелдәтә-дөпелдәтә дәвам итте: — Тагын шуны әйтеп ку-

ям: әгәр бармасаң, аерылсак, Гөлназны да алачакмын. Аңладыңмы?

Мэлс, бер йотым су да эчмичә, чишенмәгән килеш урынына барып ятты. Нәфисә үзенә аерым урын җәйде. Алар икесе дә төне буе кымшанмыйча яттылар, әмма йокламадылар. Мэлс таң белән сикереп торды. Нәфисә өстәл әзерләде. Ул ипи кисә башлауга, Мэлс кулыннан ипине тартып алды.

— Ә бу ипигә кагылмыйсың, мин аны үзем белән алам. Якшәмбе көнне иртүк кайтып җитәчәкмен.

Нәфисә, яшь тулган күзләрен мөлдерәтеп, башын аңа күтәреп карады, аның ияге, иреннәре дер-дер калтырый иде. Әйтәсе сүзен әйтә алмыйча, авызын бер ачып, бер йомып, шактый вакыт торгач, ниһаять, сыгылып бер сүз чыкты:

— Көтәр-мен... — Һәм ул үкереп елап Мэлсның күкрәгенә ауды, дер-дер калтыранган гәүдәсе белән аңа сыенды...

## 3

Фәһимә итекләрен, бүреген киде дә ишекне дә япмыйча чыгып йөгерде. Ул машинасын кайтарып җибәргән иде, кызу-кызу дирекциягә таба атлады. Аның өстеннән коточкыч зур йөк төште. Элек дус булып йөргән, аны сейф дип мактап, эч серләрен бушатырга, киңәш сорарга килгән хатыннар, Әхнәф район башлыгына әверелгәч, үзләренең элекке максатларын үзгәрттеләр: йә төшемлерәк эш урыны сорап, йә үзләренең кемнәренәдер биегрәккә юл яруын үтенеп, бәлагә тарыганнарын коткарырга ялварып, Фәһимәгә мөрәҗәгать итә башладылар. Мондый үтенеч белән килүчеләр — ә андыйлар көнләп түгел, сәгатьләп арта барды — Фәһимә өчен авыр йөккә әверелде. Якын, дус, туган, күрше, хезмәттәш дигән штатларны рәхимсез кыскартырга кирәк иде һәм, бу шактый кыен эш булса да, эзлекле рәвештә башкара килде. Аларның тагын берсенең кыскаруына ул бик шат иде. Шул ук вакытта аны башка нәрсә хафага салды: ни өчен соң әле Әхнәф, роно мөдиренең боерыгын юкка чыгарып, Нәфисәне кабат директор иткән?

Совхоз директоры Фәһимәне куана-куана үз машинасы белән илттерде. Өйгә кайтып чишенгәндә, баягы сорау аның тәмам тынычлыгын алды. Мондый мәсьәләләрне аның белән киңәшмичә хәл итми торган Әхнәф соңгы вакытларда нишләптер койрыгын тоттырмый башлады. Бу инде араларның ераклаша баруы, икесенең ике төрле уй-тойгылар белән яшәвен күрсәтүгә җитди ишарә иде. Әллә инде Фәһимә картаеп киттеме? Ул, көзге каршына килеп, үзенең йөз чалымнарын,

артка чигенеп, иелә-иелә гәүдәсен карады. Юк, әле ул элеккечә күркәм, ир-атны дулкынландырырлык иде. Кайчан ычкына башлады соң әле Әхнәф аңардан? Хатын — ирнең күңел бакчасындагы агачның сүле, син аның һәрбер капиллярына үтеп керергә тиеш. Әгәр үтмисең икән, ир дигән агач яфрак ярмый, чәчкә атмый, җимеш бирми, бөкрәеп үсәргә һәм бөтенләй корырга мөмкин. Әгәр аның һәр күзәнәгенә үтеп кермәсә, сүл булып һәр күзәнәген сугармаса, аны башкалар сугара, ул чакта инде, җиргә тигән помидор ботагы тамыр җибәргән кебек, ир-атны башка җирдән килүче сүлләр туендыра башлый, яңа тамыр җибәргән турдан исәпсез-хисапсыз вак ботаклар үсеп, куакның көчен алган кебек, ир-ат та төрле якка чәчелә, хатынын оныта ук башлый. Элегрәк ул иренең күңелендәге һәрбер тирбәлешне тоя, һәр уен белеп тора, аңа карата үзенең фикерен әйтә, авыррак мәсьәлә килеп чыкса, аны хәл иткәнче Әхнәф белән бергәләп баш вата, аның юлларын эзләшә иде. Моңа ире шулкадәр күнекте ки, хатын-кыз белән булган яшерен мөнәсәбәтләреннән тыш — ә аларның барлыгын Фәһимә сизенә иде — һәммәсен дә алып кайтып уртак бизмәнгә салды. Төптән уйлап карасаң, Фәһимә кебек хатының булу җитәкче кешегә чын табыш иде. Чөнки ул астагылар белән киңәшсә, үзен күпмедер дәрәҗәдә көчсез итеп күрсәтә, өстәгеләр белән киңәшергә ярамый. Димәк, бердәнбер таянычың булып хатының кала. Шушы нәрсәне яхшы аңлап, Фәһимә иренең икенче тәненә әверелгән иде. Күп еллар алар шулай яшәделәр. Әхнәф, һәр көн күнегелгән урынына су эчәргә, ашарга килгән мал кебек, күңел серен бүлешергә хатынына мөрәҗәгать итте. Ире моны теләмәгән чакларында да Фәһимә, үзе генә белә торган кылларына кагылып, аның сандугачын сайрарга мәҗбүр итә иде. Нишләп соң әле гомер буе яшәп килгән тәртип хәзер бозылды? Әллә Нәфисә белән Әхнәф арасында нindидер яшерен мөнәсәбәт бармы? Фәһимә, күпме генә уйласа да, бу шикле сорауга «әйе» дип тә, «юк» дип тә җавап бирә алмады. Әмма ул алай җавап бирмәүдән сорауның шиклелеге кимемәде, киресенчә, артты гына. Бу нәрсә бик мөмкин ич. Наратбаш балаларын белемле, тәрбияле итү максатыннан гына Нәфисәне мәктәпне җитәкләргә куймагандыр ире.

Ыграк уйланган саен, аның күңелендәге давыл ныграк котыра барды. Ул котырган саен, Фәһимәнең зиһене тоныкланды, әлеге сорауга фикерен туплыйсы урында, барлык күзәнәкләрен ярсу катыш ачу биләде. Бүген ул очраклы рәвештә Әхнәфнең бер генә гамәленә тап булды, аның андый эшләре һичшиксез күп, әлбәттә. Нишләп соң әле Фәһимә алардан читтә кала? Әгәр шушы вакытта ире кайтып

керсә, ул аңа нәкъ менә шушы сорау белән очып куначак иде. Фәһимәнең бәхетенә, Әхнәф соңарыбрак кайтты. Ул инде анык карарга килгән: иренә ташланмаска, сабыр гына сөйләшеп, үзенең күңелен телгәләгән шикле сорауга ачык җавап алырга. Фәһимә Әхнәфне бер алдына, биш артына төшеп сыйлады, хәтта гомер булмаганча, үзе башлап, өстәлгә коньяк та китереп утыртты. Иренең нәрсә хөрмәтенә дигәндәй сораулы күз карашына:

— Бүген мин бик нык арыдым, — дип кенә җавап бирде.

— Алайса, без шулай сөйләшик, — диде Әхнәф, елмаеп. — Мин һәр көн бик нык арыйм. Шулай булгач, син мине көн саен өстәлгә коньяк куеп каршылый торган бул.

Фәһимә аңа мут елмаеп бармак селкеде:

— Юк инде, Әхнәфкәем, минем әле синең белән бик озак еллар бергә яшисем килә, — бу әйбер ир белән хатын арасына керә торган иң әшәке дошман.

— Бүген керттең бит.

— Һәрнәрсә күләмгә караш — бу синең сүзләр. Арттырсаң — агу, киметсәң — дару.

Алар икесе дә, күңелле генә көлешеп, шул урында сүзгә нокта куйдылар. Залга чыккач, Фәһимә Әхнәфнең иңбашына кулларын салды һәм диванга утыртты. Имән бармак очы белән аның кашларын сыпырды, ике чигәсендәге чәчләре арасында нидер эзләгәндәй итте, битләренә, ияк янындагы сөйкемле миңенә кагылды.

— Син мине бик җентекләп өйрәнәсең әле, — диде Әхнәф, аның иреннәренә иреннәре белән кагылып.

— Сагындым. Уйларың да хәзер миннән ерак йөри сыман.

— Ни турында әйткәнеңне белмим.

— Наратбаш мәктәбенә Нәфисәне кую өчен бик нык тырышкансың дип сөйлиләр.

Әхнәф кинәт кенә тартылып куйды, хатынының бу сүзләре, күрәсең, аңа шактый нык тәэсир итте.

— Сөйлиләрме?! Чынлап әйтәсеңме?!

— Ә мин каян белер идем? Элек без андый мәсьәләләрне икәү хәл итә идек тә... Бусын аңлап бетерә алмадым...

— Була торган хәл бит инде, — дип куйды Әхнәф. — Безнекеләргә тырнак кисәргә кушсаң, бармакларын кисеп ташлыйлар кайчакта.

— Без синең белән Мэлсның районга кайту ихтималы турында күптән сөйләшкән идек. Нәфисәне директор итү аңа юл ачу түгелме? Карак керсен өчен урам капкасын ачып куйгандай...

Әхнәф ясалма көлү белән көлеп җибәрде. Бу хакта ул, әлбәттә, баштан ук уйлады. Нәфисәне эшеннән алу Саттаровны мәктәптән кууга килеп бәйләнгән, һич тә моны эшләр-

гә ярамый иде. Саттаров әтисе белән бергәләп, ай-һай, күп мәшәкатьләр тудырырга мөмкин! Район белән җитәкчелек иткәндә, закон дигән нәрсәне әйләнеп тә узарга туры килә. Ә моны Саттаровлар элеп кенә алалар, күпертәләр, матбугат органнарына, югары инстанцияләргә юллыйлар. Саттаровның Мэлстан күп мәртәбәгә куркынычрак икәнлеген аңлап, Әхнәф шушы адымны ясарга мәҗбүр булды. Мэлс астыртын эш йөртә торган кеше түгел. Әгәр ул районга кайтырга теләсә, беркайчан да Әхнәф өстенә басмаячак, киңәш-табыш итәчәк. Аннары Әхнәф белән Иреркнең дуслыгы да Мэлсны каршы гамәл кылдыра алмый. Бу нәрсәләрне Фәһимәгә әйтү кирәкми иде. Гомер буе күп нәрсәләрдә хатыны белән киңәшкән булса да, хәзер район башына менгәч, Әхнәф аеруча сак кыланырга кирәклеген аңлады. Шуңа күрә туры җаваптан качты:

— Керәсе карак капка өстеннән дә керә ул. Әгәр мин гаделлекне торгызмасам, халык ни әйтер? Мин ничек Нәфисә күзенә, Мэлс күзенә, Ирек күзенә карыйм?

— Бөтен кешенең дә күзенә генә карап торсаң, берни дә кылмаска кирәк.

— Юк инде, алар бөтен кеше дә түгел, якын кешеләр.

Әхнәф әлеге сүзләре өчен эченнән генә үзен мактап куйды, алар хатыны алдында аны югары күтәрәләр, димәк, көчлерәк итәләр иде...

Үзенең сорауларына җавап ала алмаган Фәһимә күңелендәге борчу тойгысының тагын да көчәюен сизде. Аның өчен инде Нәфисә ерагаеп калды, аның өчен хәзер ераклаша баручы Әхнәфне кабат элекке хәленә кайтару үтә мөһим нәрсәгә әверелде. Моны бер селтәнүдә хәл итеп булмый, моның иң элек сәбәпләрен ачыкларга, хәл итү юлларын билгеләргә һәм иртәгәдән үк эшкә керешергә кирәк иде. Фәһимә үзенең өстенә тау кадәр авыр йөк килеп утырганын тойды. Менә, дип уйлады ул, гамьсез яшәсәң, тормышның һәр борылышына, һәр мизгеленә сизгер карамасаң, упкын төбенә очуың да ерак йөрми. Ул төне буе шул турыда баш ватты.

Керфек тә какмый үткәргән бу төннең таңын ул борчулы, үз алдына әле тулысынча билгеле булмаган олы бурычлар куючы, аларны тормышка ашырырлык көч табарга тырышучы, элекке Фәһимәгә караганда тормышка икенчерәк күз белән карауччы кеше булып каршылады. Тәрәзә пәрдәләрен алсу нур белән өреткән бу таң аның тормышында хәлиткеч борылыш ясарга тиешле таң иде... Ул беркемгә дә әйтергә ярамый торган олы карар кабул итте. Аны тормышка ашырган сурәттә Әхнәфнең башы да, йөрәге дә, аяк-куллары да Фәһимәнеке булачак иде...

## 4

Сөембикә биючеләрнең республика смотрында быел беренчелекне алабыз дигән уй белән ашкынып яшәде. Чөнки болынкырлылар гомер-гомергә бию белән дан казансалар, соңгы вакытларда районлагы күп кенә талантлы яшьләрне табып, сәхнәгә тарта алдылар. Турлап-турлап оештырылган зона ярышларында иләнгәннән соң, Казанга узулары аның ышанычын тагын да ныгытты. Тик киемнәрнең искелеге эчен тырнап торды. Яз көне мәдәният хезмәткәрләре алдында чыгыш ясаганда, Әхнәф, барысының да күзләренә карап: «Быел биючеләр ансамблен тулысынча яңа киемнәр белән тәэмин итәргә сүз бирәм», — дигән иде. Озын җәйләр дә үтте, инде көзләр дә онытылды, хәзер салкын кыш, ә киемнәр һаман юк. Казанда унсигез кешелек ансамбль өч төрле бию күрсәтергә әзерләнә, димәк, һәркайсына өч төрле кием кирәк. Әгәр бу атнада да акча бирелмәсә, киемнәрне өлгертеп тә булмаячак. Моның өчен әле Уфага барып заказ бирергә, ашыгыч тектерергә кирәк. Анда да чират, син килдеңмени дип көтеп тормыйлар. Барысы да, нидер өмет итеп, күзеңә карый. Шушы уйларына батып, Сөембикә хакимият башлыгының кабул итү бүлмәсендә инде ярты сәгатьтән артык утырды. Ниһаять, аңа да чират җитте. Ул, смотрга ничек әзерләнүләре турында сөйләгәннән соң, сүзне әлеге дә баягы киемнәргә күчерде. Әхнәф кәефсез иде, теше сызлаган кешедәй, ияген учлаган хәлдә Сөембикәне бүлдермичә тыңлап утырды, ул туктаганнан соң да шактый вакыт сүзсез калды. Аннары авыр итеп сулады да:

— Биргән вәгъдәм исемдә, тик берничек тә ярдәм итә алмыйм, — диде.

Сөембикә аңа зур өметләр белән кергән иде. Әхнәфнең уен белү белән, күңелен кимсенү тойгысы биләде, бит очлары кызышып чыкты. Әгәр хәзер ул берәр сүз әйтсә, һичшиксез, чәкәләшеп туктаячаклар иде. Шуңа күрә ул тешен кысып урыныннан торды.

— Ярый, аңладым, — диде дә ишеккә таба юнәлде.

— Туктале, Сөембикә!

Әхнәфнең шулай эндәшүе аның күңелендә өмет чаткысы уятты. Ул аның каршысына килде.

— Йөзеңнән күреп торам — үпкәләдең. Финанс хәлебез коточкыч кыен. Аңлый алмыйсыңмыни?

— Аңладым дидем ич...

Сөембикә кызу-кызу атлап чыгып китте. Ул мондый хәлнең килеп чыгу ихтималын алдан ук күздә тоткан иде. Алай-болай булса дип, Казандагы берничә культура сарае

җитәкчесе белән биючеләренә кием биреп тору мәсьәләсендә сөйләшеп тә куйган иде.

Казанга баргач, аңа әллә ни булды, кемнәндер үч аласы килде. Тора-бара ул моның сәбәбен аңлады: әнә бит күрше районнар нинди соклангыч киемнәр белән килгәннәр! Болынкырлыларда гына инде ун елдан артык кигән шул ук бер әйберләр. Туктале, дип уйлады ул эченнән, нигә әле мин Казаннан кием теләнеп, дөреслекне яшереп калдырырга тиеш? Күрсеннәр, белсеннәр, нәтиҗә ясасыннар. Бәлкем, мәдәнияткә кагылышлы башка мәсьәләләр дә җиңелрәк хәл ителер.

Аларның чыгышларын көчле алкышларга күмделәр. Болынкырлылар күршеләреннән шактый өстен торалар иде. Сөембикәнең татар кызлары биюен зал әсәренеп карады. Ахырда халыкның бердәм кул чабуы, тулы бер ритмга көйләнеп, бик озак яңгырап торды. Ул ике мәртәбә чыгып баш иде, алкышлар туктамагач, биюнең азагын тагын кабатлады. Аңа бер-бер артлы чәчәк бәйләмнәре күтәреп менделәр. Чәчәк сузучылар арасында ул Арслановны да күреп алды. Сөембикә сәхнә артына ашыкты, ә чәчәк күтәреп менүчеләр аның артыннан иярделәр. Ниһаять, алар берәм-берәм төшеп киттеләр, Арсланов үзе генә торып калды.

Ул искиткеч эре кызыл розаларны Сөембикәгә сузды. Сөембикә чәчәкләрне кулына тотарга да өлгермәде, Арсланов аны кочаклап күкрәгенә кысты һәм «Рәхмәт!» дип пышылдады. Сөембикәнең күкрәгенә роза чәчәгенең чәнечкесе кадалды. Ул авыртудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Аларга кызыксынып төбәлгән күзләр аның тәнен өттереп алгандай булды.

— Рәхмәтне аларга әйтегез, Миңзаһит Усманович, — дип, үзе белән килгән үзешчәннәргә таба атлады.

Арсланов аңа ияреп барды, үзе таныганнарының да, танымаганнарының да кулларын кысты, аннары, хакимият башлыгы урынбасары Зәйнуллин белән исәнләшеп, район хәлләрен сораштыра башлады. «Шактый бирешкән, сагына, күрәсең», — дип уйлады Сөембикә эченнән генә һәм аңа тагын бер карап куйды да киемнәрен алыштыру өчен бүлмәгә юнәлде. Шунда ул өч кенә адым ераклыкта кемнәргәдер чәчәк биреп маташкан Хәятны күреп алды. Аларның күзләре очрашты һәм Сөембикә түбәнчелек белән баш иде.

— Концертыгыз искиткеч булды. Рәхмәт, — диде Хәят, аның белән күрешеп.

Ул арада Арсланов алар янына килеп басты.

— Безнең янга буфетка керегез, — диде Сөембикә, нишләптер битенең ут яна башлавын тоеп, һәм ул йөгереп китеп барды.

— Әйдә, кереп чыгыйк. Зәйнуллин да чакырган иде бит.
Миңзаһитның бу сүзләренә Хәят усал караш белән җавап бирде:
— Безгә шунда керү килешер дип уйлыйсыңмы?
— Килешәме-юкмы, ярыймы-ярамыймы, — Миңзаһит кулын селтәп куйды, — туйдым мин ул үлчәмнәрдән! Гомерем буе һәр адымны бизмәнгә салып яшәдем. Минем керәсем килә. Бетте-китте, вәссәләм!
— Ярый, мин берни дә әйтмим. Үз вакытың белән кайтырсың. Әллә нишләп күкрәгем кыса.
Миңзаһит бераз уйлап торды да:
— Кайтып киттек алайса. Минем анда үзем генә керүемне дөрес аңламаслар, — диде.
Алар кышкы Казан урамыннан ашыкмыйча гына култыклашып кайттылар. Артык салкын булмаган ап-ак шәһәр төне иде бу. Миңзаһитның Болынкырдан килеп Казан урамнарында кем белән дә булса парлашып йөргән чаклары хәтеренә төште. Менә алар кайтып җиттеләр, ишекне Миңзаһит ачты, һәм алдан, гадәттәгечә, Хәят кереп китте. Ул бусаганы атларга өлгерә алмады, авызын ачып туктап калды. Кухня ягында чырык-чырык көлгән исерек хатын-кыз тавышы ишетелде. Башын сузып кухняга карауга, ул егылып китә язды: бөтен киемнәрен салып ташлаган Рашат, анадан тума бер хатынның башын беләгенә салып, имиен имеп утыра иде. Хәят ничек чыгып йөгергәнен дә сизмәде.
Миңзаһит, аптырап:
— Нәрсә бар? — диде.
Хәят ингаляторын чыгарып авызына дару сиптерә башлады, Миңзаһитның соравына «кереп кара» дигән мәгънәдә кулы белән ишарәләде. Миңзаһит кереп аларны күргәч:
— Что это такое?! — дип кычкырып җибәрде.
Рашат урыныннан сикереп торды һәм аны дауздырыбрак җикерергә кереште:
— Ты чего, не видишь что ли?! Перед тобой женщина. Совсем стыд потерял!
Ул әтисен этеп җибәрде, Миңзаһит сүгенеп идәнгә төкерде һәм, күзләрендә ут уйнатып, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Хәят тавышсыз гына елый иде.
Алар бер-берсенә карамыйча, йөзләрен кая яшерергә белмичә, шактый гомер ишек төбендә тордылар. Ниһаять, эчтә дөбердәгән тавышлар ишетелде, келәләр, йозаклар шылтшылт килде, һәм тимер ишек ачылып китте. Сары чәчләре тузгыган, башлыгын кулына тоткан хатын аларга бәрелә язып үтте дә, култыксага тотынып, чайкала-чайкала баскычтан төшә башлады. Рашат та килеп чыкты. Аның чалыш-чолыш китереп ялгыш эләктерелгән күлмәге чалбарына да кыс-

тырылмаган, пальтосы ачылган, кышын-җәен кия торган күн фуражкасы баш түбәсенең бер як читендә генә эләгеп тора иде.

Ул:

— Постой, паскуда! Разобьешся еще, за тебя буду отвечать! — дип кычкыра-кычкыра, марҗасына иярде.

Миңзаһит белән Хәят тавыш-тынсыз чишенделәр дә, кухняга чыгып, хәйран калып, өстәлгә төбәлделәр. Анда чәлпәрәмә килгән чынаяк ватыклары ауный, идәндә ике буш шешә утыра. Ашый башлап ташланган тозлы балык кисәге эскәтергә ябышкан, аның янында ук кетчуп шешәсе авып, эчендәге томаты кып-кызыл булып өстәлгә җәелгән, агып төшеп, идән келәменә сеңгән. Бөтен җирдә тәмәке төпчекләре ауный. Табада яртылаш күмергә әйләнгән колбаса калдыкларыннан чыккан ис, тәмәке төтене белән кушылып, тынны буа. Алар, сүз берләшкәндәй, берсе — ишекне, икенчесе балкон тәрәзәсен ачып җибәрделәр. Үтәли җил өйдәге укшыткыч исне коридорга суыра башлады. Миңзаһит, салкынлыкны да сизмичә, балкон култыксасына таянып, урамны күзәтергә тотынды.

Рашат белән тарткалашып маташучы теге хатын карга барып төште, көч-хәл белән торып аягына басты. Алар нәрсәгәдер талашалар иде, күрәсең. Бер-берсенә йодрыкларын селти-селти, алар почмакка борылып юк булдылар. Миңзаһит туңудан калтыранып куйды, өйгә кереп, балкон тәрәзәсен дә, ишекне дә япты. Кухняны җыештырып маташучы Хәят янына чыкмас өчен, үзләре бүлмәсенә керде. Дөпелдәп диванга утырды да күзләрен йомды. Әгәр банкетка калган булсак, бу мәхшәрне күргәнче, рәхәтләнеп утырган булыр идек, дип үкенде ул эченнән. Рашат алар өчен чын афәткә әйләнде. Ул инде аларның баласы да түгел, читтән килгән явыз рэкетчы кебек иде. Берничә урынга эшкә урнаштырып караса да, аны бик тиз куып чыгардылар. Кайда торуын аңламалы түгел иде: әллә һавада, әллә җирдә, әллә Мәскәүдә, әллә Казанда — моны бер Алла гына белә. Ул айлар буе югалып тора да кабат кайтып керә, беркая чыкмыйча, кырынмыйча эчеп ята. Аңа туктаусыз ниндидер кешеләр шылтырата, ул тагын чыгып югала, кесәсен акча белән тутырып, тагын кайтып керә. Рашат инде күптән Хәят белән Миңзаһитка бала түгел, ул үз-үзен бу хокуктан мәхрүм итте, аларга каршы көрәшүче, аларны җәберләүче явыз көчкә әверелде. Аңа баштарак өйнең ачкычын бирмәделәр, әмма бервакыт эштән кайтуларына йозакларын ватып кергәч, моның котылу юлы түгеллеген аңладылар. Ачкычларны Миңзаһит үзе күбәйтеп алып кайтты, үз куллары белән аңа бирде. Алар аңардан бары бер генә нәрсә — ишекләрен бикләп

йөрүен генә үтенделәр. Шуңа да карамастан аның ике ишекне дә шыр ачык калдырган чаклары күп булды. Исерек вакытта аңа диңгез тубыктан, ул гыйфриткә әверелә.

Хәятның эндәшкән тавышына ул залга чыкты. Хәят залның уртасында басып тора, бөтен гәүдәсе калтырый иде. Нәрсәдер тоткан кулын ул Миңзаһитка таба сузды да, елау катыш тавыш белән:

— Юри генә карале... — диде.

Миңзаһит, берни дә аңламыйча, аның кулыннан паспорт һәм тагын ниндидер кәгазьләр алды. Паспортны ачып җибәргәч, башы әйләнеп китте. Анда Рашатның фоторәсеме, өстенә «Боголюбов Иван Степанович» дигән сүзләр язылган иде. Калган өлешен ул укып тормады, паспорт эчендәге язулардан нибары аның Мәскәүгә теркәлгәнлеген генә аңлады. Димәк, аларның улы Боголюбов Иванга әйләнгән. Ул сораулы карашын Хәятка юнәлтте һәм аның газаплы, куркыныч карашына тап булды.

— Кара, тегесен кара...

Миңзаһит, дүрткә бөкләнгән теге кәгазьне ачкач, егылып китә язды. Бу— Рашатка ниндидер мәчетнең имам-мөхтәсибе булуын раслап бирелгән шаһәдәтнамә иде. Алар, ят бер дөньяга эләккәндәй, аптырашып басып тордылар. Шул ук вакытта икесе дә ул дөньяны нәкъ менә үзләре тудырганны аңлыйлар, аны кабул да итә алмыйлар, аңардан котылу да юк, шуннан чыга алмыйча һәлак булачаклары да көн кебек иде.

Кинәт шалтырап ишек ачылды. Рашат киемнәрен әллә нинди исерек, чайкалулы хәрәкәтләр белән салып элде, ботинкаларын селтәп ишеккә таба очырды да бүлмәсенә атлады.

Шулчак Хәят әллә нинди тавыш белән аңа кычкырып җибәрде:

— Кил!

Рашат, йөзен бөтенләй аңламаслык чалшайтып, аның каршына килеп басты.

— Бу ни бу?! — дип, Хәят аның борын төбендә паспорт белән шаһәдәтнамәне селкергә тотынды.

Рашат айнып киткәндәй булды. Ул күз ачып йомганчы әнисе кулыннан документларны тартып алды да, аңа таба ияген чыгарып, йөзен якын ук китерде.

— Син нәрсә?! — диде ул, әнисенең борынына укшытырлык исле һава өреп. — Ник син минем кесәне актарасың?!

— Синең пычрак кесәңә керәсем калган! Оятсыз! Аяк астына чәчеп киткәнсең.

— Чәчсәм, кагылма!

— Кагылмам менә! Урыс та, мулла да булдыңмыни?! Тагын ничә төрле ялган документың бар?!

— Ничәү кирәк— шулкадәр бар. Сезнең катышыгыз юк!

Сыгыла-бөгелә атлап, ул үзенең бүлмәсенә юнәлде.

Хәят, тагын куркыныч тавыш белән кычкырып, аны туктатты:

— Әгәр ялган документлар белән җинаять юлында йөрисең икән, сиңа бу квартирада урын булмаячак!

— Нәрсә?! Куасызмыни?!

Рашатның авызы ямьсез булып ачылды, ул әнисенең әйткәннәрен зиһене белән бәяләргә азаплана иде.

— Син квартираны нинди хәлгә китергәнеңне кара! — диде Миңзаһит, кухня ягына кулын селтәп. — Хатын-кыз алып кайтып, шәрә килеш йөрергә оят түгелме?!

— Ә син ояла идеңме соң, Арсланов? Авылда чакта өйгә сөяркәләреңне алып кайтырга ояла идеңме?

— Тукта хәзер үк! — дип кычкырды Миңзаһит.

— Да пош-шел ты!

Рашат, саз каены шикелле чайкала-чайкала, бүлмәсенә кереп китте, эчтән ишеген бикләп куйганы ишетелде.

— Барысы да синең аркада, — диде Хәят, елый-елый. — Әнә бит әйтеп тора. Читтә генә сөйрәлүең җитмәгән, өйгә дә алып кайткансың. Гарьлегеңнән үләрсең!

— Шул исерекнең сүзләренә ышандыңмы?

— Ул сиңа караганда дөресрәк сөйли. Тфү! Бу шөпшә оясын син оештырдың. Үлмичә котыла алмам мин сездән.

Хәят ярсыганнан-ярсый барды, аннары, йокы бүлмәсенә кереп, урынына ауды.

## 5

Сөембикә, бәби итәкле алсу күлмәген, укалы зәңгәр камзулын кигән килеш, калфак өстеннән ябынган чигүле яулыгын җилфердәтеп, фойеның әле бер ягына, әле икенче ягына йөгерде. Аны котладылар, һичшиксез, беренче урын сезнең ансамбльгә тиеш, дип дәртләндерделәр. Казандагы танышлары, күрше районнардан килгән коллегалары аны кочтылар, үптеләр, шул ук сүзләр белән күңелен җылыттылар. Әмма жюриның аларга өченче урын бирүе Сөембикәнең башына күсәк белән суккан кебек итте. Тамашачылар да канәгатьсезлек белдереп шаулашырга керештеләр.

Жюри председателе, ике кулын күтәреп, тамашачыларны тынычландырды да:

— Үзешчәннәрнең осталыгы турында бәхәскә урын юк, — диде. — Әмма киемнәр мәсьәләсендә бер генә уңай сүз дә әйтеп булмый. Нәкъ шуның аркасында болынкырлылар күп балл югалттылар һәм өченче урынга төшеп калдылар.

Сөембикә күз яшьләренә буылып сәхнә артына чыкканда, аны уртача гәүдәле бер ир кеше туктатты. Ул үзен редактор урынбасары дип таныштырды. Сөембикә шулкадәр дулкынланган, күңеле шулкадәр үртәлгән иде, бу кешенең кайсы газетадан икәнен дә, исем-фамилиясен дә хәтерендә калдыра алмады.

— Сез Ирек Сабитовның хатыны буласыз, ахрысы? — дигәч кенә, аңа ныклап игътибар итте.

— Мин аның якын дусты Әхмәт. Бәлкем, ишеткәнегез бардыр? Шагыйрь.

— Әйе, Ирекнең сөйләгәне бар иде.

— Миңа чыгышыгыз искиткеч ошады. Газетага сезнең интервьюны бирергә иде.

— Мин моның кирәген күрмим, — диде Сөембикә. — Жюри алай димәде бит.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул. Мин сезне озак тоткарламам.

Әхмәт, кесәсеннән диктофон алып, Сөембикәгә якын китерде.

— Сезнең чыгышыгыз бүтән районнарныкы белән чагыштырганда иң яхшысы булды. Әмма жюриның карары безне бераз гаҗәпләндерде. Сез шуны аңлатып китә алмассызмы?

Сөембикә, смотрның шартлары турында сөйләп, сәхнә киеме мәсьәләсенә җентекләп тукталды.

Инде сүзне бетерәм дигәндә, Әхмәт:

— Үзешчәннәрне шушы кадәр әзерләгәч, нигә соң киемнәр мәсьәләсенә битараф калдыгыз? — диде.

Аның шулай әйтүе Сөембикәнең йөрәгенә килеп кадалды. Ул ярсып бу нәрсәне хәл итүнең үзеннән тормавын, акчага бәйле икәнен, ә акчаның хакимият кулында биек агач башындагы алма кебек кызыктырып торуын сөйләп китте. Аның инде буасы ерылган иде, ул клуб-китапханәләрнең шактый еллар бернинди ремонт күрмәве, культура учакларында спорт инвентарьларының, инструментларның юк дәрәҗәдә булуы, штатлар кыскартылуы турында сөйләде, тагын күп кенә тәнкыйть сүзләре әйтте. Әхмәт соңыннан Ирекнең тормышы белән кызыксынырга тотынды. Кайда эшли, язамы, пьесалары чыгамы дигән кебек күптөрле сораулар белән күмеп ташлады. Сөембикә аңа, без бергә яшәмибез, дип әйтә алмады, «әйе», «юк» дигән кебегрәк җаваплар белән котылды. Әхмәт, яңа квартира алдым, диде, әгәр Ирек Казанга килсә, берүк туп-туры безгә төшсен, диде, адресын бирде, язган әйберләрен җибәрергә кушты.

Сөембикә, инде аннан аерылып китим генә дигәндә, үзенә таба туп-туры килүче кешегә игътибар итте. Ул кеше Сөембикә интервью бирә башлаганда ук почмактарак аннан күзен

алмыйча карап тора иде. Башта ул аны Әхмәтне көтеп торучыдыр дип уйлады, ә хәзер үзенә туп-туры килүен күргәч, ялгышканлыгын аңлады. Менә ул аның каршына ук килеп җитте, авызының бер як чите белән генә сизелер-сизелмәс елмаеп, җиңелчә генә баш иде дә:

— Исәнмесез, — диде.

— Исәнмесез...

Уртачадан озынрак төз гәүдәле, илле яшьләрдәге бу кешенең затлы туны һәм бүреге нindидер түрә булырга тиеш дигән уй тудыра иде. Йөзе бөтенләй җыерчыксыз диярлек, төз борыны астында юка гына булып матур кара мыегы сызылган, алга чыгып торучы киң ияге аның тормышта ныклы адымнар белән атлый торган, зур ихтыяр көченә ия булуы турында сөйли. Кояшта янган йөзе әле генә көньякта кызынып кайткандыр бу дигән гөман уята. Сөембикәгә ул кемнедер хәтерләткәндәй тоелды, ләкин бүгенге дулкынланулардан соң, мөмкин булган барлык кичерешләрне дә күңеленнән уздырганнан соң, ул бу кешенең кем икәнлеген тәгаен генә хәтерләрлек хәлдә түгел иде.

— Сез мине, әлбәттә, танымыйсыз...

Ир кешенең тигез, шикәрдәй ак тешләре күренеп алды. Шунда Сөембикә аның уң як тешенең бераз китек икәнен абайлады. Аның күз алдында нindидер сурәт пәйда булды һәм, ни гаҗәп, ул сурәт кайдадыр еракта, зәңгәр өрфия белән өретелгән еллар артында шикелле дә, шул ук вакытта бик якын да кебек тоелды.

— Сез миңа кайчандыр салкын су чәчрәткән идегез, колонкадан...

Сөембикә кычкырып көлеп җибәрде:

— Әстәгъфирулла! Аннан соң бит инде йөз ел үткән!

— Үткән, ләкин онытылмаган, Сөембикә...

— Мин инде аның елын да хәтерләмим.

— Аның хәзер әһәмияте юк. Менә мин сезне һич уйламаганда очрату бәхетенә ирештем. Биюегезне карап таң калдым. Ике генә авыз сүз булса да әйтәсем, күзләрегезгә якыннан карыйсым килде.

— Рәхмәт, Айдар, — диде Сөембикә.

— Менә бит! Сез дә мине онытмагансыз! — диде ул, куанычын яшерә алмыйча. — Беләсезме, Сөембикә, мин бит Татарстанга бөтенләйгә кайттым, Молдавия җирләрен ташлап. Хәер, мин дөрес башламадым. — Ул кулын селтәп куйды да, әллә тиешле сүзләрен эзләп, әллә болай гына уйланып калды.

Сөембикә, үзен көтеп торуларын белсә дә, аңардан аерыла алмады, күңеле белән шул сихри төн хатирәләренә уралды.

Айдарның ягымлы тавышы аның хыялый сәфәрен бүлде:

— Нишләптер мин сезне әледән-әле хәтергә төшердем.

Татарстан җиренә кайтырга уйлаган саен, күз алдыма сез килә идегез. Туган җир тарта икән. Өй сатып алып, каядыр төпләнәсем килә.

Сөембикә, «Сез боларны миңа нигә сөйлисез?» дигәндәй, аңа мөлдерәтеп карап куйды.

— Бәлкем, сезнең якларда өй сатучылар бардыр?

— Кызыксынганым юк, — диде Сөембикә, коры гына.

— Әгәр районыгызга барып чыксам? Үзе яшәгән җиргә Болынкыр дип исем кушкан халыкның күңеле гаҗәп матурдыр сыман тоела миңа. Барыйммы соң?

— Мин сезне тыя алмыйм, ни өчен миннән рөхсәт сорыйсыз?

Айдар тыенкы гына көлеп куйды.

— Әйдәгез, икебез шушы сорауга җавап табыйк. Чынлап та, нишләп мин сездән рөхсәт сорыйм икән?

— Белмим... — диде Сөембикә, дулкынлана башлавын тоеп.

— Мин дә белмим шул. Әгәр анда баргач, сезнең янга керсәм... киңәш сорарга, куып чыгармассызмы?

— Минем ирем бик көнче, — диде Сөембикә, алдашып.

— Сезгә алдашу килешми, Сөембикә. Мин барысын да беләм...

— Гафу итегез, миңа китәргә вакыт.

Сөембикә шулай диде дә башын игән хәлдә китеп барды.

Юлда кайтканда, аның уйлары гел Айдар тирәсендә бөтерелде. Сөембикә аны онытырга теләп күзләрен йомды, ләкин, үч иткәндәй, ул тагын да ачыграк булып күз алдына килде һәм беркемне дә кабатламый торган сөйкемле елмаюы белән аның йөрәген кузгатты...

## 6

Ирекка шатланырга, беркем шатлана алмаганча шатланырга кирәк иде. Ниһаять, бүген өй туе! Инде бер ай Зәнфирә төн йокламый шуңа әзерләнә. Өйне, веранданы сабынлап юып чыкты, тәрәзәләренә өр-яңа пәрдәләр элде, кредитка алып, һәр бүлмәгә люстра куйдырды, ишегалдына гөлт итеп янучы лампочкалар чыгартты. Ә Ирекнең күңеле, ерткыч сагалавын сизгән җәнлектәй, үзенә урын тапмады. Яза торган романы әллә кайчан туктап калды, театрдан төзәтергә алып кайткан пьесасының өстенә инде тузан кунды. Әйтерсең аның тормыш арбасы олы юлдан чыгып каядыр салулады. Кеше хакына кермәде, кеше өстенә басып, бу өйне салдырмады, инде югыйсә авылда ялгызы яшәп ятучы әнисен алып килергә тулы мөмкинлекләр туды. Ләкин аның шушы бәләкәй, тәбәнәк иске өйдән һич кенә дә чыгасы килмәде.

Бүген ул әлеге уйларын онытырга тырышты. Килгән ку-

накларны елмаеп-көлеп каршы алды, кулларын кысты, кайсылары белән кочаклашып күреште, бәхете ташып чыккан кеше ролен уйнады, әмма үзе бөтенләй башка дөньяда йөзде. Әйтерсең лә ул бербөтен түгел, берничә кисәккә бүлгәләнгән ниндидер бер зат, шушы көнне ниндидер вак мәшәкатьләрне төп-төгәл үтәргә тиешле машина иде. Авырып торганлыктан, әнисенең бүгенге мәҗлестә катнаша алмавы да аның кәефен кырды. Кунаклар алып килгән күпсанлы бүләкләр дә аңа әллә ни тәэсир итмәде. Мэлс абыйсы белән Нәфисә, үзегез ни телисез, шуны алырсыз, дип, аларның кулына калын гына конверт тоттырдылар. Әхнәф белән Фәһимәнең өр-яңа стенка һәм китап шкафы бүләк итүләрен ул башына сыйдыра алмады. Алар әле генә кибеттән алынганнар, калын кәгазьләргә, катыргыларга төрелгәннәр, күтәргесез авыр иделәр. Машинага төяп килгән егетләр барысын да верандага кертеп өйделәр. Кешеләр җыелып беткәч, өй туен Мэлс абыйсы ачып җибәрде. Әхнәфкә, район больницасының баш врачына, өйне салган төзелеш оешмасына рәхмәт әйтте, шарт-шорт китереп шампан шәраблары ачылды, рюмка-бокаллар эчемлек белән тулды. Рюмкасына шифалы су салган Ирек, уртадагы буш урыннан әле түргә, әле як-якка барып, кунаклар белән чәкештерде, аларны ашарга-эчәргә кыстады. Мәҗлес кызганнан-кызды. Беренче тәнәфес җиткәндә, кунакларның телләре тәмам ачылып бетте, күңелле итеп баян уйный башлады, һәм бердәм күтәрелеп җырларга керештеләр. Ирек кенә һаман каршылыклы кичерешләрдән арына алмады, туктаусыз эче янды. Әйтерсең лә бөтенесе җырлашып-гөрләшеп ниндидер бәхет тавына күтәрелеп баралар, ә ул берүзе каядыр түбәнгә оча, берничек тә төшеп җитә алмый, алардан аерыла да алмый иде.

Икенче тәнәфестә инде кунаклар арасында шактый гына йомшаганнары күренде. Гадәт буенча, бер почмакта җырлыйлар, уртада бииләр, танцы итәләр, төркем-төркем сөйләшәләр, ирләр, туктаусыз чыгып, тәмәке тартып керәләр. Кыскасы, бөтенесе хәрәкәттә, дәртләндергеч бер көйгә буйсынып, бәхет-сәгадәт дулкынында йөзәләр. Читтәрәк басып торган Ирек янына Әхнәф килде һәм аның иңбашына кулын салды.

— Йә, дустым, син канәгатьме? — диде ул, Ирекне күкрәгенә кысып.

Әхнәфнең күкрәге дә, кулы да ут кебек кайнар иде.

— Канәгать булмыйча... — диде Ирек, елмаерга тырышып.

— Юк, син нишләптер бик күңелсез, авырмыйсыңдыр бит?

Ирек Әхнәфнең күзләренә туп-туры карап баш чайкады, әмма елмая алмады.

— Бүген син минем белән бергәләп бер генә йотым булса да тотып куярсың дип уйлаган идем.

Аның бу сүзләре гүя Ирекнең эчендә ничә еллар бөяләп торган, аны борчыган буаны ерып җибәрделәр! Ул ерылган урыннан гаҗәп тә таныш, ләззәтле чакыру аның башын әйләндерергә тотынды. Әхнәфкә буйсынып, ул караңгырак почмакка атлады, алар килеп утырдылар. Менә дусты, ике буш рюмка алып, аларга коньяк салды. Ирек бөтен гәүдәсенең шатлык һәм курку ялкыны белән тулуын тойды, тагын әллә нәрсәләр бөтенесе бергә болганды, ул шушы дулкын эчендә чайкала башлады. Ул акрын гына кулына рюмкасын алды.

— Яңа өйнең бәрәкәте, синең иҗат уңышларың өчен! — диде Әхнәф, рюмкаларны чәкештереп.

Ирекне баягы дулкын тагын да ләззәтлерәк итеп серле биеклеккә күтәрә башлады. Шушы зәһәр эчемлекне йотуга, ул янәшәсендәге бәхетле кешеләр белән бер дөньяга кушылачагын, алар кебек үк, шатлык эчендә кайнарга керешәчәген күз алдына китерде. Бу искиткеч кызыктыргыч, искиткеч ләззәтле һәм бик тә, бик тә якын иде! Ул инде эчемлекнең барлык тамырлары буйлап бөтен гәүдәсенә кайнар булып таралуын тойды, тәненең рәхәт кымырҗуын, мәлҗерәвен хыялы белән ап-ачык сизде. Хыялны чын итү өчен нибары бер хәрәкәт ясыйсы... Әхнәф шуңа әйдәде, аның сүзләренә карышу мөмкин түгел иде. Ирек рюмкасын күтәреп иреннәренә тәрәде... Шунда рюмкасын, көч-хәл белән иреннәреннән аерып, өстәлгә куйды.

— Гафу ит, күңелем болганып китте, — диде ул, калтыранып. — Бераз һава сулыйм әле...

— Мин дә синең белән чыгам.

— Юк, юк, Әхнәф. Зинһар, иярмә, миңа үземә генә булырга кирәк...

Ул бүреген, пальтосын, олтанлы итеген ашыгып киде дә, кунакларны ерып, абзарга таба китте. Бакча капкасын ачып, көрт ера-ера караңгы почмактагы балан куагы янына китте. Аның җыелып бетмәгән тәлгәшләренә кар мамыгы яткан. Ирек бер ботакны иде дә, тәлгәшләрне өзеп тә тормастан, иреннәре белән үрелеп, бозга әверелгән баланны карларыние белән шатыр-шотыр чәйнәргә кереште. Балан әчесе ботен авызына таралды. Кинәт бер тешенә, өнне алырлык сызлатып, салкын йөгерде. Әмма күңелендәге сызлау аннан көчлерәк иде, шуны басар өчен ул комсызланып әле бер, әле икенче тәлгәшкә үрелде... Калтыранган куллары белән балан ботагына ябышкан килеш, үз-үзенә тавышсыз гына җикерергә кереште: бар, тизрәк кер дә эчеп җибәр! Тик шуны бел: син аны эчсәң, элекке кебек аракы дингезенә төшәчәк-

сең! Ничә еллар буе корган шул афәттән аеручы диварны җимер әйдә! Ишетәсеңме, сине җырлый-җырлый чакыралар! Кешеләр түгел, сиңа дип салынган агу җырлый. Бу дөньядагы иң якын дустың Әхнәф үзе чакыра! Бар, кер, эч тизрәк! Якты дөньядан гүр кадерлерәк икән — тизрәк эч!

Ирекнең тәненә салкын тир бәреп чыкты. Күзгә күренми торган упкын якында гына, мөлдерәп аны чакыра... Ул өйгә бер адым атлады да кире чигенде. Үзенә булган ышанычы әллә кая китеп югалды, йөрәге Әхнәф чакыруына алгысудан туктый алмады. «Зинһар, тыелырга көч бир!» — дип ялварды ул. Шул ук вакытта үз-үзенә рәхимсез сорауны бирде: син кеше булып кала алдыңмы? Бу сиңа соңгы сорау, соңгы сынау. Хәл ит: әгәр кала алмаган булсаң тыелма. Әгәр аракы гомереңнән дә кадерлерәк икән, бу якты дөньяны, газиз әниеңне, Айгөл белән Зәнфирәне, туганнарыңны, дусларыңны корбан ит шуңа. Әгәр ул шушы яшеңә кадәр җир йөзендә ниләрдер эшләвеңнән дә олырак, мөһимрәк, мәгънәлерәк икән— эч аны! Әле тагын бик озак елларга дип бирелгән тормыш китабыңның укып бетермәгән килеш соңгы битен ябып куй. Әмма, һич югы, бу гамәлең кешечә булсын, һәрбарчасы белән бәхилләш. Ачы җимешләрен ашаткан бу балан куагы белән бәхилләш. Күктә җем-җем итүче әнә ул йолдызлар белән бәхилләш. Өй котларга җыелган кунаклар белән бәхилләш. Дөнья белән бәхилләш!

Әгәр син җиңәргә сәләтсез мескен икәнсең— җиңел! Үзләрен җиңәргә сәләтлеләр, бу дөньяның ямен-тәмен татып, бәхет диңгезләрендә йөзеп, йөзгә кадәр яшәсеннәр! Ә синең урының җир өстендә түгел, аның салкын балчыгы астында...

«Көч бир!» — диде ул тагын һәм шундук, котырып, үзенәүзе каршы төште. Кем сиңа көч бирсен?! Көч синең үзеңдә генә. Читтән ярдәм беркемгә дә юк ул. Бөтенесе үз ихтыярыңда. Нәрсә туктап калдың, дип, үз-үзен төрткәләгәндәй ачуланды тагын. Бар, кер, эч! Миллиард еллар аша бүләк итеп бирелгән гомереңне, яшәү ямен бер йотым агуга корбан ит! Кулыңдагы рюмкаң— ул синең казылган каберең! Тизрәк кер кабереңә, ашык! Гомер касәң дә үз кулыңда. Кайсын сайлыйсың — шунысын эчәсең. Беренчесен эчсәң, бөтенесе бик тиз хәл ителәчәк. Ә икенчесен эчү бик озак елларга сузылган яшәү ләззәте бирәчәк. Беренчесе гомереңне коточкыч газаплар, хурлык белән өзәчәк. Якыннарың, сине белгән кешеләр үлүеңнән соң да сиңа ләгънәт укыячаклар, исемеңне җирәнеп әйтәчәкләр, Айгөлең, оныкларың телгә алырга да хурланачак.

Күз ачып йомган арада ничек бөтен вөҗүде үзгәрде соң аның?! Бөтен хикмәт Әхнәфтә. Барлык дуслары: «Аның кыставына түзеп булмый», — ди торганнар иде, һәм бу чын-

нан да шулай. Аңарда кешене буйсындыручы, сындыручы ниндидер көч бар. Димәк, син гаепсез! Әйдә, буйсын алайса! Акланырга бик әйбәт сәбәп. Шуңа ышыкланып куркыныч үткәнеңә юнәлергә әзер бит син. Сагынган булсаң, әнә генә ул миңгерәүлек томаны эчендәге көннәрең. Иренмичә бер хәрәкәт ясасаң, шунда очасың. Әнә генә ул нурсыз, караңгы бушлык. Бүтән берни дә юк. Шул бушлык эчендә ярым мәет хәлендәге хәлсез гәүдә йөрәк белән бергә «сүнәм, сүнәм» дип калтырап тора. Әгәр шуны сагынсаң — эч! Рюмкаңны Җир шарыннан да олырак, бу якты дөньядан да кадерлерәк дип санасаң, атла упкынга. Ләкин әүвәл һәр икесен дә бизмәнгә сал, кайсы басканын ныклап кара, алдатма! Алдатсаң, кире кайту юк, соң булачак! Шул бизмәнгә әниеңне дә, Айгөл белән Зәнфирәне дә, абыйларыңны да сал.

Ниһаять, Ирекнең уйлары төгәл калыпка керә башлады. Вөҗүденең кайсыдыр почмагыннан сабырлык күтәрелүе сизелде. Ул арада ихтыяр көче хәбәр салды: кеше ниндидер түбән йогынтыларга бирешергә түгел, һәр көн аз-азлап кына булса да үзен җиңә барырга тиеш. Акрын-акрын югарыга хәрәкәтләнмәсәң, түбәнгә тәгәрисең, упкынга очасың. Икеләнү, көчсезлек томаны аша өмет чаткысы сирпелеп алгандай булды, аның үз-үзенә ышанычы кабат күңеленә иңде. Тормышның кызыктыргыч дәвамы үзенә чакырды...

Ул кергәндә, кунаклар җырлыйлар иде. Урынына барып утыру белән, Ирек аларга кушылды, дөньясын онытып җырларга тотынды. Аның тавышында яшьтән үк үзенә генә хас моң бар иде, ул моң күңеленнән шундый булып бәреп чыкты ки, барлык йөзләр аңа таба борылдылар һәм үзләрен каршылаган томса чырайлы Ирек урынында күзләре очкынланып янучы, йөзе яктырган, яшәргән кешене күрделәр. Ирек аларның үзенә ни өчен карауларын да, ни уйлауларын да бик яхшы аңлады. Өченче тәнәфестә ул биергә чыкты да Зәнфирәгә басты, алар парлашып очына-очына биеделәр, кунаклар арасында кул чапмаган, аларга сокланмаган беркем дә калмады.

— Әллә сине җен алыштырып кертте инде, — диде Әхнәф, аның янына килеп. — Болай матур итеп җырлаганыңны да, биегәнеңне дә күргәнем юк иде. Яңа йортка яңа сыйфатларыңны күрсәтеп керәсең син, молодец!

Дусты рюмка сузды, Ирек «юк!» дип баш чайкады.

— Аннан ерак торганда гына кеше мин, — диде ул. — Борыныма исе керсә дә, дөньяның асты өскә килә...

Әхнәф аны бүтән кыстамады. Мәҗлес төнге икегә кадәр дәвам итте. Кунакларны озатып бетергәч, Ирек йөгерә-йөгерә Зәнфирәгә өстәлләрне җыештырырга, табак-савытларны юарга булышты. Алар сәгать дүртенче киткәч кенә йокларга

яттылар. Күрәсең, арулары нык булгандыр, яктыргач кына уяндылар. Ирек күзләрен әйтеп бетергесез шатлык белән ачты, яшьлек җиңеллеге белән шундук сикереп тә торды. Ишегалдына чыгуга, эчендәге куанычы тагын да артты. Акрын гына ябалак-ябалак кар ява иде. Ирек кичәге упкын янына кабат беркайчан да бармаячагын аңлау шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Ул бирешмәде, ул җиңүче иде! Аның бүген җиңү көне. Бөтен җиһанны яңгыратып: «Саумы, бөек көн!» — дип кычкырасы килде. Кичә өй туе булса, ул бүген үзенең җиңү көнен бәйрәм итә. Әмма гомеренең яңа дәвергә чыгуын билгеләүче бу көнне ул беркемгә дә сиздермичә бәйрәм итәр. Хәер, әнә бит ак карлар сизгәннәр, аны котларга җиһан түреннән үк төшәләр. Аларның сафлыгы сабый бала сафлыгын хәтерләтә, алардан сабый бала исе килә...

Менә болдырда кочагына савыт-саба төягән Зәнфирә күренде. Ирек койма башыннан яңа яуган карны учлап капты да хатынын иреннәреннән үбеп алды.

— Ни булды сиңа?! — диде ул, гаҗәпләнү катыш елмаеп. — Савытларымны төшертеп җибәрә яздың...

— Мин сине карлы иреннәрем белән кайчан үпкән идем? Хәтерлисеңме?

Аның соравын көтеп кенә торгандай, Зәнфирә шундук җавап бирде:

— Яңа ел кичендә... Чыршылар каршында, кешеләр йөреп торган җирдә... Шул исемә төшсә, хәзер дә оялып куям.

— Ә син оялма, карчык! Яратуның ояты юк, — диде Ирек, акрын гына төшүче кар бөртекләренә учларын сузып. — Яңа елга туры килмәсә дә, без бүген яңа тормыш башлыйбыз.

— Әйе, яңа йортта башлыйбыз, — диде Зәнфирә, аның сүзен җөпләп һәм күршеләренә савыт-сабаларын кертә китте.

Үткән еллар офыгының кайтавазы рәвешендә яңгыраган бүгенге көн Ирек өчен иң мәгънәле, иң кадерле көн булырга тиеш иде. Ул аның бер генә секундын да бушка үткәрмәскә карар кылды. «Минем көнемне шулай ямьләгән өчен рәхмәт сезгә, ак карлар!» — диде ул күңеленнән. Нинди нурлы, нинди матур син, бүгенем! Минем тормышымда тагын бик күп, бик күп шушындый якты бүгеннәрем булачак әле! Мин аларны гомеремә һәйкәл булып калырлык итеп яшәячәкмен!

Ирек, кергән-чыккан кешеләрдән, телефон шылтырауларыннан качып, музейга барып бикләнде. Кәгазьләрен таратып, кулына ручкасын алуга, бу дөньядан аерылды. Аңа каяндыр шатлык нурлары коелды, илһам дигән тылсымлы көч ручкасын туктаусыз алга куалады, ак кәгазь битләренә

хис-кичерешләре, фикерләре ташып түгелде. Ул өйлә туры узганын да, караңгы төшкәнен дә сизмәде, романының иң зур бер кисәген төгәлләде. Моңа хәтта ышануы да кыен, элек бу кадәр әйберне язарга аңа бер ай вакыт кирәк булыр иде. Бу — аның тормышындагы Бөек көн биргән бүләк иде, чөнки ул үзе дә башка кеше иде.

Романдагы каһарманнарыннан аерылып, урамның йомшак карына басканда, аны йолдызлар җемелдәп каршы алды. Ирек сәгатенә дә карамады, чөнки моның бернинди әһәмияте дә юк иде. Ул очынып-дәртләнеп өенә юнәлде, үзе дә сизмәстән, авыз эченнән генә туктаусыз җырлады да җырлады. Юл буе аның өстенә күктән йолдызлар коелды, ә күңелендә яп-якты кояш балкыды. Үзенең күкрәгендә, кояш белән йолдызларны берләштереп, үткән еллар офыгы белән бүгенге көннең бәрелешүеннән туган кайтавазны тыңлыйтыңлый, Ирек киләчәгенә атлады...

## 7

Бүген мәдәният хезмәткәрләренең район семинары иде. Андый көнне авыл китапханәчеләре, культура йорты мөдирләре Сөембикә бүлмәсенә агылалар, акча сорыйлар, башка мәсьәләләр белән мөрәҗәгать итәләр. Бүген дә менә бер сәгать инде кеше агыла. Шунда аңа, шылтыратып, ашыгыч рәвештә Шәрифуллин үзенә чакыра, диделәр. Сөембикә ишек төбендә торучыларга көтәргә кушты да хакимияткә китте. Ул барып кергәндә, Әхнәф ялгызы гына кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Сөйләшүе бик сәер, ул тыңлыйтыңлый да «әйе», «ярар» дип куя, акланмакчы булып авыз ача, әмма теге кеше аңа сүз әйтергә ирек бирми иде, ахрысы. Ниһаять, ул трубкасын куйды да Сөембикәгә карады. Аның маңгаендагы калын җыерчыгы тагын да тирәнәйде, әле генә кечелекле кыяфәттәге йөзе кинәт үзгәреп, таштай катып калды.

— Мин синнән моны көтмәгән идем! — Әхнәф гаҗәпләнүен белдереп баш чайкап торды.

Сөембикә кыенсыну катыш курку белән аның күзләреннән сизенүен расларлык билгеләр эзләде. Ләкин алар аңа гомер булмаганча салкын, битараф карадылар.

— Син мине гаеплисең димме... — Сөембикәнең бөтен тәненә кайнарлык җәелә башлады. — Әйтеп бетер...

— Мин беркемне дә гаепләмим, — диде Әхнәф, җансыз, коры тавыш белән. Ул, башын иеп, өстәленең полировкасыннан үз шәүләсен карагандай дәвам итте. — Кеше белән гомер буе дус булып яшисең, еллар аерылмаслык итеп бергә бәйли. Ә ул тота да сиңа чокыр казый...

Сөембикәнең бит очлары уттай яна башлады, ул иңбашларын сикертеп куйды да:

— Моны миңа ник сөйләвеңне аңламыйм, — диде.

Әхнәфнең таштай хәрәкәтсез йөзеннән кинәт караңгы шәүлә йөгереп узды.

— Кыланма, бик яхшы аңлыйсың! Кылану — дөреслектән качу коралы. Син миңа корал күтәрмә инде, зинһар. — Әхнәф уң ягында өелеп торган газеталарның өстәгесен алды да, аны җәеп, кул сырты белән шапылдатып сукты. — Менә бусы да корал моның!

— Һаман да берни аңламыйм…

— Аңламагач ник кызардың соң? Әле күрергә өлгермәгәнсеңдер. Әнә укы, куан!

Әхнәф газетаны аның алдына ташлады. «Күз яшьләре катыш интервью» дип укыды Сөембикә, эре хәрефләр өстеннән күз йөгертеп.

— Мин бит, акча бирәм, дидем. Минем өскә кара якмыйча булмадымы?

Сөембикә үзе газетаны караштырды, үзе уйчан, үкенүле тавыш белән сөйли башлады:

— Безнең арада комсомолда эшләгән бер кеше бар иде. Бергә җыелган саен, шул, бездә тәнкыйть юк, дип ярсыр иде. Партия җитәкчеләре, үзләренә тел тигерүдән куркып, культка әверелеп беттеләр, ди иде ул кеше. Дөреслектән курку партиянең дә, илнең дә башына җитәчәк, ди иде. — Сөембикә, газетасын өстәлгә ташлап, Әхнәфнең күзләренә туп-туры төбәлде. — Ә хәзер? Кирәкмимени ул?

— Мине «тәнкыйтьне кыса» дип беркем дә әйтә алмас, — диде Әхнәф.

— Ә бу нәрсә соң?

— Бу аңлашу дип атала. — Әхнәфнең баягы салкын, битараф күз алмалары сикерешергә тотынды. — Икәүдән-икәү аңлашасы урында сиңа мине республика җитәкчелеге каршында пычратырга кирәк булган. Эзләсәң, җае киләчәктә дә чыгар. Мондый кешеләргә таяну— суга таяну белән бер икәнен беләм мин…

— Кем икәнемне аңлатуың өчен рәхмәт… — Сөембикәнең иреннәре елагандагы кебек тартышып куйды, ләкин ул күз яшьләрен тыеп кала алды. — Синең культура дигән гарип үги малаеңны караудан гарык мин! — Ул өстәлдә яткан чиста кәгазьләрнең берсен алды да, гариза язып, Әхнәфнең алдына атты. — Резолюцияңне сал да, син — миннән, мин синнән котылабыз.

— Син усалланма, Сөембикә! — диде Әхнәф, тамырлары бүртеп чыккан кулларына урын таба алмыйча. — Алайга китсә, мин сине чәйнәп ташлый алам бит!

Аның ачуы тавышына гына түгел, рәхимсез ялтыраучы күзләренә дә чыккан иде. Сөембикә аңа мәсхәрәле караш ташлады.

— Нык тигән бу синең үтеңә... Янаудан да курыкмыйсың.

— Курыксам, мин бу урында утырмас та идем.

— Кергәч тә шуннан башларга идең аны, — диде Сөембикә. — Арысланның муенын шартлатып өзгәнне, безнең кебек куяннар нәрсә сиңа... — Ул урыныннан торып басты. — Шулай да теләсә нәрсә чәйнәргә тырышма, тешеңә зарар килүе бар.

Сөембикәнең бу сүзләре Әхнәфнең соңгы сабырлыгын алды. Ул җилләнеп сикереп торды, уң кулы белән җайсыз хәрәкәт ясап, өстәлдәге газеталарны сыпырып төшерде һәм:

— Утыр! — дип кычкырды, шомлы тавыш белән.

Сөембикәнең аны беркайчан да мондый хәлендә күргәне юк иде. Шуңа күрә ул ничек урынына утырганын сизми дә калды.

— Белеп тор: гарип малайны аякка бастырмый торып, сиңа тынгы булмаячак! Әле эшлисең! — Әхнәф аның гаризасын шатыр-шотыр erткалады да, чүп савытына саласы урында, Сөембикәнең интервьюсы басылган газета өстенә атты. — Тик мин сиңа саграк кыланырга киңәш итәр идем. Сиңа карата булган элекке җылы тойгыларның бөртеге дә калмады минем...

— Минеке дә шулай. — Сөембикә торып басты. — Элекке дуслык хакына якын итеп кенә мин дә бер әйбер әйтим әле. Ялгыш якларга күп карап, чокырга туры килә күрмә...

Сөембикә, оста хатын-кыз булдыра алганча кыланып, юри салмак кына керт-керт атлап чыгып китте.

Семинар әйбәт кенә узды. Аннан чыгып үзенең бүлмәсенә юнәлгәндә, Сөембикә ишек янында сумка тоткан Айдарны күрде. Кул бирмичә генә исәнләшкәннән соң, алар бергәләп бүлмәгә керделәр.

— Әйдәгез, утырыгыз, — диде Сөембикә, аңа урын тәкъдим итеп.

«Чишенегез!» диюдән курыкты, алай итсә, ничектер аны көтеп торгандыр, аңа ярарга тырышадыр кебек тоелды. Айдар, урындыкка утырып, бүреген тезләренә куйды да тыныч кына аңа карап тора башлады. Сөембикә елмаеп җибәрде.

— Сез мине күзәтеп утырыр өчен генә килмәгәнсездер дип уйлыйм. Миннән берәр төрле ярдәм кирәкме?

— Сезнең шушылай җылы кабул итүегез үзе олы ярдәм инде. — Айдар сәгатенә карап алды. — Хәзер шушы җылыны йөрәгемә салган хәлдә миңа кунакханәне эзләп китәргә кирәк.

Сөембикәнең күңеле сыкрап куйды. Айдарны һич кенә дә үзеннән читкә җибәрәсе килмәде аның!

— Кунакханә моннан күренеп кенә тора. — Сөембикә шулай диде дә Айдарга каш астыннан гына назлы караш ташлады. — Тик нишләптер сезне анда куу уңайсыз. Гаеп итмәсәгез, миңа гына кайтырсыз.

Бу сүзләрне ишетүгә, Айдарның йөзе яктырып китте.

— Су сипмәссезме соң? — диде ул, елмаеп.

— Колонканың тимеренә кагылмасагыз, су сибелмәс.

Алар берьюлы көлеп җибәрделәр. Кайту мәсьәләсе шуның белән хәл ителде.

— Сәгать дүртләрдә кайтып китәрбез. Аңарчы нишлисез соң?

— Бер җитешеп килгәч, сезнең бу Болынкыр дигән күркәм җирегезне карап чыгыйм инде. Бәлкем, берәр йорты күңелемә ошап куяр.

Айдар чыгып киткәч, Сөембикә шактый вакыт уйланып утырды. Бу кешенең һәр сүзе, керфегенең һәр тибрәлеше, күз карашы, гәүдә хәрәкәтләре аңа искиткеч сөйкемле, үз булып тоелды. Әхнәф яныннан чыкканда, йөрәген моның азагы болай гына калмаячак дигән шомлы ут көйдерсә, менә хәзер, Айдар килгәч, ул үзенә таяныч тапкандай булды. Юньләп әле танышып та өлгермәгән бу кеше әйтерсең лә аны якларга дип килгән һәм Сөембикә аңа инде тулысынча ышана кебек иде.

Кичен, әзрәк мактанасы килеп, ул рульдә үзе кайтты. Машинаны капка төбенә генә куйды, гадәттәгечә шоферы аны үз вакыты белән килеп алып китә иде.

Өйгә керүгә, Айдар өстәлгә Казан күчтәнәчләрен таратып ташлады. Киемнәрен салып, ак водолазкадан калгач, ул япь-яшь булып күренде. Сөембикә аңа карарга гаилә альбомнарын бирде, телевизорны кабызды, ә үзе кече якта ашыга-кабалана ашарга хәстәрли башлады, веранда базыннан тозлы кыяр, кәбестә алып чыкты. Ул арада Айгөл дә кайтып керде. Айдарны күргәч, ул ишек катында аптырап калды. Ирен араларыннан ишетелер-ишетелмәс кенә булып:

— Исәнмесез... — дигән сүз чыкты.

— Исәнмесез, — диде Айдар, аның каршына килеп. — Мин Айдар исемле. Сезнең исемегез ничек була, чибәр кыз?

— Айгөл...

— Ай, нинди матур гөл!

Айдар җитез генә иелде дә сумкасыннан афоризмнар китабы алып Айгөлгә суздьı.

— Менә шушындагы фикерләргә таянып яшәсәгез, дөньяның иң бәхетле кешесе булырсыз, — диде ул, елмаеп.

— Рәхмәт, шулай яшәргә тырышырмын, — диде Айгөл

һәм чишенеп кухняга үтте. — Нинди шәп китап! Мин бит моны күптән эзләп йөри идем, әни! — Аннары кызның йөзе җитдиләнеп китте. — Әни, — диде ул, шыпырт кына. — Бу абый кем соң?

— Минем танышым, кызым. Казаннан килгән.

— Бер дә әйткәнең юк иде.

— Биючеләр конкурсында гына таныштым әле мин аның белән.

Айгөл белән Сөембикә бергәләп өстәл әзерләделәр. Ашап-эчкәч, залга чыгып, өчәүләп күңелле генә әңгәмә корып утырдылар, телевизор карадылар. Айгөлне берничә мәртәбә телефонга чакырсалар да, ул: «Юк, мин чыкмыйм», — дип җавап бирде. Бу вакытларда мәктәптәге берәр кичәдән яисә дискотекадан кайтырга тиешле кызының бүген өйдә утыруы сәеррәк иде. Хәер, ул моңа җавапны тиз тапты: кызы аны таныш булмаган ир кеше белән ялгызын гына калдырырга теләми иде. Сөембикә авылда әнисе белән яшәгән чакта кичергән бу тойгыны бик яхшы хәтерли. Ахыр чиктә ул — әни кешедән көнләшү, аны башка кешегә бирергә теләмәү, аны югалтудан курку.

Сөембикә Айдарга үз бүлмәсенә урын җәйде. Айгөл белән алар парлашып залдагы диванга яттылар.

— Айдар абый безгә озакка килдеме? — дип пышылдады ул әнисенең колагына.

— Белмим. Әгәр озакка килсә, ни дияр идең?

— Берни дә әйтмәм. Беләсеңме, әни, ул кемгә охшаган?

— Кемгә?

— Әбигә.

— Кайсы әбиеңә?

— Җәүһәрия әбигә.

Кызының сүзеннән Сөембикә өнсез булып калды. Чыннан да, Айдарның күзләре, борыны, бөтен йөзе әнисенекенә охшаган иде. Ә иреннәре бөтенләй дә аерып алмалы түгел, елмаюлары да әнисенекенә тартым. Сөембикәнең күзенә нишләптер йокы кермәде, төрле уйларга батып төн уздырды...

Иртән алар урамга өчәүләп чыктылар. Мәктәп янына җиткәч, Айгөл кул болгап кереп китте. Сөембикә белән Айдар урам читеннән акрын гына атладылар. Таныш-белешләр Сөембикәгә сәлам биреп китсәләр дә, берничә адым үтүгә, кабат-кабат борылып карыйлар иде. Культура бүлеге бинасы турына җиткәч, Сөембикә:

— Миңа эшкә керергә кирәк, сез нишләргә уйлыйсыз соң? — диде.

— Мин Чаллы якларыннан йорт яисә квартира сатып алырга дигән уй белән чыккан идем. Тик ул ниятемнән кайттым бугай.

— Ничек алай?

Айдар беркадәр вакыт җавап бирми торды. Аннары якягына борылып, караштырып алды да:

— Мин биредән беркая да китмәс идем, — диде.

— Сатыла торган өйләр бардыр ич, белешергә кирәк.

— Өйләр барын бардыр, миңа аның сатып ала торганы кирәкми. Эчендә хуҗабикәсе дә булсын иде.

Ул Сөембикәгә серле караш ташлады. Бу карашның мәгънәсен, төгәлрәк әйткәндә, аның ни теләвен аңларга була иде.

— Эзләгән кешегә андыйны да табып буладыр.

— Мин аны таптым кебек инде.

— Кичә килепме? Җитез икәнсез! Кайсы урамда?

— Урамын әйтә алмыйм, ә менә хуҗабикәсе минем каршымда басып тора.

Сөембикә бурлаттай кызарды:

— Мондый нәрсә белән шаярмыйлар, Айдар.

— Шаярырга уйласам, Казаннан шушында килеп йөрмәс идем мин...

— Безнең бит егерме яшьлек, хәтта утыз яшьлек чагыбыз да түгел. Бер күрешү белән андый адымга бармыйлар.

— Мин күңелемә ышанам. Беренче хатыным белән танышып бер атна йөрдек тә өйләнештек. Без бик бәхетле яшәдек. Ул авырып җиде ел хәрәкәтсез ятканда, үзем карадым. Соңгы сулышында күзләрен дә үзем йомдырдым.

Айдар тынып калды. Сөембикә бик кыен халәт кичерә иде. Ихлас сөйләнгән бу сүзләр нишләптер аның бәгырен көйдереп алдылар.

— Сез аны бик нык яраткансыздыр, әйеме?

— Әгәр ачыктан-ачык әйтсәм, сез мине аңлап бетерә алмассыз кебек тоела. Мине яратуның нәрсә икәнен белмәдем бугай. Шул ук вакытта яратмауның да нәрсә икәнен белмәдем. Без хатыным белән бер кеше идек, аерылгысыз бер җан, бер тән — аңлыйсызмы? — Ул, әллә дулкынланудан, әллә фикерен белдерергә сүз таба алмыйча, тагын бераз туктап торды, аннары нишләптер карашын читкә юнәлтеп, сүзен дәвам итте: — Шундый әйбер укыганым хәтердә. Мәхәббәт беләсезме кайчан була? Хатын яисә ир үзе сөйгән кешене яулау өчен тырышканда гына. Фәнни билгеләмәләргә ул бик үк туры килеп бетми бугай. Ә менә мин аңа ышандым. Көн саен мәхәббәт ялкынында дөрләп янган ир белән хатынны бу тормышта, шактый яшәп, минем күргәнем булмады. Бәлкем, андыйлар да бардыр.

— Кызык сезнең фикерләрегез, — диде Сөембикә. — Ләкин, Айдар, гафу итегез, аларны раслау өчен генә... Юк... Турысын әйтим, мин сезгә битараф түгел. Шуннан башка берни дә әйтә алмыйм. Хушыгыз.

Сөембикә кызулап эшенә кереп китте. Ул өс-башын чишенеп, төзәтенеп урынына утыргач та тынычлана алмады. Аның тормышында нindидер зур үзгәреш башланырга тора иде. Ул инде бик якын һәм кызыктыргыч. Күңел ярларын ялгызлык ташкыны ашап газаплаган елларга, кайнар күз яшьләре белән чылатылган озын төннәргә, шатлыксыз булып аткан алсу таңнарга чик кую мөмкинлеге туа иде, ахрысы. Бары бер тәвәккәл адым ясыйсы, тик ул ялгызлыктан коткарырмы? Әллә тагын да аяусызрак, гел уйга-башка китермәгән күңелсез көннәре белән тормыш диңгезен кайната башлармы? Әгәр бу мөмкинлекне ычкындырып, әнисе кебек гел юктан үз бәхетен үзе югалтса? Ул хакта уйласа, әнисе өчен әрнүдән Сөембикәнең хәзер дә бәгыре телгәләнә. Әнисе гомере буе бәхеткә омтылды, аңа якынайган саен, бәхете ерагая барды. Әнисе Җәүһәрия кебек биюче юк иде. Бер уйлап караганда, аның бәхетсезлегенә күбәләктәй җитез биюе сәбәпче булгандыр кебек тоела Сөембикәгә. Икенче караганда, нәкъ әнә шул биюе зур тормышка, бәлкем, дан китерә торган зур сәхнәләргә алтын бәхет ачкычы да булгандыр. Район олимпиадаларында Җәүһәрия ел саен чыгыш ясый һәм беренче урынны ала торган була. Кыз чагында Казан сәхнәләрендә дә күпләрне таң калдыра, аны укырга чакыралар, ләкин ул фермада эшли бирә. Югыйсә бәхет ачкычы кулында була бит!

Бер елны, олимпиада вакытында, биегәнен күреп, аңа районның җир бүлеге мөдире Даут үлеп гашыйк була. Зәпзәңгәр күзле, җитен чәчле, ап-ак тәнле, нәфис кенә буйлы, күзлекле бу егет көн саен диярлек кичләрен Таңтугайга Җәүһәрия янына килә башлый. Даут аның өчен җанының яртысын ярып бирерлек булып йөргән, өйләнешергә тәкъдим ясаган, Казанга алып китәм, дигән. Үтә дә тәэсирләнүчән, йомшак күңелле Даут оста гармунчы һәм биюче булган. Алар бергәләп җырлаганнар, чәйләр эчкәннәр, кайчакларда парлашып Таңтугай урамнарын әйләнгәннәр, әмма Җәүһәрия, әллә ышанып бетмичә, әллә кызык итеп, ялындырып йөри биргән. Сөембикәнең әбисе белән бабасы да Даутны бик яратканнар, әнисенең шундый дәрәҗәле кешене мәче тычканны уйнаткандай йөртүенә эчләре янып, аны ачуланганнар, кияүгә чыгарга кодалаганнар. Ахырда әнисе ризалаша. Алар өйләнешеп Болынкырга күчәләр. Әнисе культура йортына сәнгать җитәкчесе булып урнаша, Даут аны өрмәгән җиргә дә утыртмый. Өч ай яшәгәч, ул, куанып, икесенә дә санаторийга юллама алып кайта. Ашказаны авыртканлыктан, ел саен санаторийга бару аның өчен мәҗбүри була. Ләкин Җәүһәрия санаторийдан баш тарта. Даут аптыраашта кала, аны төрлечә үгетләп, кыстап карый. Алар беренче мәртәбә шунда ныклап

ачуланышалар. Бер уйлап карасаң, әнисенең каршы килерлек сәбәбе дә булмый. Атна-ун көннән алар спектакль куясы булалар, Җәүһәрия шунда төп рольне башкарганлыктан, бу чараны өзәсе килми, район үзәгенә килеп, үзенең беренче олы эшен күрсәтү теләген җиңә алмый. Иртәгә китәсе дигән көнне, үгетләп тә эш чыкмагач, Даут:

— Чамала, сиңа үкенергә туры килмәгәе, — ди һәм китеп бара.

Өч атна узуга, ул бер яшь-яшь кызга өйләнеп кайта. Җәүһәрия чәчен йолкымый, аңа бернинди үпкә сүзләре белдерми. Әтисе үзенең бу адымын «миңа буйсынмый торган хатын кирәкми» дип кенә аңлата. Әнисе, барлы-юклы әйберләрен төяп, Таңтугайга кайтып китә. Даутның тәртибен райкомда тикшереп, партиядән чыгара язалар. Күпчелекнең яклавы аркасында гына аны эшеннән алу белән чикләнәләр. Яшь хатыны белән ул Казанга күченә, аннары бөтенләй Себер якларына китеп юк була. Әнисе, авылга кайтканнан соң, йөкле икәнлеген белә.

Бервакыт әнисенең әбисе каршында чәчләрен йолка-йолка елап аһырганын Сөембикә үз күзләре белән күрде. «Их, әнкәй, Даут минем оҗмахым булган, мин шул оҗмахтан баш тарттым. Ничек үкенгәнемне белсәң!.. Ходай мине моның өчен беркайчан да кичермәс!..» — дип елады ул.

Аннары әнисе Кәшифулланы йортка кертте, аның артыннан Сәфәргали килде. Шулар арасында Фәйзрахман, башкалар буталды.

Сөембикәнең авылдан китәргә теләвен белгәч, әнисе аңа бәбкәгә ташланган тилгәндәй ташланды:

— Мин сине беркая да җибәрмим! — дип ярсыды ул. — Мин синнән башка бер көн дә яши алмыйм.

— Әгәр мин кияүгә чыксам? — дип каршы төшә иде аңа Сөембикә.

— Чыкмыйсың! Минем сүземне онытма: кияүгә чыгып, син беркайчан да бәхетле була алмыйсың.

— Нишләп?

— Безнең маңгайга шулай язылган. Минем гөнаһларым өчен Алла сине җәзалаячак. Ялгызың яшәсәң, син бәхетлерәк булачаксың.

Сөембикә шушыларны хәтеренә төшереп баш ватты. Әллә соң әнисе хаклы булганмы? Ирек белән тормышлары барып чыкмады. Менә хәзер аның алдында бәхет офыгы яктыра башлады.

Алар, иңгә-иң торып, Айдар белән Болынкыр урамнарыннан уздылар. Сөембикә юри башын югары күтәреп, төптөз басып атлады. Күз яшьләре белән үткәргән елларына үч итеп, менә мин дә сезнең кебек бит дип раслау иде бу.

Сөембикә шул уйлар тәэсирендә Айдарны туктаусыз читкә этәрде.

Айдарның нәрсә алып киткәнен, үзенең нинди авыр йөктән котылганын аңлап бетермәстән, ул җиңеллек тойды. Ул күңелендә нindидер келәнең шылт иткәнен сизде: әллә ачылды, әллә бикләнде... Ничек кенә булмасын, Сөембикә өчен бу бик тә ләззәтле иде...

## 8

Өченче көн Фәһимәне пошаманга салган хәл булды. Ул эшкә китәргә әзерләнеп маташканда, телефон шалтырады. Ят ир-ат Әхнәфне сорады. Фәһимә аның кайдан, кем булуы белән кызыксына башлады, ә ир кеше кем икәнен яшерде, шаяртып сөйләшә башлады, Фәһимә дә кыланчыкланып җавап бирде. Шактый вакыт тел чарлагач, ул Рашат икәнен әйтте, йомышым бар иде, үзе белә ул, диде. Фәһимә Рашатның телефон номерын да алды. Әхнәфне дә тулаем үзенеке итә алмавына ул тагын бер мәртәбә инанды. Ләкин шуңа омтылырга кирәк иде. Тормышның ул теләгәнчә баруы нәкъ менә шуннан торганын Фәһимә күпьеллык бергә яшәү тәҗрибәсе буенча белә. Шуңа күрә ул, Әхнәфнең күңелен йомшартуга багышлап, чираттагы акциясен уздырырга ниятләде. Ул аңа җентекләп әзерләнде. Әхнәфнең иң яраткан ризыгы — бозау башы белән пешерелгән шулпа. Кичә ул башны пешереп куйды, бүген иртән сөяктән аерып, ваклап турады, аннары зәйтүн маена салып, суган кыздырды, шуннан соң вакланган итне шулпага салып, аңа гөмбә, кыздырылган суган, йөз төрле тәмләткеч өстәде. Аш әзер булгач, шулпага лимон согы һәм кашык чумары ясап салды. Иң затлы коньякны да әзерләп куйды. Әхнәф гадәттәгечә соңарыбрак кайтты, ишектән керү белән борынын җыерып иснәнде һәм, елмаеп, Фәһимәгә:

— Әллә нинди оҗмах исләре килә, — диде.

— Ә син тизрәк чишен, юын да өстәл янына кил.

Әхнәф өстәл янына утыруга, ул аның алдына олы савыт белән яраткан ризыгын китереп куйды. Әхнәф күзләрен йомып, борынын савытның читенә тигерә язып, тирән итеп сулады һәм елмаеп җибәрде.

— Бозау башы түгелме соң бу, карчык?

— Шул шул.

— Син аны минем туган көнгә генә пешерә идең бугай.

— Ә мин менә тоттым да пешердем, — диде Фәһимә, чытлыкланып. — Безнең дә яшәү рәвеше үзгәрергә тиештер бит.

Әхнәф сәерсенеп баш чайкады һәм сораулы карашын хатынына юнәлтте.

— Әйтимме нәрсә булганын? — диде Фәһимә, бераз көттереп. — Син кушкан операцияне башкардым.

— Чынлапмы?! — диде Әхнәф, урыныннан ярым күтәрелеп.

— Авырлыгын сөйләп биримме соң? — Фәһимә аның муенына куллары белән сарылды, кайнар ирennәрен Әхнәфнең салкынча битенә тигерде. — Аз сумма түгел бит һәм банкның кредит бүлегендә нинди елан утырганын да беләсең. Сөйлимме соң?

Әхнәф, аңа борылмыйча гына, кулы белән Фәһимәнең тезләреннән сыпырды:

— Кирәкми... булдыргансың. — Ул, кинәт кенә борылып, Фәһимәнең иреннәреннән үбеп алды. — Менә хәзер мин бу өстәлнең ник әзерләнгәнен аңладым, — диде дә рюмкаларга коньяк салды. — Әйдә, шуның өчен.

Фәһимә, серле елмаеп, ике кулының да имән бармагын аның каршында кара-каршы китереп болгап алды:

— Юк, карткаем, аның өчен түгел. Әйдә Әхнәф Хәсәнович исәнлеге өчен!

Әхнәф рәхәтләнеп көлеп җибәрде, хәтта коньягы чайпалып бераз өстәлгә дә түгелде.

— Әллә син дә ялагайлана башладың инде? — Шулай диде дә, Фәһимәнең рюмкасы белән чәкештереп, коньягын йотып куйды.

Әхнәф кашык чумары салынган бу ашны ике мәртәбә бүлдереп ашады, аннары гадәттәгечә залга чыкты. Фәһимә, өстәлне җыештырып куйганнан соң, ваннага кереп китте, чәчләрен «Лореаль» фирмасының хуш исле шампуне белән юды. Комсомолда эшләгән чакта ук Әхнәф аңа, сиңа кыска чәч килешә, дигәч, үкчәсенә җитеп торган толымнарын кискән иде. Менә хәзер көзге каршына басып, ул үзенең малайларча алдырган чәчләрен ике куллап артка таба сыпырды. Әхнәфнең тагын бер ошаткан нәрсәсе бар: ул Фәһимәнең чигә турындагы чәчләренең күзләренә таба ятып торуын ярата, шулай иткәч, әллә нинди серле фәрештәгә охшыйсың, ди. Ләкин чәчне алай итеп тоту өчен шактый катлаулы эш башкарырга кирәк. Тәнен сөртмәгән килеш һәм өстенә халат та элмәстән, Фәһимә әнә шул эш белән шактый мәшгуль булды. Ул арада тәне дә кипшенде һәм ул, Әхнәф алып биргән үтә күренмәле эчке күлмәген киеп, акрын гына аның янына чыкты. Ул, алтын кысалы күзлеген киеп, журнал укып утыра иде. Арттан тавыш-тынсыз гына килеп, Фәһимә аның алдына кереп утырды. Әхнәф, журналын ташлап, аңа төбәлде.

— Йә, мин ничек? — диде Фәһимә, аның муенын бер кулы белән кочып.

— Искиткеч, —дип пышылдады Әхнәф һәм, аның чигә чәчләренә иреннәрен терәп, күзләрен йомды.

Аның кайнар сулышыннан Фәһимә кытыгы килгән тавыш чыгарып көлде, чытлыкланды.

Әхнәф Зәлияне күз алдына китерде. Фәһимәгә чәчләрен менә шушылай Зәлиянеке төсле итәргә ул үзе өйрәтте. Аның күз алдына Зәлия-Алсулар килеп баса да, кайнарлана башлаган хис-тойгыларын таратып ташлый. Ул Фәһимәне иркәләргә тырыша, әмма куллары агачтан ясалгандай хәрәкәтләнәләр, иреннәре ялкынсыз гына үбә, җаны тетрәнми, сулышы кысылмый. Егерме яшьлек Зәлияләрнең кулны өттереп торучы кайнар тәннәренең тыгызлыгы, ефәктәй шомалыгы белән чагыштырганда, хатынының гәүдәсен иркәләү мамык белән сырган фуфайканы сыпырган кебегрәк тойгы калдыра... Бөтенесен үзеңне мәҗбүр итеп, хиссез-дәртсез, ялкынсыз башкарасың. Үзенә тиешле иркәләүләрне читләр алганын Фәһимә дә сизә, Әхнәф уйлавынча, иң бәхетле ирләр — чагыштырудан мәхрүм ирләр. Нәкъ менә чагыштыру аркасында җимерелә дә гаиләләр.

Фәһимә шашып аны иреннәреннән үбәргә тотынды. Әхнәф аны күтәреп алды да йокы бүлмәсенә алып кереп китте. Ничек кенә булмасын, аларның яшьлек тойгылары сакланган иде әле... Болар — күп еллар сыналган, бернинди тормыш давыллары да сүндерә алмый торган чын тойгылар иде...

Шактый вакыттан соң, икесе дә янәшә чалкан яткан килеш, сүзсез генә нидер уйландылар.

Тынлыкны беренче булып Фәһимә бозды:

— Әхнәф, мин бит беләм, синең кешеләрең бар... Шул сөйрәлчекләрнең ниен табасың?

— Юк сүзне сөйләмә инде! — диде Әхнәф. — Гомер буе булмаган өрәкне эзләдең.

— Акланып маташма, зинһар, — Фәһимәнең тавышы гаҗәп тә ягымлы, җылы булып ишетелде. — Мин бит сине гаепләргә җыенмыйм, син ир кеше. Ачуланмыйсыңмы?

Әхнәф сүзсез генә «юк» дигән мәгънәдә башын чайкап куйды. Ул, гәүдәсе белән яртылаш Әхнәфнең өстенә ятып, аның йөзен җентекләп өйрәнергә керешә. Яңагында бер кызыл бетчәгә охшаш нәрсә күреп:

— Бер бетчә чыга, сытып эшкәртим әле, — диде.

— Юк, — диде Әхнәф һәм аны йомшак кына читкә этәрде дә торып киенергә керешә.

Фәһимә, күзләрен йомган килеш, әллә нинди ят тавыш белән:

— Мин бит синең каршыда шундый гаепле, картым... —

диде. Ул тынып калды, бераз көттергәннән соң: — Мин — хыянәтче... — дип өстәде.

Киенеп маташкан җиреннән Әхнәф ток суккандай тораташ катып калды:

— Нәрсә?! Кабатла әле!.. — дип, ул Фәһимәнең өстенә иелде.

Хатыны һаман да күзләрен ачмады.

— Син әле үзең дә кемлегеңне бәяләп бетермисең, — диде ул. — Син бит ничә еллар тамыр җибәргән Арслановны йолкып ташлаган кеше. Халык сине ярата. Ник ярата? Беренче чиратта талантың, гаделлегең өчен... Син кояш кебек...

— Тукта әле, син исереп киттең, ахрысы. Ниндидер хыянәтеңнән башлаган идең. Син шул хакта сөйлә. Әгәр минем салпы якка салам кыстырып йомшартырга уйласаң, барып чыкмас.

Фәһимә йодрыгы белән иренең күкрәген төйде һәм пышылдады:

— Бүлдермә, бүлдермә фикеремне! — дип сүзен дәвам итте. — Син үзеңнең кояш икәнлегеңне онытма, бернигә дә карамыйча тормыш күгендә йөз. Мин синең юлыңны чиста тоту өчен бөтен барлыгымны бирергә булдым. Бүгеннән башлап.

Әхнәф аптырап баш чайкады:

— Синең ни әйтергә җыенганыңны мин һаман аңламыйм.

— Без ниндидер хәлиткеч сызыкка килеп җиттек, Әхнәф, — диде Фәһимә. — Болынкырда синең хакта төрле сүзләр тарала башлады. Без дәшмибез, ә көнчеләр, гайбәтчеләр туйганчы иҗат итәләр. Син минем белән килешәсеңме?

Фәһимә аның күзләренә туп-туры карады. Әхнәф хатынының бу дәрәҗәдә дулкынланган чагын күргәне юк иде, һәм ул аның инде күптән күңелен борчып йөргән нәрсәләрне кузгатуына хәйран калды.

— Әйе, карчык...

— Син өр-яңа юлдан барасың, карткаем, — диде Фәһимә, дулкынланып. — Янәшәдә таянырга мин бар. Безгә бүгеннән башлап берни дә яшерергә ярамый. Кухнядагы су фильтрын күрәсеңме? Безгә дә шулай булырга кирәк. Бер-беребездән фикерләрне яшермәскә...

Фәһимә тынып калды. Әхнәф, учы белән ияген сыпырасыпыра, почмактан почмакка йөри иде. Ниһаять, ул Фәһимәнең каршына килеп туктады, аны ике битеннән үпте һәм кочагына алды.

— Серле кеше инде син, карчык. Кайчакларда баш җитмәслек көчле дә.

— Дуамал дамы? — диде Фәһимә, аңа мут елмаеп.

— Менә бүгенге очракта анысы юк.

— Син артык тыныч түгел микән, Әхнәф? — диде Фәһимә. — Сөембикәнең интервьюсы синең абруеңа бик нык сукты. Ник алыштырмыйсың син аны? Башкаларга акыл булыр иде.

— Юк, Фәһимә. Моңа халык нинди бәя бирәсен син аңламыйсың. Эш ягыннан минем аңа бернинди претензиям юк.

«Бәлкем, ул сиңа башка яклары белән ныграк ошый төшәдер? Очрашуларга, концертларга ул синең янәшәңдә бара, төннең икенче яртысында гына кайтып керәсез», — дип әйтәсе килде Фәһимәнең. Ләкин ул бу сүзләрне тышка чыгармады.

— Алайса, үзеңә карыйсың инде, киләчәктә дә башыңа кәкәй итмәсә ярый да.

Турысын әйткәндә, Фәһимә бу кичне, һичшиксез, Сөембикә мәсьәләсендә үзенең нияте тормышка ашар дип уйлаган иде. Иренең каршы төшүе аның йөрәгенә кайнар энә булып кадалды. Шуңа күрә ул сүзне икенчегә борды:

— Әхнәф, әйдә шушы минутта сүз берләшик: элеккечә, арада бер генә серебез дә булмасын.

— Әйдә, — диде Әхнәф. — Минем синнән яшергән әйберем юк.

— Бар бит, Әхнәф, бар!

Әхнәфнең күз карашыннан шикләнү шәүләсе йөгереп үтте.

— Менә миңа әйт әле, Арсланов малае Рашат белән нинди уртак эшең бар синең?

— Нинди сүз сөйлисең син?! — диде Әхнәф, битараф күренергә тырышып.

— Үзе әйтте, сине эзләп шалтыратты.

Әхнәф ансат кына котыла алмаячагын аңлады.

— Чаллыдан бер почмак алмакчы ул. Инде күптән ялвара, ярдәм сорый. Күрәсең, Арсланов минем анда элемтәләрем күплеген әйткән.

Әхнәф бу сүзләргә хатыны дөртләп кабар дип көткән иде, әмма алай булып чыкмады.

— И карткаем, син булдыра алмаган нәрсә юк бит ул! Алып бир аңа бер почмак. Рашат кебек тәвәккәл егетләрнең кирәк булып куюы да бар.

Фәһимә кайнар иреннәре белән аның иреннәренә сыланды. Алар шул хәлдә, бәлкем, бик озак та торган булырлар иде, кинәт телефон шылтырады. Әхнәф, хатыныннан аерылып, трубканы алды.

— Хәерле кич, Әхнәф Хәсәнович! Таныдыгызмы?

Шылтыратучы Шәвәлиев иде.

— Сезнең тавышны танымаска мөмкинмени. Исәнмесез! Сез каян?

— Сезнең Болынкырда минем бит әле кендек җебе калган иде. Шуны өзәргә дип кайттым. Бәлки, ярдәмгә килерсез?

— Сез бит хирург, Зөфәр Шәрипович. Бер кендек җебен ике кеше өзәмени?

Шәвәлиевнең кеткелдәп көлеп җибәргәне ишетелде.

— Әйбәт әйттегез. Килеп китә алсагыз, бераз сөйләшеп утырыр идек.

«Синең йөзеңне күрмәс өчен генә дә ярты еллык хезмәт хакымны бирер идем мин!» дип әйтәсе килде Әхнәфнең. Ләкин алай әйтергә ярамый иде. Әле эшлисе, яшисе, гомер итәсе бар. Ә дөнья дигән әйбер шулкадәр дә тар, гел көтмәгән кешеләргә китереп тезләндерә, баш идерә.

— Гафу итегез, Зөфәр Шәрипович, минем сезнең белән күптән сөйләшеп утырасым килә, — диде Әхнәф, Фәһимәгә күз кысып. — Сезнең районда гы хәлләрне дә белешәсе килә. Тик Ходай бүген безне ул бәхеттән мәхрүм итте. Мин утыз сигез градус температура белән ятам, башны күтәреп булмый, грипп, ахрысы.

— Кызганыч, — диде Шәвәлиев, аның алдашканын сизенгәндәй, сузынкы тавыш белән. — Сезнең монда грипп бик көчле бугай. Берничә кешегә шылтыратып карадым, барысы да температура белән яталар.

— Эпидемия шундый нәрсә бит инде ул.

— Нажия, эпидемия юк, дигән иде. Ярый, терелгәч күрешергә насыйп итсен.

— Хушыгыз, — диде Әхнәф.

Һәм алар икәүләшеп берьюлы көлеп җибәрделәр. Бу көлүгә күп нәрсә сыйган иде. Кызганыч, аны Шәвәлиев кенә ишетә алмады. Хәер, ишетсә дә берни дә аңламас иде.

## 9

Нажия үзен кыядай нык торырмын дип уйлаган иде, әмма сынды. Аның ныклыгы, күрәсең, язгы боз ныклыгы кебек кенә булып чыкты. Әнә бит елгада каткан боз өстеннән авыр йөкләр төягән трактор-машиналар көне-төне чабалар. Озын кышлар уза, язгы кояш ак кар катламын шикәр төсле сәер җемелдәтә башлый, аның эчендә нидер көйрәгәндәй була, урамнарда, ихаталарда иң әүвәл чыпчык эчәрлек кенә сулар күренә, аннары түбәләрдән кабаланып тып-тып тамчылар тама, боз сөңгеләре асылына. Беренче кар сулары киндерә юанлыгы гына эз ясап боргаланып ага

башлыйлар, аннары гөрләвекләр көчәя, бөтенесе елгага юнәлә. Ә елга, тын торса да, шешенкеләнеп китә, нишләптер җете ак төсен югалта. Бервакыт боз калка. Яз кояшы иртәдән кичкә кадәр аның өстен җылы теле белән туктаусыз ялап юкарта, ә астагы су агымы шулай ук гел ышкып, игәп тора. Боз акрынлап ваткалана, уала, кисәкләнә, хәрәкәтләнә башлый һәм беркөнне кешеләрдән үзенең җиңелүен һәм сагышын яшерү өчен тып-тын гына, күбесенчә төн заманында кузгалып китә...

Һич кенә дә кузгалмам, дип уйлаган Нәҗия дә түзде-түзде дә шартлап сынды. Зөфәр киткәч, ул чын-чынлап җиңеләеп калган, өстеннән авыр йөк төшкән кешедәй очынып йөри иде. Эченнән генә, ул булмагач, оҗмахка чыгармын, ниһаять, җаным тынар, дип уйлады. Уйлаганы рас килде, җаны тынды, Зөфәр белән яшәгәндәге кебек бәгырен учына кысып, беркемгә бер сүз әйтмичә, эченнән хурланып гомер кичерүдән котылды. Җаны тынуы тынды, әмма ниндидер аңлаешсыз бушлык барлыкка килде. Ул бушлык тирәсендә капшана торгач, үз-үзенә әйтергә куркыта торган сәбәп тапты. Күңеле әллә инде шул газаплы, хурлыклы кичерешләрне кабат тели идеме?! Һәрхәлдә, Нәҗиягә шулай тоелды. Адәм баласы бәхеттән генә рәхәт таба ала, әле берәүнең дә бәхетсезлектән ләззәтләнгәне юк. Алайса, нәрсә була соң бу? Әлеге сорауга Нәҗия тәгаен генә җавап бирә алмады...

Кичә Зөфәр, егетләре белән кайтып, шифоньер, сервант, тахта, суыткыч кебек зур әйберләрне машина белән алып китте. Нәҗия аларны озатып җибәргәннән бирле күзеннән аккан яшьләрен тыя алмады. Малае Зөлфәт белән төенчек арты төенчек төйнәде, әйберләрен тартмага тутырды. Ул тишек су багын инде күптән ачылмаган сарайга ыргытырга ниятләде. Аның ишеген ачып җибәрүгә имәнеп китте: сарай яртылаш уенчык белән тулган иде. Нәҗиянең йөрәге чәнчеп куйды, ул ялт итеп машина тартмасында варенье банкалары урнаштырып маташкан малаена карап куйды. «Йә Аллам, — дип уйлады ул эченнән. — Болар һаман исән икән бит. Нишләп аларны без моңа кадәр чыгарып түкмәгәнбез?» Ул, сарай эченә атлап, уенчыклар өстенә басты да ишекне бераз кысты. Әгәр малае күрсә, ике дә уйламыйча, шушы уенчыкларга ташланыр кебек тоелды аңа. Шунда гына аның хәтеренә багучы карчыкның: «Ул уенчыкларны түкмәгез, шакшы урыннарга эләкмәсеннәр», — дигән сүзләре исенә төште. Аларның Зөлфәтләре бик кетеп алынса да, бөтенләй көтелмәгән гадәте белән җаннарын талкыды. Малай бернигә карамыйча уенчык җыя, аңа курчак ни, машина ни, эт ни, мәче ни — аермасы юк иде. Ул үзенең өйдәге бүлмәсен уенчык белән тутырды, шунда йоклады.

— Балакаем, бу кадәр уенчык нигә кирәк соң сиңа? — дигән сорауны бирәләр иде аңа.

— Һа-а, сез берни дә белмисез! — дип кычкырып җибәрә малайлар. — Аларга мин кирәк, безне ташлама, беркемгә дә бирмә, — диләр.

— Ни сөйлисең, берсе дә дәшми бит.

— Алар аны мин йоклаганда әйтә.

— Беркем дә синең кебек бу кадәр уенчык җыймый бит. Син алар белән уйнамыйсың да. Уйнамагач, нәрсәгә?

— Үзегез әнә, кар әз, дип зарланасыз. Кар белән уйнамыйсыз бит. Нигә сезгә кар?

Малае әнә шундый булып чыкты. Сөйләшеп бора торган, үгетләп игә китерә торган түгел иде. Аның уенчык җыюдан башка шөгыле калмады. Йөзен, күз карашын олы кешенеке кебек гамь басты. Аңа уенчык ташый-ташый арыган Зөфәр белән Наҗия бервакыт аны хәйләләмәкче булдылар: ул бакчада чагында бүлмәсенә кереп, инде түшәмгә кадәр күтәрелгән уенчыклар өеменең иң астыннан ат белән бер курчак алдылар.

Өч көн үттеме, Зөлфәт бүлмәсеннән:

— Кая минем атым белән курчагым?! — дип үкереп килеп чыкты.

Зөфәр белән Наҗиянең күзләре маңгайларына менде. Тагын күпмедер вакыттан соң алар аның бер машинасын алып яшерделәр. Монысын Зөлфәт сизмәде. Әллә ничә ай узгач, әтисе: «Менә, улым, сиңа яңа машина», — дип аны китереп бирүгә, малай: «Мондый машинам икәү иде, өчесен бергә куям», — дип эзләргә тотынды. Зөфәр белән Наҗия, котлары алынып, тораташтай басып калдылар. Күп тә үтмәстән, Зөлфәт кычкырып елап та җибәрде: «Минекен урлагансыз!» Ул елый-елый әтисе белән әнисен йодрыклары белән төйде, тешләде, тырнады, әллә нәрсәләрне тартып төшереп ватып бетерде. Зөфәр белән Наҗия тын да алырга куркып, хәйран калып идәнгә кадаклагандай басып тордылар. Шушы хәлдән соң Зөфәр аны Казанга алып китте, малайларын Республика больницасында шактый вакыт дәваладылар.

Кинәт сарай ишеге шыгырдап ачылып китте. Уйларына чумып басып торган Наҗия сискәнеп куйды. Ишекне ачучы Зөлфәт иде.

— Әни, сине бер апа сорый, — диде ул.

Наҗия кабаланып сарайдан чыкты, машина янында Баллы Төбәк медпунктында эшләүче Хәлимә басып тора иде. Даруга килгән чакларда, әллә ничек ачылып китеп, бер-берсе белән серләшә торгач, инде алар дуска әверелеп беткәннәр иде. Әмма Зөфәрнең дәрәҗәсез кешеләр белән аралашырга

теләмәве аркасында алар бер генә мәртәбә дә парлашып табын янында очраша алмадылар. Инде Нәҗия ялгыз калгач, Хәлимә сирәк-мирәк кенә булса да аның йә эшенә, йә өенә сугыла иде.

— Менә ишеттем дә бер генә минутка булса да кагылып чыгыйм дидем.

— Рәхмәт керүеңә, — диде Нәҗия, күз яшьләрен сөртеп. — Бүген әллә нәрсә булды, елыйм да елыйм. Әйдә, чәй эчәбез.

— Кая ди ул! Әнә машинасын да сүндермәгән килеш, агроном көтеп утыра.

Хәлимә аны култыклап алды да капкага таба алып китте. Келәгә тотынгач туктап калды:

— Китәргә булдыңмыни?

— Әллә китәм, әллә калам... — диде Нәҗия, яшьле күзләре белән аңа карап. — Элек котылдым дип яшәдем, хәзер үлгәнче дип китәм. Миңа барыбер, кая китүем дә мөһим түгел...

— Яле, Нәҗия, әллә нинди төшенке сүзләр сөйләмә. Бер дигән яшәрсез.

— Белмим. Үзем генә калгач, бер йотым иркен сулыш алган идем. Аның белән яши башлаганнан бирле бер йотым бит ул. Хәзер шул бер йотымны эчемдә тоткан хәлдә хурлык диңгезенә чумам... Чөнки башка чарам юк.

— Син әле тагын күп нәрсәләр аңларсың, Нәҗия. — Хәлимә кулъяулыгы белән аның күз яшьләрен сөртте. — Син бит Зөфәр Шәриповичның киң җилкәсе артында буласың. Башыңдагы төшенке уйларыңны алып ташла.

— Рәхмәт, Хәлимә.

Алар бик озак кочаклашып тордылар да сүзсез генә аерылыштылар. Күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, Хәлимә абынасөртенә капка төбендәге машинага йөгерде...

## 10

— Үләм бит, берәр нәрсә бир. Ишетәсеңме, үләм!..

Бу сүзләрне әйткән вакытта Рашатка инде башы чәрдәкләнеп очар кебек тоелды.

— Үләм, эчәргә бир...

Хәят, сабыры төкәнеп, аның каршына килә, Рашатның күкшел-саргылт йөзенә, тирләгән муеннарына, калтыранган тәненә карый.

— Сорама да, бирмим! — ди ул.

— Алайса үтер мине!

Аның ике күзеннән яшь ага. Хәят түзми, инде әллә кайчан кружка төбенә салып куйган өйдәге соңгы йотым аракы-

ны суза. Рашат аны көч-хәл белән эчә, бераз хәлсезләнеп ята, аннары күзләрен ача. Беренче кат күргәндәй, әнисенә карап тора.

— Тагын бир.

— Бүтән юк.

Рашат ыңгырашып торып утырды, ялан аякларына басып кухняга юнәлде, кечкенә шкафның тартмасын ачып, пычакны алды һәм ялт итеп артына борылып карады. Аның күзләре коты очып карап торучы әнисенең күзләре белән очрашты. Хәят куркудан артка чигенә башлады.

— Юк, — дип хырылдады Рашат. — Курыкма...

Ул пычакны очы белән йөрәгеннән аскарак терәде, ике кулы белән сабыннан тотты, күзләрен чытырдатып йомды, ләкин басарга батырчылыгы җитмәде. Хәят, йөгереп килеп, пычакны тартып алды һәм каядыр зал ягына томырды.

— Бар, ят, зинһар, ят! — диде ул. — Хәзер алып кайтам...

Хәят чыгып киткәч тә Рашат шул баскан урынында шактый вакыт хәрәкәтсез торды, шкафның тартмасын тагын ачты. Бу юлы төрек кылычын хәтерләткән иң үткен, кәкре пычакны алды. Пычакны ул калтырана-калтырана муенына китерде, ләкин бугаз төененә аның үткен йөзе тию белән, кулыннан төшереп җибәрде.

— Булмый, — дип пышылдады ул. — Пистолетымны алып кайткан булсам...

Ул пычакны кабат урынына салды да кухня өстәле янына килеп утырды. Ниһаять, әнисе кайтып керде. Ул өстәлгә бер чәкүшкә аракы куйды. Рашат калтырана-калтырана аны ачмакчы булды, тик хәленнән килмәде, бөкене Хәят ачып бирде. Кружкага ул яртылаш аракы салды да өч йотуда эчеп тә бетерде, берни капмады, хәтта тын да алмады кебек. Тешләрен кыскан килеш хәрәкәтсез утырды. Аннары, күзләрен ачып, тагын шешәгә үрелде, тагын салды. Хәят, аның каршына баскан килеш, авызын юка шәле белән каплап, сүзсез карап торды.

— Рәхмәт... — диде ул, ниһаять.

Аның күзләрендә җан әсәре күренде, йөзенә адәм кыяфәте кергәндәй булды. Хәят, өстәлнең каршы ягына чыгып, аңа якын ук килеп утырды.

— Улым, — диде ул, йомшак кына. — Әнкәй дию авырмыни?

Әллә аңа җавап бирергә теләмәүдән, әллә чыннан да тамак төбенә нидер утырудан, Рашат шактый вакыт йөткереп торды.

— Әйтә алмыйм...

— Авырмыни?

— Көчләмә...

Хәят, өстәл аркылы үрелеп, аның битен сыйпап куйды, беләкләреннән сыпырып алды һәм, йомшак кына итеп:

— Ә син әйт... Әйтеп кара... — диде.

— Алдашырга теләмим. — Шулай диде дә, Рашат тынып калды, аннары кинәт йөзен әнисенә таба күтәрде. — Мин әшәке! Үземнең беткән кеше икәнемне беләм. Но сезнең кебек ялганларга теләмим!

— Ярар, синеңчә булсын. Берәр нәрсә әзерләп биримме? Ашыйсыңмы?

— Юк, берни дә кирәкми.

— Менә мин сиңа карап торам, хәзер дә бит синең күзләреңдә миңа карата ачу, күралмау. Үзең рәхмәт әйттең, хәзер генә булса да ачуланмыйча карап булмыймыни?

Күз кабакларын кыскан килеш кенә Рашат аңа астан карап алды.

— Син каян беләсең минем кемгә ачуланганымны?

— Беләм, — диде Хәят. — Закон булмаса, син икебезне дә үтерер идең.

— Ялгышасың, — диде Рашат, инде исерә башлаудан тотрыклылыгын югалткан кулын әнисенә таба селкеп. — Мин сезне теләсәм дә үтерә алмыйм. Ник икәнен әйтимме?

— Әйт, — диде Хәят.

— Сез инде мине күптән үтердегез. Ә үлгән кеше башкаларны үтерә алмый. — Үзенең шушы фикереннән ниндидер тәм табып, ул көлеп җибәрде: — Ха-ха-ха!..

— Без сине тәрбияләп үстердек.

— Юк, сез мине тәрбияләп үтердегез.

— Әтиеңне сөймәсәң дә, син миңа башкача карарга тиеш. Сине мин карадым, мин кеше иттем.

— Әйе. Сез Эльза белән икебезне аерым тәрбияләдегез. Син — мине, әти — аны. Шушы кошмарны күреп, без сезне яратырга тиеш идекме?

— Әйе, шулай килеп чыкты... — диде Хәят, күз яшьләрен сөртеп. — Моны берничек тә аңлатып булмый. Ничек кенә булмасын, мин — синең әниең. Мин сине тугыз ай карынымда күтәреп йөрдем, тудырдым, үстердем.

Хәят күз яшьләренә буылып тынып калды. Рашат шешә төбендәге аракысын борыныннан гына күтәреп эчеп куйды да инде шактый нык тавыш белән сүз башлады:

— Ә нигә син аны хурладың?

— Кемне?

— Арслановны.

— Хурламадым... Кайчакта ниндидер тиеш булмаган нәрсәләр әйтелгәндер дә... Бик нык рәнҗетелгән чакларымда.

— Юк, син хурладың. Син аның безгә каршы икәнлеген сиздереп тордың. Телең белән әйтмәсәң, кулың белән күрсәттең. Тора-бара мин: «Бу Арсланов дигән кеше нигә безне рәнҗетә?» — дип баш ваттым.

— Син үзеңә эшләнгән игелекләрне дә, әтиең аркасында ясалган ташламаларны да оныткансың, — дип бүлдерде аны Хәят. — Синең каршыда укытучылар үрә басып тордылар, икелелек җавап бирсәң — дүртле, өчлелек җавап бирсәң — бишле куйдылар.

— Син хәзер шушының белән мактанасың. Ник туктатмадың?

— Әгәр мин аны туктатсам, сине мәктәптән куачаклар иде. Синең урам малаена әверелүеңнән минем котым очты.

— Рәхмәт, — дип мәсхәрәләп көлде Рашат. — Аның урынына Мәскәү урамы малаена әвереледем. Хулиганнары да башкаланыкы, бандитлары да международный уровеньда.

— Син шуны гына әйт: миңа карата синдә аңардан аермалы буларак әз генә булса да җылы бардыр бит? — диде Хәят.

— Менә бу аракыны алып кереп, син минем үлгән тәнемә җан керттең — анысы өчен рәхмәт. Тик алдашырга мәҗбүр итмә мине. Минем өчен икегез дә бер үк, бернинди аерма да юк.

— Алай булырга тиеш түгел! — дип кычкырып җибәрде Хәят. — Алай була алмый!

— Мин дә шулай уйлыйм: алай була алмый. Тик нишләп соң ул шулай? Икегез бер агач.

— Болай яшәп булмый бит, балам. Менә хәзер синең өчен җан атабыз. Өчебез бер фикергә килергә кирәк.

— Сез, үзара тарткалашып, мине дә, Эльзаны да кара упкынга очырдыгыз. Упкыннан чыкканда, мин икенче кеше идем инде. Так что, син — әни, Арсланов әти түгел. Кыланырга мәҗбүр итмәгез мине.

Рашат сикереп торды да ваннага кереп китте, озаклап юынды, аннары чыгып үз бүлмәсендә киенергә керешге.

Шул вакыт Миңзаһит кайтып керде. Ул чишенеп, юынып өстәл янына килеп утыруга, костюм-чалбарларын кигән Рашат, бүлмәсеннән чыгып, аның янына килде.

— Бераз акча кирәк иде.

Миңзаһитның күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды:

— Ә нәрсәгә сиңа акча? Җылынырга өлгергәнсең, башың авыртмый, ашарга — өстәлдә.

— Миңа ашарга-эчәргә генә түгел, күбрәк кирәк.

— Акчаны эшләп табалар.

Рашат дәшмәде, ишек янына барып, болан мөгезенә элензән бүрекне алып куенына тыкты. Ләкин аның киенгәнен күзәтеп торган Миңзаһит моны күреп алды.

— Чыгар бүрекне куеныңнан! — диде ул, Рашатның якасыннан эләктереп.

Рашат, иреннәрен мимылдатып, аңа нәфрәтле караш ташлап торганнан соң, ияге астына китереп сукты.

— Куйды диярләр!

Миңзаһит егылып кына калмады, идән буйлап мәтәлеп үк китте. Хәят йөгереп барып аны торгыза башлады. Миңзаһит авыртудан кычкырып җибәрде:

— Кагылма! — Ул уң кул сөягенең шытырдаганын ишетте. — Зинһар, кагылма...

Алар икесе дә ишеккә карадылар. Рашат аны ябып та тормыйча чыгып ычкынган иде.

— Хәзер «ашыгыч ярдәм» чакырам, — диде Хәят, телефонга йөгереп.

— Кирәкми! — дип кычкырды Миңзаһит.

Ул, авыр сулап, аксый-аксый атлап, кухня өстәле янына килеп утырды.

— Бәйләргә берәр әйбер алып кил, — диде ул Хәятка.

Хәят ашыга-кабалана иске простыняны ертып алып килде.

— Ике кашык бир.

Алар, ике аш кашыгын кара-каршы куеп, сынган беләкне простыня белән бәйләп куйдылар. Миңзаһит, кулының сызлавына түзә алмыйча, төне буе йөреп чыкты, анальгин йотты да анальгин йотты. Икенче көнне больницада аның кулына гипс салдылар.

## 11

Таңның иртәнге нурлары үзләренә генә хас төсләре белән инде эреп юкка чыкканнар, әмма әле кояш күренми иде. Зәнфирә тыштан керде дә, аяк очларына гына басып, караватянына килде. Иреккне уятудан куркып, акрын гына урынына ятты. Ул төнге күлмәктән генә, өстенә берни дә элмичә, галуш белән генә чыгып кергән иде, шуңа күрә одеалын ябынгач, туңудан дерелдәп куйды.

— Яз исе алып кердең...

Зәнфирә сискәнеп китте:

— Мин сине уятмаска тырышкан идем, — диде ул, ярым пышылдап. — Каргалар килгән...

Ирек кайнар гәүдәсе белән аңа елышты.

— Тәннәрем салкын, якын килмә, — диде Зәнфирә.

— Кая ул салкын?

— Менә бит! — Зәнфирә Ирекнең кулын үзенең тез башларына куйды.

— Син берничек тә салкын була алмыйсың, — дип пышылдады Ирек аның колагына. — Ник икәнен әйтимме?

— Әйт...

— Син бит минем җаным...

Ирек аның гәүдәсен үзенә таба борды да кысып кочаклады. Чыннан да аның аяклары, тезләре салкынча иде, ләкин бу Ирек өчен искиткеч рәхәт, моның нишләп шулай рәхәт икәнлеген аңлатып та булмый иде. Әйтерсең лә аның бөтен тәне уттай яна, Зәнфирәнең салкынлыгы шуңа дәва иде. Ул куллары белән аның иңбашларын, билләрен сыпырды, хатынының тәне тыгыз, биле яшь вакыттагыча нечкә, хәтта ябыграк та кебек тоелды. Зәнфирәнең беләгендә киндер орлыгы кадәр генә миң бар иде. Ирек иреннәре белән шул миңгә терәлеп туктап калды. Үзе күз чите белән генә Зәнфирәнең йөзен күрсәтте. Баллы Төбәк урамнарында тилереп йөргән Зәнфирә хәзер мәңгегә аныкы иде. Тузгыган кара чәчләренең уртасында яткан ак йөзе, кара кашлары, әле бер генә җыерчык та сызылмаган туры ак муены, матур иңбашлары — һәммәсе дә Иреккеке иде. Ирек аны кысып кочаклады да кискен хәрәкәт белән үз өстенә әйләндерде. Зәнфирә теләртеләмәс кенә елмая иде.

—Ник ялкау елмаясың?

— Әле табигать уянмаган бит, — диде Зәнфирә, тавышсыз гына көлеп.

— Зәнфирә, әйт әле, син безнең тормыштан канәгатьме?

— Син янымда чакта мин бар нәрсәдән дә канәгать.

— Кешеләр әнә машина алалар, ә безнең матаебыз да юк.

— Кирәкме соң ул, Ирек?

— Белмим. Ә шулай да миңа бер әйбер җитми.

— Нәрсә?

— Икебезгә ялан кадәр өй. Әгәр шушында бер бала йөгереп йөрсә?

Зәнфирә аның өстеннән шуып төште дә, кулларына таянып, Ирекнең йөзенә якынайды:

— Ни сөйлисең син?

— Нигә, бу мөмкин әйбер түгелмени?

— Акылыңа кил. Шушы яшьтә оялыр идең.

— Ә мин чынлап әйтәм, Зәнфирә. Менә безнең әби әтине илле ике яшьтә алып кайткан. Әллә тәвәккәллибезме? Тормыш бит дәвам итәргә тиеш.

— Минем малаем бар инде.

— Минем дә кызым бар. Ә уртак балабыз юк.

Алар икесе дә шактый вакыт тынып, сүзсез яттылар. Аннары Зәнфирә акрын гына сүз башлады:

— Мин бу хакта алдарак та уйлаган идем.

— Уйлагач? Ник тәвәккәлләмәдек?

— Ирек, син ришвәт бирә аласыңмы?

Ирек дәшмәде.

— Мин дә бирә алмыйм. Шулай булгач, без ул баланы ничек кеше итәбез? Ничек аны укытырбыз?

— Барлык кеше дә ришвәт бирми ич.

— Шуңа күрә укыта да алмый. Без инде бу әйберне кулдан ычкындырдык. Хәзер соң.

Ирек торып Ык буена чыкты, әлеге сөйләшүне тагын бер мәртәбә елмаеп хәтереннән уздырды, сүзсез генә баш чайкап куйды. Зәнфирә хаклыдыр. Ул ала сыер төсле булып кардан арчылып килүче каршыдагы тау битләренә, ап-ак булып кояшта җемелдәүче Ык өстенә карап торды. Аяк астында кештердәп торган кар кичәге йомшаклыгын югалткан, китереп баскан саен, ул кетердәгән тавыш чыгара. Шул тавышны тыңлый-тыңлый, Ирек ашыкмыйча гына үзләренең тыкрыгыннан чыкты да Болынкыр үзәгенә күтәрелә башлады. Унунбиш адым атларга өлгерә алмады, ниндидер аңлаешсыз тойгы, шушы яз һавасына зәһәр ис килеп кергәндәй, аның күңелен бимазаларга тотынды. Менә шактый вакытлар инде шушы халәт аны газаплый. Моның нәрсә икәнлеген Ирек төрлечә гөманлап караса да, һич тә ачыклый алмады. Югыйсә көндәгечә гадәти тормыш дәвам итә кебек. Бу тойгы өйдә дә, эштә дә түгел, нәкъ менә урамга чыккач, аягына килеп уралган эт эчәгесе кебек, күңелен талкырга керешә. Менә ул сыраханәгә якынлашты, аның алдында алты-җиде ир-ат тәмәке пыскытып, сөйләшеп тора иде. Ирек аларның арасында Бәкерне күреп алды. Әллә Иректе танып, әллә танымыйча, ул кискен генә әлеге төркемнән аерылды да сыраханәнең артына таба атлады. Күптән күренгәне юк иде инде Бәкернең, очраган чакларда да, кыенсынган кеше төсле, әллә ничек читтән генә, кырын-кырын карап, йөгерә-атлый китеп бара иде. Миргаяз да күренми. Ул, бер хатынга йортка кереп, аракы дигән нәрсәдән шактый ук ераклашкан, диделәр.

— Бәкер! — дип кычкырды Ирек.

Ләкин Бәкер туктамады, сыраханә артына кереп юк булды. Адымнарын кызулатып, Ирек аның артыннан атлады һәм, куып җитеп, иңбашына кулы белән шапылдатты.

— Исәнме, Бәкер!

— Исәнме...

Ирекнең борынына укшытырлык итеп махмыр исе килеп бәрелде. Бәкернең башында үзе теккән шул иске бүреге, өстендә зәңгәрсу кыштырдык куртка иде. Аның замогын алып ташлап, урынына сәдәф тагылган. Сәдәфләрнең сары, теккән җебенең кара булуы үзе үк әллә нинди кимсетелүле төс бирә иде. Аягындагы ботинкаларының баулары бушрак бәйләнгән, берсенең теле эчкә үк кереп киткән, күрәсең, ул аларны чишеп-бәйләп тормый — шул килеш сала, шул килеш кия. Курткасы кесә яныннан түш ягына таба ертылган,

ул, эре-эре атлатып, әлеге кара җеп белән тегелгән. Ирекнең шуңа күзе төшүен күреп, Бәкер теккән урынын кулы белән каплады.

— Мөгезе белән кәҗә ертты, — дип куйды ул, гаепле кешедәй.

— Ни хәлләр бар соң?

— Беркөе яшәп ятабыз... Алла бабай биргәнгә шөкрана итеп.

«Бик күп бирми торгандыр Алла бабаң» димәкче иде дә Ирек, Бәкер бу сүзләргә рәнҗер дип, телен тешләде. Әгәр ул шулай дигән булса, үзен Бәкердән өстен итеп күрсәтер иде. Ә ул моны һич тә теләмәде. Беркемнән дә ким булмаган, күпләргә караганда әллә никадәр һөнәрләр белүче бу гөнаһсыз җанга аның ярдәм итәсе килде. Ул кесәсеннән акча чыгарып Бәкергә сузды.

— Минем өчен дә тотып куярсың.

— Юк, кирәкми, рәхмәт...

Бәкер чигенеп китә башлады.

— Мин бит чын күңелемнән, — диде Ирек, ялварулы тавыш белән аңа ияреп. — Син миңа әллә рәнҗедең инде, Бәкер? Ни өчен рәнҗедең? Әйт.

Муеныннан кемдер тоткандай, Бәкер башын уңга-сулга боргалады, Ирекнең күзләренә туры караудан качты.

— Юк, нишләп инде... — дип мыгырданды ул, борын астыннан гына.

— Мин бит сизеп торам. Нишләп килмисең? Миргаяз да күренми.

— Төрлебез төрле юлдан йөрибездер... Юлларны бит кушып булмый.

Бәкер шулай диде дә сыраханәдән бөтенләй читкә таба атлады. Аның бу сүзләреннән Ирек куырылып калды. Бәкер артыннан барырга ниятләде дә яңадан кире уйлады. Аның «юлларны кушып булмый» диюеннән дә күп нәрсә аңлап була иде. Бу сүзләрне ул туп-туры Ireккә төбәп әйтте түгелме соң? Ирек аның баш төзәтергә акчасы юклыгын да сизде. Нигә алмады ул аның биргән акчасын? Димәк, үпкәләү зурдан. Ә нәрсә белән рәнҗетте икән аны Ирек? Райпо турына җиткәндә, аның ишегеннән чыгып килүче Николай Кузьмич күренде. Ул ашыга-кабалана машинасына утырды да Ирек кырыннан выжылдап китеп барды. Дөрес, итагатьле итеп баш иде, әмма бит ул бүтән вакытларда туктап, елмаеп, аның каршына колачын җәеп килә иде. Ун-унбиш минут буе күгәрчендәй гөрләп сөйләшә, чәйгә-мәйгә кыстый, баш тартсаң да, буйсындырмый калмый иде.

Ул музей эчендә, ят дөньядан килгән кеше кебек, бер максатсыз йөри башлады. Мамонт тешләрен кулы белән

сыпырды, бу тешләр арасына күпме җан ияләре сөякләре-итләре белән шытырдап өзелгәндер, чәйнәлгәндер. Бу тешләр миллион еллар элек күпме абага яфракларын, гигант агач ботакларын чәйнәгәндер. Ә менә бу пулемет пулясы обоймаларының тырылдый-тырылдый үлем кургашы түкергәненә әле ул кадәр ерак та түгел. Менә бу олы иләк белән безнең бабайлар чәчү чәчкән, бөртек иләгәндер. Тукта, ник болар турында уйлый соң әле ул? Алар бит аңа рәнҗемиләр, берсе дә үпкәләми. Шулчак музей ишеге ачылып китте, аннан башына папаха, өстенә иске солдат шинеле кигән, галифе чалбардан майор Шахмин килеп керде. Ул, үкчәсен үкчәгә шапылдатып, озын гәүдәсен турайтып басты да, уң кулын чигәсенә күтәреп:

— Майор Шахмин по вашему приказанию прибыл! — диде.

Картның килгән саен караңгылана баручы чырае бүген куркыныч төскә кергән иде. Аның маңгаен, күз төпләрен, битләрен сырлаган эре җыерчыклары караңгыланып тирәнәйгәннәр, борын тишекләре киерелгән, шаулатып сулыш алганы ишетелә. Бүренеке төсле зур соры күзләре куркыныч елтырый.

— Тагын нишләп йөрисең? — диде Ирек, аның каршына килеп.

Шахминны уздырырга ярамый, аның элек стендтагы әйберләрне төшереп вата язып киткәне бар иде.

— Ак... акча кирәк!

— Шахмин агай, бу бит Сберкасса түгел. Бер үк әйберне күпме тукырга мөмкин? Бу — музей.

— Мин музейга килмәдем, мин синең янга килдем.

— Ә оятың бармы синең?! — диде Ирек, тавышын күтәреп.

— Нәрсә кычкырасың син миңа, Сабитов? — Шахмин иске шинелен ычкындырып җибәрде, аның эчендәге яшел кителенә тагылган күпсанлы медальләре, значоклары ялтырап киттеләр. — Мин немец фашистларына каршы сугышта дүрт ел кан койган кеше. Дүрт ранением, алты медалем бар. Минем яраларым сызлый. Дару алырга акча бир дә чыгып китәм.

Шахминның башы вак дерелдек белән калтырарга тотынды. Картлар йортында тыныч кына яшәп ятучы бу кешенең аңа килеп бәйләнүен берничек тә аңлатырлык түгел иде. Ул Шахминның усал елтыраучы күзләренә карап торды да хәйләләргә кереште:

— Ярый, Шахмин агай, акча бирәм, тик яшермичә әйт: кем җибәрә сине миңа?

Шахмин бу сорауны көтмәгән иде, ул тамак кырып куйды,

ютәлләгәндәй итеп, учы белән авызын каплады, нәрсәдер мыгырданды... Аннары кинәт башын күтәреп, Ирекә карады.

— Мин үзем килдем. Ә-ә, ник әйткәнеңне беләм, авырганга әйтәсең... Акча бир дә, китәм.

— Кем җибәргәнен әйтмәгәч, бирмим! — Ирек кесәсеннән акча чыгарып күрсәтте дә кире тыгып куйды. — Сугыш ветераны дөресен сөйләргә тиеш.

Ирекнең бу сүзләре Шахминга коточкыч көчле тәэсир иттеләр, аның авызы ачылып китте, нидер уйлаудан күз алмалары әле уңга, әле сулга йөреште.

Фаҗигале язмышлы кеше иде Шахмин. Ничә еллар буе ул районда президиумнардан төшмәде, слетларда, тантаналы җыелышларда ялкынлы чыгышлар ясады, һәр елны уздырыла торган 1 Май, Җиңү көне, Октябрь бәйрәме парадларында ялтыравыклы погонлы яшел кителенә барлык медальләрен тагып, билен сары каеш белән буып, көзгедәй ялтыратылган хром итеге белән, байрак тотып, гөрс-гөрс басып, иң алда Шахмин бара иде. Аның артыннан атлаучылар да Шахминча күкрәкләрен ныграк киерергә, җиргә катырак һәм тигезрәк басарга тырыштылар. Ул беркайчан да хәрби киемен салмады. Солдат булып тудым, солдат булып үләм, диде. Әйбәт кенә яшәп ятканда, Шахминның карчыгы вафат булды. Шуннан соң Урта Азиядә яшәгән кызы, Болынкырга кайтып, шыңгырдап торган зур йортны эчендәге мебельләре-ниләре белән сатты да әтисен үзе белән алып китте. Ике ел үттемеюкмы, күз кабаклары зәңгәр буяуга катырылган, иреннәреннән башлап аяк бармакларына кадәр кып-кызыл итеп буялган шөпшә билле кыз, әтисен алып кайтып, картлар йортына урнаштырды да безелдәп кире үзенең Үзбәкстанына очып китеп барды. Бу вакытта Шахминның башында зур үзгәрешләр булды. Ул, вакыт-вакыт алышынып, картлар йортында яшәүчеләрне фашистларга каршы сугышка күтәреп, хикмәтләр ясады. Менә хәзер шушы кеше Ирекнең тормышына мәҗбүри бәреп керде һәм аны чыгарып ташлау мөмкин түгел иде.

— Әйтәм, иптәш Сабитов, — дип пышылдады кинәт Шахмин. — Тик аңа җиткерә күрмәгез, ул мине кыйнаячак. Мин сиңа... — Ул туктап калды һәм куркып як-ягына карана башлады, артына борылып, ишекне тартып куйды. — Безнең бухгалтер «Сабитовның безгә бирәсе акчасы бар» ди...

— Ярый, рәхмәт, Шахмин агай, — диде Ирек һәм аңа акча тоттырды. — Бар, даруыңны ал.

— Акчаны мин бухгалтерга бирәм, даруны ул алып кайта. Үземнең баш эшләми бит. — Шахмин чыгарга кузгалды да туктап Ирекә борылды: — Берүк әйтә күрмә, иптәш Сабитов, ату мине кыйный ул.

Аны озаткач, Ирек хәлсезләнеп үзенең эш өстәле янына барып утырды, ике чигәсен куллары белән кысып, терсәкләренә таянды. Картлар йортында бухгалтер булып эшләүче Әгъләм исемле түп-түгәрәк йөзле, монголныкыдай кысык күзле, тар маңгайлы, юка иренле, тәбәнәк гәүдәле кеше белән Ирекнең беркайчан да бернинди мөнәсәбәткә дә кергәне юк иде. Әгъләмнең эшкә баруына, эштән кайтуына карап, сәгать дөресләп була, шуңа күрә Ирек аны көндез эшкә барышлый ук юлда туры китерергә ниятләде. Ул уйларының очына чыга алмады, кемдер ишек шакыды.

— Керегез, ачык бит, — диде Ирек.

Ишектә затлы фуражка, кара күн куртка, шундый ук перчаткалар кигән төз гәүдәле кеше күренде. Ул ап-ак күлмәктән, куе зәңгәрсу сызыклы галстуктан иде. Кара кашларын, кара керфекләрен сирпеп сәлам биргәннән соң, перчаткаларын салып, аяк астына карады. Башын күтәреп:

— Музеегыз белән танышып булмасмы икән? — дип сорады.

— Рәхим итегез, — диде Ирек.

Кеше аңа бик серле итеп карагандай тоелды. Пөхтә итеп кырынган булса да, артык куе һәм каты төкләр аның яңагын, ияк турыларын бераз зәңгәрләтебрәк күрсәтәләр иде. Елмайган чакта аның тешләренең тигезлегенә һәм аклыгына сокланып куйды Ирек. Ул тавыш-тынсыз гына атлап узды да мамонт сөякләре каршында туктап калды.

— Сез нинди бай, — диде ул, гаҗәпләнеп. — Авыл музеенда шушындый экспонатлар бар дип кем уйлаган? Фоторәсемгә төшереп алырга мөмкинме?

— Төшерегез, — диде Ирек.

Ул, куртка кесәсеннән кечкенә фотоаппарат алып, мамонт сөякләрен фотога төшерде, аннары акрын гына һәрбер экспонатка туктала-туктала, юлын дәвам итте. Экспонатларны караса да, Ирек ничектер аның сиздермичә генә үзенә күз төшереп алгалавын чамалады. «Кем булырга мөмкин бу?» дип уйлады эченнән генә. Һәрхәлдә, киеменнән, үз-үзен тотышыннан аның Болынкыр кешесе түгеллеге ярылып ята иде. Музейны карап чykканнан соң, ул кесәсендәге перчаткаларын кияргә әзерләнде дә Ireккә туп-туры карап туктап калды.

— Бәлкем, сезгә берәр нәрсә аңлатырга кирәктер?

— Юк, кирәсенчә, миңа аңлатырга кирәк, — диде ул һәм сүзсез генә кулын Иреккә сузды.

Алар кул кысыштылар. Аның кулы шактый каты, спорт яисә физик хезмәт белән шөгыльләнгән булуын сиздерә иде.

— Мин Айдар исемле булам, — диде ул, карашын аска төшереп һәм гәүдәсен әле үкчәсенә, әле аяк очына таба атлан-

дырып. — Без инде Сөембикә белән яши башладык. Шуңа күрә танышырга кирәк дип санадым. Мөнәсәбәтләрне катлауландырмас өчен.

Шушы сүзләрне әйткәч, Айдар тынып калды һәм, башын күтәреп, үзенең тыныч карашын Ирекка төбәде. Бу карашта нәрсәдер көтү, сорау билгесе дә бар иде. Ирек ни әйтергә дә белмәде, бу очракта ике арадагы кыенлыкны ничектер юарга кирәк иде. Ул Айдарга көнләшеп карады. Чибәрлектә дисеңме, үз-үзен тотышында дисеңме, көч ягыннанмы — ул аны үзеннән өстен санады. Ирек Сөембикә каршында тоныкланып калу ихтималын тойды һәм моны сизү күңелдә чәбәләнү, каршы күтәрелү уятты. Ләкин Айдарның гаебе юк иде. Шуңа күрә ул күңелендә кайнаганнарны мәңге чыкмаслык итеп томаларга, онытырга теләде.

— Рәхмәт керүегез өчен, — диде. — Мин бит инде Сөембикәне сезгә караганда күбрәк беләм. Әгәр дә өстәмә мәгълүматлар кирәк булса, мин аларны җиткерергә әзер.

Шушы сүзләр барысын да хәл итте дә куйды. Аларның икесенең дә күзләрендә әллә нинди чая очкын уйнап алды һәм берьюлы тыелып кына көлеп куйдылар.

— Рәхмәт, — диде Айдар, тавышсыз гына көлүен дәвам итеп. — Турысын әйтим, мин икеләнеп кенә кергән идем. Ә менә хәзер үземә яңа дус табып чыгып китәм.

— Безгә шунсыз ярамый, — диде Ирек, кинәт җитдиләнеп. — Тормыш катлаулы, без, кешеләр, үтә нечкәрдек. Кемнең гаепле, кемнең гаепсез икәнен бер Алла үзе генә белә. Сезнең янда бит минем кызым. Бер генә теләгем бар. — Ул туктап тынып торды да Айдарның иңбашына кулын салды: — Аның белән килешүегезне, аңлашуыгызны бик тә, бик тә теләр идем. Әгәр шушы теләк тормышка ашса, мин сезгә иң якын, иң тугрылыклы дустыгыз булырга сүз бирәм.

— Пожалуй, дуслар булып калырбыз без, — диде Айдар, шулай ук җитдиләнеп.

— Бирсен Ходай.

Ул арада тышта машина туктаган тавыш ишетелде. Айдар тагын бер мәртәбә хушлашты да чыгып китте. Ирек ачык ишектән культура бүлеге машинасын һәм рульдә утырган Сөембикәне күреп калды.

— Йә, ничек? — диде Сөембикә, машинаны акрын гына кузгатып.

Аның йөзенә серле елмаю, шул ук вакытта кызыксыну билгеләре җәелгән иде.

— Миңа ул ошады. Чын ир кеше.

— Гашыйк була күрмә инде, — диде Сөембикә, көлеп.

Ул машинаны, ашыкмыйча гына алып барып, банк каршына туктатты.

— Минем кереп чыгасы бар иде, машинада гына көтәсеңме? — диде.

— Ярый, көтәрмен.

Сөембикә җитез адымнар белән банкка керде, Фәһимә бүлмәсенең ишеген ачты.

— Мөмкиндер бит?

— Әйдә уз.

Шулчак телефон шылтырады. Фәһимә трубканы алды да кеткелдәп көлеп җибәрде, һәм бик кәефләнеп кем беләндер сөйләшә башлады. Ул, аягын аякка атландырып, йомшак кәнәфиенә ярым ятты, ниләрдер сораштырды, кемнеңдер көлмәген, кемнеңдер туфлиләрен тикшерделәр, кайдадыр булган мәҗлес хәлләрен сорады. Сөембикә басып тора бирде. Ул, әлбәттә, утыра да ала иде, тик Фәһимәнең кул ишарәсе белән булса да урын күрсәтүен көтте, әмма андый ишарә булмады. Ниһаять, Фәһимә, трубкасын куеп, борылмалы кәнәфиен бераз гына турайтып, Сөембикәгә карады:

— Тыңлыйм.

Сөембикәнең йөрәге урыныннан купкандай булды. Фәһимәнең һәр хәрәкәтеннән, аңа карата битарафлыгыннан ул инде үзен өнәмәвен һәм бу керүнең көтелгән нәтиҗәне бирмәячәген аңлаган иде. Шулай да, ятып калганчы атып кал дигәндәй, ниятеннән чигенмәскә булды.

— Миңа ссуда кирәк иде, шактый гына күләмдә.

— Ссуда, ссуда... — дип кабатлады Фәһимә. — Ә нәрсәгә соң ул?

— Чыгым сорый торган эшләребез бар.

— Эшләрегез бар... — дип кабатлады Фәһимә, аның сүзләрен мыскыл итеп. — Яңа гаиләнең чыгымнары күп булыр шул...

Сөембикәнең күзләрендә зәһәр очкыннар кабынды.

— Фәһимә, — диде ул, тавышын күтәреп. — Син нәрсә минем белән уйнап маташасың? Бирәсеңме, юкмы?

Фәһимә өстәлендәге ручкасын очыннан гына тотып шакышокы телефон аппаратына бәргәләп торды.

— Нәрсә, иске дуслар киткәч, капитал туплап булмый башладымыни?

— Син чамалап, Фәһимә! — диде Сөембикә теш арасыннан. — Мин бит сине чырайсыз да калдыра алам. Ишек төбендәге милиционерың да кереп җитә алмас.

— Әйе, синнән барысын да көтәргә була. Күп эшләр майтардың, сөрдең дә, чәчтең дә...

— Ә мин синең җиреңә чәчмәдем. Нәрсә чәчсәм, шуны урып та алырмын.

— Урасың бит инде. Нәрсә урасың — анысын үзең беләсең.

— Тукта әле, Фәһимә, ни булды сиңа? Кергәндә үк мине чыраеңны җимереп каршыладың. Әллә мин синең юлыңа аркылы төштемме?

Фәһимә сикереп торды, ике атлауга аның каршына килеп басты.

— Кем юлына аркылы төшкәнеңне аңларлыгың да калмаган икән. Гомер буе дус булган булып йөрдең. Яңадан эзең булмасын безнең тирәдә!

— Син борыныңны артык чөймә әле, Фәһимә! Вакыт җитәр, син аны соңрак аңларсың!.. — Ул ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

## 12

Банктан Сөембикә күзләренә яшь тулган хәлдә, иреннәрен кан чыгарлык дәрәҗәдә тешләп чыкты, сүзсез-нисез машинасына кереп утырды, дөпелдәтеп ишекне япты һәм, коточкыч газ биреп, салулый-салулый кузгалып китте. Берничә йортны үтеп тыкрык турына җиткәндә, салулап төшеп китә язгач кына, Сөембикә газны киметте.

— Ни булды сиңа? — диде куркудан күзләре түгәрәкләнгән Айдар.

— Мин кемнәргәдер яшәргә комачаулыйм...

Сөембикә гел кирәк түгелгә йодрыгы белән машинасының сигналына басып куйды.

— Кемнәр? — диде Айдар, нәрсәдер аңларга теләп.

Сөембикә аңа җавап бирмәде, машинасын зырылдатып капка төбенә куйды да кызулап өйгә кереп китте. Айдар чишенгән арада, ул үзенең бүлмәсенә кереп капланып яткан иде.

— Сөембикә, нәрсә булды соң? — диде Айдар, җиңелчә генә аның иңбашына кагылып.

Мендәр астыннан Сөембикәнең:

— Башым авырта, зинһар, чыгып тор, — дигән сүзләрен ишеткәч, ул, авыр сулап, залга атлады, бераз уйланып торды да акрын гына ишегалдына чыгып китте.

Сөембикә тавышсыз гына үкседе. Айдар белән бергә булгач, өйдә яхшылап ремонт ясатырга уйлаган иде ул. Ссуда шуның өчен кирәк иде. Фәһимәнең бу дәрәҗәдә бәрелүе Сөембикә өчен көтелмәгән хәл булды. Ул моның сәбәпләрен эзләде, әмма таба алмады. Дөрес, газетада теге интервью чыкканнан соң, Әхнәф белән аларның мөнәсәбәте үзгәрде, әмма бүгенге бәрелүгә ул гына сәбәп була алмый иде кебек. Нәрсә соң тагын? Әллә инде Сөембикәнең Айдар белән торуына бик күпләрнеке кебек аның да эче поша башлаганмы?

...Айдар Болынкырда булып киткәннән соң, Сөембикә-

нең тормышы ничектер яктыргандай булды. Алар бер-берсенә бернинди вәгъдәләр бирешмәсәләр дә, аның киләчәген Сөембикә бөтен барлыгы белән тойды, һәм ул шулай булып чыкты да. Беркөн эштән кайтуга, аны Айдар ишек төбендә каршылады. Алар башта бер-берсенә, шактый озак дәшмичә, сынаулы караш ташлап тордылар. Бу үзенә күрә икесенең дә күңелләрендә нәрсә ятканын капшау кебегрәк халәт булды. Аннары Сөембикә, үзе дә сизмәстән, нишләптер көлеп җибәрде. Айдар аңа кушылды, һәм алар бер-берсен кочаклап алдылар, яңаклары яңакка тиюгә, икесе дә курыккандай читкә тартылдылар.

— Ә мин сезне көтмәгән идем, — диде Сөембикә, ишекне ачып.

— Ә мин көткәнсездер дип уйлаган идем. Кызганыч, ялгышканмын.

— Юк, ялгыш әйттем. Мин сезне нишләптер бүген көтмәгән идем.

— Дөрес көтмәгәнсез. Мин бүген һич тә килергә уйламаган идем. Ләкин нишләптер кубарылдым да чыгып киттем.

Алар әнә шулай ярым шаярып, ярым чын сөйләшеп өйгә керделәр, чишенделәр, ашарга утырдылар. Ашап алганнан соң, ул Сөембикәгә кесәсеннән алып алтын беләзек сузды.

— Менә миннән бүләк.

— Сез нәрсә?! — диде Сөембикә, куллары белән бүләкне кире этеп. — Шушы кадәр кыйммәтле әйберне мин ничек алыйм ди...

Айдар тыйнак кына итеп көлеп куйды:

— Ә кем әле бушка диде?

— О-о-о, түләүлемени?

Айдар җавап бирмәде, күз карашын аска төшереп бераз тын торганнан соң, Сөембикәнең иңнәренә кулын салды:

— Сөембикә, мин сездән башка яши алмыйм. Менә шуны әйтергә килдем.

Сөембикә бүлмәдән чыгып китте, бераздан кабат керде:

— Син барысын да уйлап бетердеңме соң, Айдар?

— Мин шуннан башка эш белән шөгыльләнмәдем. Сезнең яннан киткәннән бирле.

— Ә миңа уйларга кирәк. Әле бит Айгөл дә бар.

— Мин көтәрмен.

Аннары алар залга чыктылар. Сөембикә үзенең фотоальбомнарын алып килде, диванга утырып, шуларны карый башладылар. Аларның иңбашлары терәлеп-терәлеп алды, чәчләре чәчкә кагылды. Бу вакытта Сөембикә инде барысы да хәл ителгәнлеген, язмышлары кушылганлыгын аңлап бетерде, чөнки ул моның ничә көннәр буе шулай булуын теләгән иде. Ләкин хатын-кыз горурлыгы аңа: «Әйе, мин көткән идем,

мин риза», — дип әйтергә мөмкинлек бирмәде. Айдарның килеп керүе аның ничә еллар буе дәвам иткән ачынулы, хәсрәтле тормышына чик куя иде. Аннары ялгыз кешенең бары үзе генә аңлый торган коточкыч бер хәсрәте була. Ул хәсрәт — ялгызлыгыңны башкалардан яшерү. Әмма иң хәтәре — бәйрәмнәр, мәҗлесләр. Бәйрәмдә парлылар арасында ялгызлыгыңны берничек тә яшерә алмыйсың, мәҗлестә дә шулай. Парлыларның сиңа юнәлтелгән күз карашында кызгану күрсәң, бусы инде иң ачы яра — кимсенү була, еларга да күп калмый.

Айдар белән альбом карап утырганда, Айгөл мәктәптән кайтып керде. Ул, чишенеп, Айдар белән исәнләшкәч, кухняга узды һәм, ашарга әзерләп маташканда, үзе янына килгән әнисеннән шыпырт кына:

— Айдар абый тагы ник килгән? — дип сорады.

— Безне сагынып, — диде Сөембикә, елмаеп. — Килмәсен идемени?

Айгөл бер сүз дә дәшмәде, иңбашларын гына сикертеп куйды. Ул көнне кызы төнге икедә генә кайтты. Беркайчан да бу вакытка калмаган Айгөлне Сөембикә капка төбендә каршы алды:

— Бу гомер кайда йөрдең? — диде ул аңа, ачуланып.

— Урамда, — диде Айгөл, аның кырыннан ышкылып үтеп өйгә кереп китте...

Айдар Чаллыда бер бүлмәле квартира алган булып чыкты. Ике көннән соң Сөембикә аңа уңай җавап бирде. Икесе дә уртак фикергә килделәр, яшәп карыйк, барып чыкса — яшәрбез, барып чыкмаса — язмыш каргавы булыр, диделәр.

Айдарның кайтуы Болынкыр халкын кырмыска оясына таяк тыгып болгаткандай шау-гөр китерде. Гайбәт өстенә гайбәт таралды. Бу адәм Сөембикәнең беренче ире икән. Иреккә чыкканчы шуның белән яшәгән икән, диючеләр дә күп булды. Имеш тә, алар мәктәптә укыган чакта ук берберсенә кайнар мәхәббәт тотканнар, өйләнешкәннәр. Айдарны армиягә алгач, Сөембикә Иреккә чыккан, ләкин оныта алмаган, һәрвакыт очрашып торганнар. Ирек, шуны сизенеп, Сөембикә яныннан чыгып киткән. Шуны гына көткән Айдар бирегә кайтып төшкән...

Гайбәтләргә Сөембикәнең артык эче пошмады, әмма бергә яши башлагач, нишләптер әнисенең бер сүзе бик еш исенә төшә башлады: «Кызым, берүк кияүгә чыкма, нәкъ минем кебек булачаксың, без беркем белән дә тора алмаячакбыз». «Нишләп?» дип өзгәләнеп сорый иде аннан Сөембикә. «Чегән әйтте, уч төбемә карады да кыз чагымда ук әйтте. Сиңа, синең балаңа да гел яшерен ярату, яшерен очрашулар язган», — диде.

Гомеренең беренче өлеше караңгы авыл читәннәре, коймалары белән уратып алынган түгәрәк эчендә калды. Менә хәзер, бала ана карыныннан чыккан кебек, ул икенче яшәешкә күчеп маташа, үтә алырмы чикне, әллә чегәннең әйткәне тагын куып тотармы? Тормышның моңа кадәрге өлеше гаять тә буталчык, аңлаешсыз үтте, анда «мин райком секретарен яуладым» дип яшерен горурланулар, борын чөюләр белән бергә шул эше өчен газаплanулар, үз-үзеннән җирәнүләр бөтенесе бергә буталды. Җирәнде, бәргәләнде һәм тагын онытты. Бала чактан ук кешеләргә дә, үз-үзенә дә, әнисенә дә буйсынмас, башбирмәс иде Сөембикә. Әнисе: «Уйнарга чыкмыйсың!» — дип, маңгаена йодрык төеп тора, ә Сөембикә җаен таба, барыбер чыга, пычракка егыла, әнисе кыйный-кыйный, тирги-тирги өс-башын алыштыра. Ул тагын чыгып югала, тагын шул ук хәлдә кайтып керә. Урамда булмасын, мәктәптә булмасын, ихатада булмасын, маңгае, тез башлары, терсәкләре канлы яра, кутыр белән каплана, күгәрмәгән җире калмый иде. Сөембикә елый, бәрелмим, киемнәремне пычратмыйм, дип ант сулары эчә, кабат бәрелә, кабат пычракка бата...

Сүз дә юк, сак яши алмады ул. Авылда чакта, сазлыкка баткан кеше бәргәләнгәндәй, үзе кылган гамәлләрнең яхшымы-яманмы икәнен белештереп тә бетермәде. Ирек белән яшәгәндә, инде тәҗрибәле хатын иде. Аны үстерим, иҗатына мөмкинлек тудырыйм дип, төрлечә баш ватты, үзенчә чаралар эзләде һәм муеныннан пычракка чумды. Чуммыйча да мөмкин булгандыр, һәркем ансатрак юлны сайлый, күрәсең. Билгесезлек куркыта, шуңа күрә Сөембикә үзе белгән, үзе сыналган юллар белән эш итте...

Авыл турында уйласа, аның хәзер дә бала йоннары кабара. Кеше гомеренең иң якты, яшьлек дип атала торган чоры аның өчен коточкыч кичерешләр белән тулы, бастырылу кебек куркыныч хатирәләр рәвешендә күңелендә калган. Аларны Сөембикә әле хәзер дә оныта алмый, ул барысын да күрде. Әниләренең хатын-кызлар, ир-ат өерләре белән бергә эчкәннәрен, ызгышканнарын, өелеп сугышканнарын да күрде, тагын әллә нәрсәләр күрде. Күпме генә яшерергә азаплансалар да, күңел күзләре барысын да эләктереп барды.

Күршеләре Рабигаттәй Сөембикәгә гел бер сүзне туглады:

— Әниең сине әтиеңә охшатып ярата.

Бу сүзләргә Сөембикә күпмедер ышана, чөнки әнисе Даутның фоторәсемен ала да бик озаклап аңа карап утыра, тавышсыз гына иреннәре кыймылдый, күзеннән яшь ага иде. Кайчакларда ул, Сөембикәне кочаклап, шул рәсемне тотып, әтисе турында әллә нинди җылы истәлекләр сөйли иде.

...Әнисе кече якта җирән Фәйзрахман белән эчеп утыра.

Сөембикә идәндә курчак уйный. Әнисе аны кертеп яткыра, йокларга куша, юрган белән томалап чыгып китә, әмма Сөембикә шундук атылып аның артыннан чыга. Әнисе белән Фәйзрахман өстәлнең ике башында кара-каршы утыралар. Җирән Фәйзрахман яланаяк, иске тишек трикодан гына. Олы аякларын сузып, әнисенең аяк йөзенә китереп баса. Әнисенең аягы авыртадыр дип, Сөембикә борчыла, ачуы кабара, түземе беткәч, өстәл янына атылып килә дә нечкә тавыш белән кычкырып җибәрә: «Әнинең аягына бачма!» Кычкырып кына калмый, олы курчагын, сыйрагыннан тотып, Фәйзрахманның тезенә бәрә. Әнисе белән алар көлешергә тотыналар, нәрсәдер пышылдашып алгач, Җәүһәрия йомрысына карлыган вареньесы салып болгата, шул ачы да, баллы да әйберне Сөембикәгә йоттыра. Аңа рәхәт булып китә, ул көлә-көлә бии башлый, нишләптер әнисе белән Фәйзрахманның елмайган йөзләре дә, өстәл дә, урыны-урыны белән акшарын бозау кимергән морҗа да, түшәм-стеналар да әйләнә. Ул әнисенең кулына авып төшә дә әллә кая оча, онытыла...

Бөтергечтәй бөтерелгән, туры сүзле, усал Җәүһәрияне авылда яратмадылар. Аның хәтта фермага барганын-кайтканын да күрми калабыз, дип сөйлиләр иде. Әнисен, төнлә силос-фураж урласа да, тота алмадылар. «Җенледер син», — ди торган иде аңа әбисе белән бабасы. Көпә-көндез ындыр табагыннан ярты капчык ашлык шудыру да Җәүһәриягә берни тормады. Ару-талуның ни икәнен белмәде, фермада эшләде, басудагы чүгендерен эшкәртте, печәнен чапты, урманга барып утынын әзерләде, коймасын койды, үзе веранда корды, мал өе салды, кулында балта-пычкы, сәнәк-көрәк уйнап кына торды. Ат арбасына печән-саламны берүзе төяде, берүзе ташыды, берүзе өйде, алҗу дигән әйберне белмәде. «Миңа көнгә унбиш минут йокы җитә», — ди торган иде ул. Әнисе аракысыз да йөрмәде, ир-атлар белән эчте, алар белән күңел ачты, хатын-кызлар аңа оядагы йомыркаларны урлап эчкән саесканга карагандай шикләнеп, сөймичә карадылар. Аның турында, берүзе ун хатын-кызга, ун иргә тора, диделәр.

Әнисе аркасында Сөембикәгә дә «алма агачыннан ерак төшми» дип карадылар. Ә аның үзен бөтен кешедән дә яраттырасы килә иде. Моңа комачаулаганы өчен ул әнисен күрә алмады. Авылда Сөембикәне кызганучылар да табылды, «Әтиең булса, болай борлыгып йөрмәс иде, нинди кешене китәргә мәҗбүр итте бит, Алланың ачы каһәре төшкере», — диделәр. Бу сүзләргә Сөембикәнең котырып ачуы чыкты, ул үзен кызгануларын һич кенә дә теләмәде. Мондый чакларда холыксызланды, кулына эләккән әйберләрне алып томырды, әнисе белән талашты, түзә алмаса, чыгып утын ярды,

бакча казыды, күрәлгән карларны кабат күрәде, күңелендәге ачуны баса алмыйча иза чикте. Күңеле утырган, тыныч кына йөргән чакларда да ул караңгы бу тормышны күрә алмады. Бу күралмау тойгысында ачу белән кызгану икесе бергә катышып буталган иде. Ачу дип ул бернигә дә каршы чыга алмады, кызганам дип беркемгә дә булыша алмады. Аларның кечкенә Таңтугай авылы диңгез уртасындагы ялгыз утрау кебек яшәде, бердәнбер юл мәктәпкә, клубка, кибеткә, колхоз үзәгенә генә бар иде. Сөембикәне бер уй — авылдан ничек булса да чыгып качарга дигән уй гына биләде. Ул аңа шулкадәр нык үтеп керде, Сөембикә үзе артыннан йөргән егетләргә дә игътибар итмәде, кем булуларына карамастан, бер сүз белән кире борды. Насыйбына язган егетләрнең юньлерәк җирдә — якты, шау-шулы шәһәрләрдә күтеп торуларына аның иманы камил иде. Шуңа күрә авыл каргалары белән вакыт уздырырга теләмәде, алар белән чуалырга дәрте дә булмады. Авылдан качу теләге тегенди-мондый шаяруларга урын калдырмагандыр, күрәсең.

Сөембикәнең теләген белгән бабасы, аны янәшәсенә утыртып, сабыр гына үз уйларын сеңдерергә теләде:

— Онытма, кызым, чын тормыш авылда гына, — дия иде ул. — Шәһәргә качу — чын асылыңнан качу. Анда ясалма корылмалар, ясалма тормыш.

Аның сүзләрен Сөембикә колак очларыннан уздырды, мәдрәсә белемле үткән заман кешесе каян аңласын аларның уй-хыялларын, дип уйлады. Ә бабасы һаман төрле яклап суктыра бирде:

— Әнә Фәйзрахман абыең белән әниеңне дә шәһәр аерды. Югыйсә бала чактан ук гел бергә булдылар. Әллә ниләр эзләп авылдан чыгып китте, шул китүдән зимагурлыкта йөрде. Ул кайтканда, әниең әтиеңә чыккан иде инде. Әтиең киткәч тә әллә ничә мәртәбә күз яшьләре белән сорап килде...

Бәргәләнгән-йөдәгән чакларында Сөембикәнең бердәнбер таянычы әнисе белән бертуган Мөнир абыйсы булды. Акыллы кеше иде Мөнир Кәбиров. Шулай булмаса, гомер буе әле авыл Советы председателе, әле партоешма секретаре итеп эшләтмәсләр иде. Кәшифулла мәсхәрәләп, үзен шау-шу кубарудан туктатып калгач, ул Мөнир абыйсына Аллага караган кебек карый башлады. Аның никадәр хаклы булганлыгын Сөембикә соңрак аңлады. Унберенче класста укучы бер кыз алданып, шау-шу кубаргач, ул кызга бөтенесе бармак төртеп күрсәтергә тотынды, ачыктан-ачык мыскыллады, ир-атлар оятсыз тәкъдимнәр ясады.

Кәшифулла белән булган вакыйгадан соң Мөнир Кәбиров кайбер нәрсәләрне Сөембикәгә ачыктан-ачык сеңдерде:

— Менә синең гөлең бар, утыртырга савытың юк. Атың бар, арбаң юк — кешедән алып торасың. Синең иң зур хыялың — авылдан чыгып китү, кая да булса урнашу. Аны тормышка ашырырга синең мөмкинлегең юк, ә бит сиңа ярдәм итәрдәй кешеләр бар. Шуларны табарга, файдаланырга кала. Ничек итеп булса да алгы планга төп мәнфәгатьне куясың. Бу — тормышның Конституция кебек төп кануны.

Ул әйткән фикерләрнең асылына әүвәл бик үк төшенеп җитә алмады Сөембикә. Әнисенә җинаять эше ачылып, авылга тикшерүче Янчурин килеп йөри башлагач, Мөнир абыйсы үз фикерләрен тагы да аңлаешлырак итеп җиткерде. Сөембикәне олы курку биләде, ул хурлыклы упкынга сикерергә теләмәде, ләкин абыйсы каты бәрелмәде, аның эчке халәтен күреп, бу гамәлләрнең зарурлыгын дәлилләп күрсәтте. Шундый сөйләшүләрнең берсендә Сөембикә ярсып китте. Аңа әллә нинди гаепләү сүзләре ташлады, бу адымга беркайчан да бармаячагын әйтте. Ләкин Мөнир Кәбиров үзенә ташланырдай булып ярсыган Сөембикәгә бик тыныч карады.

— Ярар, сеңлем, — диде ул, бераз үпкәләгәнрәк тавыш белән. — Мин сиңа үз тәҗрибәмнән чыгып ярдәм итәргә теләдем. Һавада очып йөрү әйбәт нәрсә, анда иркенлек, чисталык. Горур яшә, саф кал, әмма тәнең белән син менә шушы пычрак фермада аунаячаксың, сине авыл хатыннары язмышы көтә. Ирең дә булмаячак, күреп торасың, чын егетләр инде әллә кайчан авылдан качты, калганнары җыен әтрәкәләм, егет аламалары гына. Менә син шунда якты кояш кебек саф, горур булып яшәрсең.

Аның бу сүзләре Сөембикәнең колак төбендә әллә ничә көн яңгырап торды. Уйлана торгач, ул аңа елап барды. Әмма Кәбиров дәшмәде, аны шул хәлендә калдырып чыгып китте. Шактый вакытлардан соң гына йомшап, яңа киңәшләрен бирә башлады:

— Мәхәббәт, гаилә юк икән — кыска, очраклы очрашулар тормыштагы уен гына, — диде ул. — Хыянәт тә, бозыклык та юк. Авыл кешеләренең тормышын кара. Әнә кемнәр кем белән генә буталмый. Яшәеш буыннан буынга шулай дәвам иткән. Тәннең дә, җанның да үзенчә яшисе килә...

Сөембикә булдыра алганча читкә тартылып азапланды, ләкин инде, өстенә өй биеклеге булып килүче рәхимсез дулкын алдында калган кешедәй, үзенең көчсез икәнлеген аңлады. Аның бу карышуы соңгы талпыну, тел белән генә карышып азаплану иде. Янчуринның эшне төгәлләп судка тапшырыр вакыты җиткәч, сузарга мөмкинлек калмады. Соңгы очрашуда Кәбиров аңа:

— Җир йөзендә әнидән дә кадерле җан иясе юк, — диде. — Аны утыртсалар, икегез дә һәлак буласыз. Әгәр

Янчурин сиңа шундый тәкъдим ясаса, әниең хакына... Аңла, әз генә чигенүдән берни дә булмый. Әз генә, чепети генә чигенү...

Янчуриннан соң Шәвәлиев белән очрашуга Сөембикә өлгереп җиткән иде инде. Бу кызык уеннан үзенчә тәм табарга да өйрәнде ул. Кая таба тәгәрәгәнлеген бик соңарып аңлады.

Сөембикә Мөнир абыйсы ярдәмендә бер көйгә тирбәлә-тирбәлә акты да акты. Аңа үзенә юл ярырга кирәк түгел, бөтенесе әзер, күрсәтелгән, шул кушылган ихтыярга буйсынырга гына кирәк иде. Ярның әле бер, әле икенче ягыннан абыйсының ышанычлы сүзләре аны озата барды:

— Аңла, бөтенесе вакытлыча... бөтенесе дә узачак. Аннары яңа тормыш башлыйсың... Ә хәзергә тешеңне кысып түз — котылу юлы бары шушы гына...

— Кеше үзен гомер буе ваклап-ваклап башкаларга өләшә...

Мөнир Кәбировның бик күп сүзләре мәктәптә өйрәтелә торган, газета-журналлар, радио-телевизор аша туктаусыз сеңдерелә торган югары әхлак нормаларына тәңгәл килә иде...

Хатирәләр, елларны сикерә-сикерә әлеерактагы үткәннәргә, әле бүгенгегә кайтып, аны бик озак уратып йөрттеләр. Ул залга чыкканда, кызы телефоннан сөйләшә, Айдар өстәл янында газеталар укып утыра иде. Айгөл берничә кыска сүз белән трубкага нидер әндәште дә, кинәт Айдарга борылып:

— Сез нишләп минем сөйләшкәнне тыңлап утырасыз? — диде.

Айдар сискәнеп китте һәм урыныннан сикереп торды. Ул кулындагы газетасын бөгәрләп күкрәгенә кысты.

— Гафу ит, Айгөл... Мин синең сөйләшкәнне тыңларга теләмәдем, газета укый идем.

— Тыңлыйсыз! — диде Айгөл, ачулы тавыш белән. — Сез һәрвакыт мин сөйләшкәнне тыңлыйсыз!

Айдар газетасын куйды да башын игән хәлдә акрын гына өйдән чыгып китте. Сөембикә Айгөлнең сөйләшеп бетергәнен көтте дә аңа ияреп кухняга чыкты. Кызы мәктәптән кайтып ашарга утырган булган икән. Ул, чәнечкесенә үрелеп, котлет ашарга керешә. Сөембикә аркасы белән кухня шкафына сөялде, кулларын күкрәк турына баглап куйды.

— Кызым, нигә син аңа каты бәреләсең? — диде ул, ялварулы тавыш белән.

— Минем сөйләшкәнне тыңламасын.

— Сәбәп аңарда түгел бит. Син аңа һәрвакыт яратмыйча карыйсың. Айдар абыеңның сиңа бернинди начарлык кылганы юк. Ул синең өчен дә, минем өчен дә якын кеше. Ә син аны һәрвакыт гел авыр хәлгә куясың.

— Ярар, моннан соң гел елмаеп кына торырмын...

— Синең ясалма елмаюың кирәкми. Без кешеләрчә яшәргә тиеш. Син аны көнләмисеңдер ич?

Сөембикәнең бу сүзләренә Айгөлнең күзләре очкынланып китте, бит очлары кызарды.

— Мин көнләмим. Әгәр ул сиңа бик кадерле булса, үзеңнең бүлмәңдә генә тот.

Айгөл сикереп торып чыгып китмәкче булды, ләкин Сөембикә аны беләгеннән эләктереп алды. Икенче кулы белән яңагына чалтыратырга кизәнәм дигәндә, ничектер үз-үзен җиңеп, тыелып кала алды.

— Бу сүзләрең белән син мине бик нык рәнҗеттең, кызым, — диде ул теш арасыннан.

Айгөлнең кулын җибәрде дә кызулап ишегалдына чыгып китте. Айдар бакчадагы чатырга утырган да күзләрен йомып хәрәкәтсез калган. Бильярд шарыдай түгәрәк сап-сары «антоновка» алмаларының иң түземлеләре дә өзелеп җиргә коелып бетеп килә. Каршына Сөембикә килеп басуга, Айдар күзләрен ачты, ләкин карашын читкә алды.

— Менә тагын көз җитте, — диде Сөембикә, зәңгәр күк йөзенә, агач ботаклары арасыннан офыкка тәгәрәп баручы кояшның кызгылт нурларына карап. — Яфракларда җәйге яшеллек юк инде...

— Быел көз аяз булачак, кыш җылы килер, дип язганнар. — Айдар бармакларын чатыр өстәлендә биетте, андагы биш-алты алманы урыннарыннан күчергәләп куйды. — Ә миңа нишләптер быел кыш бик салкын булыр күк тоела.

Сөембикә аның янәшәсенә килеп утырды, күзләренә туптуры карады.

— Сиңа бик тә кыен, Айдар. Без бит кулга ияләшмәгән кыргый җәнлек белән бер...

Айдар аның чәченнән сыпырды да, елмаеп:

— Бар, чиләк алып кил әле, — диде.

— Ник?

— Коелган алмаларны җыйыйк.

Сөембикә зәңгәр чиләк алып килде. Алар чүгәләп алма җыя башладылар. Берчакны, бер-берсенә якынаеп, иңбашлары терәлде. Айдар, бер зур гына алманы алып, Сөембикәнең иңбашына сөрткәндәй итте дә шартлатып тешләп алды, аннары аңа сузды. Сөембикә дә тешләп алма капты. Алар парлашып авызларындагы алмаларын тәмләп чәйни башладылар.

— Әйбәт кеше син, Айдар, — диде Сөембикә, пышылдап.

— Синең белән мин башкача була алмыйм...

Айдарның тавышы шундый ягымлы, йомшак, елмаюы серле иде.

## 13

Бүген Әхнәф өчен үтә дә җаваплы көн көтелә иде. Шул дәрәҗәдә җаваплы, хәтта ки әле аның район белән җитәкчелек иткәндә мондый көнне кичергәне дә булмагандыр. Бүлмәсенә Әнәс Нәбиуллин килеп кергәч, ул аның махмырдан бозылган йөзенә бәйләнеп торуны да кирәк тапмады. Нәбиуллин, аның белән күрешкәч, түшәмгә сикерергә әзерләнгәндәй, каршысында катып калды.

— Барысы да булдымы? — дип сорады Әхнәф.

— Барысы да әзер.

— Кичке дүрткә, икәү генә барачакбыз, башка беркем дә булмый. Кисәтеп куям, һәммәсе дә үзеңнең өстә. — Әхнәф, туктап, бармагы белән өстәлне шакылдатып, бераз уйланып торды. — Тәк... Зәлия белән Сылу. Аңладыңмы?

— Аңладым, — диде Әнәс һәм чыгарга борыла башлады.

— Ашыкма. Теге синең супермастерың кайчан була?

— Менә бүген Чаллыдан урармын дигән идем дә...

Әхнәф аның сүзеннән йөзен җыерып куйды.

— Нәбиуллин! Ташла инде мине гаепләвеңне!

— Нишләп гаеплим ди...

Әнәс, башын уң як җилкәсенә таба кыегайтып, канат астына тыгарга әзерләнгәндәй, җыерылып бөтен гәүдәсе белән кәкрәйде.

— Гаеплисең бит. Бүген Казаннан олы кунак киләсе булмаса, Чаллыга барып, теге останы юлласы булгансың. Ярамый алай. Үзеңнең өеңне бик тиз тоттың син между прочим. Ярый, ярый, миңа куркып карама, акланырга да азапланма. Күрмәдем бит инде, чөнки күрергә теләмәдем. Ә мин синең ул вәгъдә иткән штукатурчыларыңны көтәм.

— Иртәгә үк Чаллыга китәм, — диде Әнәс, карлыккан тавыш белән.

— Әле иртәгә мен дә утыр киртәгә ул. Алла кулында. Хуҗа — кунакның ишәге. Китәрме-юкмы — билгесез. Ярый, бар, — диде ул, йөзен чытып.

Әнәс парга әйләнгәндәй юкка да чыкты. Күпме кешеләр белән эшләде Әхнәф үз гомерендә, әмма Нәбиуллин кебеген тапмады. Төзәлүгә таба үзгәрә торган бәндә түгел иде ул. Аны Әхнәф бер ягы өчен тота: теш арасыннан сыңар сүз дә чыкмый. Аннары куркытылган кеше буларак, ау эте кебек, күзгә карап, боерык кына көтеп тора...

Кара джип Ык буендагы комлы юлдан боргалана-сыргалана алга элдерә. Әхнәф рульдә үзе, янәшәсендә Николай Николаевич. Ул, табигатьтән күзен ала алмыйча, тел шартлатып, соклануын белдереп бара. Олы кунак эш белән кил-

мәде, ул Чаллыда кунарга яисә Казанга кайтып китәргә тиеш иде. Аның күңеленә ачкыч табу, Болынкырга барырга ризалату өчен Әхнәфкә барлык танышларын, дусларын туплап өч-дүрт көн эшләргә туры килде һәм барыбер ул үз дигәненә иреште: Николай Николаевич эш белән түгел, ял итәргә килде. Бу инде җиңү, бу инде киләчәккә кулына эләккән кендек җебе.

Әхнәф машинаны сулгарак, текә булып күтәрелеп торучы калкулык ягына борды. Аның итәкләрендә кызыл кыршау төсле булып шәрәләнгән җирләре күренеп тора. Ул җирләрдә тезелешеп утырган байбаклар сызгыралар, аларның тавышын тыңлату өчен, Әхнәф, машинаны туктатып, кунакны җиргә төшерде, кулына бинокль тоттырды. Байбаклар илен, офыкларга кадәр сузылган Ык буе тугайларын, әрәмәләрне, зәңгәрсу өрфия артында серле булып күтәрелгән ярларны күзәткәч, Николай Николаевич биноклен күзләреннән алды да байбак төсле сызгырып җибәрде:

— Рәхәт яшисез, матурлык дөньясында, на черта бөтенесен ташлап, әллә шушында кайтасы инде, ә?

— Рәхим итегез, сезнең өчен барысын да эшлибез.

Кунак, тирә-юньдәге әрәмәләрне яңгыратып, гөлдерәп көлеп җибәрде:

— Хәйләләмәгез, Әхнәф Хәсәнович! Монда кайтсам, түрә булудан туктыйм бит мин. Түрәлектән түбәнрәк төшә барган саен, табаныңны яларга әзер торучылар кими бара.

Алар кузгалып киттеләр. Бераздан джип Ыкның серле бер почмагына килеп туктады. Елга, агышын үзгәртергә уйлап, сул як ярының бер урынын ярып кергән-кергән дә, тирә-юньдәге болытларга җитеп торган наратларның, имәнюкәләрнең, каеннарның тамырлары белән ныгытылган җирне ашый алмыйча кире чыгып, элекке эздән агышын дәвам иткән. Ә бу сөзәк яр эченә уелып калган култык шулкадәр тыныч, җилсез, агымсыз, әйтерсең лә ял итү өчен махсус эшләп куелган бер урын иде. Су читендәге ак, сары йодрыктай эре чәчәкләрдән хуш исләр тарала, каеннар инде бармак бите кадәр генә елтыравыклы яфраклар чыгарганнар, юкә белән имән агачларының бөреләре бүрткән, җылы җитмәүдән генә ачыла алмый утыралар. Аларның исе күңелләрне дулкынландырып, йөрәкләрне сикерергә мәҗбүр итә. Николай Николаевич белән алар су кырына килеп карап тора башладылар. Ул бик тә сай, чиста иде, аның төбендә мүкне хәтерләтүче суүсемнәр, әкәм-төкәм кабырчыклары, тагын әллә нәрсәләр микроскоп белән карагандай җемелдәп торалар. Николай Николаевич чүгәләде дә, күпереп торган бер зур ак чәчәкне эләктереп, үзенә таба тартты. Чәчәкнең сабагы чәнти бармак юанлыгы бар иде, ул күпмедер су өстеннән

сузылып тартылды-тартылды да кинәт өзелде, өзелгән җиреннән сабак Николай Николаевичның көрән чалбарына килеп тиде һәм аннан аккан сузынкы сары сүл тез турына сыланды. Әхнәф, ап-ак кулъяулыгын чыгарып, аны сөртергә үрелде, ләкин кунак:

— Кирәкми, үзем... — дип, кулъяулыгы белән чалбарын сөртергә кереште. Юешләп ышкыгач, берни дә калмады тагын.

— Менә бит безнең чәчәкләргә кадәр ничек яраталар сезне, Николай Николаевич, — дип куйды Әхнәф, кыен хәлдән котылу өчен.

Алар джип эчендә шактый эсселәгәннәр иде. Агачлар арасында әкият өен хәтерләтүче ике катлы йортка тирләп-пешеп килеп керделәр. Шактый зур бүлмәдә искиткеч мул табын әзерләнгән, андагы ризыкларны санап кына бетермәле түгел иде. Николай Николаевич шундук эре су тамчылары белән капланган кувшинга үрелде һәм бер стакан чия согы салып эчте. Ул да булмады, аларның каршына ике кыз чыгып сәлам бирде. Алар икесе дә бер буйда булсалар да, бер-берсеннән аерылалар иде. Берсе искиткеч зур зәңгәр күзле, кып-кызыл калын иренле, озын керфекле, күпереп торган ап-ак чәчләре, әкиятләрдәге серле шарлавык төсле, иңбашларына таралган. Икенчесе кысыграк күзле, юкарак иренле, шоколад төсендәге көрәнсу шома йөзле кыз булып, ул энҗе тешләрен күрсәтеп, туктаусыз елмая иде. Николай Николаевич шикәрдәй ак тәнле, ак чәчле кызның күзләренең көзге аяз күк йөзе төсле төпсез һәм моңсу икәнлегенә игътибар итте. Менә шул күзләр тирәсендәге озын кара керфекләре, коңгырт кашлары тетрәнеп куйганда, ул үзен әллә кая очкандай итеп сизде. Кызлар икесе дә үтә күренмәле алсу кимонодан, тик ул кимоноларның итәк өлешен бар дип әйтү шактый кыен иде.

— Ягез, кызлар, нәрсә белән сыйлыйсыз? — диде Әхнәф.

— Әгәр сезне канәгатьләндерсә, язгы окрошка, — диде кызларның зәңгәр күзлесе.

Әхнәф кунакка сораулы караш ташлады.

— Пойдет, — диде Николай Николаевич.

Алар юынып өстәл янына утыруга, кызлар поднос белән окрошка китереп тә җиткерделәр.

— Үзегез дә утырыгыз, — диде Әхнәф.

Табын түгәрәкләнде.

— Менә бусы Зәлия исемле була, — диде Әхнәф, тутырылган рюмкалы кулы белән зәңгәр күзле кызга ишарәләп. — Ә менә бусы Сылу исемле.

Әхнәф, килгән кунакның зурлыгы, республикада тоткан дәрәҗәсе, аның Болынкыр җиренә аяк басуы зур бәхет икән-

леге турында сөйләде, Николай Николаевичка теләргә мөмкин булган барлык теләкләрне теләп, беренче тостны тәкъдим итте. Алар дүртесе дә эчеп куйдылар һәм мәҗлес шуның белән, язгы гөрләвек акрын гына юл ярган кебек, үзенең тиешле юнәлешен алды. Тостлар әйтә-әйтә ашап-эчә торгач, күңелләре җыр-моң сорады. Әхнәф бармакларын селкетеп кызларга ишарә ясауга, аңа әллә нинди ялтыравыклар белән бизәкләнгән тальян гармун китереп тә тоттырдылар. Ул өздереп «Авыл көе»н уйный башлады һәм тенор тавыш белән җырлап та җибәрде. Әхнәфнең гаҗәпләнүенә каршы, Николай Николаевич үзенең баритон тавышы белән җырга кушылды. Ул үзе җырлады, үзе эченнән генә, бу нинди милләт кешесе икән, фамилиясе дә урысныкы, аны белүчеләр дә урыс диләр, шул дәрәҗәдә татар телен, татар моңын ничек үзләштерде икән, дип уйлады. Аларга кызлар да кушылгач, кәефләр бөтенләй күтәрелеп китте. Шактый җырлашып утырганнан соң, тагын ашап-эчеп алдылар, Әхнәф бию көен сызып җибәрде. Кызлар парлашып татарча да, башкортча да, молдаванча да биеделәр, һинд биюен дә башкардылар. Чират танцыга җитте. Магнитофоннан җанны иркәләүче көй яңгырауга, Николай Николаевич Зәлияне танцыга чакырды, Сылу белән Әхнәф тә биергә керештеләр. Бүлмәгә искиткеч серле моң җәелде, гәүдәләр гәүдәгә сыланды, колакларга иреннәр нәрсәдер пышылдады. Менә бервакыт Николай Николаевичның кулы Зәлиянең бил турыннан күлмәген акрын гына өскә таба сыпыра башлады. Моны Әхнәф күз читләре белән генә күреп алды, күлмәк күтәрелгәннән-күтәрелә барып, аның итәк очы Николай Николаевичның кулына ук менеп җитте. Алар әкрен генә оеп биегән хәлдә шуннан ерак булмаган ишеккә якынлашалар иде. Килеп җиткәч, Зәлиянең үрелеп ишекне эчкә эткәне күренде һәм алар шунда юк булдылар. Сылу белән Әхнәф бер-берсенә елмаеп караштылар һәм, биюдән туктап, каршы яктагы бүлмәгә юнәлделәр...

Сүз берләшкәндәй, ике пар ике ишектән нәкъ бер вакытта чыкты. Бераз утырып алгач, Әхнәф белән Николай Николаевич саунага кереп киттеләр. Ул уттай кызу, коры һәм чиста иде. Дүрт каен себеркесе пешереп куелган, аларга тыгылган мәтрүшкә, бөтнек сабаклары, юкә, имән, миләш ботаклары — һәммәсе үзенә генә хас ис чыгарып, бөтенесе бергә кушылып, һавада бер куе ширбәт хасил иткәннәр. Пыяла шешәдә торган хуш исле үлән суын учына салып, Әхнәф ике мәртәбә ташка җибәргәч, ут булып кызган ташлар торс итеп кенә куйдылар, куе, эссе һава бер генә мәртәбә тирбәлеп алды да шул килеш тынды. Алар, тир чыгарып, ун-унбиш минут утырдылар, тәннәренең тулысынча кызып бетүен көт-

теләр. Кунакны Әхнәф ләүкәгә менәргә чакырды һәм, ул яткач, пар себерке белән чабарга керешге. Үзе туктаусыз шешә борыныннан хуш исле суны ташка сала торды. Николай Николаевич, рәхәткә чыдый алмыйча, ах-ух килде, «җитте» дип кычкырды, ләкин үзе ләүкәдән төшәргә ашыкмады. Бөтен тәне, йөзләре кып-кызыл булган кунак, ниһаять, ах-ух килеп, ләүкәдән аска үрмәләде. Әхнәф үзенең озак чабынуы, хәле бетмәве белән күпләрне таң калдыра иде. Ул күп итеп эссе салды да маймыл җитезлеге белән ләүкәгә менеп китте. Ике кулына ике себерке тотып, башына кигән эшләпәсен батырыбрак куйды да ут өертеп чабынырга керешге. Николай Николаевич аңа астан шаккатып карап торды.

Ахырда алар, күрше бүлмәгә чыгып, бассейнга чумдылар. Аннары, озын калып сөлгеләр белән сөртенеп, залга чыктылар. Кызлар аларны салкын сыра салынган бокал тотып каршыладылар. Күбекле бу эчемлек әлеге эсседән соң үзенең һәр йотымы белән тәнгә көч-куәт, әйтеп бетермәслек дәрт өсти иде. Сыраны яртылаш эчкәч, алар, ашыкмый-кабаланмый, бер-берсенә серле караш ташлап, тагын табынга юнәлделәр. Бер рюмка аракы эчкәннәр иде, Николай Николаевич сикереп торды да:

— Мин кызларның икесе белән дә биергә телим! — диде.

Магнитофонда бию көе яңгырады, ул, кызларның икесен дә кочып, акрын гына әйләндерә башлады. Николай Николаевич кызларның икесен берьюлы ике кулы белән күтәрде дә баягы бүлмәгә алып кереп китте. Анда чыр-чу килгән тавышлар ишетелә башлауга, Әхнәф эленеп торган зәңгәр халатны алып киде дә яланаяк килеш кенә тышка чыкты. Иң элек нишләптер йортның һәр ноктасын карый-карый әйләнеп чыкты, телекамера эше әйбер юкмы икәнен тикшерде. Әнәс агачлар артына ук куелган машинасы янында басып тора иде. Әхнәфне күрүгә, ул тыны-көне бетеп йөгереп килеп җитте:

— Әллә берәр нәрсә кирәкме, Әхнәф Хәсәнович?

— Молодец, Нәбиуллин! Бүген сиңа бишле! — диде Әхнәф.

Әнәс аның бу сүзләренә, чын әйтәме бу дигәндәй, башта куркып, сагаеп карап торды, хаклыгына ышангач, канәгатьләнеп елмаеп җибәрде.

— Килүче-китүче юктыр бит?

— Тып-тыныч.

— Шулай булсын.

Шактый вакыт урман сукмагыннан йөреп кергәндә, Николай Николаевич белән кызлар табын янында гөрләшеп утыралар иде.

— Әхнәф Хәсәнович, мин сиңа ачуланам, — диде кунак, шактый исерек тавыш белән.

— Ә мин сезне ачуландырмас өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләячәкмен.

— Нишләп сез Зәлияне теләсә нинди карчык-корчыкларда яшәтеп ятасыз? Алтын кебек кызны.

— Алтынга пычрак ябышмый ич, — дип шаяртып котылмакчы булды Әхнәф.

— Ябышырга да тиеш түгел! Син менә шушы минутта безнең барыбызның да күз алдында аңа аерым бүлмә ясыйм, диген. Квартирамы ул, тулай торакмы, менә шушындыйрак хан сараемы, — Николай Николаевич хихылдап көлеп алды. — Тик аерым бүлмә булсын.

— Сез әйткәч, һичшиксез, булачак. — Әхнәф, моменттан файдаланып, күптән әзерләнгән уен тузын ыргытты: — Ә менә безнең Сылу Казанга укырга керергә җыена. Кемнәрнеңдер ярдәменнән башка гына керә алмастыр ул.

Николай Николаевич тагын көлеп җибәрде.

— Сезне яһүд малае дип юкка гына атамыйлар икән, Әхнәф Хәсәнович! Ай-яй хитрый сез! Хитры-ы-ый! Шулаймы, кызлар?

Кызлар икесе дә җавап урынына сандугач тавышлары белән көлеп җавап бирделәр.

— Бергә-бер, синең файдага, Әхнәф Хәсәнович! — диде Николай Николаевич. — Кабатлап әйтәм: бергә-бер, ләкин синең файдага.

Шушы теләкләрнең чынга ашуы өчен алар рюмкаларын күтәрделәр. Әле бу мәҗлеснең башы гына иде. Май аеның эретелгән майдай йомшак ягымлы төне Әхнәфкә язлардай матур җәй, җәйләрдәй матур көз, көзләр муллыгы белән тулган кыш алып килергә тиеш иде...

## 14

Теге вакытта Ирек картлар йорты бухгалтеры Әгъләмне урам чатында эләктереп алды. Әллә аның туктатуыннан, әллә башка сәбәптән, Әгъләмнең күзләрендә кинәт кабынган курку билгеләре әле бүген дә күз алдында тора. Ул пуф-пуф китереп суырып килгән папиросын авызыннан алып атты.

— Әгъләм агай, сез ни өчен Шахминны миңа җибәрәсез? — диде ул, үгезне мөгезеннән алып.

Бухгалтер китереп суккандай чигенеп куйды. Күрәсең, бу сорау аның өчен көтелмәгәнрәк булып чыкты.

— Мин аны сезгә ник җибәрим? — диде ул, куркулы карашын арлы-бирле йөртеп.

— Менә мин шуны белергә телим дә. Ул килә дә акча сорый. Сез җибәрде, ди.

— Соң инде, иптәш Сабитов, аның кем икәнен беләсез бит. Акылы тулы булмаган кеше ни сөйләмәс.

— Сез бөгештермәгез, Әгъләм агай! — диде Ирек, янаулы тавыш белән. — Аның кайчан акылында, кайчан акылында түгеллеген бик ансат аерып була. Сезнең җибәрүегез турында әйткәндә, ул үз акылында иде. Аңлатып бирегез, эш нәрсәдә?

Әгъләм шактый вакыт эндәшмичә таптанып торды.

— Аңлата алмыйм... — диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән. — Ул күп мәртәбәләр хакимияткә дә барып керде. Акча сорый, диләр. Әхнәф Хәсәновичның кабул итү бүлмәсеннән милиция белән китергәннәре дә булды. Мин ничек акылга муафикъ булмаган кешенең гамәлләре өчен җавап бирим?..

Шулай диде дә Әгъләм китеп барды. Инде бу сөйләшүне Ирек онытып та бетергән иде, чөнки Шахмин яңадан күренмәде.

Май урталарында Ирек көнкүреш комбинатына керде. Кергәндә үк ишегалдында Кәрәм Нәҗмиев белән каршы очрашты. Күптән сагынышкан дуслар кебек, кул биреп күрештеләр, әлбәттә инде, хәл-әхвәл сораштылар.

— Менә шушы халык өчен бик кирәкле тармакны яшәтергә дип җан ату инде картайган көндә, — диде Кәрәм Нәҗмиевич, сыңар күзен кысып.

— Сезнең өчен бу кечкенә оешма нәрсә инде ул, — диде Ирек, аның салпы ягына салам кыстырып. — Сез бит районны тоткан кеше. Дер селкетеп дисәң дә, хата булмас.

Бу мактау сүзләреннән Кәрәм Нәҗмиевичнең иреннәре җәелеп китте.

— Булды эшләр. Әйдәгез керәбез, гәпләшеп утырырбыз.

— Мин чалбар тектерергә заказ бирим дигән идем.

— Бирегез, бир. Мин сезне бүлмәдә көтәм.

Кисүче яныннан чыккач, Ирек бер генә минутка уйланып торды да Нәҗмиевкә кагылырга ниятләде. Ул, директорның кабул итү бүлмәсенә кергәч, хәйран калды: бер дә хакимият башлыгыннан ким димәссең! Бүлмәне директор гаҗәп заманча җиһазлаган иде. Күрәсең, Ирекнең гаҗәпләнүе йөзенә чыкты, Нәҗмиев көлеп җибәрде:

— Нәрсә, иптәш Сабитов, чәүкә оясы күрергә уйлаган идеңмени? Нәҗмиев беркайчан да чәүкә булмас!

— Нишләп алай дип уйлыйм? — диде Ирек, ашыга-кабалана акланып. — Элеккесе белән чагыштырганда, танымады түгел бит. Халык дөрес әйткән инде: хуҗасы нинди — өе шундый.

— Рәхмәт. Мондый сүзләр өчен сезне ничек инде кофе белән сыйламыйсың?

Ирек аны әз генә чеметеп алырга уйлады:

— Кәрәм Нәҗмиевич, — диде ул, мыек астыннан гына елмаеп. — Сезне бит биредә эшләүчеләрнең вакытларын минутлап, акчаларын тиенләп санау тәртибе керткән, диләр. Ул кофе миңа бик кыйммәткә төшмәс микән?

Аның бу сүзләренә Нәҗмиев елмаю белән җавап кайтарды:

— Бөтен көч, иптәш Сабитов, бер минут белән бер тиендә.

— Таралып беткән комбинатның ни өчен аякка басуын аңладым кебек мин, — диде Ирек.

Ул арада секретарь кыз алтынланган чынаякларга салынган конфет-печенье ише әйберләр һәм икесенә ике касә кофе кертеп өстәлгә куйды.

— Мин сезгә башкасын да тәкъдим итәр идем, тик эш урынында ул нәрсәне, хәтта министр килсә дә, принципиально туктаттым. Мин килгәндә, комбинатның төп чире әнә шул эчүчелектән иде.

Кофе эчкәннән соң, Нәҗмиев, райком заманнарындагы таныш мөштеген чыгарып, сигарет кабызды һәм, ике-өч мәртәбә тирән итеп сулыш алганнан соң, төтен эчендә элеккечә куәтле, усал зат булып гәүдәләнде.

— Таныш мөштек, — диде Ирек, көлемсерәп. — Туза торган түгел.

— Аның тузарга җае юк, эченнән кайнар төтен йөреп тора. Бернинди микроб, эррозия ашый алмый. Менә сезне дә, иптәш Сабитов, үз мөштеге белән бик әйбәт суыра бит Шәрифуллин...

Сүзнең мондый юнәлеш аласын көтмәгән Ирек, тыныч кына чабып барган җәнлек ят тавыштан өркеп калгандай, сискәнеп китте:

— Элекләрдә сезнең төтен күзне әчеттерә торган иде инде ул әчеттерүен. Хәзер бигрәк тә зәһәрләнә бугай... — Ирек урыныннан торды. — Кофегыз бик тәмле булды, рәхмәт, — диде ул, шактый ачулы тавыш белән.

— Ирек туган!..

Ирек чайкалып китте, Нәҗмиевнең алай дип эндәшүен хыялга да китереп булмый иде. Ялгыш ишетмәдемме икән, дип кабатлап сорарга мәҗбүр булды:

— Нәр-сә?..

— Сез мине бүлдермичә тыңлагыз. Мин үз гомеремдә шактый кешеләрнең язмышларын теләгән якка бордым, үзгәрттем. Хәзер бөтен нәрсәнең асты өскә килде. Шуңа да карамастан татар дигән халык яшәргә тиеш. Ә син, Сабитов, безнең халыкның бер вәкиле. Болынкырда татарның

асыл егетләре кем соң? Әхнәф Шәрифуллинмы, Ирек Сабитовмы?

— Ә нигә без икебез генә? — дип сорап куйды Ирек, аның сүз сөрешенең кая барганын аңламыйча.

— Халык сезнең бергә икәнегезне күреп тора. Тик Шәрифуллин милләт улы түгел. Аңа халык кирәкми.

— Ул сезне эшегездә калдырган булса, бу сүзләрне әйтер идегезме икән?

— Мөгаен, әйтмәс идем. — Шулчак телефон шылтырады, һәм ул трубканы алды. — Исәнмесез, Әхнәф Хәсәнович. Хәзер кереп җитәм. — Ул трубканы куйды. — Кызганыч, озаклап сөйләшә алмадык. Мин сиңа бер сорау гына бирмәкче идем. Әйткән җавабыңа карап, сиңа гына түгел, хәтта тулаем Сабитовлар нәселенә бәям үзгәрәчәк яисә элеккечә калачак. — Нәҗмиев сүзен бүлде дә, авызындагы төтенен чыгарып бетергәч, Ирекккә якын ук килде һәм, аңа иелеп, пышылдаулы карлыккан тавыш белән:

— Өй туена бүләк итеп бирелгән стенка белән шкафның картлар йорты хисабына алынганын сез белдегезме? — диде.

— Ә?! — Ирекнең сулышы өзелде, күкрәгендәге һава ни эчкә кермәде, ни тышка чыкмады. — Кәрәм Нәҗмиевич... бу бит... Сез беләсезме... мондый нәрсә белән шаярмыйлар.

— Димәк, белмәгәнсез... — дип сузды Нәҗмиев.

— Соң, белсәм... мин шуны алыр идемме?!

— Мин сиңа бер әйбер әйтим әле, Ирек туган. Сезнең нәселнең бөтен фаҗигасе турылыкта. Уйный, кылана белмәүдә. Кешенең буыннары нигә сызлый? Шәмәй арасында май беткәнгә. Тормышта да шәмәй мае кирәк. Шәрифуллинда ул май бөтен Россиягә җитәрлек.

Нәҗмиев сигаретын мөштегеннән алып көл савытына китерде дә башы белән төртеп сытты, изде. Аннары тораташ каткан Ирекне бүлмәсендә калдырып чыгып китте.

Ул секретарь кызның:

— Ирек Хәйриевич, әллә авырып киттегезме? — дип дәшүеннән бераз айныгандай булды.

Ирек, урыныннан кузгалып, нишләптер каршы яктагы почмакка атлады, аннары, ялгышын аңлап, кире борылды да исерек кеше кебек бүлмәдән чыкты, саубуллашмый-нитми, коридор стенасына тотына-тотына, урамга чыгарга ашыкты. Аның буыннары бөтенләй хәлсезләнгән, тизрәк каядыр утырырга кирәк иде. Нәҗмиев сүзләренең дөреслеген тикшереп торасы юк, алар, кире кагылмаслык булып, Ирек өчен күптән расланган иде...

Читтән караган кешегә аның кыяфәте ничек күренгәндер, анысы мәгълүм түгел, әмма ул, әллә атлап, әллә үрмәләп, му-

зейга кайтып җитте. Керде дә урындыгына лапылдап утырды, уйларының очын да, азагын да табып булмый иде. Ничек Әхнәф шушыны эшли алган?!

Кичен эштән кайтканда Ирек бәгыренең бер тамырын суырып алган кеше хәлендә иде. Өйгә кергәндә үк утынлыктан балтаны эләктерде. Бу әшәкелекне бары тик шуның белән генә төзәтеп булыр кебек тоелды аңа. Чишенеп тә тормастан, стенка каршысына килде. Зәнфирә анда матур итеп әйберләр тезгән, бер урынында алтын йөгертелгән кыңгыраулы сәгать текелдәп утыра, урта өлешендә Ирекнең иң кадерле китаплары, астагы киштәдә аның язарга җыйган материаллары. Ул, тешен кыскан хәлдә, үзеннән сабырлык сорап, балтаны кабат урынына чыгарып куйды. Алар, гадәт буенча, кайсысы алдан кайтса, шунысы чәй куя, ашарга әзерли торган иде. Ирек бүген бернигә дә кагыла алмады, ул һаман чишенмәгән килеш өстәл янында утыра бирде. Менә Зәнфирә кайтты, Ирекнең шундый хәлдә кара коелып утыруын күргәч, гаҗәпләнүдән аның кашлары җыерылды, кулындагы әйберләрен өстәлгә куеп, ул Ireккә иелде.

— Нәрсә булды сиңа, карткаем? Бөтенләй төсең калмаган. Син бит авырыйсың. — Ул, аның кулын җәһәт кенә эләктереп, пульсын эзләп тапты. — Йөрәгең дулап тибә, «ашыгыч ярдәм» чакырыйк.

— Кирәкми… — диде Ирек, авыр сулап.

— Йә, әйт, нәрсә булды?

Ирек, исерек кеше кебек, башын югары күтәреп, карашын Зәнфирәгә түгел, каядыр читкә юнәлтте:

— Шундый нәрсә… безнең урамга чыгып кешеләр күзенә карарлыгыбыз беткән икән…

Аның бу сүзләреннән Зәнфирә өнсез калды:

— Әйт тизрәк, ни булды?

— Булган инде. Без синең белән ике оятсыз кыяфәтендә халык арасында йөргәнбез. Ләкин… — Ирек дөпелдәтеп берничә мәртәбә өстәлгә йодрыгы белән сугып алды. — Без моңа чик куярга тиеш!

Зәнфирәнең тыны кысылды. Ул, авырлык белән сулыш алып:

— Син мине юри газаплыйсың, ахры! — диде.

Ирек кинәт башын күтәрде, йөзенә бер көлү, бер елау кыяфәте чыкты, аннары әллә нинди уенчак, җиңел тавыш белән болай дип әйтеп салды:

— Кара син безнең стенкага, шкафка. Матурмы?

— Матур.

— Ә син беләсеңме аларның картлар йортында тәрбияләнүче гарип-гораба, авыру, тормыш тарафыннан рәнҗетелгән затларның өлеше икәнен? — Зәнфирә берни дә аңлама-

ды, аның йөзендә гаҗәпләнү артканнан-арта барды. Ирек сүзен дәвам итте: — Әхнәфләр ул әйберләрне картлар йорты хисабына китерткәннәр! Шәп бит, ә?!

Ирек әллә нинди ят тавыш белән көлгәндәй итеп куйды. Аның әйткәннәре әле Зәнфирәгә һаман барып җитә алмый иде: ул, тавышсыз гына, түбәсенә китереп суккан кешедәй, башын чайкады.

— Рәхмәт аларга, әйеме, карчык? Нинди олы җанлылык, нинди юмартлык!

— Моны сиңа кем әйтте? — диде, ниһаять, Зәнфирә, акылын җыеп.

— Моны бит бөтен Болынкыр белә икән, синең белән мин генә белмәгәнбез.

Ирек тынып калды. Ул, карашын туп-туры төбәп, Зәнфирәдән җавап көтә иде.

— Ә мин бит сизендем, — диде Зәнфирә, пышылдагандай акрын тавыш белән.

— Сизенгәч, нигә әйтмәдең? — диде Ирек, усал итеп.

— Юк ла, мин ул турыда түгел. Кешеләрнең миңа әллә ничек карауларын сизендем. Ялгышамдыр дип уйладым.

Ирек сикереп торып җиңнәрен сызгана башлады.

— Әйдә, әйберләреңне бушат, мин үземнекеләрне алып куям, стенкасын да, шкафын да сүтәбез дә картлар йортына илтеп тапшырабыз.

Зәнфирә юынгычка атлаган җиреннән туктап калды һәм, аптыраулы карашын төбәп, Ирекнең каршына килде:

— Ни сөйлисең син?!

— Башка юлы бармыни? Әйт алайса!

— Ирек, син тәртәне алай кинәт сындырма әле, — диде Зәнфирә. — Бу әйберләр хәзер урнашкан, алар безгә бирелгән.

— Нәрсә син миңа аларның тарихын сөйлисең? Бәлки, һәрбер тактасының җир йөзендәге иҗтимагый-политик әһәмиятен аңлатырсың?

— Зинһар, кызма әле! Ниндидер башка юл табарга кирәк.

— Башка юл юк. — Ирек тавышын күтәреп кычкырды: — Аңлыйсыңмы, башка юл юк! Кабахәтлек кабахәтлек булып кала. Мин аларны турарга дип алып кергән балтамны чыгарып бәргән идем. Әгәр син тагын мәмрәп торсаң, мин аны алып кереп, менә хәзер шушында күз алдыңда турап өям. Син кайсысын сайлыйсың?

— Зинһар, әз генә сабыр ит, — диде Зәнфирә, ике кулы белән башын тотып. — Әз генә тынычлан, шулкадәр куырма, башыма капты...

— Без инде болай да артык сабыр иткәнбез. Бу әйберләр картлар йортыныкы, аңлыйсыңмы?!

— Юк, безнеке... — дип пышылдады Зәнфирә, аңа яшьле күзләре белән мөлдерәп карап. Бу караштa ялвару, өмет, мәрхәмәт сорау ярылып ята иде.

— Заһит Фәхруллин каны нык агулаган икән сине.

— Аның ни катнашы бар?

— Әйбер кадерен белергә дәфтәргә язып өйрәнгәнсез бит. Шушы полировкаланган такта кисәкләренә син үзеңне дә шөрефләгәнсең. Ничек бу әйберләрдән аерырга сине?

— Эш әйбердә генәмени? Бу бөтен Болынкыр өчен, Әхнәфләр өчен коточкыч хәл була бит. Алар белән киләчәктә ничек яшәрбез?

— Алар белән?! — диде Ирек, мыскыллы тавыш белән. — Син һаман да алар белән яшәмәкче буласыңмыни? Бушат әйберләреңне!

— Бушатмыйм, үзең теләсәң нишләт! — Зәнфирә кычкырып елап җибәрде. — Миңа берсенең дә кирәге юк, турап бетер! Ишегалдына алып чыгып, ут төртеп яндыр! — Ул елый-елый бүлмәсенә кереп китте.

Зәнфирә бүлмәсенең ишегенә караган килеш, Ирек катып калды. Аның йөрәге, келәшчә белән кыскандай, сызлап сулкылдады.

Ул ишегалдына чыгып китте, тыкрыктан урамга менде, караңгырак урыннардан кызу-кызу атлады, эчендә дөрләгән ялкынны ничектер сүндерергә, тынычланырга кирәк иде. Ул, йөреп кайтып капкадан кергәч тә, ишегалдында шактый басып торды. Зәнфирәгә Заһит Фәхруллинны искә төшереп әйткән сүзләре өчен үкенде, кереп гафу үтенсә, үзенең җиңелүен таныр кебек тоелды. Ирек бер карарга килә алмады, моның сәбәбен ул ачык аңлады: Зәнфирә аны чигендерде. Өйгә кергәч, юынып өстәл янына килде. Кара-каршы утырып, бер сүз дәшмичә, мәҗбүри ашаткандай, чытык йөз белән ашадылар, чәй эчтеләр. Аннары икесе ике якка аерылды: Ирек залга чыгып телевизорны кабызды, ә Зәнфирә кухня ягында нидер эшләде.

Икенче көнне кич тагын шул күңелсез тарткалаш башланды.

— Мин бүген көне буе эштә уйландым, — диде Ирек. — Сәгать уннарда Әхнәфкә кереп, барлык ачуымны чыгарырга ниятләдем. Кабул итү бүлмәсенә аяк баскач, коелдым да төштем. Моны эшләү өчен... белмим... әйтә алмыйм инде... Бернәрсә бәхәссез: безгә бу әйберләрне илтеп бирмичә ярамый.

— Бу минем дә исемнән чыкмады, — диде Зәнфирә, Ирекнең сүзен куәтләгәндәй ялгап алып китеп. — Гаеп аларда. Шулай булса да мин бер котылу юлын таптым бугай.

— Нинди юл?

— Бәясе билгеледер бит инде аның? Акчасын түләрбез.

Аның бу сүзләренә Ирек дөртләп капты:

— Аннары һәрбер кешегә квитанция селкеп йөреп күрсәтербезме?! Әллә район газетасында белдерү генә бирәбезме? «Без ул әйберләргә акча түләдек, тулы исәп-хисап ясалды» дип. Юк, Зәнфирә! Бу мөмкин әйбер түгел. Моны мин әйткәнчә генә төзәтеп була. Җыештыр әйберләреңне!

Зәнфирә һаман да кымшанырга уйламады. Шуннан соң Ирек аңа Шахминның музейга килүләрен, Нәҗмиев белән очрашуын, дусларының үзеннән качуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бераздан авыр сулап, икесе дә эшкә тотындылар.

Ял көнне Ирек көне буе стенка белән шкафны сүтте, кисәк-кисәк итеп, шпагат бау белән бәйләде һәм верандага чыгарып өйде.

## 15

Ике көн узгач, төштән соң Ирек, Нәҗмиевтән тартмалы «УАЗ» машинасы алып, өенә кайтты. Стенка белән шкафны төяп, картлар йортына киттеләр. Машинаны капка төбендә туктаткач, Ирек бухгалтер янына керде. Ул директорның юк икәнлеген, инде шактый вакыт аның вазифаларын Әгъләм алып барганлыгын белә иде.

— Ник сез, Әгъләм агай, картлар йортының стенкасы белән шкафы безгә китерелгәнлеген әйтмәдегез? — диде ул, исәнләшеп тә тормастан.

— Ни бит... ничек әйтим? Әйтмәскә куштылар. Җитәкчеләрнең кушканын үтәмәсәң, ни була...

— Ярый, сүз озайтмыйбыз. Мин аларны алып килдем. Капкаңны ач та кертеп бушатабыз.

Ул арада ишек төбенә картлар йорты персоналы, әбибабайлар җыелды һәм кызыксынып карап тора башлады.

Өстенә дә киенмичә, Әгъләм бүрек хәтле йозак тотып чыкты да аны капкага элеп бикли башлады.

— Мин сиңа капканы биклә, димәдем, ачарга куштым, Әгъләм агай.

— Ә мин сез кушканга буйсынмыйм, иптәш Сабитов. Миңа кушучы кешеләр бүтән.

Кай арада күреп өлгергәндер, машина тирәсендә Шахмин да йөгергәләп йөри башлады.

— Алай булгач, үзеңә үпкәлисең инде, мин боларны капка төбенә бушатып китәм.

Шофер, тартма өстенә менеп, Ирекккә беренче бәйләмне сузды. Ләкин шулчак Әгъләм корт чаккандай кычкырып җибәрде:

— Иптәш Сабитов, зинһар, алай эшләмәгез! — дип ялвар-

ды ул. Әгәр мин боларны алып калсам, иртәгә үк эшемнән куачаклар бит. — Әгъләм иелеп Ирекнең ике тезен кочаклап алды һәм елап җибәрде. — Өч оныгым эшсез, бөтенебез минем акчага яшибез, харап итмәгез безне, иптәш Сабитов!

Ирек аны күтәреп аягына бастырды.

— Киттек, — диде ул шоферга.

Алар, картлар йорты каршыннан кузгалып, үзәк урамга чыктылар.

— Сезгә кайтабызмы? — дип сорады шофер.

— Юк, — диде Ирек.

— Ә кая барабыз соң?

Ирек әле һаман башында өлгергән фикерне тормышка ашырырга тәвәккәлли алмый иде, шуңа күрә ул шактый вакыт дәшми барды.

— Кайсы якка борылыйм? — диде шофер, ниһаять, урам чатына туктап.

— Борыл уңга... — Ирек тагын уйлап торды да: — Главаның өенә, — диде.

Шоферның куркудан күзләре акаеп чыкты, ул шактый вакыт машинаны кузгата алмый азапланды, ахырда Ирек әйткән юнәлешкә юл тотты. Әхнәфләр капка төбенә борылып туктагач, Ирек җәһәт кенә кабинадан төште дә капкага барды, ләкин ул бикле булып чыкты. Ишегалдында өрә-өрә бозау кадәр эт чабулап йөри иде. Ирек килеп кагылуга, ул, ике алгы аягы белән коймага таянып, башын урам ягына сузып өрергә тотынды.

— Сез Шәрифуллинның төзелеп ята торган йортын беләсезме?

— Беләм, — диде шофер, куркудан агарынып.

— Белсәң, киттек шунда.

Алар Болынкыр читендәге каенлыкка тезеп салынган өч катлы мәһабәт йорт янына килеп туктадылар. Аның турында ишеткәне, Әхнәфнең, килеп күреп кит, дип чакырганы булса да, Ирекнең монда аяк басканы юк иде әле. Ул үзенең эшләнеше, почмакларыннан күтәрелгән манаралары белән чын крепостьны хәтерләтә иде. Коймалары биек итеп тимердән тотылган, йорт үзе кызыл Мәскәү кирпеченнән салынган. Тәрәзәләрнең өсләре түгәрәкләп уелган, пыялалары фольга төсле елтырап тора. Төн караңгылыгы сеңдерелгән төсле ул пыялалар аша эчтәге бер әйберне дә күреп булмый. Ике катлы гараж, эчтәрәк тагын ниндидер корылмалар шәйләнә. Капка биредә дә бикле булып чыкты. Ләкин баганасына саннар төшерелгән калькуляторга охшаш нәрсә беркетелгән иде. Ирек шуның берничә санына баскалап алды. Күрәсең, өй эченә сигнал барып җитте, ишек ачылып, озын гәүдәле, кара мыеклы, күн фуражка кигән бер ир салмак адымнар

белән капкага юнәлде. Ныклабрак карагач, Ирек аның Миргаяз икәнлеген таныды. «Әллә соң мин төш күрәмме?» дип уйлады ул эченнән, аптыраудан гаҗиз булып.

Ул арада Миргаяз:

— Һо-о-о, Ирек Сабитов! — диде дә, колачын җәеп, Ирекне кочаклап алды, аңардан аракы исе бөркелеп тора иде. — Нинди җилләр ташлады?

Картлар йортында бер абынып ялгышкан Ирек бу юлы ул ялгышны кабатламаска теләде:

— Менә абзый кертеп чыгарга кушты, тизрәк капкаңны ач, — диде ул, Миргаязны ашыктырып.

— Пожалуйста.

Нindидер кнопкага гына басуга, зур капка шуып ачылып китте. Алар машина белән эчкә уздылар.

— Кая куярга кушты? — диде Миргаяз.

— Анысын әйтмәде, үзең хәл ит.

— Ярый, менә монда коридорга гына кертәбез.

Бәйләмнәрне кертеп сөяү озак вакытны алмады.

Эш беткәч, Миргаяз:

— Әйдә, минем бүлмәгә керәбез, әзрәк чемердәтеп утырыйк, — диде.

— Керергә вакыт юк әле, — диде Ирек. — Оныттыгыз бит мине.

Миргаяз аңа дәшмичә күзен кысып, мәсхәрәле караш ташлагандай карап торды:

— Без бит вак кешеләр, ә синең масштаблар, Ирек Сабитов, хәзер зурдан. Менә бит кемнәр белән эш итәсең.

— Ә син? — диде Ирек. — Мин ярый әле бу йортка беренче мәртәбә киләм, син яшәп үк ятасың түгелме соң?

— А как же! — диде Миргаяз. — Без дә төшеп калганнардан түгел.

— Турысын гына әйт әле, син ничек килеп эләктең монда?

Миргаяз шоферга карап куйды.

— Син бу егетеңне җибәр әле, өеңә тәпиләп кайтканнан бер әйберең дә төшеп калмас. Хәзер мин сиңа йортны күрсәтәм, берәрне кәгеп тә алырбыз.

Ирек шоферга рәхмәт әйтте дә машинаны җибәрде.

— Мин монда хәзер ел ярым инде. Ә килеп эләгү мәсьәләсенә килгәндә, биредә безнең бригада эшли. Башта бассейн ясадык, хәзер теплица корабыз. Эш муеннан.

— Ә син кем соң?

— Мин монда үзем управляющий, үзем каравылчы, үзем ташчы. Әйдә инде берәрне тотыйк!

— Рәхмәт, мин бит ул әйберне ташладым.

— Их, бар иде күңелле вакытлар, малай, ә? Мин үзем дә шактый киметтем аны. Әле бүген хуҗалар Казанга кунакка

киткәннәр иде, шуңа гына бераз бәйрәм итәм. Ул мәсьәләдә бик каты ул. Күрсә, кылыч белән башыңны гына кисә. Шаярырга ярамый.

— Ә бу күршедәге ике катлы йорт кемнеке? — дип сорады Ирек, беренче каты таштан, икенче каты шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган йортка күрсәтеп.

— Анысы Фәниснеке, хакимияттә эшли бит, Сәлахов. Шушы көннәрдә алар күченәләр инде.

Миргаяз Ирекне йортның эченә алып кереп китте. Беренче каты инде эшләнеп беткән, штукатурланган, алтын люстралар асылган икән. Шушы ук катта сауна, бассейн, үтә дә зур кухня, бәдрәф, тагын нindидер берничә бүлмә бар. Миргаяз шул бүлмәләрнең электр белән җылытыла торганында яшәп ята икән. Икенче, өченче катларда штукатурлау эшләре генә калган. Аларда йокы бүлмәләре, заллар, китапханә, спорт, бильярд бүлмәләре урнашкан. Аларны күреп-карап, хәтерләп кенә бетерерлек түгел икән. Миргаязның сөйләве буенча, инде бильярд та, музыкаль үзәк тә, һәр бүлмәгә япон телевизорлары, магнитофоннар, тагын әллә нәрсәләр складка кайтарып тутырылган. Өченче катның тәрәзәсеннән карагач, йорттан берничә йөз метр ераклыкта актарылып ташланган туфрак өемнәре күренде.

— Алары нәрсә була? — дип сорады ул Миргаяздан.

— Анда зур плотина төзеләчәк. Менә бу өйдән чыгып, бәрәңге бакчаларын узгач, әнә теге тип-тигез урынны күрәсеңме? Анысы туп тибә торган урын. Шуннан соң инде буага чумып була.

Ирекнең күңелендә әллә нинди давыл купты. Ул давылның нишләп купканын да, аны кая таба очырганын да ул инде сизми иде. Миргаяз белән әллә хушлашты, әллә юк — анысын да хәтерләмәде, шул давыл канатларында аягы белән бер җиргә тиеп, бер күтәрелеп, өйләренә кайтып җитте.

## Өченче кисәк

### 1

Миңзаһит караватыннан торып утырды, чүәкләрен дә элмичә, өстенә халатын да кимәгән хәлдә, нишләргә кирәклеген уйлый башлады. Аяк очларына гына басып, үзләренең бүлмәсе ишеген тоткасыннан бераз күтәреп әчкә этте дә тыңлап торды. Рашат бүлмәсеннән тавыш-тын ишетелмәде. Төнлә аның бөтен фатирны бер итеп дөбер-шатыр йөрүен котлары очып тыңлап ятканнар иде. Котырды, сүгенде, урын-

дыкларны аударды, ниләрдер эчте, телевизор акыртты, ахырда кереп түнде.

Миңзаһит үзен бу дәрәҗәгә төшәр дип элек башына да китерә алмас иде. Кемне дә булса шундый хәлгә калган, дисәләр, кычкырып көләр, берни дә аңламас, аны адәм актыгы дип гаепләр иде. Хәзер нәрсә? Алар Рашатка һәм үзләрен чолгап алган шул хәтәр дөньяга каршы көрәшәләр. Иң элек малайларын эчкече, куркыныч марҗадан аерырга алындылар. Марҗа инде ачыктан-ачык килеп йөри, Рашат өстеннән генә түгел, алар өстеннән дә хакимлек итеп азаплана иде. Ахырда Миңзаһитка район эчке эшләр бүлеге начальнигына керергә, үзенең нинди эшләрдә эшләгәнлеген әйтергә һәм бүгенге тормыш хәлләрен сөйләп бирергә туры килде. Баруының нәтиҗәсе озак көттермәде: марҗаны кулга алдылар, суд та булды. Ул кызлар һәм егетләрне наркотик кулланырга, башка бозыклыкларга өйрәткән булып чыкты. Рашат, бу вакыйгаларда Миңзаһитның катнашканлыгын белгәч, чын мәгънәсендә ерткычка әверелде. Аның акча сорап кул күтәрүләре гадәти хәлгә әйләнде. Миңзаһит белән Хәят акчаны төрлечә бүлгәләп, яшереп тоттылар. Рашатның котыру дәрәҗәсе бик куркыныч булса, зуррак сумма, түзәрлек булса, кечкенәрәге бирелде. Рашатның берничәшәр ай югалып торган чаклары алар өчен бәйрәмгә әверелде. Андый югалулардан соң ул баеп кайта, ресторанннарда гына типтерә, баш төзәтергә акча дауламый, сумкасыннан алып, затлы коньяклар гына чөмерә. Бервакыт югалып торгач, ул өстәлгә төргәге белән акча кайтарып ташлады. Миңзаһит белән Хәят калтырана-калтырана акчадан баш тарттылар. Рашат, аларга мәсхәрәле карап, акчаны алды да сумкасына атты, башка күрмәссез, диде.

Миңзаһит гомер буе ялган, икейөзлеләнү күреп газаплана иде. Шул ялганнан котылмакчы булса, тормыш куйган тәртипләр аның үзен дә шуңа мәҗбүр итә иде. Ниһаять, менә аның теләге тормышка ашты: аларның тормышында бер генә ялган да калмады — шәп-шәрә дөреслек! Ә ничек рәхимсез, куркыныч ул. Йөрәге әрнегән чакларда аны әллә нинди үкенечле уйлар биләде. «Нәрсә таптың син бу Казанда? Нәрсәгә ашкындың син монда?» — дип, үзен-үзе тиргәде. Ят идең Болынкырда рәхәтләнеп. Бакчасында бар дөньясын онытып уздырган көннәрен ул җәннәт рәхәтләре белән исенә төшерде. Аяк астында йомшак кара туфрак, яшел үлән, тирә-юнендә агачлар, кошлар тавышы, җил исә, яңгыр ява, ак кар бөртекләре күбәләкләрдәй оча, урамга чыксаң, таныш кешеләр сәлам бирә. Шушы таш базда җәфаланып яту кирәк идеме? Алардан кызы Эльза белән кияве дә читләштеләр, чөнки Рашатка үгет-нәсихәт укый башлауга, ул

аларны куып чыгарды. Бервакыт Эльза Миңзаһитның егет чакта алып барган көндәлекләрен биреп китте. Көрән тышлы бу дәфтәрне ул әле артыннан, әле алдыннан укыды. Укыган саен, күңелен, үткен пычак белән телгәләгәндәй, үкенү-сагыш биләде. Көндәлекләрдә аның иң гөнаһсыз чорлары ярылып ята иде. Яшьлекнең матур хыяллары, тормышның һәр көненә соклану, игелекле зур омтылышлар, яшәү матурлыгы турында романтик уйлар, нindidер китаплардан күчереп куелган фикерләр. Ул чордагы Миңзаһит белән хәзергесен чагыштырырлык та түгел, алар арасында бернинди дә уртаклык калмаган, бу ике затны бары тик исем генә берләштерә иде. «Нәрсә булды? Мин гомеремне нәрсә өчен яндырдым?!» дигән сорауларга җавап эзләп, аның башлары чеңләде. Аның бит яшьлек максатлары якты, үзен кешеләр өчен багышлауга юнәлдерелгән иде. Ә нишләп соң ул ният тормышка ашмады? Яшьлектәге якты хыяллар югалтылган иде...

Башта Миңзаһит илдәге тормышның оештырылу тәртипләрен гаепләде, әмма тора-бара уйлары, җил куып китергән дулкын кебек, һаман бер ярга — үзенә китереп бәрделәр. Аның тарафыннан бик күп язмышлар җимерелде, шул исәптән Хәятка да ул бәхет китерә алмады. Икесенең ике дөнья булып яшәвенә, балаларны аерып тәрбияләүләренә ул бүтәнчә карый башлады. Бу үзгәреш беркөнне базарда үзе белән партия мәктәбендә укыган Гапсаматовны очраткач булды. Башта алар бер-берсен танымадылар, бик озак карашып тордылар, ахырда кочаклашып күрештеләр, хәл-әхвәл сораша башладылар. Ике арадагы әңгәмәдән бигрәк Миңзаһитны курсташының тышкы кыяфәте таң калдырды. Ул укыгандагы кебек яшь-яшь, йөзләре алланып тора, битендә җыерчыклар да юк диярлек, чәчләре дә чем-кара иде. Партия мәктәбендә чакта алар кул биреп исәнләшеп китүдән ары узмаган булсалар да, Гапсаматов Миңзаһитны, ай-вайга карамыйча, үзенә кунакка чакырды. Ул ике бүлмәле фатирда яшәп ята икән. Хатыны да үзе кебек яшь, җиңел хәрәкәтле, ут борчасыдай очып йөри. Миңзаһитның кем икәнен әйткәч, аның бер алдына, бер артына төшеп, сандугачтай сайрады, җитәкләп зал ягына алып чыкты, идәндә уйнап йөргән ике бала белән таныштырды: оныкларыбызның балалары, бакчага бирдермибез, үзебез карыйбыз, чатнатып татарча сөйләшәләр, татарча җырлыйлар, татарча бииләр, диде, җырлатып-биетеп тә күрсәтте. Миңзаһит ике бүлмәле фатирдагы иркенлеккә хәйран калды. Анда артык берни дә юк, яшәү җиренең яртысын биләүче күпереп торган затлы кәнәфидиван кебек нәрсәләр тутырылмаган иде. Гапсаматов, табын янында утырганда, үзенең тормыш хәлләрен сөйләп бирде:

аны әүвәл туган авылында партоешма секретаре иткәннәр, аннары, балалары бик кыстагач, Казанга күчкәннәр, шәһәрнең кайсыдыр райкомында инструктор булган, шуннан пенсиягә чыккан. Алар, өстәлгә әллә ничә төрле затлы эчемлек куеп, Миңзаһитны кыстадылар да кыстадылар. Үзләре иреннәрен генә тигереп куйсалар да, ул нишләптер кыстаганга бирешеп эчте дә эчте, ахырда исерде. Дөресрәге, ул үзенең Гапсаматов кебек шушылай яшь, матур булып саклана алмаганына үч итеп эчте. Ахырда тавышсыз гына еларга кереште. Гапсаматов белән хатыны хафаланып аның тирәсендә бөтерелә башлагач, исерсәм елый торган гадәтем бар, дип акланды. Аның йомшавын күреп, хуҗалар аны ихлас күңелдән кунарга кыстадылар. Миңзаһит, үзенең кайтырлык түгел икәнлеген чамалап, Хәятка шалтыратты да кунып калды.

Бу очрашу аның күңелен актарып ташлады. Тормышта бернигә дә ирешмәгән Гапсаматовның ул үзеннән мең мәртәбә бәхетле икәнен аңлады. Аларның җаннары тыныч, шул затлы җиһазлар белән бизәлмәгән фатирларында бәхет касәләре мөлдерәп тулып тора иде. Көн саен түгел, хәтта сәгать саен Миңзаһит үзләренең тормышын аларныкы белән чагыштыра башлады, чагыштырган саен, аянычрак нәтиҗәгә килде...

Рашатның аяк тавышы аның уйларын бүлде. Колагын ишек ярыгына куеп, тын да алмыйча тыңларга кереште. Менә ул аякларын сөйрәп кухня ягына юнәлде, нәрсәләрдер шалтырады, шешәдән аракы салганы, голт-голт эчкәне ишетелде. Аннары Рашат ютәлли-ютәлли туалетка кереп чыкты да үзенең бүлмәсенә бикләнде. Аяк очларына гына басып, Миңзаһит кухняга керде, өстәлдә буш аракы шешәсе күрде. Димәк, Рашатның запасы беткән. Ул плитәгә тавыш-тын чыгармыйча гына чәйнек утыртты, кабат үз бүлмәсенә таба атлаганда, телефон шылтырады. Миңзаһит өлгергәнче, Рашат чыгып трубканы алды.

— Газетадагы белдерү буенча? — дип сорады Рашат, карлыккан тавыш белән. — Тә-ә-әк, андый нәрсә булмаячак! — Ул трубкасын атты да Миңзаһитның каршысына килеп басты. — Сез нинди квартира алыштырырга җыенасыз?

Ул арада Хәят та атылып чыкты.

— Безнең өч бүлмәлене икеле белән берлегә алыштырмакчы идек, — диде Миңзаһит, тотлыга-тотлыга.

— Ә мин?! Мин арттыммыни? Сезнең миннән котылырга теләвегезне мин күптән сизеп йөрим!

— Ни сөйлисең, улым?! — дип сүз кыстырды Хәят. — Без бит инде болай яши алмыйбыз. Сиңа өйләнергә кирәк. Икелесен сезгә бирербез, берлесендә үзебез яшәрбез.

Рашатның кан баскан күзләре түгәрәкләнеп киерелделәр.

— Бар әле, ояңа кер! — диде ул, калтыранган бармагын ишеккә таба юнәлтеп.

Хәят чигенә-чигенә барды да бүлмәсенә кереп посты.

Рашат кайнар юеш бармаклары белән Миңзаһитны бугазыннан буып алды:

— Әйт дөресен, ник алыштырасыз?!

Миңзаһитның тыны кысылды, сүзләрен көч-хәл белән генә кысып чыгара алды:

— Әниең әйтте бит... синең өчен...

— Мразь! Сиңа хәзер бернинди квартира да кирәк булмаячак!

Рашат икенче кулы белән Миңзаһитның иңбашына китереп сукты һәм ул, мәтәлләп, урындыкларны аудара-аудара, залның түр ягына очты...

## 2

Соңгы вакытларда Әхнәф, җае чыккан саен, районда культура эшенең торышына канәгатьсезлеген белдерә килде. Ул аны экономика мәсьәләләрен тикшергәндә дә, җайлап-җайлап китереп чыгарып, исемен әйтмичә генә, чыбыркының нечкә очы белән Сөембикәгә чиерттереп ала иде. Каршы бер генә сүз әйтмәсә дә, Сөембикәнең ачуы кабарганнан-кабарды. Бүген хакимияттәге атналык планлаштыру вакытында Әхнәф тагын җайлап кына теге таныш чыбыркысын кулына алды.

— Кайберәүләр республика матбугатында хакимият эшчәнлеген каралтып күрсәтергә тырышалар...

Моның кем адресына әйтелгәнлеген залда утыручы җитәкчеләр барысы да аңладылар. Сөембикәнең артында чышын-пышын килеп көлештеләр, кемнәрдер аңа таба борылып карады. Ул коры дары кебек шартлап кабынырга әзер иде. Әхнәфнең сүзләре, залның ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдашып алуы аны сикереп торырга мәҗбүр итте.

— Нигә аны «кайберәүләр» дип торасыз? Ачыктан-ачык әйтегез! — диде ул, Әхнәфкә туп-туры карап. — Сәхнә киемнәре тектерергә акча бирмәвегез хак бит. Хәзер безнең районда гаҗәп атмосфера урнашты. Партия заманнарында бернинди тәнкыйть булмады, имеш, берәр сүз әйткән кешене эзәрлекләделәр, дип сөйләргә яратасыз сез. Ә үзегез өф иткәнгә чер итеп кычкырасыз. Культурага акча табылмаса да, якыннарыгызга йортлар салырга дигәндә табыла тагын.

Әхнәфнең чырае бурлаттай кызарып чыкты.

— Мин сезгә үзегез белмәгән нәрсәләр турында саграк

сөйләргә киңәш итәр идем, Сөембикә Даутовна. Җитәкче кеше бит үз сүзләре өчен җавап та тота.

— Куркытмагыз, — диде Сөембикә, ярсуын тыя алмыйча. — Урлаган әйберем юк. Миңа карашыгыз шундыймы, әллә культурагамы — мин анысын төгәл әйтә алмыйм. Әмма акча дигәне сезнең бармак арасыннан безгә таммый. Планга кертелгән булса да, музыка мәктәбен ремонтларга да бирмәдегез, бүген ул ябылу алдында тора.

— Курыкмавыгыз әйбәт, — диде Әхнәф, тыныч булырга тырышып. Залдагылар бу тырышуның сугып аударылган кешенең дүрт аякланып торырга азаплануы кебек икәнлеген ачык күрделәр. — Тик бу зур батырлык күрсәтә торган урын түгел. Сез ул музыка мәктәбен ремонтларга иң элгәре үзегезнең Мәдәният министрлыгыннан тиешле сумманы алып бетерергә тиеш идегез. Алмадыгыз! Чөнки сездә аны ремонтлау нияте булмады. Ярар, сез ремонтламасагыз, башка кеше ремонтлар.

— Рәхмәт. Гаризам өстәлегездә булыр.

Сөембикә кызу-кызу адымнар белән ишеккә таба атлады. Каршысында Фәһимәнең үзенә төбәлгән мыскыллы көлемсерәвен күрде, ачудан тыны кысылды. «Шул кәнтәй котырта, шуның сүзеннән чыга алмавы хак, күрәсең», — дип уйлады ул.

Кызу-кызу эшенә атлаган җиреннән, Фәһимәгә ачуын аудармыйча тынычланмаячагын аңлап, кире борылды. Банк каршына барып, шактый вакыт таптанып торды. Ниһаять, почмактан борылып чыгып, Фәһимәнең килгәне күренде. Аның йөзендә нәкъ баягы елмаю иде.

— Йә, күңелең булдымы, авылдаш? — диде Сөембикә, аңа үзе кебек үк мыскыллы караш ташлап.

— Кеше бәхетенә көнләшеп караучылар барысы да синең хәлгә кала. Артың печән ашый башласа, рәхәт түгел шул ул.

Фәһимә Сөембикәне әйләнеп үтеп китмәкче булды, әмма ул аның каршына чыкты.

— Син район банкының сейфын гына түгел, иреңне дә итәк астыңа тыккансың.

— Ә ир-атның урыны кайда соң аның, шунда булмыйча?!

Фәһимә кычкырып көлеп җибәрде дә, Сөембикәне читләп үтеп, банкка кереп китте.

Сөембикә көне буе үзен-үзе ашады, бухгалтеры белән, инспектор хатын белән телгә килде. Аңа бөтен дөнья бармак төртеп күрсәткәндәй тоелды. Кичкырын, үзен эштән азат итүне сорап язган гаризасын алып, Әхнәфкә керде, ләкин ул юк иде. Аны кабул итү бүлмәсендә калдырырга мәҗбүр

булды. Әхнәф белән Фәһимәгә әйтелмәгән ачуын эчендә саклаган килеш өйгә кайтты.

Ул ашарга әзерләп бетергәндә, ишектә Айдар күренде. Аның авызы колагында, күзләре очкынланып яна иде.

— Сөембикә, мине котлый аласың, — диде ул, керә-керешкә. — Мин бүген эшкә кереп кайттым.

— Кайда, нинди эш?! — диде Сөембикә, гаҗәпләнеп.

— Спорт мәктәбенә. Каратэ көрәше буенча тренер булып. Түгәрәк алып барачакмын.

Көне буе җыелган ачуын чыгарып, Сөембикә кычкырып җибәрде:

— Ничек инде син минем белән киңәшмичә эшкә керәсең?!

Айдар җитдиләнеп калды, хәтта коелып төште:

— Ничек инде өйдә ятыйм... Мин сау-сәламәт, синең каршыда оят.

— Оят, оят... — диде Сөембикә, өстәлдәге савыт-сабаларны шалтыр-шолтыр китереп. — Аягың керсә, башың кермәгән дигәндәй... нинди эш ди әле...

Айдар авыр итеп сулады да, түргә дә узып тормастан, ишек янындагы кечкенә табуреткага утырды.

— Менә бит ничек... — Аның тавышы бөтенләй диярлек ишетелмәде. — Ә мин инде ышанып беткән идем...

Сөембикә күз ачып йомган арада аның каршына килеп җитте.

— Йә инде, Айдар, кичер инде син мин юләрне! — диде ул, аның битләреннән кат-кат үбеп. — Син эшкә кергәнсең, ә мин менә эштән китәргә гариза биреп кайттым.

Сөембикә яшьле күзләре белән аңа елмайды. Айдар акрын гына урыныннан торды:

— Син чынлап әйтәсеңме?

— Әйе. Авыр миңа Шәрифуллин белән эшләү. — Ул кулын селтәп куйды. — Бетмәс әле бер гади генә эш. — Аннары тагын Айдарның күзләренә туп-туры карады, гаепле кеше елмаюы белән елмайды. — Гафу итәсеңме мине?

Айдар баш чайкап көлеп куйды:

— Сине аңлый торган түгел, — диде ул. — Бер карыйсың — җен кебек бирешмисең. Җиңәм, сындырам димә. Икенче карыйсың — сүз дә кирәкми, керфек сирпүгә үк буйсынасың, ефәк кебек ураласың. Ничек шулай була инде ул?

Сөембикә аңа әллә нинди үкенечле кызганыч караш ташлады: ул әллә үзен, әллә Айдарны кызганды — моны аерырлык түгел иде.

— Алла шулай яраткач, нишлим соң?!

Айдар аның иңбашыннан кочып залга алып чыкты, икәүләп диванга утырдылар.

— Миңа кискен үзгәрүчән континенталь табигать шартларына күнегү җиңел булмаса да, ияләшергә туры киләчәк, — дип пышылдады Айдар аның колагына. — Хәзер генә кояш нурлары өттереп көйдерә, биш минуттан коточкыч давыл, кар бураны күтәрелә.

Сөембикә аның бу сүзләреннән елмаеп җибәрде. Айдарның керфекләреннән күңелне тынычландыра торган әллә нинди җылы нур сибелә иде. Шушы нурлар аны бүген беренче мәртәбә елмаерга мәҗбүр итте...

Бу кичне аның уйлары үзеннән, әнисеннән ерак китә алмады. Кече яшьтән үк Сөембикә үтә нечкә күңелле дә, хисчән дә булды. Шул ук вакытта усаллыкта да аңа тиңнәр юк иде. Вакыты белән корычтай каты, чигенмәс Сөембикә, үзе дә аңламыйча, бик тиз бирешә торган иде. Шушы сыйфатлар әнисенә дә хас булды. Ул гомер буе ясаган хаталарыннан сабак алмады, аларны кабатлый торды. Җәүһәрия Фәйзрахман белән дуслашып йөргән заманнарда колхозга Сәфәргали исемле кешене председатель итеп куйдылар. Киң җилкәле, зур башлы, әллә нинди сары күзле, эре сөякле адәм иде ул. Куркыныч чырае эре җыерчыклар белән капланган, сул яңагында күз читеннән төшүче җыерчыгы бер урында, куркыныч булып бөтерелеп, өченче күз төсле тартышып тора иде. Сәфәргали зур гына түрә булган, нәрсә өчендер янган, дип сөйләделәр. Ул килү белән авылда каты тәртип кертте, көне-төне эш дип чапты. Колхоз күзгә күренеп тернәкләнә башлады. Беркем тота алмаган Җәүһәрияне Сәфәргали ярты капчык фураж урлаганда каптырды. Фуражын фермага илттермәде, әгәр кабат эләксәң, прокурорның үзенә алып барам, дип котын алу белән чикләнде. Шул олы җанлылыгы өчен нидер өметләнеп, кичләрен Сөембикәләргә килә торган булып китте, Фәйзрахманга юл киселде. Елмаеп-көлеп сөйләшсә дә, Сөембикәнең бу кешедән нишләптер коты алына иде. Өйдәгеләр, күрәсең, аңа күнегеп беттеләр, бер килүендә ул кунып калды һәм үги әтигә әверелде. Сөембикәнең күңеле дөрес сизенгән булып чыкты: элек елмаеп-көлеп кенә сөйләшкән Сәфәргали аш-судан да, башкасыннан да гаеп тапты, өйдәгеләрне дер селкетә торган бәндә булып чыкты. Ул кайта башласа, әбисе белән бабасы да, әнисе дә, бер басасы урынга биш басып, аның тирәсендә бөтерелделәр, аның һәр боерыгына өчәүләп йөгерә торган булып киттеләр. Өйдәгеләр генә түгел, авыл кешеләре дә Сәфәргалинең күз карашыннан куркалар иде. Аны өнәмәвен белдереп, халык исемен Сәпәрәйгә әйләндерде. Бервакыт фермада бергә эшләүче дусты Саимә кергәч, әнисенә бөтенесе алдында: «Нәрсәсен таптың шуның? — диде. — Шул үләтне куып чыгарсаң, тынычлап кына яшәр идегез». Саимәнең бу сүзләренә әнисе күкрәген киереп җавап бирде:

«Ул бит, малакаем, колхоз председателе! Минем кем икәнне күрсеннәр әле! Ир ул сездә генә түгел, миндә дә бар». — «Яши алмаячаксыз бит, Җәүһәрия», — диде Саимә. «Миңа барыбер. Борын төпләренә такта куюым хак булсын».

Тора-бара Сәпәрәй салгалап та кайтты, Җәүһәриягә кул күтәрә башлады. Андый чакларда Сөембикә әби-бабасы белән өйдән мунчага чыгып качты. Сәпәрәй кайчакларда кара янып кайтып керә, берни сөйләшми, кулларын артка куя да, дөп-дөп басып, бер почмактан икенче почмакка туктаусыз киләп сара. Сөембикәләр, котлары алынып, аны тып-тын гына күзәтеп утыралар. Сәпәрәй туктаусыз яңагын чәйни, яңагындагы теге төене хәшәрәт күзе төсле куркыныч булып бер җыерыла, бер җәелә. Аның эчеп кайтып дуамаллanулары һаман ешая барды. Әнисе бер сүз дәшмәде, аңа берсүзсез буйсынды, сугудан-кыйналудан күз төпләре күгәрсә дә, аның кул астында кол кебек яши бирде. Әнисен жәлләп, Сөембикәнең йөрәгеннән кан тамды, үги әтисенә «Әнигә тимә!» дип кычкырган чакларында, Сәпәрәй аны, көрәктәй кулы белән эләктереп алып, йә өйалдына, йә тышка — ишек төбенә үк атып бәрә иде. Өйдәге гадәтләрен колхозда да күрсәтә башлагач, аның өстеннән шикаять язарга тотындылар. Берничә мәртәбә халыкның зар-моңын килеп тыңлап та киттеләр, ләкин мондый тикшерүләр, кисәтү-шелтәләр Сәпәрәйне төзәтә алмады. Күпмедер тыелып йөргәннән соң, ул кабат котыра башлый иде.

Сәфәргалигә бабасы үзенчә бәя бирде:

— Мондый бәндәләрне шәһәр әвәли, балакаем. Авылда кеше бер-берсенең күз алдында. Оят дигән нәрсә иң элек авылда барлыкка килгән. Бер-береңне кызгану, бергәләп эшләү дә авыл сыйфаты. Шәһәр баласы Сәпәрәйләр андый нәрсәләрдән мәхрүм, шуңа күрә алар мәрхәмәтсез. Кала үзе дә ясалма, тормышы да чын түгел. Бәндәгә иман әүвәл җирдән иңә. Ул табигатьнең һәр күзәнәгеннән моң булып иңә, сар-кый... Авыл бетсә, халык чәнечкеле шайтан таягыннан тукылган күлмәк кигәндәй яшәячәк. Энәләре белән чәнчеп, шул күлмәк йокыдан уятачак, билгеле вакытта каптыр-коптыр ашатачак, эшкә куалап алып барачак, куалап алып кайтачак. Бәндә таштан-тимердән ясалган капчыктан чыга алмаячак. Аның сафлыгы, беркатлылыгы беткән була. Ачудан ул менә шушы Сәпәрәй кебек авылның яшәү тамырларын кисәчәк. Әнисен үтергән кеше рәхәт күрмәгән кебек, алар әнә шулай үзләренең яшәү тамырларын үзләре үк корыталар...

Сөембикәерактагы шул газаплы үткәннәрен үзенең бүгенгесе белән чагыштырды. Айдар алдында күпмедер дәрәҗәдә Сәпәрәйне кабатлыйм түгелме соң мин, дип уйлады ул, коты очып...

## 3

Ирек диванда уйланып яткан җиреннән йокымсырап киткән иде. Ул күзләрен ачып җибәрде һәм шундук сикереп торды. Инде сәгать унбер тулып килә икән. Тәрәзәләрдән, бөтен бүлмәне алтын нурга манып, август кояшы елмая, Зәнфирәнең теге якта өй җыештырып йөргәне ишетелә. Ирек иртәнге алтыдан бирле бер генә җөмлә дә яза алмыйча газап чикте. Әсәренең геройлары, иртәнге томан эреп юкка чыккандай, каядыр китеп югалдылар.

Ул тәрәзә каршында басып торган җиреннән сискәнеп куйды, аннары өстенә кайнар су койгандай булды: капка каршына кара джип килеп туктады! Менә аның ишеге ачылды, башта сул ягыннан Әхнәф, уң яктан Фәһимә сикереп төште. Алар нидер сөйләшеп алдылар, Фәһимәнең кулына тоткан төргәкләре күренде. Капканы ачтылар да өйгә якынлаша башладылар. Ирек, үзе дә сизмәстән, кулындагы ручкасын шартлатып сындырды һәм шул хәлендә хәрәкәтсез катып калды.

Стенканы Әхнәфләргә илткәч, Болынкырда чын мәгънәсендә мәхшәр купты. Кешеләр бары тик шул турыда гына сөйли, шул турыда гына уйлый кебек тоелды Ирекккә. Очраган бере аны мактады, ә ул аларны елмая да алмыйча тыңлады. Бу хәбәрне ишеткәч, иң элек музейга Әмир Саттаров кош тоткандай килеп керде.

— Котлыйм сезне, Ирек Хәйриевич! — диде ул, Ирекнең кулын кысып селкә-селкә. — Күптән кирәк иде халыкны кузгатырга. Күпме түзәргә була?!

ТИҮдә әгъза булып торучылар, Саттаров тирәсенә тупланып, үзләренчә хәрәкәт башладылар. Болынкыр кайнарга тотынгач, Иректә ниндидер ярамаган нәрсә эшләгәндәй тойгы уянды. Шул ук вакытта аның Әхнәфкә булган рәнҗеше артты гына. Алар ялдан кайткач, эчендә нәрсәләр кайный, барысын да Әхнәфкә кереп аударырга ниятләде. Салкын акыл белән эш итә башлагач, ул моның җиңел эш түгеллегенә төшенде. Әгәр керәсең икән, аны сискәндерерлек кенә түгел, ә барысын да аңларлык һәм кыла торган гамәлләрен үзгәртерлек сүзләр табарга кирәк иде. Ирек шул сүзләрне эзләде, төрле кәлимәләрдә күңеленнән уздырды. Иң элек ул аның янына ничек итеп керәчәген күз алдына китерергә тырышты. Һәм бернәрсәне аңлады: ул Әхнәфнең күзләренә карый алмаячак. Ә нишләп карый алмаячак? Күпме генә эзләсә дә, ул бу сорауга җавап таба алмады. «Мин аның алдында гаепле мени? — дип уйлады һәм шунда ук: — Юк!» — дип җавап бирде. Ул чакта ни өчен күзенә туры карый алмый? Ярый, ул җитди төс белән төз басып Әхнәф бүлмәсенә керер, эре

адымнар белән аңа килеп салкын гына сәлам бирер, элеккечә, озак көрешмәгән чаклардагыча, Әхнәф колачын җәеп каршы килсә, чигенер яисә «кочаклашкан вакытлар еракта калды, Әхнәф Хәсәнович» дияр. Күп уйлый торгач, ул «Әхнәф Хәсәнович!» дип әйтә алмаячагын төшенде, аңа теле әйләнмәячәк иде. Иң кыены беренче сүз башлау булачак. Ирек аны меңнәрчә рәвештә күңеленнән уздырды һәм, ни гаҗәп, берсенә дә туктала алмады. Бу керүнең җиңә алмастай тагын бер өлеше бар иде: теләгән сүзләрен ул бөтенләй башка кешегә әверелгән очракта гына әйтә алачак. Димәк, гел чит кеше кебек керергә, каты һәм тәэсирле итеп сөйләшергә кирәк. Башкача булганда, керүнең бернинди мәгънәсе юк. Ләкин ничек кинәт кенә олпат, кыю кешегә әверелергә? Читтән нindидер сиңа булышырдай көч килүен көтәсе юк — бөтенесе үзеңдә. Ул көч — синең хаклы булуың. Менә шуңа таянырга кирәген аңлады Ирек. Ә нишләп таяна алмый соң?

Аларның килгәнен күргәч, Ирекнең башы берни дә эшләмәс булды. Ничә көннәр буе җиз иләктән иләгән фикерләре очкын төшеп шартлаган дарыдай юкка чыктылар. Чөнки ул Әхнәф белән Фәһимәнең үзләренә килеп керәсен уена китермәгән, бу очракта нишләргә икәненә әзер түгел иде. Ирек, сынык ручкасын өстәленә ыргыткач, сәдәфләренең каптырылганмы-юкмы икәнен тикшереп чыкты, трикосын салмыйча гына кабаланып чалбарын киде. Сул як тәрәзә төбендәге гөлне бөтенләй кирәкмәгәнгә үзенең өстәленә алып куйды, башында бик еракта, томан эчендә бер уй бөтерелде: «Ник шулай кыланам?» Ирек аңа җавап бирә алмады, бирсә дә файдасы булмас иде, чөнки хәрәкәтләре берсе дә үзенеке түгел, аларны ниндидер көч йөртә, Ирек шул көчкә генә буйсына иде.

— Әйдәгез, узыгыз, — дигән тавышы ишетелде Зәнфирәнең.

— Әллә Ирек өйдә юкмы? — Бусын Әхнәф сорады.

— Бүлмәсендә ул. — Ишектән Зәнфирәнең башы күренде. — Әйдә, чык, Әхнәф абый белән Фәһимә апа килде.

Ирекнең ике бите ут булып яна башлады, гәүдәсе калтырауга охшаш киеренке хәлгә килде. Ул, аякларын көчкә сөйрәп, алар янына чыкты. Йөзе көчләп уятылган кешенеке төсле караңгы һәм чытык иде.

— Исәнме, Ирек, — диде Әхнәф һәм аның кулына канатларын як-якка җәйгән фарфор бөркет тоттырды. — Илһам китерүче булсын бу...

Бөркет үзе ап-ак, үзе салкынча булса да, Ирекгә кызган күмердәй кызыл һәм кайнар булып тоелды. «Бусы кайсы оешма хисабыннан?» диясе килде аның, әмма теле әйләнмәде. Бу бит бүләк түгел иде. Түбәнсетелүеннән котылу

өчен ул бөркетне кабаланып урындыкка куйды. Үтә дә кыен, үтә дә авыр киеренкелек урнашты. Аны бетермәкче булып, Зәнфирә әрле-бирле сугылды, Әхнәфләрнең алып килгән күчтәнәчләрен өстәл өстенә таратты, үзенең ризыкларын ташыды, аларны табын янына кыстады. Аларның кымшанмавын күреп, Ireккә:

— Кунакларны утырырга кыста инде! — дип ялварды.

— Кунакларны?.. — Шушы сүзнең мәгънәсен аңларга теләгәндәй, Ирек маңгаен җыерып торды. Аннары, әйдә, миннән булсын яхшылык дигәндәй, кул селтәп куйды да: — Узыгыз, бәй... — диде.

Әхнәф теләр-теләмәс кенә стена буендагы урындыкка барып утырды, Фәһимәгә чакырулы карашын юнәлтте, әмма ул баскан килеш тора бирде.

— Көтмәгәндә килдек бугай, — диде Әхнәф, йөзен Ирекkә борып. — Эшеңнән бүлдек, ахрысы...

Ирекнең иреннәрендә мыскыллы елмаю җәелде:

— Көтмәгәндә... көтмәгән эшләр эшләү... синең холкыңа сеңгән бугай ул...

Инде бирегә килергә чыкканчы ук шартларлык хәлгә җиткән Әхнәф чәчрәп сикереп торды:

— Бу ни дигән сүзең була инде?!

— Аңламыйсыңмыни ни икәнен? — Фәһимәнең тавышында тыелгысыз ярсуы һәм ачуы ярылып ята иде. — Безне күрәсе килми аның. Әйдә, кузгалдык!

— Ни сөйлисең, Фәһимә апа?! — дип өзгәләнде Зәнфирә. — Чәй эчәбез әле күчтәнәчләрегез белән. Ирек, ник кыстамыйсың кунакларны?

— Нәрсә соң син койрыгы пешкән мәчедәй кыланасың?! — диде Ирек, Зәнфирәгә дөрләп кабып.

— Насырыңны корытма, Ирек, чәй эчеп тормабыз инде без болай булгач. — Әхнәф аның күзләренә туп-туры төбәлде. — Минем бер генә нәрсә сорыйсым килә: безне адәм хуры иткәч канәгатьләндеңме инде?

— Казанга ук килеп җитте тавышы, — дип өстәде Фәһимә. — Рәхмәт, бик әйбәт эшләдең.

— Тынычландымы күңелең?

— Ул әле дөрли генә башлады. Утны төрткәч, әрдәнәдән «янасыңмы?» дип сорамыйлар.

— Синең күзләреңдә әллә нинди куркыныч ялкын, — диде Әхнәф, баш чайкап.

— Әйе, ялкын! — диде Ирек, ярсулы тавыш белән. — Мин эчемнән үкереп елыйм! Әйе, сезнең белән бер өстәл артына утырасым килми!

— Ирек! — дип йөгереп килде аның янына Зәнфирә. — Шундый нәрсә булмый бит инде! — Аннары нишләргә бел-

мичә, әле Фәһимәнең, әле Әхнәфнең каршына килде. — Авырый ул, температурасы югары аның.

— Алдашма! — дип бүлдерде аны Ирек. — Син аларның безне ахмакка санап калҗа ыргытуларына нишләргә белмисең.

— Оялыр идең! Авыр чакларыңда сине Әхнәф күпме коткарды. — Фәһимә аңа имән бармагын төбәде. — Син — чын эгоист, үзеңнән башка берни дә уйламыйсың! Горурлыгың дөньяга сыймый.

— Горурлыгым ничектер — анысын әйтә алмыйм, әмма үз дәрәҗәмне беләм. Дөрес, мин хәерче, тик минем күңелем чиста. Кемнәрдер хакына гомер асрарга теләмим.

Зәнфирә аны иркәләгәндәй итте, туктатмакчы булды, ләкин Ирек аны читкә этте:

— Тик тор, мин клоун да, цирк эте дә булырга теләмим! Дәүләтебезнең хәерче дигән катлавына керүче тулы хокуклы гражданины! Үзем баш, үзем түш, беркемнеке дә түгел.

— Ю-у-у-ук! — диде Әхнәф. — Син милли герой ролен уйныйсың. Мине юкка чыгару өчен. — Аның ияк янындагы миңе дә әллә ничек усал булып ялтырап китте. — Мин бу өйгә яңадан үз гомеремә бер мәртәбә дә аяк басмаячакмын!

— Ә мин сине каргыйм, Ирек! — диде Фәһимә, аның каршына ук килеп. — Шундый итеп каргыйм, каргышым, һичшиксез, төшәчәк!

Алар кабаланып чыгып киттеләр. Зәнфирә елый-елый артларыннан иярде һәм Фәһимәгә ялварды:

— Зинһар, каргама, Фәһимә апа. Әллә нинди ул соңгы вакытта, йоклаганда ыңгыраша — баш өянәге кабат кузгала бугай. Минем белән дә юньләп сөйләшми, юньләп ашамый, күптән инде язганы да юк. Таң ата башлау белән Ык буена китә дә яр буенда йөри дә йөри. Кич җитсә — тагын шунда. Берәр нәрсә генә эшләп ташлый күрмәсен дип котым оча. Зинһар, аның бүгенге кыланмышын гаеп итмәгез... Ул Ирек түгел, аның эченә нидер керде...

Машинага утырырга әзерләнеп ишекне ачкан Фәһимә борылып Зәнфирәнең каршына ук килде:

— Эченә ни кергәнне әйтимме, үскәнем? Аракыдан дәвалануочыларның гадәте ул.

— Ул дәваланмады, үзе туктады бит.

— Барыбер. Ычкыныр чагы җиткәндә, алар әнә һәркемгә бәйләнәләр. Кулларыннан килсә, кояшны да, күзне чагылдыра, дип тартып төшерерләр, аяк астындагы сазга салып таптарлар иде. Әле күрәчәкләрең алда. Исән чакта Баллы Төбәгеңә ычкын син, монда калсаң, үкенәчәксең.

Фәһимәнең тагын ниләр әйткәнен дә, машинаның ничек

кузгалып китүен дә Зәнфирә ишетмәде. Ул капка баганасына сөялгән хәлдә тораташ катты. Әйтерсең лә аның баш түбәсеннән үкчәсенә кадәр яшен уты үтәли кисеп чыккан һәм күмергә әйләнгән гәүдәсен шунда сөяп куйган иде. Яшьле күзләре белән ул Ык буена карады, анда су коенырга төшүчеләрнең машина пыялалары ялтыраганын чамалады. Магнитофоннан дөпе-дөпе килгән ниндидер замана көе колагын тырнап үтте. Менә ерак та түгел чирәм өстенә әллә карга, әллә чәүкә көтүе фырылдап килеп төште. Алар Заһит дәфтәрләрен яндырганда җир өстеннән йөгергән күмерле кәгазьләр төсле йөгерештеләр...

Зәнфирә кергәндә, Ирек шабыр тиргә баткан хәлдә башын тотып өй буйлап йөри, йөзе кәфен төсле агарган, үзе дер-дер калтырый иде.

— Ник син аларның табанын ялыйсың? — Ирекнең теше тешкә тиеп шакы-шокы килде. — Дөнья урталай ярылган, ә син алар белән... Аларга яхшы булу өчен җан атасың. Менә бу бөркет — аларның безгә чираттагы калҗасы!

Ирек бөркетне идәнгә бәреп чәлпәрәмә китерде дә диванга барып ауды.

— Юк, Ирек, — диде Зәнфирә, күз яшьләре аша. — Сиңа әйбәт булсын өчен... Минем үземә берни дә кирәкми...

* * *

Әхнәф белән Фәһимә юл буе бер-берсенең йөзенә карамыйча, бер сүз дәшмичә кайттылар. Фәһимә аны эченнән туйганчы әрләде. Ирекнең бүләкне китереп ташлавын да, Саттаровларның азынуларын да Фәһимә Әхнәфнең курКаклыгыннан күрде. Аның уйлары да, гамәлләре дә ярты-лаш: беркавым баралар да чигенәләр, баралар да чигенәләр. Бер карасаң, аннан да батыр, тәвәккәл кеше юк, икенче караганда, әле генә очына-очына барган юлыннан мыштым гына кирегә борыла һәм шуңа мең төрле аклау таба. Ул бер эшкә дә үзе генә тулысынча тәвәккәлли алмый, аңа төрткәләп, өстереп, күрсәтеп торырга кирәк. Әгәр нәрсәгә дә булса үзе генә, кемнеңдер төрткәләвеннән башка алынса, ялкау ат камчы көткәндәй, артына борыла башлый һәм ярты юлда туктап кала. Яңа йорт төзегәндә, башта икенче катны, аннары өченче катны салуга аны күндерү өчен Фәһимәгә елан кебек бөтерелергә, нинди генә хәйләләр кулланырга туры килмәде! Күрше ике районның үзләре белән аралаша торган хакимият башлыкларын хатыннары белән кунакка чакырып, табын артында алардан басым ясатуга кадәр барырга туры килде. Бөгелеп төште Әхнәф. Аның уйлары да шулкадәр яшерен, җиде йозак белән бикләгәндәй томалана. Шул ук вакытта

Фәһимә ныклап тотынса, ул җиде йозак кинәт келт итеп ачыла да китә. Әле алар егет белән кыз булып йөргән чакта ук әбисе: «Синең бу егетең ефәктәй йомшак, яшь тал чыбыгыдай сыгылмалы күренә. Суга салсаң — балыкка, һавага ыргытсаң — кояшка, утка ташласаң ялкынга әвереләчәк. Эләктер», — дигән иде. Эләктерүен эләктерде Фәһимә, ләкин сыгылмалылык дигәнең җитәкче кешенең яртылаш алга, яртылаш артка чигенүенә әйләнгәч, башбаштаклыкка юл ачыла...

Капка төбенә кайтып туктагач, Әхнәф руль артында утыра бирде.

— Нишләп төшмисең?

— Эшкә барып кайтам.

— Бүген бит «беркая да бармыйм» дигән идең.

— Яңа исемә төште, карап куясы документлар бар.

— Сөяркәләрем исемә төште, диген, ичмасам!

Машина ишеген шартлатып ябып, Фәһимә капкага таба атлады. Иренең өйләнешкән чакларыннан ук үзенеке генә түгеллеген белеп яшәде ул. Аның ике ире бар: берсе — төссез, салкын, бозык Әхнәф. Икенчесе — югарыда, анысына район халкы баш ия, әүлия итеп карый. Аларны аермалы түгел, сиам игезәкләре сыман бергә береккәннәр. Берсе — әшәке, икенчесе кирәк. Кирәк тәмугка кертә. Иренең кыек юлда йөрүләрен Фәһимә белмәмешкә, күрмәмешкә салыша. Бүгенге авыр тормышта аерылышу турында уйлый да алмыйсың. Намус-вөҗдан дигән шикле алдавычларга ияреп аерылу, Әхнәфнең уч тутырып алган акчаларыннан, хан сарае кебек йортларыннан, ажгырып торган чит ил машиналарыннан, иң яхшы санаторийлардан, хастаханәләрдән баш тарту ахмаклык булыр иде. Тормышта бөтенесе дә өстә күренеп ятмый, барысы да бизмәнгә салып үлчәнми. Әхнәф күбрәк отамы, Фәһимәме — анысын бер Ходай белә...

## 4

Ирек, музейның түр тәрәзәсе каршына баскан килеш, тын да алмый, хәрәкәтсез басып торды. Бүген дә ыспас яңгыры туктарга уйламый. Һавадан асылынган соры болытлар, ни рәхәтләнеп җиргә төшә алмаудан, ни биеккә күтәрелеп китә алмыйча, агач башларына тия-тия тавышсыз гына елыйлар төсле. Бөтен дөнья юеш, күңелсез, салкын, шыксыз. Аның күңеленә бу ыспас яңгырларына кадәр үк салкын бушлык кереп оялаган иде инде. Ул һәр көн эшкә барды, эштән кайтты, өйдә, ихатада кыймылдап йөрде, әмма ни бер максаты, ни дәрте юк иде. Тормышның тәме китте, гүя аның гәүдәсенең иң кирәкле, көчле, тере өлеше каядыр очып киткән, кабыгы гына җирдә калган иде. Ул үзенең әнә шул югалган икенче

яртысын эзләде, әмма таба алмады. Беркем белән сөйләшмәде, Зәнфирәдән дә качты, кызы Айгөл аларга килгәч тә, йөзе ачылмады. Аны хәйран калдырып, ишегалдына чыгып китте. Ыспас яңгыры туктамады, күңелендәге бушлык җылынмады, тулмады...

Беркөнне аны хакимиятнең аппарат җитәкчесе Фәнис Сәлахов чакырып алды. Ирек аның янына күктән асылынган болытлардан да караңгырак чырай белән керде.

— Сезгә бер тәкъдим бар иде, Ирек Хәйриевич, — дип сүз башлады аппарат җитәкчесе. — Безнең бит хәзер культура бүлеге мөдире юк. Бу тармак күзгә күренеп таралып бара. Сезнең кебек кеше алынса, районда культура эше җайга салыныр иде.

Бу тәкъдим Ирек өчен бөтенләй көтелмәгән нәрсә булса да, ул артык гаҗәпләнмәде. Бары тик бер сорау гына биреп куйды:

— Ул куштымы?

Сәлахов, күрәсең, аның дулкынлануын, башка төрлерәк сораулар бирүен көткән иде. Шуңа күрә Ирекнең кискен генә әйтелгән сүзеннән каушап китте, бераз уйлап торгач кына зиһенен җыя алды:

— Нигә инде алай дияргә? Шундыйрак фикер бар.

— Риза түгел, диярсең.

Ирек шулай диде дә урыныннан торды.

— Сез бигрәк кырт кисәсез, Ирек Хәйриевич. Бәлкем, уйлап карарсыз? Без кайчандыр бер команда идек.

— Хәзер мин сезнең командага сыймыйм инде.

— Зурайдыгызмыни? — диде Сәлахов, төрттереп.

— Киресенчә: сезнең команда тарайды. Турысын әйткәнгә ачуланма. Сау бул.

Ирек акрын гына чыгып китте. Бу сөйләшү аңарда авыр тойгылар уятты. Әлбәттә, аңа эш тәкъдим итү Әхнәфнең ике араны ялгарга азаплануын аңлата иде. Мөдирлеккә ризалашкан очракта Ирек аның белән һәр көн иңгә-иң эшләргә тиеш була. Бу хакта ул Сәлахов яныннан чыккач кына уйлады һәм үзенең кискен баш тартуын куанып хуплады. Шулай да бу тәкъдим нишләптер аны тынычсызлады, буш кабыкны сөйрәп йөрткән җанына ул тагын бер йөк булып ятты.

Кичә аның ничә еллар көткән өмете тормышка ашты, тик ул аңа шатлык урынына коточкыч борчу алып килде. Ирек Минзәләгә инде күптәннән куелмыйча яткан пьесасының премьерасына барды. Әсәрне читтән килгән режиссер куйган иде. Сәхнәне ачу белән үк Ирекнең ике чигәсеннән чәнчеп ток йөгереп үткән сыман булды: декорациянең атасыанасы юк иде. Ул трапеция рәвешендә эшләнгән, сул ягында саргылт-аксыл төстәге нечкә капрон баулар тартылган, алар

тамашачының күзенә линейка белән сызылган төз сызыклар рәвешендә күренәләр, уң якта шәмәхә, зәңгәр, яшел, кызыл, кара төсләрдән торган тоташ стена; анда ниндидер түгәрәкләр, буталган, бер-берсенә чорналган сызыклар тулы бер буталчык күренеш тәшкил итәләр. Трапециянең уртасында олы ярым айга тартым нәрсә шәйләнә, аның эчендә шулай ук ниндидер машина, коточкыч биек йортларга, Кремль диварларына охшаш шәүләләр, юлбарыс койрыгыдай сырлы сызыклар, шартлау күренешләрен хәтерләтүче кызыл очкыннар, тагын әллә нәрсәләр бар. Спектакль башлангач, Ирек, пьесаның зур-зур кисәкләре төшеп калганын күреп, тешләрен кысты. Ул әйтергә теләгән кыю фикерләр бөтенләй югалган йә булмаса аңлашылмый торган ниндидер томанлы ишарәгә әверелгән иде. Актерлар җаннарын биреп уйнасалар да, халыкның күңелен били алмадылар. Әле бу, әле теге почмактан пышылдашкан, сөйләшкән тавышлар ишетелде. Соңыннан сыек кына кул чаптылар. Сәхнәгә чакыргач, Ирек халык каршында олы гаепле кеше кебек тирләп-пешеп торды, башы түзә алмаслык булып авыртты, ниндидер хатын-кыз менгереп биргән чәчәк бәйләме кулларын пешергәндәй булды...

Банкетта сүз алгач, ул тагын газапланды. Мин канәгать түгел, әсәрнең җанын алып бетергәнсез, тышкы кабыгы да таланып беткән, дип әйтергә ярамый иде. Шуңа күрә ул автор әйтеп бетермәгәнне режиссер һәм актерлар тулыландырды, дип алдашырга мәҗбүр булды. Банкетның шактый кызган өлешендә бер атказанган артистка кирәкмәгән олы авызы белән аның ике битеннән чат-чот үбеп котлады да читкәрәк сөйрәде. «Сезнең канәгать түгеллегегезне без спектакль барганда ук күреп тордык, — диде ул, пышылдап. — Пьесагызның талануына үзебезнең дә эчебез поша. Тик язмышыбыз алар кулында булгач...» Нәкъ шул чакта бөтенесен табынга чакырдылар һәм әлеге атказанган артисткага сүз бирделәр. «Мин чиксез дулкынланам... шатлык хисләрем күңелемә сыймый. — Ул авырлашкан сулышын чыгарырга ярдәм иткәндәй, кулларын күкрәк авызына куеп, күзләрен йомган хәлдә туктап торды. — Хөрмәтле режиссерыбыз Сәлмән Мәннәнович республикабызның теләсә кайсы театрын көнләштерерлек чын сәнгать әсәре иҗат итте. Спектакльне әзерләгәндә, Сәлмән Мәннәнович кулы астында без чын мәгънәсендә тагын бер актерлык мәктәбе уздык. Ул пьесаны бүгенге богаулардан азат итеп, аңа киләчәк сулышы өрде. Шуңа күрә аны бүгенге тамашачының бик үк аңлап та бетермәү ихтималы бар...»

Атказанган артистка шактый озак сөйләде, аннары башкалар сүз алды. Икенче тәнәфестә Ирекне Сәлмән Мәннәнович эләктереп алды. Ул аның пьесасыннан гел юк фикер-

не табып тартып чыгарган һәм, әллә нинди чаралар белән үстерә-үстерә, тамашачыга җиткергән икән. Сәлмән Мәннәнович ул идеяләр турында очына-очына сөйләсә дә, Ирек спектакльдә аларның шәүләсен дә тоймады. Иң соңыннан ул: «Сез декорациянең мәгънәсен аңладыгызмы?» — диде һәм Ирек котылу җаен эзләгән арада дәртләнеп аңлатырга да керешге: «Бөтенесе ассоциатив тәэсиргә корылган! Әнә сезнең фәлән-фәлән геройларыгыз гел туры сызыклар ягында уйнадылар. Бу алар язмышының туры юлдан баруын күрсәтә. Ә менә уң яктагы буталчык сызыклар фаҗигале, буталчык мәхәббәт кичерешләрен көчәйтә. Уртада исә киләчәк бәхетнең бик еракта, томанлы гына күренүенә ишарәли. Бер арада теге атказанган артистка Иректе тагын читкә алып китте. «Зинһар, дөрес аңлагыз, сез биредәге атмосфераны белмисез. Мин башкача чыгыш ясый алмыйм, — диде ул, елардай булып. — Без күңелебез теләгәнне әйтә алмыйбыз, тормышта да уйнарга дучар ителгән халык. Әмма мин сезгә баштагы сүзләремне — Ходай үзе шаһит әнә — ихластан әйттем...» Ирек банкеттан ярым үлеп чыкты.

Менә бүген ул, тышта яуган яңгырга карап, кичәге хәлләрне хәтереннән үткәрә. Олы өметләр белән язган пьесасын тамашачы кабул итәрме, юкмы? Күпме генә баш ватса да, ул моңа уңай җавап бирә алмады.

Кинәт, аның уйларын бүлеп, музей каршына «Жигули» машинасы, аның артыннан зәңгәр «УАЗ» килеп туктады. Беренчесеннән Әмир Саттаров, икенчесеннән Ильич исемендәге колхоз рәисе Ясир Рамазанов төште. Алар Ирекка заманча пөхтә итеп киенү буенча ярышалардыр кебек тоела. Икесе дә ап-ак күлмәктән, галстуктан. Рамазановның бераз чаларган чәчләре искиткеч матур булып күпереп торалар. Әмир Саттаров көл төсле замш костюм-чалбары, шул ук төстәге йомшак туфлиләре белән сәхнәгә чыккан опера җырчысын хәтерләтә. Киң маңгае, гаҗәеп тере, гел уйнап торучы яшькелт күзләре аның ниндидер олы уйлар, олы гамь белән кайнавына ишарәлиләр кебек. Ирек аларга сокланып та, бераз гына көнләшеп тә карады. Үзе ул, күпме генә теләсә дә, мондый пөхтәлеккә ирешә алмады.

Керүчеләр шау-гөр килеп күрештеләр. Утырышып хәләхвәл белешкәч, ыспас яңгырларының быел артык сузылуыннан зарланышып алгач, Саттаров тамак кырып сүз башлады:

— Иҗтимагый үзәк әгъзалары белән җыелып алырга иде.

— Нинди мәсьәләдә? — диде Ирек.

— Шәрифуллин мәсьәләсендә. Безнең болай читтән генә күзәтүебезне халык аңламас бит.

Аның сүзләре Ирекнең иң авырткан ярасына килеп бәрелде. Хәлнең болай гына кала алмаячагын ул яхшы аңлый, әмма әлеге ярага кагылдырасы да килми иде.

— Аңа ни булган? — дип куйды ул, күңелендә әллә нинди авыр, күңелсез тойгы күтәрелә башлавын сизеп.

— Урынсыз шаяртасыз, Ирек Хәйриевич, — дип сүзгә кушылды Рамазанов һәм калын мыегының уң як очын бөтерергә кереште. — Урамга чыксаң да, эшкә барсаң да, өйгә кайтсаң да, халыкның телендә шул гына бит.

Ирекнең уң як чигә турыннан башы чәнчешеп куйды. Ул карашын аска төбәде, берни дә дәшмәде. Авырту каш турына күчте һәм артка таба муенга кадәр ток суккандай чәнчеп алды.

— Сез ышанмыйсызмыни? Аның корылмаларын күргәнегез юкмы? Каенишенә йорт бетереп киләләр, — дип дәвам итте Рамазанов. — Казан янында коттедж салынып ята. — Ул төсле фоторәсемнәр чыгарып, Ирекнең өстәленә таратты. — Бу төзелешләр йортларга су кертү, канализация уздыру өчен каралган акчаларга башкарыла, диләр.

— Зәлиясенә машина алып биргән, — дип элеп алып китте Саттаров. — Экология өчен җибәрелгән бер миллион акча эреп юкка чыккан. Тагын бик күп…

Ирек башын тагын да ныграк иде.

— Әмир абый… зинһар, мине бу эшкә тыкмагыз…

Алар, ни әйтергә дә белмичә, бер-берсенә аптыраулы карап тордылар. Ниһаять, Рамазанов телгә килде:

— Ирек Хәйриевич, бу ни була инде бу? Мин гомер буе Сабитовларга табындым, сезнеңчә яшәргә тырыштым. Барыгыз да гаделлек өчен җан аттыгыз.

— Мине кыстамагыз… — Ирек учлары белән ике чигәсен кысты. — Арыдым мин, егетләр. Авыруым да көчле…

Әмирнең йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыкты:

— Ашаган авыз ояла, дисәгез инде…

— Теләсә ничек уйлагыз. Булдыра алмыйм… Беләсезме, арада бик зур нәрсә ята… Гомерлек… Без бит аның белән бергә башлаган идек…

Әмир көянтәле иске үлчәүне, бармагы белән басып, тигезләп азапланды, әмма аның бер ягы һаман аска төшкән хәлдә калды.

— Башлавын башлагансыздыр да… ул начар төгәлли бит… Сезгә ахыргача чиста булып калырга кирәк иде.

— Ул минем йөрәккә тирән яра ясады… Мин анықын тагын да ныграк яраладым. — Ирек үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде: — Тик минем хәшәрәт буласым килми! Аңлыйсызмы шуны?!

— Без бит әле сезне депутатлыкка күрсәтергә дә әзерләнә

идек, — диде Рамазанов. — Татарстан Югары Советына, аңа альтернатив итеп.

— Юк, юк! Ни сөйлисез! Андый нәрсәгә мин үтерсәгез дә ризалык бирмәячәкмен!

Рамазанов белән Саттаров бер-берсенә карашып куйдылар, урыннарыннан торып, ишеккә юнәлделәр.

— Туктагыз әле, — диде Ирек, алар артыннан атлап. — Сез ни кылмакчы буласыз?

— Район үзәгендә халык җыены җыярга, үзен дә чакырабыз.

— Бераз сабыр итәргә иде. — Ирек тиешле сүзләр таба алмыйча тынып торды. — Мин башта аңа керим, күзгә-күз карашып сөйләшим.

— Ревматизмлы буынны мазь белән сылаудан ни файда? — дип куйды Рамазанов. — Сызлавы бераз кимергә мөмкин, ә авыру көчәячәк кенә.

Алар ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып киттеләр. Ирекнең тормышында тагын болгавыр, хәвефле дулкын якынлашып килә иде кебек...

## 5

Ирек музейны бикләде дә кайту ягына юл тотты. Җанны изгән яңгырлар инде туктады, машина узып киткәндә, асфальттан тузан күтәрелеп кала. Халык ябырылып бәрәңге алырга кереште. Зәнфирә бәрәңге алу турында берничә тапкыр сүз кузгатса да, Ирек дәшмәде. Инде ничә көннәр аларның юньләп сөйләшкәне, бергә утырып ашаганы, бергә йоклаганы юк. Менә бүген дә ул, өйләренә якынлашкан саен, күкрәгендә нидер кайный башлавын тойды. Әйтерсең лә нәрсәдер котырта, аның янына кайтмаска куша. Хәер, алай гына түгел, бу көннәрдә Ирек, гомумән, беркемне дә күрергә теләми, беркем белән дә юньләп сөйләшми. Әгәр булдыра алса, музейда эленеп торган каеш чыбыркыны алыр иде дә үзен-үзе ярыр иде. Бу халәтнең нәрсә икәнен ул аңлый да алмый, аңардан котыла алмыйча да җәфалана. Ишегалдына кергәч, ул түр бакча капкасының ярым ачык булуына игътибар итте. Барып күз ташласа, Зәнфирә әллә никадәр җир казып аткан. Әйтерсең лә Ирек ничә көннәр буе шушыны гына көткән иде.

— Әллә дөньяга ут капканмы?! — дип җикерде ул аңа. — Мине көтмичә чыкмасаң, ашаган ризыгым хәрам булыр дип уйладыңмы?

— Әйтеп карадым бит, эндәшмәдең.

— Алайса, үзең чүплә, үзең керт, минем эшем бар!

Ирек шулай диде дә кызулап өйгә кереп китте. Ул Зәнфи-

рә пешереп куйган бәрәңге дучмагын ашамады, бер стакан катык эчте дә чыгып китте. Урам буйлап җил-җил атлады, әмма кая барасын белмәде. Аның максаты бер генә: Зәнфирәгә баш имәү, аныңча эшләмәү, үзе казыган бәрәңгесен үзеннән ташытып бетертү иде. Ахырда, буталып йөри торгач, ул Бәкерләргә барып керде. Бәкер бакчада бәрәңге алып ята иде. Ирек белән салкын гына күреште, ни хәлләрең бар, нишләп йөрисең, дип тә сорамады, борынын тарта-тарта, аска караган килеш казуын дәвам итте. Ирек иелеп бәрәңге чүпләргә кереште, ләкин Бәкер казудан туктады да әллә ничек төксе генә:

— Чүпләмә, үзем чүплим, — диде.

Ирек учын учка бәргәләштереп тузаннарын каккач:

— Мин сиңа нинди начарлык эшләдем соң, Бәкер? — дип сорады.

Бәкер аңа астан гына карап торды.

— Мин «начарлык эшләдең» дидеммени?

— Элек бит аерылмас дуслар идек. Хәзер бар икәнне дә белмисең.

— Менә бу бәрәңге дә тишелеп чыкты, үсте, чәчкә атты. Хәзер корыды. Дуслык та шундый әйбердер инде ул.

— Ә кем корытты соң аны? — диде Ирек, Бәкернең күзләренә туры карарга тырышып.

— Бәрәңгене кем корытты соң? Табигать. Без барыбыз да табигать эчендә.

— Ярый, Бәкер, исән бул, — диде Ирек һәм кызулап аның ихатасыннан чыгып китте.

Ул әйләнеп кайтканда, караңгы төшеп килә иде инде. Зәнфирәнең капчык белән тышкы базга бәрәңге ташыганын күрсә дә, кызулап өйгә керде дә урынына ятты һәм шул килеш тормады.

Иртән ул, гадәттәгечә сәгать биштә үк уянып, тугайларны урап кайтты. Бүген ял көне иде, теләмәсә дә, Зәнфирә белән бәрәңге алырга туры киләчәген уйлап өйгә керде һәм көтелмәгән хәлдән бусага янында туктап калды. Диванга, урындыкларга кием-салым туздырып ташланган, бер зур рюкзакка чүпрәк-чапрак тутырылган, Зәнфирә үрелеп серванттан нидер эзли иде.

— Син нишлисең? — диде Ирек, берни аңламыйча.

— Минме? — Аның тавышы ничектер көчсез һәм битараф иде. — Мин... китәм...

— Кая?!

— Минем өем авылда. Бирегә килеп ялгышканымны хәзер генә аңладым...

Ирекнең башына күсәк белән китереп органдай булды. Зәнфирә әйткән сүзләрнең мәгънәсе аңа тулысынча барып та

җитмәде; әмма бернәрсә ачык — куркыныч йөрәк ярырлык иде! Ул калтырарга кереште, тыны кысылды, иреннәре агарып киттеләр. Ул, Зәнфирәнең каршына ук килеп, күзләренә төбәлде:

— Син... син ни әйтергә телисең?!

— Кайтып китәм...

Ирекнең маңгаена тир бәреп чыкты, ул, ике кулының бармакларын тырпайтып, Зәнфирәгә таба сузды һәм елый-елый кычкырып җибәрде:

— Зә-ән-фи-р-ә-ә!!!

Аның тавышы куркыныч иде, ул аның каршына авып, тезләрен, балтырларын үбәргә, кайнар күз яшьләре белән чылатырга кереште.

— Зинһар, кичер! Мин әшәке!.. Бөтенесенә дә мин гаепле... Кичерә аласыңмы мине?!

Ул, тезләнгән килеш, яшьле күзләрен мөлдерәтеп, башын артка ташлаган хәлдә хатынына ялварып карады. Зәнфирә аны ике култыгыннан сабый баланы тоткандай күтәрде һәм акрын гына битләрен, чәчләрен сыйпады, күз яшьләрен сөртте. Иренең чәчләре кичәгегә караганда да агаргандай тоелды. Ул элекке дә, элекке дә түгел, әмма бик тә кадерле иде... Инде йөзендә җыерчыклар шактый күренсә дә, күзләре яшь чактагы кебек тере, кайнар һәм серле иде.

— Син «китәм» дидең... — Ирекнең күзләрендә курку билгеләре биеште. — Ә мин нишлим?..

— Мин дә арыдым бит, Ирек... — Зәнфирә бармаклары белән аның чәчләрен аралады. — Йөрәгем гел кысылып бетте, әллә инде бөтенләй калмады... — Аның күзләрендәге миһербанлык Ирекка хәл кертеп җибәргәндәй булды. — Ни булды соң сиңа?

— Их, Зәнфирәкәем! — Ирек күз карашы белән аның кашларын, күзләрен, иреннәрен, муенын, иңбашларын каткат капшады, шуннан соң гына үзенең эчендәгесен чыгарды: — Баш түбәмнән төтен чыга, дөрләп яна минем...

— Ни яна?

— Уй, — диде Ирек, акрын гына. — Ул бер бiләсә, кешене йә үтерә, йә күккә чөя...

— Син аны шушы минуттан оныт! — диде Зәнфирә, кинәт тавышын күтәреп. — Сине бер мәртәбә кешелектән чыгара, үтерә язды бит инде ул.

Ирек аңа аптыраулы караш ташлады:

— Син бөтенләй белми сөйлисең!

— Беләм! — диде Зәнфирә, тәмам кызып. — Синең уеңда — аракы.

Ирек әллә ничек сәер генә көлеп куйды:

— Рәхмәт, Зәнфирә. Һаман кайгыртуың, саклавың өчен рәхмәт. Тик минем ул хакта уйлап та караганым юк.

Зәнфирәнең йөзе яктырып китте, ул елмайды, менә-менә талпынып, очып китәр кебек иде.

— Чынлап әйтәсеңме?

— Чынлап.

Зәнфирә әллә нинди якты нур белән өретелде, иртән офыктан таң нурларын таратып килүче язгы кояш кебек күзләре яктырды, бит очлары алсуланды, аңардагы кайнарлык Ирекнең гәүдәсенә кагылган кебек тоелды. Шушы мизгелдә хатыны искиткеч чибәр, чын фәрештә, тере алиһә иде. Ирекнең күңел сызланулары юкка чыкты, аны бер генә уй биләде: «Ул — минеке! Мин нинди бәхетле! Мин шушы җир йөзендәге, бәлкем, бөтен җиһандагы, шушы бердәнбер күркәмлекне, соклангыч алиһә балкышын күрүче бердәнбер кеше булуым белән нинди бәхетле!» Ирекнең күңелендә аңа берәрсенең күзе төшә күрмәсен дигән хафалану уянды һәм шушы күркәмлеккә, Зәнфирәсенә үзе генә хуҗа булу теләге кинәт дөртләп кабынып, үзенең ялкыны белән бөтен барлыгын чолгап алды. Шулкадәр дә рәхәт, шулкадәр дә ләззәтле иде бу утта януы! Әмма Ирек аның тизрәк сүнүен теләде. Кемдер күрер дә, Зәнфирәне үзенеке итү өчен йөри башлар дигән шик әлеге ниятен тагын да көчәйтте. Ул бөтенесен — ләззәт-соклануларын, утларын-ялкыннарын күңеленең иң ерак почмагына яшерергә, беркемгә күрсәтмәслек итеп бикләргә, үзенеке генә итәргә теләде.

Аның шул теләген сизгәндәй, Зәнфирә кинәт җитдиләнде һәм:

— Алайса, сине нинди уй яндыра соң? — диде.

Ирекнең йөзе кинәт җитдиләнде, күзләрендәге яктылык сүнде. Ул тирән итеп көрсенеп куйды.

— Әхнәфкә керү уе...

— Аңа ник керәсең? — диде Зәнфирә, сагаеп.

— Баткан бугай ул...

— Ирек, утыр да әнә романыңны яз. Ул гайбәтләрдән һәр көн баш катып беткән инде. Ник кирәк алар сиңа?

— Син дә ишетеп йөрисең, ә миңа бер әйбер дә әйтмисең! — диде Ирек, үпкәләгән тавыш белән. — Бу әйбәт түгел бит, Зәнфирә.

— Һәр ишетелгән нәрсәне алып кайтып сөйләп, минем синең башыңны бутыйсым, эшеңне бүләсем килми.

— Син бутамасаң, башкалар бутый. Әнә килделәр, сөйләделәр — чәчләрем үрә торды. — Ирек кулы белән өстәлгә таба ишарәләде: — Зәнфирә, әйдә утырып сөйләшик әле.

Алар, бер-берсенә сыенышып, өстәл янына утырдылар. Бераз уйланып торганнан соң, Ирек тамак кырып куйды, теләсә кая чәчелгән кием-салым, чүпрәк-чапрак өстеннән күз

йөгертеп алды, әмма сүзен башлый алмады. Ниһаять, карашын бер ноктага төбәгән хәлдә сөйләп китте:

— Менә син, Зәнфирәкәем, минем башымны бутыйсым килмәде, дисең... Нәрсә ул бутау? Мине борчу. Бу очракта мине коточкыч нык борчырга кирәк! Әле ничек кенә борчырга кирәк! – Ул, бераз тынып торгач, дәвам итте: — Син сүз Әхнәф турында гына бара дип уйлыйсың. Юк шул! Сүз минем тормышым турында да бара. Ник дисәң, Әхнәф — минем тормышымның бер өлеше. Бу зур нәрсә! Шулай булгач, мин аның каршында бик нык гаепле!

Ирек башын иеп тынып калды.

— Нәрсәдә соң синең гаебең?

— Читтән күзәтеп торганга! Миңа күптән очрашырга кирәк иде аның белән! Ә мин, куркак, суздым да суздым...

Ул сине аңламаячак. Синең аның белән очрашуың борчу гына китерәчәк... барыбызга да — Зәнфирә аның ике битеннән тотып чәчләреннән үпте һәм колагына пышылдады: — Инде чәчләрең агарып бетте... Тукта, тынычлан...

— Чәчнең агаруы күңелнең агаруы түгел әле ул...

Иртәгәсен Зәнфирә күргән төшен сөйләде. Имеш тә, бер хатын аңа ап-ак туй күлмәге алып килгән.

— Син аны алдыңмы? — дип сорады Ирек.

— Алдым.

— Матур төш түгел бу.

— Син күлмәкне кем биргәнен сора.

— Кем?

— Фәһимә.

— Болай булгач бөтенләй әйбәт түгел.

— Ә без аны яхшыга юрыйк.

— Әхнәф белән очрашмый торып, бернине дә яхшыга юрап булмый. Кайсыдыр төштән бик нык ярылды...

Шулчак тәрәзә рамына песнәк килеп кунды да сикергәләргә, тәрәзә пыяласын томшыгы белән чукырга, чыркылдарга кереште. Алар икесе дә аңа төбәлделәр һәм кымшанмыйча утыра бирделәр. Ирекка песнәк үзен үртидер шикелле тоелды һәм ул аның чыркылдавыннан туктавын теләде. Ахырда ипи валчыгы салмакчы булып торуга, песнәк очып та китте. Шулчак аңа песнәк түгел, Бәкер булып күренде. Аның арыган, битараф кыяфәте менә хәзергедәй күз алдына килде дә басты, төксе сүзләре колагында яңгырады. Песнәк булып Бәкер килде... «Бу бит дөрес түгел!» дип ачынып уйлады ул. Әмма уйларга боерык бирә алмыйсың. Алар песнәк кебек гел көтмәгәндә күңел тәрәзәңә килеп куналар да ниндидер мөһим хәбәр салып китәләр. Ә кайберләре сине көннәр, айлар, еллар буе бимазалый, аларын ипи валчыгы белән алдап та туктата алмыйсың, бернинди көч белән куып та җибәреп булмый...

## 6

Ирек кабул итү бүлмәсенә кергәндә, сәгать унбер тулып килә иде. Биредә халык бик күп, барысы да пошаманда, йөзләре караңгы, һәркайсының ниндидер авыр мәсьәлә белән керергә әзерләнгәне күренеп тора.

Бер хатын бөтен кешегә ишетелерлек итеп:

— Инде бер ай була, кабул итми, нишләргә белгән юк, — дип куйды, Ирекне өнәмәвен сиздереп.

— Элек Үзәк Комитетка, обкомга жалу яза идек. Хәзер кая язасың? — дип өстәде кайсыдыр.

Төштән соң кабат килде, әмма кабул итү бүлмәсендә халык арткан гына иде. Яңадан ул кичке бишләрдә сугылды. Бүлмә ишеген ачу белән аптырап китте: секретарь кыздан башка беркем дә юк иде.

— Казаннан зур галим килде, Әхнәф Хәсәнович беркемне дә кабул итмәячәк, — диде секретарь.

— Шулай да әйтеп карагыз әле.

Секретарь аңа шылтыратты да:

— Керегез, — диде.

Ирек тирән итеп сулыш алды, яр өстеннән салкын суга сикергәндәй, Әхнәф бүлмәсенең ике катлы ишеген ачты. Керү белән аның күзенә озын өстәлгә таратып ташланган кәгазьләр күренде. Бик зур башлы, киң маңгайлы, күзлекле кеше ул кәгазьләр эченә чумып утыра. Ирек аларның йөзләреннән әле генә ашап-эчеп чыкканлыкларын чамалады, сизелер-сизелмәс кенә аракы, каклаган балык исе килә, арткы бүлмәнең яртылаш ачык ишегеннән анда эшләп утырган телевизор күренә. Ирекка бу кеше ничектер таныш кебек тоелды, аннары кем икәнлеге хәтеренә төште. Ул университетта философия тарихыннан лекцияләр укыган профессор Сазонов иде. Искиткеч үз фикерле булуы, партия җитәкчелегендәге ялгышларны шул елларда ук яшермичә әйтүе белән студентларны таң калдыра иде Сазонов. Аннары профессор кинәт юкка чыкты, эшеннән алганнар, дип сөйләделәр.

Ирек иң элек аның белән, аннары Әхнәф белән күреште. Әхнәфнең күз карашы да, кул кысышы да салкын иде.

— Таныш бул, минем диссертация җитәкчем, — диде дә ягымлы елмаеп Сазонов янына килде. — Сезне хәзер кунакханәгә алып барып урнаштырырлар, мин озакламыйча кагылырмын.

Сазонов, компьютерда басылган диссертацияне һәм кәгазьләрне җыештырып, гаять зур сары сумкасына салды да хушлашып чыгып китте. Ул ишектән чыгуга, Әхнәф, тәрәзә каршына барып, Ирекка сырты белән басты, ике кулын

чалбар кесәсенә тыккан хәлдә, үкчәләрен бер күтәреп, бер төшереп, аягында атынырга кереште.

— Йә, ник килдең инде син? — диде ул, салкын тавыш белән. Әмма бу битараф тавыш түгел, аның һәр сүзе кургаштай авыр, рәнҗешле иде.

— Кирәк булды менә...

— Өеңнән куып чыгарганда, Әхнәф кирәк түгел иде. Хәзер кирәк булдыммыни?

Ирек кулындагы блокнотын бөтерергә кереште, сүзен ничек башларга белмәде.

— Әхнәф... син туктамасаң, харап булачаксың.

— Шушыны әйтергә дип кердеңме?

— Бу кечкенә әйбер түгел. — Ирекнең әллә кайчан уйлап, җепкә тезгәндәй тәртипләп куйган фикерләре таралдылар да беттеләр. — Ник кирәк ул хан сарайлары, машиналар, башкасы?!

Әхнәф, корт чаккандай, тәрәзә яныннан атылып, Ирекнең каршына килеп басты.

— Ничек оят түгел сиңа?! — Аның ияк читендәге миңе дерт-дерт тартышырга тотынды. — Мин җәмгыять кешесе, шәхси тормышым да, әйберләрем дә юк.

— Ә намусың?

— Намусым да шунда! Гомер буе халык өчен яшим, барысы да кешеләр өчен. Ә үземә берни дә юк! — дип кычкырды Әхнәф һәм, бүлмә буйлап йөри-йөри, ярсып туктаусыз сөйләде: — Җанын шайтанга саткан Фауст кебек, үземне шушы эшкә саттым. Мин аш ташыганда — чүмеч, туфан ташыганда — көймә. Бер генә күзәнәгем дә, бер генә минут вакытым да үземнеке түгел. Мин өемә кайткач та глава, хатыныма ир, малаема әти түгел. Көндез дә, төнлә йоклаганда да мин глава, туктаусыз шылтыраталар, әле янгын, әле авария, әле башкасы, өемә килеп керәләр — мин һәр көн сугыш кырындагы кебек. Йортымны да, башкасын да белмим, белергә дә теләмим! Миңа ял итү урыны кирәк: тау куышымы ул, йортмы — барыбер. Тартып алырга телисезме? Алыгыз!

— Мин аның өчен килмәдем. Җан дигән әйбер дә бар бит әле.

— Җаным да юк минем. Ул әнә эш дигән шул гыйфриткә корбан ителгән.

Ирек аны хәйран калып күзәтте. Бу элекке Әхнәф түгел иде. Аның һәр хәрәкәте, күз карашы, һәр сүзе ниндидер олы ялганга буйсындырылган уен иде. Ул урыныннан торды да чыгарга кузгалганда болай диде:

— Мин сине кисәтеп куям, сине халык җыенына чакырачаклар.

Әхнәфнең нәрсәдер әйтергә теләп ачылган авызы хәрәкәтсез калды, маңгае буйлап сузылган җыерчыгы тагын да тирәнәйде, карашы сагайды. Аның хәрәкәтсез калуы Ирек әйткән соңгы сүзләрне аңларга тырышуын күрсәтә иде.

— Димәк, син оештырасың… — диде ул, карлыккан тавыш белән.

— Мин түгел, иҗтимагый үзәк членнары.

— Борынгы кешеләр бер-берсен ашаганнар… — Әхнәф усал карашы белән Ирекне рәхимсез капшады. — Менә хәзер цивилизацияле каннибализм килде, мине ашарга җыенасыз… Син минем уңышларымнан, тормышымнан көнләшәсең. Минем ярдәм белән аякка баскач, миңа каршы күтәрелдең. Башкаларны да миңа каршы котыртасың!

— Син әзрәк суын әле, Әхнәф, — диде Ирек, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып. — Җир йөзендә… безнең тормышта шундый нәрсәләр бар… — Ул аның ярсуын басардай сүзләр эзләде. — Ул нәрсәләр күренми дә кебек… Тамырлары әллә ничә буында… безнең дә канда… Аларны өзсәң, хөкем котылгысыз. Ул вакыт кебек сиздермичә генә килә…

Аны тыңлаган саен, Әхнәфнең күзләре кысыла барды һәм ул, бер-берсенә тоташа язган керфек очлары арасыннан мыскыллы караш ташлап:

— Син шушыны аңлатырга килдеңме? — диде.

Ирек сөйләшүнең барып чыкмаганлыгын аңлаган иде инде. Шулай да аның тып-тын гына бөгелеп чыгып китәсе килмәде.

— Аңламаячаксың, дустым! — диде Ирек. — Ник икәнен дә әйтәм: син бит хәзер ике кеше. Берсе — чын үзең, икенчесе — хыялың белән тудырылган гөнаһсыз фәрештә. Аңа бер сүз дә әйтергә ярамый, ул кагылгысыз. Янәшәңдәге яраннарың фәрештәңне туктаусыз өреп кабарталар, ә ул кабарган саен биеккәрәк күтәрелә…

— Булды! Аңладым, рәхмәт! — Әхнәф кылануга охшатып бераз башын иеп куйды. — Бу ишекнең кай якка ачылганын оныт син.

— Үзең чакырып алырга туры килмәсен.

Ирек эре-эре адымнар белән чыгып китте. Әхнәф арткы бүлмәсендә эшләп утырган телевизорны сүндерде дә плащын киде һәм кинәт туктап калды. «Ирек барысын да сизде! — дип уйлады ул, коты очып. — Аларга җыелыш җыярга ике-өч көн вакыт җитә. Барысы да законлы булачак. Анда бирелгән сорауларга үзеңне коткарырлык җаваплар таба алырсыңмы соң?» Ул чыгып өстәл артына утырды, ияге белән кулларына таянды, күзләрен йомды…

## 7

Сөембикәләр бүген бәрәңге алдылар. Айдар казыды, ул чүпләде. Айдарның эшләвенә күршеләре дә хәйран калып баш чайкадылар. Карап торуга юка гына күренсә дә, көрәккә басып та тормый, кулы белән генә батыра да бәрәңге төбен каерып чыгара. Үзе бәрәңгене йөгерә-йөгерә базга ташый, аның казыганын чүпләп барырга Сөембикә көч-хәл белән өлгерә. Эш гөрләп барса да, Сөембикәнең күңеле үсмәде. Моңа кызы сәбәпче иде. Кичә Айдар эштән кайтып керде дә Сөембикәгә кызыл кофта бирде.

— Ни хөрмәткә? — диде ул, шатлыктан елмаеп.

— Хезмәт хакы алу уңаеннан бүләк.

Аннары ул Айгөлгә малахиттан ясалган искиткеч матур картина сузды. Анда зәңгәр елга ярында үсеп утыручы өч каен сурәтләнгән иде.

— Сиңа да миннән кечкенә бүләк, — диде Айдар, аңа ягымлы караш ташлап.

Ләкин Айгөл борынын чөйгәндәй читкә китте.

— Мин каен яратмыйм, — диде ул, Айдарга арты белән торган килеш. — Каеннар һәрвакыт «Без ап-ак, сез берегез дә безнең төсле була алмыйсыз!» дип мактаналар. Безнең класста да бар андый мактанчыклар.

Айдар белән Сөембикә аптырашып калдылар.

— Кызым, син нәрсә уйлап чыгарасың? Бүләктән баш тартырга ярамый.

— Мин сәбәпсез бүләк алмыйм.

— Алайса, мин сине яңа уку елы белән котлыйм, — диде Айдар, елмаеп.

— Яңа уку елы Яңа ел түгел.

Айгөл шулай диде дә бүлмәсенә кереп китте. Айдар алып кайткан бүләген нишләтергә белмичә аптырап карап калды.

— Әйдә, үзебезнең бүлмәгә элеп куйыйк әле, — диде Сөембикә.

Айдар, аның теләгенә буйсынып, кечкенә кадак какты һәм картинаны элеп куйды. Сөембикә кызы янына керде. Ул дәрес әзерләгән булып утыра, әмма уйларының кайдадыр еракта йөргәне күренеп тора иде. Сөембикә аның янына утырды, йомшак кына итеп чәчләрен сыпырды.

— Кызым, нигә син Айдар абыеңа шулай бәреләсең? Ул бит безгә яхшылыктан башка берни дә теләми.

— Ул миңа әйбәт булып күренмәкче. — Айгөлнең күзләре очкынланды. — Мин андый кешеләрне яратмыйм. Өйдә ул барында иркенләп сулыш ала алмыйм.

— Ә нишләргә тиеш соң ул?

— Мин каян белим? — Айгөл бераз уйланып торды. —

Ул әйбәт булып күренергә теләгән саен, әбием сөйләгән әкият искә төшә. Имеш тә, җиһанда кояшлар тупланган чоңгыл бар икән. Шунда миллионнарча кояшлар балкый, ди. Чоңгылга бер чуар елан хуҗа икән. Ул еланның тиресе йолдызлар белән чуарланган, җем-җем итеп тора. Без төннәрен Киек Каз Юлы дип караган йолдызлар шуның койрык очы, имеш. Елан һәр таңда бер кояшны кабып йота, комсызланып икенчесен дә авызына каба, ләкин йота алмый — тешләп яралый. Кояш, канга баткан хәлдә, аның авызыннан чыгып китә. Ул ярасыннан аккан нурларын безгә көне буе бирә-бирә дә үзләренең каберлегенә төшеп югала, ди. Кояшлар янына килгәндә, елан үтә дә нык юхалана, аларны иркәли, әллә ниләр вәгъдә итә, шул юл белән башкаларыннан аерып ала икән. Әгәр кояшлар аның сүзләренә алданмыйча бергә ятсалар, елан берсенә дә тия алмый икән югыйсәм. Берәрсе үз генә аерылса, ул инде аның корбанына әверелә. Менә шулай кояшларны ашый-ашый, елан йөзләрчә-меңнәрчә еллар буе гомер сөрә һәм бервакыт җирне кабып йотмакчы була, ди. Аны чәйнәргә керешә, яньчи, йота алмый. Әби әйтә, елан безнең җиребезне дүрт-биш мәртәбә йотмакчы булган, ди. Шуның нәтиҗәсендә җир бүлгәләнгән, таулар-упкыннар барлыкка килгән, кыйтгалар бер-берсеннән аерылган. Менә хәзер елан аны тагын кабып йотарга әзерләнә, имеш...

Сөембикә Айгөлнең бу сүзләрен исе-акылы китеп тыңлады. Ышанып сөйлиме ул аны, нәрсәгәдер ишарәлиме, әллә Айдарга бәрелүен аклау өчен генә уйлап чыгарганмы? Ул кызының йөзеннән шул сорауларга җавап эзләде.

— Аңа бәйләнүеңнең сәбәбен әйтимме? Миңа булган үчеңне аннан аласың, — диде Сөембикә, кызып китүдән чак-чак тыелып.

Айгөлнең күзләреннән яшь бәреп чыкты:

— Нинди үч, әни?!

— Нинди үч икәне билгеле: син мине күралмыйсың! — Шушы сүзләрне әйткәч, Сөембикә үз бүлмәсенә чыгып китте...

Менә бүген алар көне буе бәрәңге алалар. Айгөл сәгать бердә үк мәктәптән кайткан иде. Мәктәптә эшем бар, диде дә чыкты да китте. Аның Айдар казыган бәрәңгене чүплисе килми, аның белән бергә эшлисе килми — сәбәп шунда иде. Аларның ике арадагы мөнәсәбәтенең, җәягә тартылган кыл кебек, һәрвакыт киеренке булуы, бу кылга тартып җибәрелгән һәрбер укның йөрәгенең нәкъ уртасына барып кадалуы аны вакыт-вакыт төшенкелек упкынына ташлый, әллә нинди хәвефле уйларга кертә иде. Югыйсә кызының үги әтисенә бәйләнергә бернинди сәбәбе юк. Айдар беренче көннәреннән үк аларның икесе янында да бөтерелеп тора, ул аларның һәр-

бер теләген үтәргә әзер, һәр күз карашларына, һәр сүзләренә сизгер. Күп чакларда ул Айгөлдән кирәк булмаганда да рөхсәт сорый. «Чәй ясыйммы? Ашны кайнарлыйммы? Мунчага барасыңмы?» дип өтәләнеп тора. Айгөл аңа бөтенләй дәшми, йә булмаса борынын чөеп чыгып китә, яисә «үземнең кулым исән», «кайчан телим, шунда...» кебек сүзләр белән аның йөрәгенә чәнчи. Сөембикә, түземе төкәнгәч, кызын йә ишегалдына алып чыгып, йә икенче бүлмәгә алып кереп әрләргә керешә. Ә аның аклануы әзер: «Ул миннән зур яшьтә, — ди Айгөл. — Нишләп үзеннән кече кешедән рөхсәт сорый?» — «Ул сине хөрмәт итә, кызым». — «Мине ни өчен хөрмәт итәргә тиеш ул? Мин аңа гел төртелеп торам. Шулай булгач, ул мине хөрмәт итми, кылана, икейөзләнә. Кояшны йотарга әзерләнгән елан да икейөзлеләнә, шуның белән туена». Икенче бервакытта Айдар аңа дәрес әзерләргә булышмакчы була. Айгөл моңа тагын үзенчә бәя куя: «Бу бит аның миңа булышырга теләвеннән түгел, — ди ул. — Бу аның, син булдыра алмыйсың, дип, мине кимсетергә теләве». Сөембикә үзе бәрәңге чүпләде, үзе туктаусыз шушы авыр уйлар эчендә йөзде. Бәрәңгенең киселгәнен, череген, вагын аерып бер читкә ташлап була, әйбәтләрен генә базга саласың. Ә менә бу уйларны чистартып кара син, чүпләп кара...

Ишегалдыннан берәүнең кереп килүе күренде. Сөембикә, башын күтәреп, җентекләп карагач, аның Мөнир Кәбиров икәнлеген таныды. Менә ул алар янына килеп җитте, кул биреп, хәл-әхвәл сорашты. Күрешкән чакта Сөембикә аның кулының җиңелчә калтыравын тойды. Мөнир абыйсы шактый йончыган, көрән фуражкасы астыннан чал чәчләре тырпаеп чыгып тора, кашлары элеккечә кап-кара булса да, күзләрендә курку ярылып ята иде. Сөембикә аны чәй эчәргә кыстый башлады.

— Чәйләр эчеп торып булмас, сеңлем, — диде Мөнир абыйсы, сәгатенә карап. — Мин Казанга очам. Сезнең белән күрешеп чыгарга гына кагылдым.

— Абыйны озатып кына килим инде алайса, — диде Сөембикә Айдарга.

Сөембикә аны, бик нык кыстап булса да, өйгә алып керде, чәй әзерләргә кереште. Ләкин Мөнир абыйсы аны бу эшеннән туктатты.

— Синнән оят булса да әйтим, чәй минем өчен хәзер бик куркыныч әйбергә әйләнде. Төненә өч-дүрт мәртәбә уята. — Ул өстәлдәге савытка өеп куелган алмаларның берсен алды да шартлатып тешләп чәйнәргә кереште. — Менә шушы җитә миңа, башка берни дә кирәкми. Былтыр бәвелем начар чыккач, хирург Надировка каралырга кердем. Ул мине карады

да, җилкәмнән кагып: «Әле тагын йөз ел яшисең. Бу яшьтәгеләрнең күбесе шулай инде ул, борчылма», — диде. Мин, шуның сүзләренә ышанып, бер ел гомеремне үткәрдем. Хәлем бик кыенлашкач, беркөн икенче врачка кергән идем, Казанга барырга кирәк, диде. Сизеп торам, Надиров сүзе белән гомерне оттырдым бугай. Бу хирург әйтә, нишләп моңарчы йөрдең, ди. Уйлап карасаң, коточкыч! Гомер бит ул! Берәү генә. Башка юк та, булмаячак та.

— Син юкка хафаланма әле, Мөнир абый, — диде Сөембикә.

Ул аның элек-электән үлемнән бик курыкканын, тәненә бетчә чыкса да, яман чир галәмәтедер дип, больница юлларын таптаганын хәтерли иде. Сөембикә аның кирәк-яраклар тутырылган зур сумкасына берничә алма, әле көндез генә плитәдә кыздырган зур тавыкның яртысын тыкты да үзе күтәрде. Барып җитеп, билетына регистрация ясаткач, аэропорт артындагы тип-тигез киң яланга чыктылар. Саргайган каен полосалары, ямь-яшел уҗымнар, сөрелгән басулар, сары эскертләр, саргаеп-кибеп баручы үләннәр — һәммәсе дә күңелдә әллә нинди сагышлы уйлар уятты. Каен полосасы янындагы бәрәңге җирләрендә сабак яндыралар, сыек төтен шуның әчкелтем исен алып килә. Әллә шул истән, әллә башка нәрсәдән Мөнир абыйсы туктаусыз борынын тарта-тарта сөйләргә кереште:

— Әллә кайтам, әллә юк... Синең белән сөйләшмичә китә алмадым... Мин синең алда шулкадәр гаепле, сеңлем...

— Ни сөйлисең, Мөнир абый?! — дип каршы төште Сөембикә. — Иң авыр чакларымда таянычым гел син булдың.

— Булмадым! Дөреслекне әйтәсе урында Надиров кебек алдаганмын. Син кырдагы ялгыз чәчкә кебек сыек идең. Җил кайсы яктан иссә, чәчәк шул якка бөгелә, катырак иссә, сына да. Мин начар җил булдым. Янчуринга ыргыттым... Аннары... үзең беләсең...

Сөембикә күңелендә нindидер кайнар, ачы нәрсә кузгалуын тойды. Ул вакытларны һич тә хәтеренә төшерәсе килми дә аның. Әмма сүз башланган икән, төгәлләмичә кая барасың.

— Хәзер шулай кебек тә... Ул чакта авылда калу минем өчен үлем иде бит.

— Кем белә... Боздым тормышыңны, боздым!..

Аның кашлары сикереп куйды, карашын ул туп-туры Сөембикәнең күзләренә төбәде, сүзләре өзелеп калды. Шактый вакыт бер-берсенә дәшә алмыйча тордылар. Алар самолетның юлына барып җитә язганнар иде. Шуны сизеп, икесе дә кире борылдылар.

Беренче булып Мөнир абыйсы сүз башлады:

— Сиңа ник кергәнемне аңлагансыңдыр... Башта котым алынса да, хәзер мин аның белән килешеп беттем бугай инде...

— Кем белән? — диде Сөембикә, аның сүз сөрешен аңламыйча.

— Үлемне чигендерерлек көчем калмаганлыгын аңлыйм мин. Аннары үләксәдәй сөйрәлеп интегүнең мәгънәсе дә бәләкәй.

Сөембикә аны һаман юатты, юкны сөйләмә, диде, тикшерел, кирәк булса, дәвалан, әле син егетләр кебек, диде. Самолетка утырганда, Мөнир абыйсының күзләре яшьләнде. Аны күрсәтмәс өчен, ул Сөембикәгә арты белән борылды. Ләкин самолетның ишеген ябар алдыннан, түзә алмыйча, тагын әйләнеп карады, Сөембикәгә кул изәде. Самолет күтәрелеп очып киткәч, аның колагында Мөнир абыйсының сүзләре кабат яңгырады:

— Боздым тормышыңны, боздым!..

Сөембикә кайту ягына атлаганда да, һаман шул сүзләр баш миен бораулады. Алар таныш ич. Нәкъ шушы сүзләрне әнисенә Сәпәрәй әйткән иде. Халыкның аңа түземе тәмам төкәнгәч, Сәпәрәйне бервакыт, төнлә кайсыдыр хатынның өеннән чыгып килгәндә, башына капчык кигергәннәр һәм туйганчы кыйнаганнар, күтәреп берничә мәртәбә койрык сөяге белән җиргә бәргәннәр, үкчәсен төйгәннәр, диделәр. Ул, ун-унбиш көн кузгала алмыйча, сидеген эчеп ятты. Аягына баскач, районнан кемнәрдер килеп төште, халык белән сөйләштеләр, аңлатмалар җыйдылар.

Июнь азагына гына хас матур җәйге бер көнне Сәпәрәй канаты сынган кош кебек кайтып керде. Сөембикә китап укый, әнисе фермада, әбисе белән бабасы чәй эчеп утыра иде. Ул, бер сүз дәшмичә, кулларын артка куеп, почмактан почмакка йөри башлады. Аның чыраенда усаллыкның әсәре дә калмаган иде. Шулай да Сөембикә куркудан бөтен тәне белән дер-дер калтыранды, алып бәрмәсә ярар иде, дип коты очты. Сәпәрәй Җәүһәрия кайтканчы шулай йөрде, аннары бер сүз дәшмичә өйдән чыгып китте. Кичкырын Гарәфи алашасына җигелгән кабык арбага утырып кайтып килде. Арбада зур гына тартма бар иде. Аны өйгә алып кереп, өстәлгә конфет-прәннекләр, биш-алты кап шикәр алып куйды. Ашарга әзерләп йөргән Җәүһәриягә зур бер түтәрәм бик симез сыер ите сузды, аннары костюм кесәсеннән боерык чыгарып, өстәлгә куйды:

— Менә монда миңа тиешле өч центнер ипи, алып кайтырсыз, — диде.

Сөембикә дә, әбисе белән бабасы да, берни аңламыйча, аптырап карап утырдылар.

— Ни булды? — диде әнисе, аңа таба якын килмичә генә.

— Минем шулкадәр кеше буласым килгән иде... — Сәфәргали авыр сулап никтер ишек катыннан әйләнеп килде, теше сызлаган кешедәй, яңагын сыпырып куйды. — Була алмадым. Кабат яши алсам, сезне уч төпләремдә генә йөртер идем. Булмый инде... Сизеп торам: күпме тырышсам да, барыбер үзгәрә алмыйм мин. — Аннары дымланган күзләрен әллә ничек чыт-чыт йомып, соңгы мәртәбә күреп калырга теләгәндәй, Җәүһәриягә карап торды да төшенке тавыш белән әйтеп куйды: — Мин генә боздым синең тормышыңны!

Ул кыршылып беткән зур чемоданына барлы-юклы әйберләрен тутырды.

— Мин сезне яңадан борчымам. Теге дөньяда очрашканга кадәр хушыгыз! — Шулай диде дә чыгып китте.

Ул киткәннән соң бер атна эчендә әнисе суырылып кипте. Моны Сөембикә дә, әбисе белән бабасы да шаккатып күзәттеләр. Әнисе юньләп сөйләшмәде, юньләп ашамады, эштән кайтты да караватына барып ауды.

Чыгарылыш кичәсе көнен Сөембикәнең мәңге онытасы юк. Ул иртүк әнисе белән әбисенең мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышына күзләрен ачты. Аннары шундук йомды, йоклаган булып яткан килеш тыңларга кереште.

— Нәрсәсен таптың шуның?! Ни кыяфәте, ни холкы, ни кешелеклелеге! — диде әбисе.

— Их, әнкәй! — Әнисенең лышык-лышык борын тартуы ишетелде. — Миңа тәмуг кирәк. Ул минем өчен җәһәннәм иде. Бу гөнаһлы тәнемне кайларга куйыйм?! Әллә мине әти белән синнән, Сөембикәдән оялмый дип уйлыйсыңмы? — Аның тагын озаклап сулкылдаганы, борын тартканы ишетелеп торды. — Мин әле тәмугта янсам да, ир хатыны идем. Хәзер берни дә түгел. Мич алдындагы утын агачы да миннән бәхетлерәк: ул яна да көлгә әйләнеп котыла. Ә мин күз көеге булып йөри бирәм. Шырпы төртеп яндыручысы юк...

— Алладан курык, кызым! Һәркемнең дә язмышы Алла тарафыннан язылган.

— Минем өчен дога кыл, әнкәй.

— Даутны оныта алмыйсың син.

— Ул минем оҗмахым булган. Мин шул оҗмахтан баш тарттым. — Әнисе тагын үксеп елап җибәрде, сүзләрен күз яшьләре белән кушып дәвам итте: — Ничек үкенгәнемне белсәң, әнкәй! Бу газаплар шуның өчен миңа...

Әнисенең күз яшьләре, кайнар кургаш кебек, Сөембикәнең йөрәгенә тамдылар. Сөембикә, торып ашагач, бакчада эссе кояш астында тыелгысыз ярсу белән бәрәңге кәтмәнләде, ызан араларында күтәрелеп килүче алабута, песи тарысы, билчән, эт эчәгесе кебек чүп үләннәрен рәхимсез кырды. Өйгә керсә,

ни күрсен: Сәфәргали вакытында бизеп беткән хатыннар кабат җыелышып эчеп яталар. Сөембикә, йөрәген ничек басарга белмичә, велосипедына атланып, урманга китте.

Ул кайтып кергәндә, әнисе караватта йоклап ята иде. Сөембикә чәчәкләрне салкын сулы чиләккә утыртты да чыгарылыш кичәсенә киясе күлмәген үтүкләргә ниятләде. Өстәлгә одеял җәйде, учактан алып, үтүккә күмер салды, күлмәген алу өчен сандыкны ачты. Өскә генә куелган ак күлмәк юк иде. Ул әйберләрне актарырга кереште, сандыкның төбенә үк төште, кабат-кабат актарды һәм, ниһаять, күлмәкнең юклыгына инанды. Ишегалдында йөргән әбисе янына йөгереп чыкты.

— Әби, минем ак күлмәгем кая икән, белмисеңме? — дип сорады.

Әбисе аптырап иңбашларын сикертте, авыз эченнән пышылдап, нәрсәдер укынды:

— И балакаем, өченче көн генә карадым бит, шунда гына тора иде.

Сөембикәнең күңеле ниндидер күңелсез нәрсә сизенә башлады. Ул йөгереп керде дә аракы исе аңкытып, тирләп йоклап яткан әнисен селкетергә кереште. Шактый вакыттан соң Җәүһәрия күзләрен ачты.

— Әни, минем күлмәгем кайда? — диде өзгәләнеп Сөембикә.

— Минем эчемдә, — диде дә Җәүһәрия гырлап йоклап китте.

Сөембикә, үз-үзен белештермичә, аның иңбашларына, кабыргаларына сугарга кереште, үзе туктаусыз елады, нәрсәләрдер кычкырды. Әбисе кереп аның кулларыннан әләктерде дә ишегалдына алып чыкты, чәчләреннән сыпырып, иңбашларыннан кагып тынычландырды, салкын су белән юындырды.

— Синең бит чуар чәчәкле күлмәгең бар, кызым. Әле ул агына караганда матуррак та, — диде ул, аның бер алдына, бер артына төшеп.

Сөембикә велосипедына атланды да кабат урманга китте. Ул анда юләр кеше кебек кичкә кадәр йөрде, печәнчеләрдән калган шалашка тап булды. Кояш баеганда, шунда кереп ятты һәм ничек йоклап киткәнен сизми дә калды. Ул уянганда, таң беленә иде инде.

Алар ике көн буе әнисе белән сөйләшмәделәр. Кичтән фермадан кайтып, эш киемнәрен алыштырып маташканда, Сөембикә, аның тәнен күреп, өнсез калды: әнисенең иңбашлары, ябык беләкләре күп-күмгәк иде. Сөембикә кычкырып елап аңа ташланды. Кысып кочаклап алды, күгәргән тәннәрен шашынып үбәргә кереште.

— Әнием, зинһар, гафу ит. Кичерә аласыңмы мине?! — Ул аның күзләренә мөлдерәп карады. — Кичерә аласыңмы син мине?!

— Син мине кичер, кызым. — Әнисе тавышсыз гына үкседе. — Мин кабахәт, чучка...

Алар бик озак елаштылар, Сөембикә һич кенә дә тынычлана алмады, бөтен тормышларын күз алдыннан үткәрде. Күкрәгендә үзе өчен дә, әнисе өчен дә үч алу тойгысы кабынды. Әгәр кулыннан килсә, ул барлык ир-атларны, үзенә буйсындырып, кол итәргә әзер иде. Шуны эшләү мөмкинлеге бар, тик гомереңне генә бир, дисәләр, ул моңа бернинди икеләнүсез ризалашыр иде. Ул ирләрдән гомере буе үч алырга ант итте, әмма антында тора алмады, әнисе кебек үк, ир-атларны үзенә генә хас ярату белән яратты Сөембикә...

## 8

Ирек белән Зәнфирә эштән кайтып ашарга гына утырганнар иде, ишек кыңгыравы шылтырады. Кашыгын куеп, Ирек өйалдына чыкты, ишекне ачып җибәрде. Каршысында иңбашлары аска иелгән, иреннәре ачудан кысылган Әмир Саттаров басып тора иде.

— Әйдә, керегез, Әмир абый, — диде Ирек һәм күрешергә кул сузды.

— Мин сезгә кул бирмим! — Әмир, күзләрен усал елтыратып, кулларын артка яшерде. — Без ышанган идек... Ә сез сатлык булып чыктыгыз!..

— Туктале, Әмир абый, әйдәгез өйгә кереп аңлашыйк. Ни булды?

— Кермим. «Мин сезне Шәрифуллинга әләклим» дип туп-туры әйтергә идегез ичмасам! — Әмир туктап тын алды да мыскыллы тавыш белән дәвам итте: — «Аңа каршы бара алмыйм, булдыра алмыйм, имеш!»

Аягына элеп, Ирек аның янына чыкты.

— Сез юньләп кенә аңлата аласызмы?

— Аңлатып торасы да юк. Әнә хәзер ТИҮдә йөрүче егетләрне берәм-берәм сындырып бетереп баралар. Сәлахов милициясен дә, прокуратурасын да, башкасын да эшкә җиккән. Минем дә үткәннәрне казый башладылар, дәресләремә көн саен йә ронодан, йә үзебездән кеше керә. МСОның бухгалтеры белән мелиорация егетен кыса торгач, берсе эшеннән чыгып, Болынкырдан китәргә йөри, икенчесе, йөрәге тотып, больницага эләккән. Нык ялгыштык без сезгә әйтеп!

Ирек эшнең нидә икәненә төшенеп бетте. Ул үзенең намусы алдында гаепсез булса да, Саттаровлар каршында мең мәртәбә гаепле иде.

— Мин барысын да яшермичә, аның йөзенә бәреп әйттем. Сез миңа ышанган кебек, мин дә аңа ышанган идем, — диде Ирек һәм борылып ишеккә атлады.

— Туктагыз әле, каты әйткәнем өчен кичерегез, — диде Саттаров, аның артыннан ияреп. — Сездән башка булмый. Без бер мәртәбә җыелган идек инде.

— Соң?

— Кычкырыштык та таралыштык. Безгә хәзер аерычөере килмәскә, бер йодрык булып сугарга кирәк.

Ирек, аның эчендә нинди утлар янганын үтәли күрсә дә, алар теләгән учакның үзенең күңелендә кабына алмавын тойды. Ул кемдер эткәнгә йөри алмый, эчке инанусыз кымшанмаячагын күптән белә. Ләкин менә бүген, хәзер, ул үзенә чигенер урын калмаганлыгын аңлады. Җаны-тәне белән карышса да, үзен аклау өчен генә булса да, ул хәзер иҗтимагый үзәк кешеләре алдына чыгып басарга тиеш. Шушыларны уйлаганнан соң, Ирек көрсенеп куйды да:

— Сез ТИҮ егетләрен чакырып чыга аласызмы? — диде.

— Алам, әлбәттә.

— Ул чакта иртәгә сәгать өчкә музейга җыелыйк.

* * *

Сәгать өч тулганда, иҗтимагый үзәк әгъзалары берәмберәм музейга җыела башладылар. Утырырга урыннар әз иде, күпчелек кешеләр басып торды. Санап карагач, ТИҮдәге кырык җиде кешенең уналтысы килгән булып чыкты. Сөйләшү бик кискен башланды. Берәүләр җыен җыю ягын каерса, икенчеләре югары органнарга адресланган хат белән Казанга баруны хуп күрде. Ирек, тарткалашучыларны тынычландыра алмаудан йөдәгәч, музейдагы җиз кыңгырауны шылтыратырга кереште. Шулчак шартлап ишек ачылып китте һәм анда Әхнәф Шәрифуллин белән Фәнис Сәлахов күренде. Бу хәлдән бөтенесе яшен суккандай аптырап калдылар. Карашлар Ирекка төбәлгән иде. Шушы аңа нindидер көч бирде.

— Без монда җыелыш үткәрә идек, — диде ул, дулкынлануын яшерергә тырышып. — Әгәр музейда йомышыгыз булса, җыелышны туктатып торабыз.

— Рәхмәт шундый кечелеклегегез өчен, — диде Әхнәф. — Революция штабы утырышы шушында, дигәннәр иде, хак икән. Безгә дә катнашырга ярыйдыр бит?

— Катнашырга ярый, — дип куйды Ирек.

Әхнәф, экспонатларны барлагандай, кулы белән акрын гына кагыла-кагыла эчкәрәк узды.

— Лентасы-ние белән пулемет бар, автомат-винтовкалар,

штык-кылычлар бар. Кораллы восстаниегә һәммәсе әзер. — Ул стенадагы мамонт сөякләрен сыпырып куйды. — Мамонт сөякләре дә янәшәдә генә.

— Тере мамонтларны мондый кораллар белән генә җиңеп булмас шул, — диде Ирек. — Хәзер аларны аудару өчен атом бомбасы кирәк.

— Йә, нәрсә тикшерәбез? — диде Әхнәф, аның янына килеп.

— Мин бит кисәткән идем, — диде Ирек. — Җыен җыю турында киңәшәбез менә.

— Җыен әйбәт нәрсә инде ул, — диде Әхнәф һәм ТИҮ әгъзаларының йөзенә берәм-берәм озаклап карап чыкты. — Анда ни сөйләшмәкче буласыз инде?

Шулчак Саттаров башкалардан аерылып алгарак чыкты.

— Булабыз, дип әйтегез, Әхнәф Хәсәнович, — диде ул, һәр сүзенә басым ясап.

Әхнәф көчәнеп елмайды:

— Ярар, сезгә каршы килмим. Ни сөйләшмәкче булабыз?

— Халык хакимият җитәкчеләре белән сөйләшергә бик сусаган, диләр. — Ирек Әхнәфкә охшатып елмаерга тырышты. — Шуны оештырырга исәп. Ленин әйткән бит, югарыдагылар булдыра алмый, астагылар өнәми. Бездә дә шундыйрак хәл.

Әхнәф бу кешеләрнең йөзләреннән ахыргача барачакларын аермачык күрде. Куркытулар тәэсир иткән булса, алар бирегә килмәсләр иде. Сәлахов белән ул мәгънәле генә карашып алды да болай диде:

— Ә нигә безгә менә шушылай күзгә-күз карап сөйләшмәскә? Барысын да ачыктан-ачык. Әңгәмәне тәфсилләп газетада яктыртырбыз.

— Әлбәттә, шулай эшләргә кирәк, — дип күтәреп алды аны Сәлахов. — Дөнья кубарып халык җыйсак, бу бит бөтен республикага таралачак. Газета-журналлардан, телевидениедән иснәнеп килеп җитәчәкләр. Үзебезнең эчке мәсьәләләрне үзебез хәл итәргә сәләтле түгелмени без?

— Ай-яй хәйләкәр сез, ә! — дип баш чайкый-чайкый көлеп җибәрде Саттаров. — Хәзер алай эшләргә соң инде.

— Нишләп соң булсын?

— Әгәр сез безнең ТИҮ кешеләрен эзәрлекләмәгән булсагыз, бәлкем, моны эшләп тә булыр иде.

Әхнәфнең йөзенә аптырау билгеләре чыкты:

— Кайда ул? Кемне эзәрлекләгәннәр? — диде ул, якягына каранып. — Сез беләсезме, иптәш Сәлахов?

— Минем андый нәрсәне ишеткәнем юк, — диде тегесе.

— Сез инде безне гел юләргә саныйсыз, ә бездән калган

халык, гомумән, ахмак дип уйлыйсыз. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик.

— Саттаров! — диде Әхнәф, кинәт усал итеп. — Әгәр турыдан-туры сөйләшсәк, син үзеңнән спирт исе генә калганын беләсеңме?

— Әйе, минем андый чирем бар иде. Ләкин мин ул өянәкне җиңдем. Ә менә сезнең чирегез халык күз алдында эшләнә торган җинаять.

— Әле син хакимият башлыгына җинаятьче исеме дә тагасыңмыни? — диде Сәлахов, аның каршына ук килеп.

Саттаров аны этеп җибәргән төсле хәрәкәт ясады:

— Бик якын килмә, биредә нинди кораллар барлыгын күреп торасың. — Аның күзләре әллә нинди кыргый ялтырау белән кабынып китте. — Без сезнең чын йөзегезне ачмыйча туктамаячакбыз.

— Кем кемнең йөзен ачар — карарбыз, — диде Әхнәф.

Алар, дөп-дөп басып, музейның ишеген дә япмыйча чыгып киттеләр.

— Сизденме? Болар туктамаячак! — диде Әхнәф. — Кыйнагыз, кирәк булса, бишеккә салып тирбәтегез, тик җыен дигән нәрсәгә ирек куярга ярамый. Әгәр ирек куйсаң, синең башың беренче булып очачак. Аңладыңмы, Фәнис Сәлахов?

— Мин аны күптән аңладым инде...

Әхнәфнең көне буе кәефе булмады. Башка көннәрне кичке алтыларга-җиделәргә кадәр эшләсә, секретарена бүген булмаячагын әйтте дә сәгать бишенче яртыда җәяүләп кенә кайтып китте. Районда ниндидер зур нәрсә кузгала, аның исе менә шушы сулап барган һавадан да ачык сизелә иде. Фәһимә белән озаклап сөйләшеп, моңа каршы тору планын эшләргә, барысын да җентекләп уйларга, хәстәрен күрергә кирәк. Ул еракган ук үзләренең турында Фәһимәнең машинасы торганын күрде. «Нишләп соң әле машина монда?» дип уйлады Әхнәф. Ул болдырга күтәрелеп ишекне тартты, әмма ул бикле иде. Кесәсеннән ачкыч чыгарып ачты да сак кына адымнар белән эчкә керде. Каядыр еракта Фәһимәнең чыркылдап көлгән тавышы ишетелә иде. Көлүдән ул кычкыруга да күчкән сыман булды, аннары тынып калды. Шоферы Сәгыйрьнең бер генә сүз әйтеп куйганы ишетелде. Әхнәф, ишек төбеннән үтмичә, һаман тыңланып торды. Аның кергәнен сизгәндәй, эчтә дә тавыш бетте. Әхнәфнең күңелен нидер тырный башлады, башына әйбәт булмаган уйлар килде. Эчтә савыт-саба шылтырады, шаулатып су агыздылар. Күрәсең, алар кухняда иде. Әхнәф туфлиләрен салды да плащын ычкындырган, фуражкасын тоткан килеш кухняга узды. Сәгыйрь белән Фәһимә юынгычта шаулатып су агы-

зып нидер эшлиләр һәм көлешәләр иде. Ул тамак кырып куйды. Алар ялт итеп икесе дә аңа борылдылар.

— Исәнмесез, Әхнәф Хәсәнович! — диде Сәгыйрь, кулындагы яшел үләненнән идәнгә су агызып.

— Исәнмесез, — дип төксе генә җавап бирде Әхнәф.

— Менә ухага әрмән үләне кирәк булды да кайтырга туры килде, — диде Фәһимә, аклангандай.

Ул үләнне, Сәгыйрьнең кулыннан алып, полиэтилен букчага салды. Сәгыйрь узып киткәндә, аннан аракы исе бөркелде.

— Син кая җыендың соң әле болай?

— Ничек инде син шундый сорау бирә аласың?! — диде Фәһимә, гаҗәпләнүен яшермичә. — Ревизорларны сыйларга кирәк, кунакханәгә киттем.

Хатынының да авызыннан аракы исе бөркелә иде.

— Озак тоткарланма, сөйләшәсе сүз бар, — диде Әхнәф.

— Кызык син, әйеме? Сиңа иртән кайтырга да ярый, кунакның күңеле булганчы сыйламасаң, ул икенче көнне әллә нәрсәләрне казып чыгара башлый.

Әхнәф Фәһимә белән сүз көрәштереп тормады. Аларның машинага утырып киткәнен тәрәзәдән карап торды да, ихатага чыгып, Миргаяз утыра торган почмактагы кечкенә бүлмәгә керде.

— Килүче-китүче булмадымы?

— Фәһимә Әсгатовналардан башка юк.

— Алар ничәдә кайткан иде?

— Нәкъ дүрттә, — диде Миргаяз.

Әхнәф аның яныннан күңелсез уйлар белән чыкты. Димәк, Сәгыйрь белән Фәһимә өйдә бер сәгатьләп булганнар. Шул гомер нишләмәк кирәк? Ул хатынының иренендәге помаданың да сөртелеп бетә язганлыгына игътибар иткән иде. Сәгыйрьдән бер генә хатын-кыз да калмый, дип сөйлиләр. Әгәр Сәгыйрь шундый икән, Фәһимә каршы тора аламы? Ул үзенең шундый түбән уйлар белән утыруына хәйран калды. Бу чын мәгънәсендә ваклану, ир кеше буларак үз-үзеңне югалту иде. Ә ни өчен ишек бикле иде соң? Ни өчен шофер белән начальник кеше шулай көлешә, чытлыкланып сөйләшә? Аны аяклары ихтыярсыз рәвештә йокы бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Урын-җир изелмәгән, бар нәрсә дә урынында иде. Бәлкем, алар эчкәннәрдер? Ул, кабаланып барып, берәм-берәм рюмкаларны тикшерде, чынаяк-бокалларны иснәп карады — берсеннән дә аракы исе килмәде. Ә нигә алар өйдә эчәргә тиеш? Кичә алар кунакханәдә булдылар, Фәһимә бүген дә шунда ревизорларга сый-хөрмәт күрсәтә. Нишләптер Сәгыйрьнең уртачадан тәбәнәк, юантык гәүдәсе, түп-түгәрәк йөзе, күпереп торган мыегы, муены-

на кадәр үскән саргылт йоннары гел күз алдында бөтерелде. Әллә инде галлюцинация башлана, дип уйлады Әхнәф. Ул һәммәсен дә онытырга теләде, ләкин башын, чүкеч белән төйгәндәй, бер сорау авырттырды: бер сәгать! Бер сәгать нишләп була? Бу бит коточкыч күп вакыт. Әрмән үләнен үстереп алмаганнар ич алар. Түтәлдән алып кереп юу өчен биш минут вакыт җитә.

Төптән уйлап карасаң, һич тә аңлата алмаслык хәл: асылда Әхнәф Фәһимәгә битараф бит. Ә нигә болай бәргәләнә? Менә шушында чагыштыру дигән нәрсә күңелгә килеп керә. Фәһимәнең шоферы яшь, өрлектәй таза, ут чәчеп тора. Әгәр ул аны Әхнәфтән кайнаррак иркәләсә, аңа күбрәк ләззәтләр бирсә? Фәһимә, шуны чагыштырганнан соң, гомерен Әхнәф белән бәйләгәне өчен үкенсә? Юк, хатынының күзе алдында һич тә мескен булып күренәсе килми аның! Аннан да хәтәррәге — алданасы килми! Чыннан да хыянәт итәме ул, әллә шулай тоела гынамы? Ул хатынының күзләреннән, йөрәк тибешеннән, йөзеннән, тәнендәге исеннән, һәр хәрәкәтеннән, үз-үзен тотышыннан әлеге сорауга җавап эзли — таба алмый. Районда беренче зат бул да өйдә мәхлукка әйлән инде. Акылга муафикъ кешенең йөрәге мондый каршылыкка түзә алмыйча шартлап ярылырга тиеш!

Әхнәф инде меңенче мәртәбә тагын бер хакыйкатькә инанды: әгәр бәндәнең башына бер уй керсә, ул, коры мүккә төшкән очкын кебек, иң элек пыскый башлый, аннары төтенли, ахырда ялкынланып үрләргә тотына. Ялгышып кына кергән уй да кешене тәмам чыгырдан чыгарырга мөмкин икән. Сәгыйрьдән ул кайчандыр әллә ничек кенә шикләнгәндәй булды. Моның өчен үзен шундук эт итеп сүкте дә әле. Ә теге уйнап кына калыккан уй эченә корт кебек керде дә утырды, үрчепме-үрчеп, бөтен барлыгын биләде. Хәзер инде ул уйдан Әхнәф Зәлия янында да котыла алмый. Мин монда, алар кайда икән, дип яшерен хафалана, очрашуның тәме китә...

Әгәр Фәһимәгә туп-туры, мин барысын да сизеп йөрим, дип әйтсәң? Ә ул, мин комсомолдан ук сизеп йөрим, гомер буе түзәм, нишләп син сабыр итмисең, дип, авызыңны капласа? Ә син, йөргәнне исбатла, дисәң? Син дә минекен исбатла, димәсмени Фәһимә? Нигә бу тормыш адәм баласын газаплый торган, җавабын берничек тә табып булмастай табышмаклар бирә икән?

Кайчакларда ул, бөтенесенә күз йомып, кул селтәмәкче була. Йөри бирсен, ул бит күпме генә йөрсә дә, Зәлиядән арттыра алмаячак, дип уйлый да шундук сискәнеп туктап кала. Чү әле, ди, туктале, ди икенче тавыш. Зәлияләрдән дә хәтәррәк кыланса? Менә бу сорау Әхнәфне инде чын чиргә

сабыштыра. Фәһимәнең күзләреннән гомер буе комарлык, йөзеннән бетмәс-төкәнмәс дәрт бөркелде, йөрәгенең ярсып тибүеннән, күкрәгеннән чыккан кайнар һавадан борын яфраклары ярсу атныкы төсле киерелеп тора. Ун Зәлияне уздырырга мөмкин ул ачарбак. Болай уйлагач, Әхнәфтә хатынына карата нәфрәт катыш җирәнү тойгысы уяна, кичләрен аның янына кереп ятарга үзен мәҗбүр итә алмыйча газаплана. Фәһимәнең йоклап киткәнен көтеп, залда юк әйберне бар итеп гомер уздыра, янына ятарга кергәч, хатынының ак, таза иңбашларын, беләкләрен умырып-умырып чеметәсе, йодрыклары белән төясе килә.

— Менә бит нинди яман чир йокты. Операция белән кисеп ташлый торган булса, күпме акча сорасалар да кызганмас идең. Әмма кисеп ташлана торган нәрсәләр рәтенә керми шул бу, каһәр. Ниһаять, аңарда берәр көчлерәк экстрасенска күренеп карау теләге туды. Чөнки бу кичерешләренең бик үк нигезле түгеллеген Әхнәф чамалый башлаган иде инде. Казанга алдагы баруында, дөньясының чите кителсә дә, психотерапевтка керергә ныклап карар кылды.

Ул телевизорны кабызды. Фәһимә әзерләп куйган котлетны кайнарлап ашады. Башы таш булып каткан, бөтен гәүдәсе арыган иде. Телевизор карый башлауга йоклап та китте, әллә нинди куркыныч төшләр күрде, бастырылып бетте. Фәһимә кайтып кергәндә, сәгать унынчы киткән иде. Аның күзләренең майланып елтыравы, ике битенең чиертсәң кан чыгарлык булып янып торуы, ерактан килеп бәрелгән тәмәке катыш аракы исе Әхнәфнең ачуын китерде.

— Әллә син тарта да башлагансың инде?

— Тартып күрсәтимме соң? Ха-ха-ха!

Фәһимә, көлә-көлә кухняга чыгып, бер стакан салкын су эчте дә кабат залга керде.

— Нишләп шулкадәр тәмәке исе килә синнән?

— Мин ревизорларны тартудан тыя алмыйм ла инде. Җитмәсә, Сәгыйрь дә машинада туктаусыз пыскыта.

— Нишләп син аңа тарттырасың?

— Минем тәмәке исе яратканымны беләсең лә. Тәмәке төтене иснәгәч, минем башым яктырып китә, әллә нинди фикерләр килә.

— Бик әйбәт вакытың икән, — диде Әхнәф, кинаяле тон белән. — Беләсеңме, ТИҮ бүлекчәсе Ирек җитәкчелегендә халык җыены җыймакчы була.

— Алар тырнак астыннан кер эзләргә ясап куйган кебек инде.

Әхнәф, борынын җыера-җыера булса да, аның янәшәсенә утырды:

— Нишлибез соң?

— Хәзер бу сорауны бирергә соң инде, — диде Фәһимә, аңа ачу белән карап. — Безне синең әнә шул стенкаң харап итте. Бармыйк шул хәерчеләргә, араны шартлатып өзик, дидем. Ә син тыңламадың. Хәзер мин сиңа нинди киңәш бирим?

— Киңәш бирмә, бергәләп уйлашыйк. Без бит синең белән барысын да ачыктан-ачык сөйләшергә сүз бирештек, бернине дә яшермәскә.

— Әйе шул, — диде Фәһимә. — Син аны үтисеңме соң?

— Үтәмичә.

Фәһимә кинәт урыныннан сикереп торды, аның иреннәре дерелдәп китте, ачудан күзләре түгәрәкләнде.

— Сөйләп торасың, сөйрәлчек!

— Нишлисең син?! — диде Әхнәф, гаҗәпләнеп. — Әллә корт чактымы?

— Әйе, Зәлия исемле шөпшә чакты. Мин юләр сиңа ышандым, ә син һаман шул азгынлык юлында. Җирдәге тормышны кабат динозаврлардан башлап буладыр, сине генә яңадан ясап булмый.

— Хәзер син дә гайбәт җыеп йөри башладыңмыни инде?

— Дәшмә, оятсыз! Әнә шул фахишәңнән киңәш сора! Әле бит шуны элемтә бүлекчәсенә урынбасар итеп куярга җыенасың, диләр.

— Барысы да гайбәт! — Әхнәф аклану өчен шуннан ары сүз таба алмады.

— Нишләп синең бүлмәңә кереп йөри ул?

— Миңа теләсә кем керә.

— Фахишәләр свиданиегә киләләрме?

— Тукта, зинһар! Әйт, кем миңа шундый пычрак ата?

— Әйтсәм, иртәгә үк ябырылыр идең. Ирләрнең сөяркәсе турындагы хәбәр, бөтен халык сөйләп, онытып беткәч кенә, аның хатынына барып ирешә дигән сүз хак икән. Әгәр шул фахишәне урынбасар итеп куйсаң, белеп тор: шул көнне үк судка аерылышырга гариза бирәчәкмен! Бусы бер. Икенчедән, син аны районнан китәргә мәҗбүр итәргә тиеш.

— Ничек?

— Юлын тап. Аңа якынаерга юл тапкансың бит.

— Фәһимә, син бөтенләй сүзне икенче якка бордың. Хәл бит бик җитди. Аннан котылу юллары турында минем белән сөйләшергә ниятең бармы?

— Юк! — диде Фәһимә, кистереп. — Мин арыдым, минем йокым килә. Миңа башка бер сүз дә дәшмә!

Үз бүлмәсенә кереп, аның чаштыр-чоштыр чишенгәне, шифоньер ишеген япканы һәм включательгә басып утны сүн-

дергәне ишетелде. Әхнәф, аякларын аерып баскан килеш, япа-ялгыз торып калды. Тулаем алганда, Фәһимә хаклы, әмма менә хәзер аяк астында җир янып килгәндә, ул хаксыз гына түгел, Әхнәфкә һөҗүм итүче дошманга әверелгән иде. Ә кайда соң бер ярдәмче, таяныр кеше? Гомер буе шушы Болынкырда яшәп, нишләп соң аның янында җанын бирерлек бер генә ышанычлы кеше дә юк? Моңа кем гаепле? Әхнәфме, Фәһимәме, биләгән урынмы, әллә бу берни аңламаслык быкырдап аккан болганчык тормыш елгасымы?..

## 9

Кәрәм ләззәт дулкынында тирбәлгән хәлдә йокысыннан уянды. Сикереп торды да, өстенә сырмасын элеп, ишегалдына чыкты. Октябрь үзенекен итә, каты гына кырау төшкән, өй түбәләрен, агачларны, коймаларны һәм җирне сизелер-сизелмәс кенә он сипкәндәй бәс сарган. Инде яктырылып бетеп килә, шулай да әле иртәнең җетелеге җитми, кояш нурлары күк гөмбәзенә җәелә барса да, кыйбла якның һавасы карасу-томанлы булып тора, офык күренми, бераз өстәрәк шул томансу болганчык төссезлек эчендә зур су багы капкачы кадәр ай шәйләнә. Ул өлгермәгән карбызның эче төсле аксыл, бераз гына алсу, уң як чите күренми — юкарып ашалган. Нәкъ шушы айның уртасыннан ниндидер кош очып бу якка килә, канат очлары айның читләреннән үк үтеп чыккан, ул канатларын еш селкетми, очкан чакта өскәрәк тә, аскарак та төшә, уңга-сулга да тартылгалый, үзе гел шул ай турында. Бер карасаң, ул ай да түгел, йомры тишектер, әлеге кош та шуннан очып чыгып болайга киләдер кебек. Биш-ун минут үтмәгәндер, күршеләренең өй артыннан чиста яктылык ныклап җәелә башлады, әмма әле туры нурлар чәчелми. Кояш җиргә яткан чак, бакча түрендәге өйләрнең стеналарына, коймаларга кояш яктысы төшкән, алар саргылт булып күренәләр. Күк йөзендә дә зәңгәрлек кыйблага таба һөҗүм итә. Бакчаның бу башындагы агачларның шәүләләре сузылып түрдәге коймага ук барып җитә.

Кәрәм, ишегалдына чыккач, үзенең җир өстеннән сузылган кара шәүләсенең шуышуына игътибар итте. Ул тагын борылып кыйбла ягына карады, шул арада ай эреп юкка чыккан, кош та күренми, теге болганчык томан да таралып, офыкның сызыгы зәңгәр күк гөмбәзе белән тоташкан иде. «Күптән чакыра, бүген Гайсалардан урап кайтырга кирәк әле», — дип уйлады Кәрәм, күңелендә кайнаган дәрткә буйсынып.

Ашап-эчеп, вак-төяк эшләрне карагач, машинасын әйбәтләп юды, яхшы киемнәрен киде һәм базарга юл тотты. Кон-

фет, апельсин ише әйберләр һәм бер ярты коньяк алып, «Авангард» юлына чыкты. Мәрзия, кая барасың, дип төпченсә дә, юри әйтмәде. Әйтсә, барып керүгә Гайсаларга шылтырата башлар, кеше килде, тизрәк кайт, дип җанга тияр, дип уйлады. Хатыныннан котылып чыгып китү аның өчен еланның кабыгын салуы белән бер, иркенәеп, рәхәтләнеп, яшәреп кала ул.

Аны күргәч, Гайса белән Разия йөгереп каршысына килделәр, кулларын кысып күрештеләр, кат-кат рәхмәт әйттеләр, өйгә чакырдылар. Гайсаның елкылдап торган төрек түбәтәеннән йөрүе, өстәлдә үтүк һәм үтүкләнә башлаган күлмәк торуы аларның каядыр әзерләнүе турында сөйли иде.

— Мин вакытсызрак килдем, ахрысы? — диде Кәрәм, түргә үтеп.

— Сезнең килү вакытсыз буламы соң, — дип өзгәләнде Разия. — Инде безне оныттыгыз, дип үпкәләп тә бетергән идек.

Кәрәм аларның икесенең дә сизелерлек картаеп китүләренә игътибар итте. Хәер, кем белә инде, көн саен көзгедән карап торгач, үзеңне гел шул килеш торам дип уйлыйсың. Бәлкем, алар да Кәрәм турында нәкъ шул фикердәдер.

Разия плитәгә чәй куйды да өстәлдәге күлмәкне үтүкли башлады.

— Коръән ашына барырга әзерләнә идем, — диде Гайса, чалбар каешын ныграк кысып куеп.

— Сине картлар белән йөри дигәнгә ышанмаган идем — хак икән. Әллә чынлап ук ышана башладыңмы?

— Бәлкем, мин элек үк ышанган булганмындыр.

— Юкны сөйләмә! — дип кул селтәде Кәрәм. — Ышансаң, алай яшәмәс идең.

Гайсаның йөзенә ачу чыкты:

— Кайсылай ул?

— Ярар инде, сүз озайтмыйк. Менә бу күчтәнәчләрне алып куй әле, Разия.

Разия күчтәнәчләрне өстәлгә таратты, коньякны да алып куйды.

— Син инде бу юлда йөргәч тотмыйсыңдадыр, мин китәм.

— Юк, юк, җибәрмим! — диде Гайса. — Бер сөйләшеп утырмыйча, ничек инде... Шәраб — Ходай ризыгы, анысын да әзрәк авыз итәрбез. Мин бармый да калыр идем, сүз биргәч, ярамый инде.

— Ярый, мин көтеп утырырмын. Озак буламы ул?

— Сәгать ярым-ике сәгать. Әйдә бергәләп барыйк.

Гайса аның башына бик затлы түбәтәй кигерде, кулына дисбе тоттырды.

Кәрәм икеләнеп калды:

— Барсаң, начар булмас иде булуын.

— Синең катнашканың бармы соң андый мәҗлесләрдә?

— Яшь вакытта гына...

— Бик тә начар, Кәрәм, начар! Үз халкыңның тормышын белмисең дигән сүз бу.

Разия да айга-вайга куймый кыстый башлагач, Кәрәм биреште. Бирешмәс иде, өенә әйләнеп кайтасы килмәде, ике сәгать буе көтеп утыру да аның өчен газап булыр иде, шуңа күрә тәвәккәлләде.

Хуҗалар аларның килүенә куанып бетә алмадылар, Кәрәм Нәҗмиевич, дип, бер алдына, бер артына төштеләр, гел аның янында бөтерелделәр. Түр якта картлар җыелып бетә язган иде инде. Кәрәм белән Гайса аларның һәркайсы белән ике куллап күрешеп чыктылар, картлар аларның килүе хөрмәтенә дога кылды, икесен дә мулла янына түргә үк хөрмәтләп утырттылар. Бик ягымлы итеп бөтенесе, исән-сау гына ятасызмы, гаиләләрегез иминме, балалар-оныклар авырмыймы, дип, хәл-әхвәл сораштылар. Шунда үзара «мәҗлестән соң Хәбир дигән кешенең хәлен белергә кирәк» дип сөйләштеләр. Хәбирне кинәт кенә авыру еккан икән, аягы белән кулын параличлаган.

Бу таныш исемне ишеткәч, Кәрәм:

— Кем ул, әллә элекке баш инженерыгызмы? — дип сорады.

— Әйе, әйе, — диеште картлар.

— Заманында бик яхшы эшләгән иде, техника өлкәсендәге барлык яңалыкны ул кертте, — диде Кәрәм.

Мулла урынында утыручы аның белән килешмәгәндәй итеп болай диде:

— Инженер да, техника да юк, төрмәдә утырган кеше дә юк. Без барыбыз да Хода бәндәләре. Менә шуңа күрә хәлен белергә кирәк тә.

Картлар барысы да үтә дә чиста, пөхтә киенгәннәр, күбесенең чәче кырып алдырылган, башларында түбәтәйләр. Мулланың гаҗәп тә пөхтә итеп кырылган сакалын күреп, Кәрәм хәйран калды. Моны үзе кырды микән, әллә башка кеше башкарды микән, дип уйлады ул эченнән. Тугыз кеше җыелгач, хуҗа килүчеләрнең беткәнлеген белдерде.

Шунда мулла:

— Иң элек йөз мәртәбә тәһлил әйтербез. Аннары иман укырмын, — диде.

Барысы да, дисбеләрен чыгарып: «Лә илаһә иллаллаһ Мөхәммәде рәсүлуллаһ», — дип тәһлил әйтергә керештеләр. Кәрәм дисбенең төймәсен дөрес итеп тарта алмый азапланды, төймәсен тартса, тәһлилен онытты, «лә илаһә»сен әйткәнче, өчәр төймә дә тартып ташлады. Шулай азаплана торгач, ул

дисбене әйләнеп чыкты, әмма башкалар әле һаман авыз эченнән пышылдап тәһлил әйтәләр иде. Ул яшеренеп кенә тагын төймәсен тарткан кебек кылана башлады, астан гына аларның бетергәнен күзәтте. Барысы да төгәлләгәч, дога кылдылар да мулла үзенең юка гына гәүдәсенә һич тә туры килмәгән көчле тавыш белән көйләп Коръән укый башлады. Кәрәм аның күзләренең тулысынча диярлек йомылып бетүен, әз генә елтырап астан күренүен чамалады. Мулла шадра иде. Шадралары да җыерылып, каядыр күз тирәсенә җыелды кебек. Ул бу дөньядан аерылган, үзенең бөтен уйлары белән кайдадыр икенче серле дөньяда иде. Кәрәм картларны берәм-берәм күзеннән үткәрде, арада өчесенең нәкъ мулла кыяфәтендә, бу дөнья кешеләре түгеллеген чамалады. Калганнарының йөзләрендә, кыяфәтләрендә андый инану, билгесез ераклыкка күңел белән тоташу юк иде. Андый нәрсә Гайсада да күренмәде.

Коръән укып бетереп дога кылгач, хуҗалар бер-бер артлы хәер өләштеләр, аннары өстәл өстендәге чиста сөлгеләр белән каплап куелган ризыклар ачылды, һәркемнең алдына чәчәкле сөлге салынды. Юеш һәм коры сөлге белән, акча тотканнан соң дип, бөтенесе дә кулларын сөртеп чыктылар. Олы кәстрүл белән өстәл башына аш чыгарып утырттылды, картларның берсе аш бүлде. Кәрәмнең мондый тәмле токмачлы ашны үз гомерендә дә ашаганы юк иде, картлар да аның кебек үк мактау сүзләре әйттеләр. Аннары бәлеш, ит килде. Чәй алдыннан кемнәрдер алып килгән күчтәнәчләргә атап дога кылдылар, чәйдән соң рәхмәт укып, мәҗлес халкы ашка дога кылды. Кәрәм бернәрсәне игътибарга алды: муллага ияреп, дөньяларын оныткан теге өч карт мәҗлес беткәндә ничектер яшәреп киткәндәй булдылар, аларның күзләрендә дә икенче очкын, бит очларында алсулык барлыкка килде, сөйләшүләре дә башкача иде. Һәркайсы да, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, урыннарыннан кузгалдылар, ашыкмыйча-кабаланмыйча, сөйләшә-сөйләшә киенделәр, икешәрләп-өчәрләп урамнан өйләренә таралдылар.

— Йә, ничек, ошадымы? — дип сорады Гайса, алардан аерылгач.

— Начар түгел инде бу, — диде Кәрәм. — Синнән мәҗлескә кергәнче үк сорармын дигән идем: бу юлга ничек аяк басасы иттең соң әле син?

— Ә син берүзең калып кара, — диде Гайса. — Төнлә дә, иртә-кичен дә — көне буе берүзең. Урамга чыксаң, сиңа юньләп дәшүче юк, клубка-мазар барып утырсаң, ике ягында өч-дүрт буш урын — берүзеңне калдыралар. Бәйрәмнәрдә дә шулай. Күренмәс кыршау белән әйләндереп алгандай, түгәрәк бушлык. Язын да, җәен дә, көз көннәрендә дә, озын кыш

айларында да шулай. Яшьрәкләр, әллә белеп, әллә белмичә, сәлам биреп китәләр китүен, ә сөйләшер кеше юк. Разия белән дә сөйләшеп сүзләр беткән инде. Картларга кушылмый чараң юк. Партия заманнарындагыча әйтсәк, коллектив бит ул. Менә шулай мәҗлесләрдә очрашып торабыз, бер-беребезнең хәлләрен сорашып белешәбез, иң мөһиме — син эшләгән вакытта болай идең, тегеләй идең, дип, беркем дә үпкә белдерми. Үзебез дә елга ике-өч мәртәбә Коръән укытабыз. Разия белән безнең алдыбызда бу олы бурыч булып тора.

Разия аларны өстәл тутырып сый-нигъмәт белән каршы алды. Табын янына килеп утыргач, Гайса белән Кәрәм елмаеп бер-берсенә карадылар.

— Синең теге күчтәнәчне нишләтәбез соң инде?

— Син бит дин юлында йөрүче, хәл ит, гөнаһы сиңа булыр, мин әлегә кушылмаган.

— Ярый, синең хөрмәткә Ходай кичерер. Китер, Разия, күчтәнәчне.

Алар берәрне тотып куйдылар. Гайса, беркаян бернинди хәбәр алмагандай, район хәлләрен комсызланып сораштырырга керәште. Кәрәм сөйләде дә сөйләде.

— Әллә син район газетасы да укымыйсыңмы? — диде ул, тагын бер рюмка тоткач.

— Укуын укыйм, аннан син ни алып була дисең? Беркем берни сөйләмәгәч, утырасың инде күзле бүкән шикелле. Әйтеп торам ич: ялгыз мин.

— Ул хакта алданрак уйларга идең, — дип куйды Кәрәм.

Гайса аңа рәнҗешле караш ташлады һәм ачу белән әйтеп куйды:

— Уйлаттыгызмы соң?

— Йә, йә, шаярттым гына.

— Арсланов белән дөньяны ару болгаттыгыз сез.

— Без микроблар гына булганбыз, менә хәзер динозаврлар эш итә. Нишләгәннәрен белмиләр.

— Ярар, зарланмыйк, — диде Гайса, нәрсәдер исенә төшкәндәй. — Ходай шулай кушкандыр. Минем әйберемне күршем урлый икән, мин аны каргамыйм. Ходай кушуы. Менә син бая Шәрифуллинның властька килүен, халык байлыгын үзләштереп, олигархка әверелүчеләрне сүктең. Ул Шәрифуллиннарны, Сәлаховларны кем тәрбияләде соң?

— Бәлкем, Россиянең шушы хәлгә төшүенә дә мин гаепледер? — диде Кәрәм, йөзенә ризасызлык билгеләре чыгарып.

— Анысын әйтә алмыйм, — диде Гайса, рюмкаларны тотып. — Бусын тотып куйыйк та аннары мин сиңа бер сорау бирәм әле.

Эчкәннән соң, итнең кимерчәклеләрен сайлап чәйни-чәйни, Кәрәм Гайсага төбәлде.

— Әйдә, бир соравыңны.

— Әллә күңелең кытыклана?

— Кытыклануын кытыкланмый да...

— Менә син бая стенканың каян килүе турында Сабитовка әйткәнеңне сөйләдең. — Гайса тагын коньяк салды да Кәрәмгә усал караш ташлады. — Ник кирәк булды инде сиңа аларны маңгайга-маңгай бәрештерү? Һаман тынып булмыймыни?

— Исән кеше беркайчан да тынарга тиеш түгел, — диде Кәрәм, Гайсаның бу сорауны ник бирүен аңламыйча. — Тынса — ул үлә.

— Игелек кылу юлында булса — шулай. Ну, турысын әйткәнгә үпкәләмә, син бит һаман б...та казынасың. Карга кебек.

Гайсаның бу сүзләре Кәрәмнең күңелендә инде картлар белән утырганда ук уянган бер тойгыны дөрләтеп җибәрде. Ничек соң әле баштанаяк гөнаһка баткан Гайса, аны узып, югарыга үрләп маташа? Чиста, илаһи биеклеккә исәп тота. Нәрсә бәрабәренә? Әле менә аның белән бер дәрәҗәдә салып та утыра. Имеш тә, Кәрәм пычракта казына, ә ул фәрештәгә әверелмәкче...

Кәрәм бөтен ачуын берьюлы селкеде дә салды:

— Ә син, шушы картлар белән йөреп, калак сөякләреңә канатлар үсәр дип өметләнәсеңме? Әллә нинди корбаннар чалып, Коръәннәр укытып, хәерләр бирсәң дә, син фәрештә була алмаячаксың. Гомер буе кеше каны эчеп, пакь калып булмый ул.

— Ә минем канны кем эчте? Минем аракы белән болгатып, — диде Гайса, усал карап. — Сез түгелмени?

Кәрәм Гайсаның чирен кузгатмагаем тагын дип, төче елмайды, юк дигән мәгънәдә баш чайкады.

— Мин кан эчмәдем, уйнадым гына, — диде ул, елмаюын дәвам итеп. — Тормыш тактасында шахмат уйнадым.

Ләкин Гайса аның елмаюына тешләрен шыгырдатып җавап бирде:

— Син уйнаганда, мин җан-фәрман, тамырларым шартлаганчы көчәнеп, олы хуҗалыкны күтәрү өчен көрәштем. Бернинди белемсез килеш... Катылыгым да шуннан килеп чыкты.

— Көрәшүен көрәштең, колхоз председателеннән ары күтәрелә алмадың. Һәркем җәфалана-җәфалана югарырак үрләмәкче. Кемдер, ярты сәламәтлеген биреп, райком секретаре, райбашкарма рәисе дәрәҗәсенә күтәрелде. Кемнәрдер обкомга ук үрләде. Тик болар бердәнбер гомереңне кыскарту бәрабәренә, коточкыч стресслар аша эшләнде. Ә мин шахмат кына уйнадым.

Гайса, аның әйткәннәрен аңламыйча, ачулы күзләрен челт-челт йомып Кәрәмгә карап торды да:

— Ул уенның мәгънәсе нәрсәдә соң? — дип сорады.

— Һәрвакыт өстә калуда, — диде Кәрәм, кистереп. — Кемнәрдер тиресеннән чыгардай булып тартышты. Ә мин көчәнмичә генә хәтта Арслановлардан, Шәвәлиевләрдән дә югарыда калдым.

Гайсаның күзләре сәер ялтырап китте, ияге калтырарга тотынды.

— Алайса, син минем белән элекке уеныңны дәвам итәргә килдең?

Кәрәм абайларга өлгерә дә алмый калды — Гайса өстәлдәге барлык нәрсәне ике беләге белән сыпырды да төшерде. Күрәсең, хатыны кухняда аларның сөйләшүен тыңлап торган — шундук атылып та керде. Гайсаны кочаклап алып тынычландырырга да кереште:

— Гайсакаем, зинһар, тынычлан, утырыйк әле урыныңа, син бит тыңлаучан, буйсынучан, сабыр, түземле...

Бу сүзләрне әйткәндә, сул кулын «тизрәк чыгып кит» дигән мәгънәдә аңа таба болгады. Кәрәм җәһәт кенә чыгып ычкынды. Ул ашыкмыйча кайтты, Гайсага килгәннән алып киткәнче булганнарны хәтереннән уздырды, бөтенесен тәртипкә салырга тырышты. Картлар һаман аның күз алдыннан китмәде. Аларның тыныч, шау-шусыз гына яшәүләре кызыктыргыч, кай ягы беләндер мәгънәле дә кебек иде, әмма Кәрәм үзенең беркайчан да бу юлга баса алмаячагын аңлады. Аның өчен җәмгыять кануннарына корылган тормыш кына мәгънәле, ул шунда нидер эшләргә тиеш. Кешеләрнең язмышларына йогынты ясый алмаса, аркылыны торкылыга булса да алып салырга тиеш. Әтисе белән әнисе, әбисе белән бабасы бик диндар кешеләр булса да, Кәрәм яшь чакта да, олыгайгач та алар ышанганнарга ышана алмады, аның өчен бары шушы бер мәртәбә бирелгән гомер һәм җир йөзендәге бердәнбер яшәештән башка берни дә юк иде. Гайсага яңадан беркайчан да бармаска карар кылды ул. Дары мичкәсе янында шырпы белән уйнауның кызыгы юк. Кәрәмнең тормыштагы мәңгелек уенын Гайса аңлый алмады. Аңламавы хәерле дә. Беркайчан да беркемгә дә чыгармаган гомерлек серен чиште дә ташлады бит. Ах, ул уен! Тормыш тактасында үзең оештырган ул могҗиза — иң комарлы уен, бөтен дөньяны оныттыра. Ул чакта хис-кичерешләр шундый да кайнарлана, шундый да нечкәрә, гүя син оҗмах ләззәтләре кичерәсең! Моны үзе татыган кеше генә аңлый ала... Уенның яшәвенең төп мәгънәсе икәнлегенә төшенгәч, Кәрәм дәрәҗә артыннан да, байлык артыннан да кумады. Райком секретаре яисә райбашкарма комитеты рәисе дәрәҗәсенә

үрмәләсә, ул, тыштан өстен калса да, асылда колга әвереләчәк, уйный алмаячак иде. Кәрәм исә, бу эшнең остасы буларак, астагылар белән дә, өстәгеләр белән дә виртуозларча уйнады. Югарыдагыларга үзен түбәндә итеп күрсәтте, көчен яшерде, ә чынбарлыкта алардан өстә калды. Адәм баласының бу дөньядан кайчан китәсе биологик сәгать белән билгеләнгән икән, аның көче дә шуңа җитәрлек итеп үлчәп салынган. Саклап тотмасаң, биологик сәгать белән каралган гомереңне үзең үк кыскартасың. Шуңа күрә җиңел яшәргә, артык көчәнмәскә, борчылмаска, күп вакытта борчылуны уйнарга өйрәнде. Кеше бөтен нәрсәдән, хәтта күз яшьләреннән дә, үлемнән дә ләззәт алырга тиеш. Кеше үлеменнән генә түгел, үзеңнекеннән дә! Кәрәм үлгән чакта да башкалардан өстен калу турында хыяллана. Әгәр үз акылында булса, хәл белергә килүчеләргә, аны саклаучыларга ул елмаячак, авыртуларны җиңеп булса да, телдән калса да елмаячак. Бу елмаюның астында «мин котылам, ә сез әле күпме вакытлар үлемнән котыгыз алынып яшәячәксез» дигән уй ятачак һәм ул Кәрәмгә күпмедер ләззәт, өстенлек бирәчәк...

Кинәт дөнья караңгыланып китте, ябалак-ябалак җепшек кар ява башлады. Кәрәм пыяла чистарткычны тоташтырды. Юл да, ике яктагы урман да, күк йөзе дә юкка чыкты, туктаусыз бөтерелүче, пыялага сыланучы эре кар бөртекләре генә калды. Кәрәм мөштегенә сигарет тыгып кабызды да тәмләп, тирән итеп суырып җибәрде, авыз-борыннарыннан куе төтен чыгарды. Менә шушы медицина агу дип йөрткән тәмәкене дә тәмләп тарта белергә кирәк. Күпләр аны лыш-лыш суыра да ыргыта. Болай эшләү үзеңне алдау гына. Акрын гына суырсаң, төтеннең һәр хәрәкәтен, ачкылт тәмен үпкәләрең белән генә түгел, бөтен гәүдәң белән тойсаң, ул, дәвалаучы бальзам булып, тәнеңә дә, җаныңа да иңә...

Шулчак көтелмәгән хәл булды: машинаның арты кинәт текә күтәрелде дә, Кәрәм каядыр очты, югалды.

— Кәрәм Нәҗмиевич! Кәрәм Нәҗмиевич!

Ерактан килүче таныш тавыш... Кем соң бу? Кәрәм авырлык белән күзләрен ачты һәм үзенең өстенә иелгән Әхнәф Шәрифуллинны күрде.

— Авырткан җирегез бармы? — дип сорады ул.

— Юк...

Кәрәм әле һаман берни дә аңышмый иде. Ниһаять, ул үзенең юлдан читтә яңа яуган кар өстендә ятуын чамалады. Юлдан төшкән «Нива»сының дүрт тәгәрмәче дә өстә икәнен күрде. Юлга биш-алты машина туктаган, кемнәрдер җыелышып «Нива»ны торгызырга маташалар.

— Хәзер «ашыгыч ярдәм» килеп җитәчәк, — диде Әхнәф.

— Нигә? — Кәрәм шулай дип тормакчы булган иде, башы әйләнеп, кабат ятарга мәҗбүр булды.

Ул арада кулына тимер тартмасын тоткан медсестра белән районның баш врачы күренде. Алар Кәрәмне җентекләп тикшергәч, сынган, бәрелгән җире юк, диделәр һәм култыклап «ашыгыч ярдәм» машинасына алып киттеләр. «Нива»ны торгызганнар иде инде. Кәрәм аның арткы тәрәзәсе ватылганлыгын һәм түбәсенең бераз яньчелгәнлеген күрде.

— ГАИ чакыртыйкмы?

— Кирәкми, — диде Кәрәм.

— Ул чакта минем шофер машинагызны ихатагызга кайтарып куяр, — диде Әхнәф.

Больницада тикшергәч, башының бәрелүеннән тыш нәрсә тапмадылар, бер-ике көн ятып чыгарга туры килер, дип, ялгызын бер палатага урнаштырдылар. Әллә башы сызлаудан, зиһене ярсып-ярсып эшли иде. «Бу дөньяда уйнаучы син генә түгел, ахрысы!» — дип үртәде ул үз-үзен. Мондый мажараларга тарырга бернинди нигез юк иде бит югыйсә. Ул иң әүвәл бүгенге көннең, аннары тормышының әле бер чорын, әле икенчесен хәтереннән уздырды, күбрәк уздырган саен, күбрәк буталды. Ниндидер буеннан-буена сузылган дөрес түгел бер җеп бар сыман тоелды, аны зиһене белән күпме генә капшарга, тартып чыгарырга азапланса да, булдыра алмады. Аннары инде моның белән шөгыльләнергә ирек бирмәделәр. Иң элек баш врач хәл белешергә керде. Ул чыгып өлгермәде, апасы Гандәлифә килеп керде. Аның күзләре яшьле иде.

— Бик кызу кайта идеңмени? — диде ул, караватянындагы урындыкка утырып.

— Кызу түгел лә. Кар юлны бутады. Син нишләп йөрисең?

— Нишләп йөрим — авырып ятам! — диде апасы, горурлангандай. Аннары Кәрәмгә таба иелеп иснәнеп алды да өстәп куйды: — Эчмә, дип күпме тукыдым, барысы да шул каһәр суккырыдан!

Аның бу сүзләре дөрес һәм мәрхәмәтсез иде.

— Апа, миңа тып-тыныч ятарга кирәк, диделәр, берни уйламыйча...

— Шулайдыр шул... — Гандәлифә сикереп торды да Кәрәмнең маңгай чәчен берничә мәртәбә йомшак кына сыпырып куйды. — Берүк кенә терелә күр, үскәнем. Син бит минем бердәнбер якын туганым...

Гандәлифә күз яшьләрен сөртә-сөртә чыгып китте. Кәрәмнең күңелендә кызгануга охшаш бер җылы тойгы кымшанып куйгандай булды да шундук сүнде. Юк, апасына күңеле эри алмады, алмаячактыр да. Кәрәм аны, зур тырышлыклар

салып, бергә булырбыз дип, Болынкырга кайтарган иде. Әмма Гандәлифәдән Чукаевага әверелгән апасы Кәрәмнәр алып барган эшләрне теләсә нинди җыелышта, теләсә нинди киңәшмәдә пыр туздырып тәнкыйтьләде, Кәрәмне, энем түзәр, гаепләмәс, дипме, гел юкка чыгарып ташлаган чаклары күп булды. Алары гына җитмәсә, өйләренә килеп сүкте. Апасы аның иң күрә алмаган кешесенә әйләнде. Гомер азакларына якынлашып киләләр, һаман да туганнарча җылы мөнәсәбәт кора алганнары юк. Инде бөтенесе җайланды, шулай тыныч кына яшибез дип йөргәндә, Гандәлифә усал эт кебек өрергә, таларга керешә.

Аның уйларын бүлеп, тыны-көне беткән хатыны килеп керде. Аның артыннан ишектә көнкүреш комбинатының баш инженеры, район финанс бүлеге мөдире пәйда булды. Барысы да аны кызгандылар, барысы да аңа ничек тә булса ярдәм итәргә теләделәр. Гомере буе больницаның кайда икәнен дә белмәгән Кәрәм өчен кинәт кенә бөтенесеннән дә зәгыйфь, көчсез, мескенгә әйләнү башка сыймаслык хәл иде. Шуңа күрә баш врачтан өенә кайтаруны үтенде, барлык даруларны да тиешенчә эчәрмен, ятып кына торырмын, дип инандырды. «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән өенә илтеп куйгач, ул, башы җиңелчә әйләнсә дә, хатынының сузган кулына да тотынмыйча, элекке Кәрәм булып бусагадан эчкә атлады…

## 10

Ирек эшкә китәргә әзерләнгәндә, телефон шылтырады. Трубкада Әмир Саттаровның көр тавышы ишетелде:

— Хәерле иртә, Ирек Хәйриевич! Мин сезгә үземнең чыгышымны бирермен дигән идем. Мәкалә язганда файдалану өчен. Сез хәзер музейга киләсездер бит?

— Әйе, барам, — диде Ирек, теше сызлагандай йөзен чытып.

Ул эшенә теләр-теләмәс кенә атлады, чөнки Саттаров белән очрашу аның кәефен бозачак иде… ТИҮ бүлекчәсенең соңгы җыелышы бик гаугалы булды, ахырда ул кем ни тели, шуны сөйләүгә әйләнә башлагач, Ирек чыгышларны кискен туктатты да үзе торып басты.

— Сезгә зур үтенечем бар, — диде, һәр сүзенә басым ясап. — Мин бүлекчәне оештырдым, күп еллар җитәкләдем. Хәзер сәламәтлегем бик какшады. Шуңа күрә башка кеше сайласагыз, әйбәтрәк булыр. Менә гаризам.

Ирек гаризасын өстәлгә салды. Моның шулай буласын алдан ук белгәндәй, Әмир Саттаров сикереп тә торды, сөйләргә дә кереште:

— Без сезне аңлыйбыз, Ирек Хәйриевич. Ләкин бүлекчәгә сезнең кебек абруйлы кеше кирәк. ТИҮнең формаль җитәкчесе булып кына торыгыз, ә барлык эшләрне үзебез башкарабыз.

Аның сүзләрен хуплап, тагын берничә кеше чыгыш ясады.

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, — диде Ирек алардан соң. — Мин күз буяп йөрергә теләмим. Хәлемнән килгәнчә ТИҮ эшендә катнашырга сүз бирәм. Ә бүлекчәне җитәкләүне без Әмир Җаббаровичка тапшырыйк.

Ахырда аның тәкъдимен хупладылар.

Саттаров, җитәкче булып алгач, тынгысызлыгы, ару-талуны белмәве белән таң калдырды. Ул иртүк торып Нараtбашка китә, мәктәптә дәресләр беткәч, Болынкырга кайтып җитә, әле теге, әле бу оешмага кереп,ниндидер мәгълүматлар җыя, төрле чаралар билгели, һәркемгә нинди дә булса эш йөкли. Күп тырыша торгач, ул халык җыены җыйнауга да ирешә. Әмма җыелыш көнне Әхнәф юкка чыкты, аны ашыгыч рәвештә Казанга чакырып алганнар, диделәр. Аның урынбасарлары, бүлек мөдирләре, аппарат җитәкчесе Фәнис Сәлахов куелган сораулардан төрлечә качтылар яисә өстәнөстән генә җаваплар биреп котылдылар. Әхнәфне якладылар. Кыскасы, бу җыелышта үзара кычкырышудан башка берни дә булмады. Ахырда, районадагы гаделсезлекләрне чагылдырып, республиканың мәртәбәле газетасына зур мәкалә язарга һәм бу эшне Иреккә йөкләргә дигән карар кабул иттеләр. Ирек җыелыштан авыр тойгылар белән кайтты. Халык алдына чыгып, «мин булдыра алмыйм» диярга кыюлыгы җитмәде. Шуның өстенә алдагы көнне генә Мәскәүдән Гроссманнан хат килгән иде. Ничә еллар үтеп тә, аның һаман исән булуына һәм адресны саклавына хәйран калды Ирек. Алексей Абрамович фәнни эш өчен кайбер нәрсәләр сораган. Әйтик, татарларның русларга мөнәсәбәте нинди? Хөкүмәтнең карарларын, ил тормышындагы соңгы үзгәртүләрне халык хуплыймы? Дин тотучылар күпме? Нинди диннәрне тоталар? Халык көнкүрештән канәгатьме? Кешеләрнең якынча ничә проценты хөкүмәт политикасына ризасызлык күрсәтә? Ул кешеләр берәр төрле җәмәгать оешмаларында әгъза булып торалармы? Һәм башкалар, һәм башкалар... Сораулар илнең нигез ташларына кагыла иде. Ирекнең җаваплары берничек тә фәнни эшкә кертерлек факт була алмый лабаса! Алайса, Гроссманга ник кирәк бу нәрсәләрне ачыклау? Нишләп соң әле Әхнәф тә, Саттаров та, әллә кайдагы Гроссман да Иректән нидер көтә? Ул бернинди дә җавап язмаска булды һәм хатны ертып ташлады.

Саттаров аны музей янында көтеп тора иде инде.

— Мин ашыгам, менә сезгә материаллар.

Ирек ул сузган папкага үрелмәде.

— Әмир Җаббарович... Зинһар, мине дөрес аңлагыз, мин бу эшне булдыра алмыйм...

— Үз исемегездән кыен булса, минем исемнән языгыз.

— Юк, мин моны берничек тә яза алмыйм икән... — Ирек, сөйләшү бетте дигәндәй, музей баскычының өченче киртенә күтәрелде, кесәсеннән ишекне ачарга ачкычын алды. — Әгәр мин шуны язсам, үз-үземнән җирәнер идем...

— «Аең, көнең уртак булсын, малың уртак булмасын» дип юкка әйтмәгәннәр шул...

Ирекнең бөтен йөзенә дөртләп ут капты.

— Минем аның белән нинди уртак малым бар соң?!

— Үзегез беләсездер...

— Минем яшерен бернием дә юк. — Ирек, баскычтан җәһәт кенә төшеп, Саттаровның каршына ук килде. — Бөтенесе халыкның күз алдында. Абыну-сөртенүләрем дә, башкасы да. Тормышым Әхнәф белән янәшә узды. Анысын да яшермим.

— Шәрифуллинның җинаятьләрен күрергә теләмәвегез шуннан аңлашыла да инде...

— Аның канына миннән дә күбрәк тоз салучы булмаганын сез яхшы беләсез бит.

— Язучылар әсәрләрендә безне гаделлек, хакыйкать өчен көрәшергә чакыралар. Тик итәкләренә күмер төшсә, үзләре читкә таю ягын чамалыйлар икән...

Әнә шул сүзләр белән йөрәккә пычак кадагандай, Саттаров китеп барды. Ирек, читлектәге җәнлек кебек, арлы-бирле йөрергә тотынды. Ул гаепле иде. Ул барлык кешеләр алдында да гаепле. Әхнәф алдында да, Саттаровлар алдында да, Зәнфирә белән Сөембикә алдында да. Ә иң зур гаебе — үзе каршында һәм Айгөл каршындадыр. Соңгы вакытларда аның белән аралашу теләге, кызын үзенең янәшәсендә күрәсе килү тойгысы аның бәгырен телгәләде. Айгөл исә, уч иткәндәй, торган саен читләшә барды. Өйгә килсә дә, музейга сугылса да, юньләп сөйләшми, сорауларга кыска гына җавап бирә дә китү ягын карый. Моны кызының инде тәмам балалыктан чыгуы, үсеп җитү галәмәте дип аңларга да була, ләкин Ирек белүенчә, бу һич тә алай түгел. Айгөл нык үзгәрде һәм моның нindидер Иреккә билгесез сәбәпләре бар иде. Йөрәгенең януына түзә алмыйча, өченче көн ул аптырап, бик кыен булса да, Сөембикәгә шылтыратты. Сөембикә китапханәдә библиограф булып эшли башлаган иде. Әллә янында кеше күп булды, ул да бик җәелеп китмәде. Бераздан ул үзе музейга йөгереп килеп җитте. Туктаусыз күз яшьләрен сөртә-сөртә Айгөлнең юньләп укымавын, өйдә әле

үзенә, әле Айдарга ташлануын, тырт-пырт чыгып китүен, соң гына кайтуын, алар белән бергә утырып ашамавын сөйләп хәйран калдырды. «Нигә соң син моны моңа кадәр әйтмәдең?» — дип үпкә белдерде Ирек. «Әйтүдән ни файда? Синең янга кереп йөри бит инде ул». — «Кереп йөрсә, аның бит мондый хәлне сөйләгәне юк». Менә шуннан соң Айгөлнең үзенә шылтыраткан, үзе янына чакырган иде Ирек.

Өйлә турында бар дөньяга ябалак-ябалак кар бөртекләре тузгытып буран чыкты. Ноябрь аеның тәүге бураны яшь әтәч кебек усал иде. Төштән соң эшкә барганда, җилнең чырайга бөтереп-бөтереп эре кар бөртекләре сибәләве Ireккә ничектер яшьлек дуамаллыгын, сафлыкны хәтерләтте. Әйтерсең лә ул һәр җиргә үтеп керүе белән, үсеп утырган агачларны селкетүе, дөмбердәтеп өй-каралты түбәләренә кагылып узуы белән чикләнмәгән көч-куәтен күрсәтергә, бөтен нәрсәнең игътибарын үзенә тартырга тели иде.

Ул, музейга кереп, битләрен, кулларын җылытырга да өлгермәде, ишектә Айгөл күренде. Ирек аны йөгереп барып каршы алды.

— Исәнме, кызым? — дип, Ирек аны кочаклап алды һәм алланып торган салкын бит очыннан үбеп куйды. — Укуларыгыз беттеме инде?

— Әйе, бүген иртәрәк бетте.

Ирек аның сумкасын кулына алды.

— Синең соңгы вакытта бер дә көндәлегеңне күрсәткәнең юк.

— И, ярар инде, әти... — Айгөл кып-кызыл булды, күзләрен елтыратып, астан гына Ireккә карап куйды. — Анда өчлеләр мыжлап тора инде.

— Нишләп өчлеләр генә соң анда? — диде Ирек, икәүләшеп өстәл янына килеп утыргач.

Айгөл экспонатларга күз төшереп алды, өстәлдә яткан иске тиен акчаларны бармагы белән әйләндергәләде.

— Кайчангы акчалар бу?

— Петр I заманындагы бакыр акчалар. Ә син бик хәйләкәр, кызым.

Айгөлнең йөзендә елмаю билгеләре чагылып китте.

— Ни әйтәсеңне беләм инде, әти. Әни дә кабатлап тора. Төзәтәм мин ул өчлеләрне. Аттестат аласы ел икәнен дә беләм.

— Ул бик хәтәр әйбер. Өчле көчле, дип юкка әйтмиләр бит. Алар бер сөйри башласа, котылам димә.

— Синең дә шулай булганың бармыни?

— Мин бит университетта читтән торып укыдым. Ул чакта вакыт җитмәүдән газап чиккәннәрне әйтеп бетерерлек түгел. Өченче курста өчлеләр сыртка менеп атлана баш-

лаган иде, көч-хәл белән котылдым да яңадан якын китермәдем.

— Мин дә шулай итәрмен, әти. Яңа елга берсен дә калдырмаска сүз бирәм. Мин бит сине яратам.

— Мин дә сине сагынып торам. Ешрак кил.

— Ярый, килермен.

— Өйдә ничек соң анда хәлләр? Әниең әллә ничегрәк сөйләште.

— Кичә син шылтырату белән аңладым инде. — Айгөлнең йөзенә ачулы кыяфәт чыкты. — Миннән зарланган.

— Хаксызмыни?

— Белмим.

— Каты бәрелмиләрдер бит?

— Юк. Айдар абый ярдәм итәргә генә тора. Ә мин аны юри кире кагам.

— Нигә алай эшлисең?

— Ярдәм иттерәсем килми.

Алар шактый вакыт сүзсез утырдылар.

Ирек торып түр яктан әйләнеп килде, аннары түшенке тавыш белән сүз башлады:

— Әниең алдында да, синең алда да мин гаепле инде, кызым, — диде ул. — Әйдә, әниеңне кабат борчымыйк. Аңа да җиңел түгел бит. Айдар абыеңа да каты бәрелмә.

Айгөл, аның яңагына чалтыратып чапкандай, кинәт кенә:

— Миңа яңа әти кирәкми, — дип ярды да салды.

— Ялгышасың, кызым. Ул бит сезгә терәк. Син аны якын итәргә тиеш.

Айгөлнең керфекләре, иреннәре калтыранып китте, йөзе еларга әзерләнгәндәге кебек кыйшайды. Әллә нинди мескен, хәлсез тавыш белән:

— Әти, гел кайтмассың микәнни?! — диде.

Ирекнең тамак төбен нәрсәдер яндырып алды, күзләрен әчеттереп яшь килде. Ул бит аны һаман кайтыр дип көтә икән!

— Бу инде... кызым, бу хәзер мәңге мөмкин түгел...

— Мин сезнең бергә торуыгызны телим!..

— Әниең белән очрашуыбыз баштан ук ялгыш булган.

— Минем тууым да ялгыш булган алайса? — диде Айгөл, кинәт тавышын күтәреп.

Ирек өстенә кайнар су койгандай сикереп торды:

— Юк, кызым, мин алай дияргә теләмәгән идем.

— Шулай дидең, шулай дидең! — Айгөлнең күзләреннән яшь бәреп чыкты. — Мин бу дөньяда синең өчен артык!

— Кызым, зинһар, кичер мине! — Ирек аны кочакламакчы булды, әмма Айгөл кулын читкә этте дә музейдан чыгып йөгерде.

Ирек тешләрен кыскан хәлдә музейга керде дә хәрәкәтсез калды. Урам почмагына борылып югалган Айгөлнең гөнаһсыз йөзе, рәнҗешле карашы үзәк өзгеч кайнар дулкын булып күңеленә керде. «Әти, син гел кайтмассың микәнни?!» дигән сүзләре колагында яңгырап торды. Кинәт аның күз алдына кызының башлангыч класста укыган чагы килде дә басты. Ул кара көнне Ирек хәл эчендә ята иде... Айгөл килеп керде дә нечкә беләкле бәләкәй куллары белән өстәлне җыештырды, идәнне юарга кереште. Кызын кочаклаганда, сусәргән пальтосы аша аның төртеп торучы ябык калак сөякләрен тойган Ирек үзе дә кулына мунчала алып идәнгә тезләнергә мәҗбүр булган иде. Шул чакта Айгөл, нәкъ менә хәзерге кебек, күз яшьләре аша: «Син безне яратмыйсыңмыни?» — дип сорады да аңа үзе үк: «Юк, яратмыйсың, әти», — дип җавап бирде һәм нәкъ менә хәзерге кебек чыгып йөгерде...

Чәчләргә көмеш сыкылар сибеп еллар узды. Инде кызы сабыйлыктан тәмам чыкты, бер-беребезне аңлаштык дип йөри иде Ирек. Алай булмаган икән шул. Колак төбендә кызының әлеге сүзләре көне буе яңгырады, шуны әйткәндә еламаска тырышуын, иреннәрен әрнеп бөрүе күз алдында торды. Кызына җитдилек килгән, сагыш килгән, балалык чоры еракта калган икән! Айгөлнең ул белмәгән ниндидер уй-кичерешләр белән кайнап торган тормышы барлыгын тою, үзенең әлеге тормыштан читтә калуын сизү аның бәгырен телде. Ирекнең бу дөньяда бердәнбер кызы аңа гаҗәеп якын да, әйтеп бетергесез ерак та иде, моның шулай булуын күкрәк читлеген өттереп яндыручы йөрәге күтәрә алмый иде...

## 11

Ирек эштән гәүдәсен көчкә сөйрәп кайтты. Тавыш-тынсыз чишенде дә бүлмәсенә кереп ятты. Кухня ягында мәшәләнгән Зәнфирә аның янына керде.

— Пилмән әзер иде.

— Мин соңрак ашармын, хәзергә нишләптер берни дә кабасым килми.

Зәнфирә аны сораулар белән бүтән җәфаламады, акрын гына чыгып китте.

Колагыннан һаман кызының сүзләре китмәде: «Әти, гел кайтмассың микәнни?!» И бала! Йөрәгеннән ничә еллар буе кан саркыган! Әгәр Ирек белгән булса, бу канлы яраны ничек тә акрынлап төзәтү хәстәрен күрер иде. Тик шунысы сәер, нишләп соң ул хәзер генә төртеп чыкты? Моңа, бәлкем, Айдар сәбәпчедер? Ул Ирек урынын алгач, кызы аның кай-

та алмаячагын бөтен чынлыгы белән аңлагандыр, Айдар белән элгәләшеп торуы да шуннандыр.

Ирек күзләрен чытырдатып йомды, әмма Айгөлнең рәнҗешле карашыннан котыла алмады, йөрәге сулык-сулык килеп сызды, йөрәге сызган саен, кызының ни дәрәҗәдә үз, якын икәнлеген ныграк тойды. Шул ук вакытта Айгөленнән бөркелүче ягымлылыктан, наздан, җылылыктан аны аерып торучы күренмәс элпә кайнар күз яшьләре кебек күңеленә бәрелде…

Ул, җанына урын таба алмыйча, залга чыкты, телевизорны куйды һәм экранга төбәлгән хәлдә катып калды. Анда Вышка сөйләп ята иде. Шул ук куркыныч ак чырай, озын пеләш баш, пөхтә, затлы костюм, галстук.

— Яшьләрне тәрбияләү проблемасы хәзер безнең ил өчен яшәү белән үлемнең бергә чорналган йомгагы булып тора. — Вышка шулай диде дә, озын имән бармагын күтәреп, өндәү билгесе куйгандай хәрәкәт ясады. — Партия беткәннән соң, без идеологиясез калдык, комсомол таралды. Ә нишләргә тиеш яшьләр? Алар арасына төрле җинаятьчел группалар үтеп керә башлады, алар яшьләрнең зиһенен агулыйлар, кызларны-егетләрне наркомания, бозыклык, азгынлык, көчләү һәм үтерү юлына сөйриләр. Мин бу нәрсәләргә каршы Дәүләт Думасына сайланганчы ук аяусыз көрәш алып барырга тырыштым. Ул көрәш вакытында бик күп авырлыклар кичерергә туры килде. Минем гомеремә күп мәртәбәләр һөҗүм оештырылды, ләкин мин сайлаган юлымнан чигенмәдем. Наркобизнесның тамырлары дәүләт структураларында утыручы чиновникларга кадәр барып тоташа. Мин зур җаваплылык белән белдерәм: бу җинаять өстендә эләгүчеләргә бернинди рәхим-шәфкать булмас!

Аңа тапшыруны алып баручы сорау бирде:

— Сез илне кризистан чыга алыр дип саныйсызмы? Әгәр аңа уңай җавап бирсәгез, моның өчен күпме вакыт кирәк булачак?

— Яшьләрне саклап кала алсак, әлбәттә, ил кризистан чыгачак. Өмет иң соңыннан үлә, диләр бит. Өметләник әле. Вакытын әйтү кыен. Моның өчен ким дигәндә ике-өч дистә ел кирәк булыр. Ирек телевизорны сүндерде дә, бүлмәсенә чыгып, диванга ауды. Аның хәзер караганы берничек тә башка сыярлык түгел иде. Яхшы белән яманның, ак белән каранын, кабахәтлек белән изгелекнең, золым белән кешелеклелекнең үзара буталуы… Җирдәге тормышның җимерелүенең тәүге билгеләре шушыдыр, мөгаен…

Ирек үзен кешесез япа-ялан кыр уртасында калган кебек хис итте. Алай гына да түгел, тормыш аңа явыз көч рәвешендә гәүдәләнде. Театр пьесасын сәхнәгә гарипләндереп

чыгарды. Ике китаптан торачак романының беренчесенә журналларда урын табылмады, кайсылары, мондый әсәрләрне күп чыгардык, диделәр, кайберләре башка сәбәп тапты. Әхмәт, нәшрият хупласа, үзем редакторы булырмын, дип алып калган иде, хат та, хәбәр дә юк. Ирек, сикереп торып, язу өстәле янына чыкты. Икенче романының таратып ташланган кулъязмаларын әле алдыннан, әле азагыннан укырга кереште. Укыган саен гайрәте чигә барды. Үзе язганнарны халыкка юл күрсәтүче Вышкалар белән чагыштыргач, бөтенләй коелып төште. Бүген сабакны Ирекләр түгел, Вышкалар бирә. Нигә алай булды? Югыйсә Ирекнең игелекле фикерләре җиһан биеклекләренә юнәлгән иде. Алар торган саен күбрәк кешеләрнең күңелләрендә урын алырга, ил чикләрен үтеп, Җир шарын биләргә, буыннардан буыннарга күчеп, тормыш сабагы бирергә тиешләр иде. Димәк, Ирекнең хыялын тормышка ашырырга көче җитмәде. Газиз баласының ятимлеге дә, мәңге юылмас рәнҗешле күз карашы да аның намусында. Димәк, аның язарга да хакы юк. Башкаларны яшәргә өйрәтү кебек илаһи эш белән әхлагы югары кешеләр генә шөгыльләнергә тиеш. Ул, кискен карарга килеп, бөтенесен җыештырырга тотынды. Кулъязмаларының барысын да зур бер букчага тутырды, аннары алгы якта сырмасы белән бүреген киде, итеген элде дә ишегалдына чыгып китте. Күк йөзе чалт аяз, чип-чиста чирек ай өй түбәләрен якты нурга коя, аяк астындагы кар аның нурлары астында көмеш тузаны сипкәндәй җем-җем итә. Койма, агач күләгәләре кап-кара булып, ачык сызыклар белән кар өстенә сузылганнар. Ирек, мунча кабызырга чыралап, ваклап куйган утыннарны, тузларны сарайдан алып, бәрәңге бакчасына чыкты. Кар әле тирән түгел иде. Дүрт-биш адым атлагач, итекләре белән сыпыргалап җирне ачкандай итте дә, утыннарны җайлап куеп, шырпы белән тузга ут кабызды һәм аны аска тыкты. Бераз ачкылт төтен чыгарганнан соң, кызарып кына күренгән ялкын өскә күтәрелә башлады һәм утыннар дөрләп янып киттеләр. Ирек букчадан төрлечә бөтәрләп, дыңгычлап тутырган кулъязмаларын умырып алды да бер генә мизгелгә туктап калды. Аның бөтен тәне калтырый, кулы кәгазьләрне чытырдатып кыскан иде. Бугазына ниндидер кайнар төер килеп тыгылды, күзләреннән яшь чыкты, кыргый тавыш белән кычкырып җибәрәсе килде. Кычкырмас өчен тешләрен шытырдатып кысты һәм ыңгырашып кәгазьне ялкынга томырды. Ялкын бер генә мизгелгә сүнеп алды, күрәсең, кәгазьләр аны томалады. Аннары ут күтәрелеп китте, кәгазьләр дөрләп янарга тотынды, янып күмергә әйләнгәннәре берничә кисәккә ваклandылар һәм, йөгереп баручы кара кошларны хәтерләтеп, кар өстеннән читкә шудылар. Шулчак аның артында

аяк тавышлары ишетелде. Ул борылып карады һәм көлмәкчән, яланбаш хәлдә, ялан аягына галуш элгән Зәнфирәнең аңа таба йөгергәнен күрде.

— Ирек, акылыңа кил! — дип кычкырды ул, әллә нинди кыргый тавыш белән, һәм килә-килешкә тезләнде дә Ирек эткәләп куйган карларны шәп-шәрә куллары белән ашыга-кабалана ялкын өстенә көри башлады.

Ирек, берни аңламастан, тораташ катып торды.

Ялкын басылуга, Зәнфирә, кәгазьләр, утыннар өстенә менеп, бөтенесен таптарга керешге, тагын кулы белән, эт оя казыгандай, кар сипте, кисәүләр чаж-чож килде, тирә-юньгә әче төтен, җылы бу таралды.

— Сүндермә! — дип кычкырды Ирек, ниһаять, телгә килеп.

Ул букчасыннан тагын кәгазьләр алмакчы булды, икенче кулы белән Зәнфирәне этеп җибәрергә теләде. Әмма хатыны өлгеррәк булып чыкты. Ул, Ирекнең букчасын тартып алып, муеныннан кочаклады, үзенең иреннәре белән аның күзләрен, маңгаен, колакларын кат-кат үпте, юешләнгән карлы чәчләре белән яңакларына, муенына ышкылды, туктаусыз елады, туктаусыз бер сүзне кабатлады:

— Ирегем, җаным! Зинһар, тынычлан!

Зәнфирәнең бер кат күлмәге юешләнеп беткән, тәне дердер калтырый иде. Ирек аны күтәреп өйгә йөгерде. Хатынының шәрә аякларыннан галушлары салынып, карга чумып калды. Өйгә кергәч, Ирек сырмасын, итекләрен, бүреген ишек төбенә салып ыргытты да диванга барып ауды һәм шул килеш гырлап йокыга китте...

Иртән алар сүзсез генә торып юындылар, кичтән әзерләгән ризыкларны сүзсез генә ашап утырганда, машина килеп туктады.

— Кем йөри бу вакытта?

— Мэлс абый ул. Ачуланма, Ирек, аңа мин шылтыраттым, — диде Зәнфирә.

— Ник?

— Белмим.

— Кичә минем нишләргә азапланганны әйттеңме син аңа?

— Юк, әйтмәдем.

— Менә анысы өчен рәхмәт. Берүк әйтмә. Чыннан да арыдым бугай мин, Зәнфирә. Әле дә ярый син бар.

Ишектә Мэлс күренде. Ул, пальтосын салгач, Ирек белән дә, Зәнфирә белән дә кочаклашып күреште. Зәнфирә аларга өстәл әзерләде. Өчәүләп хәл-әхвәл белешә-белешә чәй эчтеләр.

Зәнфирә Нәфисә турында сораштыра башлагач, Мэлс кул гына селтәп куйды:

— Алып китәсе булмаган икән аны! — дип көлде ул, рәхәтләнеп. — Чын Әби-патшага әйләнде. Эшкә киткәнне, эштән кайтканны сәгате-минуты белән санап кына тора.

— И-и, Мэлс абый, сине бик нык ярата ул, — диде Зәнфирә. — Аңа монда ялгыз яшәве бик тә авыр булды бит. Әнә шул Әби-патша сыйфатлары булганга гына түзә алды ул.

— Арттырып әйтәм, — диде Мэлс. — Аңа да, миңа да акыл керә бугай. Ул пешергән ашлар да ресторанныкыннан тәмлерәк тоела башлады, әйткән сүзләре дә акыллырак сыман.

Зәнфирә эшкә киткәч, Ирек аңа бөтен зар-моңын сөйләп бирде. Бары бер өлешен — кичәге ахмак адымын гына яшереп калдырды.

— Мин чыннан да авырыйм бугай, абый, — дип төгәлләде ул сүзен. — Һаман нәрсәгәдер ирешмәкче булам, тырышкан саен, миңа каршы кешеләр арта бара. Мин ялгыш юлда, ахрысы. Зәнфирә бик урынлы чакырган сине. Элек әти икебезне бәргәләп-суккалап туры юлга чыгара иде, хәзер әти урынына син калдың.

— Алай уйлавың өчен рәхмәт, — диде Мэлс. — Менә тыңлап-тыңлап тордым да каршы төшәргә булдым әле. Ялгыш юлда түгел син. Чиреңә килгәндә, ул синең югары күтәрелгәндәге чирең. Үз-үзеңне күтәрү җиңел түгел. Син аны күптән башладың.

— Ләкин бит, абый, элек болай булмый иде, — диде Ирек, аны бүлдереп. — Әйтсәм әйтим: менә мин хәзер япа-ялгыз. Әнине мондый әйберләр белән борчый алмыйм, Зәнфирә дә син калдың. Ә тынычлык тапканым юк. Туктаусыз күңелем актарыла, бәгырем телгәләнә. Шушындый тормыш өчен тырыштыкмыни соң без?

— Анысы барыбызның да йөрәген яндыра, — диде Мэлс. — Бөгелергә ярамый. Элек без яшь идек. Аннары син үзеңне башкалар дәрәҗәсенә күтәрү өчен бик газаплы чор кичердең. Ә хәзер башкалардан югарырак күтәрелү өчен тырышасың.

Киенеп чыгып машинага утыргач, Мэлс өйдә башланган сүзне төгәлләп куйды:

— Турысын гына әйткәндә, мин синнән көнләшәм, энекәш. Мин калышам кебек.

— Ни сөйлисең, абый?! — диде Ирек, гаҗәпләнүен яшермичә. — Минем өчен син һәрвакыт эталон булдың.

— Һи-и-и-и, энекәш! — дип сузды Мэлс. — Җитәкче — беткән кеше. Гел теләмәсәң дә, пычракка батмыйча булмый. Өстән боералар — буйсынырга туры килә. Коточкыч хәл. Син кызган безне.

— Әхнәфне дәме?

— Әхнәф өчен җавап бирә алмыйм. Ичмасам, син чиста

кал. Бәлкем, мин дә күтәрелермен әле. Ә хәзер карыша-карыша түбән шуам... Шартлар — коточкыч көч, куркыныч система...

Мэлс музейга кереп тормады, алар баскычта кул биреп күрештеләр. Ирек ишектән эшкә дәртләнеп атлады. Гадәттәгечә, Мэлс абыйсыннан аңа ниндидер бик кадерле, җанны җылыта торган нәрсә күчкән иде...

## 12

Узган елны әйбәт кенә төгәлләделәр. Яңа елга атлаганда, игенчелеген дә, терлекчелеген дә, башкасын да бераз матурламыйча булмады. Әхнәфнең район җитәкчесе буларак иске елны төгәлләп, яңасына беренче мәртәбә генә чыгуы түгел. Һәркайда да шулай инде: Татарстан Мәскәү көзгесенә карап, районнар Казан көзгесенә төбәлеп, керфекләрен озайталар, сөрмәсен тарталар, иннек-кершәнен салалар, затлырак киенәләр. Яңа елның икенче атнасында ук, алдан сөйләшенү буенча, районга Николай Николаевич килде. Комсомолдан ук аерылгысыз дуслар булган Әхнәф белән Николай Николаевич искечә Яңа елны иң югары кимәлдә каршыладылар. Дүртесеннән башка (Әнәс Нәбиуллинны кертмәгәндә) беркем дә берни белмәде. Ул киткәч тә, Әхнәф әле шул Яңа ел тантанасы биргән күтәренке рух белән бик озак йөрде. Әмма һич көтмәгәндә аяк астында бомба шартлагандай булды: «Вечерняя Казань» газетасында Әхнәфне җитәкче буларак тар-мар китергән зур мәкалә чыкты. Аны Саттаров язган иде. Мәкаләне укыганда, Әхнәфнең күзләреннән кан тамды кебек. Иң элек аның, район башлыгы булгач та, киң колач белән эш җәелдерүе, экономиканы алга җибәрү, яңа төзелешләр алып бару буенча куанычлы адымнар ясавы күрсәтелгән. Шуннан соң, башка күсәк белән органдай, аңгырайта торган утлы юллар китә. Шәрифуллинны, дигән Саттаров, халыкка ят уйлар били башлады, аның күңеле бүтән эшләргә тартылды. Аның исеменә халык тарафыннан хәзер тискәре мәгънә салына, дигән. Моның сәбәпләре дә күрсәтелә. Өй салулар, машина алулар, максатчан җибәрелгән акчаларның югалуы... Ул акчаларның суммалары, һәрберсенең документ номерларына кадәр күрсәтелгән. Саттаровның моны кайдан, кем аша белгәнлегенә Әхнәф хәйран калды. Мәкаләнең шактый өлешен кадрлар мәсьәләсе алып тора. Имеш тә, үз фикерен әйткән кешеләр, җитәкчелеккә ризасызлыгын белдерүчеләр эштән куылган. Алар урынына ялагайлар, хакимият башлыгының әшнәләре, туганнары җыелган.

Мәкаләнең шулкадәр көйдергеч ирония белән язылуында

Әхнәф Ирек каләмен күрде. Мондый стиль, мондый үтергеч тел белән бары ул гына яза ала. «Әгәр ирек үз фамилиясен куйса, бу кадәр рәнҗемәс идем!» — дип, газетаны Фәһимәнең борын төбендә шатыр-шотыр селкеде ул. Бу арттан пычак кадау гына түгел, аннан да әшәкерәк гамәл иде. Саттаров мәкаләне, ксерокс аша чыгарып, һәр авылга тараткан булып чыкты. Район халкы шау-гөр килде, бу тәнкыйть күпләрне канатландырып җибәрде, Казанга шикаять арты шикаять яудыра башладылар, халык белән ике арадагы каршылык көчәйгәннән-көчәя бара иде...

Бүген Әхнәф, эш бүлмәсеннән кайтырга чыкканда ук, йөрәк даруларын тамчылап санап тормыйча, чәй калагын тутырып кына җибәрде. Урамга чыккач, баскычта бераз тирән сулап торды. Йөрәге тынычлангандай булып китте. Ишеп-ишеп кар ява, җил дә чыга, төнгә буранга көйләргә уйлый, ахрысы. Урам лампалары яктысында менә шулай бөтерелеп карлар яуганда, ул элекләрдә очынып-дәртләнеп атлый, бер басасы урынга биш баса, күңеле әллә кайларга ашкына иде. Шушы яктылыкта бөтерелүче кар бөртекләре, ак күбәләкләр төркемедәй, аның күңеленә очып кереп тулалар, каядыр күтәреп алып китеп, еллар катламын кичеп, сабый балага әверелдерәләр; аягына тимераяк, чаңгы тактырып, чана тарттырып, авылның таныш тавына сөйрәп менгерәләр, инешендә чумачума коендыралар, серле ай нурлары белән тулган урамнардан кызлар-егетләр белән җырлатып үткәрәләр иде... Ә менә хәзер яуган бу кар бөртекләре Әхнәфкә күктән укмашып төшкән корым кисәкләре булып күренделәр. Өенә уравыч урамнар белән кайтса да, борчулы уйлардан ул котыла алмады, җаны тынычланмады, нервылары тартылган кыллар кебек зеңләделәр. Ул кайтып кергәндә, капка төбендә Фәһимәнең машинасы тора иде. Каршыга шоферы Сәгыйрь очрады. Алар сүзсез генә кул биреп күрештеләр.

— Берәр җиргә барасызмыни? — дип куйды Әхнәф, кырыс кына.

— Мин белмим, көтәргә кушты, — дип җавап бирде шофер.

Ишектән керү белән, Әхнәфкә бизәнгән, төзәтенгән Фәһимә карчыгадай очып кунды:

— Нәрсә бик иртә кайттың? Коллектив секс булмадымыни?!

Әхнәфнең башына кан бәрде, йөрәге ярсып тибәргә кереште.

— Син ни сөйлисең?! — диде ул, йөзенә гөнаһсыз кыяфәт чыгарырга тырышып.

— Синең тәтәйләр йортыңны телевизорга төшерергә килгәннәр бит, адәм тәганәсе! — Фәһимә елый ук башлады. —

Бөтен халык шаулый. Мин аның шулай икәнлеген сизеп йөрдем. Бу дәрәҗәдә түбәнлеккә төшәрсең дип уйламаган идем.

— Әйдә, син дә җыя бир инде гайбәт, бергәләп тырышыгыз…

— Ичмасам, дәшмәскә идең! Әнәсең әнә телевизор кешеләрен ул азгынлык урыныгызга кертмәс өчен ачкычын авызына кабып йоткан, диләр. Кабахәт син! Ничек җир күтәрәдер?

Бу сүзләрне әйткәндә, Фәһимә киенеп беткән иде инде. Ул нәрсәләрдер тутырылган сумкасын алды да ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

Әхнәф, өстен дә салмаган килеш, ишек янындагы кечкенә урындыкка утырды. Хатынының бу сүзләре аның өчен бик күп нәрсәләрне ачып бирде. Әйе, бүген телевидение кешеләре аның янында булдылар. Әллә нинди сораулар биреп, Әхнәфнең җанын ашадылар. Барысын да төшереп бардылар. Ә менә аларны ял базасына барырга кем өйрәткән? Ничек «коллектив секс» дигән нәрсә халык теленә килеп кергән? Бусы башка сыярлык түгел. Бу мәсьәләләрдә комсомолда эшләгән чакта ук конспирацияне тиешле югарылыкка куйганлыгы өчен Әхнәф һәрчак макталды, күпләрне шаккатырды. Үзенә калса, ул хәзер дә нәкъ шул чаклардагыча эш итте. Ә менә ялгышкан икән, димәк, барысын да сизгәннәр, күзәткәннәр. Ярый әле Николай Николаевич белән булганда шунда телевидение килеп басмаган. Менә бит нинди адәм баласы: ерып чыга алмаслык нәрсәгә кер дә, моннан да начаррак булу ихтималы бар иде бит, дип куан. Юк инде, суга төшкән тавыкның бер мөшкел талпынышы гына бу…

Ул өстен-башын чишенде дә, торшерны гына кабызып, залга кереп ятты. Фәһимәдән аракы исе килә иде. Менә хәзер генә шушы нәрсәгә игътибарын туплый алды Әхнәф. Нишләп эчкән соң әле ул? Сумкасына әйберләр алып, бу вакытта кая бара? Әллә, чыгып китәргә уңайлы булсын өчен, юри тавышландымы ул? Мондый хәлләр шактый еш кабатлана башлады. Фәһимә белән әле кайнар сөешеп, кыз белән егет булып йөргәндә үк, Әхнәф аның күзләренең ниндидер комарлык, беркайчан да канәгать булмау билгеләре белән ялтыравын шикләнеп күзәтә иде. Ул чакта ук бу күзләрнең, үзенә генә шулай майлы карап, башкаларга коры, салкын рәвешкә кермәгәнен ул яшерен көнчелек белән уйлап йөрде, әмма берни дә кыла алмады. Өйләнешеп яши башлагач, гаилә камыры ябыша алмыйча таралып-төерләнеп торганда, берничә мәртәбә аерылу чигенә җиткән чакларда, хатыны көне-төне кайнар яшь койса да, ул яшьләр аның күзләренең

ялтыравын юып төшерә алмадылар. Күрәсең, мае гомеренә җитәрлек иде.

Әхнәф йоклап киткәнен сизми дә калды. Күзләрен ачса, ике сәгать узган! Ул ашамады-эчмәде, иңбашына тунын салып, ишегалдына чыкты, капка янына барып, аның кайтып керүен көтте, әмма хатыны күренмәде. Ә тышта инде юлларны капларлык булып буран котыра, койма буендагы көртләр җил бөтерүдән, сабан төрәне рәвешенә кереп, өскә күтәреләләр. Ачуы, гарьлеге, рәнҗеше эченә сыеша алмыйча бәргәләнгән Әхнәф башта, хатыны кайтып керү белән, аның яңагына тондырырга әзерләнде. Бары шуннан соң гына акыртып елатып, сытып, кайда йөргәнен сыгып чыгарырга, яңадан кабатланмаслык итәргә ниятләде. Ул, шушы гамәлен, әйтәсе сүзләрен эченнән кабатлап, өй буенча идәннәргә дөп-дөп басып, читлектәге җәнлектәй йөрде. Әмма вакыт узган саен, ниндидер көч, аның итәгеннән тарткандай, моны эшләмәскә кушты. Ахырда ул әлеге көчкә буйсынды һәм буйсынуның сәбәбен дә аңлады: хатынының «коллектив секс» дип очып кунуы. Әгәр Фәһимә төпченә башласа, берни алдында да туктамаячак. Моны уйлагач, аның тәне эсселе-суыклы булып китте. Тормышның шушы рәвештә агуын саклап калу өчен, шик-шөбһәләрен йотарга, күпмедер чигенү булса да, дәшмәскә кирәк. Бу карарга килгәч, аның эчендәге яшерен уе баш калкытты: ник сиңа читләр белән шаярырга яраганны аңа ярамый? Яши башлаганда, бөтенесен дә кылып була, хәзер, гомер азагы җиткәндә, акыл белән эш итү сорала. Хәзер килеп чыккан матавыкта бигрәк тә. Бер уйласаң, коточкыч хәл: тыштан караганда син нинди биектә! Бөтенесе хөрмәт итә, мактый, һәр боерыгыңны үтәргә әзер торалар, сиңа төбәлгән күзләрдә бирелгәнлек, йөзләрдә ягымлы һәм ялагай елмаю. Үзеңә әүлия итеп карауларын һәр секунд сизеп, күреп торасың. Шәхси тормышыңда берәр нәрсә шылт кына итсен! Аны шундук күпертеп, мең төрле калыпка салып төрләндерәләр, шау-гөр киләләр. Шушыны булдырмау өчен син посасың, барлык уй-теләкләреңне үзең үк тышаулыйсың һәм тере мәеткә әвереләсең. Чөнки син хакимият башлыгы, синең урының биек, шуның өстенә әле намусың чиста булырга тиеш. Шушы хәл сине машинага әверелдерә. Чын үзең, ягъни тере Әхнәф читтә сыкрап, рәнҗеп тора. Әмма ул рәнҗесә дә, үз-үзеңнән баш тартырга, җаныңны-тәнеңне үтерергә куша. Үтереп кара! Шуннан туа да инде яшерен гамәлләр... Әнә шулай арттан куалаучы көч буенча тормыш арбасын алга таба этәсең дә этәсең. Ләкин син кеше түгел, хисләреңне, уйларыңны хәрәкәтсезлеккә дучар иткән, яшәмичә яшәүче җан иясе. Бөтенесе томаланган, йөрәк карышса да тыелган.

Моннан котылу өчен бер юл бар кебек. Ул юл — эшеңнән баш тарту. Гади кешегә әверел дә тышауларыңны чишеп җибәр, кирәксә, өр-яңа гаилә кор! Әмма Әхнәф мондый уйларын рәхимсез куды. Ул тышкы дөньяның борчуларына түзә алмаячак, салкынын-җылысын, авырлыкларын, мохтаҗлыкларын җиңү өчен ялгыз тырышырга аның көче җитмәячәк. Ул яшь чакта гел үзенә генә ышана иде, ә менә хәзер яшь чактагы «үзе» дигән нәрсә юк! Әйе, ни аяныч, юк! Шулай булгач, бары тик башкаларга гына таянып була. Синең кул астында үтәүчеләр армиясе күзеңә карап тора, җаваплылыкның зурысы синдә булса да, башкаручылар алар. Боерганың үтәлмәсә, алар гаепле, күсәк алар башына төшә. Алар — атакага баручылар. Бу һөҗүмдә башлар да киселә, күпләп корбаннар да салына, әмма син урыныңда каласың. Калу өчен, әлбәттә, кәнәфиеңне күз карасы кебек сакларга, көрәшергә кирәк.

Элек аның эчендә нииндидер гаҗәеп кояш бар иде. Ул да гел көлеп кенә тормады торуын. Әмма ул беркайчан да сүнмәде, кайчакларда шулкадәр куәтле җылытып, нурлап җибәрде, җирдән атлап түгел, очып йөри башлый идең. Әхнәф көчне гел аңардан алды. Ә хәзер ул кояш югалды. Бүген аның өчен кояш Казаннан чыга, елмайса да, йөзен чытса да, аңа якыная алмыйсың. Моның шулай икәнлеген менә хәзер районда купкан мәхшәр вакытында бик ачык тойды Әхнәф. Кояш салкынайды да, нурларын да киметте. Югарыдан шылтыратулар да кимеде. Казанга барсаң, салкын гына күрешәләр, сөйләшү кыска һәм һич тә синең файдага булмый. Бөтенесе дә элеккечә кебек, ләкин сизеп торасың, сиңа ниндидер котылгысыз йогышлы чирле кешегә карагандай карыйлар, читләшәләр, үзләренә дә ул авыруны йоктырудан куркалар кебек. Әле анысына гына түзәр идең, үзең кебек хакимият башлыклары да читкә кагарга тырышалар, гүя ул уртак эшкә хыянәт итте. Әле өченче көн генә Казанда киңәшмәдә утырганда, әллә юри ишетсен дип, аның артында ике коллегасы пышын-пышын сөйләштеләр. Сүзнең үзе турында барганын Әхнәф аңлап утырды. Иң соңыннан берсе, бөтен сөйләшкәннәренә йомгак ясап: «Бер т... сыер бөтен көтүне пычрата инде ул», — диде.

Аның фикере кая барып бәрелергә белмәде, тик ул бер нәрсәне бөтен рәхимсезлеге белән сизде: яшь чактагы кояшыңны, үзеңне табарга кирәк. Ә каян, ничек табарга аны? Кемнәр белән эзләргә? Кайчакларда һич уйламаганда теге яки бу авыр мәсьәләнең асылына бик ансат кына төшеп, күзне һәм зиһенне ачып җибәрә торган Фәһимә дә әнә төнгә каршы чыккан котырган буран эченә кереп югалды. Ул буран эченә кереп югалды, Әхнәфне бүтән буран куркыта, адаштыра, беркайчан да туктамый торган буран чолгап алды...

## 13

Бүген физкультура дәресендә чаңгыда узыштылар. Айгөл кызлар арасында икенче урынны алды. Соңыннан бер төркем малайлар, кызлар спорт мәйданчыгында туйганчы шаярыштылар, үртәштеләр, куыштылар, кар сибештеләр. Әле өйгә кайтып кергәндә дә Айгөлнең дулкынлануы бетмәгән, бит алмалары ут яна иде. Зал ягында китап укып утырган Айдар абыйсына да ул башка күзләр белән карады, әллә әтисенең үгетләүләре тәэсирендә, әллә болай гына, аның муеныннан кочаклап аласы килде. Ике-өч мәртәбә аның яныннан акрын гына үтеп китте, әмма ул күтәрелеп карамады. Соңгысында Айгөл бер генә мизгелгә аның кырында туктап калды, чәченнән сыпырмакчы булды. Ул хәтта арттан килеп кулын да сузды, бармак очы белән аның дулкынланып торучы чәчләрен турылыйсы һәм маңгаена төшкән бер учмасын өскә күтәреп куясы килде, тик кыюлыгы җитмәде. Әйе, әтисе хаклы. Аларга бергә яшәргә, бергә яшәп аеры да, аеры яшәп бергә дә булып була икән шул. Әнисе дә, әтисе дә аның Айдар абыйсы белән тату яшәвен тели икән, ни өчен карышырга? Моның сәбәбе дә юк кебек.

Ул кухняда кулларын юып, плитәгә чәй куеп йөргәндә, гадәттәгечә аның чыгып өстәл әзерләвен, гадәттәгечә мәктәп хәлләрен соравын көтте. Әмма бүген Айдар абыйсы чыкмады. Әле бая гына аның янында җылы тойгыларын ничек белдерергә белмичә бөтерелеп йөргән Айгөлнең ачуы кабарды. Ул юньләп ашамады, савыт-сабаларын да юмады, шалтыр-шолтыр китереп өстәлгә өйде дә куйды. Айдар һаман дөньясын онытып китап укып утыра иде. Әйдә, санаса Айгөлне бала-чагага саный бирсен. Ул үзенең бүлмәсенә керде дә күлмәген, гамажын салып ыргытты, тездән күпкә югары халатын киеп, көзге каршына килде, аннары нидер уйлады да аның өске һәм аскы сәдәфләрен ычкындырып җибәрде. Халат, уртадагы сыңар сәдәфкә эләгеп, ярым ачык хәлдә калды. Аңа күлмәген үтүкләргә марля кирәк иде. Юри дөп-дөп басып чыгып, залдагы сервантның бер бүлкәсен ачты да актарынырга керешге. Шулчак Айдар, аңа таба башын борып:

— Чит кеше каршында болай йөрмиләр бит, Айгөл, — диде.

Айгөлнең ачудан күзләре елтырап китте, йөзенә мыскыллау билгеләре җәелде:

— Син бит чит кеше түгел, — диде дә, әллә нинди ят, үтергеч басым белән: — Үги әти, — дип өстәде.

— Әти кеше алдында бигрәк тә ярамый.

— Ничек телим, шулай йөрим! — Моңарчы тыеп килгән

ачуы Айгөлнең тәнен калтыратып җибәрде. — Сиңа ошамый икән, анысын мин әйтә алмыйм. Ошый торган кешеләреңә кара.

Айгөл марляны алды да, дөп-дөп басып, тагын бүлмәсенә кереп китте. Бүген беркая барырга тиеш булмаса да, кайсыдыр күлмәген алып үтүкләде, киенде, һәм, бер сүз дә әйтмичә, ишекне шартлатып ябып чыгып китте.

Урамга чykканда, ачудан аягы белән карны капкага таба типкәләде, чәчте, итеге тезгә кадәр карга буялды, аны ике куллап тырный-тырный чистартты, әмма күңелендәге ачу һаман басылмады. Кая барганын да белмичә, урам буйлап китте. Айгөлне Айдар абыйсының үзенә карата бөтенләй битарафлыгы котырта, ул вакыт-вакыт аңа йодрыклары белән ташланыр дәрәҗәгә җитә. Иң гайрәт чигергече шунда: битарафлыгын яшерү өчен, ул һәрвакыт игътибарлы булып кылана. Ә бит әнисе белән ул үзен бөтенләй башкача тота, аның бер генә мәртәбә дә Айгөлгә әнисенә елмайган төсле елмайганы юк. Салкын, ясалма елмаюы йөзенә май сөртеп ялтыраткан төсле төче булып ярылып ята. Шул чакта аның чыраен тырнап төшерәсе килә Айгөлнең. Ә күз карашы? Әнисенә җылы караш ташлый, күзләрендә серле, әлләниләр аңлатучы очкыннар уйный, әмма андый җылылыкны ул Айгөлдән кызгана. Сүзләре дә икенче төрле, эчтәлекләре дә башка. Әнисенә ярым пышылдап йомшак әйтелгән сүзләр, Айгөлгә юллангандa, салкын җилле яңгыр, борчактай рашкы кебек килеп бәреләләр. Айгөл үзенең нинди кеше икәнен бик күрсәтер иде, әмма курка. Нәрсәдер куркыта аны. Ул аңа якынаюдан курка һәм шуннан котылу өчен, Гандәлифә апасы өйрәткәнчә, усал булып кылана. Айгөл урамнан атлап барган җиреннән кинәт кирегә борылды. Нигә соң әле Гандәлифә апасы янына кермәскә? Ул һәрвакыт аннан тынычланып, күңеле хушланып чыга. Ә менә бүген, бүген генә түгел, инде күптәннән күңеле тулы борчулы уйлар йөрткәндә нигә кермәскә аңа?

Гандәлифә Айгөлне кочаклап каршы алды.

— И кызым, бер дә күренмисең. Әллә уку бик катымы? — диде, аның киемнәрен чөйгә элеп.

— Бар инде, — дип куйды Айгөл. — Мәктәпне тәмамларга җыенабыз бит.

Аңа Гандәлифә апасы күзгә күренеп картайган кебек тоелды. Элекке килгәнендә битләрендә, беләкләрендә эре көрән таплар азрак кебек, аларның төсләре дә сыеграк иде бугай.

— Әби, Таһирдан хат юкмы? — дип сорады Айгөл.

— И кызым, булса, хәбәр итмимме соң инде мин? Әле хаты килгәнгә унбиш көн дә юк түгелме соң?

— Ә мин көн саен көтәм.

Болынкырда имеш-мимешләр, гайбәт таралмасын дип, Гандәлифә адресына хат язуны Таһир уйлап тапкан иде. Конверт тышына җибәрелгән адресына «Т.Чукаевтан» дип хат яза да, аннары Айгөл тып-тын гына килеп ала.

Гандәлифә аңа тары ярмасы белән пешергән кабак бәлеше салып бирде, кайнарлап чәй ясады. Бәлеш бик тәмле иде, Айгөл аны ялт иттереп куйды.

Гандәлифә аның йөзеннән күзен алмады, ахырда үзен борчыган уен белдерде:

— Күңелең тыныч түгел бугай, кызым...

Айгөл чәен шопырып йотты да чынаягын куйды.

— Нәрсәгә икәнен үзем дә аңламыйм...

— Үги әтиең белән боткаң пешмиме?

— Барысы да миннән, Гандәлифә апа, — диде Айгөл, авыр сулап. — Мин аны күралмаска тырышам. Әгәр кулымнан килсә, җенгә, пәригә әйләндерер идем. Аны начар итеп күрсәтү өчен әллә ниләр эшлим, төртмә сүз әйтәм, мыскыллыйм, бәйләнәм.

— Нигә алай эшлисең соң?

— Синең кебек усал булырга тырышам.

— Минем кебек булу нигә кирәк сиңа? Мин бит аны үземне яклау өчен уйлап таптым.

— Мин дә үземне яклыйм.

— Ул сине кыерсытамыни?

— Мин үзем аңа таба бөгелә барам.

— Соң, бик тә әйбәт бит инде, кызым. Тормышта үги әтисен чит күреп җәфаланучылар әллә никадәр. Яшәвегез көйләнә дигән сүз.

— Бу бит ниндидер аңлашылмый торган нәрсә. Гел куркытып тора. — Айгөл, үзенең уйларын аңлатырга тиешле сүзләр эзләп, шактый уйланып торды, чәен йотып куйды, аннары дулкынланып сүзен дәвам итте: — Мин аңа һөҗүм итәм, шуның өчен үземне-үзем күрә алмыйм. Аны шайтанга әйләндерәм дип, үзем шайтанга әйләнәм. Бер караганда, мин хаклы кебек, икенче караганда, бөтенләй дә хаксыз. Мин аның үпкәләвен, каршы әйтүен, күтәрелеп бәрелүен көтәм, шуңа котыртып, үзем кабызган учакка туктаусыз утын ыргытам. Ә ул, үч иткәндәй, һаман башын түбән ия, буйсына гына бара, кызгандырырга телиме — белмим.

Гандәлифә, аның белән килешмәвен белдереп, башын чайкап куйды:

— Юк, кызым, ул сезнең икегезне дә ярата, хөрмәт итә. Шуңа күрә каршы әйтергә дә кыймый. Алай кискен бәрелмә син аңа. Үтәрсеңме мин әйткәнне?

— Белмим, — диде Айгөл, башын аска иеп.

Айгөл чыгып киткәч, Гандәлифә үзенең иргә чыккач,

аерылгач кичергән газаплы, коточкыч көннәрен хәтеренә төшереп утырды. Казанда эшләгәндә, алар янына Николай Чукаев дигән бер керәшен егете килгән иде. Ул аерып кына бер кыз белән дә йөрмәде, аерып кына берсен дә кинога да чакырмады, озатып та куймады, тулай торакның бер бүлмәсендә яшәүче дүрт кызның да якын кешесенә әверелде. Ничәдер ай үткәч, абыйсы килеп, кызларның иң элек берсенә (әлбәттә, башкалардан яшереп) энесенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган. Кызлар бер-бер артлы баш тарта торгач, чират Гандәлифәгә җитте. Коля аның өчен чит тә түгел, якын да түгел, үзләренең авылындагы күршеләренә ничек караса, шулай карый торган кеше иде. Ул да кияүгә чыгарга теләмәде, институтны бетермичә ул турыда уйлап та карамыйм, диде. Әмма Коляның җиңгәчәсе — тасма телле керәшен хатыны — Гандәлифәне тере килеш суйды: ул сандугач булып сайрады, күгәрчен булып гөрләде, аккошлар булып биеде һәм Гандәлифәне җир йөзендә Колядан да әйбәт кеше юклыгына ышандырды. Аның белмәгән һөнәре, башкармаган эше юк икән, Казанның читендә йорт бетергән, гүрнәчәдәй өйдә ялгызы яшәп ята, акчаны көрәп ала, кыюлыгы гына җитми. Аннары ул җайлап-җайлап Гандәлифәнең чибәрлек якларына, тән төзелешләренә ишарәләп алды. Бу очракны ычкындырса, яңадан ир затлары тәтемәячәген дә искәртте. Керәшен хатыны хаклы иде. Әгәр Коляга чыкса, шәһәрдә патша хатыны кебек яшәячәге, ә авылда өстеннән каткан сырма, аягыннан резина итек төшмәячәге дә Гандәлифәгә мәгълүм иде. Кызлар да Коляны мактап туймадылар, ләкин аларның икесенең егете бар, ә берсе авыру әти-әнисе янына авылга кайтырга тиеш иде. Шул рәвешле алар да Гандәлифәне кияүгә чыгарга күндерделәр. Шау-гөр килеп, керәшеннәр, Казанның Яңа бистәсен дер селкетеп, бер атна туй иттеләр. Чыннан да Коляның байлыгы хәйран калмалы иде. Утыз яше дә тулмаган килеш мунчалары-ниләре белән салган өе, мотоциклы, өй тулы җиһазы аларның тормышын берничнди кайгысыз дәвам итәргә нигез булып тора иде кебек. Әмма яши башлагач, Коляның коточкыч саран булуы, шуның өстенә һәр көн каян да булса нидер урлап кайтуы Гандәлифәне хәйран калдырды. Ул аракы эчми, тәмәке тартмый, берсе тузмый торып, икенче кием-салымны алмый, беркем белән дә аралашмый иде. Бер ай яшәр-яшәмәс, ул Гандәлифәгә, институтны ташла, ди башлады. Гандәлифә, әлбәттә, аның ул сүзләрен колагына да элмәде. Ул инде эченнән күптән, исән-имин чакта бу бәндәдән котылу турында хыяллана иде. Коля әйткән сүзендә катты, ул да укуын ташламады. Шуннан соң ире аны тотып кыйнады. Усал булып кыланырга өйрәнгән Гандәлифә берни дә эшли алмады. Ул аңа кияүгә

чыгу белән усаллануын онытты, аңа нидер булды. Хәтта кыйнагач, күршеләре, ул эшли торган заводның җитәкчеләренә барып әйт, дисәләр дә, Гандәлифә алай эшләмәде. Әйберләрен җыештырды да таныш тулай торагына юл тотты. Чукаев килмәде, аерылышыйк та димәде, шулай итеп ул гомер буе аның фамилиясендә калды. Тулай торакка кире кайткач, ул кабат усал Гандәлифә битлеген киде, аңардан курыктылар, аңа ярдәм сорап килделәр. Ул тормыштагы гаделсезлекләрне әнә шул ярдәм сорап килүчеләр аша тирәнрәк күрә, аңлый башлады.

Болынкырга эшкә кайткач, кимчелекләрне аяусыз тәнкыйтьләвен күреп, кешеләр тагын аңа тартыла башлады, ул инде теләсә дә чигенә алмады. Иң гаҗәбе шунда: курку һаман аның эчендә утыра бирде. Күрәсең, ул аның канына тумыштан салынган иде, гомер буе эчтән калтырап торды, әмма Гандәлифә «мин куркам» дип ычкындырмады, һаман үҗәтләнеп куркынычның эченәрәк керде. Ул үзе тудырган усал, бернидән дә курыкмый торган Чукаева булып калырга, шуның биеклегенә күтәрелергә тиеш иде. Һәм чыннан да курка-курка курыкмый торганга әверелде. Ул, әкияттәге камырдан әвәләп ясалган Камыр батыр кебек, үз куллары белән үзен әвәләп ясады. Ә иң әйбәте ялгызлыктан котылу булды. Югыйсә ул аңардан мәңге котыла алачак түгел иде. Качты ялгызлык. Гандәлифәгә килмәгән кеше калмады, ул барысын да якларга тырышты. Йөзенә кигән усал кеше битлеге аның үз-үзен тотышына да кырыс билгеләр салды. Әлбәттә, күңелдәге җылы хисләрне бикләсәң дә, барыбер алар чыгарга телиләр. Гандәлифә ул тойгыларын үзенең малтуарларына, кош-кортларына, чәчәкләренә бирде. Ул аларны ит, сөт, йон, йомырка өчен асрамады, алар аның күңел җылысын уртаклашучы җан ияләре, гаилә әгъзалары иде.

Бер карасаң, ул бик кызганыч кеше кебек иде. Гомер буе ялгыз яшәде, дуслары, аралашкан кешеләре дә күп булмады. Ләкин язмышта шулай язылгач, нишләмәк кирәк? Зарланмады Гандәлифә, язмыштан зарлану көчсезлек, түбәнлек дип санады. Дөньяда сиңа яшәү бирелгән икән, нинди генә шартларда да аны үзеңә бүләк ителгән бәхет дип санарга кирәк. Барысы да нинди уй белән гомер кичерүеңә бәйле. Аның ярдәмендә теләсә нинди караңгы, газаплы яшәешне дә үзгәртеп, хәтта капма-каршыга әверелдереп була. Яктыга карап эш итсәң, тормыш хәрабәләрен уй, зиһенеңнең куәсе яңадан төзи, караны — акка, газапны шатлыкка әверелдерә ала. Уең нинди — хәятың шундый. Аның белән шатлыкны — кайгыга, акны — карага, яктылыкны караңгыга да әверелдереп була. Ни аяныч, алай яшәүчеләр дә күп, бик күп! Кешенең үзен-үзе тудыруы ана карыныннан чык-

кач башлана. Тар өйдән йә булмаса шәһәр фатирыннан, шул кысаны ертып, югары хакыйкать дөньясына күтәреләсе бар. Бары шул гына чын туу була. Бусы уй ярдәмендә башкарыла, чигенүләр, икеләнүләр, каушау-куркулар аша башкарыла. Кеше тормышның тар көпшәсеннән, икенче төрле әйткәндә, язмыш мылтыгыннан илаһи галәм биеклегенә пуля булып атыла, тәтегә уй бармагы баса. Утлы коралдан ату, пуляның барып тиюе секундлар эчендә булса, кешенең атылып очуы гомер буе дәвам итә...

Гандәлифә кешене көчсездән көчле итә торган менә шул зиһен куәсе дигән коралны яулаган иде. Бары шуның ярдәмендә генә ул куркак Гандәлифәдән батыр Чукаевага әверелде һәм ул шулай булып дөньядан да китәчәк...

* * *

Айгөл кайтып кергәндә, әнисе өстәл артында елап утыра иде. Аның битләре шешенеп беткән, чәчләре, күз яшьләренә чыланып, яңакларына ябышкан.

Айгөл, йөгереп барып, әнисен кочаклап алды:

— Ни булды, әни?

Әнисе аны этеп җибәрде:

— Шатлан, теләгеңә ирештең! — диде ул үксеп һәм алдында яткан кәгазьне Айгөлгә атты.

Айгөл бер күз атуда аны укып чыкты: *«Сөембикә, Айгөл! Мин түзә алган кадәр түздем. Бүтән сезгә яшәргә комачауларга теләмим. Бәхетле булыгыз! Мин китәм. Айдар».*

— Әни, мин бит аның китүен теләмәдем!.. — диде Айгөл, өзгәләнеп.

— Теләдең, аны син мәҗбүр иттең! Син аңа көн күрсәтмәдең. Рәхмәт, кызым...

Айгөл кычкырып елап җибәрде:

— Юк, юк, юк! Мин аның китүен теләмәдем, әни! — Айгөл сәгатькә күз төшереп алды, әле соңгы автобус китәргә биш минут вакыт бар иде. — Мин аны хәзер борып алып кайтам!

Ул курткасын кулына гына эләктерде дә чыгып йөгерде. Аның йөрәге чыгардай булып типте, күкрәге уттай янды, күзеннән кайнар яшь акты. Ул Айдар абыйсының кыерсытылган, мыскылланган хәлдә вокзал ишеге төбендә боегып басып торуын күз алдына китерде. Айгөл, тынына буылып, урам буйлап чапты. Ул барып җиткәндә, автовокзал бушап калган иде. «Соңгы автобус китте инде», — диде кассир. Бу сүзләр Айгөлгә хөкем карары кебек яңгырады. Менә хәзер аның күз алдына кызганыч, рәнҗетелгән кыяфәте белән әнисе килеп басты. Ул хәлсезләнеп автовокзал ишегеннән ерак булмаган электр баганасына барып сөялде...

# Дүртенче кисәк

## 1

Миңзаһит ике сәгать буе, әле лабораториягә барып, әле өлкән шәфкать туташы янына кереп, әле соңгы уколларын алып, хәлдән тайганчы чабулап йөрде. Сәгать унберләрдә үзләре ята торган ун кешелек палатага кереп, караватына барып утырды. Бик тә ятып торасы килде, әмма курыкты. Ятуы була, күз алдында әллә нинди хәшәрәтләр хәрәкәткә килә. Бүген ул бигрәк тә курыкты. Кычкырып җибәрермен дә тагын чыгармаслар, озаклап ятарга туры килер дип коты очты. Рашат бер генә мәртәбә дә больницага килмәде, Миңзаһит аны күрергә дә теләмәде. Аның өчен ул, гомумән, кеше булудан туктаган иде.

Арыганлык җиңде, Миңзаһит акрын гына мендәренә таянды һәм шундук күз алдына әллә нинди ямьсез, йөрәгеңне ярырлык кеше башы пәйда булды. Аның бөтен җирен миң баскан, пеләш башында кечкенә кеше башлары миң кебек тырпаешып торалар. Ияге түп-түгәрәк, шулай ук кеше башы төсле ялтырап тора. Менә баш түбә чәркәсе ягына сузылырга тотынды, сузылган саен нечкәрде, нечкәрә-нечкәрә ике колагы кара-каршы кушылды да шул турыдан кызыл күз килеп чыкты. Ул зураеп бүрек кадәр булды. Аның уртасында авыз барлыкка килде, авыз киереп ачылган, тамак төбе туры тишек, шул тишектән артта үсеп утырган агачлар күренеп тора, авыз тулы сары черек тешләр, алар арасында үлеккә охшаган куе нәрсә сузылган; менә баш әйләнергә тотына, аның белән бергә Миңзаһит үзе дә әйләнә, башларның саны ишәя, ниндидер балалар пәйда була, аннан соң сакаллы картлар күренә, бөтенесе, ишелеп, әллә нинди ярсыз-нисез су өстендә ага башлыйлар, ул су ага да ага, үзе яшькелт, үзе кызгылт, үзе сары, үзе көмештәй ялтырап китә... Миңзаһит саташканын аңлый, бу галлюцинациядән котылырга тели, тешләрен кысып, кулын кулга ышкый, үзен ияртеп барган ташкыннан ахырда сикереп төшеп кала. Күз алдында больницаның ак түшәме пәйда була. Ул тирән итеп сулыш алып торып утырды. Башы җиңелчә генә әйләнә һәм маңгай турыннан сызлый иде. Биредә ятканда аның инде күрмәгән әйберсе калмады. Ул хәтта үзенең балачагын да, үлгәнен дә, кабердә ятканын да, оҗмах-тәмугларны кичкәнен дә күрде. Әгәр бу дөньяда аңа ни дә булса күрсәтсәләр, ул һич тә гаҗәпләнмәс иде. Шул коточкыч саташулар аның чәчләрен ап-ак итте, ул калтыравыкка әйләнде, ашаган вакытта авызыннан әйбере коелды. Гомер буе бритва белән кырынган Миңзаһит

Хәяттан электр кырынгычы китертте. Аның белән янәшә физика фәннәре докторы ята иде. Миңзаһит аңа үзенең саташуларын сөйләде. Галим бөтенесенә квалификация ясады: сезнең галлюцинацияләрегезнең төп характеры зурдан кечкенәгә, кечкенәдән зурга әверелү, бар якка да сузылу һәм өзелү, бер ноктадан әллә ничә төрле әйбер барлыкка килү һәм шуларның кушылып тагын бербөтен әйбергә әверелүе, астан да, өстән дә, уңга-сулга да ташкын рәвешендә агу, бөтерелү һәм шуларның бөтенесе нindидер шакшы, лайлалы әйберләр белән буталу, дип, схеманы сызды ул. Боларны Миңзаһитның организмда бара торган процессларның чагылышы дип аңлатты. Димәк, ул процесслар һич тә яхшыга илтә торган рәвештә бармыйлар. Аннары тагын, аның аңлатуынча, безнең организмдагы бу процесслар иҗтимагый тормыштагы таркалуның, черүнең, анда барлыкка килгән яман шешләрнең чагылышы булып тора. Профессорны тыңлыйтыңлый, Миңзаһитта кайчакларда фикер галлюцинациясе башланды. Анысы инде бөтенләй акылдан язуга тиң. Шушы саташулар ташкыны әллә кайларда ыргытып йөрткәндә, бервакыт ул ап-ачык итеп үзенең әбисен күрде. Әбисе зәңгәр һавада утырып тора, ап-ак яулык бәйләгән, ап-ак күлмәк кигән, яулык астыннан көмеш чәчләре күренә. Миңзаһит аңа кычкыра, зинһар, коткар, ди, бу ташкыннан тартып ал, әбием, ди. Әбисе дәшми, кулындагы көрән төстәге акча янчыгын ачып, акчаларын саный-саный да карап тора. Миңзаһит аңа бик озак ялынды, әмма әбисе әллә күрмәде, әллә күреп ярдәм итмәде...

Өлкән шәфкать туташы кереп, аңа башының томографиядә яздырган кәгазьләрен, берничә рецепт бирде.

— Инде сезгә китәргә мөмкин, — диде.

Миңзаһитның күптән борчыган бер олы уе бар иде. Ул әллә ничә мәртәбә профессорның кабинет ишегенә барып килде, әмма анда, гадәттәгечә, кулына кәгазьләр, рентген рәсемнәре тоткан авырулар чират торалар, баш тыгарга җай юк иде. Көндезге ашка чакырган вакытта гына профессор янына керә алды ул.

— Тыңлыйм сезне, — диде врач.

Миңзаһит, бүлмәдә беркем югын белсә дә, як-ягына каранды, калтыранган куллары белән туктаусыз җиңнәрен тарткалады, аякларын урыныннан күчереп-күчереп куйды.

— Мин инде сезгә үземнең кем аркасында мондый хәлгә төшкәнемне сөйләгән идем, — диде ул, карлыккан хәлсез тавыш белән. — Инде мин яңадан больницага эләгә алмам... туп-туры зиратка гына алып китәчәкләр.

Ул шунда туктап калды, сүзен дәвам итәргә хәле җитмәде.

— Рецептларыгыз язылган, тыныч кына яшәгез, дәваланыгыз. — Врач шулай диде дә урыныннан торды.

— Сез минем ник кергәнемне белмәдегез, — диде Миңзаһит, кабаланып. — Әгәр минем теләгемне үтәсәгез, үлгәнче сезгә рәхмәт укыр идем.

— Нинди теләк?

— Бирегез берәр көчлерәк йоклата торган дару. — Миңзаһит, куркудан калтыраучы башын тыярга тырышып, куллары белән тотты, үзенең куркынган карашы врачта иде. — Сез бит минем хәлемне аңлыйсыз. Зинһар, кызганыгыз...

Врачның йөзе бозылды:

— Сез, Арсланов агай, бик җебегән кеше булып чыктыгыз. Ир кешегә хас нәрсә түгел бу. Кешеләр яшәү өчен көрәшәләр, ә сез...

— Мин бит... мин дә... — дип мыгырданды Миңзаһит.

— Хәзер үк чыгып китегез!

Ул, аякларын лыштыр-лыштыр сөйрәп, коридорга чыкты, ачынып үзләренең палатасына керде һәм урынына утырды. Нияте барып чыкмады, димәк, бүтән әмәлен табарга кирәк иде.

Травмотология институтының баскычыннан төшкәч, Миңзаһит үзе яткан бинага озаклап карап торды, аның ишек янына беркетелгән алтактасын кат-кат укыды, аннары җәяүләп трамвай тукталышына юл тотты.

Аның бәхетенә, Рашат өйдә юк иде. Ул кайтып ишектән керү белән, Хәят, нишләп хәбәр итмәдең, тагын егылып улбу булса, син бит ярты гына кеше, дип тиргәде дә тиргәде. Өйгә кайткач, җаны тынычлап киттеме, ул атна буе йокылыуяулы халәт кичерде. Саташулары бөтенләй бетте диярлек. Әллә инде ми күзәнәкләре ял итәргә теләделәр, әз генә утырып торса, йөреп алса, барды да ятты, хырылдап йокыга да китте. Уянып өлгермәде, исерек кеше кебек тагын ауды. Шулай итеп атнага якын вакыт узды. Ә теге уй аңа һаман да тынгылык бирмәде. Бер-ике мәртәбә Хәят белән кибеткә дә чыгып керделәр. Әмма бу бәхетле көннәргә Рашатның кайтуы чик куйды. Аның элеккедән дә хәтәррәк исереп тузынулары, икесенә дә бәйләнүләре, акча сораулары башланды. Миңзаһитның йокысы качты, галлюцинацияләр тагын да куркынычрак рәвештә бөтен барлыгын агуладылар. Ял көнне, түземе бетеп, ул базарга чыгып китте. Акчасы кесәсендә, букчасы кулында, нияте башында иде. Ул, анда-монда сугылмыйча, базарның үлән сатыла торган почмагына китте. Электән үк сөйләшеп йөргән таныш карты белән күреште. Көн салкынча иде, карт күгәреп-туңып беткән, туктаусыз тә-

мәке пыскыта һәм бер урында таптанып тора. Алдына төрле үлән тамырлары, үсемлек орлыклары тартма-тартма итеп таратып куелган.

— Миңа йоклата торган үлән табып бир әле, — диде ул аңа, пышылдап кына.

— Әнә бит, ал, — диде карт. — Сукыр кычыткан, бөтнек, валериан тамыры — беткәнмени шунда.

— Юк, миңа көчлерәге кирәк. — Ул картның колагына үрелеп пышылдады: — Мәңгегә йоклата торганын табып бир...

Карт тирән итеп суырган тәмәке төтенен эченә йотты да, чыгармыйча, тын алудан туктап, Миңзаһитка төбәлде, шаяртып кына әйтмиме дип сынап караВы иде ул аның. Миңзаһит кесәсеннән бөкләнгән мең сумлыкны чыгарып күрсәтте. Картның күзләре майланып китте, борыныннан төтене дә чыкты, әллә ничә мәртәбә төкреген йотып куйды.

— Бар, — диде ул, шыпырт кына. — Иртәгә кагыл.

Миңзаһит кайтырга кузгалды, ул үзенең дәртләнеп атлавына хәйран калды. Ул бу җир йөзендә башкарачак соңгы эшенә әзерләнә. Ул инде гомеренең күп калмаганлыгын аңлый, салкын кабернең хәтта исен дә тоя кебек. Бөтенесе гади, ачык һәм рәхимсез. Кире борылу юк, ишекләр бикләнгән, бер генә нәрсәне дә үзгәртеп булмый.

Балаларын җитәкләгән бәхетле парларга карый-карый, ул менә шушы кара уен күтәреп атлады. Шугалакта чана шуучы балалар янына басып карап торды, тәгәрәп аунаганда аларның киемнәренә ябышкан карларын кагып төшерде. Ул үзеннән җирәнергә тиеш иде, ләкин шаккатып күңеленең тынычлыгына, битарафлыгына хәйран калды. Аның инде хәзер хәтта Рашатка да нәфрәте, ачуы беткән иде кебек. Бары тик теге уй гына яши, ул гына тизрәк тормышка ашыруны таләп итә...

## 2

Иреккә мамонтның бәрмә теше очыннан чатный башлаган кебек тоелды. Ул, кулына лупа алып, урындыкка басты да сөякне җентекләп карарга керешә. Шулчак ишек ачылды һәм Әхнәф килеп керде.

— Син музейга кергән һәр кешене дә шушылай каршылыйсыңмыни? — диде Әхнәф, йөзенә ясалма елмаю чыгарып.

Ирек аңа таба борылып та карамады, мамонт тешен тикшерә бирде.

— Ни бар? — диде ул, тамак төбе тавышы белән.

— Төш инде, болай сөйләшеп буламыни?

— Ни бар, дим?

Әхнәф аңа таба атлый башлады:

— Әллә авырыйсың инде...

— Якын килмә! Ни бар?

— Ай-яй-яй! Өскә сикерергә җыенган җанвар кебек син.

Ирек кинәт йөзен аңа таба борды, ачулы күзләрен елтыратып:

— Оясын актарсаң, агусыз елан да тешли, — диде. — Ник килдең?

— Сүз бар иде.

— Безнең сүз бетте. Бүлмәңнән ничек озатканыңны хәтерләмисеңмени?

— Ярый, сөйләшергә теләмәсәң. — Әхнәф тирә-ягына карап уйланып торды. — Экспонатлар карарга мөмкиндер бит?

Ирек «ә» дә, «җә» дә димәде. Әхнәф, акрын гына экспонатларга күз салгалап, иң түргә барып җитте. Почмактагы ап-ак сакаллы карт төшерелгән фотоны кулына алды.

— Кудряшов Алексей Григорьевич, — дип кычкырып укыды ул. — Хвощинский исемле бояр шушы крестьянны Себердән бер көчеккә алмаштырып алып кайткан. Фаҗига инде бу. Шулай да дуслыкны дошманлыкка алыштыру кебек үк түгел. Әле андый кешеләр дә бар бит арада...

Ирек, кысылган тешләре арасыннан сыгып:

— Йә, йә, әйтеп бетер, — диде.

— Бетерәм: сине күпмегә сатып алдылар?

Ирек болай да гәүдәсеннән үтәли яшен уты уздыргандай киеренкелектә тора иде. Әхнәфнең бу сүзләре аны тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Нәр-сә-ә?! — диде ул, үз тавышына үзе буылып.

— Дуслыкны Саттаровлардан нәрсәгә алмаштырдың? Акчага сатылдыңмы, бүтән әйбергәме?

Ирек үзенең урындыктан ничек сикереп төшкәнен, ничек аның каршына атылып барып җиткәнен сизми дә калды.

— Мин сатылдыммы?!

— Сатылмасаң, Саттаров исеменнән мәкалә язмас идең. Ичмасам, үз фамилияңне куйсаң, ирләрчә булган булыр иде.

Әхнәфне бирегә күпме вакытлар тынгылык бирмәгән шиге алып килде. Теге мәкаләне шушылай үтергеч ирония салып Ирек кенә яза ала, димәк, ул гына язган дип уйласа да, Фәһимә һәр көн «бары шуның гына кулы» дип тукып торса да, күңел түрендә «бәлкем, ул түгелдер» дигән шиге бар иде. Берәр Казан журналисты язган булса? Моны ачыклау аның өчен тәкъдирен билгеләр дәрәҗәдә мөһим иде. Әгәр Ирек шушы эшне эшләгән булса, аларны үзара тоташтыручы соң-

гы җеп тә өзелде дигән сүз. Әхнәф исә моны һич тә теләми, чөнки ул япа-ялгыз иде. Юк, юк, ул Иректән бернинди дә ярдәм өмет итми. Аның янәшәдә икәнлеген генә булса да тоярга кирәк хәзер. Еракта гы ата-ананың исәнлеген белеп тору җанына тынычлык биргән кебек, үзенә начар итеп карамаучы Ирекнең барлыгын булса да сизеп торасы килә иде аның.

— Кем әйтте?! — диде Ирек, аның җиңеннән эләктереп.

Әхнәф чигенеп куйды: Ирек менә-менә аңа ташланыр төсле иде. Ул, җиңен ычкындырмакчы булып, кисәк кенә читкә тартылды, әмма Ирекнең кулы аны чытырдатып кыскан, бармак буыннары агарып тора, кул сыртындагы тамырлары зәңгәрләнеп бүртеп чыккан иде.

— Кем әйтте?!

Әхнәф тегенди-мондый сылтау белән котыла алмаячагын аңлады.

— Беркем дә әйтмәде, — диде ул. — Саттаров аны мәңге яза алмый. Синнән башка беркемнең дә кулыннан килмәгәнлеге билгеле бит.

Ирекнең бармаклары үзеннән-үзе йомшардылар, ул, авыр итеп көрсенеп, маңгаендагы тирен сөрткәннән соң:

— Их Әхнәф! — дип куйды да хәлсезләнеп шундагы урындыкка утырды, башын түбән иде.

Бу сүзләр аның күкрәгеннән әрнү һәм рәнҗеш ялкыныдай бөркелеп чыктылар да Әхнәфне башыннан аягына кадәр көйдереп алдылар. Ирекнең ике чигәсе сулык-сулык чәнчешергә тотынды. Ул, көч-хәл белән өстәл янына барып, графиннан стаканга су агызды, шуның белән даруын эчеп куйды.

Бераз хәл кергәч, сагышлы тавыш белән:

— Син миннән ерагайганнан-ерагая барасың, — диде. — Шулкадәр тырышасың...

Әхнәф аның сүзләрендәге аяусыз хаклыкны эченнән коты очып икърар итәргә мәҗбүр булды. Аның өчен инде хәзер Ирекнең Саттаров мәкаләсенә кул тыкмаганлыгы да бәхәссез иде. Әхнәф акрын гына аның янына килде.

— Кичер мине, — диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән. — Син дип уйлаган идем... Булдыра алсаң, зинһар, кичер...

Ирек дәшмәде, Әхнәф кадаклагандай шул урынында басып тора бирде. Әхнәфкә үз гомерендә беркайчан да бу дәрәҗәдә таяныч кирәк булганы юк иде әле. Аның йөзенә ялвару билгеләре җәелде, иреннәренең дерелдәвен сиздермәс өчен, ул аскы иренен шактый вакыт тешләп торды.

Аннары:

— Ирек, әйдә, бер ачыктан-ачык сөйләшик әле, — диде. — Йөрәкләрне учка салып...

Ирек урыныннан кузгалмады, башын күтәреп, аны тыңларга җыенганын белдерде:

— Әйдә соң...

— Бар иде бит яшь чаклар! Гел искә алам, сагынам!.. Син дә сагынасыңмы?

— Сагынам, билгеле, — дип куйды Ирек, уйчан кыяфәт белән.

— Кояшлы чаклар булган икән! — дип дәвам итте Әхнәф. — Авырлык чыккан саен, бер-береңә йөгереп барасың, эч сереңне бушатасың, күңелләр яктырып китә! Шулчаклар искә төшкән саен, күңел сыкрый... — Әхнәф Ирек берәр нәрсә әйтмәсме дип көтеп торды, әмма ул иренен дә кыймылдатмады. Әхнәф уйларына баткан хәлдә мамонт тешләре янына китте, хәтсез генә аларга карап торды. — Менә бу тешләр күпме җан ияләрен кыймагандыр, он-талканга әйләндереп ашамагандыр... — Ул кире борылып килде, як-ягына күз йөгертеп сүзен дәвам итте: — Бүгенге тормыш тегермәне дә рәхимсез, үзенең ташлары арасында адәм баласын туйганчы әвәли, хәтта бүтән затка әверелдерә. — Ул шунда, башын капыл гына Ирекка борып, аның күзләренә туп-туры төбәлде. — Әмма ул сине миңа каршы кеше итәргә тиеш түгел иде!

Ирек баш чайкап куйды:

— Әгәр киресенчә булса? Сине миңа каршы кеше ясады бугай ул...

Әхнәфнең йөзе бурлаттай кызарып чыкты, күз алмалары сикерешергә тотынды.

— Ярар, теләсә ни әйт! — Ул кулларын селтәп куйды. — Яши алмыйм мин болай! Кулым эшкә бармый, дөньяның яме, яшәүнең тәме калмады.

— Кем гаепле соң? — диде Ирек.

— Менә, менә, син гадәттәгечә гаепли дә башладың! Тормыш дистиллированный су түгел, ул хәтта фильтрланмаган да, болганчык булып, бөтен ләме, чүп-чары белән ага. — Әхнәф, ярсуын баса алмыйча, музейның икенче башыннан әйләнеп килде.

— Тормышны гаепләү ансат. Син аның һич югы берәр шөребен булса да үзгәртергә, яңадан ясарга тырышып карадыңмы соң?

— Минем гомер буе шуннан башка шөгылем булмады!

— Юк, Әхнәф, — диде Ирек, кашларын җыерып. Күңелеңә авыр алсаң алырсың, тымызык күлдә кармак салучы кеше җилдән курыккан шикелле яшисең син.

— Бөтенегез миңа каршы! Тирә-юнем тулы кеше мыжгып тора, җаныңны ачып салырлык беркем юк. Берүзем, япа-ялгыз!

— Ә син аласың килсә, үзең дә бир.

— Мин бирмиммени?! Җилкәмдә күтәрә алмаслык йөк. Дөнья күренми, менә хәзер гөрселдәп авам дигән көннәрем күп!..

— Кол шулай булырга тиеш инде ул.

— Кол?!

— Әйе. Сары май эчендәге балавыз кебек син. Үзең кол.

— Менә сөйләшкән саен синең уйларыңның миңа каршы икәне ачыла бара. Революция кирәк сезгә...

— Ә кемнәр соң сине заманында депутат итеп сайлату, райком секретаре итү өчен тырышты? — диде Ирек, аның сүзен бүлеп. — Мин түгелме? ТИҮ егетләре түгелме? Син менә бер соравыма җавап бир әле: без элек күмәк тормыш, уртакны тигезләп бүлү кебек изге нәрсәләр белән яшәдек. Чынлап та инанган идеңме син шушыларга?

— Ирек, син вакытны туктатырга азапланасың! — диде Әхнәф, ачынып. — Тигезләп булмаганын күрдек бит инде. Тәрәзәдән үрелеп кара: тышта бөтенләй икенче климат! Әллә бу мамонт сөякләрең борынгы дәверләргә сөйриме сине? — Ул сәер генә җилпенеп алды. — Вакыт поезды алга чаба, кешелек икенче төрле дәвергә күчте, бүтән заман килде. Әгәр аны кабул итмәсәк, вакыт җиле безне кибәк урынына очырачак. Элекке төшенчәләрнең күбесе мәгънәсен үзгәртте. Ә син виртуаль дөньяда яшисең.

— Нык шомаргансың син, хәтта куркыныч! — диде Ирек, гаҗәпләнеп. — Инанган булсаң, үзең әйткән теге поездга ансат кына сикереп утырмас идең. Шамбы балыгы кебек шомаргансың. Минем соравыма җавап бирәсе урында әллә кайларга алып кереп батырдың. Әле үткәннәргә, әле киләчәккә, әле фәлсәфә чытырманлыкларына... Болай булгач, барып чыкмый безнең йөрәкне учка куеп сөйләшү.

Ирек урыныннан сикереп торды. Аларның карашлары очрашты.

— Ирек, үтенеп сорыйм... — Әхнәф җайлырак сүзләр эзләде. — Һич югы син миңа каршы чыкма... Башка берни дә сорамыйм. Сүз бирәсеңме?

— Бик җиңел хәл итәсең син, Әхнәф. Утын ярган кебек кенә. Шарт-шорт — шуның белән вәссәлам!

Әхнәфнең йөзе кара янып чыкты. Ул Иректән уңай җавап ала алмаячагын аңлаган иде инде.

— Синдә үткәннәрдән берни дә калмаган икән! — диде ул, ачу белән.

— Чишмәгә нәҗес әйберләр салсаң, аның суы агулана. Өстенә чүп-чар аударсаң, бөтенләй коруы да бар.

— Димәк, син Саттаровлар белән һаман миңа каршы казыначаксың?

— Аллам сакласын андый түбәнлектән! — Ирек үзалдына сәер генә көлеп куйгандай итте. — Минем нидер эшләвемнең әһәмияте юклыгын син берничек тә аңлый алмыйсың.

Әхнәф, кабаланып, калтыранган бармаклары белән галстугын бушайтып куйды — аңа һава җитми иде.

— Хәйләләмә, мин ахмак түгел! — дип кычкырды ул, инде ачуын яшерә алмыйча.

— Юк, юк, ахмак түгел! — диде Ирек, аның сүзен җөпләгәндәй. — Син акыллы да, хәйләкәр дә. Тик син бер нәрсәдә ялгышасың: тормыш аргамагына атландым да, гел шушылай чабып барырмын, дип уйлыйсың. Ә аргамагың гел упкын читенә каера...

— Ни әйтмәкче буласың син? — диде Әхнәф, шомланып.

— Берүзем дип зарландың. Тимер койма белән сине беркем дә мәҗбүри аермады. Шуны алып атмасаң, олы бәла киләчәк сиңа!..

Әхнәф, әйтер сүз таба алмыйча, кара янып, аңа шактый вакыт туп-туры карап торды. Әмма Ирекнең керфекләре дә селкенмәде.

— Синдә миңа карата бернинди игелек тә юк икәненә мин тәмам ышандым! — диде ул һәм, кискен борылып, музейдан чыгып китте.

Йөрәкләрне уч төбенә куеп сөйләшү барып чыкмады...

## 3

Бу ял көнен Таһир беркая да чыкмыйча семинарга әзерләнеп үткәрергә уйлаган иде. Иртүк торып, өч сәгать буе укыды, язды. Ләкин ручкасының карасы бетеп, ерак булмаган киоскка китте. Ручкасына паста алып кайтып килүенә, ишеккә язу кисәге кыстырып киткәннәр. Ул аны кабаланып укып чыкты: *«Таһир, кайда йөрисең? Урнашып беткәч, мин кабат кагылырмын әле. А.»* Аның йөрәге туктап калгандай булды, аннары шатлыктан ашкынып тибәргә кереште. «Ул килгән! Ул килгән!» — дип кабатлады ул эченнән. Күңеле юкка алгысымаган, сизенгән бит ул Айгөлнең киләсен. Таһир, әйберләрен өстәлгә куеп, кабат имтиханга әзерләнергә утырды. Бер минут укыды, ике минут, ун минут укыды, тик башына берни дә кермәде. Ул конспектларын, китапларын

ябып куйды. Ә бәлкем, ул ярты сәгатьтән әйләнеп килер дип уйлады Таһир. Димәк, аш салырга, өстәл әзерләргә кирәк. Ит юып аш салды, суыткычта булган азык-төлеген алып, өстәлгә таратты. Үзе пычагы белән әйбер турады, үзе әледән-әле, зал ягына чыгып, Айгөлнең язуын күзеннән үткәрде, үзе туктаусыз елмайды, тамак төбе белән генә күңелле көйләр көйләде.

Аш та еште, өстәл дә әзерләнде, Айгөлне көтә торгач, өйлә туры да узып китте. Вакыт үткән саен, Таһир ныграк бәргәләнә барды, баштарак китапларына, конспектларына күз төшереп маташса да, соңга таба миен туктаусыз бер уй борауылады: «Нишләп һаман килми, кайда йөри?!» Ул, әле бер, әле икенче тәрәзәгә барып, урамны, подъезд алдын күзәтте. Сәгать икенчеләр киткәч, ишек кыңгыравы шылтырады. Таһир, атылып-бәрелеп, кем икәнен дә карамыйча, ишекне ачып җибәрде — каршысында елмаеп Айгөл басып тора иде. Ул аны кочаклап күтәреп алды һәм шул хәлендә зал уртасына алып кереп берничә мәртәбә әйләндерде дә киемнәре белән диванга салды. Аларның иреннәре иренгә тоташты. Айгөлдән кар исе, кояш исе килә, салкын битләре Таһирның яңагын рәхәт итеп иркәли иде. Ниһаять, алар телгә килделәр.

— Миңа тунымны, итекләремне салырга мөмкинме?

— Юк, — диде Таһир, елмаеп. — Мин сине шушы көе күтәреп кенә йөрим.

— Тун белән мин пешәрмен ич.

— Пешсәң, ашармын.

Алар шулай сөйләнә-сөйләнә шифоньер янына килделәр, Таһир Айгөлнең өс киемнәрен элеп куйды.

Аннары, күзләренә туп-туры карап:

— Йә, исәнме, — диде дә ике бите очыннан үбеп алды.

— Исән булмасам, җирдә басып торыр идеммени?

— Ничек килеп чыгасы иттең?

— Олимпиадага алып килделәр. Химия буенча.

Таһир, борынын җыерып, мыскыллагандай көлеп куйды.

— Ничек яратып була шул химияне?

— Химиядән башка ничек яшәп була, диген син.

— Мин аны күралмыйм.

— Син бит юрист, ә мин булачак врач.

— Син, Айгөл, шуны әйт: химияне яратмаган егет белән химияне яратучы кызның бергә кушылуыннан нинди химик реакция туа?

— Шартлау, — диде Айгөл, көлеп.

— Син озакка килдеңме соң?

Айгөлнең күзләрендә шаян очкыннар кабынды.

— Килеп кергәнемә яңа, инде син кайчан китүем турында белешмәкче буласың. Теләсәң, хәзер үк чыгып китәм.

— Нәкъ шуны телим, — диде Таһир.

— Киттем алайса, — диде Айгөл, ишеккә таба атлап.

— Туныңны алып биримме, үзең киенәсеңме?

— Рәхмәт, үзем генә киенәм.

Айгөл шифоньердан алып бүреген киде, тунына үрелде.

Шулчак Таһир аны арттан килеп кочаклап алды һәм колагына пышылдады:

— Ә мин сине гомумән җибәрмим.

— Әгәр мин, китәргә уйламыйм да, дисәм?

— Синең ни әйтүең минем өчен мөһим түгел.

Өстәл янына утыргач, Айгөл Таһир әзерләгән ризыкларны мактап туймады. Бергәләп савыт-сабаны җыештырганнан соң, урамнан урап кермәкче булдылар. Айгөл залга чыгып китте, Таһир үзенең бүлмәсеннән күлмәген алып чыкты, залга күз ташлап, Айгөлнең нишләгәнен күзәтә-күзәтә, аны акрын гына киде. Шулчак аңа нидер булды. Айгөл алтын нурлар белән өретелгән түр тәрәзә каршында яны белән басып тора иде. Бер кулы белән тәрәзә төбенә таянган, фоторәсемгә төшәргә әзерләнгәндәй, башын бераз гына югары күтәргән, өстендәге ап-ак свитеры тал песие төсле папайланып тора. Ул аны, үзем бәйләдем, дигән иде. Гәүдәсе җыйнак, кечкенә, биле нечкә, кара итәк матур булып тезләренә җитәр-җитмәс тартылып тора. Башы да зур түгел, чәче өскә үк кабартып куелган. Әйтерсең лә ул менә хәзер кинәт кенә күтәрелеп очып китәргә әзерләнә. Ияге, бөтен йөз чалымнары шуңа ишарәли кебек. Кояш нурлары Айгөлне үтәли күрсәтәләр төсле. Таһир өчен ул бу җир кешесе түгел, алтын нурлар эчендә балкучы серле зат булып тоелды. Шушы мизгелдә гаять зур, куанычлы нәрсәне тагын бер мәртәбә аңлады: ул Айгөлдән башка яши алмаячак! Бу — мәхәббәтме, түгелме, анысын Таһир анык кына әйтә алмый. Тик Айгөл инде күптән аның янәшәсендә, аның җанында, ул аны әле куанычлы утка сала, әле шатлык канатларында югары күтәрә, аны янәшәсендә тойганда, Таһир барлык мәсьәләләрне дә җиңел хәл итә, аның шәүләсе югалса, күз алдын авыр болытлар каплый, сагыш-сагыну уты эчтән яндыра башлый…

Таһир, акрын гына атлап килеп, бармак очлары белән Айгөлнең иңбашы турындагы свитер йонына сак кына кагылды. Ул аңа ялт итеп карады. Шул ук мизгелдә Таһир аның яңакларының, муенының кызарып чыгуын күрде, ул аңардан бәрелгән кайнарлыкны да тойды кебек. Айгөлнең киерелеп ачылган күзләрендә гаҗәпләнү катыш сорау билгесе чагылды.

— Свитер бәйлим, дип язган идең, — диде ул, пышылдап кына. — Шушымыни?

— Әйе.

— Бу бит свитер түгел.

— Тунмыни? — Айгөлнең иреннәренә сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәү җәелде, күзләренә шаянлык билгеләре чыкты.

— Бу бит... язгы тал песие. — Таһир бармак очлары белән кагылыр-кагылмас кына свитерның тырпаеп торган йоннарыннан үтте. — Бу свитер түгелдер, синең секундлардан торган гомереңнең бер кисәгедер. Әнә бит ул нинди тере, синдәй матур, йомшак.

Айгөл аңа нидер әйтергә теләп иреннәрен ачты, әмма Таһир ул иреннәрне үз иреннәре белән каплады...

Алар чыгып киттеләр, Казан урамнарын күпме ураганнардыр, әмма эчләренә салкын төшкәч кенә кабат әйләнеп кайттылар. Чишенгәч, икесе дә ут яндырмыйча гына залга үттеләр һәм тәрәзә каршына килеп бастылар. Казан аларның күз алдында мең төрле утлары белән җем-җем итеп җәйрәп ята иде.

— Синең тәрәзәңә бөтен Казан сыйган, Таһир.

— Әллә безнең күзләргә микән?

— Минә хәзер миңа Казан олы бер чәчәк бәйләме булып күренә. Ничек матур булып җемелди ул.

— Мин аны сиңа бүләк итәм. Ал үзеңә.

— Куркам. Бу кадәр зур чәчәк бәйләмен мин ялгызым гына саклый алмам.

— Үзем булышырмын.

— Юк инде, Таһир, имтиханнарымны әйбәт кенә тапшырсам, көзгә мин үзем шушы чәчәк бәйләменең эчендәге студент булып йөриячәкмен. Тик нишләптер икеләнәм.

— Шулай булачак, Айгөл, икеләнмә.

Аларның тагын иреннәре иренгә ялганды...

Сәгать төнге унынчы яртыда Айгөл китәргә җыена башлады.

— Бу вакыттамы?! — диде Таһир, аның каршына төшеп. — Мин сине беркая да җибәрмим!

— Ай-яй, ансат уйлыйсың син! — Айгөлнең йөзе җитдиләнде, күзләре түгәрәкләнде. — Азагын исәплисеңме соң?

— Синең биредә калуың ул бит әле... — Шулай диде дә Таһир туктап калды.

— Әйтеп бетер.

— Аңладың ич инде... Без барыбер бергә булачакбыз.

— Шулай булгач, көтик без ул бәхетле көнебезне.

Айгөлнең карашы шундый җитди иде, Таһирга аны озатып куюдан башка чара калмады.

# 4

Рашат әледән-әле спидометрга күз төшерә. Күсәк — асшофер: йөз егермедән киметми. Арттагы утыргычта сакалмыеклары эченә баткан Фишке йоклап бара. Болынкырга якынлашкан саен, Рашатның йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып типте. Юл буендагы яшь каеннарның яфрак исе борынына керде. Ул туктаусыз тәмәке тартты, еш-еш сулады, хыялы белән әллә нинди уйларга бирелде. Хәзер инде кичке караңгы төште. Әгәр мөмкин булса, ул Болынкырга, машинага сирена куйдырып, бөтен халыкны тораташ катарлык итеп, үкереп килеп керер иде. Биредә аның бер генә якын кешесе дә юк. Әгәр шундый мөмкинлек булса, бөтен халыкны үзәк урамга алып чыгып тезәр иде, җәзалар иде, Спартак восстаниесен бастыргандай, дар агачлары утыртып, берәмберәм асып чыгар иде. Кызык өчен үзе белән Арслановны да алып килер иде. Иң соңыннан дар агачына аны әләр һәм бу гадел булыр иде. Егет чактан ук әтисен күралмады Рашат. Аның, үзеннән түбән булып та, шундый югары урында эшләп йөрүе, кешеләр белән командалык итүе котырып ачуын чыгарды. Үзеннән өстен булырга теләгән теләсә кем аның өчен дошман иде. Ә Арсланов Рашатны кол итәргә теләде. Бала чакта кыйнавы да, аның үтенечләрен кире кагулары да, мыскыллаулары да күп булды. Егет булып үсеп җиткәч, Рашат баш бирмәде, аңа теш күрсәтте, йодрыгын төйнәде. Болынкыр аңа Арслановның туйганчы ләззәт алган, хатын-кызлар белән типтергән, аракы эчкән урыны буларак ачуын китерде. Менә хәзер бу егетләргә кушып, бер башына үзе барып, Болынкырга өч урыннан ут төртер иде. Тик моны эшләп булмый. Ул бүген бердәнбер бурыч белән килә, аны тиз генә үтәргә дә Казанга борылырга кирәк. Төн коточкыч караңгы иде, машина фаралары аз гына урынны яктыртып бара, бер генә йолдыз әсәре дә күренми. Төннең шулай булуы аларга бик тә кулай. Болынкырның җем-җем килгән утлары аның ажгырган күңелен бераз баскан кебек булдылар, ул хәтереннән бала чактагы, егет чактагы ниндидер күңелле хатирәләрне барларга теләде, әмма берсе дә күз алдына килмәде, әйтерсең лә алар бөтенләй булмаганнар яисә каядыр качышып беткәннәр иде.

— Сулга борыл да беренче тыкрыктан уңга кер, — дип боерды Рашат.

Тыкрыкка борылгач, ул машинаны туктатты, фараларын сүндерделәр.

Үрелеп Фишкенең күкрәгенә төртеп алды:

— Барысын да сөйләшкәнчә эшлибез: башта мин керәм, сез икегез ике якта торасыз. Минем боерыктан башка берни

дә эшләмәскә. Ул хәзер өйдә үзе генә булырга тиеш. Фараны яндырмыйча гына, акрын гына кузгал, кайда туктарга икәнен мин әйтермен.

Кызыл «Жигули», тыкрыктан акрын гына үрмәләп барып, Ирекләрнең өе турына җитте.

— Менә шушы йорт, — диде Рашат. — Машинаны читкә куябыз. Әйдә турыга.

Рашат өйрәтүе буенча, чирәм өстеннән барып, машинаны шактый ерактагы бакча артында үскән карт тал төбенә куйдылар, аннары өчәүләп тавыш-тынсыз гына Ирекләрнең өенә киттеләр. Өйнең тәрәзәләрендә балкып ут яна, капка ачык иде. Ишегалдына кергәч, бераз тыңланып тордылар. Рашат болдырга күтәрелде дә ишекне тартып карады — ул бикле иде; капшанып табып, ишек кыңгыравының төймәсенә басты. Шундук ут янды һәм Ирекнең «Кем бар?» дигән тавышы ишетелде.

— Мин әле бу, — диде Рашат. — Бәлки, иске танышыңа чәй эчереп чыгарырсың?

Ирек ишекне ачып җибәрде. Ул кара трикодан, ак күлмәктән, яланбаш иде. Рашат яшен тизлеге белән аның касыгына китереп төртте. Ирек бөгелеп төшүгә, чәченнән эләктерде дә башы белән борыска китереп бәрде, аның маңгаеннан чәптереп кан ага башлады, бөтен йөзе, күлмәкләре, идән канга манчылды.

— Утларны сүндереп чыгыгыз, — диде ул Күсәк белән Фишкегә, үзе Ирекне чәчләреннән сөйрәп аска алып төште.

Барлык утлар сүнде, өй тирәсе караңгылыкка чумды. Рашат Ирекнең пульсын капшап карады — ул исән иде.

— Түрдә мунча булырга тиеш, — диде Рашат, Фишкегә пышылдап. — Карап килегез әле. Ачык булса, шунда алып керәбез.

Берездан тегеләр килеп җитте.

— Мунча ачык.

— Тәрәзәгә берәр нәрсә куегыз да утын яндырыгыз.

— Булды, бар да тәртиптә, — диде Фишке, килеп.

— Әйдә тот култыгыннан.

Алар Ирекне сөйрәп алып киттеләр һәм мунча эченә алып керделәр. Ул аңында түгел иде. Рашат бактан бер чиләккә су агызды да Ирекнең өстенә сипте. Ул акрын гына күзләрен ачты, ыңгырашып, кулы белән маңгаеның ярылган урынын тотты.

— Йә инде, йә, бала-чага булма, — диде Рашат, аның култык астыннан тотып торгыза-торгыза. — Кая утырасың: ләүкәгәме, әллә менә бу астагы киң тактагамы?

Ул аны стена буйлап сузылган утыргычка чүңкәйтте.

Ирекнең маңгаеннан аккан кан күзләрен томалый иде. Ул, берни аңламыйча, кулы белән күзләрен уалады, авызына кергән канны төкерде.

— Хәзер, хәзер, якын кешегә беренчел ярдәм күрсәтү кирәк, — диде Рашат, дәртле тавыш белән. Ул стенада эленеп торган бер сөлгене алды да Ирекнең маңгаен кысып бәйләп куйды. — Менә булды.

Ирек канга баткан кулларына, күлмәгенә, трикосына аптырап карап торды, ул һаман да аңына килә алмый иде.

— Фишке, булмаса, шешәне ач әле, — диде Рашат. — Зиһенен җыйдырырга кирәк бит.

Фишке кесәсендәге яртысыннан капрон стаканга аракы агызды:

— Әйдә тот берәрне, — диде Рашат, Ireккә аракы сузып.

— Эчмим мин.

— Эчәрсең.

Ирек аңышканчы, Рашат аның чәченнән кинәт артка тартты да ачылып киткән авызына аракы салды. Ирек аның күпмесендер йотты, аннары тончыгып ютәлләргә кереште.

— Ярый, шул җитеп торыр, — диде Рашат.

Аннары алар, стаканга тутырып-тутырып салып, аракыны эчеп бетерделәр, өчесе дә тәмәке кабыздылар. Мунча эчен зәңгәр төтен каплады.

— Табигать тере затларны мәзәк яраткан: берәр нәрсә кыландырсаң, мелт итәләр дә сүнәләр.

Аның күз читләрендә көлгәндәге төсле җыерчыклар пәйда булды, иреннәренә ләззәтле елмаю таралды.

— Ну, ничек, хәзер эшнең кая таба барганын аңладыңмы? — диде ул, Ireккә туп-туры карап.

— Син нишләргә уйлыйсың? — диде Ирек, авызындагы канлы төкерeген учы белән сыпырып алып.

— Менә бит телгә килдең, — диде Рашат, көлеп. — Бу инде начар түгел. Минем сине нишләтүем үзеңнән тора. Безгә берничек тә исәп-хисап ясамый булмый. — Рашат кулы белән аның яңагын җиңелчә генә чәбәкләп алды. — Болынкырга килгәннән бирле син миңа яшәргә комачаулადың. Аннары Мәскәүгә килеп буталдың. Тагын минем юлга аркылы төшәсең.

— Минем синең юлыңа аркылы төшкәнем юк.

— Ничек кенә төшәсең! Теге чакта мин кушкан тәрҗемәне эшләмәдең. Ачу кабарып калды — кул җитмәде. Ә хәзер син мине кабат чакырдың. Менә шушы мунчаңның матчасына асам да китәм.

— Ни кирәк сиңа?

— Аңлатырга озак. — Рашат сигаретын ыргытты да шун-

дук икенчесен кабызды, тирән итеп суырып, аның төтенен Ирекнең йөзенә өрде. — Нишләп син Шәрифуллинга каршы барасың?

Ирек чак кына сикереп тормады. Ул кулларына таянып күтәрелә башлады да урынына утырды. Аның башына мең төрле уй килде. Тик ул Әхнәф белән Рашат арасына бернинди күпер сала алмады, моның нигезе дә, максаты да, мәгънәсе дә юк иде. Әтисен урыныннан очырып беренче секретарь булган кешене, аларның гаиләсенең кубарылып Болынкырдан китәргә мәҗбүр иткән кешене Рашат тереләй тотып ашарга тиеш кебек.

— Инде тыңла, — диде Рашат теш арасыннан.— Шәрифуллинга син комачаулама. Аңладыңмы?

— Аңладым, — диде Ирек. — Ул сиңа акча бирәдер...

Рашат аның яңагына сугып җибәрде. Ирекнең борыныннан кан китте.

— Засранец-писака! Минем монда элемтәләрем җитәрлек. Атна саен дуслар белән сөйләшеп торам. — Ул сәгатенә карап алды. — Безнең вакыт тар. Туктарга сүз бир дә, без китәбез. Әгәр башкача булса... — Ул мунчаның матчасына карап куйды. — Бер генә юл кала.

Рашаттан барысын да көтәргә мөмкин икәнлекне аңлаганга, Ирек нindидер үзен коткарырдай җавап эзләде. Ул җавап бар иде, «ярар» дигән бер сүз җитә, ләкин кан исен сизгән ерткыч дошманына ташланган кебек, ул әлеге сүзне әйтә алмады, авыр сулап утыра бирде, башы торган саен аскарак иелде.

Рашат бармак очы белән аның иягеннән тотып, башын күтәрде һәм, сүзләрен санагандай, берәм-берәм бастырып тезде:

— Син мине һаман да шаяртадыр дип уйлыйсың. Акылыңа кил. Син бит үзеңчә кемнәргәдер яхшылык эшләргә телисең. Шулаймы?

— Әйе.

— Яхшылык дигән нәрсә бетте. Яманлык та юк. Алар кушылдылар, җөен дә таба алмыйсың.

— Ә нәрсә генә бар соң?

— Эш белән түләү. Әгәр кемдер пистолетның тәтесенә баса икән, аңа төзәп интеккән, бармагын бөгеп көч сарыф иткән өчен акча түләнә.

— Син мине калдыр, Рашат. Икебезгә дә яхшы булыр...

— Ю-у-ук! — дип сузды Рашат, төкерегенә тончыга-тончыга. — Син юлыма аркылы төшмәсәң дә, мин моны эшләр идем. Ник син шулай яшәргә тиеш? Ә мин? Минем хакым юкмыни? Миндә коточкыч көч! Кем аркылы төшә, барысы да тезләнәчәк, сытылып калачак! Сез «печән басуы» дигән

сүзләрне хәтерлисеңме? Менә чабучылар якынлашты, килеп җиттеләр, без күп, барыбер кол булачаксың син дә.

Фишке яңа шешәне ачты, алар өчесе дә эчеп куйгач, Рашат, тәмәкесен суыра-суыра, ләззәтләнеп сөйләргә керешге:

— Сез өстә нинди гыйфрит утырганны белмисез. Бөтен Җир шарына ул хуҗа. Астарак, — ул башы белән Фишкегә һәм Күсәккә ымлап куйды, — тагын бер кавем бар. Тик ул кавем, өстәгеләр белән чагыштырганда, күселәр өере генә. Шуларның икесеннән җирнең үлем шәүләсе барлыкка килә. Өстә безгә урын юк, астагысында чәбәләнергә туры килә. Йә, соңгы сүзеңне әйт.

— Синеңчә булыр...

— Менә бусы егетләрчә! Кисәтеп куям: кемгә дә булса теш араңнан бер сүз ычкындырсаң... кызың... хатының юк дип уйла... Тагын кадерле кешеләреңне барла, үзеңә кадәр алар расходка китәчәк. Ә маңгай өчен үпкәләмә, ныграк чиертелеп китте, элеккеге исәп-хисап бар бит безнең. Мәскәү исәп-хисабы.

Алар дөбер-дөбер чыгып киттеләр. Ирек, бармагын да селкетмичә, урынында бик озак утырды. Кем эше? Мең мәртәбә үлчәүгә салып карагач, ул Әхнәфнең бу адымга баруына шикләнде. Әхнәф Рашатның кем икәнен бик яхшы белә, аның белән мондый уен уйнау үз башыңа үзең элмәк киюгә тиң икәнен чамалый. Кем кулы? Рашат Әхнәфтән нәрсә даулый? Күпме генә эзләсә дә, бу сорауга җавап табылмады. Ул чайкалып урыныннан торды, башы җиңелчә әйләнә, тәне тораташ сызлый иде. Иң элек ничек кенә булса да бу канлы эзләрне юарга, Зәнфирә бернидән дә шикләнмәслек хәлгә китерергә, аны борчымаска кирәк иде... Әмма ниятен тормышка ашыру ансат кына булып чыкмады. Җыештыруын җыештырды, әмма өйгә кереп идәнгә ауды. Иртән Зәнфирә эштән кайтканда, ул шул хәлдә ята иде. Больницага «ашыгыч ярдәм» машинасы алып киткәнне Ирек юньләп хәтерләмәде дә...

## 5

Ирек өч көн буе башы әйләнеп, укшып җәфаланды. Йокысы качты. Хәтта газета укырга да рөхсәт итмәделәр. Үзе белән бер палатада яткан биш кеше аша дөнья хәлләреннән хәбәрдар булды. Ярый әле, аның кыйналуын ишетү белән, Зәнфирәнең малае Зирәк Казаннан кайтып җитте. Ул, ГИДУВның иң яхшы врачлары белән киңәшеп, өч төрле дару юнәткән иде. Әлеге даруларны кабул иткәч, стенага то-

тынып кына атлаган Ирекнең баш әйләнүе дә, сызланулары да кимеде. Айгөлнең килеп йөрүе дә аның сызлануларын күпмедер оныттырды. Кызы белән алар шактый нәрсәләр сөйләштеләр, аңлаштылар. Прокуратура тикшерүчесе ул көнне булган хәлне, әллә ничә мәртәбә килеп кат-кат сөйләтте, төпченде, һәрберсендә протоколга кул куйдырды.

Менә бүген Ирек беренче мәртәбә стенага тотынмыйча йөреп килде. Маңгаен бәйләтеп чыкканда, дәвалаучы врачы аны бүлмәсенә чакырды, үзе каядыр китеп барды. Ул сәерсенеп кенә ишекне ачса, өстәле артында иңбашына халат элгән Әхнәф утыра иде. «Болай гына килгән, сүз булмасын өчен», — дип уйлады Ирек.

Әхнәф каршы килде дә аны, ярым кочаклап, иңбашыннан какты, аннары бер адым чигенеп, аңа карап торды. Гаҗәпләнүен белдереп баш чайкады.

— Эләктерсеннәр генә, һичшиксез ачык суд ясатачакмын! — дип куйды ул, аклангандай.

Иреккә әллә ни булды, әйтерсең лә аның битләренә, чәчләренә йомшак кына кагылып, җылы талгын җил исеп китте. Моңа кадәр сиздермичә генә барлык яшәү тамырларында йөргән иң кадерле тойгылар, кайнар күз яшьләредәй, бер мизгел эчендә күңеленнән бәрделәр дә чыктылар...

— Хәлләрең ничек?

Әхнәфнең бу соравы Ирекне күпмедер айнытып җибәрде. «Хәзер тереләм инде, сызлаулары бетә» димәкче булды, әмма тамак төбендәге кайнар тыгызлык тавышын томалады. Шуңа күрә барлык тырышлыгын туплап, көч-хәл белән:

— Аруга таба... — дип кенә куя алды.

Әхнәфнең кайгылы күз карашын, борчулы йөзен күргәч, аның хакында начар уйлаганы өчен Иреккә оят булып китте. Бу күзләргә, бу йөзгә нәкъ менә аны Мәскәүгә укырга җибәрмичә тилмерткән көннәрдәге хафалану билгеләре кунган иде.

Әхнәф аңа туп-туры карады да:

— Син минем килгәнгә ачуланмыйсыңмы? — дип сорады.

Аның күзләрендә икеләнү билгеләре чагыла, кулларының җиңелчә калтыравыннан каушаганлыгы күренеп тора иде.

— Ни сөйлисең, Әхнәф?! Чын күңелемнән рәхмәт...

Әхнәф ул кичтә булган хәлне җентекләп сөйләтте, гаҗәпләнде, нәфрәтләнде. Ирек аңа дөресен сөйли алмаудан кыенлык кичерде, әмма ул, Зәнфирәгә дә, тикшерүчегә дә, башкаларга да ялганлап сөйли торгач, моңа күнегеп бара иде инде.

Аны тыңлап бетергәч, Әхнәф:

— Без буталдык... — диде. Безгә бүтәнчә яшәргә кирәк...

Аның сүзләре Ирекнең бәгырен көйдереп узды.

— Миңа да бик кыен, — дип сүз башлады Ирек. — Соңгы вакытта төрлесе булды: үпкәләштек тә, тарткалаштык та... — Дулкынланудан ул күңелендәген белдерергә сүзләр таба алмыйча туктап калды. — Мин сиңа бер әйберне әйтмичә кала алмыйм. Вакыт-вакыт бик ерагайдык та... бәрелештек тә... Мин барыбер бергә булачакбыз дигән өметне сүндермәдем.

Аның башы чәнчешергә тотынды һәм ул үзе дә сизмәстән ыңгырашып куйды. Әхнәф аңа кып-кызыл помидорлар, кара һәм яшел виноград, хөрмә, тагын нindидер җимешләр тутырылган пакет тоттырды.

— Тизрәк савыгуың өчен витаминнар...

Әхнәф, коридор башына җиткәч, икенче катка төшүче баскычның һәр киртен берәмләп санагандай, аска таба лап-лоп атлады. Әйтерсең лә аның иңбашларына күтәрә алмаслык авыр йөк салынган һәм шуны исән-имин алып төшеп җиткерергә кирәк иде. Ул бертын туктап та алды, Ирек янында узган ярты сәгать вакыт аның бөтен дөньясын актарып ташлаган һәм ул шул дөньяны һич кенә дә бербөтен итеп җыя алмый иде... Ул больницага барасы кеше түгел иде. Башта ул Ирек белән булган хәлне игътибарсыз гына уздырырга карар кылды, әмма карар бернинди сәбәпсез кинәт юкка чыкты һәм ул бармыйча кала алмаганлыгын аңлады. Тик бу барыбер җаны теләп түгел, мәҗбүри генә бару иде. Ярар, дип уйлады ул, андый чакта кешенең күңеле нечкәреп китүчән, бәлкем, яңадан Әхнәфкә каршы эшләр оештырып йөрмәскә бер этәргеч булыр. Халык күзлегеннән караганда, бу Ирек каршында аның күпмедер дәрәҗәдә баш июе, хәтта куркуы дип тә бәяләнергә мөмкин. Күңелен шушылар тырмап торганлыктан, ул ихтыяри-мәҗбүрирәк килгән иде. Ирекнең күгәргән, сыдырылган йөзен күргәч, аның бөтен гәүдәсен көйдереп, кызгану тойгысы үтте, бермәл ул, әллә каушап, әллә аны кызганудан, өнсез булып басып торды. Ә менә хәзер ул нәрсәдер урлаганда тотылган кеше кебек кайтып бара.

Машина хакимият бинасы баскычына терәлә язып килеп туктады.

— Нишләп монда алып килдең? — дип кычкырды Әхнәф.

Шоферның күзләре шакмак булды, йөзенә аптырау билгеләре чыкты.

— Кая барасы иде соң, Әхнәф Хәсәнович?!

Сәгатенә карагач, Әхнәф әле унберенче ярты гына икәнен күрде.

— Өйгә, — диде ул, акрын гына. Аннары нишләптер пышылдап тагын кабатлады: — Өйгә...

Хуҗасының бу вакытта, хәтта ял көнне дә өенә кайтканын күргәне булмаган шофер, машинасын чак кына арттагы газонга кертмичә, выжылдатып алып китте.

Әхнәф, өйгә кайту белән, теге авыр йөкне җилкәсеннән төшергәндәй, диванга барып ауды. Аңа, бөтен дөньясыннан качып, ялгызы гына калырга кирәк иде. Ирекнең ихлас тойгыларын күрү аның күңелен кайнатып җибәрде. Ул кабат үзара якынаю өметен өзгән иде бит инде. Ә менә Ирек ул өметне саклаган булып чыкты. Әхнәф үзенең аңардан күпкә түбән икәнлеген аңлады. Ирек элеккечә үк сабый җанлы, элеккечә үк усаллык тойгысыннан мәхрүм иде. Әхнәф инде ничә еллар буе үзенең тулысынча ышанырлык бер генә кешесе дә калмаганын белә. Язмыш чәчәгенең бу әче нектарын инде ничә еллар буе тавышсыз гына йота ул. Кеше, җәннәтнең түрендә утырса да, ялгызы гына бәхетле була алмый. Бәхетле булу өчен кимендә ике кеше кирәк. Ә бит җир йөзендә аның таянырлык бер кешесе бар икән! Тик ике арадагы җепләр генә өзелгән. Менә бүген аларның ялгану мөмкинлеге аермачык күренде. Бу олы куаныч иде! Ләкин ул җепләрне кем өзде соң? Үзен акларлык дәлилләрен күпме генә барласа да, бизмән аның файдасына баса алмады. Җепләрне башлап өзүче Әхнәф үзе иде. Аңа Николай Николаевичлар, тагын әллә кемнәр кирәгрәк иде. Дөрес, райкомның беренче секретаре булгач, ул Ирекне үзенә ныграк бәйләргә уйлады. Шул максат белән секретарьлык кәнәфиен юу сылтавы астында аны махсус чакырды. Әмма Ирек партиягә кабат керүдән дә, редакторлыктан да баш тартты. Әхнәф, болай булу ихтималын күздә тотып, алдан ук тозак корып куйган иде: ничек булса да Ирекне эчерергә! Чөнки ул бик зур көч иде, беренче секретарь йогынтысыннан читтә калган, аңа буйсынмаган кеше кирәкми иде. Шуңа күрә ул Ирекне, эчертеп, элекке эзенә төшерергә, көчен сындырырга ниятләде. Әлеге адымны ни дип атарга? Ул бу сорауны читкә куалады, игътибарны тизрәк башка нәрсәләргә күчерергә теләде. Әмма уйлары һаман бер тирәдә бөтерелде. Әхнәф аларга йортны да Ирек үзенә каршы чыга алмасын дип салдырды. Бүләк итеп бирелгән стенкага килгәндә, анысын Фәһимә Әхнәфкә сиздермичә генә хәл иткән булып чыкты. Теләсә, ул моны ярты юлда шып туктата ала иде. Кинәт ул дөреслеккә якыная башлау белән чигенүен, сорау туу белән җаваптан кача баруын тойды. Бу халәтне урлашканда кулыннан эләктерелгән каракның халәте белән генә тиңләп буладыр. Карак беркайчан да үзен хаксыз дип санамый.

Әхнәф яткан җиреннән сикереп торды. «Мин кабахәт түгел!» дип кычкырасы килде аның. Алайса, нишләп әйбәт булмаган гамәлләр кылынган? Абынулар булгандыр, аның урынына менә хәзер ул үзен аяусыз хөкем итә, битәрли икән, димәк, вөҗданына хилаф нәрсәләрдән шушы рәвешле арына, савыга бара. Әллә соң ул, Ирек теге чакта әйткәнчә, ике кеше булып яшиме? Беренчесе — яшь чактагы саф Әхнәф. Әмма ул мәет кебек хәрәкәтсез, өстән бик авыр нәрсә белән бастырып куелган. Үзе тере булса да, берни дә кыла алмый. Икенчесе — бүгенгесе — хакимият башлыгы, бөтенесен дә баш идереп тота, буйсынмаганнарга чара күрә, эштән куа, җәза бирә, өстеннән бастырып куя, тәнкыйтьли, әрли, сүгә. Аның уйларында, хис-кичерешләрендә, башында һәм йөрәгендә җир, техника, машиналар, мал-туар, фермалар, гектарлар, тонналар, меңнәр, миллионнар... Ул — йөрәкле роботның бер төре. Тиешлене генә белә, шул тиешне чынга әверелдерү өчен көненә мең төрле маска кия. Бер тәндә, бер җанда аерым яшәүче бу ике кешене ничек бергә кушарга? Күпме генә эзләсә дә, Әхнәф моңа ачык җавап таба алмады...

## 6

Рашат белән канлы очрашу Ирекне шактый какшатты. Сагынулы-сагышлы уйларның адәм балаларын саргайтып-киптереп үтерүе турында җырлар күп, алар гомер буе җырланган, әмма уй дигән нәрсәнең бер генә минут та баштан китмәвенең нинди коточкыч газап икәнлеген Ирек хәзер генә аңлады. Аның күңелен туктаусыз курку, ачыну, кимсенү уты көйдерде, көндез дә, төнлә дә ул әнисенә, Айгөлгә, Зәнфирәгә бер-бер нәрсә кылмасалар ярар иде дип шомланды. Эшенә дә ул болай гына, җансыз кеше кебек барып кайтты. Язуын бөтенләй онытты, уйлар өермәсе аны бер генә минутка да җибәрмәде, туктаусыз бөтен көчен, җанын суырды. Ярый да Ирек сүзендә торды: беркемгә берни сиздермәде, аның шартына күнде. Ә ул сүзендә торырмы соң? Рашатның уе биш минут эчендә биш төрлегә үзгәргәнен Ирек бик яхшы белә.

Менә бүген, больницадан кайтуының икенче көнендә, бакчада агач төпләрен йомшартып йөргәндә дә, ул авыр уйларыннан арына алмады. Өйалды ишеге ачылып, Зәнфирә ашарга чакыргач, Ирек, көрәк-тырмасын куеп, салкын су белән юынды, яхшылап сөртенде, инде ямь-яшел булып күпереп утыручы Ык буе әрәмәләренә, еракта күкшелләнеп сузылып киткән тауларга карап торды. Дару исе, чытык йөзле авырулар белән тулы, йокы качыргыч больница палаталарын-

нан соң бу күренешләр шулкадәр сагындырган, шулкадәр якын иделәр...

— Сиңа ниндидер хатын-кыз шалтыратты, — диде Зәнфирә, аш бүлеп аның алдына куйгач.

— Нинди хатын-кыз? — диде Ирек, аптырап.

— Белмим. Хәзер кагылып чыгам әле, диде.

Мондый шалтыратуларны инде шактый ишеткәнгә күрә, Ирек тагын берәрсенә берәр нәрсә язып бирергә кирәктер инде дип уйлады да тавык шулпасын ашарга керешге. Шулчак машина туктаган тавыш ишетелде, озак та үтмәстән, ишек кыңгыравы шылтырады. Зәнфирә, урыныннан җәһәт кенә кузгалып, тышка чыгып китте. Аның кем беләндер сөйләшкәне ишетелде һәм шундук бусагада Нәкыя күренде. Ирекнең кулындагы кашыгы чак кына төшеп китмәде. Ул башта, урындыкка беркетелгәндәй, кузгала алмыйча торды, аннары, көч-хәл белән аягүрә басып, Нәкыянең сәламенә җавап кайтарды. Зәнфирәнең йөзенә аптырау билгеләре чыккан иде.

— Әйдәгез, узыгыз, — диде ул, ниһаять, аның каршына килеп.

Нәкыя кулындагы дипломатын куяр урын эзләде, моны сизгән Ирек аны тиз генә алып, трильяж янына сөяде. Алар Нәкыяне кыстый-кыстый өстәл янына утырттылар. Зәнфирә аш бүлгән арада, Ирек аны игътибар белән күздән үткәрергә өлгерде. Ул теге вакыттагыга караганда бераз ябыккан булса да, йөзендә җыерчыклар күренми, элекке чемкара чәчләре арасында чал кунганнары шактый күренә күренүен. Казанда чактагы затлы муенсалар, беләзек-алкалар юк иде. Нәкыя гәүдәсенә сыланып торган куе шәмәхә күлмәк кигән, аның итәгеннән кояшта янып каралган шома тезләре ялтырап күренеп тора, күкрәк турындагы декольтесы аның муенына һәм иңбашларына килештереп, таман гына уелган иде.

— Бу... Нәкыя була... — диде Ирек, Зәнфирәнең сораулы карашына җавап итеп. — Китап нәшриятында рәссам. Ә бусы — минем хатыным Зәнфирә.

— Сез инде, зинһар өчен, мине гаеп итә күрмәгез... — Нәкыянең озын керфекләре тибрәлеп куйды, ул карашын аска төшерде, кыенсынудан бит очлары алланып китте. — Бирегә эш белән килгән идек. Главагыз чакыруы буенча.

— Без килгән кунакка һәрвакыт шат, — диде Зәнфирә, аны кыстап.

Аш ашаган арада Нәкыя инде Болынкырда атнадан артык эшләүләрен, иртәгә китәчәкләрен сөйләде, биредәге халыкның ачык йөзле булуын, кунакчыллыгын мактады. Алар

кунакханәдә яшәгәннәр, Ыкта һәр көн су коенганнар, табигатьнең иң матур урыннарында йөргәннәр. Хакимият башлыгы урынбасары Зәйнуллин рәссамнарга табигатьнең иң матур җирләрен күрсәткән. Ашап-эчкәч, алар өчәүләп зал ягына чыктылар, Ирекнең эш бүлмәсен карадылар. Нәкыя көнләшкәндәй баш чайкап куйды.

— Ә шулай да бәхетле сез, — диде ул, елмаеп. — Шәһәр кешесе, ни генә әйтсәң дә, дүрт стена эченә бикләнгән тоткын инде ул. Әгәр дә мин шушындый табигать кочагында яшәсәм, инде әллә кайчан бөтен дөньяга танылыр идем.

Үз-үзенә ирония белән әйткән бу сүзләрдән Нәкыя матур гына итеп көлеп куйды.

— Соң, күчегез безгә, — диде Зәнфирә. — Сатыла торган йортлар күп бит.

— Белмәссең, белмәссең, — дип куйды Нәкыя, ничектер серле генә.

— Иҗат эшләрегез ничек бара соң? Нәрсәләр ясыйсыз?

Ирекнең бу соравын ишеткәч, Нәкыянең йөзеннән ниндидер кара күләгә үткәндәй булды, ул ярым көчәнеп елмайды.

— Безнең рәссам халкының менә шушылай инде: кайда бераз акча исе бар — шунда ташланасың, ә зур полотнолар өстендә эшләү өчен бик күп вакыт, акча кирәк. Акча эшләсәң, полотно тора, полотно иҗат итсәң, акчасызлык китереп тери.

— Гел кул кушырып утырмыйсыздыр әле?

— Юк, әлбәттә! Өч елдан артык инде мин бер триптих язам.

— О-о-о! — дип куйды Ирек. — Нәрсә турында була соң ул?

— Аны аңлату озак, — диде Нәкыя. Ул дипломатын алып килде дә Ирек алдына бер альбом куйды. — Кызыксынсагыз, таныша торыгыз. Бәлкем, берәр фикер әйтерсез?

Ирек альбомны ачуга, Нәкыя белән Зәнфирә кече якка чыгып киттеләр. Ул башта берни дә аңламады. Күзгә беренче бәрелгән нәрсә аның рәсемнәрендә давыллап килгән яшенле болыт төсендәге куе буяуларның өстенлек итүе иде. Шунда ниндидер сары, кызыл нурлар, тәртипсез сибелгән таплар шәйләнә. Альбомның битләре беркетелмәгән иде, Ирек аларны берәм-берәм алып тезә башлагач, ниндидер питомник эчендәге картина пәйда булды. Иң үзәктә шәрә гәүдәле, ап-ак сакал-мыеклы, ап-ак чәчле кеше утыра. Аның тез өстендә Җир шарын хәтерләткән түгәрәк бер йомарлам тора. Янәшәсендә кызыл, ак, кара, зәңгәр, яшел төстәге балчык өемнәре. Ул шуның кызылын алып, шәрә ир кеше ясап

маташа, үзе, телен колашаландырып, шуңа таба өрә. Ике күзендә ике кеше. Аның берсе монголны хәтерләтә, икенчесе Иреккә иконалардан таныш булган Гайсә пәйгамбәргә тартым булып күренә. Озак карый торгач, ул әлеге затның күзләренең түгәрәге пушка көпшәсенең башы төсле булуына игътибар итте. Өченче биттә ярым елан, ярым кош төсле ниндидер куркыныч зат ясалган. Аның гәүдәсе күпмедер дәрәҗәдә кешене дә хәтерләтә кебек. Ул куркыныч бармакларын кып-кызыл йөрәккә батырган, ә йөрәк болытлар белән борып, ялтыравыклы сары нәрсә белән тарттырып ясалган. Эчендә пружина, шестернялар, көмеш кан тамырлары күренә. Ирек боларны карап, аптыраудан гаҗиз булды, ул берни дә аңлый алмады. Бөтен рәсемнәрнең артында шәрә балалар, кызыл алма, граната кебек нәрсәләр, тәре төсле чәчәкләр, пычаклар, айга охшаш кылычлар, яфраклар, шестерня-йолдызлар, сүнеп баручы кояш-тәгәрмәч, тагын әллә ниләр дулкын-дулкын булып сузылган, кайсысы бик чекерәеп күренә, кайсысы өрфия кебек сизелер-сизелмәс кенә. Болардан үзенең берни дә аңламаганын сизгән Ирек альбомны тиз-тиз генә карап чыкты. Аның соңгы битендәге Коръән белән Библиянең янәшә сурәтләнүе, аларның икесенең дә тышына зур күз төшерелүе Ректә әллә нинди аңлаешсыз тойгылар уятты. Альбомны япкач, аның күз алдында бер биттәге канлы куркыныч авыздан чыгып торган шәрә бот, ул ботка кадалган шприц бик озак җуелмыйча торды.

Зәнфирә белән Нәкыя кергәч, Ирекнең җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй булды.

— Йә, ничек? — диде Нәкыя, елмаеп.

Ирек тә, аның елмаюына җавап бирергә тырышып, акрын гына баш чайкады:

— Гафу итегез... Безнең ише авыл гыйбадларына барып җитә торган нәрсә түгел бу. — Ирек үзенең авызыннан чыккан «нәрсә» дигән сүзне ничек җыеп алырга да белмәде. Ашыгып хатасын төзәтергә тырышты: — Иҗат эше димәкче идем. Зур панорама икәнлеге, олы фикер салынганлыгы әллә каян сизелеп тора. Мин үземне бөтенләй ят дөньяга күчкән кебек хис иттем. Бәлкем, аңлатып бирерсез? Безгә бик тә кызык, гыйбрәтле булыр иде бу.

— Сез нәрсәдер тойгансыз, — диде Нәкыя. — Чыннан да, ят дөньяга күчү бар монда. Моны тою сезнең иҗат кешесе икәнлегегезне күрсәтә. Ә инде теләсәгез, мин үзем язачак триптихның кайбер моментларын сезгә әйтеп китә алам. — Ул кулларын кушырды да түшәмгә карап шактый вакыт сүзсез торды, өске тешләре белән аскы иренен тешләде, аннары кисәк кенә карашын Зәнфирәгә юнәлтте дә: — Сез дә

утырыгыз, — диде. — Мин сөйләгәндә йөрергә яратам. Беләсезме... Бу триптих адәм балаларының фаҗигасе турында. Төгәлрәк итеп әйткәндә, кешенең мәңге алдануга дучар ителгән зат булуы турында. Ул беркайчан да дөреслекне, чын хакыйкатьне аңлый алмаячак. Иң элек адәм баласы үзен илаһи көчкә ия дип саный, барлык өмет-хыялларына ирешер кебек тоела, үлем турында искәртеп торсалар да, ул аны ишетергә теләми. — Ул, сүзен бүлеп, Ireккә карап бик озак торды. — Бу алдану иң ачысы, иң газаплысы. Алданганнарын аңлаганнары да үзләре эшләгән хатаны төзәтә алмыйлар, чөнки бу төр алдану кешене тәмам гарипләндерә. Аннары адәм баласы мин бу эшне дөрес башкардым, бу гамәлне кылып савап алдым дип алдана. — Нәкыя, сүзеннән туктап, залның икенче башыннан ук әйләнеп килде һәм, Иректең каршына ук басып, сүзен дәвам итте: — Менә сез — язучы, күпчелек әдипләр ни язганнарын аңламыйча дөньядан китеп баралар. Ә аларның һәркайсы бөтенләй икенче нәрсә язарга тиеш булган булып чыга...

Нәкыянең бу сүзләре Ирекнең йөрәгенә килеп кадалды. Бер караганда, ул чыннан да хаклы иде. Ireккә карата аның әйткәннәре туры да киләдер, ләкин бит әле монда әдәбиятның йөзек кашлары — олы каләм осталары бар. Нәкыянең барысына җыеп куйган бәясе, өсләренә шартлатып кара мөһер сугуы Ireккә ошамады.

Шуңа күрә ул аның сүзен тупас бүлде:

— Ә рәссамнар ничек соң? — диде ул, кыза баруын яшермичә.

— Рәссамнар да, башка иҗатчылар да шулай.

— Сезнең бу триптихыгыз нәрсәгә әйди инде?

— Сәнгать әсәре әйдәргә тиеш түгел. Ул тормышка ишарә генә ясый, ниндидер хис-тойгылар, уйлар уята. Һәркем үзенә ни кирәк, ни ошый — шуны ала.

— Ә бу йөрәкне әләктергән зат ни?

— Анысы кешеләрнең бүгенге әнә шул ялган уен гәүдәләндерә. Йөрәкнең сары, ялтырап торуы — алтын төсе. Бөтенесен байлыкка кайтарып калдыру.

— Алайса, бу Иблис була инде, — дип куйды Ирек.

— Әйе, алай дияргә дә була. Сез һәммәсен дә төшенчәләр кысасына кертмәкче буласыз. Кирәкми төшенчәләр!.. Мин фикеремне төгәллим. Кешенең тагын бер ялгышы — мин уйлап яшим дигән уй белән дөньядан китүендә. Баш җитмәслек хәл: ничә мең еллар узган! Ә кеше хайвани инстинктлардан ары һаман да күтәрелә алмый. Тик бөек шәхесләр генә ниндидер бөеклеккә ирешәләр. Шушы алдану аркасында кешелек упкынга очып бара. Аны сискәндерү, тук-

тату өчен яңа нәрсәләр, зур мәгънәви әйберләр кирәк. Моны икенче төрле өр-яңа философия дип атап буладыр.

Нәкыя тын алган арада, Ирек тиз генә альбомның соңгы битен ачты да аңа күрсәтте:

— Менә монда Коръән белән Библияне янәшә ясагансыз. Мин андый зур нәрсәләргә үрелүне хуплап бетерә алмыйм.

— Нишләп? — диде Нәкыя, күзләрен зурайтып.

— Чөнки болар — илаһи нәрсәләр. Безнең акыл җитә торган түгел. Аннары сез бу изге китаплар артында кар бөртекләре кебек бөтерелүче ниндидер аңлаешсыз нәрсәләр ясагансыз. Алар гарәп хәрефләрен дә хәтерләтәләр, эротикага да ишарәлиләр, аларда кешенең хромосомалары да чагыла кебек. Кыскасы, мин монда ниндидер ирония күрәм.

Нәкыя башын чайкап көлеп җибәрде:

— Мин сезгә рәхмәт кенә әйтә алам! — диде ул, кулларын чәбәкләп. — Бик күпләр аңламаган нәрсәне сез бер карауда тотып алгансыз. Әйе, биредә ирония бар. Игътибар иткән булсагыз, триптих зур бер питомник эчен хәтерләтә. Минем яшерен үткәргән фикерем мондый: безне бу җиргә ниндидер ят, чит планетадан китереп ташлаганнар. Безнең Алла дип табынганыбыз — әнә шул планета затлары. Коръәндә дә, Библиядә дә алар бу хакта: «Без сезне яраттык, без сезне изге юлга чакырабыз, без сезне җәзага тартабыз», — дип туп-туры әйтәләр. Бөтен галәмнәрне бар иткән Аллаһы Тәгалә булса, «Мин» дип сөйләр иде. Менә бу да кешенең тагын бер бик зур алдануы. Алар, бирегә кешене китереп, үзләре көткән, яхшыртылган токым алырга ниятләгәннәр. Алар бит бездән кешеләрне гел алып китеп торалар, тикшерәләр, күрәләр, нәтиҗә чыгаралар. Өметләре акланмады, кеше ирекле яшәде, токымы элеккедән дә начараюга таба китте. Хәзер инде колбиләүчелеккә кайту юлы гына калды. Антик чор кабатланачак. Кемнәрдер кара эшне башкарырга тиеш, кемнәрдер, югары рухи тормыш белән яшәп, әүлия югарылыгына үсәргә тиешләр. Алар шундый токымны алып китәргә ниятлиләр. Бүгенге тормышта стихияле рәвештә колбиләүчеләрнең берләшүе бара. Алар моны аңлап эшләмиләр, капитализмга барабыз дип куаналар. Асылда, һәммәсе теге планета затларының планы буенча бара. Ә коллар берләшергә сәләтсез. Аларның һәркайсына алтын богау кигерелә. — Нәкыя, сүзеннән туктап, шактый вакыт Ирекнең күзләренә карап торды, аннары сүзен дәвам итте: — Кыяфәтегездән күрәм, сез минем белән килешмисез...

— Әйе, — диде Ирек, кызуланып. — Сезнең бу үтә дә

баш әйләндергеч, үзегез әйткәнчә, сискәндерерлек фәлсәфәгезне мин йота алмыйм. Ясаган рәсемегездә кызыклы гына нәрсәләр күрдем, әмма мин анда татар милләтенең җанын, рухын чагылдыра торган бер генә чалым да таба алмадым.

Шуны гына көткәндәй, Нәкыя дөртләп капты:

— Кирәкме соң ул?! Милләт, тел, Ватан дип тартышу нигә? Җир шарына глобализация килә.

— Триптихыгызны аңларлармы икән соң?

— Россиядә аны беркем дә аңламаячак. Аның урыны Көнбатышта.

— Мин үз кавемем саклансын иде дигән нияттән чыгып язам. Үлгәндә дә шуннан чигенмәячәкмен.

Нәкыя аны үртәгәндәй көлеп куйды:

— Сез берни дә кыра алмыйсыз. Бәргәләнергә кирәкми, иптәш язучы, — диде ул, һәр сүзенә басым ясап. — Рус дворяннары халыкны революциягә кузгаткан. Аларда югары әхлакка табыну культы яшәгән. Намус өчен алар дуэльгә чыккан. Ә хәзер нәрсә? Байлык культы. Кайда сез кайгырткан халык? Мисез, йөрәксез яңа байлар, аның өстенә басып, гафу итегез, мастурбация белән шөгыльләнә.

— Алар сезнең бу сүзләрегезне ишетсәләр, нишләтергә белерләр иде...

Нәкыя үпкәләгәндәй Ирекнең алдыннан альбомын кискен генә тартып алды.

Нәрсәдер уйланып, иреннәрен эчкә суырды, аннары тирән итеп сулады да:

— Сез Шәрифуллинның дусты икән, — дип куйды. — Дөресме?

— Әйе... Алай дияргә дә ярый...

— Кеше үзенең дустының кем икәнен белергә тиеш. Шуңа күрә мин сезгә әйтмичә китә алмыйм. Ул безне үзенең яңа йортын бизәргә чакырган иде. Көненә ундүртәр сәгать эшләдек. Минем белән тагын ике рус художнигы тир түкте. Алар агачтан уеп бик күп нәрсәләр ясадылар. Безне кайбер түрәләр үзләренең хан сарайларын бизәргә чакыралар шулай. Тик Шәрифуллин сүзендә тормады, безгә вәгъдә иткән акчасының яртысын гына бирде. Бездән килешүгә, ведомостька кул куйдырды, ә тиешле акчаның яртысын үзенә тотып калды. Бернинди сәбәпсез! — Нәкыянең күзләре дымланды, тавышы калтыранып чыкты. — Менә бу колбиләүче була инде.

Ирек, берни дә әйтә алмыйча, карашын аска төбәгән килеш сүзсез утыра бирде.

— Хәер, ул үзе дә кол хәлендә, — диде Нәкыя. — Аның белән хатыны ничек тели, шулай идарә итә.

Ул, альбомын дипломатына салып, сәгатенә күз төшерде дә:

— Ой, миңа кузгалырга кирәк икән бит! — дип ишеккә таба атлады, кунак иткәннәре өчен Зәнфирә белән Ирекккә кат-кат рәхмәт укыды.

Алар Нәкыяне озата чыктылар. Капка төбендә хакимиятнең ак төстәге «УАЗ» машинасы тора, рульдә Зәйнуллин утыра иде. Ул, сикереп төшеп, Ирек белән күреште дә, машинаның алгы ишеген ачып, Нәкыяне утыртты. Алар кузгалып киткәч, Зәнфирә белән Ирек хәйран калып сүзсез тордылар. Ирек, ни өчен, кая атлаганын да белмичә, Ыкка таба юнәлде, әйтерсең лә аңа һава җитми иде. Болай дәвам итә алмый, болай яшәсәк, күңелләребездә, рухыбызда берсеннән-берсе матуррак, ямьлерәк нәрсәләр тамыр җибәрәсе урында агулы еланнар, чаяннар, аждаһалар, гыйфритләр кайнап торырга мөмкин икән... Барысы да сөзелеп бер урынга җыйнала, күрәсең...

## 7

Миңзаһит базардагы үлән сатучы картка бик озак барып йөрде, әмма ул йоклаткыч нәрсәне бирергә ашыкмады. Башта биш йөз сум сорады, Миңзаһит ризалашкач, «Үләнем бетеп китте» дип сузды да сузды. Аннары, үләннең бәясе бер мең сумга күтәрелгән, диде. Шул сумманы кулына алгач, үләнне биреп, төнәтмәне ничек ясарга икәнне өйрәтте. Миңзаһит, яшеренеп кенә подвалга төшеп, аны кызыл аракыга салып куйды. Өйгә алып керергә дә кыюлыгы җитмичә бик озак йөрде. Гүя бөтен җиһан, җирдәге тормыш алга ага, ә ул берүзе шуңа каршы бара, ул гына әлеге гомуми агымнан әшәкелеге белән аерылып тора һәм шуның өчен кешеләрдән алып соңгы бөҗәккәчә аннан җирәнәләр, әмма ул алар каршында үзен аклау өчен берни дә кыла алмый иде. Ахырда Рашат атна буе акча сорап, эчеп, холыксызланып җаннарын ашагач, ул төнәтмәне диван артына алып кереп яшерде. Моны эшләгәндә, бөтен гәүдәсен вак калтыравык биләде, сулышы кысылды, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Йөрәк даруларын эчеп бераз тынычлангач, диванына барып ятты да көтәргә кереште. Рашатның гырлап йоклаганы ишетелеп тора, ул, уянгач, һичшиксез, алпан-тилпән атлап, аның янына килеп җитәчәк. Бу минутны Миңзаһит төне буе калтыранып көтте. Рашатның тора башлавын ишетү белән, җәһәт кенә кухняга чыгып, пычакларны яшерде. Хәят әле тормаган иде. Менә Рашат, мәрәләп, кухняга килеп керде, кызарган куркыныч күзләре белән ашардай булып Миңзаһитка төбәлде.

— Бир, төзәтергә... — диде ул, гырылдап.

Шулчак кухняга Хәят килеп керде, нидер сизенгәндәй, шикле карашын әле Миңзаһитка, әле Рашатка юнәлтте.

— Нәрсә чекерәеп торасың инде? — диде Миңзаһит, аны артка таба этеп. — Кеше болай да газап чигә, бар, урыныңа кереп ят.

Хәят теләр-теләмәс кенә кухнядан чыгып китте. Миңзаһит калтыранган куллары белән шешәне алып килеп Рашатның алдына өстәлгә утыртты. Рашат кружканы тутыра язып төнәтмә салды.

— Әллә нинди исе бар...

— Күптән тора иде. Мускат чикләвеге салынган аңа.

Рашат кружканы күтәргәч туктап калды, борынын якын китермичә генә иснәде, һаман эчәргә ашыкмады, шикләнгәндәй карап куйды. Куркудан Миңзаһитка аның кулындагы сары кружка дер-дер калтырап күренде. Рашатның имән бармагы өзелгән сул кулы йодрыкланган килеш өстәлдә тора иде. Әгәр тәменнән чит нәрсә салынганын сизсә, буып үтерәчәк, шушы бармаксыз кулы белән ул инде аны әллә ничә мәртәбә акча сорап буды. Әмма бусында исән калдырачак түгел. Эчсен генә, тынычлансын гына... Мәңгегә тынычлансын... Ул инде ничек җавап тотасын да уйлап куйды: баш төзәтергә берәр нәрсә кертергә кушып шалтыратты да кемдер ишек аша гына бирде, диячәк. Дулкынланудан Миңзаһитның теше тешкә тимәде.

Менә Рашат кружканы авызына китерә башлады, ул йоткандагы кебек хәрәкәт ясап куйды. Нәкъ бала чактагыча. Аның шул хәрәкәтеннән алар Хәят белән икәүләшеп рәхәтләнеп көләләр иде. Шуны күрер өчен Миңзаһит аңа юри берәр тәмле әйбер бирә иде. Ул апельсинмы, виноградмы — ни генә булмасын, кулына алуга, Рашат иң элек тәмле итеп төкереген йотып куя иде.

— Әле бит капмадың, нәрсә йотасың син, улым? — дип көлә әнисе.

— Төкелек йотам, — ди иде Рашат, үтә җитди итеп.

Күзләрен алмыйча аларның үзен күзәтүләрен аңларга теләп, ул әле әнисенә, әле әтисенә карый иде...

Рашат кружканы иреннәренә терәүгә, Миңзаһитның бугазын, үпкәләрен яндырып кайнар һава тыгылды. Ул, әллә нинди кыргый тавыш чыгарып, кружкага китереп сукты, агулы шәраб Рашатның йөзенә чәчрәде, өс-башына түгелде, кружка шалтырап идәнгә очты. Шул мизгелдә Хәят та алар янына чәчрәп килеп чыкты. Рашатның күзләре шартлардай булып акайдылар, кашлары маңгаен җыерып өскә күтәрелде.

Шушы коточкыч кыяфәтендә сикереп торды да ярсулы тавыш белән:

— Ник түктең?! — дип кычкырды.

Аның бөтен гәүдәсе билгесез кул белән тотып селкеткәндәй дерелди иде. Ул инде кайнар даруга тиң сыеклыкның капмас борын эчендә татлы кымырҗуын тойган һәм шуны түгүчене нишләтәсен үзе дә белми иде. Миңзаһитка ничек җитезлек килгәндер, ул күз ачып йомганчы шешәне эләктереп, форточкадан тышка томырды. Рашат бер сикерүдә аны эләктереп, буып алды.

— Нигә әрәм иттең?! Ник түктең?! — дип үкерде ул, аны тәрәзә яңагына терәп.

Миңзаһит аякларының идәннән күтәрелеп-күтәрелеп китүен тойды. Аңа барыбер иде инде. Ике күзеннән кайнар яшь коелды, алар, битеннән агып төшеп, иреннәрен чылаттылар. Хәят, үзен белештермичә, Рашатның кулларына килеп ябышты, сүзен әйтә алмады, бары тик бугазыннан ниндидер аңлаешсыз авазлар гына чыкты.

— Үтер мине тизрәк! — диде Миңзаһит, сулкылдап.

— Улым, тимә!..

— Аракыны ник түкте ул, ник түкте?! Мине газаплау өчен юри түкте!

— Ул агу иде, — дип пышылдады Миңзаһит.

— Нәрсә?!

— Агу иде... Мин яшәргә тиеш түгел. Мин җир йөзендәге иң кабахәт кеше! Сине агуларга теләдем...

Рашат аның якасын ычкындыруга, Миңзаһит идәнгә сыгылып төште һәм, тезләнеп, аның күзләренә тилмереп карады. Күз яшьләренә чыланып беткән чырае, асылынып төшкән ияге карарга куркыныч, бөтен гәүдәсе калтырый, күзләрендә коточкыч курку һәм ялвару чагыла иде. Рашат аңа сүзсез карап торды, гыжылдап сулаганы өйгә генә түгел, бөтен шәһәргә ишетеләдер кебек тоелды Хәятка. Ул да, сүзсез-өнсез калып, авызына ингаляторыннан дару өрдерде. Рашат сукмады, сүгенмәде, эчендәге барлык һавасын чыгаргандай, тирән итеп бер сулыш алганнан соң, бүлмәсенә керде дә урынына гөрселдәп ауды. Өйлә турында Хәят аны ашарга чакыргач, җавап бирмәде, арты белән борылып ятты. Ул кичен дә ашарга чыкмады.

Хәят белән Миңзаһит керфек тә какмыйча төн уздырдылар. Аның кубарылып чыгып нидер кыласын көттеләр, әмма Рашат төнлә дә тормады. Иртән ул киенгән килеш килеп чыкты, кулына теге зур куркыныч сумкасын тоткан иде.

— Мин китәм, — диде ул, әллә нинди ят, тонык тавыш белән.

— Соң, юынып, кырынып, капкалап алыр идең, — диде Хәят, курка-курка гына.

Рашат гүя әнисенең сүзләрен ишетмәде, аның күзләре ябыштырып куйган боз кисәкләредәй хәрәкәтсез, үле иде.

— Бүтән күрмәссез... котыласыз...

Хәят, акырып елап, аның муенына барып асылынды.

— Улым! Китмә, ташлама безне!

Рашат, башын югары күтәреп, тыны беткән кешедәй, түшәмгә төбәлде, йөзе ачы әйбер капкандай җыерылды, муен төене йоткандагы кебек хәрәкәтләнде. Ул шул хәлдә шактый торды. Миңзаһит бер сүз дә әйтә алмады, ул сындай тораташ каткан иде. Ниһаять, Рашат тирән сулап хәл алды, әнисен ике кулы белән үзеннән аерып урындыкка утыртты.

— Кирәкми... Бергә яшәү юк безгә... Йә мин сезне, йә сез мине үтерәчәкбез.

Ул ишеккә таба борылуга, Миңзаһит калтыранган тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кая?! Кая китәсең, у... — Үз гомерендә беренче мәртәбә Рашатка «улым» димәкче булды, әмма теле тыңламады, авызында хәрәкәтсез калды. — Кая китәсең?..

— Әгәр очратсагыз, миңа дәшә күрмәгез. Мине сагалаячаклар...

Тимер ишек дөпелдәп ябылды.

Алар газиз балаларыннан, ниһаять, котылдылар... Күпме вакытлар бергә-бергә дә, аерым да теләгән теләкләре тормышка ашты. Кайчандыр икесенең кайнар йөрәк тибешенең кушылуы, әллә нинди якты өметләр, матур хыяллар белән җир йөзенә китерелгән газиз балаларыннан алар, ниһаять, котылдылар... Күпме гомерләр алар бер генә теләк белән яндылар: котылырга, котылырга иде! Үлсен иде, бетсен иде, мәңгегә бу дөньядан югалсын иде! Менә теләкләре кабул булды, аңардан котылдылар! Кулындагы тугыз бармагы, авызы тулы алтын тешләре, башындагы пеләше белән мәңгегә алардан китте, югалды... Әмма алар бернинди җиңеллек тә тапмадылар. Киресенчә, капкынга ике аягыннан берьюлы эләккән һәм, кычкырсам, килеп тотарлар дип уйлап кычкыра-елый да алмаган мескен җәнлек төсле кара коелып утыра бирделәр. Тимер ишек салкын, хәрәкәтсез, тып-тын иде. Ул инде бу ишекне кабат беркайчан да килеп какмаячактыр. Алар моны ачык тойды, бу тойгы шулкадәр ачы, ул аларның калебләрен, гәүдәләрен генә түгел, өсләрендәге киемнәрен, бүлмәдәге әйберләрне дә көйдерә иде. Ул көек төтене фатирга томан булып җәелде һәм томанның эчендә, бик еракта ике кулына ике кызыл алма тоткан сабый пәйда булды, аның тәмле итеп йоту хәрәкәтләре ясаганы күренде. Алмалар әле исән иде, сабый әле йөри генә башлаган, егылмаска тырышып, өстән ике, астан өч теше чыккан авызын киереп

ачып, шырык-шырык көлә-көлә аларга таба атлый иде. Менә ул дык итеп артына утырды, кулыннан ике алмасы төшеп тәгәрәп юкка чыкты. Сабый үрмәләп алмалар артыннан кереп китте һәм томан эчендә югалды... Нишләптер колак төбендә аның сүзләре генә бертуктаусыз яңгырады да яңгырады:

— Төкелек йотам бит!

— Мин төкелек йотам бит!..

## 8

Мэлсның беркайчан да мондый җиңеллек белән очынып атлаганы юк иде. Ул, язгы һаваны күкрәген тутырып сулый-сулый, гүя урамнан түгел, һавада асылынып торган кабарынкы болытлар арасыннан очып бара. «Нәрсә булды миңа?.. Нәрсә булды миңа?..» Ул борын эченнән акрын гына ниндидер көй көйли башлаганын да сизде. Кызулап ишегалдына кайтып керде, иң элек абзар-сарайларга таба узды. Затлы сигаретын кабызып җибәрде. Борыныннан, авызыннан чыккан төтен аркылы инде шактый түбәнәергә өлгергән кояш әллә нинди сихри шар булып күренде. Алмагач, шомырт, миләш ботаклары арасыннан төшүче нурлар инде шактый шиңәргә өлгергән карны ялыйлар, берничә урыннан боз сөңгеләре асылынган. Әнә берсенең очыннан туктаусыз тамучы көмеш тамчылар иң элек койма башына төшәләр, койма тактасыннан агып, җепсәгә җыелалар, җепсәдән карга каплап куелган тимер бакның төбенә тып-тып тамалар. Карлыган, алма ботакларында инде бөреләрнең шактый зурайганлыгы сизелә, аларның төпләрендәге карлар чокыраеп шиңгән.

Мэлс, ихатага күз йөгертеп, һәр урынын барлап чыкты. Аңа кадәр торган идарә начальнигы сыерын да, сарыгын да тоткан, печән-салам өю өчен биек итеп урынын да ясаган. Алар хәзер һәммәсе дә буш, ихатада тавык белән күркәдән башка җан иясе юк. Өй зур, астында подвалы гына да тулы бер өй кадәр. Салкын суы, кайнар суы краннан агып тора. Мунчасы да шунда, бөтенесенә газ кергән. Бер уйласаң, боларны ташлап китәрлек тә түгел. Тукта, каян башына килде соң әле бу уй? Мэлсның беркайчан да китү дигән нәрсә күңеленә килгәне юк иде. Димәк, ул иң яшерен почмакта тавыш бирмичә генә яткан. Ә нишләп ташларга тиеш соң ул бу йортны, бу ихаталарны? Бәлкем, пенсиягә чыккач, биредә калып булыр? Юктыр кебек. Ул бит монда кадак та какмады. Менә бу буш торучы сарайларның берсен дә сүтеп ташларга да уйламады. Аларның Мэлсны тарту көче дә, этү

көче дә юк, ахрысы. Үзләре чит-ят та түгел. Ә шулай да Баллы Төбәк күз алдында тора. Күрәсең, җир дигәне шулай тартадыр. Быел кыш көне әнисен ике мәртәбә кунакка алып килеп карады Мэлс. Ниләр генә кыланмадылар Нәфисә белән. Аңа ярау өчен килен кеше ниләр генә пешермәде, ничекләр генә итеп мунча кертмәде, кайларга гына алып бармады. Юк шул, әниләре барыбер өч-дүрт көннән ары тормады. Кыбырсып, туктаусыз шаярып торучы бала тез өстендә озак тормыйча шуып төшеп йөгергән кебек, ул да Баллы Төбәккә ашкынды. Мэлс әллә дулкынланудан тәмәкесен тирән суырды һәм ютәлләп җибәрде. Ютәлләвенә ишегалдында йөрүче ата күркә голдыр-голдыр килеп җавап бирде. Ул, борын өстеннән асылынып төшкән кызыл кикриген селкетә-селкетә, канаты белән карны хәтәр ышкытып, үзенә генә хас тавышлар чыгарып, Мэлска якынлашты. Аны тагын голгырдату өчен, Мэлс җиңелчә генә сызгырып куйды. Күркә җавап бирде. Ләкин ул кабат аңа таба килмәде, читкә борылды. Мэлс сызгыра-сызгыра аны үртәргә кереште, үзе күз чите белән генә ике як күршенең ишегалдын күзәтеп алды. Янәсе, күркә белән үртәшкәнен күрмиләрме? Алар бит аңа бик олы начальник итеп карарга, әтисенең исеме белән дәшәргә, баш иеп сәлам бирергә өйрәнгәннәр. Ә ни өчен Мэлска күркәне үртәргә, аның белән шаярырга ярамый? Нәфисә курка күркәдән. Ул аны таламый да, тик чыгу белән, кырына килеп, пошкырган кебек хәтәр тавышлар чыгара-чыгара озатып йөри, үзенчә эзәрлекли.

Мэлс бәрәңге бакчасындагы карның инде шактый кимүен, урыны-урыны белән көздән калган түмгәкләрнең каралып башлары чыгуын күргәч көлемсерәп куйды. Нәфисәне, киләсе ялда һичшиксез чаңгыда йөрергә чыгабыз, дип өметләндерә торгач, озын кыш та узып киткән икән. Бу карлар киләсе елга кайтмаслар инде. Исән-имин озын җәйләрне уздырып, алтын көзләрне озатып, яңа карларны күрергә, алар өстенә Нәфисә белән парлашып чаңгыда басарга язсын. Хатыны бирегә килгәч нык үзгәрде, ул һәр көн зарядка ясый, кичләрен, буйсындыра алса, Мэлсны да һавада йөрергә алып чыга, әллә нинди үлән сулары кайната, битләренә маска, буыннарына компресс куя, бик нык карышмаган чакларда, үзенең дәвалау чаралары белән Мэлска да актив һөҗүм оештыра.

— Бүген ял көне, төшкә кадәр генә эшлим, дигән идең, сүзеңдә тордың.

Нәфисә аны әлеге сүзләр белән елмаеп каршылады һәм әле генә мунчадан чыккан кып-кызыл йөзе белән сәгатькә ишарәләде. Сәгать дүрт тулып киткән иде.

— Шифалы пар белән, карчык, — диде Мэлс, ихлас күңелдән.

— Рәхмәт.

Нәфисә бөтнек, мәтрүшкә исләре белән бөтен өйне тутырган чәен чынаякка агыза башлады һәм Мэлска:

— Сиңа да ясыйммы? — диде.

— Миңа каты итеп тегенди чәй яса әле.

— Йөрәгеңә ярамый ич. Хәзер мунчага барасың бар. Ясыйм шушыны гына.

— Ярый алайса, — диде Мэлс, килешеп.

Бөтнек тәмен бик өнәмәсә дә, хатынының сүзенә каршы килмәде, ризалашты. Ул әчкелтем чәйне бер мәртәбә йотты да туктап калды. Аннары ике калак чумырып алып шикәр комы салды. Моны күргәч, Нәфисә аның кулыннан эләктерергә теләгәндәй талпынып куйды һәм өстәлдәге кечкенә савытларга тутырылган хөрмә, йөзем, кара җимеш, өрек, әстерхан чикләвекләрен аңа этеп-этеп куйды.

— Нигә син шушыларны капмыйсың? Шикәр бит ул диабетка китерә торган әйбер. Соңгы вакытларда суны да күп эчә башладың, — диде Нәфисә, аңа ялварулы караш ташлап.

— Нигә, су җәлкемени? — диде Мэлс, аны үртәп.

Нәфисә җавап бирмәде, кәстрүлдән ботка алып, аның алдына куйды. Мэлс, үлән чәен тагын берничә йотканнан соң, чәнечке белән ботка ашый башлады. Ләкин авызына ике мәртәбә капса да, йота алмыйча шактый вакыт теле белән әвәләп торды. Ботка төче, тозсыз һәм йөземле иде. Ул чәнечке белән йөземнәрен казып чыгарып, өстәлгә төшерергә кереште.

Нәфисәнең кашлары җыерылды:

— Нишлисең инде син, Мэлс?! Аның нәрсәсен актарасың?! Аша да куй инде! Бер дигән витаминлы, югары калорияле ботка. Син бит Болынкырда чакта бер дә сайланмый идең.

Мэлс авыз эченнән генә көлгәндәй итеп куйды:

— Сайланмаганмындыр. Синең ботка эчләренә җимеш тезеп, үлән сулары ясап интектергәнеңне бер дә хәтерләмим мин.

— Әйе шул. Минем ул чакта вакытым булмады, — диде Нәфисә, урындыгын аңа таба шуыштырып. — Без икебез ике якта чаптык. Көне-төне мәктәптә генә түгел, әле лектор да, политинформатор да, стена газетасы редакторы да булырга туры килде. Гомер буе политукуларны да алып бардым. Хәзер үзебез турында кайгыртыр чак җитте.

— Ярар, ашармын мин синең ботканны, — диде Мэлс, чәнечкесе белән һаман алдындагы ботканы болгатып. — Берәр кисәк ит бир әле.

— Бирмим, — диде Нәфисә, урыныннан торып залга таба атлый-атлый. — Кичә генә сөйләштек, сакланам, дидең, итне киметәм, дидең.

Ул үз бүлмәсенә кереп китүгә, Мэлс акрын гына урыныннан торды да коштабак алып верандага чыгып китте. Ул андагы шкафны ачып, ярты кисәк каклаган тозлы казны өйгә алып керде. Аның очлаеп торган иң симез җирен зур итеп кисеп алды да ипи белән умырып ашарга кереште. Шуны гына көткәндәй, бүлмәсеннән Нәфисә килеп чыкты һәм кулларын чәбәкләп җибәрде:

— Әстәгъфирулла! Булсаң да булырсың икән сабырсыз кеше! Үт куыгыңдагы ташың нишли инде?

— Нишләсен, тора, — дип куйды Мэлс, ит һәм ипи белән тулы авызын көчкә ачып.

Аның шулай шап-шоп каз мае ашап утыруына Нәфисәнең җене чыкты.

— Ичмасам, ул корсагыңа карар идең. Йөкле хатыннарныкы кадәр бар бит, — диде ул, ярсып. — Оялмыйча каз күтәкәсе ашап утырасың!

Нәфисәнең шулай акрын гына гаилә көймәсен ызгыш-талаш диңгезенә сөйрәп кертүен белгәнгә күрә, Мэлс шаяру белән котылырга уйлады:

— Соң, күтәкә яраткач нишлим соң инде? — диде ул, каз итен кулында әйләндереп карый-карый. — Менә бит ничек матур булып түгәрәкләнеп тора ул. Ә корсак мәсьәләсенә килгәндә, мин бит чыннан да йөкле. Минем өскә мең төрле, юк, мең генә түгел, санына чыга алмыйм, әллә никадәр эш йөкләнгән. Алар минем башымнан йоклаганда да чыкмыйлар. Хәтта төшләремдә дә күрәм. Үткән айда фуражка киеп эшкә китеп бара идем, тышта егерме дүрт градус салкын. — Мэлс каз итен умырып тешләп алды да аны сузган хәлдә елмаеп Нәфисәгә таба атлады: — Син дә бер кабып кара әле, карчык.

Ләкин Нәфисә аның шаяртканын һаман да аңламады.

— Кит, бүксәңне күрәсем килми! — диде ул, аның күкрәгеннән этеп.

Мэлс стена буендагы трильяж каршына барды да күлмәген күтәрде һәм юри корсагын сыпырып куйды:

— Нигә зур булсын инде бу, нормальный корсак. Ир кешенең шушылай да корсагы булмагач ярыймыни?

Нәфисә җәһәт кенә аның кырына килде дә, чүгәләп, аның бил турына карашын төбәде:

— Кайчан чыкты бу?

— Нәрсә ул? — диде Мэлс, башта берни аңламыйча.

— Менә бит бер сөял.

Аның чыкканына ике-өч ай бар иде инде, Мэлс моны игътибарга алуны кирәк дип тә санамады.

— Кычытамы?

— Үлеш, — диде Мэлс юри.

— Мин чынлап сорыйм. Катымы?

— Катылы-йомшаклы, — диде Мэлс, тагын шаяртып.

Шул арада Нәфисә сузылып ике бармагы белән сөялне капшый башлады.

— Кыйкырт! — дип кычкырып җибәрде Мэлс һәм буш кулы белән җиңелчә генә Нәфисәнең иңбашына төртеп куйды.

Хатыны куркуыннан чүт егылып китмәде, Мэлс аны көчхәл белән тынычландырды, үзенең үлән суларын эчерде.

— Нигә син шулкадәр битараф үзеңнең сәламәтлегеңә? — диде Нәфисә, бераз хәл алгач. — Кайчаннан бирле әйтеп киләм, күзеңне дә күрсәтмисең. Иртәгә үк больницага барасың. Әгәр бармасаң, үзем җитәкләп алып барам. Мондый сөялләр белән шаярырга ярамый.

— И карчык, — диде Мэлс, каз итен чәйни-чәйни. — Бу дөньяда әле беркемнең дә үлми калганы юк. Кемдер иртәрәк, кемдер соңрак. Гел аның турында уйлап торсаң, яшәүнең ни тәме кала? Вакыты җиткәч, ала да китә инде ул.

Шулчак телефон шылтырады.

Трубканы Нәфисә йөгереп барып алды да Мэлска сузды:

— Бухгалтер хатының... — Аның йөзе кара янып чыкты.

Нәфисә читкәрәк китте дә Мэлсны күзәтергә кереште. Иренең йөзе шул мизгел эчендә кояштай балкыган, күзләре очкынланган, кашлары сикергәли иде. Һәрвакыт шулай, әгәр шул хатын шылтыратса, Мэлс алыштырып куйган кебек була һәм моны күрү Нәфисәнең йөрәгенә пычак кадаган кебек тәэсир итә. Ничек шулай булырга мөмкин? Бервакыт Мэлс авырып кырык градус температура белән ята иде. Теге хатын шылтыратуга сикереп тә торды, сау-сәламәт кешегә әверелеп, сөйләшергә дә кереште. Һәм иң гаҗәбе, Нәфисәне шаккатырганы шул булды: ярты сәгать узуга, иренең температурасы утыз алты да алтыга төште, ул, өстәл артына утырып, ике тәүлек ашамаган ризыгын ашады да, чум-чум атлап, эшенә китеп барды. Бу хатынның шылтыратуы Нәфисә өчен йөрәк яралагыч бер вакыйгага әйләнде. Иренең аның белән сөйләшүен карап торудан аның сулышы кысылды, бөтен тәнен кайнар ялкын чорнады, башы таш булып катты. Бу халәттән котыла алмыйча, ул икешәр-өчәр көн җәфаланды. Мэлска бу хакта турыдан-туры әйтергә аның бернинди дә дәлиле юк иде, үзенең дәлилләр эзләмичә дә, түземсезләнеп, иренә күп мәртәбәләр ташланганын хәтер-

ләсә дә, бу очракта нишләптер телен аркылы тешләде. Ул хатынны аның берничә мәртәбә күргәне, яшерен генә көнләшеп күзәткәне булды. Мәдинә (аның исеме шулай иде) җиһанның нинди могҗизалы вакытында яралгандыр да ничек тугандыр, әмма аңа татар хатын-кызларына хас барлык гүзәллекне, барлык ягымлылыкны Ходай мөлдерәмә итеп биргән иде. Таныш-белешләреннән, укытучылардан тыңланып, Нәфисә аның хакында күптөрле мәгълүмат җыйды, әмма бер генә кеше авызыннан да Мәдинәнең абруен төшерерлек сүз ишетмәде. Мондый хатыннар үзләренең чибәрлекләреннән тормышта бик оста файдалана беләләр, ә инде авыл хуҗалыгы идарәсе кебек җаваплы урында баш бухгалтер да булып торгач, Мәдинәгә моны Ходай үзе рөхсәт иткән кебек тоела. Һәм ул тыйнаклык үрнәге булып яши бирде. Алай булгач, нишләп соң ул аңа ял көнне өйгә шылтырата? Нишләп соң ул шылтыраткан саен Мэлс икенче кешегә әверелә? Нәфисә, йөрәгенең чәнчүенә түзә алмыйча, бүлмәсенә кереп дару эчте, тел астына валидол салды. Ул чykканда, Мэлс телефоннан сөйләшеп бетергән, каз итен дә ашап бетергән иде.

— Син бит миңа юри каршы эшлисең, — диде Нәфисә, аңа күзләреннән очкыннар чәчеп. — Дөнья яралганнан бирле сез ирләр безгә карата нинди дә булса начарлык кылуны үзегез өчен мөрәвәт саныйсыз. Гомумән... — Нәфисә, фикере чуалып, бераз тынып торды. — Бүгенге хәлне генә кара. Илне кем шушы хәлгә төшерде? Сез түгелме? Сәясәтчеләр, властьта утыручылар, коррупция, халыкны талау — бөтенесе ирләр эше.

Мэлс аның гасабиланып, әрле-бирле йөрүен астан гына карап утырды, баягы шаярту теләге инде юкка чыккан иде.

Шулай да ул, үзен көчләп булса да, җайлап кына хатынының ярсуын басарга теләде:

— Юкны сөйләмә, карчык, — диде ул, тыныч кына. — Безне сезнең аркада җиргә сөргән Ходай. Ирләрнең иң тәүге шәхси милке — хатын-кыз. Ә җирдә дөнья яралганнан бирле бөтен тарткалаш милек өчен. Дөнья белән милек идарә итә, ирләр түгел. Сез — төп милек, сез идарә итәсез. Патшалар хатыннарына бүләк итү өчен тулаем дәүләтләрне яулаганнар, менә сез кем!

— Майлы кулың белән ул күлмәгеңне ник тотасың инде?! — диде Нәфисә, тавышын күтәреп. — Патша, патша!.. Теш щеткаңны урынына куя алмаган килеш, әйтер идем инде!..

Аның бу сүзләреннән Мэлсның да ачуы чыкты.

— Менә син тагын үз эзеңә төштең, Нәфисә, — диде Мэлс,

бармак селкеп. — Минем һәр хәрәкәтемне, тамак кыруымны, төкерүемне, көлүемне, салган киемемне элү-элмәвемне күзәтеп утыру сиңа ләззәт бирә. Гомер буе хронометраж астындагы җан иясе мин. Дәрестәге укучыларыңны тәрбияләгән кебек, син мине туктаусыз чемчеклисең, кымтырыклыйсың.

— Мин хаксызмыни? — диде Нәфисә, аңа зәһәр караш ташлап.

— Син хаклы, мең мәртәбә хаклы!

— Шулай булгач, үтәве авырмыни?

— Ничек кенә авыр! Өйгә кайтып кергәндә үк, минем эчтә ниндидер җанвар кымшангандай була, ул акрынлап башка күтәрелә, аннары бөтен тәнемә «мин дөрес эшлимме икән?» дигән хафалану тарала. Кул юсаң да, ашарга утырсаң да, телевизор карасаң да, ятсаң да.

— Яткач мин сиңа берни дә әйткәнем юк, — диде Нәфисә, савыт-саба юган җиреннән йөзен аңа таба борып.

— Ничек юк?! Йөрәк ягына ятарга ярамый, дип, син мине күпме битәрлисең?

— Ярамый шул. Кеше күбесенчә чалкан йокларга тиеш.

— Чалкан йокласам, мин гырлыйм. Гырлагач, син китереп төртәсең дә уятасың.

— Җитте, шулкадәр вакланма инде, — дип кычкырды Нәфисә.

— Мин әйткәч, вакланy була, әйеме? Ә син «песине сыпырган кулың белән мине тотасың» дип бәйләнгәндә, вакланy түгел. Кыскасы, щетканы куйган өчен дә, каз күтәкәсе ашаган өчен дә, песине кайчан тотарга икәненә дә үземә җаваплылык алырга рөхсәт ит син миңа. Бөтен җаваплылыкны аңлы рәвештә алырга мөмкинлек бир.

— Әле син аңлап эшлисең икән! — Нәфисә юа торган савытларын шылтыратып табагына ташлады. — Минем түземлегемне юри сыныйсың икән!

— Ә минем түземлекне көне буе астан да, өстән дә сыныйлар, — диде Мэлс та, тәмам кызып. — Өйгә кайткач, дәрт белән син чукырга тотынасың. Мин нишләргә тиеш инде?

— Вакланмаска тиеш.

— Әйе шул, көлеп үләрсең! Әйберсе вак, давылы зур.

— Мэлс, син шуны аңла: мин бит сине шәхес буларак үстерергә телим. Ә син карышасың.

Мэлсның эчендәге шайтан тагын күңел кылларына кагылып алды, ул ике кулы белән, бераз киерелеп, шапы-шопы корсагына суккалады да:

— Бу минем шәхескә керми микәнни? — диде. — Кер-

сә-кермәсә, минем шушы чәбәкләрлек дәрәҗәгә җитүем үзе генә дә синең педагогик чараларыңның нәтиҗәлелеген дәлилли түгелме соң?

Аның беренче шаяртуын ничектер үткәреп җибәрә алган Нәфисә бусында түзә алмады, күзләренә яшь бәреп чыкты.

Еш-еш сулыш алган хәлдә, сүзләрен өзә-өзә:

— Сине җиңеп буламы соң?! Мәңге юкны!.. — диде дә бүлмәсенә кереп китте, эчке яктан келәсен элеп куйганы ишетелде.

Мэлс, аның ишеге янына барып:

— Йә инде, карчык, шаярттым гына бит, — дип куйды.

Эчтән тавыш-тын ишетелмәде. Мондый чакларда Мэлс аңардан гафу үтенә, хатыны хаклымы-хаксызмы, аңа ниндидер яхшылык эшләргә тырыша, үзен хаклы санаса да, ачу-үпкәсен йотып җибәрә, җыеп кына әйткәндә, аны көйләргә, кәефен күтәрергә тырыша иде. Ә менә хәзер ул өстәл янына барып утырды да бер нәрсәгә хәйран калды: гафу да үтенәсе килмәде, аны көйләргә дә теләмәде, гомумән, үз гомерендә беренче мәртәбә хатынының елавын, рәнҗүен җитди кабул итмәде. Гомере буе ул шулай безелдәде, киләчәктә дә шулай булачагын яхшы тоя, әмма әз генә дә күңеле сызланмады, моның белән тулаем килеште, шулай булырга тиеш кебек кабул итте. Төптән уйлап карасаң, монда бәрешерлек, эләгешерлек нәрсә дә юк, күпертә башласаң, тәмам бозылышып, чыгырдан чыгып та бетәргә була. Ә менә Мэлс тып-тыныч утыра. Күрәсең, «син хаксыз, мин хаклы» дип әрепләшүләр узып бара, вакыт дигән нәрсә тормыш арбасын тиешле эзенә төшереп бетереп килә иде. Тып-тыныч кына утырганда, ул шушы нәтиҗәне ясады.

## 9

Алар бүген иртәдән бирле елмайдылар-көлделәр, туктаусыз ашыктылар, кабаландылар, бер-берләренә бәрелделәр, шуңа куанып тагын көлделәр, әледән-әле сәгатьләренә карадылар, мәктәп коридорларының бу кадәр чыр-чуны әле ишеткәне булмагандыр. Ниһаять, алар укытучылары кушуы буенча бер сафка тезелеп бастылар, урамдагы кешеләрнең сәламнәре, котлаулары астында мәдәният сараена юнәлделәр. Әле Болынкыр күгендә мондый кояшның күренгәне булмагандыр. Ул яктыртып, җылытып кына калмый, әллә нинди көлтә-көлтә куе нурлар булып, аларның өсләренә иңә, һәммәсен коендыра, дөньяны гарык итә. Аларның артыннан мәдәният сарае эченә күпсанлы кунаклар, дуслары, әти-әниләре кереп тулды. Бер-берсеннән еракта утырсалар да, Ирек

белән Сөембикәнең уйлары гел Айгөл тирәсендә бөтерелде. Алар аның өчен чиксез куандылар, шул ук вакытта түземсезләнеп кызларының өлгергәнлек аттестаты алуын, чыгыш ясавын дулкынланып, хафаланып көттеләр.

Айгөл әнисе турында да, әтисе турында да уйлый алмады. Ул, гомумән, уйлау сәләтен югалтты кебек. Иртәдән бирле аның күз алдында елмаюлы йөзләр, бик күп булып чәчәкләр биеште, колагы бары тик шатлык авазлары гына ишетте. Зал шулкадәр якты, матур иде, тыштагы кояш, аларга ияреп, аның эченә үк кергәндәй тоелды. Сәхнә читеннән яшеренеп кенә залга күз ташлаганда, ул әнисен дә, әтисен дә күргәч, җиңел итеп сулап куйды. Шуның белән, ахрысы, күңеле тынычланды, ул аларны онытты, шундук каядыр очты. Кайсыдыр бер мизгелдә күңеленең түреннән Таһир яктырып үткәндәй булды. Аннары ул да юкка чыкты, бөтенесен бергә берләштергән сихри төш башланды. Ул төш аның тормышын инде күптән хыялланган якты юлга алып кереп китәчәк, Айгөл бүген шуңа хокук алачак. Ул бүгеннән бөтен кешегә сүзсез буйсынучы мәктәп баласы булудан туктаячак, өлкәннәр кебек бер дәрәҗәдә, тигез булачак. Юк, алай гына түгел, ул киләчәктә иксез-чиксез биеклекләргә күтәреләчәк, бик тә, бик тә озак яшәячәк, әллә нинди игелекле эшләр кылып, дөньяны таң калдырачак...

Айгөл үзенең игътибарын, уйларын, күз карашын бер генә минутка да аерым нәрсәгә юнәлтә алмады. Ул кемнәр беләндер нидер сөйләште, кемнәрдер аны үптеләр, кулларын кыстылар, ул үзе шулай ук кемнәрнедер кочты, үбеп алды, котлады. Өлгергәнлек аттестаты алырга үзен чакыргач, ул калтыранып китте, мәктәп директоры каршына күкрәгенә кайнар сулышы тулган хәлдә талпынып килеп чыкты, аттестатны тирләгән бармаклары белән тотканда, аны шудырып төшереп җибәрде, әмма ни гаҗәп, ничек аңарда шундый өлгерлек туды — аны идәнгә төшкәнче, очып барган кошны эләктергәндәй, үзе үк тотып та алды. Урта мәктәп тәмамлаучы егет-кызларны район хакимияте башлыгы Әхнәф Шәрифуллин котлады. Аның артыннан тагын бер-бер артлы кемнәрдер сәхнәгә күтәрелде. Үзенә сүз биргәч, Айгөл аякларының идәнгә басканын сизмәде, әйтерсең лә ул трибунага очып кына менде. Ул һава җитмәүдән, тамак төбенә килеп утырган кайнар төенне кузгата алмаудан башта гаҗиз булып тын калды. Кинәт бөтен гәүдәсен, һәр күзәнәген ниндидер кайнар, ләззәтле дулкын өтте һәм, ул шуңа буйсынып, ашкынып сөйләргә кереште, аның сүзен бүлеп, зал әллә ничә тапкыр күтәрелеп кул чапты. Менә ул укытучыларына рәхмәт әйтергә теләде, аларның исем-фамилияләрен атый

башлауга, гел көтелмәгән хәл булды, дулкынланудан күзләренә яшь тыгылды һәм ул туктап калды. Зал да, аның халәтен күреп, тын алудан туктады, анда утыручыларның да күзләренә яшь тыгылды. Бу мизгел үтеп, укытучыларны котлагач, Айгөлнең күзе әнисенә төште.

— Мине тәрбияләп үстергән, тормыш күгендә очарлык нык канатлар биргән...

Дулкынланудан аның тагын күкрәге кысылды. Кызыннан бер генә секундка да күзен алмаган Ирек бөтен гәүдәсенә кайнар тир бәреп чыгуын тойды, сулышы ярты юлда туктап калды, әйтерме ул аның исемен, юкмы? Бу мизгелдә Сөембикә дә тынсыз-өнсез иде... Ул кызының әтисенең исемен әйтүен теләде, берүк калдырмасын иде, дип эченнән кабатлады, кайнар битләрен, шул уен кызына җиткерергә теләгәндәй, ике кулы белән кысты.

— Әтием белән әниемә мин чиксез рәхмәтле, — диде Айгөл.

Ул тагын ниләрдер сөйләде, әмма Ирек тә, Сөембикә дә аның башка сүзләрен әллә тыңладылар, әллә юк. Алар өчен баягы әнә шул кадерле сүз генә кирәк иде, мөлдерәп тулган күңелләренә шул иң кадерле, иң татлы, иң кайнар бер тамчы җитми иде. Аларның бөтен газаплы тормышын сыйдырган, фаҗигале язмышларының зәһәр ачысын үзенә алган бу бер тамчы күңелләрне язгы судай ташытып җибәрде...

Айгөл әйбәт чыгыш ясадым микән дип борчылмады, башкаларны да тыңлый алмады, бу сихри төшнең, бу шатлыкның өзелмәвен, мөмкин кадәр озаграк дәвам итүен генә теләде. Соңыннан, котлаулар беткәч, әнисе белән әтисе чәчәк бәйләмнәре сузып аның каршына килгәч, ул аларның икесен берьюлы кочаклап алды һәм, әллә нинди шатлыклы да, сагышлы да тойгының буып алуына түзә алмыйча, тавышсыз гына елап җибәрде...

Татлы бу төшнең азагы Ык буендагы әрәмәлектә дәвам итте. Гүя аларның бәйрәменә ямь өстәргә теләп, яр буеннан башланган әрәмә, ун-унбиш адым читкә китүгә, ике якка аерылып, бер кечкенә генә күлгә урын биргән. Аларның Ык буена төшәсе урын алдан билгеләнгән иде. Шуңа күрә әрәмәгә килеп җиткәндә, әйләнәсен су эчендә үсүче эре ак чәчәкләр такыядай бизәгән күл буенда ак күлмәк, ак чалбар кигән Таһир аны колач җәеп каршы алды. Серле төшне инде ул Таһир белән янәшә дәвам итте. Ә бу төшнең әле бер, әле икенче күренеше алышынып тора, Ык өстеннән йөздереп, классташлары арасында Таһир белән бергә кояшка таба алып бара иде...

Айгөл, арттан килеп, Таһирның иңбашына кулларын сал-

ды, яңагын аның яңагына терәде. «Йа Аллам, — дип уйлады ул эченнән. — Моңа кадәр бу гүзәллекне мин нишләп күрмәдем икән?!» Шомырт, балан, карама, тал, элмә куакларының ялтыравыклы яшел яфраклары арасына яшеренгән мең төрле кошларның мең төрле җырлары сузып-сузып та, чут-чут итеп тә алсу таң нурларына кушылып, бөтен һавага тарала, Ыкның шул ук таң нурларын үзенә алган пыяладай өслегенә иңә, су өстеннән акрын гына шуышучы сыек томан пәрдәсеннән саркып, аның эченә тула, судан ялкау гына агучы эреле-ваклы күбекләргә дә кагыла кебек. Каршыдагы кызыл текә яр өстендә, әллә шушы кошлар җырын ишетергә теләүдән, әллә җиһанның уянуына исәреп утыручы мәгърур имәннәрне, каеннарны нигә моңа кадәр бер генә мәртәбә дә килеп күрмәде икән соң Айгөл?! Әллә соң болар бөтенесе дә чыннан да сихри, гүзәл төш кенәме? Аның шул уйларына җавап биргәндәй, төнбоекларның ак, сары чәчәкләре, сылу буйлы яшел күрәннәр аңа серле итеп елмайдылар. Айгөл, җем-җем итеп торучы чык бөртекләре кунган үләннәр, тукранбашлар, меңьяфраклар һәм ромашкалар уртасында сикергәләп, аларга кул болгады, чырык-чырык көлде, ниләрдер кычкырды, тик аның тавышларын кош сайраулары барыбер күмеп китте. Алар җитәкләшеп тагын күл янына киттеләр. Түгәрәк күл аларның килүен күптән көткән, әгәр шулай булмаса, ул эре ак чәчәкләрен такыя итеп әйләндереп салмас иде. Хәзер аның суы алсуга манылган, күлгә нишләптер томан төшмәгән, ә менә бераз арырак сузылган үзәнлекне ап-ак томан диңгезе каплаган. Ул томанның артында ялгыз өянке кучкылланып күренә, аның да өске ябалдашлары гына шәйләнә, кәүсәсе томан эченә баскан да шунда туктап калган. Битләргә әллә нинди рәхәт дулкын кагыла. Тәннәргә җылы, йомшак аккош мамыгы белән сакланып кына сыпыргандай, җәйге һаваның кыяр-кыймас кына кагылуы сизелә. Оялчан икән җәйге таң, бөтенесе белән килешеп, бөтенесен үз кочагына сыендырып, тын гына, сабыр гына татлы йокымсыравын дәвам итә...

Йә бер Аллам! Болар һәммәсе бер төштер, бөтенесе тыптын, бөтенесе һаваны тетрәтеп җырлый, бөтенесе серле томан белән өретелгән, шул ук вакытта бөтенесе аермачык чатнап торган сызыклары белән яп-якты булып күренәләр, күңелгә кереп, кайнар дулкындай уйныйлар, гәүдәне җирдән аерып күтәрәләр, күз күрмәгән, колак ишетмәгән хыялый ераклыкларга, өмет нуры белән балкучы серле офыкларга әйдиләр. Алар бөтенесе дә Айгөл белән Таһирныкы. Боларның бөтенесенең хуҗасы — алар икесе. Юк, магнитофон, гармун, гитара тавышларына бу гүзәллекләрнең берсен дә алыштырып

булмый. Бөтенесе шушы табигать дигән бөек дөньяның уртасында бөтерелеп биилә р, җырлыйлар, хыялларында очалар. Алар гына түгел, Айгөл ал нурларга манылган очсыз-кырыйсыз җиһанның сулыш алганын, җырлаганын сизде. Әйе, әйе, ул илаһи җиһан, кошлар җырына кушылып, тантаналы моң сузды, аларның аяк астында чайкалып торучы хәтфәдәй яшел келәм белән бергә чайкалды, аларны алкышлап торучы яшел куаклар, җырчы сандугачлар белән бергә алкышлады, бергә мәңгелек көй сузды.

Ничек тиз үткән вакыт! Алар Таһирның «Шевроле» машинасында капка төпләренә кайтып туктаганда, сәгать иртәнге алтынчы ярты иде. Айгөл арткы утыргычтан ридикюлен, чәчәкләрен алды да Таһирга ялварулы караш ташлады.

— Таһир, әйдә иртәгә. Бүген кермә син безгә.

Таһир бер сүз дә дәшмәде, аны култыклагандай итеп, капкага сөйрәде.

— Керәбез, Айгөл, керәбез.

Ишекне ачуга, тәмле булып борыннарына камыр, май исе килеп бәрелде. Сөембикә кече якта кыстыбый бөкләп маташа иде. Ул атылып аларның каршысына чыкты, кочагына күтәргән чәчәкләре арасыннан елмаеп карап торган кызын тагын бер мәртәбә күкрәгенә кысты.

Чәчәкләрне кулына алып:

— Әйдәгез, түрдән узыгыз, — диде.

Айгөл белән Таһир зал ягына кереп киттеләр, ә Сөембикә кыстыбыен бөкләп бетерергә ашыкты. Ләкин аның төне буе куаныч белән типкән, татлы сулкылдау белән кызын көткән йөрәге әз генә вакытка туктап калгандай булды. Туктале, диде ул үз-үзенә, нишләп соң әле ул аны иярткән? Ничек соң әле ул бирегә килеп керә ала? Бер карасаң, монда искитәрлек әйбер дә юк кебек. Икенче карасаң, бу һич тә башка сыймый иде. Дөрес, Сөембикә белән Ирек бергә яшәгән чакта, Таһир белән Айгөл гел аралаштылар, әмма инде ул заманнар бик еракта калды. Фәһимәләрнең малае Казанда укый. Айгөл бүген генә аттестат алды, кайда ничек очрашканнар алар? Ул арада Айгөл аның янына йөгереп килеп җитте, майлаган кыстыбыйларны өстәлгә куйды, чәчәкләрне вазага утыртты, ашау-эчү кирәк-яракларын тезде, үзе нәрсәләрдер сөйләнде. Сөембикәгә ул ничектер үзгәргән кебек тоелды. Төне буе йөреп бәйрәм иткәннәрдер, әллә соң ул эчкәнме дип шомланып уйлап куйды һәм җаен китереп тә, китермичә дә кызына якынаеп, аны иснәштереп алды. Юк, Айгөлдән бернинди дә аракы исе килми иде. Ул арада икәүләп өстәл янына утырдылар. Айгөл сикергәләп аттестатын

алып чыкты, аны мактый-мактый, озаклап карадылар. Шулчак Сөембикә Таһирның ак күлмәк якасына тигән помада эзенә игътибар итте. Бу инде нәрсәнеңдер ул теләмәгән якка киткәнлеге турында искәртә иде. Алар үбешкәннәр дигән уй йөгереп үтте Сөембикәнең күңеленнән. Ул Айгөлнең иреннәренә игътибар белән карады, аның помадасы йокмаган, бозылмаган, чатнап тора. Димәк, ул аны әле генә салган. Бу уйлардан чәй ясарга дип үрелгән Сөембикәнең кулындагы чәйнеге чак кына төшеп китмәде.

— Син утырып кына тор, әнием, — диде Айгөл, аның кулыннан чәйнекне алып. — Үзем ясыйм.

Ул сөтләп чәй ясады, әле Сөембикәне, әле Таһирны ашарга кыстады. Таһир кыстыбыйны умырып кабып, мактый-мактый ашады. Сөембикә аны астан гына күзәтте, ул әнисе кебек чибәр, чем-кара чәчләре бераз бөдрәләнеп тора, калын кашлары, тыныч карауы зәңгәр күзләре Әхнәфне хәтерләтә. Кызыл юка иреннәре Фәһимәнекенә тартым. Кыенсынмый, иртүк килеп кергән, ул әнисеннән өзелеп төшкән булырга тиеш, дип уйлады Сөембикә, күзләрен Таһирның туры карашыннан яшереп. Аңа алардан нидер сораштырырга кирәк иде, теле әйләнмәде, карашы һаман Таһирның якасындагы помада эзеннән китмәде. Аңа караган саен, сиздерми генә эченә ниндидер салкын төшә барды. Әгәр алар үбешкәннәр икән, бу инде һич тә әйбәт билге түгел. Бу хакта уйлагач, Сөембикәнең йөрәге ачытып куйгандай булды, куллары калтыранып китте. Ул, үзенең борчылуын сиздермәскә теләп, урыныннан сикереп торды.

— Хөрмә алып керергә оныткманмын икән, — диде дә верандага чыгып китте.

— Таһир, сизәсеңме, әни борчыла башлады, — диде Айгөл, пышылдап. — Әйдә, бүгенгә калдырып торабыз.

— Юк, Айгөл, юк! — дип кырт кисте аны Таһир.

Ул арада Сөембикә кереп хөрмә җимеше юды һәм аны алып килеп өстәлдәге бәллүр савытка сала башлады. Таһир сиздермичә генә өстәл астыннан Айгөлнең аягына баскаларга кереште. Айгөл кып-кызыл булды, Таһирга карады, ә аның күз карашы ялварулы да, кисәтүле дә, кырыс та иде. Айгөл, башын аска игәннән-ия барып, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Әни... Без... Таһир белән бергә булабыз инде... — диде.

Башына сукканны көткәндәй, ул күзләрен йомды, тын алудан туктады. Кичә көндездән бирле дәвам иткән тылсымлы әкият дөньясы, татлы төш шушы урында өзелде. Сөембикә берәмләп салып маташкан җимешләрнең өстәлгә

чәчелеп китүен сизми дә калды. Ул хәлсезләнеп урындыгына утырды.

— Аңламадым, — диде, көч-хәл белән телен әйләндереп.

Айгөл аңа карарга курыкты, башын тагын да ныграк аска иде.

— Без бергә яшәргә ниятләдек...

— Кайда яшәргә?

Чыннан да, кайда яшәргә? Айгөлнең бөтенләй башы әйләнеп китте. Әнисенең бу соравы сискәндергеч төстә төгәл җавап сорый иде.

— Өйләнешеп... — диде ул, алдагы фикерен дәвам итеп. — Яши башлыйбыз.

Соңгы ике сүздән соң Сөембикәнең инде икеләнер урыны калмаган иде. Ул барысын да аңлап бетерде, әмма моны күңеле кабул итәргә теләмәде.

— Кем белә-ә-ән?! — диде ул, әллә нинди ят, елак тавыш белән сузып.

Күпме генә күрергә тырышса да, кызы күзләрен яшергән иде, ул аның дерелдәп куйган озын керфекләрен генә күрә алды. Ул керфекләрнең дерелдәве йөрәгенә килеп кадалган очлы энәләр кебек тәэсир иттеләр.

— Кем белән, дип сорыйм?!

Айгөл, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Таһир... — дип кенә куя алды.

Сөембикә, ник икәнен дә сизмәстән, ялт итеп Таһирга башын борды. Ул да авызына капкан җимешен чәйни алмыйча хәрәкәтсез утыра иде. Сөембикәнең җан өшеткеч карашы астында күзләрен ачып шактый торганнан соң, түземлеге җитмичә, керфекләрен аска төшерде.

— Ә миңа ник әйтәсең? — диде Сөембикә, кабат кызына борылып.

Айгөл, курка-курка гына керфекләрен күтәреп, аңа астан кыюсыз караш ташлады:

— Син бит минем әнием...

Сөембикә, сикереп торып, калтыранган куллары белән өстәлгә таянды да Айгөлгә таба иелде:

— Мин сиңа кайчаннан әни соң? — дип пышылдады.

Айгөлнең иреннәре калтырап китте, күзләре түгәрәкләнде, ул бер сүз дә әйтә алмады. Сөембикәнең ике чигәсе пычак белән сызгандай сыкрарга кереште. Аны кызының әйткән хәбәре ул кадәр таң калдырмады, иң хәтәре аның моңа кадәр яшерен уй белән йөрүендә иде. Сөембикәгә әле Айгөлнең кияүгә чыгу-чыкмау мәсьәләсе әллә кайда офык артында дөбердәгән яшенле яңгыр авазы кебек кенә иде. Ә менә хәзер ясаган шушы беренче адымы... аның белән бернинди

киңәшмичә... бу аның башына берничек тә сыймады. Аның инде куллары гына түгел, бөтен тәне калтырый башлаган иде.

Ул, һәр сүзенә басым ясап, тагын бая әйткәннәрен кабатлады:

— Кайчаннан мин сиңа әни, дип сорыйм?! Җавап бир!

Әнисенең куркыныч йөзеннән карашын читкә алып, Айгөл, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Туганнан бирле... — диде.

— Шула-а-аймыни?! — дип сузды Сөембикә. — Менә бит ничек икән! Мин ник кирәк соң сиңа?!

Айгөлнең йөрәге каядыр төшеп китеп, күңеленә салкын елан шуышып килеп кергәндәй булды. «Ник әйттем?! Ник әйттем?!» дип өзгәләнде ул эченнән. Үзен тыңламаганы өчен ачу белән Таһирга карап алды, тик хәзер соң иде инде.

— Ник элек әйтмәдең?!

— Ул чакта... мин бит әле... өлгермәгән идем...

— Ә-ә-ә, аңлашылды! — дип сузды Сөембикә. — Менә бу катыргыны алып кайткач, өлгердең, шулаймы?

Айгөл дәшмәде.

— Мин гомерем буе синең өчен яшәдем, синнән берни яшермәдем. Ә син әллә кайчаннан үзеңчә яшәгәнсең, киңәшер өчен мине кешегә дә санамагансың!

Күзләре яшь белән мөлдерәп тулган Айгөл кычкырып елап җибәрде һәм әнисен кочаклап алды.

— Алай түгел, әни, алай түгел!

Сөембикә аның кулларын үзенең муеныннан каерып алды:

— Син бу сүзләреңне аңлап әйттеңме?

Айгөл әнисенә җавап бирә алмады, ул инде кычкырып ук елый башлаган иде.

Таһир, сикереп торып, аны юатырга кереште, үзе, Сөембикәнең күзләренә карап:

— Без барысын да уйладык, — диде. — Хәзер инде кирегә юл юк. Без бу көнне сәгатьләп санап көттек. Карар озак уйлап кабул ителде...

Сөембикәнең аның яңагына чабып җибәрәсе килде. Ул тешләрен кысып сабыр итәргә тырышты, кулларын йодрыклаган хәлдә, зал ягыннан урап килде. Ничектер тынычлангандай булды, кулларын күкрәк янына кушырды да, башын артка ташлап, аларның икесенә дә мыскыллы карашын юнәлтте:

— Карар кабул иткәч, барыгыз, яшәгез! Минем кирәк юк бит сезгә. Рәхмәт, бик тиз мөстәкыйль тормыш юлына баскансыз. — Ул Таһирның йөрәгенә тиярдәй сүз эзләде, әмма таба алмады. Кинәт зиһене яктырып киткәндәй булды: — Әтиеңнең халыкныкын талап җыйган малы күп бит, яшәгез!

Таһирның бөтен гәүдәсе чыбыркы белән сыдыргандай тартышып куйды, ул нидер әйтмәкче булды, ләкин әйтә алмады, ахырда ишеккә ташланды, аңа елый-елый Айгөл иярде.

Сөембикә урындыгына утырды да, терсәкләре белән өстәлгә таянып, ике кулы белән башын учлады. Шул хәлдә ул күпме утыргандыр, Айгөлнең дәшүенә генә сискәнеп күзләрен ачты.

— Әни, нигә инде син шундый сүз әйттең? — диде ул, тавышсыз үксеп.

— Хәзер миңа сүз әйтергә дә ярамый икән, — диде Сөембикә, — битараф тавыш белән һәм акрын гына урыныннан күтәрелде. — Ә сиңа менә ничек яраласаң да ярый! Йөрәге ярылыр дип тә уйламагансың...

— Мин бүген теләмәгән идем дә... ул мәҗбүр итте... — диде Айгөл. — Бөтен гаеп миндә. Менә хәзер, үтерсәң дә, син хаклы. Тик... мин аны ташлый алмыйм... Мин аңардан башка яши алмыйм!

Айгөл шулай диде дә кызулап бүлмәсенә кереп китте һәм диванга ауды. Сөембикә исерек кеше хәлендә иде. Кая барырга? Кемгә эчен бушатырга да кем белән киңәшергә? Ни аяныч, аның андый кешесе юк иде. Ул салкын су белән юынды, чәчләрен төзәтте, иренен кызартты, керфекләренә сөрмә тартты. Телефоннан Чукаеваның номерын җыйды, тик ул җавап бирмәде. Сәгатенә күз төшергәч, кискен карарга килде: Мөнир Кәбиров янына барып кайтырга. Мөнир абыйсы, Казанга барып дәваланып кайтканнан соң, җир җимертеп яшәп ята, теге вакытта төшенкелеккә бирелүләре үзен-үзе чираттагы куркыту гына булып чыккан иде. Сөембикә хәзер Болынкырда калса, ниндидер юләрлек эшләячәген бөтен барлыгы белән сизде. Йә кызын кыйнап ташлар, йә дулап Фәһимәләргә барып керер. Хәзергә болар берсе дә кирәк түгел, ничек булса да суыну ягын карарга кирәк иде.

## 10

Сөембикә, эссе, бөркү автобустан төшкәч, җиңел сулап куйды. Таңтугайга моннан нибары бер чакрым ара, инде элекке юллар-сукмакларны үлән басып киткән. Болын һавасы аның тирләгән йөзен, муенын, бөтен тәнен рәхәтләндерде. Бөтен дөньяны аксыл пәрдә булып томан сарган, чокырсу урыннарга ул ак аттай җайлап бөкләнеп яткан, биек булып утыручы кәҗә сакаллары, балтырганнар, шома көпшәләр, ат кузгалаклары, хан үләннәре сөттәй сыеклык белән нурланган

бу дөньяда күпсанлы кәҗә көтүенең өскә тырпайган мөгезләредәй каралып торалар. Сөембикә, авылга таба атлаган саен, үләннәрнең, чәчәкләрнең балтырларыннан йомшак кына сөюләрен, кагылуларын тойды, серле пышылдауларын ишетте... Гүя алар аңа балачак иленнән тавышсыз гына сәлам бирделәр. Кошлар тавышы да, бу сихри томанның серле тынлыгы да аларның сәламенә комачауламады, киресенчә, куәт кенә бирде. Бу гаҗәеп, гаҗәеп һәм тирән, тирән һәм серле, серле һәм моңсу, моңсу һәм үтә дә ерак, үтә дә ерак һәм шулкадәр дә якын балачак, яшьлек тойгысы аны әсир иткән, үзенә алган иде инде... Ул бөтенләй җиңеләеп калды. Еракtагы ялгыз карама, урман ниндидер коточкыч зур, ерак, серләр тулы дөнья булып үзенә чакыра. Тирә-юнь бал исеннән, мең төрле үлән, чәчәк исеннән гарык булып утыра, җир белән күкне күренер-күренмәс пәрдә тоташтырган, кояш та әле күзләрен ачарга иренеп-иркәләнеп ятучы сабыйдай уянып бетмәгән, бөтенесе хәрәкәтсез, кошлар тавышына оеп, изрәп утыра... Берни дә аңлашылмый, кошлар түгел, томанлы шушы серле дөнья үзе тоташ бер җан булып сайрый, ахрысы... Бөтенесе бер аһәңдә, кайнар иген басуы өстендәге рәшәдәй тетрәп тора. Тик бу рәшә һава дулкыны түгел, тирә-юньгә кошлар җырыннан тарала...

Сайрагыз, кошлар, сайрагыз, үләннәр, сайрагыз, яфраклар! Сайра, таныш тугай, сайра, төпсез күл урыны... Бөтенегез бер булып, Сөембикәнең кайнар йөрәген соңгы мәртәбә сынагыз, бәгырен өзегез! Түзә алырмы ул бу кадәр кичерешләргә, әзрәк хәле калганмы аның бу җырларны күтәрерлек, аларны үзенә алырлык?.. Сез башына ак ромашкалардан кояшны көнләштерерлек итеп такыя үргән, иртәнге чыктан аяклары туңып, итәкләре чыланып беткән кызны сагынып килгәнсездер! Сез бит очлары алсуланып янган, күзләре шашкын дәрт чәчкән кызны, үзе туктаусыз кошларны уздырып җырлаучы, тыела алмыйча көлүче, чыпчыктай туктаусыз чыркылдаучы кызны сагынып килгәнсездер! Менә ул каршыгызда басып тора. Такыялар шиңеп төшкән, чәчләренә чал кунган, күзләрендәге тиле очкыннар сүнгән, йөрәге ярсу газаплардан арынган, тәннәре хәлсезләнгән, аяклары бу чыклы үләннәрне инде күптән оныткан...

Сөембикә, туфлиләрен салып, чыклы үләнгә басты. Йа Аллам! Шул мизгелдә үкчәләреннән баш түбәсенә кадәр ниндидер куәтле нур ага башлады. Аңа кинәт үзе бик таныш та, үзе бик ерак та бөек бер көч канатлары белән сарылды. Ул гына да түгел, әлеге көч аны югары күтәрә башлады. Сөембикә аякларының җирдән ерагаюын тойгандай булды. Ул, башын артка ташлап, йөзен кояшка куйды һәм бернинди хә-

рәкәтсез тынып калды... Аңа бу дөньяда хәзер берни дә кирәкми иде. Ул бу иксез-чиксез галәмнең иң-иң бәхетле заты иде. Ул саф, гомер яшәп җыелган барлык кайгы-борчулардан, гөнаһ-газаплардан азат алиһә иде. Томанлы аһәң дөньясының саф алиһәсе... Тик нишләптер туктаусыз күз яшьләре генә коела, нинди сихри халәт соң бу? Күзен йомган хәлдә, ул такыя кигән кызның йөгереп килүен күргәндәй булды. Колак төбендә берөзлексез тантаналы моң яңгырый... Нурланып тантаналы моң уйный... Бу мизгелләрдә Сөембикәдән дә бәхетлерәк зат юк иде. Бәхетле генә түгел, ул иң саф зат итеп тойды үзен. Зиһененең җиһан түреннән алып җир куенына кадәр булган очсыз-кырыйсыз киңлекне берьюлы колачлавына, бөтенесенең шулкадәр дә ачык, аңлаешлы булуына хәйран калды. Ул бөек иде, җиһанның бер өлеше иде, аларны бер-берсеннән аеру мөмкин түгел иде. Нигә соң адәм балалары шушы илаһи бөеклектән читкә тайпылалар, гөнаһ диңгезләренә, газап-михнәт дәрьяларына баталар? Сөембикә бабасының «Чын тормыш авылда гына» дигән сүзләренең мәгънәсенә менә хәзер генә төшенде. Адәм баласына, шушы камиллекнең бер өлеше буларак, һичшиксез, аны тагын да ямьләү вазифасы йөкләнгәндер. Ул бу бөек миссияне гомере буе үтәргә тиештер. Илаһи зарурлыктан чыгып караганда, меңнәрчә буыннар бу дөньяны тагын да камилләштергәч, яктырак, нурлырак, җылырак, җырлырак иткәч, кабат кайтып күрергә, үзләре яшәгән чор белән чагыштырырга тиешләрдер...

Сөембикә атларга теләде, әмма аяклары буйсынмады. Ул күзләре белән тирә-юньгә караш ташлады, әмма берсенә дә аерым туктала алмады. Ул каршындагы чәчәкләрнең кайсына да булса кул сузарга, иркәләргә теләде, әмма булдыра алмады, томан да, тантаналы бу аһәң дә — бөтенесе бербөтен, нәрсәнедер аерып ярату мөмкин түгел иде. Ул биредә тоташ бербөтен сөю генә яшәгәнлеген аңлады. Күңелгә бөтенесе якты аһәң булып иңә, күңел шуның белән тулган саен, рухың, вөҗүдең белән һаман югарырак күтәреләсең, югарырак күтәрелгән саен, җирдәге кешеләргә тартыласың, аларны да үзең кебек күтәрәсе килүдән, әмма бу теләкне тормышка ашырырга мөмкин түгеллеген аңлаудан күңел сыкрый, аларга карата кызгану хисе көчәйгәннән-көчәя, аларның син аңлаган олы хакыйкатькә төшенә алмаулары өчен көяләнәсең, син күргәннәрне күрә алмаулары, син кичергәннәрне кичерә алмаулары өчен уфтанасың. Аларга шушылар турында әйтеп дәшәсе килә, әмма тавышың чыкмый, чөнки күңелең мөлдерәп тулган... Бары тик татлы бер мәхәббәт уты — аларны чиксез ярату тойгысы, аларга әз генә булса да, берәр генә

булса да яхшылык эшләү тойгысы йөрәгеңне рәхәт итеп яндыра. Йөрәге рәхәт итеп янган кешеләр — җирдә иң бәхетле кешеләр. Йөрәкләре кан-яшь белән янган кешеләр, йөрәкләре таштай каткан, хиссез, салкын кешеләр кебек үк иң бәхетсез кешеләр. Син бер генә нәрсә телисең: кешеләр үзләренә карата булган синең шушы кайнар тойгыларың хакында белсеннәр генә иде! Ә теге билгесез көч сине һаман югарырак күтәрә, күтәрелгән саен, калебең әүлиялар, әнбиялар тынлыгына, җиһан хуҗасы тудырган тынлыкка ныграк чума. Сөембикә бу көчнең үзен бирегә махсус тартканлыгын, аның авылга дип чыгып китүенең очраклы булмаганлыгын аңлады...

Кинәт җил исә башлады, томан хәрәкәткә килде, сыегайды, тора-бара матур төш кебек бөтенесе дә эреп югалды. Кая китте һәммәсе дә? Кайда такыялы кыз? Кайда әле хәзер генә аның күккә күтәрелгән чагы? Ул, күзләрен йомып, кулларын югары күтәрде, талпынды, әмма бөтенесе җиргә төшкән, һәммәсе дә аермачык күренә, аңлаешлы, баягы серле, илһамлы очышның әсәре дә калмаган иде. Аның йөрәге шуны эзләп дөп-дөп типте, әмма ул татлы мизгелләрне томан белән бергә җил ияртеп алып киткән иде... Югыйсә кошлары да баягыдан ныграк сайрый, уйсу урыннарда әле томан да ята, әмма баягы серле дөнья гына югалган иде...

Сөембикә шашынып калды. Аның иң татлы, гомеренең иң ләззәтле чаклары, ач кешенең шикәр тәмен тел очы белән генә тоеп калуыдай, сизелмичә дә үтеп киткәннәр. Адәм баласының тормышы да, гомер иткәндәге ләззәтле чаклары да әнә шулай кыска, серле төш кебек, аңышмый да кала торган икән... Сабый чаклар, чәчәктәй яшьлек инде мәңге кабатланмаячак, аларны гына түгел, әле менә берничә генә минут элек кичергән илаһи халәтне дә кайтарып булмый — ул юк, очты, югалды, йөрәктә татлы сагышы, моңы гына калды...

Аның бөтен барлыгын әллә нинди ут көйдерә башлады. Бу әллә сагыш, әллә үкенеч, әллә бөтенесен бергә берләштергән бүтән бернәрсә иде... Аны бөтенесен мәңге кайтара алмаслык югалту хәсрәте кабызды. Сөембикә, тирән уйга чумып, бик озак хәрәкәтсез басып торды, бөтен ихтыярын туплап, һәр күзәнәге белән сулкылдап, әле генә үзе кичергән саф халәтнең кабат кайтуын теләде, әмма күпме генә тырышса да, сыгылып чыккан кайнар күз яшьләре аша күккә карап тавышсыз аһырса да, халәт кайтмады. Гомер буе аның белән ниндидер көчләр уйнады, ахрысы. Менә хәзер дә нигә кирәк иде аны күтәреп төшерергә? Уйлана торгач, ул әлеге фикеренең хаклыгына тагын да ныграк ышанды: үзе теләгәнне гел дә эшли алмаган икән ул! Нәрсәләрнеңдер мәҗбүр

итүе, китереп кысуы аркасында гына ниндидер гамәлләр кылынган, үзе теләгәнен эшли алмаган. Ә үзе ни теләде соң ул? Тора салып килеп туган бу сораудан Сөембикә өнсез калды. Чыннан да, ни теләде соң ул? Авылдан китәргә теләде. Укырга, кеше булырга, эшкә урнашырга, гаилә корырга. Ул боларның барысына да иреште кебек. Таңтугайдан китеп иреште. Ә шаулап-гөрләп торган авыл юк инде. Бөтенесен уртак анадай туплап яшәгән авыл инде үлгән... Бергәләп бәрәңге утыртулар, бергәләп басуда эшләүләр, авылның картын-яшен туплаган печән, урак өсләре... Фәкыйрьлектән арынмасалар да, кая гына барма, туктаусыз уен-көлке, шаярулар булыр иде. Эштә дә, урамда да, клубта да гел бергә. Сабантуйлар, башка бәйрәмнәр, егетләрне бөтен авыл белән өйдән өйгә ашка чакырып армиягә озатулар, кайтканнарын тагын шулай каршы алулар, кичке уеннарның тальян моңнары, җырлаулар, биюләр, чыр-чу килеп шаярышулар менә бүгенгедәй күз алдында, күңелдә саклана. Ә ул кичке уен вакытларында янган учаклар!.. Әнә теге каеннан ерак та түгел аларның ялкыннары, җәйге күктәге йолдызларга таба сибелгән очкыннары бүгенгедәй күз алдында торалар. Сөембикәләр үзләре дә шул очкыннардай төрлесе төрле якка сибелеп таралыштылар... Язмыш бөтенесен аеры-чөере китерде. Иң элек Фәһимә, аннары Миңнур белән Зәлифә, аларга ияреп, Сөембикә ташлады авылны. Алар артыннан егетләр юкка чыкты. Авылны ташлап киткән Сөембикәләр аны үтерүчеләр дә булып чыгалар түгелме? Авылда яшәүчеләрнең дә барысы да түбән тәгәрәмәде бит. Ул, билгесез, әмма үзен куркыткан ниндидер хәтәр нәрсәгә якыная башлавын тоеп, уйларын читкә куарга теләде. Сөембикә кабаланып чәчәк җыярга кереште, такыя үрә башлады, әмма нияте барып чыкмады. Аны уйлары рәхимсез төстә эзәрлекләде, такыя үрүче кулларыннан өләктереп, һаман үткәнгә сөйрәде... Гел үзе өчен генә пешәләнгән икән шул Сөембикә. «Үземне корбан иттем» дип санаганы да башкалар өчен булмаган. Димәк, гаепне әллә каян эзлисе юк, күпме генә читкә кусаң да, һәммәсе дә үзеңә борыла да кайта...

Гомернең иң кадерле, мәңге онытылмас саф чагы авылда, менә шушы җирләрдә булды аның. Үги әтисе харап иткәнгә кадәр шулай иде. Юк, юк, алай түгел икән. Әле Шәрифулла мәсхәрәләгәч тә, ул югарыда иде, кешеләрнең йөзенә туры карады. Бөтен дөньясын күрә алмаса да, ул өстен, ул хөкем итүче, гаепләүче иде. Ә менә Янчуриннан соң ул әлеге хокуктан мәхрүм калды. Ул чакны Сөембикә яхшы хәтерли. Шуннан соң аңа кылану, үзен мәҗбүр итү кирәк булды. Ул инде үзе түгел иде. Сөембикә бернинди тузан кунмаслык,

тап тимәслек биеклектә тотучы раушандай нәрсә югалтканлыгын аңлады. Тормыштагы урын, эш, яшәүнең тагын бик күп, бик күп Сөембикә атлап узган баскычлары ул раушан каршында кечерәеп юкка чыктылар...

Ул авылның көнбатышындагы җырлы тугайга — үзләренең кечке уен урыннарына, андагы ялгыз каенга таба атлады. Барып җиткәч, Сөембикә исе-акылы китеп туктап калды: каен яртылаш ауган, кызганыч хәлдә иде. Алар әйлән-бәйлән уйнап кичке уеннар корган, бөтен авылның яшьләре җырлап-биеп йөргән каен янындагы тигез чирәмлек юкка чыккан. Аны урман авызыннан төшүче инеш борылып кереп ашап бетергән. Ике метр киңлектәге бу инеш Сөембикәләр бәләкәй чакта ук әллә кайдан, җирнең үзәгенә тишеп керергә теләгәндәй, ун-унбиш метр аста ага иде. Ярлары ике яктан да ишелеп теп-текә булып төшкәнгә күрә, халыкта ул Кәҗә ерганагы дип йөртелә иде. Чөнки бу ярларда кәҗәдән башка берни дә йөри алмады. Әнә шул яр якынаеп, каенны аударырга теләгәндәй, инде астына ук кергән, мескен агачның тамырлары һавада асылынып тора, иң зур ботагы, төптән үк сынып, очы белән ярга кадалган. Аны бөтенләй умырылып төшеп китүдән, күрәсең, шул гына саклый. Кәүсәләрен бүрек-бүрек кара кутырлар каплаган, өрфиядәй юка тузлары ертылып, иске ситсы төсле җилдә җилфердәп тора. Тирәюньне кеше биеклеге кычыткан, әрекмән, әрем, алабута баскан. Бер урында алсу-шәмәхә булып хан үләне чәчәк атып утыра. Аны русча «иван-чай» дип йөртәләр. Әбисенең сөйләве буенча, имеш тә, бер хан йокысызлыктан һәм баш авыртудан газапланган. Аның табибы шушы үләнне һәр көн аңа эчерә торган булган. Күпмедер вакытлардан соң хан үзенең авыруыннан котылган. Менә шуннан соң аны хан үләне дип атый башлаганнар. Алсу-шәмәхә чәчәкләрне бал кортлары сырып алган. Алар очалар да каеннан ерак булмаган юкә кәүсәсендәге тишеккә кереп китәләр. Сөембикә сакланып кына, үләннәргә тотына-тотына аска төште. Биредә салкынча, кызыл балчык исе, су исе, әрекмән, кычыткан, үги ана яфрагы, тагын әллә нинди исләр дымык булып борынны ярып керәләр. Күтәрелеп өскә карауга, Сөембикәнең башы әйләнеп китте! Ул хәйран тамашага тап булды. Каен тамырлары арасыннан зәңгәр күк, анда агып баручы болытлар хыял җитмәс биектә күренәләр. Бер уйлап карасаң, бу һич тә башка сыя торган хәл түгел иде. Әнә шул тамырлар сузылган турларда Сөембикәләр, кичке уенга җыелып, җырлап-биеп йөриләр иде. Нәкъ аның баш очында үзләре яккан учак янгандыр. Ул учактан шарт-шорт килеп кызыл очкыннар сибелә, ялкын телләре әллә кайларга үрли, югары

күтәрелгән сыек төтен аша ай шәүләсе күренә. Ә яшел чирәм өстендә алар туктаусыз бииләр, әйләнәләр, танцы итәләр. Менә шушы тамырлар аша күренеп торган күк йөзедәй, барысы да еракта... Учакларда яшьлек хыяллары да дөрләде. Авыл үзе бик караңгы, үзәк юллардан ерак булса да, Сөембикәләрнең уй-омтылышлары киләчәккә төбәлгән иде. Сүз дә юк, ул теләкләрнең күбесе тормышка ашмады, тик алар бар иде бит. Әнә шунда, өстә генә бөтерелделәр, яндылар, ашкын йөрәкләренә көч бирделәр. Шушы мизгелләрдә Сөембикә сәләмә киемле кызларны-егетләрне, ягъни үзләрен аермачык күргәндәй, ишеткәндәй, тән җылыларын тойгандай булды.

Ул тагын өч-дүрт адым аска төште дә ерганак төбеннән агучы су кырына чүгәләде. Су күп булса кул яссуы тирәнлегендә, төбендәге һәр ком бөртеге, кызыл балчыгындагы һәр сызык аермачык күренә, хәтта ашыгып-бөтерелеп аккан су бөтерчекләренең шәүләсенә кадәр төшә иде. Сөембикә салкын су белән кулларын юды, битләрен сыпырды. Аягүрә торып, уң якка күз ташлады һәм су кырындагы бер түмгәк астында күренеп торган ак әйбергә игътибар итте. Ул, аңа якынрак баргач, сискәнеп китте, тәне чемердәп куйды. Ул ак нәрсә баш сөяге иде! Сөяк кырын ята, аның авыз ягы күренеп тора, теш төпләре шактый каралган, бер урыннан ничәседер төшкән, шул бушлыктан үлән үсеп чыккан. Ниндидер бөҗәкләр очып килеп, әле үләнгә, әле баш сөягенә куналар. Сөембикә, аяк астында яткан бер ботакны алып, башны түмгәк астыннан этеп чыгарды. Менә бу башның кайчандыр эчендә мие булган, бу якты дөньяга караучы күзләре, алсуланып торган йөзе, колаклары булган. Ул да ниндидер өмет-хыяллар белән яшәгәндер, гашыйк булгандыр, гаилә коргандыр, балалар үстергәндер. Кинәт Сөембикәнең балачакта ишеткәннәре хәтеренә төште. Аларның авылында беренче булып колхозны Фәйзрахманның әтисе төзегән. Бер төнне басуларны әйләнеп кайтырга дип киткән җиреннән ул юкка чыккан. Тирә-юньдәге урманнарны, чокырларны, бер җирне дә калдырмыйча эзләгәннәр, әмма файдасы булмаган. Авылдан кулак дип сөрелгән берәү Чиләбе якларында яшәгән. Имеш, шул үләр алдыннан әйтеп калдырган, аның гәүдәсен Кәҗә ерганагы ярыннан эзләгез, дигән. Ә бәлки, ул да түгелдер. Сөембикәләр авылын чирмеш зиратына якын гына урнашкан дип сөйлиләр иде. Ерганакның каенга таба ашап килүе, бәлкем, шуның белән аңлатыладыр да. Менә бу башның инде хисләре дә, уй-тойгылары да юкка чыккан, аны берни дә борчымый. Безнең тормыш та, аның һәр көне, һәр ае, һәр елы, актарып карасаң,

менә шушындый үлгән хисләр, сүнгән өметләр, гәүдәсеннән өзелеп әллә кайларга киткән башлар белән тулыдыр. Сөембикә үз гомерендә ничә мәртәбә үлеп терелде икән? Аның иң беренче үлеме Кәшифулладан соң булды. Беркемне күрәсе килмәде, кулыннан эш төште, йөзеннән нур качты, яшәүнең мәгънәсе калмаган иде. Авылдагы ул чактагы тигезсезлек, Сөембикәләр гаиләсенә кимсетеп карау моны тагын да көчәйтте. Аны үлеп барганда Мөнир абыйсы коткарды. Болынкырга күчеп киткәндә, ул намусы һәм җисеме белән пычракка баткан, хәтта инде моңа күпмедер күнеккән дә иде. Әлбәттә, аны район үзәгендә беркем дә андый дип уйламады, әмма ул ялгыз калган чакларында еш кына ачы сагыш белән елады. Үзеңнән качып булмый иде шул. Болынкырга килү белән, комсомолда эшләүче Әлфия белән дуслашты. Әлфия искиткеч саф, беркатлы, тормыш тарафыннан бозылмаган, егет-җиләннең кулы тиюдән дә коты алынып тора торган кыз иде. Аның белән дус булып йөргәч, Сөембикәгә дә Әлфиягә биргән бәяне бирделәр, ул үзенә какшамаслык абруй яулады. Ләкин сирәк булса да, Шәвәлиев аны үзе белән очрашырга мәҗбүр итте. Аңа карышу мөмкин түгел, чөнки киләчәктә югары күтәрелүе дә, квартира алуы да шуның ярдәмендә хәл ителәчәк иде. Моны Шәвәлиев туктаусыз аның исенә төшереп торды.

Икенче үлеме Ирекка кияүгә чыккан көнне булды. Туй ахырына якынлашкан саен, Сөембикә куырылганнан-куырыла барды. Бу аның өчен үлем сәгатенең якынаюы иде. Хәтта ул бер тәнәфестә йөрәгенә түзә алмыйча, Иректән оялып чыгып йөгерде. Тик ниятен тормышка ашыра алмады, кемдер күреп калган булып чыкты. Аны тотып алып керделәр. Шулай оста итеп шаярткан дип уйладылар. Зөфаф кичендә ничек түзгәндер, Ирек теш арасыннан бер сүз чыгармады. Әгәр ул икенче көнне куып җибәргән булса, бәлкем, Сөембикәнең тормышы башкачарак, гөнаһсызрак юлдан киткән булыр иде...

Өченче үлеме Ирек белән аерылышкач булды. Еллар узар, менә Сөембикәнең баш сөяге шушындый хәлгә төшәр. Дөрес, ул ерганактан агып әллә кайларга тәгәрәп китмәс. Әмма җир астында нәкъ шушылай агарып, күз урыннары баткан килеш, тешләренә, бөтен җиренә балчык тулып ятар. Димәк, кешенең тере чакта һәрбер уе, һәрбер хис-кичереше аңлатып бетерә алмас дәрәҗәдә бөек, илаһи, кабатланмас. Шушы җир йөзендә үзенең тәнендәге җаны белән шатлыкларын, кайгыларын кичерә, савап-гөнаһларын кыла. Аны Ходай шулай итеп яраткан. Җир йөзендәге үз эш-гамәлләре өчен үзе җавап тота. Сөембикәгә дә әнисе өчен, үзе өчен, ире белән баласы өчен үзен корбан итүе җиңел булмады. Һәм

ул хөкемнән качарга да теләми. Баш сөяге аның күз алдында бер караганда, томан пәрдәсенә төренеп юкка чыккандай булды, икенче караганда, һәр сызыгы, уемы белән аермачык булып күренде.

Сөембикә кабаланып яр өстенә үрмәләде, кемнәндер качкандай, йөгерә-атлый авылга таба китте. Әле анда биш өй исән иде. Ул иң элек үзләре нигезенә туктады. Инде монда кайда өй, кайда абзар-кура булганын чамаларлык багана ише нәрсәләр дә калмаган. Бары тик картаеп беткән бер сәрви куагы сакланган. Нәкъ аның турында, урамда, кечкенә эскәмия бар иде, кичләрен, күңел ачып шунда кайткач, кызкыркын утыра, яшьләргә кадәр әниләре дә шул утыргычта гәп корырга яраталар иде. Сигезенче класстан алар колхоз үзәгендәге урта мәктәпкә йөреп укый башладылар, шул чакларда тылсымлы җәйге кичләрдә бу утыргычта Сөембикә белән Фәһимә, алар янында Әхнәф ярты төнгә кадәр чыркылдашып, үртәшеп гомер үткәрерләр иде. Кайсыдыр бер арада Әхнәф Сөембикәгә бик якынайды, Фәһимә алар янына килми торган булып китте. Хәтта бервакыт Әхнәф аны үпкән дә иде. Инде гел дуслашып беттеләр дигәндә, нишләптер аралары суынды, Сөембикәнең урынын Фәһимә алды. Ул инде кабат Әхнәфне кулыннан ычкындырмады. Шул чакта ук алар арасыннан, сизелер-сизелмәс кенә булып, кара мәче йөгереп үтте. Каядыр югалган ул мәче соңгы елларда тагын килеп чыкты, усал мыраулап, аларның арасына керде. Хәзер инде ул, чын юлбарыска әверелеп, Әхнәф белән Фәһимәнең хан сараедай йортларын, гаилә бөтенлеген саклап тора. Айгөл ул кара мәченең барлыгын башына да китерми. Бу мәче исән чакта кушыла алмаячакны аңласалар, аларның малае да, Айгөл дә бер-берсеннән мөмкин кадәр ераграк качарлар иде. «Әллә мин шушыннан башка берни дә уйлый алмыйм инде?» — дип, үз-үзен битәрләде Сөембикә. Туптуры Мөнир абыйсы янына барган булса, бәлкем, күңелен дә бушатып өлгерер, бу кадәр кыен да булмас иде.

Сөембикә үзләре өеннән өч кенә нигез аша утыручы, ак балчык белән сыланган кечкенә өйгә юнәлде. Анда йөз яшьлек Камәрниса карчык гомер сөреп ята. Кайткан саен Сөембикә аңа хәер кертә, ата-бабалары рухына дога кылдыра иде. Әмма бүген ул ниятенә ирешә алмады: карчыкның капкасы эчтән терәтелгән, ишеге йозакланган булып чыкты. Каршы яктагы тәрәзәләре такта белән кадакланган ике өй турыннан узып, ул Сәфиулла мулла өенә тукталды. Авылның иң мөхтәрәм кешесе саналган мулла абзыйны Сөембикә яхшы хәтерли. Тирә-юньдә дин әһелләрен Себергә сөреп бетергәндә дә, аны халык яклап калган. Чөнки ул бу төбәк авыллары

кешеләренә гомере буе гыйлем нурлары тараткан, үз өендә балалар укыткан. Аның карчыгы, абыстай, авыл халкына үлгәнче кием текте. Сөембикә дә кыз булып өлгереп җиткәнче ул теккән күлмәкләрне киде. Алар икесе дә йөз яшькә җитә язып вафат булдылар. Өйләрен кемнәрдер сатып алган дигән сүзне ишеткәне бар иде, димәк, дөрес булган. Элек авылның күрке булган өйнең абзар-куралары инде хәрабә хәленә килгән. Күкрәп торган, бөтен авылны алма белән тәэмин иткән мулла бакчасында кәкрәеп-бөкрәеп беткән чәнечкеле бер төп кыргый алмадан башка берни дә юк иде. Селкенеп тора торган сайгакларга шикләнә-шикләнә басып, ул өйгә керде. Ишекне ачуга, борынына бәргән сасы истән чак кына укшып җибәрмәде. Өстәл янында чал чәчләрен асылындырып, идән буявы төсле кара-кучкыл сары йөзле хатын утыра. Аның битендәге нечкә тимерчыбык белән чорнаган шикелле вак җыерчыкларның санына чыкмалы түгел, ул үзе шул җыерчыкларга ябыштырып кына куелган төсле. Эчкә баткан яңаклары, юка иреннәре арасыннан күренеп торган кара тешләре баягы баш сөяген күз алдына китерделәр. Хатынның күлмәге яка турларында, җиң очларында беләүләнеп, ялтырап тора. Өстәлгә юылмаган савыт-саба өелгән. Шунда ук аракыдан бушаган ике шешә, стаканнар утыра, идән чүп-чар белән тулган. Караватта хатыннан да ябыграк бер адәм ята. Аның да чырае майлы корым буягандай ялтырап тора, сирәк сакалы өскә тырпайган, кайчан юылганы да билгесез аякларына балчык-тузан каткан.

Сөембикә хатынны ишегалдына чакырып чыгарды, сөйләшә-сораштыра торгач, аларның Урта Азия якларыннан кайтканын белде. Камәрниса карчыкны оныклары мунча керергә алып киткәннәр, бүген-иртәгә китерәселәр икән. Хатынның сүзләреннән тәрәзәләре кадакланган теге ике өйнең дә сатылачагы мәгълүм булды. Өйләрне әллә Корея, әллә Кытай кешеләре карап киткәннәр, алар бу җирләрне арендага алып, дару үләннәре үстермәкче булалар икән. Авылны табуын дөрес тапканнар: урман буендагы үзәнлектә чәнчә үлән, андыз, мәтрүшкәләр, меңьяфрак, валериан, тагын әллә нинди дару үләннәре котырып үсә. Кәҗә ерганагының кызыл балчыгын да, Ленинград, Мәскәү шәһәрләреннән килеп, нindидер чирләрдән дәваланырга алып китәләр иде. Ул үләннәрнең, кызыл балчыкларның сихәтләндерү үзлекләрен Сәфиулла мулла белән абыстай бик яхшы беләләр, үз авыл кешеләрен генә түгел, шушы төбәкләрнең халкын да бик күп чирләрдән терелтәләр иде.

Сөембикә, колхоз үзәгенә Мөнир абыйсы янына кагылып, Айгөл хакында киңәшермен дип килгән иде, әмма бу

уеннан кире кайтты. Аның күңелендә кызының теләгенә каршы килүен йомшартучы ниндидер бер очкын кабынды. Өченче кеше булып, бу өрфиядәй юка, ертылырга-җимерелергә торган дөньяга Мөнир абыйсы түгел, керсә Ирек кенә керә ала иде. Ул шушы уйлар белән башы каткан хәлдә, үзенең яшьлеге үткән, газап-кайгыларны туйганчы чөмергән, гомеренең иң кадерле өлешен алып калган авылыннан олы юлга таба атлады. Бу аның теге хәтәр уйдан качуы иде. Кызы бит һич кенә дә аңардан акылсыз түгел, бар ягын да уйлагандыр, икәүләп киңәшкәннәрдер. Адәм баласының гомере бик кыска, аның кыскалыгын яшәүнең ахырына якынлашканда гына сизәсең. Менә шул бер мизгеллек бәхеткә тукынмыймы Сөембикә? Ләкин шундук аның бу уйларына, давылдай бөтерелеп, икенчеләре каршы килде. Фәһимә белән Әхнәф малае Айгөлне бәхетле итә алырмы? Алма агачыннан ерак төшми, Фәһимәнең кем икәнен бала чактан бирле белә. Байлык өчен иң якын кешесенең гомеренә тукына ала ул. Әхнәфтә астыртынлык, икейөзлелек көчле. Аның шундый икәнлеген гомере буе яшәп, менә яңа аңлап бетерделәр. Таһир аларның бу сыйфатларыннан азат булып тумаган, әлбәттә. Димәк, Айгөлнең аның белән бергә булуына ризалык бирү, аны бу адымыннан туктатмау бәхетен җимерүгә тиң. Ләкин безнең арада кем генә фәрештә соң дип, өченче уй каршы төште тагын. Син үзең фәрештәме соң? Адәм баласында барысы да бергә кайный. Тормыштагы шартларга карап, ул үзенең асыл йөзен югалтырга, бөтенләй үзе теләмәгән гамәлләрне дә кылырга мөмкин. Юк, хәзергесе вакытта Сөембикә бу уйларының очына һич тә чыга алмый икән. Ул фикерен чуалткан уй чоңгылының һаман хәтәррәк урынына суырыла барды...

Өенә кайтып керүгә, Айгөлне күрүгә, аның башындагы уйлары очып юкка чыктылар, күңелендәге элекке борчулар кабат яңарды һәм ул, ялгыш адым ясаудан туктатмакчы булып, кызын битәрләргә керешә. Айгөл аны сүзсез генә тыңлады да йөгереп чыгып китте. Сөембикә кайнар күз яшьләренә күмелеп еларга керешә. Аның тормышына катышмаска дигән сүзендә тора алмаганы, үзенең көчсезлеге өчен тыела алмыйча елады...

## 11

Бүген Әхнәф ял көне итеп эшкә соңрак барырга ниятләде. Уянгач та торырга иренеп, берничә көн каралмаган газеталарны күздән кичерде, аннары ваннада озаклап коенды. Ул сөртенеп чыкканда, каршысына халатын ярым ычкындырган Фәһимә килде.

— Нишләп алай йөрисең? — диде Әхнәф, ярым пышылдап. — Таһир торып чыкса?..

Фәһимә, якын ук килеп, аның күзләренә серле караш ташлады.

— Кайтмады бит әле ул.

Хатынының тәненнән килүче кайнарлык дулкын булып Әхнәфнең күңелен җылытып җибәрде. Затлы хушбуй исе тойгыларын кузгатты. Ул, елмаеп, кулларын аның иңбашына салды, әмма стена сәгатенә күз төшергәч, кинәт җитдиләнеп китте.

— Ничек кайтмады? — дип сорады ул, Фәһимәнең күзләренә төбәлеп.

— Мин каян белим?! Яшь чагы бит, исән йөрсен.

— Кызы-мазары бар микәнни?

Фәһимә, серле итеп елмайган хәлдә, аңа таба иелеп:

— Кызларын белмим, мазарлары Болынкырда буа буарлык бит инде аның, — дип куйды.

Әхнәфнең уяна башлаган тойгылары сүрелде, кулларын Фәһимәнең иңбашыннан алып кухняга чыкты. Өстәл уртасындагы җиләк-җимеш арасыннан керешли үк зур кара виноград алып капты да үз урынына утырды. Фәһимә, аның артыннан чыгып, алдына яшелчә салаты, карабодай боткасы белән котлет, томат согы куйды. Кухняда бөркү иде.

— Тәрәзәне ач әле, — диде Әхнәф, салатка үрелеп.

Фәһимә пәрдәне тартып тәрәзәне ачуга:

— Әнә кайткан бит ул, — диде.

Әхнәф тә килеп ачык тәрәзәдән үрелеп карады. Таһир ак «тугызлы» машинаның уң як ишеген ачып баскан да кем беләндер сөйләшә, сүзләр ишетелми. Ишектән сузылган кызлар кулын тотып, аны чыгарга кыстый, ахрысы. Алар бу күренешне шактый озак күзәттеләр. Машинаның кара пыялалары аның эчен күрсәтми иде. Ахырда Таһир, кызның кулларын ычкындырып, машина ишеген япты да өйгә таба борылды. Әхнәф белән Фәһимә, берни күрмәгәнгә салышып, өстәл янына утырдылар һәм ашарга керештеләр. Менә ишектә Таһир күренде. Туфлиләрен салып, акрын гына алар янына килде.

— Хәерле иртә, — диде ул, тирләгән йөзен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә.

— Хәерле иртә, — диде Әхнәф, улына сынап карап.

Таһир ничектер үзгәргән иде. Әле бер, әле икенче аягын күчергәләп, бер урында таптангандай итте, уң кулын кесәсенә тыгып, нәрсәдер эзләде, тагын йөзен сөртте, еш-еш сулыш алганы ишетелде.

— Улым, бер-бер хәл булдымы әллә? — диде Фәһимә. — Әйдә уз, утыр.

Таһир аның сүзләрен җавапсыз калдырды. Аннары, бөтен гәүдәсе белән талпынып, аларга таба атлады да, ничектер ят тавыш белән:

— Мин өйләнергә булдым, — диде.

Фәһимәнең кулындагы чәнечкесе төшеп китте, Әхнәф тә шактый вакыт тораташ катып торды.

Аннары көч-хәл белән:

— Ничек өйләнергә? — дип куйды.

— Ничек булсын... Өйләнәм.

— Бу уй кайчан килде инде башыңа? — диде Әхнәф, ачулы тавыш белән.

— Күптән, кыш көне үк.

— Ник? Ник өйләнәсең? — диде Фәһимә, калтыранган кулларын аңа таба сузып.

— Сез ник өйләнсәгез, мин дә шуңа өйләнәм.

— Нәрсә, түзәрлегең калмадымыни? — диде Әхнәф, аңа каш астыннан карап.

Аның соравына Таһир җавап бирмәде, бары тик күз карашын түбән төшерде. Фәһимә кычкырып елый башлады.

— Укуыңны кайчан бетерәсең, шул чакта өйләнерсең. Аңладыңмы?

Әхнәфнең бу сүзләреннән Таһирның бите кып-кызыл булды.

— Юк, мин хәзер өйләнәм.

Ул борылды да ишеккә юнәлде.

— Тукта! — дип кычкырды Әхнәф. — Хәзер үк безнең каршыга кил!

Таһир, аның сүзенә буйсынып, тагын нәкъ шул урынга килеп басты.

— Ярый, — диде Әхнәф, аягүрә басып. — Безнең килен кем булачак инде?

— Айгөл, — диде Таһир.

— Нинди Айгөл?

— Сабитова Айгөл.

Әхнәф белән Фәһимә аптырашып бер-берсенә караштылар.

Фәһимә елавыннан туктады да, көч-хәл белән теш арасыннан кысып чыгарып:

— Нинди Сабитова? — диде.

— Үзегезнең дустыгыз...

Фәһимә калтыранып аның каршына килде:

— Хәзер үк «юри әйттем, шаярттым» диген!

— Чын әйттем, — диде Таһир, тыныч кына. — Айгөлгә өйләнәм.

Фәһимә тагын кычкырып еларга тотынды, ул Таһирны күлмәгеннән тотып селкетә башлады, йодрыклары белән иңбашларына сукты, аннары урындык артында эленеп торган сөлге белән йөзенә сыдырырга кереште, нәрсәләрдер кычкырды. Әхнәф аны тотып көчкә үз бүлмәсенә алып кереп китте, дару эчерде, тынычландырды. Алар чыкканда, Таһир диванда утыра иде.

Фәһимә, аның каршына килеп, урындык алып утырды һәм ягымлы тавыш белән сүз башлады:

— Улым, аңлыйсыңмы, син бит минем җаным. Синең белән күпме газаплар кичердек, туганнан бирле башың чирдән чыкмады. Ничә еллар мин сине кайнар күз яшьләрем белән сугардым, санаторийларга йөрттем, үзем чиргә сабыштым, җанымны сиңа күчереп терелттем...

— Рәхмәт, әни, — диде Таһир, аңа җылы караш ташлап. — Мин барысын да аңлыйм. Әмма сез дә мине аңлагыз.

— Юк, мин сине беркемгә дә бирмим!

— Укуыңны бетермичә авыз да ачмыйсың! — дип өстәде Әхнәф.

Таһир аларның әле берсенә, әле икенчесенә аптыраулы караш ташлады да күзләрен тәрәзәгә таба төбәп:

— Ата-аналар балаларын үзләренең коллары итү өчен яраталар икән, — дип куйды.

— Син бик өстән фикер йөртәсең, — диде Әхнәф, аңа каршы төшеп. — Әллә кешелек җирнең колы түгелме? Әллә барлык тереклек табигать колы түгелме?

— Минем кол буласым килми.

— Синең Айгөл колы буласың килә! — диде Фәһимә, аңа җикереп.

— Ә сез мине Булатовлар кызының колы итәргә телисез.

— Кол түгел, патша! — диде Фәһимә, ярсып. — Альбина белән таныштыру өчен Казанга без махсус бардык. Нинди затлы нәсел! Бөтен республиканы тоталар. Югары культура, югары әхлак дөньясы. Альбинаның үзен генә кара тагын. Шуның нәрсәсе ярамады?

— Әйе, ул искиткеч кыз, — диде Таһир, аптыраулы карашын әнисенә төбәп. — Мин аңа табынам, тик...

— Нәрсә тик, нәрсә тик?! — диде Фәһимә, аңа якын ук килеп.

— Әйтә алмыйм. Ул янәшәдә булса да... ара якынаймады, якыная да алмый иде. Айгөл Болынкырда килеш тартты да алды.

— Их балакаем! — Өзгәләнүдән Фәһимәнең тыны кысылды, тавышы буылып чыкты. — Әйе, алар тартып ала

беләләр. Акула кебек «хап» кына йоталар. Сөембикә Ирекне йотты, тагын әллә кемнәрне. Сөембикәнең әнисе беренче ирен, тагын күпләрне йотты. Аларның тормышы — фаҗигаләрдән генә торучы куркыныч чылбыр. Алар белән беркем дә бәхетле була алмый!

Түземе бетеп, Таһир урыныннан сикереп торды һәм чыгып китмәкче булды.

— Без бәхетле булачакбыз!

Фәһимә, аның каршысына төшеп, ике кулы белән ишектән читкә этте.

— Әнисен рәнҗеткәннәр бәхетле була алмый. Әгәр аңа өйләнәм дигән сүзеңне тагын бер генә әйтсәң дә, каберемдә рәнҗеп ятачакмын, мәңге рәхәт күрмәячәксез!

— Ник соң сез мине аңламыйсыз?! — диде Таһир, кызып. — Мин аны яратам!

— Буярату түгел! — Әхнәф имән бармагын чигәсе турында боргалап алды. — Синең яшьлек юләрлегең генә!

— Юләрлектер, тик ул мине үзенеке итте. Мин инде хәзер аңардан башка яши алмыйм...

— Их, балакаем! — дип, Фәһимә тагын елый башлады. — Кабатлап әйтәм: минем җаным синдә! Ә аны мин теләсә кемгә бирмәячәкмен!

Таһир, мәсхәрәле көлемсерәп, сүзсез генә баш чайкады, аннары тонык тавыш белән, һәр сүзенә басым ясап, акрын гына болай диде:

— Сез берни дә бирмисез. Беркемгә дә. Беркайчан да.

— Бу ни дигән сүз?! — дип ташланды Әхнәф. — Әзрәк оялыр идең! Мин гомеремне халыкка бирдем, әниең минем белән янәшә булды.

— Юк, әти, сез аласыз гына. Бөтен кешенекен, һәрбер урыннан. Аз-азлап та, күпләп тә. Күрсәтеп тә, күрсәтмичә дә.

— Менә ниче-ек! — дип сузды Әхнәф. — Хәтәр әйберләр сөйлисең син.

Фәһимә аның сүзләрен күтәреп алды:

— Сөйләмичә, тамак тук, машина кулда, квартира бар. Рәхмәт, улым, моны көтмәгән идек без синнән.

— Әрепләштек — булды! — диде Әхнәф, йодрыгын селкеп. — Юкса ачуланышып, әллә нишләшеп бетүебез бар. Без ничек әйттек — шулай була.

— Юк, әти. Сез безне аерабыз дип уйлыйсыз да... Юк! Сезнең бу мине урталай өзүегез...

Таһир акрын гына башын чайкады, куркыныч итеп яңак итләрен чәйнәде. Аның йөзе кәфендәй агарган, тәне калтырый иде. Фәһимәнең куркудан коты очты.

— Ярый, улым, ярый. Альбина булмасын, — диде ул, кабаланып. — Тик аңа гына түгел...

— Аңа гына, яисә...

— Нәрсә «яисә»? — Фәһимә аның күзләреннән җавап эзләде.

Өйне күтәргәндәй, сузып-сузып телефон шылтыырга тотынды. Әмма трубканы алырга беркем дә бармады. Шылтырау озак дәвам итте, гүя аларның өчесенең дә түземлеген сынийлар иде.

Ул тынгач, Таһир сүз башлады:

— Әйтерсең лә мин үзебезнең өйдә түгел, әллә нинди чит дөньяда. Ярты сәгать вакыт эчендә бер-беребездән мең чакрымга ерагайдык... Әллә мең елгамы?.. — Таһир дулкынланып торган коңгырт чәчләрен акрын гына артка таба сыпырып куйды. — Кошлардан да бәхетле җан ияләре юк... Кош булсам, әллә кая, күз күрмәгән җирләргә очар идем...

Әхнәф, малаеның киң маңгаена, чиста күзләренә карап, ниндидер кимчелек эзләде, әмма таба алмады. Бераз алгарак чыгып, әнисенекен хәтерләтеп торучы киң маңгайдан ниндидер көч бөркелүен күреп, тәне калтыранып куйды. Аның әле бер генә мәртәбә дә кырынмаган җыерчыксыз шома йөзеннән яшьлекнең юләр дәрте тибә иде.

— Күп газаплар китергәнем өчен кичер, әни. Мин сиңа кабат энә очы кадәр дә борчу ясамаячакмын.

Таһир урыныннан кузгалмакчы булды, әмма Фәһимә аңа ташланды. Малаеның әле генә әйткән сүзләре аның котын алды. Бу сүзләр астында аңа олы һәлакәт килгән кебек булды. Таһирның чигенмәячәге көн кебек ачык иде. Ул аны иркәләргә, үбәргә, кочарга тотынды, үзе елады, үзе туктаусыз ялварды:

— Улым, ярый, синеңчә булыр. Тик бер генә үтенечемне тыңла: бер генә ел сабыр ит! Бер ел! Үтәр дә китәр, аннары өйләнерсең. Теләсә кемгә өйләнерсең. Бер ел гына көт! Әйт: көтәм, диген! Бер генә ел көтәм, диген!

Әмма Таһир аның ялваруларына әллә нинди моңсу, сагышлы карашын төбәп, берни күрмәгәндәй, берни ишетмәгәндәй, сыңар сүз әйтмичә басып торды да, кинәт бәйдән ычкынгандай, ишеккә таба ыргылды.

— Улым, тукта! — дип кычкырды Әхнәф.

Таһир очып киткәндәй юкка чыкты, машинасының ишеген ачып япканы, гөлт итеп кабызып газ биргәне, көпчәкләрнең капка төбендәге асфальтны шытырдатып бер урында әйләнә-әйләнә кузгалганы гына ишетелеп калды.

Тагын сузып-сузып телефон шылтырарга тотынды. Әхнәф юри бик озак трубканы алмыйча торды. Аның беркем

белән дә бер генә сүз дә сөйләшәсе, берни ишетәсе, берни күрәсе килми иде. Сабыры тәмам төкәнгәч, ачу белән трубканы умырып алды. Шылтыратучы Рашат иде. Аның тавышын ишетүгә, Әхнәфнең йөрәген утлы чыбык кисеп үткәндәй булды.

— Мин синең заказыңны үтәдем, Әхнәф Хәсәнович, — диде Рашат. — Хәзер синең чират.

— Минем сиңа бернинди заказ да биргәнем юк, — диде Әхнәф, аның ни турында сөйләвен аңламыйча.

— Нәрсә кыланасың! — Рашатның карлыккан тавышы ачулы булып яңгырады. — Другыңны проучить итәргә хатының аша заказал. — Әхнәф эшнең нидә икәнен аңлады. — Миңа до зарезу квартира кирәк! Күп алдадың син мине. Ә хәзер никуда...

— Юк, булмаячак! — дип, бөтен көченә гәүдәсен алга ия-ия кычкырды Әхнәф, гөбе тавышы чыгарып. — Юк квартира!!! Кабат шылтыратып та торма!!!

Ул трубкасын ыргытты. Рашатның җәфалавыннан ул шулкадәр туйган иде, аннан котылу өчен теләсә кая чыгып качарга әзер иде. Бер минуттан телефон тагын шылтырады.

Рашатның янаулы тавышы яңгырады:

— Син үзеңне әйбәт тотмыйсың. Может передумаешь?

— Не передумаю...

— Ну, смотри, Шарифуллин, үзеңә үпкәлә, мин алдалауны кичермим!

Бусында трубканы Рашат куйды. Әхнәф лапылдап урындыкка утырды. Олы афәтнең колак төбендә генә куркыныч итеп сулыш алганын аермачык ишетте ул...

## 12

Айгөл таң атканда гына кайтты. Сөембикә аның, аяк очларына гына басып, үз бүлмәсенә кереп ятканын ишетеп торды. Өйдә кичәдән бирле яшенле яңгыр якынлашкандагы кебек киеренкелек иде. Кызы качты, ә Сөембикә аны туктатырга курыкты. Кабат сүз башлап, тагын үзе теләмәгән җавапны ишетәсе килми иде аның. Шуңа күрә ул Айгөл кебек үк аяк очларына гына басып ишегалдына чыкты да шунда юынып керде. Бер чынаяк салкын чәй эчте, чәй авызга алгысыз тәмсез иде. Өстәл янында уйланып утыра торгач, үзе эшли ала торган һәм эшләргә тиешле бердәнбер ниятен тормышка ашырырга уйлады: Камәрниса карчыкка барып, хәер биреп кайтырга. Шул арада, бәлкем, кызы белән ничегрәк сүз башлау җаен да табар. Зур полиэтилен букчага

чәй, лимон, кәрәзле бал, төрледән төрле җимешләр тутырды да автовокзалга юнәлде. Билет алганда да, юлда барганда да янәшәсендә кемнәр барын күрмәде, белмәде. Автобустан төшкәч кенә, ул чын дөньяга кайтты. Күк йөзендә бик биектә төркем-төркем болытлар йөзә, җил чыккан, кояшның әле эсселеге сизелми иде. Авылга якынлашкан саен, эчендә нәрсәдер күтәрелә башлады, моны берничек тә аңлатып булмый иде. Истәлекләр дә түгел, сагыну да түгел, үкенү дә түгел — ниндидер аңлаешсыз тойгы һәм ул туктаусыз көчәя барды. Шул тойгы йогынтысында Сөембикә Камәрниса карчыкның ак балчык белән сыланган өенә килеп җитте. Әле ихата шактый нык, яңартылган, балаларының кайгыртучан кулы сизелеп тора иде. Ул кергәндә өйалдында стена буйлап эленгән үләннәргә игътибар итте, аларның борынны ярып кергән төрле-төрле исләреннән башы әйләнде.

Ишекне ачуга, Сөембикә үзенә балачактан ук таныш булган күренешкә тап булды: тәрәзә өсләрендә чиста түрләмәләр сузылган, иң өстә борынгы шәмаил, өстәлдә олы җиз самавыр, аның түбәсенә керәч чәйнек менеп кунаклаган, тәрәзәләрдә чачаклы сөлгеләр. Мич буенда Камәрниса әбинең тәһарәт ала торган җиз тазы белән җиз комганы, өстәлдә шактый биек итеп өеп куелган борынгы дини китаплар, бераз читтәрәк Сөембикәгә таныш Коръән ачып куелган. Аның чәчәккә охшатып ясалган нокталар белән аерылган һәр җөмләсен, гасырлар төсенә кереп саргайган бу китапны Сөембикә сабый чактан ук хәтерли. Камәрниса әби үзе, күлмәкләрен биленә кадәр сыдырып, шәрә аякларын алга сузган килеш, шакмаклы палас җәелгән борынгы сәкесендә утыра. Ул тезләренә кызыл балчык сылаган, аяклары корыган ике агач ботагы төсле ябык, бот ите юк диярлек, тез шәмәе бот сөяге белән тубык турына караганда юанаеп тора. Камәрниса карчык башына алсу чәчәкле кәшемир яулык бәйләгән, буйлы яшел күлмәгенең җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганган, үзе күзләрен йомып, йокымсырап утыра иде. Сөембикә кереп сәлам бирүгә, чулпыларын чылтыратып башын күтәрде, аның сәламенә җавап бирде.

— Ни хәлләрдә ятасың, Камәрниса әби? — диде Сөембикә, аның салкын, ябык, шакмакланып беткән бармаклы кулын үзенең учына алып.

— Әйбәт кенә, бәбекәчем, шөкер генә. — Карчыкның йөзендәге җыерчыклар, җанлы хәрәкәтләнеп, елмаю рәвешенә керделәр. — Исән икәнсең.

— Кичә дә сине күрим дип кайткан идем дә, балаларың алып киткән диделәр.

Камәрниса карчык аның бу сүзләренә җавап бирмәде, кызыл балчык сылаган аяклары өстендә кулларын йөртеп:

— Бүген балчыкка барып кайттым, шыгырдый башладылар, — диде, көлгәндәй итеп.

Аның тешсез кызыл казналары Сөембикәгә мич авызын хәтерләткәндәй булдылар.

Сөембикә күчтәнәчләрен, ул күреп торсын дип, берәм-берәм өстәлгә алып тезде.

— Менә, Камәрниса әби, җылы як күчтәнәчләре, борының кычыткандыр, чәй эчәрсең.

Карчык аның хәрәкәтләрен сынагандай астан гына карап торса да, рәхмәт әйтмәде.

— Җылы яклар бездә ул, — дип куйды ул, Коръән укыгандай мәкам белән. — Ул урман буйларындагы, Имән күле янындагы кош тавышларын тыңласаң... оеганмын, әллә нинди дөньяларга киткәнмен. Бүген сандугачкайларым, карлугачкайларым җиһанны кызыл буяу белән буйыйлар.

Сөембикә аның сүзләреннән берни дә аңлый алмады.

— Кемнәр буйый дисең, Камәрниса әби?

— Сандугачларым, карлугачларым дип торам лабаса!

— Алар ничек буясын инде?

— Ничек, ничек! — дип куйды ул төксе генә, тешсез авызын ачулы мимылдатып. — Телләре белән буйыйлар. — Карчыкның йөзе тагын әллә нинди серле, моңлы төс алды, ул тагын да көчлерәк мәкам белән дәвам итте: — Бөтен галәмне шулар бизәкли. Телләренә нинди генә буяулар алмыйлар алар җаныкайларым! Сез күрмисез, сез сукырлар. И-һи-һи! Бүген менә кызыл төсне мулрак алганнар. Балчыкка баргач, мине сырып алдылар, бергәләп туйганчы серләштек, телләренә кызыл төсне дә шуннан алдылар. Аннары алар шул төсләрне чәчәкләргә, агачларга, үләннәргә тигезеп чыгалар, сеңдерәләр, күкне ничек күркәм итеп иртә-кичен бизәгәннәрен күрсәгез! Болытларны матурлап буйыйлар. Көнен дә, төнен дә мең төскә кертәләр, ару-талуны белмиләр, үзләре гел сөйләшәләр, көлешәләр, куанышалар...

Камәрниса карчык шунда капыл гына туктап калды, күзләрен йомып, уйга батты. Ниндидер дулкынга эләккәндәй, аның гәүдәсе сизелер-сизелмәс кенә як-якка чайкала иде. Аның бу халәтен бозудан куркып, дәшәргә кыймыйча шактый торды Сөембикә. Бераздан әби күзләрен ачты.

Сөембикә, кулында әзерләп тоткан акчасын аңа сузып:

— Камәрниса әби, хәер алып килгән идем, кабул итеп ал әле, — диде.

Ләкин карчык кулын кымшатып та карамады, акрын гына баш чайкады:

— Зиратка бармагансың, — диде ул, кисәтүле тавыш белән.

Аның моны белүе Сөембикәне хәйран калдырды.

— Хәзер шунда китәм...

— Иң элек шунда бар... — Карчык шулай диде дә күзләрен йомды.

Сөембикә кабаланып өйдән чыгып китте. Зиратка бара торган юл түгел, анда хәтта тар сукмак та калмаган иде инде. Ул үзенең такыялар үргән җирләреннән атлый-атлый зиратка килеп җитте. Аның коймалары җимерелеп бетеп бара, такталарының, җепсәләренең нинди төстә икәнен дә аерырлык түгел. Аларга карасу-яшькелт күгәрек, яңа тишелгән мүкне хәтерләтүче вакыт черегә утырган. Кайбер урыннары каралган, кайбер урыннарда җепсәләр сынып, череп коелганнар, коймалар йә эчкә, йә тышка авышып тора. Шундый коймасыз урыннарның берсеннән кереп, ул әнисенең каберен эзләп тапты. Аның уртага утыртылган ташы, язылган язуы да исән-сау, тик ул бераз авышып кына киткән иде. Чардуганның инде буяулары кубып бетә язган. Кайчандыр аны яшелгә Фәйзрахман буяган иде. Кабернең нәкъ уртасында яшь усак лепердәп утыра, Сөембикә утырткан миләш нишләптер корыды, ә усак җил белән килгән орлыктан тишелгән иде. Әнисе кабере янына килгән вакытларда Сөембикә аның күтәрелгәнен күрде, әмма никтер йолкып атарга уйламады, аның миләшкә зарар салырын чамаламады. Ә менә хәзер баксаң, аның утырткан миләше юк, җилдән килгән усак үсеп утыра. Әнисенең кабереннән ерак түгел Фәйзрахман кабере, аның белән янәшә хатыныныкы. Шулчак Сөембикә бер генә минут та тынмаган яфраклар шавына игътибар итте. Ул, башын күтәреп, әйләнә-тирәсенә күз салды һәм хәйран калды: кайчандыр тип-тигез булган, чардуганнар тезелгән урыннарны урман кебек усак каплап киткән икән. Алар шулкадәр күп, алар көчле, башка агачлар берни дә кыла алмый, аларның күләгәсе астында үсәргә, үсә алмаганнары корырга мәҗбүр. Нәрсәгә дип бу кадәр шаулашалар алар? Сөембикәгә усаклар белән җил шушы каберстанда туй итәдер кебек тоелды. Алар шаяралар, җил агачларның барлык урыннарын капшый, башта бер яктан исеп ботакларын сыга, яфракларын шыбыр-шыбыр аралый, аларның аскы аксыл яклары күренеп күтәрелә, җил, һаман ныграк дәртләнеп, аларга ныграк сылана, теләгенә ирешә алмагач, кинәт кенә юнәлешен үзгәртеп, башка яктан исә башлый, ботаклар шул якка бөгелә,

яфраклар шул якка таба җилферди, шаулый. Аннары алар, әллә үзара килешеп, бер генә мәлгә тынып калалар. Җир белән күк арасында шомлы тынып калган бу исәпсез-хисапсыз яфраклар, кемнеңдер килүен сизенеп, танырга теләгәндәй карап торалардыр кебек. Аннары, «ә, бу икән» дигәндәй, кабат шауларга керешәләр. Теге тынлык югала, әмма аның шомы, җәйге челләдә өскә утырган кайнар тузандай, күңелдә кала...

Аяк астында, җирдә мәңгелек тынлык. Әнисе дә, бабасы белән әбисе дә — аларның каберләре өч кенә адымда — Фәйзрахманнар да инде күптән йоклыйлар. Усак яфраклары ни дип шаулый, агачлар белән җил ни дулый, алар ни дип сөйләшәләр, шыбырдашалар? Бу хәтәр шыбырдашу да, лепердәүләр дә әллә ничә гасырлык елларның шәүләсе кебек. Уйлап карасаң, биредә ничә буыннар ятмый. Шушы җир өстендә яшәп алар гомер иткәннәр, шатланганнар, куанганнар, газапланганнар, үз кыйблаларын табарга тырышып, ниндидер максатлар куеп, эш-гамәлләр кылганнар. Аннары бакый дөньяга китеп барганнар. Алар артыннан яңа буыннар шуны ук кабатлаган. Шушы җир өстеннән җилдәй исеп, ничәмә-ничә елар узган. Җил кебек еллар да ашыга, аларның үткәнен сизми дә каласың. Менә инде әниләре артыннан Сөембикәгә дә вакыт җитә. Айгөл дә тормышка аяк басты. Айгөл, Айгөл... Нигә соң әле ул да шушы кадәр ашыкты? Бармы мәгънәсе ул ашыгуның? Сөембикәгә усак яфраклары шыбырдавы белән бергә Фәйзрахман җыры ишетелгән кебек булды:

Агыйделне буйлый-буйлый,
Килә аккош атучы.
Атма аккош, ат сандугач —
Шул безне саргайтучы...

Фәйзрахман аны гомере буе җырлады, елый-елый, сыкрап җырлады. Салып алган чакларында авылның әле бер очында, әле икенче очында аның йөрәкләрне өздерерлек тавыш белән шул җырны сузганы ишетелә иде. Авылда яшәгәндә, тормышның бик күп сорауларына җавап таба алмады Сөембикә. Шул серле сорауларның берсе — әнисе белән Фәйзрахман арасындагы мөнәсәбәт иде. Фәйзрахман бик усал хатын белән яшәде, үзе аннан да усалрак иде. Алар һәр көн диярлек сугыштылар, әллә ничә мәртәбәләр, Фәйзрахман Кәримәсен кыйнап үтереп ташлаган, диделәр. Әмма Кәримә терелде. Фәйзрахман эчеп алдымы, Сөембикәләргә килеп керде. Кайчакларда әнисе аны, әллә нинди сүзләр

әйтеп, өйдән куды, уклау белән сыртларына кундырды, әмма Фәйзрахман чыкмады, әнисенең йөзләренә төбәлеп, теге җырын сузды. Авылда йөргән сүзләргә караганда, Фәйзрахман, читтән баеп, киенеп кайтып, авыл халкын аһ иттергән. Сөембикәнең әнисе аңа кияүгә чыкмагач, ул тагын гаип булган да, күпмедер вакыттан соң, бөтен җирен сипкел баскан, таза гәүдәле, мичкәдәй юан Кәримәне алып кайткан. Ләкин ни гаҗәп, алар өйләнешеп яши башлагач, әнисе Фәйзрахманга үзләренә килергә рөхсәт итә иде. Иң элек Кәримә үлде. Аларның балалары авылдан чыгып китеп юк булдылар. Ул үлгәч, Фәйзрахман Сөембикәләргә килүен ешлатты. Аннары әнисе үлде. Фәйзрахман көн саен баш күтәрмичә эчәргә кереште, теге җырын җырлап зиратка китте. Үз хатыны каберенә түгел, Сөембикәнең әнисе каберенә барып, кайнар яшьләрен түкте. Менә бу дөньяда алар юк инде, өсләрендә усаклар җырлашып утыра. Нәрсә ул кеше гомере? Бармы ул мәхәббәт? Әгәр бар икән, ул нинди була? Әниләрен, Фәйзрахманнарны, Кәримәләрне ул мәхәббәт уты ничек көйдергән? Алар ни дип яшәгәннәр? Тормыштан берәр олы мәгънә тапканнармы? Ул мәгънә хәзер кайда? Шушы усак яфракларын лепердәткән җил кебек еллар аларны алып китеп югалтканмы? Ә бит уйлап карасаң, һәрбер кешенең яшәгән чакта үзе генә ачкан хакыйкатьләре бардыр. Ни өчен ул хакыйкатьләр, шушы усаклар кебек, җир йөзендә утырып калмый? Юк, алар җирдә түгел, кешеләр күңелендә калырга тиеш. Ә соң әниләре, Фәйзрахманнар тормышыннан Сөембикә андый хакыйкать алып кала алдымы? Күпме генә уйласа да, ул моңа җавап тапмады. Әгәр сабак алган булса, ул үзенең тормышында әнисе җибәргән хаталарны кабатлар идеме? Бәлкем, ул аларны игътибарсыз калдыргандыр? Кабатлау-кабатламау турында уйламагандыр. Сораулар, артканнан-арта барып, аның башында усак яфракларыдай шаулый, бөтерелә башладылар.

Сөембикә, рәшәткә аша үрелеп, усакның кытыршы кәүсәсенә кулын салды һәм әнисенең куллары хәтеренә килде. Аның өчен бер хакыйкать бар: әнисенең куллары. Сөембикә аны белә-белгәннән бирле ул куллар шушы усак кабыгы кебек яргаланган, сөялле иделәр. Үлгәндә дә әнисе шул куллар белән китте. Ул көне-төне эшләде, эшләү аның өчен ашау кебек үк табигый нәрсә булды. Әбисе белән бабасы, аңа карап, бу бала берәр кайчан ару-талчыгу дигән нәрсәне белә микән дип аптырашалар иде. Эшкә ничек аяусыз булса, кешеләр белән аралашуда да, ир-ат халкына да, бер караганда, аяусыз, бер караганда, талымсыз иде әнисе. Әллә

инде гомер буе язмышым шулай дип яшәдеме икән — анысын Сөембикә әйтә алмый. Юк, аңа тизрәк зираттан чыгарга кирәк. Болай да яралы күңеленә элеккеге яралар да өстәлгәч, түзү мөмкин түгел.

Ул, акрын гына атлап, җимерек урыннан үтте, тагын бер мәртәбә борылып, әниләренең мәңгелек урынына сагышлы күзләре белән карап торды. Зираттан ераклашып, авыл урынына килеп җиткәндә дә, усакларның шомлы шаулавы колак төбендә яңгырады. Шуның белән бергә Фәйзрахманның йөрәкләрне туктата, бәгырьне кисә торган үзе чыгарган көе, шул көйгә яңгыраган җыры озата барды:

Атма аккош, ат сандугач —
Шул безне саргайтучы...

Сөембикә Камәрниса карчыкның өенә, борып чыгармаса ярар иде дип, курка-курка керде. Ул нәкъ шул урында утыра, бары тик аякларын яшел күлмәгенең итәкләре белән каплаган иде.

— Сөйләштеңме Җәүһәрия белән? — диде ул, күзләрен йомган килеш.

— Сөйләштем, — диде Сөембикә, акрын гына.

Баягы хәер акчасын сузды, карчык сүзсез генә аны кабул итеп алды, икәүләп дога кылдылар.

— Рәхмәт, Камәрниса әби, — диде Сөембикә, урыныннан торып. — Мин кузгалыйм инде.

— Көттермә син аны. — Карчык, корышкан кулларын аңа таба сузып, бармакларын дерелдәтеп шактый торды. — Үткәнеңне онытма...

Сөембикә шунда аның ачулы карашын күрде.

— Онытмыйм, — диде ул, акрын гына.

— Үзеңнең үткәнеңне әйтәм... — Камәрниса карчык аңа тишәрдәй итеп карап алды. — Түрәләр белән...

Әйтерсең лә Сөембикәнең йөрәгенә ул без белән чәнчеде. Чагарга сузылган елан кебек хәтәр нәрсә аңа якын ук килгән, инде угын аның йөрәгенә тигереп тә алды кебек. Сөембикә моны аермачык сизде, әмма ышанасы килмәде.

Ул авыр итеп сулады да:

— Нинди... түрәләр белән? — дип сорады һәм тын алудан туктап көтә башлады.

Әби бу сүзләрне саташып кына сөйли ала, чөнки Сөембикә күргән-кичергәннәрне аның берничек тә белүе мөмкин түгел иде. Камәрниса карчыкның җыерчыклы йөзеннән елмаюга охшаш шәүлә йөгереп үтте дә кайгы-сагыш төсле булып ябышып калды.

— И бәбчегем! — Ул ябык беләген алга сузып сыпырып куйды, андагы кан тамырлары барысы да аермачык күренә иде. — Бөтен кеше дә берни белмиләр дип уйлый. Бәндәнең ни кылганын ниятләгәндә үк Аллаһы Тәгалә белә, шуннан соң гына бүтәннәр.

Карчык шулай диде дә тынып калды. Сөембикәнең йөрәге ярсып тибәргә кереште.

— Син әйтмәдең, Камәрниса әби... түрәләр белән нәрсә?..

Карчыкның йөзендәге сагыш кинәт әллә аптырау, әллә ачу белән алышынды.

— Шаярды-ы-ың, кы-ы-ы-зы-ы-ым!..

Ул шундый итеп сузды, тавышы бер төште, бер күтәрелде, бер нечкәрде, бер калынайды, тагын әллә нинди төсмерләргә керде. Шул ук вакытта бу тавыш, «Мә, ал, бик теләсәң» дигәнне аңлата иде. Сөембикә кычкырып елап җибәрүдән иреннәрен тешләп кенә тыелып калды.

Бераз хәл алгач:

— Үз өстеңә гөнаһ алам дип уйламыйсыңмы, Камәрниса әби? — диде, сулкылдап.

Бу вакытта карчык эре көрән таплар белән чуарланган ябык кулларына хөрмә төшеннән ясалган дисбесен алган иде. Ул, иреннәрен мыймылдатып, ашыкмыйча гына аны тартырга кереште. Сөембикә нишләргә белмичә, аңа коты очып карап торды, гүя аның каршында тәкъдирен хәл итүче судья хөкем карары чыгара иде. Камәрниса карчык күзләрен йомган хәлдә дисбесен тартып бетергәч, дога укып, битен сыпырып куйды.

Әллә онытты, әллә ишетмәде дип уйлап, Сөембикә чыгарга кузгалды, әмма артында карчыкның баягы мәкамгә охшаган сузынкы тавышы ишетелде:

— Гөнаһны миннән эзләмә, бәбчегем. Сулар кибә, утлар сүнә, искән җилләр туктый, халыклар яшәп үлә, таулар тузанга әйләнеп тигезләнә, дәрьялар пар булып күтәрелә, ә гөнаһ юылмый. – Ул, чекерәеп, Сөембикәгә карады. — Савап та, игелек тә, башкасы да...

Сөембикә бүтән түзә алмады. Инде бөтенесе дә ачык иде. Камәрниса карчык каршында ул оятсызлык күрсәтеп утырганын аңлады. Дәшмичә калган булса, әби бу соңгы сүзләрне мәңге әйтмәс иде. Камәрниса карчык шуңа күрә түзмәде, шуңа күрә ярды да салды. Нигә моңа кадәр Сөембикәгә берни дә сиздермәде икән ул? Аның бит хәер бирергә елга берничә мәртәбә килгән чаклары күп булды. Әллә соң Сөембикәнең күңеленең шушылай кан саркып торган чагын юри көткәнме?

Үзеңә үзеңне корбан итү юк икән бит! Акча, әйбер, тәнең, каның, җаның гына үзең өчен үзеңнеке. Ә югарыга күтәрелгәч... Вөҗдан, иман, хакыйкать, гореф-гадәт, игелек-сафлык кебек нәрсәләргә күчкәч, алар беркайчан да, беркемнеке дә үзенеке генә була алмый. Ул илаһи нәрсәләрербөтен, алар һәммәсе дә җиһаннан килә икән, үземнеке дип уйлап ярамаган чиктән атлап чыгу ул төзәтә алмаслык гөнаһ икән. Юк, гөнаһ кына түгел, җинаять! Гаиләң, кавемең, милләтең, гомумяшәеш каршында җинаять!

Сөембикә, Камәрниса карчык белән үз гомерендә беренче мәртәбә саубуллашырга да онытып, өйдән чыгып китте, карчыкның рәхимсез сүзләреннән ераккарак качарга теләгәндәй, берни күрмәгән күзләре белән урам башына атлады. Ашыкты, кабаланды, күкрәгендә йөрәгенең ярсып тибүен ишетте. Ә йөрәге бер генә тавыш белән типте: син гаепле, син гаепле! Син гөнаһлы! Сөембикә беркемне дә хөкем итәргә хакы юклыгын аңлады. Аның Таһир белән Айгөл тормышына да тыкшынырга бернинди хакы юк. Әхнәф тә, Фәһимә дә нәкъ менә Сөембикә аркасында Таһирның тормышын Айгөл белән бәйләүдән тыялардыр. Асылда эш менә шулай тора! Үзе гомер буе эзләп таба алмаган төп хакыйкатьне, ниһаять, ул тулаем аңлап бетерде: беренчел, иң мөһим нәрсә — күңелдәгесе, рух. Калганнары, эш тә, урын да шуннан соң. Ә Сөембикә киресенчә эшләде. Рухи нәрсәләр бөтен яшәешнең дә, үлемнең дә кыйммәтен билгели, синең алга баруыңны яисә артка тәгәрәвеңне дә, югары күтәрелүеңне яисә түбәнгә мәтәлүеңне дә, игелегеңне-игелексезлегеңне дә, көмештәй балкуыңны яисә дегеттәй каралуыңны да бизмәнгә сала. Рух бөтенесен кубарып бәрә, кайчан да булса барыбер үз хакимлеген урнаштыра икән бит, бөтен җиһанның бөек хәрәкәте шуңа корылган, ахрысы...

Ә соң аңа ни кылырга? Кабат күтәрелү өчен нишләп була? Ул үзләренең инде әллә кайчан тигезләнеп, үлән каплап киткән өй нигезенә басты да әнә шул сорауга җавап эзләде. Озак торды Сөембикә, тамак төбенә килгән кайнар яшьләрен йотып бетергәнче торды һәм теге сорауга җавапны тапты: гөнаһларын танырга! Ә кем каршында? Ирек белән Айгөл алдында... Сөембикә моны үлсә дә булдыра алмаячак! Уйлана торгач, ул моны беркем алдында да эшли алмаячагын аңлады. Ул хәлсезләнеп нигез чирәменә тезләнде. Үзен бу җир йөзендә бернинди таянычсыз, япа-ялгыз, иң бәхетсез кеше итеп тойды. Ни өчен, ичмасам, Аллага ышана алмады икән ул? Аның бит әбисе дә, бабасы да гомер буе намазлык өстеннән төшмәделәр, ураза тоттылар, шәригать

билгеләгән югары кануннар белән яшәделәр. Шуңа күрә алар үлемнән дә курыкмадылар, бу якты дөньядан тыныч күңел белән, барлык авылдашлар белән бәхилләшеп китеп бардылар. Сөембикә кайнар күз яшьләре аша күк йөзенә төбәлде, әмма берни дә күрә алмады: югарыда тоташ бер олы кояш, зәңгәр күк тә, болытлар да юк, ялкын төсле тоташ сарылык кына иде.

Кемгә мөрәҗәгать итүен дә белмәстән, телләрен яндыручы утлы күмердәй сүзләрен ул җиһан чоңгылына юллады:

— Гафу итмә мине! Йчмасам, үз гомеремдә бер мәртәбә, бары бер мәртәбә үзем теләгәнне генә эшләргә ирек бир! Бир миңа коточкыч газап! Бир миңа тәмуг уты кебек күпме янса да сүнми торган газапларыңны! Кызганма, бир иң каты җәзаңны! Мин аны күтәрергә әзер! Берүк гафу гына итмә мине! Кичермә мине! Мин аңа лаек түгел!

Ул тынып калды. Үзе сораган җәзаны көткәндәй, башын иеп, тавышсыз гына сулкылдады. Ул елый да алмады, тора да алмады, уйлый да алмады. Сөембикә җиргә беректе. Дөнья каядыр очты, аны калдырып китте. Китте, чөнки Сөембикә аның өметен акламады. Хәзер ул берүзе калды. Ә нигә хәзер генә? Ул бит баштан ук, балачактан ук берүзе. Әйе, утрау кебек. Аңа дәрьялар кагылып үтте, нindидер ләмнәрен сылап калдырды, әмма ул барыбер берүзе булды. Гомер бер генә, аны кабатлап яшәү мөмкин түгел. Соңгы тукталышның кайчан икәнен генә белгән юк...

## 13

Ирек телефон трубкасын алуга, Сөембикәнең кабаланган тавышы ишетелде:

— Тиз генә килеп җит әле!

— Ни булды?

— Булачак! — диде Сөембикә һәм аңа елый-елый энәсеннән җебенә кадәр барысын да сөйләп бирде.

Ирекнең ике чигәсе сулкылдый башлады, гәүдәсенең чайкалганын күреп, Зәнфирә килеп тотмаса, бәлкем, ауган да булыр иде.

— Бер-бер хәл булдымы әллә?

Шактый вакыт сораштыра торгач, Зәнфирә эшнең нәрсәдә икәнен аңлады.

— Йә, ни дип шулкадәр бәргәләнәсең? — диде ул, елмаеп. — Өйләнешү юк нәрсәме? Табигый хәл ич.

— Ни өчен Фәһимә белән Әхнәф малаена?! — диде Ирек, йодрыгы белән өстәлгә сугып. — Ни өчен?!

Зәнфирәнең сүзләрен тыңлап та тормыйча, ул кабаланып чыгып йөгерде. Нидер кылырга, кызын бу ялгыш адымнан туктатырга иде. Ул шуннан башканы белмәде. Йөгерә-атлый олы юлга борылуга, артыннан «уазик» машинасы килеп туктады.

— Әйдәгез, утырыгыз, Ирек Хәйриевич, — диде, машинаның ишеген ачып, Фәнис Сәлахов.

Ирекнең һич тә аның белән очрашасы килмәсә дә, баш тарта алмады. Алар кузгалдылар. Ирекнең чыраеның кара болыт каплаган күк йөзе төсле икәнлеген күргән хәлдә шактый вакыт баргач, Сәлахов:

— Сез мине күрә алмыйсыз инде, — дип куйды.

Ирек бер сүз дә дәшмәде.

— Минем музейга кереп күптәннән икәүдән-икәү сөйләшәсем килеп йөри иде.

— Нәрсә сөйләшмәкче буласыз сез минем белән?

— Без бит бергә идек. Сез инде мине каргыйсыз.

— Минем беркайчан да кеше каргау белән шөгыльләнгәнем юк. Андый түбән эштән Ходай үзе сакласын.

— Сезнең миңа булган мөнәсәбәтегезне күреп йөрим ич. — Сәлахов, машинасының баруын акрынайтып, аңа борылды. — Сезгә кая?

Ирекнең Сөембикәнең капкасы төбендә төшеп каласы килмәде.

— Сөт заводы турында, — диде ул.

— Бик сынап карыйсыз...

— Өйрәнәм. Элекке Сәлахов шушымы икән дип.

— Ник кирәк ул?

— Язучы аламасы бит. Кирәк булуы бар.

— Куркытмакчы буласыз.

— Хакимият кешеләрен астан куркытып буламы инде? Алар өстән төшкән сигналларга гына бик сизгер.

— Сез абсолют хаклы. Ә шулай да күңелне бушатасы килгән иде. Биш минут вакытыгызны кызганмасагыз, машина эчендә булса да тыңлагыз, зинһар.

Ирек килешеп баш какты.

— Фәнис Сәлахов гаделлек өчен җанын да бирергә әзер иде, — дип башлады ул. — Элекке төшенчәләр бетте. Хәзер гаделлек нәрсә ул? Пәрәнҗә ябынган фахишә кебегрәк бер әйбер...

Ирек аңа ялт итеп борылды да:

— Кешеләр шул ук бит, — диде.

— Кеше бармыни әле ул? Сез ялгышасыз. Кешеләр бетте.

Сәлахов шунда читкә таба борылды, машинасының тормозына басты.

— Нигә дәвам итмисез? — диде Ирек.

— Итә алам. Сезгә көрәшүдән туктарга кирәк түгелме икән? Дөньяны үзгәртмәкче буласыз, ләкин барып чыкмаячагы көн кебек ачык. Бөтен Җир шарында бер үк хәл. Аны үзгәртергә без Алла түгел. Хакимияткә каршы көрәшергә азаплануыгыз да стакандагы давыл гына. — Сәлахов машинасын туктатты, чәчләрен сыпырды, як-якка каранды һәм Ireккә борылды: — Хәер, мин бу сүзләрне әйтергә тиеш түгел идем. Мин әйтергә тиешле сүзләр менә бусы: үз урыным өчен соңгы тамчы канымача көрәшәчәкмен! Теләмәсәм дә, көрәшәчәкмен!!! — Аның күзләре яшьләнде, күз кабаклары еш-еш йомыла башлады. — Әнкәйнең өен сатып, үзебезгә алып килдем... Бер районнан икенчесенә куа торгач, ике бүлмәле фатирда торып калдым. Әнкәйдән оялам... Күзендә рәнҗү... Хатынымнан оят! Өч баламнан оят! Башкаларның тормышына төртеп күрсәтәләр. — Ул туктап маңгае белән рульгә ятты һәм шул килеш сүзен дәвам итте: — Менә үземне саттым. Мин — кабахәт... Тик мин эчемнән янам. Мин элекке Фәнис. Ул Фәнис эчендә богаулап ташланган, елап ята... Ичмасам, үлми дә... Эш урыны — зур нәрсә ул, йә яшәү, йә үлем. Нинди көлке! Борынгы кешеләр мамонтны тотканнар да һәркем үзенә тиешлесен умырып алган. Ул аны беркемгә дә бирмәгән. Шуны ашагач, әле ит бетмәгән булса, яңасына үрелгән. Эш урыны — шул калҗа кебек: үз ирке белән беркем дә бирми. Кемгә кисәкнең зуррагы, кемгә бәләкәйрәге. Тешенә, көченә карап. Калҗаны ычкындырсаң, син ачтан үләсең.

— Рәхмәт ачыктан-ачык әйтүегез өчен, — диде Ирек, аның эчендә кайнаган барлык кичерешләрен аңлап.

— Бүтән кешегә булса, бәлкем, алдаштырыр да идем, тик сезнең алда булдыра алмыйм...

Сәлахов машинасыннан төшеп калгач, Ирекнең йөрәге китереп кысты. Урам уртасында күкрәген тотып басып торудан кыенсынды, тирән итеп сулый-сулый, акрын гына алга атлады. Ул килеп кергәндә, Айгөл мендәренә капланып яткан, Сөембикә өстәл янында утыра иде. Ирек аның иңсәсенә кагылды. Кызы, сикереп торып, аны кочып алды.

— Кызым, мин барысын да беләм, — диде ул, аның күзләренә карап.

Айгөлнең озын керфекләренең юешләнеп укмашуыннан, күз агының кызарып торуыннан Ирек аның инде күптәннән яшь түгүен аңлады.

— Мин сиңа бер генә әйбер әйтәм… — Ирек Айгөлнең яңакларыннан тотып йөзен үзенә каратты. — Кызым, без алар белән туганлашып яши алмаячакбыз…

— Әти… әтием! — дип өзгәләнде Айгөл. — Аңласаң, мине син генә аңлый аласың. Син бит пәйгамбәр кебек кеше… Язучы… Без Казанга китәбез. Сезгә дә, аларга да комачауламаячакбыз.

— И кызым! Яшәү ничә көн соң ул? Әгәр күбәләк гомере яшәсәгез, шулай булыр иде. Безгә бит бик озак еллар бергә-бергә тормыш күтәргә туры киләчәк.

— Әти, без берни дә сорамыйбыз. Үзебезчә яшәргә генә телибез.

Ирек аның белән килешмәвен белдереп баш чайкады:

— Укырга да кермәгән килеш, мәктәп стенасыннан чыгу белән кем гаилә кора?

— Үзегез яши алмагансыз. Кем белә, иртәрәк өйләнешкән булсагыз, яшәгән дә булыр идегез. — Айгөлнең йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. — Әллә миңа рәхәт булдымы әтиле килеш әтисез үсүе?!

Ул күз яшьләрен тыя алмыйча чыгып йөгерде. Өйдә тынлык урнашты. Сөембикә әллә елый, әллә нидер сөйләнә — аерырлык түгел иде. Ул башын тоткан килеш үзалдына сулкылдап утыра бирде.

— Әйдә, Әхнәфләр белән сөйләшик, — диде Ирек, ниһаять.

Сөембикә бик озак дәшми торды, аннары акрын гына башын күтәрде.

— Нәрсә сөйләшәбез?

— Белмим. Бер карарга килергә кирәк бит инде…

Сөембикәнең күзләрендә зәһәр очкыннар елтырап китте.

— Әллә бала-чаганың теләгенә башыңны имәкче буласыңмы?!

— Баш ию түгел… уйларга кирәк.

— Фәһимә каршына мәңге барасым юк.

— Ярый, тешемне кысып булса да, мин үзем барырга тырышырмын, — диде Ирек.

Сөембикә мәсхәрәле төстә көлеп җибәрде:

— Ай Алла, әллә егылыплар үлимме?! Бар, кайтып кит, ичмасам! — Ул кинәт ажгырып Ирекнең каршына килде. — Юк аларга кыз! Син үстермәдең, шуңа күрә сиңа барыбер. Мин ни әйтәм — шулай булачак!

Ирек өйдән чыкканда, Айгөл бакчада да, урамда да юк иде инде…

## 14

Ирек аларның ишегалдына кергәндә, Фәһимә коену костюмыннан гына бакчада йөри иде. Аны күрү белән, ул өстенә зәңгәр халатын киеп куйды. Үтә күренмәле бу халат бик кыска, итәге тез өстеннән кул яссуы күтәрелеп тора иде. Алар Әхнәф белән өйләренә килеп киткәннән бирле Ирекнең Фәһимәне күргәне булмады. Ул тәненең уттай кызышуын тойды, ничек итеп сүз башларга да белмичә аптыраудан маңгаендагы яра эзен бармаклары белән сыпыргалады. Ахырда бик авырлык белән генә:

— Әхнәф өйдәме? — дип сорады.

— Әхнәф өйдә юк, — диде Фәһимә, биленә кулын куеп.

— Эшендә туры китерә алмадым, әллә өйдәме дигән идем...

— Аның кайчан өйдә торганы бар соң? — диде Фәһимә һәм чәчәкләргә су сибәргә кереште.

Ирек аңа якынрак килде.

— Балалар турында сөйләшергә иде бит.

Фәһимә су сибүеннән туктады, гаҗәпләнгән карашын аңа төбәде:

— Нинди балалар?

— Айгөл белән Таһир турында. Бер фикергә килергә кирәк бит инде...

Ирек гладиолус, георгин чәчәкләре өстеннән кулын йөртеп алды.

— Бернинди фикергә киләсе юк. Бала-чаганың юләрләнеп йөрүенә юл куярга безнең башыбызга тай типмәгән.

— Алар чигенергә охшамаган...

— Син каян беләсең? — Фәһимә, Ireккә якын килеп, аның борын очына бармагы белән кагылды. — Менә син күкрәгеңнән йөрәгеңне суырып ал да, үзегезнең турга төшеп, Ыкка агызып җибәреп кара әле!

— Яратам дип баласын бәхетсез итүчеләр дә күп тормышта...

— Син башта бала үстереп кара, аннары сөйләрсең!

Фәһимә артларын уйната-уйната бакча түренә атлады...

Ирек, күпме генә баш ватса да, кызын ялгыш адымнан туктатырлык яңа дәлилләр таба алмады. Инде әйтәсе сүзләр әйтелгән, Әхнәфләрнең дә бу өйләнешүгә каршы икәнлекләре билгеле. Иртәдән бирле аның күңелен әллә нинди хафалану биләде. Җанны ашый торган бу халәт аның зиһенен томалады, кул-аягын богаулады. Нindider бик начар нәрсә килеп чыгар кебек тоелды. Сизенүе юкка булмады, өйлә турында елап Сөембикә шылтыратты: Айгөл белән Та-

һир юкка чыккан. Казанда да, туган-тумачаларда да, дусишләрдә дә юк иде алар. Әхнәф кушуы буенча аларны милиция эзләргә керешкте. Бу хәбәрне Ирек башта хатын-кыз чәпчүе кебегрәк кабул итте. Яшьләр табигатьтәдер, барлык җирне дә карап бетереп буламыни дип уйлады. Әмма торабара эченә шик төште: Айгөлнең дә, Таһирның да бу көннәрдә нервылары талкынып бетте, ни булмас? Төрле шомлы уйлар белән көн үтте, кояш батты. Керфек какмыйча төн уздырдылар. Әгәр исән-имин булсалар, бер генә каршы сүз әйтмәм, үзләре теләгәнчә яшәсеннәр, дип, ант сулары эчте Ирек. Иртән ул авызына тәгам ризык капмыйча эшенә китте. Музейда җанына урын таба алмыйча әрле-бирле йөргәндә, телефон шылтырады. Ирек шомланып трубканы алды. Шылтыратучы әнисе иде.

— Алар бездә, — диде ул. — Әле генә килеп керделәр. Тизрәк кайтып җитегез. Сөембикәне дә ал.

Айгөлләрнең исәнлеген ишетү шатлыгын ул шул минутта ук Сөембикә белән уртаклашты, Зәнфирәгә хәбәр итте. Ярты сәгатьтән Зәйнуллин машинасы белән Баллы Төбәккә юл тоттылар. Тып-тын гына кайтып керделәр, салкын гына хәл-әхвәл белештеләр. Айгөл белән Таһир, куркып поскан җәнлектәй, икесе бер почмакта утыра иде.

— Яшьләрнең уен белдем, — диде әниләре, аларга таба ияге белән ишарәләп. — Син ни әйтерсең, улым?

Ирекнең иелгән башы тагын да түбәнрәк салынды. Ул өч кенә сүз пышылдый алды:

— Мәхәббәтләре чын булса...

— Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?! — дип сикереп торды Сөембикә. — Әле үзләре балалыктан чыкмаган килеш... Алар бит харап булачак!

Өйдә тып-тын булып калды. Моңа кадәр үзенең барлыгын да сиздермәгән стена сәгате башка суккандай текелдәве белән бөтен өйне тутырды. Болай да узмаган вакытка ул әллә нинди эчпошыргыч кисәтү өстәде кебек. Бөтенесе дә Гөлҗамалга төбәлде.

Әниләре уртага чыгып басты:

— И балалар, Ирекkәем, Сөембикәм! Нишләпләр бетмәдегез! Нәрсә аркасында? Кызуында сукмаганга. — Әниләре Зәнфирәнең чәчләреннән сыйпап куйды. — Барыбер килен белән кушылдың, улым. Сөембикә килен сыңар канат булып калды... Мин берегезне дә гаепләмим. Гаепне бизмәнгә салып утырудан бәхет артмый. Үлчә-үлчәмә — гомер уза да китә. Балаларга аркылы төшмәгез. Минем сүзем шул...

Бу сүзләрне әйткәндә, әнисе үзенең көйрәп торучы күз-

ләре белән һәркайсының йөзен капшап үтте. Сүзе беткәч, сабыр гына урынына барып утырды. Аңа каршы беркем ләммим авыз ачмады. Бу халәт аларга балачактан ук таныш. Әниләре Ирек белән абыйсының уйларын алдан ук белеп тора һәм, сыңар сүз дә әйтмичә, йә ым ярдәмендә, йә күз карашы белән ул уйларны үзе теләгәнчә үзгәртә иде. Ни каты әтиләре дә, күпме генә карышса да, барыбер әниләрен тыңлый, ирлек горурлыгын, кырыслыгын җиңеп, аның эзенә төшә иде. Шулай итеп, ике төрле уйларга урын калмады.

Машиналарга төялеп, Сөембикәнең өенә кайтып төштеләр. Ул абына-сөртенә чабулап өстәл әзерләде. Әмма ашлар ашалмады, чәйләр эчелмәде — барысы да бер киеренке халәттә, күңеле белән авыр хис кичереп, олы бер сорауга җавап эзләде: Әхнәфләр белән ничек сөйләшергә? Таһир белән Айгөл, өркетеп куып кертелгән җәнлекләрдәй, моңсуланып бер почмакта утыра бирде. Ахырда Ирек Сөембикә янына килде.

— Әйдә, барып сөйләшик, — диде ул, акрын гына.

— Булдыра алмыйм... Әнкәйгә буйсынып кайттык, ә эчемнән һаман ризалаша алмыйм.

— Башка юл юк. — Ирек йомшак кына аның иңбашына кагылды.

Сөембикәнең бөтен тәненнән җылы йөгерде. Күңелендә үткәндәгеләр уянды, күзләре дымланды, үз-үзен кулга алу өчен, утырган урындыгының артын чытырдатып кысты. Ул Ирекнең куллары иңбашында озаграк торуын теләде, сабырлыгы өчен ул кулларны үбәсе килде. Ниһаять, авыр сулап, урыныннан торды һәм нибары бер сүз әйтте:

— Ярар...

Күчтәнәчкә торт, җиләк-җимеш, затлы коньяк алып, Әхнәфләргә юл тоттылар. Барып җитеп, Ирек ишек яңагындагы чылтыравыкка басуга, Әхнәф килеп чыкты. Аларны күргәч, ул каушап китте, сүз әйтә алмыйча, әле берсенә, әле икенчесенә карап торды.

Аннары, үз-үзен кулга алып:

— Әйдәгез, узыгыз, — диде.

Фәһимә кухняда мәшәләнгән җиреннән, кулына сөлге тоткан килеш алар каршына чыгып, салкын гына исәнләште.

— Фәһимә, өстәл әзерлә, — диде Әхнәф, һәм аларны залга кыстады.

Ирек — коньяк белән җимешләрне, Сөембикә тортны өстәлгә куйды да залга үттеләр. Хәл-әхвәл сораштырып, төп мәсьәләгә кагылмыйча гына сөйләшкән арада, Фәһимә аларны өстәл янына чакырды. Табын кайнар өчпочмаклар-

дан, башка нигъмәтләрдән сыгылып тора иде. Бәллүр рюмкалар куелса да, коньяк шешәсенә беркем дә кагылмады.

Ирек хуҗаларның әле берсенә, әле икенчесенә күз ташлап алды да:

— Йә, нишлибез? — диде.

Фәһимә мәсхәрәле елмаеп аның каршына килде:

— Мин дөрес аңласам, сез кызыгызга кияү сорарга килгәнсез? — диде ул.

Әхнәф яшен суккандай сикереп торды:

— Нишләп инде син шулай, Фәһимә... Ошамаганны, — диде ул, тотанакланып.

— Һәрнәрсәнең исемен әйтеп сөйләшергә кирәк. Яшь чакта исәрләнү кемдә булмаган...

— Мин үзем сабыр итү ягында, — диде Әхнәф. — Берберсен сынасыннар. Айгөл укырга керсен, аралашсыннар.

Аның бу сүзләренә Фәһимә ямьсез итеп карап куйды.

— Безнеңчә дә шулай, — диде Ирек. — Тик аларның поезды, үзең әйткәнчә, башка бит, Әхнәф.

— Сезнең икегез өчен дә бала — тәкереп киткән тәкерек кенә ул. Таһирымны мин теләсә кемгә бирмәячәкмен!

Баядан бирле сүзгә кушылмый утырган Сөембикә түзә алмады:

— Синең өчен Таһир мөһим түгел, иң мөһиме — үзең, — диде ул, ярсуын тыя алмыйча.

— Акыллы сүзләр сөйләү өчен акыллы яшәргә кирәк, — диде Фәһимә, аның күзләренә туп-туры карап. — Ике арада ут, сез туганлашу турында сүз алып барасыз.

— Утның булганы юк. — Ирек, ниндидер фикер эзләгәндәй, учы белән маңгаен ышкыды. — Әйе, җайсызрак хәлләр килеп чыккалады... Ә шулай да яхшысы яманнан күбрәк бит. Без барыбер бергә булачак кешеләр... Шулай түгелмени, Әхнәф?

Әхнәф бурлаттай кызарды, ул бер Фәһимәгә, бер Сөембикәгә, бер Ирекка карады, әмма ләм-мим бер сүз әйтмәде.

— Килешмисеңмени? Әллә кисеп ташлар идең?

— Юк... — диде, ниһаять, Әхнәф, карлыккан тавыш белән.

Шуннан соң бүлмәдә тынлык урнашты, һәркайсы үз уена батып утыра бирде.

— Килештекме соң инде? — дип, Ирек астан гына Фәһимәгә карады.

Фәһимә йөзен Әхнәфкә борды.

Әхнәф авыр сулап бер әйләнеп килде дә:

— Үзләре белән кабат сөйләшеп карыйк әле, — диде.

Алар хушлашмыйча гына аерылыштылар.

## 15

Айгөлләр ягының уңайга борылуын күргәннән соң, әтисе белән әнисен бу якка аударуның бары үзеннән генә торуын Таһир яхшы аңлады. Шуңа күрә сүзеннән бер генә мәртәбә дә чигенмәде. Киеренкелек артканнан-артты, мөнәсәбәтләр катлауланды. Соңгы сөйләшүгә ул бик нык уйлап, алдан ук җентекләп әзерләнде.

— Сез миңа тормыш бирдегез, үстердегез, — диде Таһир. — Инде үземчә яшәргә рөхсәт итегез.

— Ә син шуны беләсеңме, улым, — дип каршы төште Әхнәф. — Синең тормышың үзеңнеке генә түгел бит.

— Ничек үземнеке генә түгел?! — Таһир әтисенә аптыраулы караш ташлады. — Ә минеке? Минем өлешем бармы соң?

— Бар, бар! — дип ашыга-кабалана сүзгә кушылды Фәһимә. — Тик калганы безнеңчә булачак. Гомер буе сине кеше итәргә тырышуыбызның нәтиҗәсен күрергә тиештер бит инде без.

— Рәхмәт... — Таһир бик озак уйланды, дәшмичә торды. Аннары, әле генә сискәндереп уятылган кешедәй: — Мин... нәтиҗәмени? Алайса, ник җан бирдегез?! — диде ул, башы белән бәрелергә теләгән кешедәй әрле-бирле укталып. — Мин аннан азат булам хәзер! Тулаем сезнеке булам. Сезнең хакка үз өлешемнән баш тартам!

Таһир шулай диде дә атылып-бәрелеп чыгып йөгерде. Әхнәф белән Фәһимә аның артыннан ташландылар, әмма Таһир ишеккә тышкы яктагы аркылы тимерне төшергән иде. Алар ни кылырга белмичә шашынып калдылар. Әхнәф тәрәзәне ачып тышка сикерде, ишекнең тимерен ачып, Фәһимәне чыгарды. Әчке бер сизенү белән, икәүләшеп сарайга йөгерделәр. Таһир матчага алдан әзерләп куелган элмәкле бавын бәйләп маташа иде. Әхнәф белән Фәһимә аны берьюлы кочакларына алдылар.

Чынында асылыну дигән нәрсә Таһирның уенда да юк иде. Аның үз дигәнен итү өчен уйлап тапкан бу хәйләсе көтелгәнгә караганда да шәбрәк килеп чыкты: әтисе белән әнисе күз яшьләре белән аның алдына тезләнделәр.

* * *

Инде барысы да хәл ителде, борчылырлык берни дә калмады дип тынычлануга, аяз көнне яшен суккандай хәл булды: районга республика Югары Советының хисап па-

латасы вәкилләре килеп төште. Аларны бик хәтәр очракларда гына җибәрәләр. Әхнәфнең күңелен шомлы уйлар биләп алды. Тикшерүчеләр рәхимсез иде, алар табигатькә чыгу, ял итү, күңел ачу дигән нәрсәләрдән катгый баш тарттылар. Көне-төне казына торгач, бик күп нәрсәләр ачылды. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, шушы ут йоткан вакытта Әмир Саттаровның Әхнәф өстеннән президентка хат язуы, депутатлардан хатка кул куйдырып йөрүе, аны алып Казанга китәчәге турындагы хәбәр килеп иреште. Моны ишеткәч, Әхнәф бүлмәсенә Сәлаховтан башка беркемне дә кертмәскә кушты, ишекле-түрле йөрде, бәргәләнде. Саттаров белән сөйләшүнең мәгънәсе булмаячак иде. Бердәнбер таяныч булып Ирек калды. Аны музейдан тиз генә Сәлахов шоферы алып килде. Ирек, Әхнәфнең суырылып калган йөзенә күз ташлау белән, хәлнең үтә дә җитдилеген аңлады. Тикшерү барганын ул ишеткән, тик үзе эчендә кайнамагач, колак очыннан гына уздырган иде. Әхнәфнең дулкынланган чакларда уң күз кабагы тартып куя торган гадәте бар, хәзер дә аның туктаусыз дерт-дерт сикергәләп торуын күреп, Ирек хәйран калды.

Әхнәф, сүзсез генә кул кысышкач, хәл-әхвәл дә сорамады, шундук сүз башлады:

— Барысы да бетте! Рәшәткә! — диде ул, калтыранган иреннәрен ялап. — Синең ярдәм кирәк.

— Ни булды?

— Бар монда хәлләр! Бер яктан, тикшерүчеләр казына, икенче яктан, Әмир Саттаров минем өстән президентка хат алып китәргә йөри, ди. Аны син генә туктата аласың.

Әхнәф, Ирек каршына килеп, ялварулы күзләре белән аңа төбәлде.

— Аны туктату... ай-һай! — дип куйды Ирек, бераз уйлап торгач.

— Туктатырга кирәк — башка юл юк! Якла мине! Саттаров сине тыңлаячак. Күпме акча кирәк? — Әхнәф сейфына таба атлады.

— Юкны сөйләмә! Саттаров акчага сатып алына торган кешеме соң?!

— Алайса, син дә аның белән бергә мине рәшәткә артына тыгарга уйлыйсың?

— Ни сөйлисең син, Әхнәф?! Мин бит инде ул ТИҮ эшләреннән читләштем.

— Беренче ерганакны син ярып җибәрдең! — Әхнәф ачулы кыяфәт белән бармак янап куйды. — Саттаровлар син башлаганны дәвам гына итәләр.

— Тукта әле, нинди рәшәткә сөйлисең соң син? — диде Ирек, аны бүлдереп.

— Тимер рәшәткә! — дип кычкырды Әхнәф елак тавыш белән һәм тәрәзә каршына барып тынып калды.

— Синдәй җитәкчене рәшәткә артына тыгу өчен бик күп кирәк бит ул...

Әхнәф урыныннан кымшанмады, йөзен тәрәзәгә борган килеш, таш сындай басып торды. Кинәт аның гөбедән чыккандай шомлы тавышы ишетелде:

— Әгәр... күп булса?

— Нәрсә?! — Ничек кычкырып җибәрүен дә, аның янына ничек барып җитүен дә сизми калды Ирек.

Әхнәф ишетелер-ишетелмәс тавыш белән дәвам итте:

— Күп шул. Бик күп!.. Әллә ничә рәшәткәгә җитәрлек...

Ирек, үз-үзенә урын таба алмыйча, ишек яныннан әйләнеп килде.

Әхнәфнең күзләренә туп-туры карап:

— Син бит шулкадәр чиста күңелле идең, — диде ул. — Кай арада сазлыкка кереп баттың соң?

Әхнәфнең күзләре дымланды:

— Минем Сусаниным үзем белән янәшә бит... — дип куйды ул.

— Син безнең изге әйберләрне таптап киткәнсең... — Ирек сызланып баш чайкады. — Бик зур чикне үткәнсең. Моны эшләү өчен... мин белмим... ни йөзең белән эшләмәк кирәк?!

Әхнәфнең яшьле күзләрен Ирекнең үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде. Бу берничек тә башка сыймый, моны күңел кабул итә алмый иде. Ул кабаланып читкә китте һәм стена буендагы урындыкларның берсенә барып утырды да куллары белән башын учлады.

— Әйе, мин нык ялгыштым! — дип кычкырды Әхнәф.— Коткар мине! Сөйрәп чыгарыгыз! Миңа бүген исән калырга кирәк. Аннары барлык гөнаһларымны юармын, чәчем белән җир себерермен! Син Саттаровны туктатырга сүз бирәсеңме?

Аны өнсез калып тыңлаган җиреннән Ирек:

— Хәзер эзләп табам, — диде.

— Ялгышымны төзәтерлек көчем бар әле минем. Пычрансам да аякка басарлык көч табармын!..

Әхнәф яныннан чыгып, музейга кергәч, Ирек хәлсезләнеп урындыкка утырды, күзләрен йомды. Бу тормыш мине генә шулай илиме соң, әллә башкаларны да зырый-бырый китерә микән, дип уйлады ул. Менә хәзер дустын, булачак кодасын

яклап, Саттаров каршына барырга кирәк. Әмма аңа бу хурлыклы адымны ясарга туры килмәде. Ул Саттаровны көне буе эзләде, хәтта машина яллап Наратбашка да барып кайтты. Әмма Саттаров беркайда да юк, кайдалыгын хатыны да белми иде. Кичен Ирек бик кәефсез хәлдә арып-талчыгып кайтып керде. Ишекне ачканчы ук борынына әллә нинди тәмле исләр килеп бәрелде. Ул бусаганы аптырабрак атлады, кояштай балкып торучы Зәнфирәне, мул табынны күреп хәйран калды.

— Нәрсә хөрмәтенә бу? — диде ул, төксе генә.

— Ә син башта утыр, аннары әйтермен.

Ирек юынып өстәл янына килеп утыруга, алдындагы китапка текәлеп калды. Ул кабаланып аны кулына алды. Бу аның китабы иде! Ирек китапның битләрен бармаклары белән барлагандай итте дә елмаеп башын күтәрде. Зәнфирә, кайнар беләкләре белән аның муенына сарылып, яңагын яңагына терәде.

— Котлыйм, карткаем!..

— Юк, мин сине котлыйм! — Ирек йөзен аңа таба борды һәм Зәнфирәнең иреннәреннән үбеп алды. — Бу китап бит синеке, син мине коткармаган булсаң, язылa алмый иде ул... Рәхмәт сиңа! — Аннары ушына килеп: — Каян алдың соң син моны? — дип сорады.

— Әхмәт җибәргән.

Зәнфирә аңа Әхмәтнең хатын сузды. Сигнальный экземплярын җибәрәм, икенче китабыңны көтеп калабыз, дип, кыска гына хат язган иде ул. Алар өчен бу кич ничәмәничә еллар буе көткән олы бәйрәм киче булды. Ирек, шатлыгын уртаклашып, абыйсына шылтыратты, Мэлс, иртәгә үк махсус кайтам, юарга бер тартма аракыңны әзерләп куй, дип көлде.

— Кеше үз гомеренә җитәрлек кенә максат куймаска тиеш икән, — диде Ирек, уйланып. — Берничә гомерлек максат белән яшәргә кирәк икән. Шул чакта гына үзеңнең бер гомерлек максатыңа ирешәсеңдер.

— Ә син үзең болай дип язасың бит. — Зәнфирә китапны ачты да укырга кереште: — «Һәр кеше берәү генә түгел, икәү. Икенчесе күктә йолдыз булып яна. Җирдән торып, шул күктәге икенче үзең белән элемтә урнаштыра алсаң, син — иң бәхетле кеше. Аны ничек урнаштырырга? Җиһанны билгән Мәңгелек хакыйкатькә буйсыну сине үз йолдызың, ягъни икенче «мин»еңбелән куша. Син, шул мизгелдән башлап, һәрнәрсәне мәңгелек белән үлчисең, чикләнмәгән куәткә ия буласың һәм, тормышның барлык алдауларын, әшәкелек-

ләрен, ваклыкларын җиңеп, бертуктаусыз рухи биеклекнең яңа офыкларына күтәреләсең...»

— Бу юлларны син яздың, Зәнфирә.

— Юк, син, карткаем...

Бүген аларның бәхетле көне иде.

Төнге уннарда дөнья кубарып телефон шылтырады. Шылтыратучы Әхнәф иде.

— Эш бетте, дустым хәбәр итте. Саттаров хатны бүген илтеп тапшырган инде.

— Президенткамыни?

— Редакциягә. Хат президентка мөрәҗәгать рәвешендә язылган. Мин таң белән Казанга китәм. Теге дус белән редакторга керәбез.

Ирек аңа хәерле юл теләде.

Икенче көнне төштән соң музейга елап-шешенеп беткән Айгөл килеп керде.

— Казанда Әхнәф абыйга инсульт булган! Уң ягы параличланган. — Ул, елавыннан тыела алмыйча, яшьле күзләре белән, тилмереп, Ireккә карады: — Хәзер ни була инде, әти?!

— Тынычлан, кызым, — диде Ирек, аның күз яшьләрен сөртеп. — Һичшиксез тереләчәк ул. Таһир кайда соң әле?

— Ул әнисе белән Казанга больницага китте.

Ирек Айгөлне шактый озак юатты, тынычландырды, ә үзенең күңеленнән тынычлык качты...

## 16

Барысы да төштән башланды. Имеш тә, Миңзаһит Болынкырдагы бакчаларына Рашат белән Эльзаны җитәкләп килеп керә. Алар тугач, һәрберсенә атап утырткан ике алмагач шау чәчәктә утыралар. Тик шунысы сәер, аларның ботаклары, имеш тә, җирдән үк башлана, үзләре җәелеп бергә кушылганнар да ярты бакчаны алып торалар. Рашат белән Эльза, Миңзаһитның кулларыннан ычкынып, шул катыктай алмагач чәчәкләре эченә йөгереп кереп югалалар. Ул балаларына «Чыгыгыз!» дип кычкыра, алмагачларны әйләнеп йөри, аларның шаркылдап көлгән тавышларын ишетә, үзләрен күреп кала. Аны бик озак үртәгәннән соң, балалары парлашып чәчәк арасыннан чыгалар да аңа таба йөгерә башлыйлар. Миңзаһит җиргә чүгәли, балаларының чәчләренә, битләренә, иңбашларына алма чәчәге таҗларының ябышканлыгын күрә, аларны бөтереп кочагына ала...

Сәер төш иде бу. Ул аны башта Хәятка сөйләмәкче бул-

ды да шундук ул ниятеннән кире кайтты. Сөйләве һич тә үз файдасына булмаячагын алдан ук чамалады. Соңгы вакытларда Хәят исеп куйган җилне дә Миңзаһитка каршы борды, әгәр, бүген көн бик матур, кояшлы икән, дисә, хатыны: «Эчең пошадыр, башкаларга әйбәт була бит», — дип, аның авызын йомды. Бөтенләй аларга кагылмаган, ерактагы нәрсә турында сүз чыкса да, Хәят аны ансат кына Миңзаһитка каршы китереп салды. Кичә телевизор караганда, диктор Америка президентының белдерүе турында әйтүгә, Хәят: «Бу да синең кебек бер дивана инде», — дип куйды. Аның белән сөйләшү түгел, хәтта янәшәсендә дә торырлык түгел иде. Баштарак Миңзаһит аны теленә ни туры килә, шуны әйтеп сүкте, алар кым-кырыч килеп талаштылар, хәлдән таеп, ярсып беткәч, һәркайсы үз урынына кереп ятты. Әмма болай яшәп булмый, йөрәк түзмәячәк иде. Миңзаһит өчен бер нәрсә аермачык булып тәгаенләнде: Хәят үзгәрде, аңардан курыкмый башлады. Үтә дә кызып киткән чакларда, ул, аны якасыннан эләктереп: «Буып үтерәм хәзер!» — дип тә карады. Әмма Хәятның йөзенә курку урынына мыскыллы елмаю җәелде: «Үтер!» — дип гыжылдады ул аңа, күзләрен коточкыч ачу белән төбәп. Бу күзләрдә аның Миңзаһиттан өстен икәнлеге, аны буйсындыруы ярылып ята иде. Үзе дә сизмәстән, Миңзаһит хатыны астында калды һәм моннан котылу мөмкин түгел иде.

Ничәдер көн үткәннән соң, ул теге төшне кабат күрде. Аңардан айный алмыйча күпме йөргәнен Миңзаһит хәтерләми. Әмма ләкин беркөнне өеннән чыгып китте. Ник чыгып киткәнлеген соңрак, кибетләрне, базарларны, кафе-рестораннарны, вокзалларны урап чыккач кына аңлады: ул Рашатны эзли икән ләбаса! Әмма бу башка сыя торган хәл түгел иде. Алар өчен Рашаттан котылу үлемнән котылу булды. Аның нәрсәгә кирәге бар? Ләкин ул бернинди максатсыз эзләнеп йөрүен дәвам итте. Аны инде кибет-базарлардагы сатучылар, вокзалдагы таксистлар, контролерлар белеп бетерделәр. Ул ап-ак күлмәктән, галстуктан, кара костюм-чалбардан, күз явын алырлык ялтыратылган туфлиләрдән йөрде. Кайда гына күренсә дә, яхшылап кырынган, хушбуй сибелгән йөзе, чал чәчләре аңа хөрмәт-ихтирам уятты. Ни эзләде соң ул? Газап-михнәтләрнеме, Рашат кулыннан теге дөньяга күчүләренме? Аның болай йөрүләре гайре табигый, бернинди мантыйкка да сыймый иде. Ул аны үзе шулай аңлады, әмма тыела алмады. Шул чакта Хәятның аны тетрәндергән сүзләре хәтеренә төште:

— Мин шушы гомер яшәп, Алланың юклыгына ышан-

дым, — дигән иде ул, чәй эчеп утырганда. — Аның юклыгына мине син ышандырдың. Әгәр ялгышсам, син генә гөнаһлы буласың.

— Шулкадәр олы нәрсәгә мин сине ничек ышандырыйм?!

— Әгәр Алла булса, гомер буе синең мине газаплауларыңа түзеп тора алмас иде, нинди дә булса җәзасын табар иде. Юк ул! — Хәят шулай дип кычкырып ингаляторына тотынды.

Миңзаһит соңгы вакытларда икеләнә башлады: әллә бар микән? Ул Аллага гомер буе ышанмады. Бар микәнни? Шулай булмаса, Рашат аларны шушы кадәр газаплар идеме? Инде аңардан котылдык дип куангач, кабат аны эзләтер идеме? Нindидер көчнең барлыгы бәхәссез. Миңзаһит карыша, атларга теләми, ишек янына барып киенергә керешкәч, кабат борылып кереп ята. Күзләрен йома, берни уйламаска тырыша яки, телевизорны ачып, иң кызыклы тапшыруларны карарга керешә, әмма... Ничә минут үтәдер, телевизорны ничек сүндергәнен, кай арада киенгәнен оныта, ул инде Казанның кеше кайный торган урыннарына омтыла... Нindидер көч аны ашкындыра, эзләтә.

Ул беркөнне Рашатны тапты да кебек. Базарда иде ул, читтә, җыен шпана кайный торган җирдә. Кызыл буяу тигән ертык фуражкадан, сакал-мыек баскан берәү белән Миңзаһитның күзләре очрашты. Буе аныкы, күз карашы аныкы, йөз рәвеше аныкы, алтын тешләре иреннәре арасыннан күренеп кенә калды. Миңзаһит аңа таба атларга теләде, әмма аяклары буйсынмады. Теге көч атлатмады, юри богаулап газаплады кебек. Шул арада бу сәер бәндә юкка да чыкты. Миңзаһит яңадан ничә көннәр буе бу урынны саклады, андагы барлык шмон белән танышып бетте, әмма теге адәмне очрата алмады.

Кичен өйдә телефон шылтырады. Хәят трубканы алды, әмма җавап бирүче юк, аның сулыш алганы гына ишетелә иде.

— Улым, син бит бу! — дип кычкырды ул трубкага. — Бер генә сүз эндәш! Ичмасам, ник бер генә күренмисең?! Вакытсыз үлсеннәр дисеңме?!

Трубканы куйдылар. Мондый хәл элегрәк тә булган иде.

Анысында Миңзаһит сөйләште:

— Шулай шылтырат кына, — диде ул, кабаланып. — Дәшмәсәң дәшмәссең, шылтырат кына, исәнлегеңне генә белик!..

Бервакыт Миңзаһит Матбугат йорты каршындагы урам-

да китап сатучы янында туктап калды. Алар шактый вакыт сөйләшеп торганнан соң, сатучы:

— Ни эзлисең соң син? — дип сорады.

— Юньле китап эзлим, — дип шаяртты Миңзаһит.

— Менә бик әйбәт китап. Мин үзем туктый алмыйча укып чыктым.

— Үтереш, порнография, сексны беләм мин.

— Юк, бу андый түгел, — диде сатучы, аңа зәңгәрсу тышлы китап сузып.

Миңзаһит китапны кулына алып, күзлеген киеп карады да:

— Ирек Сабитов! — дип кычкырып җибәрде.

— Әллә танышыгызмы?

— Шулайрак, — диде Миңзаһит.

Ул тиешле акчасын бирде дә китапны алып читкә китте, шунда ерак булмаган эскәмиягә утырды һәм укырга тотынды. Шуннан соң ул бу дөньядан ычкынды. Караңгы төшкәндә, күзләре күрми башлагач кына туктап калды.

Хәяткa ул китапны алып кайтып күрсәтү олы вакыйга булды. Башта аны Миңзаһит укыды, аннары Хәят ике төн эчендә укып чыкты.

— Дөрес түгел, ялган, арттырылган! — дип чәбәләнде Миңзаһит, китапны икесе дә укып чыккач.

Ул башта, Сабитовны тар-мар итәргә уйлап, мәкалә язарга уйлады, аннары нәшриятның баш редакторына кермәкче булды, әмма Хәят аның бу уйларын бер сүз белән юкка чыгарды:

— Их, Миңзаһит! Монда бит меңнән бере дә язылмаган. Безнең тормышка җиңел караган синең ул Сабитовың. Минем бер генә көнлек кичерешләрне сурәтләсә дә, кешеләрнең тормышка күзләре ачылыр иде.

— Арттырасың, — диде Миңзаһит. — Мин беркайчан да зверь булмадым.

— Фәрештә буласың килгәч, элегрәк уйларга кирәк иде. Һәр адымыңны.

Алар узган гомерләрен актарырга керештеләр.

— Арттырмыйча гына сөйләсәм дә, хәйраннар калырлык бит, — диде Хәят. — Мин шуны уйлыйм: ник аерылышмаганбыз, ник кирәк булган шушындый тормыш. Ул түгелгән көчләрне, йөрәк кайнарлыкларын берәр файдалы эшкә юнәлткән булсак, нәрсә булыр иде икән? Үземә һәйкәл куярлык эш калдырган булыр идем. Ай, ничек юкка исраф ителде зиһен көче, йөрәк тибешләре! Ай, ничек юкка! Һәм моны син эшләдең, Миңзаһит, син! Ник эшләдең син моны?! Шушыңа

җавап бирмәсәң, мин сиңа үлгәндә дә бәхиллек бирмәячәкмен!

Хәятның бу сүзләреннән соң, Арсланов бик озак уйланып йөрде. Көн саен аны Хәят: «Кая җавабың?» — дип кысты.

Ахырда ул беркөнне:

— Син ул җавапка ышанмассың, — диде.

— Шулай да әйт.

— Берни дә уйланмаган, узган да узган, таң аткан да кич булган, матур гына атып утырган чәчәк кебек. Гел шулай мәңге дәвам итәр кебек тоелган. Менә тукталышка килеп җиттек — бүтән барыр җир калмады.

Алар ник яшәделәр? Ни калдырдылар? Бу сорауларның берсенә дә уңай җавап табып булмый иде. Бер уйласаң, ничек инде адәм баласы, җир йөзендә дистәләрчә еллар яшәп, нидер калдырмаска тиеш? Миңзаһиттан ни калды соң? Ул як-ягына каранды: дүрт якта дүрт стенадан башка берни дә юк иде. Үткәннәр дә юк, киләчәк тә юк, аралашыр кешеләр дә юк.

Беркөн кызы Эльза килгәч:

— Ахмакларның — акыллы, кабахәтләрнең фәрештә булып кылануы чиктән аша бара, — диде. — Азагы синеке кебек, менә шушылай бетәчәк...

Кыска һәм рәхимсез карар иде бу. Миңзаһит, һава җитмәгәндәй, форточканы ачып, тәрәзәгә капланды. Күк йөзендә кургаштай авыр болытлар йөзә иде. Алар каядыр агалар, әмма бер генә җире дә ачылмый, шуның бер генә урыны ертылган кебек булды, аның артында нindидер яктылык шәйләнде. Әмма аңа өмет бәләкәй иде...

## 17

Әхнәфне дүрт күз белән көттеләр. Таһир белән Фәһимә больницадан кайтып кермәде. Аны ай ярымнан соң гына алып кайттылар. Ул, култык таякларына таянып, көч-хәл белән генә йөри иде. Авызы ямьсез булып кыегайган, теле тотлыга. Сөйләшә башласа, тыела алмыйча елап җибәрә. Врачлар, авызы урынына кайтачак, аягы да рәтләнәчәк, тотлыгуы да бетәчәк, дип юаттылар. Ул кайтып бераз торгач, туй көне билгеләнде. Исемлек төзелде, чакырулар өләшенде, бүләкләр алынды.

Халык гайбәт казанына салынган бәрәңге кебек кайнады. Имеш тә, Әхнәф урынына Зәнфирә малае Зирәк кайтачак икән, терелгәнен генә көтәләр икән, имеш тә, аның урынбасары Зәйнуллин, теге рәссам хатынга өйләнеп, Казанга китә икән һәм башкалар, һәм башкалар...

Туй мәшәкатьләре белән әвәрә килгән беркөнне Әхнәфләрне генә түгел, бөтен Болынкырны тетрәткән хәл булды. Нәкъ төн уртасында икмәк пешерү комбинатында көчле янгын чыкты. Котырынган җил, утны күрек белән өргәндәй, барлык урыннарга үрләтте, биш-ун минут эчендә комбинат үкереп яна иде инде. Янгын сүндерүчеләр күпме генә тырышсалар да, комбинат тулысынча диярлек көл-күмергә әйләнде. Тикшерү утның төртелүен раслады. Хәтта өч данә бензин канистрына кадәр табылды. Халык аптырашта иде. Әхнәф кенә моның Рашат кулы икәнлеген чамалады. Икмәк комбинатын күптән түгел генә ул үзенә алган иде. Бу хәлләрдән соң ул сөйләшкәндә тагын да ныграк тотлыга башлады...

Таһир белән Айгөл Чаллыга туй кирәк-яраклары юллап базарга бардылар. Шунда Айгөл тораташ катып калды: аның каршысында Айдар басып тора иде. Таһир белән Айдар кул биреп күрештеләр.

— Ни хәлләрдә ятасыз? — диде ул, елмаеп. — Сөембикәнең хәлләре ничек?

— Ул сезне сагына...

— Сагына?! Син шаяртасың, Айгөл.

— Юк, юк, чынлап. — Айгөл керфекләрен аска төшерде. — Сез мине кичерегез, Айдар абый... Мин аңлап бетермәгәнмен.

— Сезнең гаебегез юк.

— Бар! — диде Айгөл. — Мин хәзер генә барысын да аңладым... Сезнең түземлегегезгә... Мин сүз таба алмыйм...

Айгөл мең төрле кичерешләр уртасында бәргәләнде. Моны беркемгә дә әйтә торган, аңлата торган түгел иде. Бу — Айгөлне үзеннән-үзе оялта торган сәер тойгы иде. Ул күңеленең иң ерак почмагына бикләп куелган газаплы уй булып калды. Айдар аларда яши башлагач та, Айгөл әллә нишләде: Айдар абыйсы дәрестә дә, урамда да гел елмаеп аның каршына килде дә басты. Башта Айгөл аны, үги әтисе буларак, шулай күзенә күренә дип уйлады. Аннары, коты очып, моның алай түгеллегенә ышанды. Айдар аның күңеленә ныклап, хәтта Таһирны читкә этеп кереп бара иде! Моны туктату өчен Айгөл, теләмәсә дә, гакылы белән боерып, аңа тупас бәрелде, туктаусыз бәйләнде, йөзен бозды... Сөембикә аның хәлен аңламады, тиргәде, Айдарга каты бәрелмәскә кушты. Айгөл күңеле белән аны иркәли, сөя иде һәм шушы тойгысы өчен үзен иң әшәке бәндә дип сүгә, азгынлыкта гаепли иде. Йә Айдар, йә ул өйдән чыгып китәргә тиеш булып калды. Айгөл Айдарның озын керфекләр белән уратып

алынган күзләренә тыныч кына карый алмады. Әйтерсең лә алардан килгән нур аны исертте, акылын алды. Мондый халәттә ул үзенә баш була алмавын аңлады. Бу — кыз кеше өчен куркыныч, хәвефле халәт иде. Айдарның тигез ак тешләрен әз генә, авызының бер як читеннән генә күрсәтеп елмаюы аны тәмам шаштырды...

Айдар киткәч, күңеле белән бик озак чирләп йөрде Айгөл. Барысы да үтте, менә хәзер ул бәхетле иде. Ул хәзер аңа абый итеп, кирәк булса үги әти итеп карый ала.

— Мин сезнең түземлегегезгә хәйран калам...

— Үткәннәрне онытыйк, — диде Айдар, кечелекле елмаеп. — Сез нинди эш белән соң әле?

Айгөл белән Таһир аңа барысын да сөйләп бирделәр. Алар Айдарны, көнен-сәгатен әйтеп, туйга чакырдылар. Ул Чаллыда квартира алган булып чыкты. «Һичшиксез котларга кайтам», — диде, бәхет теләде.

Туйга өч көн кала, күчтәнәчләр төяп, ак «Жигули»дә кайтып та төште. Ул Таһир белән Айгөлгә кухня телевизоры алып кайткан иде.

Яшьләр чыгып киткәч, алар сүзсез генә бер-берсенә якынлаштылар да:

— Кайтуың өчен рәхмәт, — дип пышылдады Сөембикә. — Син киткән көннән бирле йөрәгемнән кан тамды. Көндез дә, төнлә дә...

— Врачлар күп кенә авыруларны кан агызып дәвалыйлар, — диде Айдар, аның күзләренә туп-туры карап.

— Йөрәктән түгел бит! — дип пышылдады Сөембикә.

Аларның күңел дәрьялары чишелде. Айдар үзенең, әгәр Сөембикә кабул итсә, кайтырга теләге барлыгын белдерде. Сөембикә дә риза иде. Шушы нәрсә ачыкланганнан соң, ул үзләренең авылында сатыла торган ике өй барлыгы турында әйтте.

— Соң, әйдә әйләнеп кайтабыз, — диде Айдар, дәртләнеп. — Табигать кочагында дача йорты булдыру ул минем гомерлек хыялым бит.

Шулай итеп алар авылга китеп бардылар. Өйләрне карагач, Айдар монда кайтырга ризалашты. Ерганак янында яшьләр учак якканнар, гитара, магнитофон акырталар иде. Күршедәге карчык аларның һәрвакыт килүен, акырышуын сөйләп бирде. Сөембикә Айдарны авыл башындагы бөрлегәнлеккә алып китте. Чытырманлыкка кеше аягы басмаган иде. Алар мәмрәп пешкән бөрлегәннәрне банкага җыя башладылар. Айдар, тулышкан эре җимешне алып, Сөембикәнең авызына китерде, кызыл иреннәренә терәде. Сөембикә иреннәрен ачты һәм бөрлегәнне авызына алды. Беркадәр

вакыттан соң ул да, бик эре бөрлегән алып, Айдарның иреннәренә терәде. Әмма ул иреннәрен ачмады.

— Ник ачмыйсың?

— Ризыгым калсын әле, — диде Айдар, көлеп.

Алар кочаклаштылар да йомшак чирәмгә аудылар...

Сөембикә белән Айдар бөрлегәнлектән чыкканда, яшьләр аларның машинасын сырып алган иде.

— О-о, әби, бабай! — дип сикергәләде берсе, аларның каршысына килеп.

— Дай ключ! — дип, Айдарның кулыннан тартты икенчесе.

Айдар ачкычны бирмәгәч, ул аңа селтәнеп җибәрде. Сөембикә шунда хәйран калып тора бирде: Айдар янына килгән егетләрнең һәркайсы очып барып җиргә төштеләр, әйтерсең лә ул ниндидер махсус куелган багана иде. Ахырда алар машинага кереп утырдылар. Берни дә тимәгән кебек күренсә дә, Айдарның уң як яңагыннан кан ага иде. Алар кузгалдылар. Сөембикә бер нәрсәне яхшы аңлады: биредә тыныч тормыш булмаячак. Артка юл юк икән, хәзер бу җирләргә шайтан белсен кемнәр хуҗа.

Айдар бер кич кунды да, иртән чәй эчкәч:

— Миңа кузгалырга вакыт, — диде.

— Ничек?!

— Хәзер сезнең туй мәшәкатьләре башлана.

— Ә син?! Ничек китәсең?!

— Шулай кирәк.

Сөембикә аның күзләренә рәнҗүле карашын ташлады.

— Мин үпкәлим бит, Айдар.

— Син үпкәли алмыйсың, Сөембикә.

— Качасыңмыни?

— Бу качу — сиңа таба качу.

— Аңламыйм, аңларга да теләмим.

— Соңрак аңларсың. Бик теләсәм дә, бу туйда катнаша алмыйм мин. Туйлар узгач, кайтырмын.

Айдар шулай дип китеп барды. Җыйган бөрлегәннәре коштабакта тулып өстәлдә калды...

## 18

Ирекнең күз алдыннан барысы да ташкын кебек үтте: капка төбенә килеп туктаулар, Таһирны өйгә уздырмыйча интектерү хикмәтләре, һәр ишектән үтеп керү мәшәкатьләре, ниһаять, табын янына утырулар, анда әйтелгән матур сүзләр, Айгөлне капка төбеннән озатып калулар — барысы да артта калдылар. Әмма иң авыры алда иде.

Нәкъ ул көткәнчә, Фәһимә шылтыратты:

— Әхнәф туйга барырга теләми...

— Ярый, мин кагылырмын, — диде Ирек.

Ул аларга бер сәгать алдан керде. Аны күрү белән, Әхнәф култык таякларын шапылдатып идәнгә ташлады да кысып кочаклап алды. Ирек юка күлмәк аша аның йөрәгенең очарга талпынган коштай леп-леп ярсып тибүен тойды. Ай-яй, кызу тибә иде ул йөрәк! Ирекнең сулышы тамак төбен яндырып туктап калгандай булды.

— Әхнәф, — диде ул. — Әйдә барыйк. Бергә утырырбыз. Арысаң, кайтарып куярбыз...

Әхнәф кинәт әллә ничек уң кулының учы белән күзләрен каплады да, тынсыз-өнсез калып, башын чайкады. Шул чакта Ирекнең бәгырен әллә нәрсә телеп алды... Аның каршында зәңгәр күзле, шоп-шома йөзле, дулкын-дулкын чәчле яшьлек дусты түгел иде инде. Ирекне тагын бер нәрсә куркытты: Әхнәфнең уң як күзе, пыяла күзне хәтерләтеп, шактый зурайган һәм кабагы ябылып бетмичә кала. Әле беркөн күрешкәндә бу нәрсә юк иде.

— Синсез балаларга кыен булыр бит.

— Ю-ю-к-к, — диде Әхнәф, әллә ничек бытыр-бытыр килеп. — Ми-ми-нем анда уты-уты-рыр-лык эр-эр-эррә-тем юк...

— Син бит гел элеккечә. Юкны сөйләмә, — диде Ирек, аның күңелен күтәрү өчен.

Әхнәф нидер әйтмәкче булды, әмма көчләп кысылган иреннәре җәелеп киттеләр — ул елый башлады. Аның бара алмаслыгын Ирек аңлаган иде инде. Шулчак Мэлс белән Нәфисә килеп керде. Алар Әхнәфне икесе ике яктан кочаклап алдылар, әллә нинди юаткыч сүзләр әйттеләр, әмма ул һәр әйтелгән сүзгә каршы баш чайкау белән җавап кайтарды. Инде кыстауның мәгънәсе калмагач, барысы да җыендылар да бергәләп кузгалдылар. Әмма ишеккә барып җиткәч, Ирек чыгып китә алмады, әйтерсең лә аның каршында таш дивар тора иде. Ул, кабат борылып, Әхнәф янына килде, кулы белән йомшак кына аның иңбашларыннан сөйде һәм, җылы бер эчке тавыш белән:

— Туйдан мин синең яныңа килгәләп торырмын, андагы хәлләрне сөйләрмен, — диде.

Әхнәф янында әнисенең сеңлесе Фатыйма калды. Алар артыннан ишек ябылуга, Әхнәф көч-хәл белән ике адым сөйрәлде дә мунча миче кадәр булып утыручы, һава тутырып кабартылган кәнәфигә чумды, кычкырып елап җибә-

реп Фатыйма тутасын куркытмас өчен, аскы иренен тешләде, ияге дер-дер килде, күзләреннән яшь акты. Шул хәлендә ул менә хәзер башланачак, гөрләячәк туйдан аерылып очты, гомумән, бу тормыштан умырылып, төпсез упкынга очты... Моны туктату инде хәзер беркемнең дә кулыннан килмәячәк иде. Тормышның әллә нинди тирән, баш җитмәс буталчык чоңгылларын үз гомерендә күп мәртәбәләр исән-сау кичеп чыкты Әхнәф. Һәм менә барысы да үз урынына утырды дигәч, типтигез болын уртасына чыккач, үз-үзен югалтты. Чәчәк, нектар исләренә исерде, гүзәллекләр алдында тезләнде, күз явыңны алырлык аллыгөлле булып балкучы ялтыравыкларга үрелде, тагын әллә нинди кызыктыргыч-ымсындыргыч шалтыравык-челтерәвекләргә сузылды.

Әхнәф күзләрен ачты. Күрше бүлмәдә Фатыйма тутасының шылтыр-шылтыр китереп җеп ураганы ишетелә, ул орчыкны калай бадьянга куя да зыр-зыр әйләндерә. Әхнәф Ирекнең баягы кул җылысын кабат иңбашларында тойды һәм упкынга очуыннан тукталгандай булды. Күзләрен ачып, шактый уйланып утырды. Бу җир йөзендә иң якын кешесе Ирек кенә икәнлеген, ничә еллар буе кире кагып килеп, шуның хаклыгына ул менә хәзер кабат ышанды. Аның җылы кулларына гына таянып була икән. Юк, упкыннан коткарсын өчен түгел, бары аңласын өчен. Моңа кадәр дә ул Әхнәфне аңлады, киләчәктә дә аңлаячак. Димәк, Әхнәфне яратучы да ул гына. Бу дөньяда иң олы байлыгы, иң кадерле кешесе булып Ирек кенә калды. Бүген килеп кергәндә, ул Ирекнең йөзендәге эчке сызлануны бер карауга ук күреп алды. Бу сызлануның үзе өчен борчылудан икәнлеген яхшы тойды. Ирек эчке газабын елмаюы белән яшерергә теләде, шуны эшләргә тырышудан аның бөтен гәүдәсе киергедәй тартылды. Әхнәфне аудармау, аны аякта тоту өчен булган бу елмаюы бөтен йөзенә җәелде. Әхнәф аңа моның өчен эченнән генә рәхмәт укыды, аның ни дәрәҗәдә якын икәнлеген тойды. Ирекне бары тик күзләре генә саттылар: алар елмая алмады, алардагы эчке сызлану үзгәрешсез калды... Тик аны моның өчен гаепләп булмый иде. Дустының шушы коточкыч тырышлыгы белән тудырылган ихлас халәтенең Әхнәф үзенең җанына,канына эреп керүен, адәм баласы күтәрә алмаслык, үзе өчен җәһәннәм газапларына тиң шушы минутларда гөрселдәп авудан, ә бәлкем, йөрәге ярылып үлүдән дә саклап калгандыр.

Фәһимә дә шунда иде, ул да кунаклар белән бергә ишектән чыгып китте, тик аның йөзендәге тынычлык Әхнәфнең йөрәген парә-парә телгәләде. Больницада ятканда, Фәһимә аның янына беренче мәртәбә килгәч тә, йөзендәге хис-тойгылар үзләре генә дә икенче инсульт алырлык иде. Аның эчендә Әхнәфнең үзе өчен авыр йөк булуыннан курку кайный һәм болар тып-тын караңгы төндә бернинди күкрәүсез уйнап торган аҗагандай, аның йөзендә туктаусыз уйнап торалар, ул аларны берничек тә яшерә алмый, күрәсең, яшерергә теләми дә иде. Әхнәф күпме генә эзләсә дә, аның йөз чалымнарыннан, күзләреннән һич югы кызгану чаткысы таба алмады. Әхнәф хәзер аңа бөтенләй кирәк түгел иде! Фәһимә аңа күптән чыгарып атасы иске җиһазга карагандай карады. Тик үзенә булгач, картлар йортыныкы ярамый, үтә дә затлысы, бөтен кешенекеннән дә матуррагы, шул ук вакытта шыгырдамастай ныклысы, бик озак искермәстәе кирәк иде...

Моның шулай икәнлеген Әхнәф больницадан кайтканнан соң бигрәк тә нык аңлады. Хатынына аның авыр йөк икәнлеге бәхәссез иде. Аның үзенә дә Фәһимә һич тә кирәкми һәм инде күптән кирәкми. Ләкин бөтен фаҗига хәзер аның Фәһимәдән башка яши алмавында, шуның кулына калуында, тилмереп аның күзенә карап торуында. Шул яратмаган хатыны, авырыксынуын булдыра алган кадәр йотып, йотып бетерә алмаганын йөзендә, кискен, тупас хәрәкәтләрендә сиздерә-сиздерә, аны мунча кертә, ваннада юындыра. Шул яратмаган Фәһимәне бер кулы белән иңнәреннән кочып, икенчесе белән култык таягына таянып, Әхнәф өйдән ишегалдында утырырга чыгарга, күпмедер вакыттан соң шул рәвешле кабат өйгә керергә мәҗбүр. Өйнең беренче катыннан икенчесенә менү дә, икенче каттан беренчесенә төшү дә яратмаган Фәһимә җилкәсендә. Өченче катка Казаннан кайткан вакытларында Таһир гына менә. Ник кирәк булган бу икенче, өченче катлар? Беренчесендә дә буш бүлмәнең саны юк. Бер катлы дип башлаганнар иде, Фәһимә тырыша-тырмаша торгач, өчкә күтәрде. Менә хәзер үзе җәфа чигә. Хәер, җәфа чигә микән? Шоферы Сәгыйрь белән алар бер арбага мичәлгән пар атлар кебек. Ул килгәч, Әхнәфне икесе ике яктан эләктереп, җилпеп кенә йөртәләр. Ишегалдындагы иске кәнәфигә ничек чыгып утырганын да сизми кала. Әхнәф икенче катта булса — астан, ишегалдында утырса — тәрәзә аша аларның туктаусыз нидер сайрашканын, көлеш-

кәнен ишетеп тора. Ул Сәгыйрьне күралмый, Фәһимәне күралмый, көлешүләренә җене котыра, килеп тәненә кагылуларына, икесен дә буып атардай була. Шулай ярсып, үзен-үзе кая куярга белмәгән чакларында, әнисенең сүзләре хәтеренә килә дә төшә. Шушы йортның барлык урыннарын күрсәтеп чыккач, Әхнәф аны үзләре янына торырга чакырды. «Аллам сакласын! — дип, шундук каршы төште әнисе. — Бу бит өй түгел, шайтан оясы, улым!» — «Ничек алай булсын инде, әни?!» — «Мин үземнең өемдә чәй эчеп утырганда, рәхәтләнеп тәрәзә төбемдәге гөлләремне сыпырам, шулар белән сөйләшәм, — дип дәвам итте әнисе. — Өй зурайган саен, аңа җен-пәриләр тула. Буш бүлмәгез бар икән, белеп торыгыз: ул — шайтан оясы! Буш бүлмәсе күп йортта яшәүчеләрнең тормышларын кара син! Тыштан ялтырый, эчтән калтырый. Без бәләкәй генә агач өйдә унбер җан гомер кичердек. Шунда бозау, каз-үрдәк, бәрәннәр. Элекке кешеләр нишләп җен-пәри күргән дип беләсез сез? Алар җаныбызга керә алмаганга. Өйгә аяк басуга, без аларны күреп ала идек. Без терәлешеп, бер-беребезнең күңел җылысын алып яшәдек. Ә сезнең әйләнә-тирәгездә дә, җаннарыгызда да бушлык, шул бушлыкта шайтан котыра, күңелләрегезне шулар бутый...» Әнисе хаклы булып чыкты, ахрысы. Фәһимә белән икесенең өстенә өченче шайтан — шофер Сәгыйрь килеп кушылды. Ул хәзер өйнең беренче катында да, өченчесендә дә чын хуҗа кебек йөри...

Әхнәфнең зиһене үткен, хәтта авырганчыга кадәргедән дә үткенрәк иде. Хәзер исә шул үткенлек өстенә ачы рәнҗеш, үкенү, рәхимсезлек өстәлде. Хәзер ул үзен үткен борау кебек һәрнәрсәнең төбенә төшәргә тырышу белән газаплады, йөрәген туктаусыз тырнады, кан саркып торган күңел ярасына учлап тоз сипте. Бу тормыштан, гомерен багышлаган олы мәгънәви эшләрдән аерылып билгесезлек упкынына очу фаҗигасен ул бары тик үзен-үзе җәзалап кына җиңә иде.

Әхнәф авыр сулап урыныннан торды, култык таякларына таянды. Йөгереп чыккан Фатыйма тутасын, берни дә кирәкми, дип, кабат орчыгы янына куды. Ул көзге каршына килде. Чырае көл төсенә кергән, соңгы чәчләре дә агарган әнә. Күз тирәләре шешмәкләнеп тора. Иреннәре, ямьсез булып тартылып, сул якка күтәрелгәннәр. Алар йомылып бетә алмаганлыктан, ике теше күренеп тора, ирен почмагында төкереге ялтырый. Өченче көн уң як күзенә дә әллә ни булды. Хак әйтәләр: берәүнең ашы сыек, икенче берәүнең авызы кыек.

Искәрмәстән туа проблема. Әле кайчан гына аның авызы туры, аяклары йөри иде.

Әхнәф кабат кәнәфиенә барып утырды. Ә шулай да инсульт алырга тиеш идеме соң ул? Йөрәге бик нык борчыган чакларда, Казан больницасына кереп яткалады, тик беркайчан да дәвалау курсын алып бетермәде, вакытыннан алда чыгып ычкынды. Хаста җитәкчене сөймиләр, әнә Шакировны, җитди чире беленгәч, депутат та итмәделәр. Авырсаң, син бу машинадан алып ташланасың, урыныңа өр-яңа шестерня куялар. Машина дистә еллар буе, бер генә секундка да акрынаймыйча, дөбер-шатыр әйләнә, туктап тын алу түгел, артка борылып карарга да вакыт тими. Шуның өстенә коттедж — менә бу шайтан оясы. Алары да кирәк булгандыр инде. Башка җитәкчеләр ничек, ул да шулай. Җыен карга арасында чәүкә булып кала алмыйсың.

Инсульт сугар алдыннан, иртәгә Казанга китәм дигән көнне очрашкач, Ирекнең әйткән сүзләре менә хәзер күпме вакытлар Әхнәфнең күңелендә утлы энә кебек бөтерелә: «Чикне үтеп чыгу...» Тормышны тотучы изге нәрсәләрне ата-бабалар сабый чактан ук маңгайга кашык белән сугып та, сыек чыбык, кычыткан тәмен татытып та, башкача да сеңдерделәр. Аннары шул ук нәрсәләрне пионер, комсомол, партия корыч кыршаулар белән ныгытты. Аларны какшату мөмкин түгел иде кебек. Әхнәфнең күңеле хәзер дә пакь ич. Ул беркайчан да кешеләр башыннан йөрмәде, аның ашкын йөрәге дә, уй-омтылышлары да гел зур нәрсәгә — яшәүне матуррак, яктырак итүгә омтылды. Юк, Әхнәф беркайчан да үз бәхете турында уйламады. Ашкын яшьлекнең тылсымлы көннәре һәм төннәре дә, аннан соңгы җитлегү еллары да бер утта — халык өчен дип дөрләп янды. Районның бер чигеннән икенче чигенәчә, бер офыктан икенче офыккача җәелгән хезмәт кырында ул гомерлек эш аты булды. Әлеге кырның өй урыны кадәр генә җирендә аның шәхси кишәрлеге бар иде. Аны зурайту Әхнәфнең исенә дә кереп карамады. Ә ул сиздермичә генә киңәйгән, киңәю генә түгел, бер-бер артлы көшелләр дә калыккан. Көшелләр шулкадәр үскәннәр, ул эш аты булып җигелгән кырның барлык почмакларыннан да күренеп торырлык дәрәҗәдә биегәйгәннәр. Канәгатьсезлеккә охшаш тойгы уята бу, сагайта. Гөнаһ та түгел кебек үзе. Кишәрлекнең чиге дә, чамасыз җәелә торгач, югала ук язган... Тик Әхнәфнең монда катнашы юк! Дөрес, күрмәмешкә салышты... Дәшмәде... Тук-

татмады... Аннары бик үтенеп сорагач, нәрсәгәдер рөхсәт бирде... Тора-бара икенчесенә дә рөхсәт бирде, өченчесенә... Берни дә сизелмәде, тормыш үз көенә тыныч кына акты. Әкырда эшләре гөрләде, аны мактадылар. Һәммәсе үз урынында. Өмет-хыяллар тагын да яктырак. Хакыйкать тә иң югары биеклектә. Дуслар да күп. Эш аты буларак тарткан йөге бермә-бер зурайса, авырайса да, Әхнәф аны яшь чактагыдан да ныграк куәт белән сөйрәде. Шушы бүгенге рәхәт, бүгенге ләззәтле тормыш дәвам гына итсен...

Әмма һич көтмәгәндә бөтенесенең асты өскә килде. Нишләп, ни сәбәпле аның кояшын аяз көнне яшен сукты?! Кайчан башланды соң бу? Төптән уйлап карасаң, Ирек хаклы бит. Чыннан да чикне атлап чыгылган. Кайчан? Бу сорау аңа торган саен аяусызрак һөҗүм итте.

Әхнәф авыр сулап тагын көзге каршына килде. Аның маңгае уртасыннан буеннан-буена тирән җыерчык уза. Ул култык таягын җайлабрак куйды һәм шул җыерчыкны бармаклары белән сыпырырга керешге һәм «Нәрсәне икегә аерасың соң син?» диярге теләде. Әмма авызы ямьсез булып чалшайды да ул кабаланып читкә борылды. Әлеге уттай сорауга җавап, бәлкем, күңеленең берәр ерак почмагында яшерелгәндер? Тормыш мең төрле капма-каршы сыйфатлары белән һәркемне, үзенчә әвәләп, кайнар миченә ата, көйдерә-көйдерә пешерә, аннан чыкканда, бөтенләй танымаслык та итә. Тик Әхнәф үзен андыйлар рәтенә кертә алмый. Ул узган гомеренең әле бер чорын, әле икенчесен, көзгедән карагандай, хәтереннән уздырырга тотынды. Әмма соравына җавап таба алмады. Көннәр, айлар, еллар, вакыйгалар, шатлык-борчулар җилдәй искән дә искән, дәрья суларыдай аккан да аккан. Эчеп исергән кешегә берни кирәкми, бөтенесе җитеш, ул ләззәт томанында тирбәлә, аның дөньяга сизгерлеге югала. Алайса, ап-ачык сорауга, күпме вакытлар җавап эзләп тә таба алмагач, тормышның иң зур өлеше эчмәгән килеш бүтән төрле исереклек белән үтте микәнни?! «Тукта, Әхнәф!» — диде ул шунда үз-үзенә. Аның зиһене ачылып китте. Баш катырган сорауга җавап табыла бугай. Күрмәмешкә салышу... Ризалашу... Рөхсәт итү... Менә кайда ул хәтәр борылыш! Бер күзәнәктән башланган хәтәр яман шешкә ул бармагы белән килеп төртелгәндәй булды.

...Районны җитәкли башлаган дәверләр. Очынып йөргән чаклар. Кул урынында канатлар. Алар икәү генә түгел, егермедер. Әхнәф бик югары күтәрелде, әллә кая, йолдызлар-

дан да биегрәккә атылды. Әнә шул чакта, коточкыч биеклеккә иңгәч, як-ягыңа карауның, гамәлләрен үлчәүнең кирәге калмады. Бик кыска арада эчке пружина йомшады. Аңа барысы да, кояшка туры караган кебек, каш өстенә кулларын куеп, күзләрен кысып карадылар. Ә бит ул йолдызлар биеклегенә сикергәнгә кадәрге тормышында иманыннан, ата-бабалары инандырган юлдан тайпылмас өчен, үзенә иң югары таләпләр куеп яшәде. Ул таләпләрне һәр көн күз уңында тотты, шулар буенча гына эш-гамәлләр кылды. Ә кояш булып алгач, һәр көн вакытында чыгып, хезмәт кырын яктырткач, җылыткач, аңарда бернинди таплар булуы мөмкин түгел иде. Менә Әхнәф теге хәтәр адымның ясалу урынына, ниһаять, барып чыкты. Кеше биектә туа, туу белән түбән тәгәри башлый. Шундый сәер канунга корылган бу яшәеш дигән нәрсә. Түбән тәгәрәүне туктату өчен, адәм баласы гомере буе, көн саен үҗәтләнеп тырышмаса, упкын читенә килеп җиткәнен сизми дә кала икән...

Әхнәфнең бар дөньяга ишетелерлек итеп, күкләрне чатнатырлык итеп кычкырасы, «Зинһар, мине упкынга очудан туктатыгыз!!!» дип оран саласы килде. Әмма ни аяныч, инде туктау өчен беркая да якорь ташлап булмый иде... Ул, җанына урын таба алмыйча, тагын көзге каршына килде. Тураермы бу авыз? Ныклап йөреп китәрме бу аяклар? Тутасының чүәкләрен лаштыр-лоштыр сөйрәп атлап килгәне ишетелде.

— Әхнәф, берәр нәрсә кирәк түгелдер бит?

— Юк, түти, рәхмәт, — диде ул, аңа борылып.

— Алайса, мин бройлер чебиләренең ашарларына салып кына керим әле.

Тутасының бу сүзләре Әхнәфкә юри әйтелгәндәй тоелды, йөрәге чәнчешеп куйды. Ул хәлсезләнеп кәнәфиенә барып утырды. Ничә көннәр буена ишегалдында шул мәхлукларны күзәтә торгач, ул аларны үзеннән өстенрәк дип тапты. Чебиләр барысы да диярлек аксаклыйлар, аксакласалар да, йөгерәләр. Ә менә ул култык таякларына таянып та көчкә йөри. Әхнәфнең аларга үз гомерендә бер мәртәбә дә күз төшереп караганы юк иде. Туктаусыз тыгынуларына хәйран калды. Чебиләр өреп кабарткандай күперәләр, көч-хәл белән ауман-тәүмән атлыйлар. Берничәсе тәгәрәп үлгәч, Фәһимә районның баш ветврачын чакыртты. «Күп ашаудан аларның бавыры таркала, — дип аңлатты ветврач. — Аяклары гәүдә авырлыгына түзә алмыйча имгәнә. Йомыр-

кадан чыгуга, ай үсәсен көн үстерү өчен, чебиләрне төрле препаратлар, ясалма ризыклар белән туйдыралар. Бавыр, табигый булмаган бу коточкыч йөкне күтәрә алмыйча, тузып мунчалага әйләнә. Ә чеби ашый да ашый. Инерция буенча...»

Әхнәф йокымсырап китте, бер генә мизгелдә төшләнеп алды һәм сискәнеп уянды. Төшендә әллә нинди гыйфриттәй зур бройлер күрде. Күз ачып йомган арада аның гәүдәсе кабырчык белән капланды, муены болытларгача сузылды, коточкыч зур авызында ул шатыр-шотыр китереп нидер чәйнәде дә, кояшка үрелеп, аңа очлы тешләрен батырды... «Динозавр!» дип уйларга өлгерде Әхнәф. Уянгач, ул бу саташудан үзенчә мәгънә эзләде. Динозаврлар миллион еллар элек җирдә яшәп юкка чыкканнар. Ясалма рәвештә барлыкка китерелгән бройлерлар алардан ничек аерыла? Ә Әхнәф үзе? Аны да кемнәрдер ясады, кояш итеп күтәрде түгелме соң? Мутантлар, клоннар, тагын әллә ниләр... Ясалма җан ияләре, ясалма гамәлләр, ясалма хис-тойгылар... Ясалма ризыкларга күчеп, кешелек үзе дә бройлер кебек симерә бара. «Тфү» дип төкереп куйды Әхнәф. Ясины чыгылган, язмышы хәл ителгән, бройлерлар, динозаврлар гына җитмәгән иде. Тычкан, тишегенә сыймаса, койрыгына тукмак тагар, дип хак әйтәләр, ахрысы. Хәзер аңа хурлыгыннан мамык җебе белән әремгә асылынырга гына иде югыйсә...

## 19

«Таң йолдызы» кафесы каршысындагы машиналарның санына чыкмалы түгел. Алар килә тора, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан кунаклар бинаның икенче катына күтәрелә бара. Ирекләр дә бергәләп туй залына үттеләр. Биредә җирен-күген тоташ шатлык алган. Елмаеп-көлеп күрешүчеләр, ай-кояштай балкучы йөзләр, төркем-төркем булып әңгәмә коручылар, куллардагы, өстәлләрдәге күзнең явын алырлык аллы-гөлле чәчәкләрдән таралган хуш исләр, табындагы авыз суларыңны китерерлек ризык-нигъмәтләр, стена-түшәмнәргә асылган шарлар, көмеш люстралардан түгелүче нурлар, колакларны иркәләүче ягымлы музыка, күзгә чагылып-чагылып кына алган тагын әллә нәрсәләр — һәммәсе дә бер могҗиза булып берләшеп, башларны әйләндереп, исертеп җибәрделәр. Айгөл белән Таһир, кояштай балкып, аларны каршы алдылар, берәм-берәм кочаклап үптеләр,

рәхмәтләр укыдылар, йөзләреннән ташып торган бәхет нурлары белән коендырдылар. Кызының Зәнфирәне кысып кочаклавын, аның колагына пышылдап ниләрдер әйтүен, шактый вакыт яңагын Зәнфирәнең яңагына терәп торуын Ирек тын да алмыйча күзәтте, шул чакта бөтен тәнен рәхәтләндереп җылы агым йөгереп узды... Аннары башкалар белән күрешеп-тәбрикләшүләр китте, хисләр хискә, уйлар уйга сарылды, гүя һәрбарчасын бер дәү сихри каекта җырлы-моңлы дулкын талгын гына тибрәтергә кереште. Зал ай-кояштай йөзләрдән балкый, эчкерсез күрешүләрдән күңелләргә мөлдерәп тулган шатлык хисләреннән, колакны иркәләүче әңгәмәләрдән гөрләп, корт иледәй гөжләп тора. Бөтен җирдән гөлләр тама, сихри нурлар коела, мәхәббәткә мәдхияләр укыла, бәхет җырлары яңгырый. Ireккә могҗизалы бер төш кенә күрәдер кебек тә тоела, аннары тагын моның чынлыгына ышана. Бу, әнисе әйтмешли, бисмиллалы көн, күңелләрне җилкендергеч ак җәймәле көн, бәхеткә мәңгелек сәфәрнең башы бу. Аны Ирекләрнең үткән гомерләре, үткән еллары юлдаш булып озата бара... Бәхетле, тылсымлы, җырлы бу ыгы-зыгы мәңге дәвам итәр кебек.

...Ирек үзе дә, үзе дә түгел иде, ул бәхет-шатлыктан исереп елмайды да елмайды. Тәне изрәсә дә, зиһене торган саен ачыла, кайнарлана барды һәм туктаусыз бер нәрсәне искәртте: гомерләрнең яңа дәвере башлана! Ул, шуны әйтмәкче булып, Зәнфирәгә карый, хатыны Ирекнең ни әйтергә теләгәнен аңлый, күзләреннән очкын сирпеп елмая. Ирек аның энҗедәй тезелгән тешләренә, чем-кара чәчләренә карап соклана, кешеләргә нидер эшләргә әзер торучы, үзен коткарып калган бу изге җанның кайгыртучан кулларын йомшак кына учына ала, үбәргә әзерләнеп, өскә күтәрә башлый, әмма Зәнфирәнең куллары карыша, шунда алар күзгә-күз төбәп сүзсез генә аңлашалар, бу гамәлнең башкаларга кылану булып күренәчәген сизеп, тыелалар, әмма ярты юлда өзелгән бу үбүнең кайнарлыгын, ихласлыгын икесе дә тоялар һәм ул чынга ашмый калуы белән тагын да татлырак, кадерлерәк булып хәтерләрендә сурәтләнеп кала.

Өстәлләрдә чәчәкләр артканнан-арта бара. Аларның ак, кызыл, зәңгәр, ал, шәмәхә, күгелҗем, тагын әллә нинди күз камаштыргыч төсләре сихри нурлар белән каелган парчаны хәтерләтәләр, ул парчадан таралган хуш исләр залда тагын музыка белән бергә рәшәдәй тетрәп тора. Менә кемнәрдер аларга ап-ак лаләгөлләр китерде. Ирек белән Зәнфирә, яңак-

ларны яңакка куеп, йөзләре белән шул чәчәкләргә терәлделәр. Лаләгөлләрнең салкынча таҗлары аларның иреннәрен, битләрен, маңгайларын иркәләде.

— Кар исе килә, — диде Зәнфирә, шыпырт кына.

— Ник икәнен әйтимме соң?

Алар йөзләрен лаләгөлләр арасыннан алдылар да бераз кунаклардан читкәрәк киттеләр.

— Ни өчен?

— Бу ак чәчәкләр кайчандыр өзелеп калган бәхетебезне искәртәләр... — Ирекнең бу сүзләреннән Зәнфирәнең озын керфекләре сискәнгәндәй дерелдәп куйды. — Хәтерлисеңме теге Яңа ел төнен? Мамык карлар яуган тылсымлы кич, чуар кар пәрдәсе аша чабучы кыңгыраулы пар атлар, яшел чыршылар, гирляндалар. Ак моң булып кунган кар бөртекләре... Мин сине карлы авызым белән үпкән идем... Әхнәфләр белән Яңа ел каршыладык... Әмма... — Ирек туктап калды, Зәнфирәнең күзләре дымланганын күреп, сүзен ашыктырды: — Без шунда өзелеп калганны дәвам итәбез. Бүген — ак кояшлы шул Яңа елыбызның дәвамы...

— Чыннан да, — дип кушылды Зәнфирә. — Бу ак чәчәкләр шул чактагы хыялыбызга охшашлар...

— Яңа еллар, үткән еллар офыгына бәрелеп, киләчәккә кайтаваз булып яңгырыйлар. Без бүген яңа вакыт бусагасын атлап чыгабыз... — Ирекнең сүзләрен бүлеп, тагын килеп күрештеләр, Зәнфирәнең кулларына алсу гладиолуслар тоттырдылар. — Газап-әрнүләребез калсын иде...

— Хәерле кич!

Аларны уртак фикер агышыннан бүленергә мәҗбүр итүче бу тавыш Сөембикәнеке иде. Ул яшәреп киткән, битләре алланып тора, иреннәренә елмаю элengән, кулында кызыл канәфер чәчәкләре. Зәнфирә аны кочаклап алды, аннары алар бер-берсенә мондый вакытта әйтелә торган мактау сүзләре әйтештеләр. Ирекне аларның ихласлыгы, кунаклар алдында сынатмаулары куандырды, моның өчен ул аларның икесенә дә рәхмәт укыды. Шунда Сөембикә капыл гына Ирекка борылды һәм алар шактый вакыт күзләрен магнитлангандай бер-берсеннән ала алмыйча тордылар. Моны Зәнфирә дә, башкалар да ачык күрде. Аларның күз карашларына ифрат та күп нәрсә сыйган иде... Ирекнең Сөембикәне иңбашларыннан иркәлисе килде. Ул да бу дөньяның бәхет өчен яратылган бер баласы ич. Бәхетне татып карау, аңа ия булу өчен ул да үзенчә тырышты, әмма тормыш дулкыны аны гел

читкә какты, әрнүле юшкыннар гына калдырды. Ничек кенә булмасын, алар бу якты дөньяга Айгөлне бирделәр, аны Сөембикә ялгызы үстерде, кеше итте.

Алар янына ике кулына да дәлия чәчәкләре бәйләме тоткан Фәһимә килеп туктады.

Ул, бәйләмнең зурысын Сөембикәгә сузып:

— Балаларның да, үзебезнең дә шушы чәчәкләр кебек матур яшәве өчен! — диде.

Елмаюында күпмедер көчәнү сизелсә дә, бу аның тарафыннан эшләнгән олы игелек буларак кабул ителде. Барысы да аны хуплауларын белдерделәр, рәхмәтләр укыдылар. Әллә кай арада килеп чыккан Зирәк аларның дүртесен бергә фотога да төшереп алды. Ирекнең Фәһимәгә ниндидер ягымлы сүзләр әйтәсе килде, ләкин андый сүзләр таба алмады. Әхнәфләр белән ике арадагы дуслык җепләренең өзелүе, ике якның да бер-берсен гаепләүләре соңгы елларда Ирек өчен йөрәгеннән кан саркыткан авыр җәза булды. Менә бит язмыш ике якның тормышын аерып җимерелгән күперне кабат ялгау өчен аларның балаларын якынайтты, шушы гаделсезлекне бетерүне аларга йөкләде, ахрысы. Барысы өчен дә яшәүнең яңа дәвере башлана! Ничек кенә булмасын, яшәешнең узганы да, бүгенгесе дә әрнү-сызлануларына, бәргәләнүләренә дә карамастан, искиткеч матур, татлы һәм кадерле!

Ирекләр ашыгу-кабалану заманына туры килделәр. Аларга хыялда көйрәүче офыклар бик якын тоелды. Алар хыялланганнарына тизрәк барып җитү өчен ашкындылар, вакыт-вакыт аяусыз кыландылар, усалландылар, вакландылар, эш-гамәлләрен биектән торып бәяли алмадылар. Хыялый офыклары җирдән күтәрелмәде, үзләре дә җәйге рәшә кебек гел җиргә ятып йөгерделәр, җирнең ис-тәмнәрен тойдылар, шуңа канәгать иделәр.

«Ак бәхетләр телибез!» Әллә шул теләкнең чын төсе итеп, кунакларның күбесе гел ак чәчәкләр алып килгәннәр иде. Ә алар Ирекнең хәтерен мамык карларга күмелгән теге Яңа ел кичен сөйрәделәр. Ул кичнең карлары әллә кайчан эреп диңгезләргә җиткәндер, парга әйләнеп кабат кар булып яугандыр. Барлык әйберләргә дә вакыт тузаны сара, диләр. Вакыт дигән нәрсәнең дә карлары ява микән? Явадыр. Күктән төшеп җиргә яткан карлар, озын шифалы гөрләвекләр булып, җирне яшеллеккә күмә. Вакыт карлары эрегәндә исә, һәр әйберне сиздермичә генә ашыйдыр-ашыйдыр да мәңге-

леккә озатадыр... Бу җирдә Иреклрнең эзләре калырмы? Әллә вакыт аларны, эрегән карлары кебек, эзсез генә мәңгелеккә озатырмы?

— Исәнмесез, Ирек абый!

Ирек уйларыннан бүленде. Аңа пәһлеван гәүдәле, бит очлары янып торган яшь ир-егет һәм янәшәсендәге сылу хатыны кул суздлы. Ирек, аларның кем икәнен хәтеренә төшерә алмыйча, чал чәчләрен бармаклары белән аралады, гүя җавап шунда яшерелгән иде.

— Сез кем буласыз соң әле?

— Үрмештән Илһам Шаһзамановларның оныгы Тәфкил, — диде кунак, кара мыегы астыннан шикәрдәй ак тешләрен күрсәтеп. — Бабай белән әти сезгә күп итеп сәлам әйттеләр.

Менә бит, әнисе ягыннан якын туганнарын танымый да тора икән!

— Илһам абыйның быел да комбайнга утырганын газетадан укыдым. Сиксәнгә якынлаша түгелме соң инде?

— Ерак калмый, — диде Тәфкил, елмаеп. — Әле ул тегенди-мондый яшьләреңне орып бирә.

— Юбилеена безне чакырырга онытмагыз, һичшиксез барачакбыз, — диде Ирек.

Ул тагын бик күп туганнары белән күреште, хәлләрен сорашты. Әтисе ягыннан туган Нуриасма түтиләренең малае Мизхәт белән хатыны Зөбәрҗәтнең килүенә куанып бетә алмады, башка районда яшәсәләр дә, якын итүләре өчен кат-кат рәхмәт әйтте. Баян абзыйның Гөлчәчәген, Газдал белән Кәүкәбелҗәннәтнең Альфредларын, Зәйнуллин белән Нәкыяне (алар өйләнешергә йөри икән, дип пышылдады Зәнфирә), тагын бик күпләрне күрү Ирекне исертеп, әллә нинди дөньяларга, ерак үткәннәргә алып китте. Узган гомерләрнең, вакытның ерак офыкларына бәрелеп бүгенгедә яңгыраган кайтавазы шушы түгелмени? Кызык та, гыйбрәтле һәм мәгънәле дә! Язгы гөрләвекләр ындырлардан, таулардан шаулап Ыкка төшкән, аның бозларын күтәреп, суларын ярларыннан чыгарлык итеп куәтле бер ташкын хасил иткән кебек, аларның уртак бәйрәменә күпме якыннары җыелган! Бу бәхет түгелмени?! Уйлап карасаң, адәм баласының югалтулары никадәр күбрәк булса, ул тапканнарының аз гынасына да чиксез куана, шөкрана итә икән. Кеше югалтулар ачысын татымаса, бөтенесе дә җитеш, теләгәнчә булса, ул беркайчан да канәгатьләнми бугай... Әгәр теге Яңа ел кичендәге хыяллары өзелеп тә, кабат ялганып та, әллә никадәр

четерекле, җәрәхәтле еллар кичелмәсә, Ирек белән Зәнфирә бүгенге бу көннең ни дәрәҗәдә тантаналы, ни дәрәҗәдә кадерле икәнлеген аңларлар идемени?!

Шулчак ишектән әниләре килеп керде. Аны ике ягыннан Таһир белән Айгөл җитәкләгән иде. Нинди олпат аларның әниләре! Ул таң алсулыгын хәтерләтүче озын алсу күлмәк, аның өстеннән яшел бәрхет камзул кигән. Камзулының якалары, ялаулары, җиң-итәк очлары алтын җепләр белән каелган. Башындагы яшел калфагы көмештәй ялтыраучы эре сәйлән белән нәкышләнгән. Калфак өстеннән ябынган ак ефәк шәленең чуклары тез турына ук җитә язган. Тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы белән ул бөтенесенең уртак анасын хәтерләтә иде. Аны күргәч, барлык кунаклар, тылсымлы таяк хәрәкәтенә буйсынгандай, аягүрә бастылар һәм кул чабарга керештеләр. Акыллы иде аларның әниләре, зирәк иде! Һаваланып күкрәгән дә киермәде, түбән дә иелмәде. Йөзеп кенә баргандай, чәмчәле читекләре белән түргә таба атлады, кунакларны сизелер-сизелмәс кенә баш иеп тә, илаһи карашы белән дә сәламләде, ак шәле астыннан чулпыларының чылтыравы ишетелеп калды. Әниләре түргә узуга, барысы да дәррәү урыннарына утырыша башладылар. Мәлс белән Нәфисә, аларның Алмазы, Гөлназ, Ирекләр, Сөембикәләр әниләрен уратып алдылар. Ул һәркайсына тәмле сүзен тапты, изге теләкләрен теләде. Аннары: «Барыгыз инде, балалар, утырышыгыз», — диде дә Ирекне кулларыннан тотып туктатты. Менә әнисе учы белән аның беләкләрен сыпырырга кереште, үзе иреннәре белән генә пышылдап туктаусыз нәрсәләрдер укыды, Ирекнең кулларын кысыпкысып куйды. Әнисенең кул җылысы аның бөтен тәненә таралды. Бу җылы бала чактан ук таныш, искиткеч сагындырган иде. Ирекнең күзләренә яшь тулды. Ниһаять, әнисе аның кулларын җибәрде, әмма Ирек кузгалып китә алмады, нишләптер телсез-өнсез булып басып тора бирде. Ул әнисенең олпат гәүдәсенә, тантаналы йөзенә, каядыр бик тә, бик тә еракка төбәлгән кодрәтле күз карашына йотылып карады. Аның йөзендәге җыерчыклары, каш-керфекләренең, иреннәренең тибрәнеп-тибрәнеп куюы күңелендә ниндидер кайнар, гайре табигый хәрәкәт барганын сөйлиләр һәм әнисенең аны башкару өчен ифрат та зур көч салганлыгы сизелә иде. Ирек аның киң ак маңгаена вак кына тир бөртекләренең бәреп чыгуын да күрде хәтта. Әнисе аңа ым какты. Бу аның хәер-фатиха бирүе иде. Ирек күңеленә

моң, күзләренә яшь тулган хәлдә Зәнфирә янына барып утырды һәм тагын әнисенә борылып карады. Күз яшьләре аша ул бераз калтырабрак күренде, аннары тоташ түгәрәккә әверелде, чит-читләре көмеш белән өретелгән алсу-яшькелт кояш рәвешенә керде... Ирек шулчак бөтен тәнен кымырҗытучы бер җиңел, нәфис дулкынга эләккәнен тойды. Бөтен гәүдәсе эреп юкка чыккандай җиңеләйде, йөрәге дәртләнеп тибәргә кереште. Аңа әйтеп бетергесез рәхәт иде. Бу нинди тылсым? Ни булды? Ул үзенә ниндидер көч иңгәнлеген аңлады...

Ирекнең зиһене ачылып, яктырып китте. Бу яктыру әллә нинди серле, туктаусыз биеккә, югарыга күтәрелә баручы яктыру иде. «Рәхмәт!» диде ул эченнән генә. Ирек моны язмышка әйттеме, теге көчкәме, әллә башка берәүгәме — үзе дә анык кына белмәде. «Кичерегез, барысы өчен дә кичерегез!» — дип пышылдады. Теленә бу сүзләрнең нинди кодрәт белән килгәнен һәм аларның кемгә мөрәҗәгать ителгәнен Ирек шулай ук белмәде, күрәсең, моның әһәмияте дә юк иде. «Рәхмәт!» — Бусын янәшәсендәге Зәнфирәгә юллады. Аннары чак кына арырак утырган Сөембикәгә ялварып карады: «Кичер, кул күтәргәнем өчен кичер!» — диде ул эченнән генә. Аңа Сөембикәнең үзенә караганда бәхеткә хакы күбрәк тоелды, Ирек хәзер шулай теләде. Инде бөтенесе урыннарына утырганнар, менә-менә мәҗлес башланачак тантаналы мизгелләр иде бу. Ирек табындагыларны рәттән күзеннән үткәрде. Нинди сөйкемле, күркәм, мәртәбәле аның кунаклары! Алар Ирекләр хыялланган, өлешчә шуңа ирешеп тә ирешә алмаганнарын балалары тормышка ашырсын иде дигән изге ният белән уртак мөнбәр астына җыйналдылар. Ирек бу минутларда алар өчен үзен корбан итәргә әзер иде. Алай гына да түгел, җирдәге барлык кешеләр өчен гомерен бирергә әзер иде. Шушы олы теләген кычкырып әйтмәве, яшертен генә кичерүе аңа ниндидер бер рәхәтлек бирде. Ул бәхет шәүләсен аермачык сизде. Ул шәүлә Айгөл белән Таһирны кавыштырган илаһи көч тарафыннан Ирекнең дә күңеленә иңдерелә иде... Әлеге көч, соңарып булса да, Ирек белән Зәнфирәне дә актык сулышкача бергә кушкан иде. Ирекнең һәр көне Зәнфирә белән башлана, аның белән дәвам итә, аның белән төгәлләнә, яшәү уты аның газиз кулларында яна иде...

Кемдер аларның турына зәңгәр кыңгырау чәчкәләре китереп куйды. Алар чәчәкләргә сокланып карап тордылар

да, сүз берләшкәндәй ялт борылып, бер-берсенә төбәлделәр, озак итеп, бернинди сүзсез, күзләре белән генә сөйләштеләр. Дымланган керфекләр уртасында елтыраучы күзләрдән узган гомерләрнең, яшәлгән елларның дәверләр офыгына бәрелгән кайтавазы сирпелеп-сирпелеп түгелде... Ирек акрын гына әллә нинди кайнар эчке тавыш белән аның колагына пышылдады:

Соңардым, кирәкми, димә син,
Алар бит шыттылар җанымнан.
Сөюебез сагышы бөркелә
Яшьлекнең мизгеллек ярыннан...

Зәнфирә, нәрсәнедер хәтерләргә теләгәндәй, бер генә мизгелгә күзләрен йомып алды да йөзен Ireккә якын ук китерде һәм аның кып-кызыл матур иреннәре хәрәкәткә килеп, ягымлы тавышы яңгырады:

Китмә син! Соңгы кат кул сузам,
Өзмәче бәгырьне, кал, туктап!
Кал, зинһар! Кул җылың тоюга,
Яшь түгәр бу гөлләр шатлыктан...

Зәнфирәнең күзләре якты нурлы, гайре табигый елтыраучы рыйлар иде. Ирек бу күзләрдә үзенең шәүләсен күрде һәм ул тормышында Зәнфирәне очраттырган көчкә, аның белән бу дөньяда бик азга гына булса да бергәләп яшәве, менә хәзер янәшәсендә утыруы өчен рәхмәт укыды һәм үзен җир йөзендәге иң бәхетле кеше итеп тойды...

*Июль, 2005*

Литературно-художественное издание

***Садриев*** *Фоат Миннахметович*

**СЧАСТЬЕ НЕСЧАСТНЫХ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Садриев*** *Фоат Миннәхмәт улы*

**БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ**

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *З.З.Хәкимов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.05.2007. Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 20,58. Нәшер-хисап табагы 21,19 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ С-643.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420059. Казан, Оренбург тракты ур., 20 а.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.